# КАЗАН УТЛАРЫ

8. 1991



# КАЗАН УТЛАРЫ

АЙЛЫК ӘДӘБИ-НӘФИС ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ЖУРНАЛ

ОЕШТЫРУЧЫЛАРЫ:
ТАТАРСТАН
ССРның
ЯЗУЧЫЛАР
БЕРЛЕГЕ,
ГАЗЕТА-
ЖУРНАЛЛАР
НӘШРИЯТЫ,
РЕДАКЦИЯНЕҢ
ХЕЗМӘТ
КОЛЛЕКТИВЫ

1922 ЕЛНЫҢ
МАЙ АЕННАН
БАШЛАП ЧЫГА

**8**

**1991**

КАЗАН


## *Бу санда*


ЧӘЧМӘ ӘСӘРЛӘР

БАТУЛЛА. Сөембикә кыйссасы. *Роман* . . . . 3
Н. ФӘТТАХ. Кичү. *Роман* . . . . . . . . . 72

ШИГЪРИЯТ

М. ӘГЪЛӘМОВ. Кереш. *Шигырьләр* . . . . . 61
Э. ШӘРИФУЛЛИНА. Тәмуг кисәве. *Поэма-мәрсия* . . . . . . . . . . . . . . . . . 64
К. МОСТАФИН. Кем җаннары яши икән . . . 69

ӘДӘБИ МИРАС

Х. МИҢНЕГУЛОВ. Үткән гасырларның бүләге . 144
С. САРАИ. «Гөлстан бит-төрки» . . . . . . . 147

ӘДӘБИ ТӘНКЫЙТЬ

Әйдә халыкка хезмәткә! *(Язучы М. Мәһдиев белән әңгәмә)* . . . . . . . . . . . . . . 157
А. ГЫЙЛӘҖЕВ. Илче. *(И. Салаховка 80 яшь)* . 168

ТАТАР ХАЛКЫ: ТӨРЛЕ ТӨБӘКЛӘРДӘ, ТӨРЛЕ ИЛЛӘРДӘ

Д. ИСХАКОВ. Пермь татарлары . . . . . . . 171

Коръән сүрәләре . . . . . . . . . . . . . . 180

КИТАП КҮЗӘТҮ

З. ГОМӘРОВА. Иртәгә дә яшисе бар... . . . . 187

Иҗтимагый-мәдәни тормышыбыздан . . . . . . 188
Тышлыктагы сурәтләр . . . . . . . . . . . 190

*Баш мөхәррир*

РАВИЛ ФӘЙЗУЛЛИН

*Редколлегия*

ГАРИФ АХУНОВ
МАРСЕЛЬ ГАЛИЕВ
МИРКАСЫЙМ ГОСМАНОВ
АЯЗ ГЫЙЛӘЖЕВ
МАРСЕЛЬ ЗАРИПОВ
ФЛҮС ЛАТЫЙФИ
*(җаваплы сәркәтип)*
МӘДИНӘ МАЛИКОВА
САЛИХ МАННАПОВ
ФӘРВАЗ МИҢНУЛЛИН
ФЛҮН МУСИН
МАРАТ МӨЛЕКОВ
РИНАТ МӨХӘММӘДИЕВ
РАШАТ НИЗАМИЕВ
*(баш мөхәррир урынбасары)*
ГӘРӘЙ РӘХИМ
КОЯШ ТИМБИКОВА
*(бүлек мөхәррире)*
МӨДӘРРИС ӘГЪЛӘМОВ
ТӘҮФИКЪ ӘЙДИ
*(бүлек мөхәррире)*
АЗАТ ӘХМӘДУЛЛИН

Безнең адрес: 420066,
Казан, Декабристлар ур., 2.

Телефоннар:
баш мөхәррир — 53-07-60,
баш мөхәррир урынбасары — 53-07-09,
җаваплы сәркәтип — 53-36-12,

*бүлекләр:*

чәчмә әсәрләр, шигърият, очерк — 53-07-61,
тәнкыйть, фән, сәнгать, хатлар — 53-07-63,
корректорлар — 53-07-65.

## В НАШЕМ НОМЕРЕ:

«Проза и поэзия»: окончание романа Н. ФАТТАХА «Брод», начало романа Р. БАТУЛЛЫ «Сказание о Сююмбике»; стихи М. АГЛЯМОВА, К. МУСТАФИНА, поэма-элегия Э. ШАРИФУЛЛИНОЙ.
«Литературное наследие»: Памятник татарской литературы XIV века «Гулистан» СЕЙФА САРАИ. Вступительная статья Х. МИННЕГУЛОВА.
«Литературная критика»: «Служить своему народу» — беседа писателей М. Магдиева и Р. Низамиева; статья А. ГИЛЯЗОВА «Посол» посвящена 80-летию писателя И. Салахова.
«Татарский народ: в различных регионах страны и мира»: Д. ИСХАКОВ. «Пермские татары».
Суры из Корана.
«Библиография»: З. ГУМЕРОВА рецензирует новую книгу Р. Башарова.
Дневник общественно-культурной жизни.
На наших обложках: «Позолоченная майолика» — из археологических раскопок эпохи Казанского ханства; лауреат Государственной премии Республики Татарстан им. Г. Тукая поэт М. Шабаев.

*Бүлек мөхәррирләре:* Мансур Вәлиев, Рәдиф Гатауллин.
*Мөхәррирләр:* Нияз Акмалов, Шамил Маннапов, Рәшит Әхмәтҗанов.
*Хезмәткәрләр:* Л. Гатауллина, Г. Моратова, Ф. Сабирова, Т. Сибгатуллина, Г. Хөснетдинова.

Производствога бирелде 13.06.1991 ел. Басарга кул куелды 26.08.1991 ел. Офсет ысулы белән басыла. Кәгазь форматы 70×108 1/16. Учетн.-изд. табак 14,2. Басма табак 12(16,8).
Тираж 38449. Заказ И-274. Бәясе 1 сум 50 тиен.

Татарстан газета һәм журналлар нәшрияты басмаханәсе.
Казан, Декабристлар урамы, 2.

© «Казан утлары», 1991 ел.

**Батулла**

# СӨЕМБИКӘ КЫЙССАСЫ

## Игезәкләр

Сайгөле бикә бик озак тулгаклады; инде өмет өзгәндә, Хансарайның кендек әбисе әйтте:

— Кыл бияләй белән тартырга кала!— диде.

Баланы кыл бияләй кидергән кыскыч белән тартып алдылар.

— Угыл олан!— диде кендек әбисе.

Угыл оланның кендеген кисеп, ике аягыннан күтәреп, чәбәкләп карадылар. Бәбәй тавыш чыгармады.

— Һамамга йөгерегез! Бер ләгәнгә җылы, икенчесенә салкын су коегыз!— диде әби. Үзе, баланы чүпрәккә төреп, мунчага йөгерде; мунчада җансыз сабыйны әвали-әвали, чәбәкли-чәбәкли, бер — салкын суга, бер талык суга чумдыра-чумдыра уятырга тырышты. Булмады инде, туктатыйк бу эшне дигәндә генә, бала хәлсез генә аваз чыгарды. Угыл оланга җан иңде. Кендек әбисе аның терелгәненә куанмады кебек. Эчтән генә ул: «Аллаһ алса, хәерлерәк булыр, мантырга охшамаган»,— диде. Сабыйның озынча башын ике учы белән йомарлап, сак кына кыскалап алды. Баланың баш кимерчәге имгәнгәнен ул беркемгә дә белгермәде.

Ул арада эчкәридән бала елаган тавыш ишетелде. «Бәрәкәти-и, Иляһем,— дип уйлады кендек әбисе.— Игезәкләрме икәнни? Бирсен Ходай!»

Кыз олан, тууга ук, чырыйлап кычкыра башлады.

— Сайгөле солтан, кыз оланың да бар!— диделәр. Сайгөле башын калкытты:

— Углым кайда, углым нигә дәшми?

— Кызыңны күреп бак, озакламый углыңны да алып килерләр.

— Углымны терелтегез, углымны-ы терелтеге-ез!— дип ачынып кычкырды Сайгөле.

---

БАТУЛЛА (1938) — *әдип, драматург, Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе, Г. Исхакый исемендәге бүләк иясе, күп санлы драма әсәрләре һәм китаплар авторы. Казанда яши.*

* Әсәр кыскартып басыла. Аны журнал өчен Н. Акмал редакцияләде.

Кызны коендырып, җофар мае белән сыпырып-сылап биләүләделәр.

Сайгөле һаман:

— Углым кайда? Углымны китерегез!— дип елый иде.

Йосыф мирза йорты янына яшь мирзалар, яшь бикәчләр, балаоланнар җыелып, Сайгөле бикәнең баладан котылганын көтә. Үзләре һай-һулап кычкыра; кайсы, казанга арба кендеге белән сугып, чаң тавышы чыгара, кемдер чуен таба кага, бәрәбан дөмбердәтәләр; берәүләре ярык быргы акырта, кулында корал-фәлән булмаганнар муен тамырлары шартлардай итеп кычкыра:

— Албасты, юлбасты, якын килмәң, кит! Өйгә кермәң — кач! Һай-йа-һу, һай-йа-һу! Албасты, йортбасты, сабыйды шетләтеп оз!— диләр.

Таң атар-атмастан Карабистә күчәләрен кәрнай, дөм-дөмбак, давылбаз авазлары уятты.

— Йосыф мирзаның игезәкләре бар! Берсе угыл, берсе кыз бала!— дигән хәбәр һәр курага, һәр колакка үтеп керде.

Карабистә халкы сөенә, базар халкы сөенә, мирзалар бистәсе сөенә, Хансарай сөенә — бөтен ил сөенә. Муса түрә кырык көн туй ясарга әмер бирде.

— Нинди генә вакыйгалар булса да, туй азагынача дәвам итсен!— диде түрә.— Яу килсә, туйга алыгыз. Давыл чыкса, давылдан соң бәйрәм итегез! Туйны үлем-җитем булса да туктатмагыз!

Туй башлангач та, угылларын чакыртып, Муса түрә васыятьнамәсен игълан итте.

— Һәрберегез үзбаш,— диде ул.— Әмма сез — бер йорт. Афәт килгәндә бөтен бәкләр, мирзалар Сарайчыкта олуг бәк кем — шуңа баш ия! Бүген, миннән соң, Шәехмамай бәк әмир кала...

Сарайчык каласының һәр йортында, һәр күчәсендә сый, уен, дуен гөрли.

Йосыф мирза Карабистәнең Атакай дәрвишне сарайга китертте. Тантана ясап, дирбияләнгән яхшы бәйгер атның тезгенен Атакай дәрвишкә тоттырды. Бала туена җыелган мирзалар, чит ил кунаклары алдында әйтте:

— Юраганың юш килде, сиңа иң яхшы атым мал булсын!— диде.— Йола кушуынча, син, бу атка менеп, минем белән Айдаланы әйләнеп кайтырга тиешсең.

Бу хәтле дә олы бүләк, бу хәтле дә бөек хөрмәт берәүләрне аяктан егар иде, ә менә Атакай дәрвиш куанмады, әмма биргән бүләктән баш тартуны да кирәксенмәде. Тезгенне, салмак кына, үз кулына алды.

Сайгөленең бәбәйләвен зарыгып көткәннәр арасында иң алгысыганы Муса түрә иде. Игезәкләрне аның әмере илә эчкәригә алып керделәр. Ул, «Сөбханалла, бисмилласын» әйтеп, балаларны кулына алып бакты. Ир балага карап: «Сөен, олан, үскәч, Сөен бәк булырсың»,— диде; кыз балага карап: «Сөен, тутай, кияүгә чыккач, Сөембикә булырсың»,— дип дәште.

Сөен бәк белән Сөен тутайны даяга тапшырып, Муса түрә эчкәридә ялгыз калырга теләде. Йосыф мирза исә Атакай дәрвиш белән ияргә менде. Якыннары Йосыф мирзага — угланны, дәрвишкә кыз баланы бирде. Кәрнайлар, бәрәбаннар чалынды.

Атлар алга ыргылды. Нугай иле — Елкы илендә — яңа туган баланың авызына елкы мае сөртеп, ат менгезеп урам әйләндерү бишек туеның башы икәнен дә, җилкендерү өчен сабыйны атасына биреп, бер урам әйләнеп, Хансарайга кайтырга тиеш икәнен дә Атакай дәрвиш яхшы белә. Әмма, җилкендерү йоласында катнашканы булмагангамы, әллә кочагында аның кыз кардәше Сөенеч яткангамы, соклануын яшермичә, «сөбханалла», дип, куана, елмая иде.

Йолада катнашучы яшь мирзалар. Йосыф мирзаның якыннары, артта калды. Йосыф мирза атын бар көченә куалый. Дәрвиш тә аннан калышмый. Бераздан алар Карабистәдә, аннан Айдалада иде инде.

Биләү читен ачып, дәрвиш Сөенеч кызга карады.

— Сөбханалла, сөбханалла! Бул син язмыш бакчасында талмас былбыл!— диде ул.— Атаң-анаң тигез булсын. Яхшы ат юлдашың булсын!

Айдала буйлатып, дулый-дулый, рәхәтләнеп чаптылар. Аннан соң, атларны иркенгә куеп, ике җайдак тигезләнде; кайтыр юлга борылдылар. Атакай дәрвиш күз кырые белән генә Йосыф мирзага карады. Мирза бәхетле иде, сизелер-сизелмәс кенә елмая; авыз эченнән генә моңланамы, дога укыймы — нидер көйли. Айдала түрендә бихисап елкы, куй көтүләре салмак кына утлый. Ат аягы астында — кылганнар дулкыны. Йомшак, назлы дала җиле исә. Күк чите монарланып, кымырҗып тора. Һава тулы тургай тавышы.

Атакай дәрвиш янә сабый кызның йөзенә бакты. Кызчык еламый, атка менгезгәч, җилкендергән чакта имчәк баласы елаудан туктаса, яхшы фал. Димәк, аның гомере дәрәҗәдә, тәкъдир иярендә узачак. Ике бала да тыныч. Кыз баланың күзе ачык. Дәрвишнең исе китте. Сөенеч тутайның карашында мәгънә бар сыман тоелды аңа. Ул гаять җитди, күзләрен тутырып агасына карый. Сабый бөтенесен аңларга тырыша кебек. Саба җилне дә тоя, тургайларны да күрә, ишетә сыман. Биш тәүлеклек сабый ат өстендә, агасы кулында җилкенеп чапканын да аңлыйдыр шикелле.

— Таныйсыңмыни агаңны?— диде дәрвиш.

Сөенеч карашын күктәге тургайгамы, болыткамы күчерде, баланың күзендә тилгән сурәте пәйда булды. Дәрвиш тә тиз генә күккә карады. Аның йөрәге жуылдап алды. Күктә, биектә, Каракош оча иде. Канатларын җәйгән, һич талпынмыйча, күккә, далага, ике җайдакка, ерак елкыларга, куйларга, дөяләргә мин генә хуҗа дигәндәй, үз көченә инанып, Каракош сабыр гына оча.

Йосыф мирза һаман елмая. Ул бәхетле.

Дәрвиш Йосыф мирзадан:

— Биектәге козгын Каракошны күрәсеңме?— дип сорады.

Йосыф мирза югары бакты. Алай карады, болай карангалады да:

— Берни дә юк анда!— диде.

Каракошны Йосыф мирзаның күзе дә әлдерми икән. Ә козгын бар. Козгын һавада йөзә, күктә хуҗа. Озакламый, бик тиздән ул далага да, даладагы бөтен малга да тырнак батырыр кебек. Каракош ашыкмый, форсат көтә... Атасы күрми, яңа туган сабый кара козгынны күрә.

Муса казый балалары арасыннан иң мәшһүре, иң сабыры — Йосыф мирзадыр. Сеңлесе Сайгөлене Йосыф мирзага ярәшкәч, Мөхәммәдъяр бик куанган иде. Яхшы ир насыйп итте Сайгөлегә. Нугай далаларындагы муллык, Нугай йортының абруе һәркемгә мәгълүм: шул йортның атаклы мирзасы мәһабәт ир-егет Йосыфның хәләле булу — ханбикә булу белән бер. Әмма Нугай түрәсе Муса казый үзе дә, башка угыллары да дәүләт эшләрендә алдан күреп, һич югында биш-ун елга гына булса да киләчәккә карап эш йөртә белмәделәр. Үзара кырышып, дала-җәйләү бүлешеп, күршеләр белән барымта-карымта уйнап, кечкенә бер җиңүне дә бөек галәбәгә санап, чит ил сәүдәгәрләре, илчеләренең юк-бар бүләгенә алданып, сөенеп яшәделәр. Нугайларның иң олы түрәсе дә Мәскәүнең гап-гади сәүдәгәре, җәбәхәер генә монахы хәтле дә алга карап эш кыла алмады. Бүген, бүген булмаса — иртәгә Нугай тәхете бушаячак. Муса казый әҗәл шаукымы белән генә аякланды. Монысы

хак. Кем тәхет варисы? Шыгаймы? Итәк мирзамы? Шәехмамаймы? Өлкән угыл калыр, әмма яшь агыннан өлкән угыл, сай зиһенле булса, илне кая алып китәр? Нугай йортының төзек-төзек түгеллегенә Казан йортының язмышы да ай-һай, нык бәйле. Тәхеттә кем булса да, аңа акыл бирердәй яхшы киңәшче кирәк. Әлбәттә, Йосыф мирза бу эшкә кулайларның кулае да бит, югыйсә...

Шулай уйлады дәрвиш. Атлар салмак адымга күчкәч, әйтте:

— Әссәләмегаләйкем вә рәхмәтуллаһе вә бәрәкәтүһ! Исән-аманмысың, Йосыф мирза кияү!

Күзгә күз текәлде. Дәрвиш аңлады, бу беркатлы кияү моңарчы аны танымаган. Йосыф мирзаның гаҗәпләнеп ачылган күзләрендәге сөальгә җавап булырак ул:

— Дөрес,— диде.— Дөрес, Йосыф кияү, бу — мин.

— Мөхәммәдъяр кайнагам?— диде мирза. Бу аның гаҗәпләнүе дә, соравы да, җавабы да иде.— Кайнагам!.. Охшаттым, биңзәттем... Сунардан кайтканда ук охшаткан идем. Кара, дидем, бу суфый минем кайнагам Мөхәммәдъярга биңзәр, дидем... Алышынгансың, кайнагам. Затлы бәк киемнәрен ташлаганыңны ишетә беләбез...

— Ташлатканнарын беләсез,— дип өстәде Мөхәммәдъяр.

— Ие, кыен булгандыр... Болай, дәрвиш ямаучалары киеп, сукбайлыкта йөридер, дип башыма да китермәдем.— Йосыф мирза елмайды.— «Мең дә бер кичә» дәге Мәгъриб шымчысына биңзәгәнсең.

Йосыф мирза, әлбәттә, бу сүзләрен шаярып әйтте, әмма Мөхәммәдъяр елмаймады. Ул тирән сулыш алды: дөресрәге, бу — көрсенү иде. Авыр бер кайгыданмы, үз язмышының шулай алмашынучан булганыннанмы, Мөхәммәдъяр үпкәләренә кергән дала җиле өтеп алырдай кайнарланып чыкты:

— Мирза кияү,— диде ул.— Мин, чыннан да, шымчы бит.

Йосыф мирза ялт итеп Мөхәммәдъярга бакты. Атакай дәрвиш кыяфәтендәге кайнагасы шаяртмыймы икән, дип, сынап карады ул. Юк, Мөхәммәдъяр чыраенда уен чаткылары күренмәде.

Кайнагасы янә әйтте:

— Казан сараеның шагыйре, хаҗи углы хаҗи Мөхәммәдъяр, иңенә суфи чикмәне бөркәнеп, җәяүләп ил гизәргә мәҗбүр икән, монда шаккатырга урын бардыр, ихтимал... Нугай йорты тулы, Сарайчык базарлары тулы кяфер шымчылары йөргәндә кайнагаң исем яшереп юл чыккан икән, ни гаҗәп?

— Нинди шымчы? Кайда шымчы?— диде мирза.

— Мөселман чапаны ябынып, Исмәгыйль мирзаны кунакка чакырып, юк-бар уенчык, утчагар-мылтык белән алдап, хәмер эчертеп, сәрхүш ясап сыйлаган Филапи карабаш булыр.

— Балаби дәрвишнеме әйтәмсең, кайнагам?— диде мирза һәм, җавап та көтеп тормаенча, көлеп куйды: — Йа-а, Тәңрем, шул бичара суфимы шымчы?

— Күрсәтер әле ул үзенең бичаралыгын! Үзебез бичара булып калмагаек!— диде Мөхәммәдъяр.

— Йә, кайнагам,— диде мирза.— Балаби суфи Филапи кафер булсын да ди, нишли ала ул монда, Нугай йортында?

Мөхәммәдъяр бичарадай коелып төште. Әчтән генә: «Беркатлы сабый син, Йосыф мирза кияү»,— дип, тагын көрсенде. Сүзне ерактанрак башларга кирәк иде.

— Мирза,— диде Мөхәммәдъяр,— син Мөхәммәт Әмин ханның үлем түшәгендә ятканын беләсеңме?

— Казаннан чапкын килде. Хода кушса, савыгыр, иншалла!

— Хан үлем түшәгендә, мирза. Ханны агуладылар.

— Ярлыкта андый сүз юк.

— Бел, кияү. Мөхәммәт Әмин ханны агуладылар. Бу турыда агулаучылар белә дә, мин генә беләм.

— Үз хастасыдыр, кайнагам. Аны кем агуласын?

— Кырык сигез яшь яшьмени ул ир кешегә? Тап-тазадыр. Баһадир иде. Хәзер — хаста. Эт кебек улап ята. Урыныннан тора алмаячак. Кем эше? Шымчылар эше. Безнең ханнарны йә агасы үтерә, йә баласы агулый, йә чит ил шымчылары багышлый. Үз үлеме белән үлгән хан тарихта юк. Далагыз киң шул сезнең, нугайлар-кардәшләр, җил-болыт кебек күчеп йөрисез, таш калалар салырга вакытыгыз да, теләгегез дә юктыр. Төптәнрәк уйларга теләмисез. Җилләр үтәр, сүзләр бетәр, күп халыклар комга судай сеңәр, таш шәһәрләр мәңге калыр, таш шәһәре булган халык бетмәс.

— Ташкалалар салдырып Айдаланы бозаргамы, кайнагай?— диде мирза.— Юк инде, монысы булмас, даладагы елкылар, елкычылар шәһәрдә яши алмас!

— Чик буйларында кирәк ул таш кальгалар, кияү. Кереп качар өчен, икмәк тотар өчен кирәк алар. Яу чабар өчен түгел, илне тотар өчен кирәк. Һәр бакчаның булыр багучысы, багучының булыр өе-тирмәсе. Җанымның бер өлеше, бәгыремнең бер кисәге — Нугаем иле! Җилдән җитез атлар белән генә даланны дошманнардан саклап булмый. Утчагарлар, туплар, тимер мылтыклар кирәк? Айдала мирзаларының максаты — күрше туганының малын куып, барымта ясау.

— Уйлап бак,— диде Мөхәммәдъяр бераз дәшми баргач.— Ниләр кылына якын илләрдә, ерак илләрдә? Казан ханы — кабер якасында. Казанның икенче ханы Мәскәү зинданында чери. Бармы башка бер ил, бүтән бер падишаһ, кайсыдыр ки күрше ил падишасын төрмәдә черетә? Бармы? Синең атаң Муса казый ябып тотамы берәр ханны, берәр патшаны? Солтаннармы җиңелгән патшаларны зинданнарга яба?

— Бөек кенәз Уасили Габдел Латыйф ханны азат иткән!— диде мирза.

— Иткән!— диде Мөхәммәдъяр.— Азат иткән. Ни өчен ул Габдел Латыйф ханны Кырымга да, Казанга да җибәрми?

— Патша аңа Кашира каласын бөтен кереме белән биргән...

Мөхәммәдъяр көрсенде:

— Курчак белән уйнагандай уйный Уасили патша безнең ханнар белән!

Йосыф мирза җавап кайтармады. Мөхәммәдъяр да тынып калды. Ләкин аның әйтәсе сүзе әле бетмәгән иде. Ул эчтән көйде.

Касыйм ханы Шәех Әүлияр мәрхүм булды бу ел. Тәхеттә — аның углы Шаһ Гали. Шаһ Гали Мәскәү сүзеннән беркайчан да чыкмаячак. Казанның борын төбендәге бу хан Казанга мәңге дошман булачак. Мәскәүнең тырнагы еракка төбәлгән, ай-һай, ерракка сузылган аның кулы. Мәскәү — Кырым юлына Тула ташкирмәнен ныгытып маташа. Тула шәһәрендә туп, мылтык ясаучылар кайнаша. Йөзәр тимерче берьюлы туп ясый, ядрә коя. Чик буендагы калаларны таш диварлар белән әйләндерәләр. Чиркәүләр салалар. Һәр чиркәү амбарларында елларга җитәрлек ризык туплана. Поплары, карабаш монахлары чиркәүләргә күпләп-күпләп икмәк җыя. Су өстен тутырып сугыш көймәләре ясый урыс. Дөньяга чәчелеп, суфи-дәрвиш кыяфәтенә кереп, карабашлары-каратуннары күзәтә, эчкә керә, серләр ала, мәгълүмат туплый. Ай-һай, еракка, тирәнгә суза кулын Мәскәү. Даланы да кулга алса, бетте Казан, китте Нугай, китте Хаҗитархан...

Сабыйлар кыбырсый башлагач, алар ыргып чаба башлады. Йола буенча алар, атларны куалап, күбеккә батырып кайтырга тиешләр иде.

— Һәй-дә-ә!— дип җилкендереп кычкырды Йосыф мирза.— Оч, Турыкай!

Күптәннән узышасы килгән айгырлар кала ягына томырылды. Карабистә халкы аларны каршы алырга чыккан:

— Мең яшә, углан, мең яшә!— дип кычкыралар.

Ләкин Мөхәммәдъяр шушы алкышларда бер тынлыгу, теләртеләмәслек сыман бер нәрсә сизде. Карабисталеләр артык күп түгел, анда-санда кулларына песи тотканнар. Аргы якта, Карабистә белән дала тоташкан кырда, берничә кеше җан-фәрманга мәче куып йөри, олы-олы ир-атлар, малай-угланнар мәчеләргә зур ау оештырган. Мәет аша мәче сикереп чыкса, ләхеткә иңдергән төнне үк мәрхүмнең җаны әрвах булып өйгә кайта икән. Имеш, шул әрвах туганнарына гел йокы бирмәячәк икән. Шуңа күрә бу якларда, кеше үлгәч, бөтен мәче халкын мәет җирләгәнче бикләп тоталар. Мөхәммәдъяр аңлады: калада мәет бар, кемдер үлгән. Нугай түрәсе Мусадыр мөгаен. Әмма ул Йосыф мирзага бу турыда берни дә әйтмәде. Хансарайга җиткәч, алар кулыннан балаларны даялар алды. Йосыф мирза иярдән сикереп төшүгә, Шаехмамай килеп:

— Атакай...— диде.

Башка сүз кирәкми иде. Хансарай капкасы алдында да, сарай эчендә дә кинәт бузлаучылар җылый башлады. Берничә җегет гадәттәгечә сул яктан түгел, уң өзәңгегә басып, чаптарларына атланды. Атлылар төрлесе төрле урам буйлап чабып киттеләр. Алар, бераз баргач, атларын тыя төшеп:

— Ваккас углы Муса казый җәнаблары фанидән китте-е...— дип еламсырап кычкыра башладылар.

Бузлаучы хатыннар тавышы ишетелә:

— Һай, бавырым, йөрәгем!.. Ногай илнең тоткасы-гу... Идегәйнең нәселе, гуу... Кылыч тотса, кырган-гу-у... Җәя тотса, сырган, гу-у.. Ялан тотса — өзгән, гу-у... Уәккас баба баласы, илне тоткан атасы Муса пигамбәрдин ат алган, дала иңләп мал талган, Урда буйлый дан тоткан Муса түрә, ник кичтең! Ник кичтең?..

— Урда буйлый дан тоткан Муса түрә-ә...

Мәрхүмнең васыятен тоттылар. Аның җеназасында ясин чыгучы Атакай дәрвиш-Мөхәммәдъяр булды.

Муса казыйны җирләгәч, Сарайчык бушап калды. Илче-килчеләр дә, туган-тумача да, кунак-күршеләр дә таралышты.

Дөнья бераз тынычлангач, Йосыф мирзага ияреп, Мөхәммәдъяр Сайгөле бикә янына керде. Тамак кырып алгач, Йосыф мирза сүз башлады:

— Атакай җеназасында коръән чыкканда, бигрәк моңлы бу дәрвишнең мәкаме, дигән идең, менә дәрвишнең үзен алып килдем.

Сайгөле бикә аптырап калды. Хатыннар ягына бер генә ирнең дә кергәне юк. Хәтта Йосыф мирзаның да башка бер ир ияртеп бирегә иңгәне булмады. Бу гайре табигый хәлне Сайгөле бикә аңлый алмады.

— Яхшылабрак кара!— диде Йосыф мирза.

— Исән-амансыңмы, сеңлем,— диде Мөхәммәдъяр.

— Әстәгыйфируллаһ, йа Аллам, йа Ходам!— диде Сайгөле бикә.— Абыкаем ла!

Бертуган абыйсын күрүгә артык куанмады, кайчандыр бәкләр, шаһзадәләрдәй затлы кием киеп, мәгърур-төз атлап йөргән остаз Мөхәммәдъярның тупас йон белән каты киндер алача җеп катыштырып суккан ямаулы җөббә кигән суфи-дәрвишкә әверелгәненә ачындымы Сайгөле бикә, кинәт сулкылдап, абыйсы күкрәгенә йөзен яшерде, сүз әйтә алмыйча:

— Абыкаем ла,— дип кабатлый иде ул.

Беркемне чакырмаенча, алар өчәү генә озак утырдылар. Чәй-

кымыздан соң, игезәкләрне китереп, янәшә салдылар. Сабыйлар өстендә хаҗи углы хаҗи Мөхәммәдъяр остаз коръән чыкты. Коръән укыганда да, соңра балаларны берәм-берәм сөйгәндә дә Мөхәммәдъяр шуңа игътибар итте: Айдалада җилкендереп йөргәндә дә чамалаган иде — Сөен бәк еламый да, ашарга да эзләнми, тик ята; зәгыйфь кенә ыңгырашып йоклый; Сөенеч кыз тупырдап тора, елый, боргалана, эзләнә, чәбәләнә.

— Аллаһ хәерле кылсын.— диде Мөхәммәдъяр.

Ата белән ана Мөхәммәдъярның тел төбен аңламады, ә остаз белә иде: Сөен бәк гариплеккә дучар.

Сайгөленең сабый чаклары, Казан елгасында су коенулары, батып үлә язганда аны абыйсы Мөхәммәдъяр коткарганы, Ханбольндагы сабан туйларын — барысын да бәйнә-бәйнә, кайта-кайта искә төшереп, рәхәтләнеп сөйләштеләр...

Мөхәммәдъяр белән Кошчак олан Карабистә очындагы алачыкта төн уздырдылар.

Мөхәммәдъяр Хаҗитарханга баручы кәрваннарның берсенә ялгызы гына тагылып китәргә тиеш иде. Колынтай аннан калырга теләмәде. Дөресе шул, Мөхәммәдъярның да аны монда калдырырга теләге юк иде. Дилазар мирза талаган мөлкәтен Колынтай кире сорамады, ике яхшы тай, атасының алтын-көмешле ике дирбиясен алды. Куй, елкы, дөя көтүләре өчен бераз акчалата алып, Атакай дәрвиш — качырга, Кошчак олан Йосыф мирзаның сөенчегә биргән атына менеп, Хаҗитарханга юл алды.

Куш атлар да, җайдак үзе дә, терек-терек атлап баручы качырга атланган Мөхәммәдъяр да офыкка кереп, күренмәс булды. Алар киткән яктан ишетелгән сорнай авазы «Янмас кыз» көен яңгырата иде. Бәлки ул көй Сайгөле бикә колагында калып шулай озак ишетелә торгандыр, аның күңелендә яңгырыйдыр? Ханым бикә кызчыгы Сөенечне сак кына өскә күтәрде. Көйне тыңла, кызым, агаңны күреп кал, дигән сүзе булгандыр, әллә Кояшка күрсәтергә теләдеме ул кызның йөзен? Әллә Айдала эченнән килгән җылы-йомшак җилгә баласын иркәләтәсе килдеме? Сабый, уянып, күзен ачты. Дала ягыннан искән җил алып килгән үзәк өзгеч сорнай моңын Сөенеч кызчык та тыңлыйдыр сыман тоелды Сайгөле бикәгә. Яңа туган сабый күрәме икән соң, ишетәме икән соң? Ихтимал, бәлки чыннан да Сөенеч кыз «Янмас кыз» көен тыңлыйдыр. Бәлки, аның нәни зиһененә, саф күңеленә менә шушы көй, әче тәкъдир көе язылып бара торгандар! Ихтимал!

Бу вакыйга һиҗрәтдин соң туккыз йөз дә еккерме икенче сәнәдә, Күсе Елы (1516) тарихында булды.

## Ятимә

Игезәкләр тапканнан соң, Сайгөле бикә тернәкләнә алмады, еллар буе мантыр-мантымас йөрде дә, үлем түшәгенә ятты. Үз хәлен үзе белгәндер инде, өзелер-өзелмәстә балаларын чакыртып алды. Эчкәридәге, ягъни бикә бүлмәсендәге хатыннар, хаста янында ике сабыйны калдырып, алгы якка чыкты: әҗәле килеп җиткәнче сабыйларына гына әйтәсе сүзе бардыр бикәнең, дип уйлаганнардыр инде. Әмма Сайгөле бикәнең бернинди дә яшерен васыяте юк иде. Итагать саклаучы хатыннарга ул:

— Китмәгез, калыгыз! — димәкче булды... хәле җитмәде, бу сүзләрне әйтсә, балаларына багышласы әманәтын әйтергә көче калмасын сизеп, дәшмәде.

Ана балаларына елмаерга тырышты, кече кызы Сөенеч әнисенең йөзендә интегү галәмәтләрен генә күрде. Сөен бәк, бичара, ни-нәрсә

булганын аңламый: ул, аяк астындагы келәмгә утырган да, чулак кулының ике бармагын имә.

— Сөенечем, кызым, — диде ана. — Сөен бәк карындашыңны ташлама... Шәһәри Казанга...

Бу Сайгөле бикәнең соңгы сүзе булды. Шуның белән ул өзелде.

Казан каласыннан Нугай иленә килен булып төшкән Мәхмүт хаҗи кызы, Йосыф мирзаның иң сөекле хатыны Сайгөле бикә игезәкләре Сөен бәк олан белән Сөенеч тутайны калдырып, фани дөньядан мәңгелек йортка күчте. Анакайлары вафат булганда игезәкләргә җиде яшь иде.

Сөен тутай анакаеның соңгы сулышы белән әйткән шул ике сүзен гомере буе онытмады.

Чыны шул. Атасыз ятим — ярты ятим, анасыз ятим — кара ятим; анадан калган, гәүдәсе гарип, акылы зәгыйфь бала — кара ятимнәрдән дә ятим. Аталары Йосыф мирза йә ауда, йә яуда дигәндәй, гел өйдә тормый. Аннан соң ханнар, әмирләр, мирзаларның өйдә чакта да тез башына бала утыртып сөйгәннәре бик сирәк. Ир олан булса — ул тәрбияче аталык кулында, кыз олан булса, тәрбияче остазбикә карамагында яши.

Анадан туганда имгәнгән Сөен бәк сабыйны башта бик нык тәрбиядә тоттылар. Табиплар, өшкерүчеләр, зәм-зәм сулары — берсе дә ярдәм итмәде. Кендек анасы үзе вафат булыр алдыннан әйткән, имеш: йөрмәгез, аңар һични ярдәм итә алмый, туганда ук Сөен бәк оланның башына кан сауган иде, дигән.

Җиде яшькә җитеп, сабыйның теле ачылмады, уң аягы, уң кулы зәгыйфь булып, тәпи йөрергә дә өйрәнмичә, утырган килеш, шуышып кына урын күчә ала иде.

Анасы Сөен бәкне имезгәндә Сөен тутай озаклап карап торыр иде. Сөенеч кыз үзе күкрәктән тиз аерылды. Бәбиен имезгәндә анасы гел елый, елап туктагач, тулгап-көйләп сөйләнә башлый.

— Сөенечем минем, көенечем минем... Сөен бәгем минем... Савыгырсың, углым, тазарырсың, колыным. Шәһәри Казаннарда бәк булырсың, күз нурым...

Үзе Казан кызы булгангадыр, ахрысы, «Шәһәри Казан, Казан каласы таш кала, безем ханлыгымызда» кебек сүзләр Сайгөле бикәнең теленнән төшмәс иде.

Сөен тутай Казан турындагы һәр сүзне, һәр хикәяне йотлыгып тыңлый, хәтеренә сеңдерә барды.

— Һе-ей, Сөен бик тутай, ни сәбәпле сән каурый белән язарсән? — диләр иде ахирәтләре. — Каршыңда — камыш каләм, атаң Йосыф мирза сәңа сүәк каләм дә апкайтты.

Сөен тутай җавап бирми. Дөрес, камыш каләм белән язуы рәхәт, тик язганда камыш каләмнең сызгырганын, шыгырдаганын сөйми ул — тешкә тия, теңкәгә тия. Сөяк каләм белән язарга хыялланучылар да күп, әмма андый каләм төртелеп җанга тия.

— Иң уңае каурый каләм, — ди Сөен тутай.

— Хикмәте сызгыруда да, төртелүдә дә түгел, — ди ахирәтләре. — Каурый каләмнәр Казан йортыннан килгәнгә... Сөен тутабызның анакае Сайгөле бикә дә каз каурыеннан ясалган каләмнән башка бер төрлесе белән дә язмады...

Чыны шул, каз канатларын, каурый каләмнәрне Сайгөле бикәгә Казаннан абзасы Мөхәммәдъяр остаз җибәреп торды. Хәзер дә Казан ягыннан килгән һәр кәрванчы Сарайчыкта бер бәйләм каләм калдырып китә. Сайгөле бикә вафатына ничә ел узды, Мөхәммәдъяр остаз һаман шул гадәтен тота. Сеңлесенең кызы Сөен тутайга каурый каләм, каз канаты кирәклеген ул бик яхшы белә. Каз канаты белән идән-палас себереп була; кием-салымга кунган тузанны да каз канаты белән сафландыралар. Ә менә Сөен тутай каз канаты белән

йөзен, тәнен сыпырырга ярата. Бу гамәлне ул бары тик япа-ялгыз калганда гына эшли. Канат ялангач тәнгә, йөзгә, керфекләргә, ирен-нәргә тияр-тимәс кенә, йошмак-назлы итеп кагылып уза. Иренгә тигәндә бигрәк тә сәер була. Канатның йомшак йоны иренне генә түгел, бөтен гәүдәне кытыклый сыман.

Казан ягыннан — Казиленнән килгән каурый-канаты белән эчкәридәге келәмнәрне сыпырганда Сөен тутайның анасы бик моңлы итеп җырлый иде:

Каз канатлары ак була,
Ир канаты ат була...

Сөен тутай мәет өстендә бузлаучылар елаганга да түзде, анасының җеназасын кабергә иңдереп, балчыктан тау хасил булгач та еламады... Хәер, еласа да аның күз яшьләрен һичкем күрмәс иде: ул, карга каурыедай чем-кара толымнарын таратып, йөзен, бөтен гәүдәсен каплаган да, бераз бөкрәя төшеп, хәрәкәтсез басып тора. Сарай агалары да, кабер казучылар да, бузлаучы хатыннар да таралды.

Иң сөекле, иң яшь хатынын җирләгән көнне Йосыф мирза Хансарайга кайтмады, хәсрәтен юаргадыр, ахрысы, ерак җәйләүгә, кымыз йортына китеп барды... Каберстанда Сөен тутай ялгызы гына калырга теләде, аның елыйсы килә иде. Елыйсы бик килсә дә, бугазына әче төер булып утырган күз яшьләрен кире йотты ул. Кабер янында тутай белән ахирәт кызлар гына торып калды. Алар да тирән кайгыда. Кеше тавышлары тынгач, зиратта шомлы-серле мохит урнашкач, ахирәтләр Сөен тутайны уратып, чәчләрен тузгытып, илаулап-илаулап бузлау җыруын башладылар. Сөен тутай аскы иренен кан чыкканчы тешләде. Ләкин кайгы мохите аның ихтыярыннан көчлерәк булып чыкты. Бузлаучы кызлар мәрхүмәнең чибәрлеген мактап алкыш-җыру җырлады. Аның уңганлыгын, борынгы затлы нәселдән, Болгарның атаклы әмире Габдулла хәзрәттән килгәнлеген дә бәян иттеләр. Йосыф мирзаның иң сөекле хатыны Сайгөле бикә булганлыгын да бузлауга салдылар. Бузлауның икенче өлеше Сөен углан белән Сөен тутайның ятим калганлыклары турында иде. Зәгыйфь олан белән җиде яшәр кыз баланың кыйсмәте — тәкъдиренә күчеп, ахирәт кызлар бузлауның иң куәтле түбәсенә җиттеләр: сүзләре дә, моңнары да, чын күз яшьләре белән үксеп елаулары да, кызлар үзләре дә, зират та олы кайгыга күмелгән иде. Сөен тутай түзеп тора алмады, ике күзеннән кайнар яшь, күкрәк эченнән хәсрәт өне бәреп чыкты. Тутайның елавы бузлаучыларга яңа көч өстәде бугай: алар, берсеннән-берсе уздырып, монда, кабер янында, әле яңа гына уйлап чыгарган кайгы сүзләрен үзәк өзгеч моңга салып илаулый башладылар. Ихтыяр көче белән озак тыелып торган кайгы мәкаме кабер ташларына бәрелеп озак йөрде... Чәч-башларын тузгытып, ярсуның хәтәр җирендә йөзне тырнап, чәч йолкып бузлаганнан соң, Сөен тутай да, кызлар да бушанып, хәлсезләнеп, кичке эңгер төшкәч, күләгәдәй тын гына атлап, каберстаннан чыкты...

Анасы Сайгөле бикәне гүргә иңдереп кайткан кичне Сөен олан төнката елады. Алганны да салганны да белмичә, үксеп-ярсып бетте, бичара. Ими аналары, даялар, сарайдагы барча хаста багучылар җыелып, сабыйны юатырга тырышты. Ләкин ярсып беткән оланны һичкем туктата алмады. Төн узып, таңнар аткач та бала йокламады. Еларга хәле калмаса да, авыру мәче баласыдай, көчкә-көчкә мияулап, хырылдаган тавыш чыгарып ятты.

— Инде үлә, мирзага хәбәр салырга кирәк! — диде хатыннар.

Җәйләүгә, кымыз йортына чапкын күндерделәр. Ләкин Йосыф мирза, кымызны ташлап, үлем түшәгендәге төпчек олан белән бәхилләшергә кайтмады...

Сөен тутай да ул төнне, күзе йомык ятса да, йокыга китә алмады. Бала багучылар тыз да быз кереп-чыгып йөргәндә: «Инде үлә... Ул

мескеннең үлгәне хәерлерәк», — дип үзара сөйләнгәннәрен ишеткәч, сикереп торды да карындашы бүлмәсенә йөгерде.

Багучылар инде баланы юатырга тырышмый, аңа уенчык та шалтыратмыйлар, хаста багучы хатын сабыйның ирennәренә каз канаты белән әз-әзләп су тигезеп утыра. Калганнары, бик алҗыган суратттә, кулларын тезләренә салындырып, ял итә. Инде ясинчыга да кеше җибәргәннәр бугай... Сөен тутай карындашы Сөен оланга сәерсенеп карап торды-торды да, кинәт атылып, әчкәридән чыкты. Ишегалды буйлап ул атлар аранына таба йөгерде. Атбагарлар иртүк торган, аран тирәсендә мәш киләләр. Алар арасында араннар хуҗасы Комбар ата йөри. Ул кемнедер шелтәли, кайсыларына йомыш куша.

— Комбар ата, Комбар ата! — диде Сөен тутай. — Миңа Колынъялны иярлә!

— Ай-баяу! — диде Комбар ата. — Таңнан кая йөрерсәң, Сөенеч тутай, ә?

Сөен тутай, аңа җавап кайтармастан, кирегә борылып, әчкәригә таба томырылды.

Тутайның үз җаны кебек кадерле өч аты бар. Шуларның иң җитезе — Колынъял. Узышасы булса, Сөен тутай гел Колынъялны иярләтә.

Таң атар-атмаста нинди узыш булсын?.. Сөен тутайның ахирәтләре түгел, Карабистәдәге кызлар да уянмаган. Нәрсә булды бу кызга? Анасы үлгәнгә җанын кая куярга белмидер... Шуларны уйлый-уйлый, сөйләнә-сөйләнә, Комбар ата бер урында тик тора алмый торган Колынъялның сыртына ияр салды. Коешкан каешын ат койрыгы астына кертеп, түшлекне бәйләп бетергәндә әчкәридән Сөен тутай чыкты. Ул, хаста багучы хатыннарның ай-ваена карамастан, карындашын күтәреп, Колынъялы янына килде. Хаста оланны Комбар атага биреп, үзе җәт кенә атка атланды да:

— Монда бирең, Комбар ата! — дип ике кулын сузды.

Комбар ата оланны Сөен тутай алдына урнаштырды. Тутай, аякларын өзәңгегә басып, тезгенне тотты; «Чу!» — дип чөңгергәнче үк, әче кешнәп, арт тояклары белән ком-таш аттырып, Колынъял капкага таба ыргылды. Армай торучы сакчы егет капканы чак ачып өлгерде.

Тояк тавышын ишетеп, артка борылып, янга тайпылып юл салган җәяүлеләрне Сөен тутай, сызгырып, һай-һулап кисәтеп бара. Мирза кызы Колынъялына атланып күчәгә чыкса, бөтен җан иясе диварларга сеңеп кала иде.

Карабистәне узып, айдалага чыккач, Сөен тутай тезгенне тагын да бушатты: бәйгерне үз иркенә куйды. Яшь айгырга шул гына кирәк иде, ике сабый бер үсмер егеткә дә тормый — җиңел, рәхәтләнеп чап та чап, дала киң... Сөен тутай карындашын бер кулы белән генә тотып бара иде, тезгенне ташлагач, ул оланны ике куллап кочаклады. Мәхлүк сабыйның сау кулын ияр җәясенә куйды:

— Тотын, Сөен бәк, нык ябыш! — диде.

Олан җәягә чытырдап тотынды. Нәрсә булгандыр сабыйга, ул атка менгәннән бирле еламый, сулкылдап ыңгырашмый, әллә биеклектән, әллә ыргып чапканнан куркып, тын калган, бәлки сарайдагы тынчу һавадан арынганга, кинәт салкынча таң һавасына, далага чыкканга шулай үзгәргәндер. Дала түреннән печән исе, чәчәк исе, кизәк исе, төтен исе килә. Ихтимал, бу исләрнең барысы да сырхауга дәва булгандыр... Байтак баргач, атын тыя төшеп, Сөен тутай, як-якка карады. Балага су кирәк иде... Җәйләү юлы өстендәге коега җиткәч, ул карындашын иярдән төшерде. Хаста сабыйның сусавы хәттин ашкан иде: ул, йотлыгып-йотлыгып, тыны капланганчы су эчте. Тутай, оланның битен-кулын салкын су белән юды да, тезгенен бәйләп, атны далага җибәрде. Үзе карындашы янында калды. Сөен бәккә

җан керде. Бичара хәлсез сабый иркенгә чыккан атны күзәтә, зәгыйфь кулына кунган кигәвен-чебеннәрне аулап-куалый. Сөенеч тутай, дала чәчәкләре җыеп, такыя үрергә утырды. Олан аның такыя үргәнен карап утыра, үзе чулак кулының ике бармагын суыра. Болай да зәгыйфь бармаклар, еллар буена суыра-суыра, тагын да агарып, нечкәреп, җыерчыкланып калган.

Суырсын әйдә, үзәкләргә үтеп еламасын гына... Читтән күзәткән кеше кое янында апалы-энеле туганнар утыра, дип уйлар иде, мөгаен. Чирле Сөен бәк, юантык булса да, гәүдәгә кыска. Сөен тутай нәзек-зифа, хаста кардәшеннән буйлырак. Тутай әзер такыясын олан башына кигездә. Сырхау мәхлүк чыраенда елмаюга охшаш бер хәрәкәт булып алды. «Инде үлә» дигән карындашының шомлы елавыннан туктавы, елмаерга тырышуы кызга тәэсир итте: ул, туганын ярсып кочты да, үксеп еларга тотынды. Анасыз ятим калу хәсрәте идеме бу, әллә хаста оланның хәлен җиңеләйтә алуына куану яшьләре идеме?..

Кала ягыннан коега таба якынаючы тузан болыты күренде. Юл тузанын күрүгә, тутай күз яшьләрен сөртте, йөзенә салкын су бөркеде. Ахирәтләре аларны эзли чыккан булырга тиеш. Шөкер, ул ялгышмаган иде. Ахирәтләре каберстанда да аңа терәк булды, бүген дә алар аның белән бергә булырга тели.

Ярсып чапкан атлары кое янына җитәр-җитмәстән, кызларияр өстеннән очып-очып төштеләр. Сөен бәкнең такыя киеп утырганын күргәч, «Сөбханаллаһ-машаллаһ!..» — диешеп, игезәкләрне уратып алдылар.

Шулай итеп, Сөен бәк исән калды. Кала халкы да, дала халкы да үләргә йөз тоткан бичара сабыйның савыгып китүен төрлечә юрады. Кемдер Аллаһ Тәгаләнең кодрәтенә шөкеранә итте, бәгъзеләре бу эшне җен вә иблис атына сылтады, кайсысыдыр тумыштан хаста малайның исән калуын Сөен тутайның зирәклегенә бәйләде. Менә шул вакыйгадан соң, Сөенеч тутай зәгыйфь карындашын үз янына алды. Буыны тотмас Сөен олан аның өчен тере курчак та, бала да, юаныч да, хафа да иде. Шуңа күрә, ятим калу хәсрәте арткарак күчте... Нугай иленең иң олуг мирзаларыннан берсе Йосыфның кызы Сөен тутайның укуы-язуы да, уйнавы-җырлавы да, Айдалага җайдак чыгулары да карындашы Сөен бәккә бәйләнгән. Сөен олан күзгә күренеп үзгәрде. Ул хәтта аягүрә басып тора башлады. Ләкин Йосыф мирза гына кызының гарип олан белән шулай мавыгуына разый түгел иде бугай.

Шулай итеп, Сайгөле бикә вафатыннан соң биш былтыр узды да китте: хаста олан үз аягы белән йөри, сакау-тыңкыш булса да, теле дә бар. Әллә угыллары бик күп булганга, Йосыф мирзаның күңеле барыбер Сөен бәккә ятмады. Ул мәхлүк баланы Аллаһ Тәгалә алган булса, мең шөкер дә бит, үлде дигәндә карындашы алып калгач, ни хәл итәрсең? Уйлап баксаң, Мирзаның бу хафасы улының гариплегеннән дә түгелдер әле; кызы сылуларның да сылуы булып өлгереп килә. Тот та, бүген үк кияүгә бир. Аның яшендәге тутайлар туй узгарып ята. Ә моның уенда да юк. Тутайның бөтен көче, вакыты олан янында уза... Кызны олы тормышка әзерләргә кирәк. Анасы Сайгөле бикәне кайчандыр сөйгәнгәме, Йосыф мирза Сөен тутайны да аерып сөя, кадерли, кызының кыланмышларына юл куя килде. Сөенеч кыз гаять чая, чәтертән булып үсте, әче итеп сызгырыр иде; үзе маймылдай җитез, ат сыртына ябышып үскәндәй хәтәр җайдак булды. Егылгач елаганын, борын салындырып үпкәләп утырганын күрүче булмады.

Кымыз мәҗлесләрендә мәшһүр мирзалар әйтә килде:

— Һай, Йосыф мирзам, синең сиккез углыңның сиккезенә торыр кыз оланың бар гү! — диләр иде.

Ярты ятим калгач, гарип оланны үз янына алгач, Сөен тутай бөтенләй үзгәрде, кырысланды, аңа олы киленчәкләр кыяфәте иңде. Ул зәгыйфь бала карый, көн-төн китап укый, ниләрдер яза-сыза, аннары ахирәтләре белән Сөен бәкне алып, дала эчендә атналар буе куна-төнә йөри. Дус кызлары да үзе кебек — җен ташлары, кызкыркын димәссең. Ләкин Сөен тутайны бәхетсезлек сагалап кына торган икән...

Игезәкләргә унике яшь тулган көнне — мөшәл бәйрәмендә булды бу хәл.

Сөен тутайның өстендә затлы кием, кулында сөяк саплы, бизәкле камчы. Шушы көн өчен атасы Хаҗитархан базарыннан кавыштырма изүле, алтын ука белән чигелгән, биле бөрек кысма җилән алып кайткан иде. Җиләне бик тә матур, сүз юк, ә менә шул биле бөрүле җиләнне кигәч ни булганын күреп, тутайны киендерүче яшь бикәчләр телсез калды. Әллә кыйммәтле җилән матурайтты кызны, әллә үзенең гүзәллеге җиләнгә күчте, гаҗәеп килешле иде алар бер-берсенә. Сөен бәккә дә яңа җилән тектерделәр, өр-яңа кысма тун кигезделәр, биленә көмеш аеллы каеш бәйләделәр, каешка сөяк саплы көмешләнгән хәнҗәр тактылар, башына рахшын-түбәтәй кидерделәр... Олы бәкләр дә, мирзалар да, яшьләр дә игезәкләргә мөшәл бүләге китерделәр.

Бәйрәмгә Йосыф мирзаның энесе Исмәгыйль мирза да киләчәк иде. Сөенеч тутай исә: мөшәлем туена Исмәгыйль-Елмаймас мирза килмәсен, дип теләк теләде. Килде Елмаймас мирза аның унике яше тулган көнне, килде, аты коргыры. Исмәгыйль мирза андый мәҗлесләрдән каламыни?! Аның бөтен рәхәте — туй бозу, мәҗлестәшләрне талаштыру, һич югында утчагар мылтыклары, чабышкылары белән мактану булыр.

Кайбер вакыйгаларны Сөен тутай өч-дүрт яшеннән үк хәтерли. Даялар, бикәләр авызыннан ишеткәннәрен дә исендә тота: аның агасы Исмәгыйльнең җандусты Дилазар исемле мирза, далада атаклы Таргын мирзаның токымын кырып, яндырып, бөтен мөлкәтен барымтага алган. Таргын углы Кошчак олан бергә-бер ярышта Дилазар мәлгуньне үтергән. Исмәгыйль мирзаның үч кайтаруыннан куркып, сабый Кошчак Кырымга күчеп киткән, имеш. Озак та узмый, Исмәгыйль мирза мәрхүм Дилазарның җәйләвен туздыра. Дилазарның хатыннарын, балаларын, малларын куып алып кайта... Бу вакыйга Нугай илен генә түгел, бөтен күрше-тирә халыкларның җанын сыкындырды. Әмма Елмаймас мирза халык нәфрәтен игътибарына да элмәде: көче җиткәннәрне талый торды, кыра торды. Ул хәтта үзе белән бертуган мирзалар өлешенә дә керә башлады. Шәехмамай бәктән дә, Шаһым мирзадан да, хәтта абыйсы Йосыф мирзадан да ул курыкмый. Ун олыс түрәләре, берләшеп, авызлык тешләп явызлык ташыган бу чыгымчы мирзаны акылга утыртырга булдылар. Әмма Исмәгыйль мирза бу мәҗлескә килмәде. Курыктымы, әллә абзаларын мыскыллавы булдымы — туганнары белән сөйләшәсе урында, күп елкы куып, мул бүләкләр төяп, Мәскәвиягә, олуг кенәз Василийга кунакка киткән. Василий белән дуслашып алгач, Исмәгыйль мирза үз туганнары белән бөтенләй санлашмас булды. Далага ул хуҗа. Кайсы җәйләүдән елкы куасы килә — шунда барымта ясый.

Хәтерли Сөен тутай, бик яхшы хәтерли. Ул вакытта аңа җиде яшь тулып килә иде. Исмәгыйль мирза, углы Динәхмәт тугач, зур туй ясады. Кемнәр генә юк иде бәби туенда: Нугай йортының әмирләре, мирзалары да, чит мәмләкәтләрдән килгән илчеләр дә, Кырым ханы Мөхәммәт Гәрәй дә, хәтта Төрек солтаны бөек Сөләйманның илчесе Искәндәр Маңкуби да килгән иде. Һай-баягу! Муллык өстендә муллык иде туйда. Озакка сузылды ул сыйланулар, сунарга чыгулар, кымыз-буза, тагын әллә нинди хәмер-шәраб эчүләр.

— Хәерлегә генә булсын, артыкка китте бу туй!.. Азагы гына яхшы бетә күрсен! — дип дога укып, изге теләкләр теләде Сайгөле бикә.

Сөен тутай анасының тавышында шөбһә барлыгын күңеле белән сизгән икән... Илче-килчеләр таралгач, якын туганнары — Нугай йортының ун олыс мирзалары гына иркенләп утырырга да, шуның белән туйны төгәлләргә булдылар. Туйның әнә шул соңгы кичендә Исмәгыйль мирза пылаудан чәч бөртегеме, сакал төгеме чыкканга, үзенең олы бавырчысы Гожан аганы табын өстендә суйган. Динәхмәт оланның бишек туе әнә шулай кан-мәет белән тәмамланган иде.

Сөен тутай Исмәгыйль агасыннан куркып үсте. Агасы хакында яхшы сүз ишетмәгәнгәме, Исмәгыйль мирза килгәнне белсә, әнисе янына кереп кача, Елмаймас агасы киткәнче шуннан чыкмый иде ул.

Бу юлы — мөшәл туенда — Сөен тутай агасыннан качмады; әмма, аннан ераграк булырга тырышып, күбрәк уенчылар арасында чуалды.

Уеннарның иң кызган чагында Исмәгыйль мирза, бүртенеп, кымыз эчеп кызарып утырган урыныннан калкып, уеннардан читтәрәк җәелгән келәмдә әсседән йокымсыраган Сөен бәкне күтәреп алды да үзе кебек үк җүләр-җүнтек, пырдымсыз Айтояк исемле атына атландырды. Бичара олан куркып елый башлады.

— Мирза баласымы син, кем баласы? — дип кычкырды Исмәгыйль дуамал. — Челләдә җебеп утырма, бар, атта узыш! Валлаһ газим, син беренче киләсең!

Шулай диде дә, кошагыннан табанчасын чыгарып, һавага атты. Әле өйрәтелеп тә бетмәгән яшь айгыр кушаяклап алга сикерде; бичара олан тезгенне тотарга да өлгермәде, ике куллап ияр киергесенә ябышты. Айгыр мәйданнан, кешеләрдән читкә, урманга таба очты. Исмәгыйль мирза шаркылдан көлә, аның әтрәманнары-куштаннары һүррәләп, һай-һулап кычкыра, сызгыра. Халык шаулаганга, мылтык тавышына Сөен тутай да борылган иде, җүләрләнеп чапкан тай өстендә Сөен олан икәнен күрде. Әле генә затлы киемнәргә уранган салмак тутайны танырлык түгел иде: ул җен тизлеге белән башындагы асылташлы-тамгалы бүреген кызларга ташлап, иң якындагы атка сикереп атланды да, дулаган тайны куа китте. Хәтәр ярыш иде бу. Авызлыгын тешләгән ярым кыргый асау ат өстендә зәгыйфь олан менә егылам, менә егылам дигәндәй атынып бара, аның артыннан чәче-башы тузган Сөен тутай атына камчы ора-ора ыргый. Исмәгыйль мирзаның аты Айтояк җитезрәк иде шул, ара һич якынаймады. Дуамал ат, бичара оланны алып, урманга кереп китте. Бераздан урман эчендә ярсыган, курыккан атның әче кешнәгәне ишетелде. Ул арада Сөен тутай да урман юлына төшкән иде инде. Күзләре кан савып акайган яшь айгыр урманнан атылып чыкты да, Сөен тутай атыннан читкә тайпылып, далага чапты. Айтояк иярендә Сөен мирза юк иде. Кыз атына янә камчы орды, алар чытырманлыкка барып керделәр. Ат кинәт башын иде, Сөен тутай да шулчак, нидер сизенеп, башы белән атның ялына сеңде. Ат кырга тайпылды, Сөен тутайның баш түбәсенә тияр-тимәс кенә, агач кәүсәсе яшен тизлеге белән узып китте. Тутай ярсу атны тыйды. Кире борылып, юлга аркылы үскән агач янына килде... Юл уртасында Сөен бәк ята иде. Кыз имәнеп куйды. Оланның баш капкачы ярылган, аннан ургып кара кан ага. Ат гәүдәсеннән чак кына биек булып үскән агач ботагында Сөен бәк оланның рахшын-түбәтәе эләгеп калган. Тутай, рахшынны алып, ирдән сикерде. Яралы оланның башын күтәрә төшеп, түбәтәе белән каплап, муен яулыгы белән урап, канны туктатырга теләде.

Карындашы Сөен оланны җирләгәч, тутай тилерә язды. Сөекле туганының әҗәле аны шулкадәр тетрәткән иде, хәтта явыз агасы Исмәгыйль мирзага да ул каргыш сүзен әйтә алмады. Кешеләр зә-

гыйфь сабыйның үлүенә бик уфтанмады. Аллаһ үзенә алды, гөнаһсыз сабый иде, урыны җәннәттә булыр диделәр дә — вәссәлам!

Сөен олан һәлак булгач, тутай күңелендә нидер кителде. Ахирәтләре аны бер мизгелгә дә ялгызын калдырмыйча саклады. Бераз сихәтләнә төшкәч, ахирәтләре тутайны далага алып чыга башлады. Шулай итеп, бу тораташ халәтеннән ул бик озак айныды. Сәламәтләнеп беткәч, тутайның иң беренче әйткәне— «Исмәгыйль мордар мирза!» — дигән сүз булды. Гомере буе «Исмәгыйль агам» дигән Сөен тутай, әлеге фаҗигага исенә төшкән саен, чирканып:

— Елмаймас мордар мирза! — дип куя иде.

Әче хәсрәтнең ни икәнен ул, анасы Сайгөле бикә дөнья куйгач, җиде яшендә аңлады. Ошбу җиһанда кара кайгы барын ул Сөен оланның фаҗигале үлеменнән соң татыды. Тагын бер яңа хис аңа үзен танытты: хыялый, чая кыз Сөен тутай нәфрәтнең ни икәнен төшенде. Нәфрәте кайгысына караганда да хәтәррәк икән. Кайгыхәсрәтле бәндә үз җаена яши бирә. Нәфрәт асраучы адәм һичкайчан да үз җаена яши алмаячак. Якын туганыңа нәфрәтле булу тагын да яманрак. Исмәгыйль мирзага булган нәфрәте аны үчкә чакыра иде. Ул үч алуның ләззәтен көтеп яши. Төннәр-көннәр буе уйлап, хыялый җиңүдән коры ләззәт алуның чирканыч икәнен үз зиһенендә ача алмаса да, күңел түре белән сиземли иде. Бер таңда ул үч кайтарыр өчен дәртләнеп уяна. Икенче таңда, ташка каршы аш атарга кирәклеген тәкърарлый...

Ике ут арасында ачыргаланып шашмас өчен, ул максатсызтеләксез генә далага чыга. Иң авыр чакларда, үзенә терәк һәм юаныч булган ахирәтләрен дә күрергә теләмичә, атын соң көченә куып, дала эченә кереп югала...

Шулай бер көнне ул тагын далага чыгып югалды. Атын кара тиргә батырып, кояш кичкә авышкач кына сарайга кайтты. Бичара атын Комбар атага тапшырмыйча, бер сүз әйтмичә, эчкәригә, үз ятагына кереп ауды. Юатырга кергән бикәләрне дә, өшкерергә килгән имчеләрне дә күрергә теләмәде.

— Алмашына бу яшь бикәч! — диештеләр хатыннар. — Йосыф мирзага хәбәр салырга кирәк.

— Алмашынмый, — диде бәгъзеләре. — Өлгергән, пешкән...

— Ирдән төшәргә нәүбәт җиткән... Әнә, ун мәмләкәттән ун яучы тутайның ирдән төшүен көтә.

— Килмәгән җире юктыр: җайрандай зифа буйлы, тулган айдай чәһрәсе... Падишаһка хәләл булырлык!

Бу сүзләрне ул ишетеп ятты. Әлеге хатыннар, ул ишетсен дип, юри кычкырып сөйләште сыман. Юкса, хәсрәтле тутай ханәкәсенең ишеге төбендә үк болай кычкырып сөйләшмәсләр иде.

— Үз баласыдай кадерләп бакты карындашын, бик юксына...

— Бер карында ятканнар бер-берсеннән башка яши алмый...

— Чүп тә булмас, — диде карт дая. — Яшь мирзабәйне ул анасы кебек багып үстерде. Мирзабай вафат булгач, ике кулы буш калды. Бала урынына бала кирәк аңа...

Хатыннар тавышы тынды. Сөен тутай ятагына торып утырды. Ике кулын түшәккә терәгән, ияге күкрәгендә, чәче таралып, идәнгә, келәмгә тигән. Шул сурәттә байтак утырганнан соң, ул ике кулы белән чәчен як-якка аерды, чәч тузгымнарын ике колак артына кыстырып, йөзен ачты. Аның карашында хәсрәт түгел, яшәү нуры балкый; аның йөзендә өметсезлек сөреме түгел, билгесез куаныч, нидер эстәү яна иде. Җитез күз карашы белән ул диварларга бакты, аның карашы нәзакәт маллары тутырылган кулсандыкта тукталды. Ул, җәһәт торып кулсандык өстендәге күнчекләрне як-якка ташлап, капкачны ачты. Асылташлы чәч кыршавы, энҗе тезгән калфаклар, алтын укалы чәчкапларны туздырып, сандык төбеннән саплы көзге

тартып чыгарды. Вафатына атна-ун көн кала, анасы Сайгөле бикә аңа үз көзгесен сонып:

— Төсем итеп сакларсың, — дигән иде.

Көзге йөзен җиңе белән сөртеп алды да, яктыгарак килеп, көзгесен өскәрәк күтәрә төшеп, үз йөзенә бакты. Күзләр тикшереп, гаҗәпсенеп бага; һәр керфекне, аскы ирен кырыендагы бердәнбер миңне, колак очларын, борын яфракларын барлый. Көзге эчендәге кызның ак маңгаена ишелеп-ишелеп төшкән сумкара чәч көлтәләрен түгәрәк матур бармаклар як-якка аралый. Тыңлаусыз, үҗәт чәч учмалары, көзгедәге серле гүзәл йөзне яман күздән яшерергә теләгәндәй, колак артына эләктергән җирдән ычкынып, әледән-әле кызның чыраен капларга тырыша. Матур кул аларны янә колак артына юллый. Шул арада икегә аерылган чәч чаршавы артыннан ике чем-кара күз бага. Юк, чем-кара түгел бугай, көзгене чак кына боргаласаң, күзләрдә коңгырт төс чалынып китә. Яктылык кими төшсә, алар чем-кара була. Димәк, бу күзләр — яктыда куе коңгырт, күләгәдә чем-карага әйләнә. Күз агы ап-ак, бераз карап торсаң, зәңгәрсу булып күренә. Керфекләре карга каурыедай зәңгәрсу-кара. Керфекләр майлы суда чылаткан кебек елкылдый, сирәк кенә, салмак кына талпынып ала да, янә зәңгәрсу-ак дәрья уртасында кап-кара түгәрәк утраулар пәйда була. Ике кашы — ике җәя, өске ирене сانай җәя кебек, киртләч ясап тора, аскы ирене шул җәяне тарттырган кереш сыман. Бу керешкә, бу җәягә сәрпи ук куйсаң, һич шик юктыр ки, җәя атачак; атачак вә угы төбәлгән алманың кыл үзәгенә кадалачак. Ул алма урынында ир-егет, егет-җилән йөрәге булса, атылган ук әлеге йөрәкләрне үтәли тишеп чыгачак һәм мәңгегә мәхәббәт җәрәхәте салачак... Көзгедәге шушы серле чырайнымы соң хатыннар «падишаһка лаек» диде? Шушындый буламыни инде ул гүзәллек?! Зөләйханың йөзе дә шушылай булды микәнни? Көзгедәге бу чырай Ширинның чәһрәсе кебек нурлымы икән? ... Сөен тутай аптыраштa калды. Көзгедән гади бер кыз карап тора, башкалардан бер дә артык җире юк. Шушы ябай чырайда нинди гүзәллек булсын? Шушы да чибәр чырай икән, димәк, барча кызлар да чибәр. Мондый кызлар белән бөтен Нугай йорты тулган... Юктыр... Хатыннар арттырган. Ни өчен соң хатыннар күрәләтә ялган сөйләде икән?... Йә, хуш! Шулай да булсын, ди. Чибәр икән — чибәр.

Ә чибәр кызларның карашы сагышлы була микәнни? Гүзәлләр гүзәле, газәлләр газәле Ләйләнең дә багышы шулай моңлы булдымы икән? Анасыз, иркәдәшсез калган ярты ятимнәр бу җиһанда аз түгел, берсенең дә йөзенә мондый шаукымлы сагыш сирпелмәгән. Бер-бер фаҗигаме көтә көзгедәге кыз баланы?

Тышкы якта тавышлар ишетелде. Ишек төбендә үк кемдер тамак кырды. Сөен тутай, көзгесен сандыкка ташлап, өстенә мендәр ыргытты.

— Кереңнәр! — диде тутай.

Бу — Сөеннең иң сөекле ахирәте, ханәкә ишекчесе Сөмбел тутай иде. Сөен тутай аны, яратып-сөеп, «Сөмбел тутай» дип түгел, «Сөмбелтай» дип йөртә.

— Нә хәбәрең, Сөмбелтай, кемнәр анда? — диде Сөен.

Сөмбелтай, тез йөгенеп, янә аягүрә басты.

— Җантутаем, — диде ахирәт кыз. — Атакаең олуг мирза Йосыф түрәмез синең янга килә.

— Килсен! — диде тутай.

Сөмбелтай янә тез йөгенде дә:

— Башым өсте, йөзем түбән! — дип юкка чыкты.

Ул чыгуга, ишек төбендә янә тамак кырдылар. Болары тутайны киендерүче, йоклар алдыннан чишенергә булышучы ахирәтләре Алиәк белән Бадәмгөл иде. Алар артыннан ук Сөмбелтай ~~келәмче кыз~~

Татлыбик фәррашны ияртеп керде. Келәмче кыз тәрәзәләрне каерып ачты. Курҗыныннан — күн янчыгыннан — чакматаш белән ку алды, ташка чакма чагып, куга ут төшерде. Курҗыныннан сандал агачы алып көйрәтте. Коры сандал чыбыгы чытырдап кабынды. Әтрафка хуш ис таралды. Ул арада Сөен тутай киенеп өлгергән, урын-җир җыелган, бөтен җиргә затлы келәмнәр капланган, келәм өсләренә мендәрләр ташланган иде.

Ишек артында ир кеше тамак кырды. Тутай кызларга ым какты. Дүрт ахирәт шәүләдәй юк булды.

— Кереңнәр! — диде Сөен.

Йосыф мирза ханәкәгә үтте.

— Һайди, атакай, узың! — диде кыз.

Олуг мирза ялгыз иде. Ул игътибар белән, тәфсилләп-сынап карады кызына. Урыныннан тора алмыйча сырхаулап ятучы баласын күрергә дип килгән ата гаҗәпкә калды. Хатыннар, даялар әйткән хаста кыз урынында, киенгән-ясанган, җикән камышыдай төз буйлы, Сөен тутай елмаеп басып тора... Дога кылып, йортка хәер-фатиха биргәч, Йосыф мирза кактырып-суктырып, Сөен тутайның үсеп җиткәнлеге, ялгызлыгы, алдагы тормышны уйлый башларга кирәклеге турында да сүз башлады. Итагать саклап, атасының сүзен бүлдермичә тыңлагач, җае чыгуга, Сөен тутай әйтте:

— Атакаем, — диде.— Өлгермәгән җимешне ашыгып өзсәң, әче була!

Йосыф мирза әйтте:

— Артык өлгергәнгә караганда, өлгерер-өлгермәстә өзеп куйсаң, өйдә дә пешә ул җиләк-җимеш,— диде. Ярым шаяру, ярым җитди сөйләшү шуның белән төкәнде. Уен-көлкеле бу сүзләрдә, Йосыф мирзаның тавышында шаяруга караганда кырыслык микъдары күбрәк икәнне тутай бик яхшы аңлады: көт тә тор, озакламый яучылар киләчәк!

Йосыф мирза кызыннан артыгы белән канәгать иде. Аның теләкләре фәрештәнең амин әйткән чорына туры килгәндер, ахрысы, хыялы тормышка аша тора: гүзәлләрдин гүзәл, газәлләрдин газәл булган ич аның кызы Сөен тутай. Ирдән төшеп, берәр ханга, солтанга кияүгә чыгып, тәхет-сарай яме булырлык сылу килен үстергән ләбаса Нугай даласы. Шул уйлар белән, куанычлы хыял белән Йосыф мирза, Сәгадәт Гәрәй хан чакыруы илә, көтүе белән елкы куып, олы бүләкләр алып, Кырымга-Бакчасарайга юл алды.

## Ирәмбаг

Атасы Йосыф мирза белән сөйләшкәннән соң тутайга нидер булды. Гомергә кияүгә чыкмаенча, гарип кардәше Сөен мирзачыкны багып яшәргә, шулай тамырында корып, әҗәле килгәч, сабыр гына фани дөнья белән алыш-бирешне төгәлләргә ниятләгән иде ул, нәрсә булды соң аңа бу арада? Сарай хатыннарының астарлап әйткән сүзләреме аны җилкетте? Ханәкәгә кергәч, атасы аның буй-сынына, чәһрәсенә карап, сәерсенеп торды; аның чибәрлеге, үсеп-өлгергәнлеге турында шулай хәбәр салдымы? Нигә соң әле ул янә көзгегә бакты? Атасы чыгып киткәч тә ул янә көзгегә карады. Озак кына үз йөзен тикшергәч, уйга калды. Димәк, ул ямьсез түгел. Ямьсез булмагач, димәк, ул матур. Үзенең гүзәл булуына ул әле һаман ышанмый. Аның хыялындагы гүзәллек ул — Зөләйха, Ләйлә, Зөһрә вә Ширин. Менә ул дөнья гүзәллеген үзләренә җыйган илаһи затлар. Аның хыялындагы гүзәллек ул — Ирәмбаг. Шушы Ирәм бакчасында рәхәт кичүче газәлләр.

Шул төнне үк Сөен тутай Ирәмбагны төшендә күрде. Нә гаҗәп

ки, төш түгел иде бугай ул. Шулкадәр чын иде ул бакча, бакчадагы җимеш агачлары; агачлардагы сандугачлары, тутый кошлар; бакча уртасындагы чирәм, чирәмдәге тавислар, һөдһөд кошлары; бакча уртасындагы күл, күлгә коючы чишмәләр, күлдә йөзүче аккошлар, күл уртасында һавага су аттырып торучы алтын көпшәләр — барысы да аермачык, бер хаятта иде. Могҗиза эчендә могҗиза булып, бакчада бер ханәкә пәйда булды. Ап-ак сөяктән эшләнгән утыргыч-көрсиләр; ул көрсиләрнең бормалы бизәкләре, сырлары-ырмаулары — саф алтыннан. Бакча сукмагы буйлатып, акбүз атта бакчаның хуҗасы Шәддад падишаһ килә. Фил сөяге кебек акдин-ак, пакьдин-пакь бу гайрәтле айгырны каян таптылар икән? Ап-ак атта — зәңгәрсу келәм, келәм өстендә — иярдә — шәм йоткандай, төз Шәддад падишаһ утыра. Ул үзе дә ап-ак кием кигән, башында да ап-ак чалма, акбүз атның кыңгырау айдары да ап-ак ләкләк каурыеннан ясалган, шундый ук каурый Шәддад падишаһның чалмасында да... Шәддад киләсе сукмакка тавис койрыгы аркылы сузылып яткан, Шәддад падишаһ сак кына тезгенен тартты, акбүз ат туктады. Тавис үз койрыгын сөйрәп алып бетергәнче, акбүз ат урыныннан кузгалмады, бер җирдә таптанып торды. Тавис ераклашкач кына, падишаһ тезгенне бушатты, аның аты Сөен тутай янында, ханәкә ишеге турында туктады.

— Сөенеч бикәч! — диде мәгърур падишаһ. — Син минем хәләлем. Әйдә, кил куеныма, Ирәмбаг сараенда безне никах мәҗлесенә көтәләр.

Шәддад падишаһ Сөен тутайга кулын сузды, алар ат өстендә икәү булдылар. Падишаһ кызны куенына алды. Акбүз ат һавага очып менде. Шул мизгелдә кемдер үзәк өзелерлек итеп «Янмас кыз» көен уйный башлады. Баксаң, Шәддад падишаһ та бу көйне белә, бу көйне җаны белән сөя икән... Әнә шул ләззәтле мәлдә генә Ирәмбаг өстендә, аларның баш очында Каракош пәйда булды. «Янмас кыз» көе бозылып, буталып бетте. Очып барганда акбүз ат аска егылды. Сөен тутай, кычкырып, үз тавышына уянып китте...

Төш күргәннән соң Сөен тутай, чыннан да, алмашынды. Аның теләге үзгәрде. Азагы куркыныч булса да, бу маҗаралы төш аңа ләззәт бирде. Аңлата алмаслык бер ләззәт иде ул. Аның уе-зиһене дә, хыялы да, тәне-бәдәне дә рәхәт изрәүдә яши башлады... Төшен ул берәүгә дә юратмады, фалчыга да бармады. Матур, әмма дәһшәтле бу хыялый вакыйганы ул иң якын ахирәте Сөмбелтайга да сөйләргә базмады... Шуннан соң ул төш юратуның файдасыз бер шөгыль икәнлеген аңлады. Юратучының күңеле булсынга юраучы төшне яхшыга юрый, ә ни уйлаганын, төшнең шомлы мәгънәсен яшереп калдыра. Төшен яманга юраганны берәү дә сөйми. Инде дә яманга юрасалар, юраганы юш килеп, шул яманлык бәндә башына төшәчәк. Бәс, күргән төшең сер булып үзеңдә генә калсын. Сер никадәр тирән яшерелсә, шулкадәр ләззәтлерәк булып сулкылдый. Сөен тутай тагын бер хакыйкатьне аңлады: ул — Сөен тутай — мәхәббәт Йосыф төшеннән дә, гүзәлләрдән гүзәл Зөләйха төшеннән дә мәгънәлерәк төш күргән икән. Мондый төшне мендәрең астына мең төрле бөтик язып салсаң да күрмәссең! Мондаен да мәгънәле төшне алтын-көмешкә дә сатып алалмассың, биллаһи!.. Үзенчә юрады ул төшен. Бу төш Аллаһ Тәгаләдән бер-бер хәбәрдер. Ирәм бакчасы, китапларда гына түгел, бу җиһанда да бар ул. Ләкин фани дөньядагы бәхет-сәгадәт бакчасын эзләп табарга кирәк. Ул бакчаның асыл хуҗасы сине көтә. Бар син, эзләп тап ул рәхәтият багын. Тутайдан син бикәгә әверелерсең, дидеме бу төш?.. Ә нәрсәне хәбәр итә ул Каракош? Акбүз атның Шәддад падишаһ вә Сөен тутай белән бергә упкынга очуы ни-нәрсәгә ишарә?.. Әстәгыфируллаһ, ул турыда уйламавың, төшне юрамавың хәерлерәк...

Ирәмбагтагы падишаһ Шәддад тагын төшемә кермәсме дип, ул йокы ястыгына иртәрәк ята башлады. Эңгер-меңгер төшүгә, үз ханәкәсенә кереп бикләнә дә түшәгенә чума. Йокламый ул. Күзен йомып, хыялындагы Ирәмбагта йөри. Чәчәкләр, кошлар белән сөйләшә, акбүз аттагы Шәддад падишаһка эндәшә. Аның бер үзе сөйләнгәнен ишетеп, сарай бикәләре:

— Саташа! Көннән-көн алмашына бара! — диделәр.

Хәзер аның төп яшәеше шул сихри бакчада — Ирәмбагта. Ул карыны ачкач — ашарга, атын сагынгач, далада ат чаптырып кайту өчен, ара-тирә генә бу дөньяга да кайткалый шикелле. Тора-бара ул Ирәмбагның барлыгына ихластан ышана башлады... Шулай итеп, Ирәмбаг сөйкемле сөяк Сөен тутайның бөек максатына әйләнде.

Әмма, Ирәмбагны эзләп сәяхәткә чыгар өчен, кызларны ир-егетләр генә күтәрә алырлык михнәтләр чигәргә, коллыкка төшмәс өчен — кылыч айкарга өйрәтү шарт иде. Тик кайдан, каян аласың андый останы? Сарай кылычбазарларына сер чишү ахмаклык булса, вак мирзалар арасында бу эшне аңларлык, кызлар серен яшереп сакларлык егетләр егете, ирләр ире юк.

Соң тапкыр далага чыкканда ул уеннарга катнашмады. Колынъялына атланып, дала түренә хәтле чапты. Чеҗлә бөҗәкләренә чыдый алмыйча, Колынъял авызлыгын тешләп, хуҗасын чүл эченә алып кереп китте. Тутай, аякларын өзәңгегә терәп, җан ачуы белән ике куллап тезгенне каерды, әмма яшь айгыр күзен акайтып, башын бирмичә җене белән чаба да чаба иде.

Ярсу ат һаман чүл эченә керә барды. Бара торгач, ул ак күбеккә батып туктады. Ком атның хәлен алды. Сөен тутай, турсыгыннан бер уч су алып, атның иренена тигезде, көнчәлегеннән бер локма ләваш алып, атка каптырды.

— Менә шулай, — диде кыз. — Менә шулай... сабыр-сабыр...

Икесе дә тынычлана төште. Ул җәяүләнде, атның тирен сыпыргалап, янә икмәк каптырды. Хәзер кайту юлын карау кирәк, дип, тутай янә ияргә менде. Алай карады, болай бакты да — чүл эченә кереп адашканлыгын аңлады. Ярар, ни булса шул булыр, килгән эзгә басып кайтырбыз, дип, атын тояк эзләренә таба борды. Әмма, бераз баргач, әлеге эзләр дә юкка чыкты: ком өстендәге тояк эзләре йомылган иде. Ат тагын тынычсызлана, тартыла, артка чигә, чыгымлый башлады.

Чүл өстенә төн төште. Тутайның күңеленә шом иңде. Күпме генә сызгырып, кычкырып караса да, аңа җавап бирүче булмады. Бер генә җан иясе дә очрамады. Бу якта, йөз чакрымнан ким арада, бер генә кышлак та юк иде, ахры. Ара-тирә чүл бүресе улаганы гына ишетелә. Шулай шомланып, бер йокымсырап, бер уянып, ул берьялгызы төн кичте. Таң аткач, ияргә басып офыкка карап торганда, ыңгырашкан өн ишеткәндәй булды. Тутай, алак-ялак карангалап, чүлне тыңлады. Хак икән, ыңгырашу саксаул ягыннан ишетелә...

Саксаул төбендә комга күмелеп бетә язган бер гәүдә ята. Килеп җитәр-җитмәстән, тутай ияrdән сикереп төште. Йөзтүбән яткан гәүдәне чалкан әйләндерде. Кешенең йөзе күренми, чал сакалы барлыгы гына беленә иде. Ком катыш кан сыланган чырайны ул турсыгындагы су белән чылатты, кибешкән иреннәргә аз гына су тамызды. Адәм күзен ачты. Бер күзе чабык иде — кылыч эзенә ком-кан укмашып каткан. Сөен тутай, үрелеп, ияргә бәйләнгән тулымын алды:

— Мә, адәми, зат, эч! — дип, әлеге бәндәгә кымыз йоттырды. Җәрәхәтле адәмгә бераз хәл керде.

— Җегет... — дип пышылдады ул. Сөен тутайга сәерсенеп карап торганнан соң. Сөен тутай: «Юк, мин җегет имәсмен! Мин кыз затыннан булырмын», — димәкче иде, теле аңкавына ябышып калды. Димәк, аны егет дип таныйлар. Далага чыкканда ул, аягына күн

чөлкә кия, чәчен җыеп, башлыгы астына тутыра да, ябынча бөркәнә, күлмәген бил тиңентен өскә күтәреп бәйли, чалбарын бөктәрләп чөлкә эченә тыга иде. Ихтимал, үсмер-егет сыман күренәдер.

— Сул якта... ваһа булыр...— диде яралы адәм. Сөен тутай ул күрсәткән якка бакты, офыкта һични күренмәде.

— Ошул тарафта...

Җәрәхәтле адәм җөмләсен әйтә алмады, биһуш булды. Бераздан, аңына килгәч, тутай аны көч-хәл белән ияргә менгезде. Байтак кына баргач, офыкта каракучкыл бер нәрсә күренде.

— Җитәбез...— дип ыңгырашты чүл абзасы.

Ваһа дигәне чүлнең бер аулак почмагындагы агачлык булып чыкты. Агачлыкта — алачык, бераз читтәрәк — кое күренә. Алачыкта караңгы, салкынча. Күзе ияләшә төшкәч, тутай күрде: алачыкның тышы киез белән тышланган, эче дә киез белән эчләнгән; идәндәге ком балчыгына хәтле алынган, такыр, салкынча; такырга тула җәелгән. Чүл уртасындагы җәннәт иде бу җир. Ул җәрәхәтлене тәбәнәк сәкегә яткызды. Яраларын янә юып бәйләде, янә кымыз эчерде. Бераз хәл алгач, абзый әйтте:

— Туланы күтәр, — диде.— Базда бар...

Тула астында — агач капкач, капкач астында — баз авызы, базда — тулым-тулым кымыз, йомарлам-йомарлам корыт, дуга-дуга казы, тутырма. Сөен тутай хәйран калды. Бер корыт, бер казы, бер тулып алып, баздан чыкты.

— Кичерең, олан, — диде хуҗа.— Тора алмам. Үзең сыйлан.

Икәүләшеп тамак ялгадылар.

— Сиңа олуг рәхмәтем, — дип, хуҗа үзен коткаручыга хәнҗәр сузды.

— Куй! — диде тутай. — Бу хәнҗәр — дөнья бәһасе...

Хуҗа чын күңелдән әйтте:

— Рәнҗетмәң олы агаңны, — диде.— Атаңмы юк өйрәтергә? Күрә карашлымы син? Ак сакалымнымы күрмәзсәң? Затлы сөяк, асыл канлы күренерсең. Биләңдә булса бу хәнҗәр, кәмсетмәс ул синең сөягеңне...

Бу сүзләрне әйтү хуҗаның актык җегәрен алды; ул, биһуш булып, саташа башлады... Тутай төн буе хаста хуҗаның башындагы әтрәк-чүпрәкләрен алыштырып, чылатып торды. Хуҗа ыңгырашудан туктады, ләкин күзен ачмады. Ул йоклый иде бугай...

Ике тәүлек фани дөнья белән бакый дөнья арасында бәргәләнгәннән соң, хуҗа кеше күзен ачты. Ачык тавыш белән су сорады. Дәшмичә генә, казылык белән нан җыйды. Янә салкын кымыз эчте.

Ризыктан хушлангач, хуҗа әйтте:

— Кемдер син, олан? Атың кайнар канлы, үзең тиленканлы, кайсы мирза нәселендин булырсың?

Мондый сорауны тутай күптән көтә иде, шуңа күрә, җавабы әзер иде:

— Атым булыр Акмирза, атам булыр Йосыф бай, бабам булыр Муса казый.

— Идегәй бәктин икән токымың... — диде хуҗа.— Күренә шул, күренә нәсел. Сөягең затлы зәррәдин, телең татлы шәкәрдин... Сөхбәтеңдә син, җегет, асылдырсың, көләч йөзле, ширин сүзле, ләтыйф сурәтле, зариф сиратлы, җиһан кайгусындин азат булгыл, мине коткаргучы мирзабәй... Атаң җәйләвендә бәйгеләрдә мин өч ел Бүзтарланым белән алда килдем, бәйге-йөлте алдым... Атым минем Аблак баба...

Сөен тутай таныды. Бу бит чүл бабасы. Ничә еллар Нугай илендә ат бәйгеләрендә баш бирмәгән атаклы Бүзтарлан йөргөнең хуҗасы бу. Һәр ярышта беренче бүләк-йөлте ала килгән серле баба. Аның кайда яшәгәнен дә, кайсы ырудан икәнен дә белүче

булмады. Чүлдән чыга, чүлгә китеп югала. Өченче ел да, Исмәгыйль мирза аның Бүзтарланын сорады. Сатмады Чүлбаба атын. Бәя арттырганнан-арттыра барып, Исмәгыйль мирза Бүзтарланга бәрабәр ике яхшы айгыр, ике дөя, бер утчагар куйды. Мәгърур баба Бүзтарланын барыбер сатмады, сикереп атына менде дә чүл ягына китеп юк булды. Исмәгыйль мирза ирене өзелердәй булып ысылдап сүгенде:

— Токымыңны кыраем! — дип, бәйгедән китте.

Чүлбабаның кайда яшәгәнен әйтүчегә Исмәгыйль мирза мал вәгъдә иткән, диделәр. Әйтүче булмаган. Белсәләр дә әйтмәгәннәрдер. Аның кайдалыгын Исмәгыйль мирза белә калса, ни буласы мәгълүмдер ки: ул Чүлбабадан Бүзтарланны талап алачак.

— Идегәйнең токымында ала да бар, кола да бар, баба,— диде Сөен тутай.

— Хак,— диде хуҗа.— Елмаймас мирзадай фетнәдар адәмне мин очратмадым. Мәкербаз үз башын гына харап итсә — мең шөкер. Ай-һайли, яманнар ил башына җилкенә, шунысы аяныч, мирзабәй...

Хаста хуҗаның гыйбрәтле хикәятен тыңлап, тагын бер тәүлек узды. Егет сурәтендәге Сөен тутайга дөнья гизгән ир кешенең сөйләгәнен тыңлап сабак алу бик тә кирәк иде: шуңа күрә, аның ихтыярыннан тыш башланган «җегет мирза» уенын ул ялгышмаенча дәвам итәргә тиеш иде.

Габдел Каюм иде аның чын исеме, әмма сабый чакта шаярыпсөеп кенә Аблак диделәр. Үләт мулы чыгып, җәйләү-җәйләү адәммал кырылды. Шул заманда Аблак сабый ятим калды. Аны мәетләр арасында табып, бер кәрванчы үзенә угыл итте. Аңа тарун ата булды. Сабый Аблак кәрван берлә юл күчеп, ел күчеп, ничәмә-ничә икълим җир гизде. Аблакның зиһенен, эшен күреп, тарун ата үгәй углын Мысырда укырга калдырды. Юл йөргәндә хәрамиләр кәрванчы тарун атаның башын чабып, бөтен мөлкәтен талап алган. Аблак-ятим, мәдрәсәне ташлап, хуҗадан-хуҗага күчеп, тамак хакы өчен хезмәт кыла. Хуҗаларын яклашып, бик күп орышларда иштиракчы була. Шулай итеп, гомер уза, бераз мая җыеп, үз тамагын үзе туйдырырдай елкы-дөя асрап, бер Алла Тәгаләгә сәҗдә итеп яшәмәк була. Шәйдәк бәктән дә, Шаехмамай мирзадан да, Йосыф түрәдән дә ярлык алып, берәүсенеке дә булмаган шушы чүлдә яшәп, актык гомерен төгәлләргә ният кылган. Җиде елда җитмеш елкы, илле дөя үрчетеп, үзбашка тормыш корып, Аллаһ Тәгаләгә йөз куеп, һичкемгә зыян-зәхмәт күрсәтмәенчә яшәп ятканда, аның елкыларын, дөяләрен барымтага куарга килгәннәр, ялгызы гына булса да, Аблак бичара каты орыша. Әмма кылыч белән аның уң күзенә чапканнар.

— Күп һөнәрләр белдем. Тылмач та мин: фарсы, гарәп, төрки — туган телләрем. Чинча яхшы гәп орамән. Фрәнчә дә аңлаша алам, ᵀәскәүчә алыш-биреш ясарга да куәтемнән килә. Кол да булдым. Түрә дә булдым, олан. Әмма бәхетем, азатлыгым гына булмады... Нә җазыгым бардыр Илаһ каршында!.. Нә эш кыйлсам әгәр, башы яхшы, азаккы һәрчак яман тәмам итәр. Яшь ятим — ятим түгелдер, карт ятим — кара ятим. Әй-йа, Ходам, йөрдем мин хезмәтеңдә һич карусыз, кайчак тук булдым, күпчак — ач. Илаһем, коткаргыл мине бу михнәтдин, дип, ачы теләкләр теләдем. Бирде Ходам миңа бу муллыкны, шундук тартып та алды...

Сөен тутай әйтте:

— Аллаһ-Тәңре алмады малыңны, Аблак баба,— диде.— Бу — угры хәрамилар эше, мотлак!

— Син фәрештә минем чөн, Акмирза бәй. Аллаһка ирешсен кыйлган эшең. Нөкәрләреңне һәм табарсың...

— Аблак баба,— диде Акмирза сурәтендәге тутай.— Син са-

вығырсың, аякланырсың, иншаллаһ. Мин дә нөкәрләрем белән кавышырмын. Әмма бер гозерем бар сиңа, баба...

— Тарыкмагыл, тугрысын әйт! — диде хуҗа.

— Мин сабый... Нөкәрләрем дәхи артык яшьтер. Син өйрәткел безне яугир һөнәренә? Савыккач...

— Сараенда Йосыф мирза кылычбазлар асрамыймы?

— Яугирләр күп, әмма синең янда яшәп, сиңа аркадаш булырдек, баба...

— Болай хуш күрдек, Акмирза олан,— диде хуҗа.— Алып кил нөкәрләреңне.

Аяклангач, юл өйрәтеп, Аблак баба яшь дустын озатып калды. Ат менгән дустының шәүләсе офыкка кереп йотылганчы, урыныннан кузгалмады. Әгәр яшь мирза вәгъдәсендә тормаса, аңа берабер зыян килсә, чүл уртасындагы бу алачыкка һичкемнең юлы төшмәс. Бер елкысыз, бер дөясез ул, атна-ун көннән ачыга башлап, киезенә ятып ялгыз башы җан тартачак.

Сөен тутайның ахирәтләре дала белән чүл кушылып аралашкан җирдә, Колынъял дулап, ком эченә кереп киткән тирәдә киез йорт корып, казан асып яшәп ята иде. Алар, әледән-әле икешәр-өчәр җайдак күндереп, югалган тутайны эзли-эзли тәмам гаҗиз булып беткән. Сау-сәламәт, көр күңелле Сөен тутайны күргәч, рәхәтләнеп елаштылар.

Атасы сәфәргә киткәч, Сөен тутай утыз ахирәтен дә дала түренә чакырды; янәсе, алар ат бәйгесе узгаралар. Сәбәп ат чабыштыру түгел иде, яшерен сер әйтү өчен тутай ахирәтләрен иркенгә алып чыкты. Сарайның күзе — мең, колаклары — бихисаптыр, әйткәнеңне түгел, уйлаганыңны да ишетеп торалар.

Дала буйлап ат кыздырып уйнаганнан соң, алар Табанлыкүлгә җиттеләр. Яр чишмәсе янында туктап, Сөен тутай ахирәтләренә сафка тезелергә кушты. Утыз кыз атланган утыз ат җепкә тезеп бастыргандай бер саф булды. Сөенеч тутай, атын саф каршына куеп, өзәңгегә баса төшеп, ияреннән калыкты:

— Ахирәтләрем! — диде ул. — Сез Йосыф мирзаның сөекле кызы Сөен тутай белән ахирәткәчә бер тән, бер җан булып яшәргә ант эчтегез, шул хакмы?

— Ха-ак! Без бергә! — диде кызлар беравыздан.

Тутай янә әйтте:

— Ант эчкәннәр урында кала. Антсызлар өч торык алга чыксын! — Ике җайдак кыз, сафтан аерылып, өч торык чамасы ара калдырып, туктады. Сафның башында торучы Сөембелтай, сүз сорап, камчылы кулын баш очына күтәрде. Сөен аңа ым какты: сөйлә, Сөмбелтай!

— Сөйкемле Сөякле Сөенеч тутай! — диде ишекче кыз.— Болар сиңа буй сындырып, яныңда тез йөгенеп яшәү өчен ихтыяри хезмәткә килгән ике кыз. Утыз ахирәтем булсын, дидең. Кабул кыйлсаң, без хәзер — утыз!

Тутай әйтте:

— Бәс, алдымда Җимбуйлыклы Каранугай ыруының Казаяк тамгалы Карышкан мирза кызы Нәргә тутай торыр? Кайсыгыздыр ул?

Җирән аттагы кыз камчылы кулын күтәрде.

— Сөйләң! — диде тутай. Кыз башлады:

— Җимбуйлыклы Каранугай ыруының Казаяк тамгалы Нәргә тутай мин торырмын, Сөйкемле Сөякле Сөенеч тутай! Минемчөн багышың — балкыш, карашың — каргыш!

— Шәван атта йөрү сиңа төс түгел, Нәргәтай! — диде Сөен. Янда кыздан күзен алмыйча, өстәп куйды.— Сөмбелтай, Комбар атага җиткергел, Нәргәтайга Акбәкәлне күндерсен.

— Башым өсте, йөзем түбән,— диде Сөмбел.

Сөен тутайның карашы икенче кызга күчте. Яңа кыз, яшь кыз бу тантанадан каушаган, телсез калган; ул тиз генә авызын ача алмады. Бу уңайсыз тынлыкны Сөмбел тутай бозды:

— Сайгөле Сөен тутаемыз, бу — ятимә бер кыз баладыр. Төнәген Агабазарда коллыкка сатып торырлар ирде. Ярлыкаң мине, сөякле тутай, базаркәннән мин сатып алдым. Кирәк — үлтер, кирәк — асраң!

Сөен тутай җәһәт кенә Сөмбелгә бакты. Ике-өч ел элек Сөен тутай сүз иярә генә әйткән иде, ахирәтләрем арасында житен чәчле, күк күзле кыз булсайды, дигән иде. Шуны онытмаган Сөмбел. Ул юк-бар кол өчен мал түкмәс.

— Колың Сауфия атлы,— диде Сөмбел тутай.— Мәскәү йөзбашының бердәнбер кызы. Кормыш сугышында атасы үлгән. Анасы Казанда Сафа Гәрәй хозурындадыр.

Сөен тутай янә колиһәгә текәлде. Картаеп бара торган аргамакка атланган сигез-тугыз яшәр бер сабый аңа багып тора. Аның күз карашы хәнҗәрдәй иде. Аксыл-сары, елкылдаулы чәче тап урталай, Киек Каз юлы ясап аерылган, ике күзе күк касәседәй фирүзә-зәңгәр. Кыз әле тулып җитмәгән, сөякчел беләкле, әмма якын киләчәктә, дүрт-биш елдан бу бичара кол кызның гүзәлләр гүзәле булачагын сиземләп буладыр ки... Ахирәт кызлар белән күз йомдырыш уйнаганда Сөен тутайны егерме сигезнең берсе дә җиңә алмый. Кирәк икән, кеше күзенә карап, сәгать буе күзен йоммый тора ала ул. Кызлар аның күңеле булсын өчен генә шулай җиңелгән булып, күз кабакларын алдан йомадыр. Ләкин бу кол кыз Сауфия Сөен тутайның каты карашын күзләре белән озак тотып торды. Хәтәр ярыш иде бу. Ярышта хуҗа тутай белән кол кызы тигез иде. Сафтагы кызлар хафалана, пышылдаша башлады. Ахирәтләр икесе өчен дә җан ата иде, ахрысы. Сөен тутай җиңеләчәген сизде. Җил бу ярышны колиһә файдасына хәл итте. Дала җиле тутайга бәреп исә, Сауфиягә арка яктан иде. Сөен тутайның күзләрендәге дымсулык кипте, яшь килә башлады. Күз кабаклары үзләреннән үзләре кагылып алды, ике күзеннән ике зур бөртек яшь тәгәрәде.

— Ишекчем Сөмбелта-ай! — дип гайре табигый аваз белән кычкырды Сөен тутай. Аның авызыннан мондый хәтәр өн ишетмәгән Сөмбелтай әллә каушады, әллә ялгыш кына, атының ике як бөеренә өзәңгесе белән типте, ярсу ат ыргылып сафтан чыкты; Сөмбелтай, тезгенне каерып, атын Сөен тутай янында туктатты.

— Ләббәй, тутай! — диде ул.

— Сауфия атлы бу кыз балага арандагы иң яхшы атны бирсен Комбар ата!

Арандагы иң яхшы ат Сөен тутайның үзенеке, ерак юлга чыкканда куш итеп алып чыга торган Җөргетай иде.

— Җөргетай? — дип кайтарып сорады Сөмбел.

— Дөрест! — диде тутай.— Җөргене Сауфиягә багышлыйм.

Тутайның бу кылмышын сафтагылар аңламады. Нигә кирәк бу мәгънәсез юмартлык? Сатып алынган кяфирәгә ярамаганмы яудан кайткан Карабаер!

Сөмбел аңлады: Сөен тутай җиңелүеннән нишләргә белми. Бу оятны, бу ачуны басар өчен ул нинди дә булса гадәттән тыш бер эш кылырга тиеш иде.

— Башым өсте, йөзем асты! — диде Сөмбел тутай.— Синең әмерең, минем күнүем!

Чыннан да, Сөен тутайның иң якын ахирәтләре аның җиңелүен онытып, Җөргетайның, берсенә дә тәтемичә, кичә генә сатып алынган кол кяфирәгә насыйп кылынуы кызлар эчендәге көнчелек кортын уятты. Тутай моны сизде, шул кортны басар өчен тагын

бер вакыйга кирәк иде. Сөен тутай атын бер урында бөтереп алды да көчле тавыш белән әйтте:

— Нәргәтай вә дә Сауфия! — диде. — Сез һәрберегез минем белән бер тән, бер җан булып яшәргә ант эчәргә әзерме?

Кызлар әзер иде. Сөен тутай Сөмбел ахирәтенә ым какты. Ант эчү йоласына әзерлек башланды... Суынып өлгергән елкыларга су эчерделәр. Сөмбелтай атларны далага җибәрергә боерды. Ахирәтләр, чыгымчы тайларга тышау салып, атларны иркенгә куйды. Кызларның бер өлеше, чатыр корып, дәстәрхан тәйарларга кереште. Ике кыз ике якка сакка басты. Уенчы кызлар саз, чыңгырак, сорнай, кылкубызларын көйли башлады. Ализәк белән Бадәмгөл Сөен тутайны да, ант эчәргә тиешле кызларны да чишендерә башлады... Сөен тутайның:

— Аллаһ Тәгаләнең үзенә тапшырдык! — дип әйтүеннән һәм кул ишарәсеннән соң уенчылар «Янмас кыз» бәетен башлады.

Сорнайның кискен тавышыннан, шөлдерле чыңгыракның шапылдавыннан куркып, камышлар арасыннан пырхылдап киек үрдәк чыгып очты. Бакалар бер-бер артлы суга чумды. Ялгыз челән дә, сунарын ташлап, дала ягына очып китте... Моңлы көйне бераз тыңлагач, Сөен тутай уртага — мәйданга чыкты. Атлап чыгу түгел иде бу, аккош кебек йөзү иде. Кешегә күрсәтү өчен түгел, ахирәтләре алдында көязләнү өчен түгел, үз рәхәте, күңел ихтыяҗы өчен, онытылу өчен, бу дөньядан азмы-күпме ваз кичеп, үз-үзеңне күзәтү-тикшерү өчен эшләнә бу тамаша... Уенчы кызлар үзләре уйный торган бу көйгә үзләре мөкиббән булып тәэсирләнгән. Сөен тутай алар чыгарган көйгә сихерләнгән, ахирәтләрнең куәсе илә дөньяга чыккан моң күңелләрне богаулаган. Утыз бер кыз — утыз бере тиң сихер эчендә. Сөен тутай ни өчен мәйданга чыкканын оныткан — ул, әкрен-салмак бии-бии, бөтенләй чишенә башлады. Көйнең бер мизгелендә ул, иң әүвәл, болай да нечкә билен өзәрдәй булып торган кошагын чиште. Шул кошак аның кулында елан кебек бөтерелә-уйный. Икенче якка әйләнгәндә — әллә ялгыш, әллә юри ычкындырды — алтын укаларын җемелдәтеп, кошак чатыр ягына очты. Чатыр янындагы кызларның берсе, кошакны алып, кадерләп төреп, алдына салды. Бераз биегәч, тутай күлмәгенең көмеш каптырмаларын берәм-берәм ычкындырды. Тутай бөтерелгәндә чишелгән күлмәк кабарып-җәелеп китте, шулчак Сөен тутай — күлмәге эченнән үзе шуып чыктымы, күлмәкме хуҗасын ташлап, җилгә очты — ул ятак күлмәкчән генә калды. Һавадагы күлмәк, салмак кына җилфердәп, тамашачы кызлар өстенә төшеп кунды. Чәчбавын кай арада чишкәндер, куе кара озын толымнары таралып, гәүдәсен каплаган, шул кара пәрдә — чәч артыннан кызлар тарафына ятак күлмәге дә чыгып очты. Тутайның тәнендә һичнинди кием әсәре юк: колак очындагы алкалар, муенындагы мәрҗән муенса, ике беләгендәге беләзек, бармакларындагы йөзекләр генә. Сөен тутай комга чүгәләде, чәче чүмәләдәй булып, гәүдәсен каплады. Уенчылар ике-өч мизгелгә генә шып туктады. Сулыш алгач, ишетелер-ишетелмәс кенә кылкубыз уйнарга тотынды. Кап-кара чәч чүмәләсенә җан керде. Сөен тутай әкрен генә калыкты, кинәт башын чайкап, чәч болытын артка ташлады. Бер мәлдә аның күкрәкләре, ендек но тасы чагылып алды. Кара чәч белән капланган гәүдә, уенчыларга, тамашачыларга арка куеп, әкрен генә күлгә кереп китте... Ант эчүче кызлар да шушы йола биюен кабатларга тиеш иде. Сөмбелтай ым какты. Уртага Нәргәтай белән Сауфия чыкты. Рәкыс-бию тәмамында, көйнең тиешле урынында алар су коенырга күлгә керде. Алар артыннан, анадан тума чишенеп, барча кызлар да суга чумды. Ул-бу булмагае дип, каравылга куелган ике кыз гына ярда, ат өстендә калды... Табанлы-

күл аларны бик тә сагынган, ул ихтыярсыз, карышмады: коенсыннар гөнаһсыз кызлар, истирахәт алсыннар; ахирәтләрнең чырчуына, су чәчрәтеп, зеңгелтәп көлгәннәренә, күлне айкап йөзгәннәренә су төбендә йоклап ятучы карт җаен уянмасмы!.. Гап-гади бер көн, юкса. Кояш та, камышлар да, су да шул ук, утыз кыз да Аллаһ Тәгалә үзе яраткан адәми зат балалары, Тәңренең бәхетле балалары. Узар гомер, үтәр еллар, язмыш-кыйсмәт бу сабыйларны төрле тарафларга бәрер-сугар. Җәбер-хыянәт, кара кайгы, әче хәсрәт баскач кына алар Табанлыкүлдә су коенганда бәхетлеләрдән бәхетле булганнарын аңларлар. «Булдымы соң ул Табанлыкүл буендагы рәхәтият?» — дип көрсенерләр. Ә хәзер алар өчен бу гадәти йола, антлашу алдыннан су коену, тән сафландыру гына... Судан иң беренче Сөмбел, Ализәк, Бадәмгөл, Татлыбик тутайлар чыкты. Алар артыннан ике кыз чыгып, каравылны алмаштырды. Сактагы кызлар ат өстеннән үк суга сикерде. Сөмбел кушуы белән мәйданчыкка тире чыгарып салдылар, тире өстенә киез көрпә, көрпә өстенә затлы келәм җәйделәр... Судан чыкканда Сөен тутайның аягы астына, күл буеннан келәмгәчә тире җәеп сукмак салдылар. Судан чыгуга, тутай тире сукмакка басты. Татлыбик зур-кытыршы сөлге белән тутайның юеш чәчен корытып сөртте, ике кыз тутайның табаннарын чүпрәк белән киптерде... Мотрибчы кызлар тагын баягы көйне уйнарга тотынды. Сөен тутай тар сукмак буйлап килде дә келәмгә тезләнде. Соңра Нәргәтай белән Сауфия да нәкъ шулай эшләде.

— Мәрхәбә! — диде Сөмбелтай.

Нәргә тутай белән кол Сауфия икесе берьюлы сүз башлады.

— Мәшһүр Йосыф мирзаның кызы Сөен тутай белән ахирәткәчә бер тән, бер җан булып яшәргә ант эчәбез. Бу антымны бозсам, Аллаһ суксын. Сөен тутай ихтыярыннан башка кияүгә чыкмаска, аның гозереннән битәр беркайчан да аннан аерылырга теләк белдермәскә Аллаһ Тәгалә исеме белән ант итәбез!

Мотрибчылар көчлерәк уйный башлады. Татлыбик Сөен тутайга хәнҗәр сузды. Бу — мәрхүм Сөен оланның төсе, затлы хәнҗәр иде. Сөен тутай акрын гына сузылып хәнҗәрне алды, догамы, әфсенме укып, тиз-тиз талпынып, хәнҗәр очы белән ике күкрәгенә җәрәхәт ясады. Борылып карамыйча гына, хәнҗәрне Татлыбиккә бирде. Уенчылар бәрәбаннарга катырак орып, кылларга ныграк чиртеп, сорнайга көчлерәк өреп уйный. Тез өстендәге ике кызга Сөмбелтай ишарә ясады. Нәргәтай — сул имчәктән, Сауфия уңысыннан сызылып чыккан канга иреннәрен тигезде.

— Йотыш кирәк,— диде Сөмбелтай.

Ант эчүче ике кыз, тамчылап, Сөен тутайның канын йотты. Кызлар күкрәктән аерылганда Сөеннең тәнендә бернинди кан тамчысы да, бернинди җөй дә күренмәде.

Шулчак Сөмбелтай әйтте:

— Менә хәзер сез — Сөйкемле Сөяк Сөен тутайның ахирәтләре! — диде.

Сөмбелтай чакыруы илә, ике сакчыдан башка, ахирәтләр чатырга керде. Чатыр күләгәсенә җәелгән келәмнәр өстендә бай дәстәрхан: салкын кымыз, салкын буза, йөзем суты, җиләк-җимеш, казылык вә нан-ләвәш әзер тора.

Бик күңелле узды бу мәҗлес. Сөен тутайны танырлык түгел иде. Ул җырлады, биеде, рәхәтләнеп «Йосыф» кыйссасын тыңлады, бусын Сөмбелтай гаҗәеп оста башкара. Сөен үзе дә мәшһүр дастаннардан кыйтгалар әйтте. Мәҗлес азагында Сөен бик тутай, аягүрә торып, тантаналы аваз илә болай диде:

— Ахирәтләрем! Ерак сәфәргә әзерләнегез. Өч көннән, ягъни шимбә көн, без, куш атларыбызны алып, Ирәмбагны эзләргә чыгабыз.

Кызлар ашаудан, уеннан туктады. Бу бик зур яңалык, көтелмәгән хәбәр иде. Сынар өчен генә әйтмәдеме икән тутаебыз, дигәндәй, ахирәтләр Сөен тутайга, аннан бер-беренә караштылар. Әмма Сөеннең чырае үтә дә җитди вә тәвәккәл иде.

— Ялгыш әйтмәдем,— диде тутай.— Бөек максатым — рәхәтият иле, гүзәллек бакчасы Ирәмбагны эзләп табу. Бар ул җиһанда Ирәм бакчасы, бар. Иншаллаһ, ахирәт җәннәтенә өлгерербез. Суфилар сүзе: бу дөнья оҗмахында яшәп калыш лаземдер. Ирәмбагны мин табармын, табармын вә мәңгегә шунда калырмын... Сәфәр ерак, озын-озак булыр. Курыкканнар, теләмәгәннәр хәзер үк әйтсен: андыйлар калыр. Үпкәм юк аларга, Аллаһ шаһит. Әмма юлга чыккач, беркем дә кире борыла алмый. Уйлагыз!

Кызлар-ахирәтләр уйлап тормады, бөтенесе дәррәү дәрт белән:

— Без бергә! — дип кычкырды.

— Аллаһ Тәгалә хәерле кылсын! — диде Сөекемле Сөяк Сөен тутай.— Бәс, һәркем мәргәнлеккә өйрәнергә, кылыч айкарга, аркан-буганак ташларга, пычак уйната белергә тиеш. Бу эшкә мин маһир бер кылычбаз ялладым. Дала түрендә, аулакта ул безне яугирлеккә өйрәтер. Хода кушса!

— Без бергә, тутай! — диде ахирәтләр.

Менә шуннан соң алар, сарайдагылардан яшереп кенә, сәяхәткә әзерләнә башлады.

Сөен тутайның көр күңел белән йөрүен сарай бикәләре үзләренчә юрады. Алар сүзен сүз итеп, Йосыф мирза сырхау кызы белән аталарча, түрәләрчә каты сөйләшкән, кызын бизәнеп-ясанып, күңел ачып яшәргә кү'дергән. Димәк, Сөен тутайга озакламый яучы-димче халкы килә башлар, иншаллаһ. Ихтимал, бу турыда мирза үзе дә якыннарына әйткәндер; якыннары үз якыннарына, тегеләре хатыннары колагына төшергәндер. Маллар кышлауга кайткач, Йосыф мирза кызы Сөен тутайның туе була, дигән хәбәр тиз таралып, тутайның үзенә дә килеп иреште.

Әмма иртәрәк куанган икән әле халык. Көннәрдән беркөнне Сөен тутай белән утыз ахирәте дала түренә ат юырттырырга киткәннән әйләнеп кайтмады. Бер тәүлек көттеләр, ике көн узды. Сарайда хәвефләнүчеләр булмады. Сөен тутайның сәер гадәтләренә күнеккән бикәләр дә, сарай агалары да, араннар хуҗасы Комбар ата да:

— Тутайның дала эчендә куна калгалаганы күп булды, кайтыр! — диделәр.

Унынчы көнне дә кайтмагач, сарай эченә шом иңде. Сораштырдылар, як-якка чапкыннар күндерделәр; кәрванчы, юлаучы, чабан-көтүче халкыннан, күчүче-узгынчылардан тәфсилләп белештеләр — юк, югалганнарны күрүче, белүче булмады. Утыз бер җайдак кыз, дала эченә кереп, җир йоткандай юкка чыкты.

Йосыф мирза сәфәр-сәяхәттән кайткач кына мәсьәлә бераз ачыкланды. Сарайда, тәхет-диван ханәсендәге көрсидә «Йосыф мирза атакаема» дип язылган хат ята иде. Хат, төрелеп, читләр ачып укымаслык итеп, җеп белән бәйләнгән, җепкә балавыз сылап, Сөен тутайның балдак мөһере басылган, соң очы балык җилеме белән ябыштырылган иде. Мирза, мөһерне ватып, җепне өзеп, балык җилемен куптарып, хатны сүтте.

«Аллаһ Тәгалә гыйнияте илә, тәкъдирем кодрәте берлә ун олыслы Нугай иленең олуг мирзасы атам Йосыф түрәгә,— дип башланган иде хат.— Моңарчы итагатьтә булган кызың Сөен тутай бүген шайтан котыртыгы белән түгел, үз котыртыгына үзе котырып, атасы сүзеннән чыкты. Сәүгеле атакаем, Аллаһ хаккы өчен мине эзләмә. Син ошбу сатырларне укыганда мин ахирәтләрем илә ерак сәфәрдә булырмын. Насыйп булса, бер кайтырмын. До-

гагыздан ташламагыз. Хода хаккына кызыңны ярлыка, атакай! Ошбу мәктүп һиҗрәтдин соң туккыз йөз дә утыз биш сәнә узгач, Күсе Елында яз чәлләнең уникенче көнендә бителде. Бу битекне Йосыф мирза кызы Сөен бик тутай язганлыкка шаһит итеп, балдак мөһереми сугам».

Хатны укыгач, мирза ике төрле уйда калды: кыз бала харап булмагае, юл өсте тулы хәрамилар-юлбасарлар... Хәер, Сөен тутай югала торган бала түгел, исән-сау кайтыр, Аллаһ боерса!

Шулай итеп, олуг мирза Йосыф Сөен тутайны эзләтмәде. Кызы ничек тели, шулай булсын.

Чүл түреннән чыгып, ахирәтләр белән Табанлыкүл янында бер-ике көн истирахәт кичергәч, Сөен тутай кинәт кырысланды. Аның кызлары як-яктагы кышлаулар, шәһәрләргә барып, базар сөйләменә колак салып, шымчы булып йөреп кайткан иде. Елкыдөя көтүен Исмәгыйль мирза кешеләре Ак Урданың бу як җәйләвенә куган. Хәбәр өстенә хәбәр өстәлә торды: җәйләү җыеннарында Исмәгыйль мирза, бәйгеләрдә катнашып, яңа аты Чуерташ белән алга чыга башлаган. Имештер, ул, ягъни Исмәгыйль мирза, Чуерташны йөз алтын, биш елкы, өч дөя биреп, Чүлбабадан алган. Әмма ни сәбәпле соң Чүлбаба бу бәйгеләрдә үзе катнашмый. Анысын беркем дә белмәде... Сөен тутай ачу белән әйтте:

— Чуерташ түгел ул атның исеме — Бүзтарлан. Борынгы бабам Идегәйнең Бүзтарланы ядкәренә шулай аталган..."

Бу сүзләрне әйткәндә Сөен тутай хәнҗәр үткенләп утыра иде, ул кинәт калыкты, сәбәбен-сылтавын аңлатмастан, кап-кара ике толымын кисеп ташлады. Чулпылары, авыр көмеш тәңкәләре, чәч баулары белән дүрт кадаклык йөктән котылгач, Сөен тутайның башы алга иелә төшкәндәй булды. Аһ итте кызлар. Бары тик берәү генә тыныч иде — Сөмбелтай. Башка кызлар айныганчы, Сөмбелтай да толымын кисеп атты.

— Кияүгә чыгасым булса, тутаебыз шулай фәрман кылса, биш елда чәч янә үсеп җитәр!

Сөмбелтайның бу сүзләре кызларга да тәэсир итте: ахирәтләр, чыр-чу килеп, бер-берсенең толымын кисә башлады. Чыр-чу — көлүгә, көлү бер каһкаһәгә әверелде. Сөен тутай каршында алтмыш толымнан тау өелде. Кемдер чын күз яшьләре белән елый, дөнья бәһасе торырдай толымы белән саубуллаша, кемдер авыр-калын йөктән котылуына җиңел сулый.

— Карагыз! — диде тутай.— Монда йөз-йөз егерме кадак көмеш бар. Ул чулпыларны, филисәләрне тагарга чәч юк. Димәк ки, мондагы көмеш безгә хәзинә булачак. Чәч булмагач, алка-сырга нигә кирәк!

Ул үз алкаларын, беләзекләрен салып, күнтубалга ташлады. Кызлар да шулай эшләде. Тубал арты тубал затлы мал белән тулды.

Бары бер кыз гына табаны баскан урыннан кузгалмады.

— Син, Сауфия ахирәт? — диде тутай.

Сөмбелтай, ялангач хәнҗәрен тотып, Сауфиянең ике толымын урап, Сөен тутайга бакты. Сауфия бичара, тезенә төшеп, башын комга тигезеп, елап-сыкрап сүз башлады:

— Тутакаем, мирзабикәчкәем, зинһар, миннән ир ясамаң. Калсын чәчем — анам төсе. Арагызда булсын һич югы ике толым. Табаныңда туфрак булаем, тирләгәндә этрәк булаем, ятканыңда түшәк булаем, кисмә чәчемне...

— Хуш! — диде тутай.— Шулай хуп күрдек. Калсын!

Сөмбел, кулына уралган толымны теләр-теләмәс кенә сүтте дә, нидер мыгырдап, читкәрәк китеп, үзенә эш тапкан булды.

Хәнҗәрен кынысына тыгып, Сөен тутай әйтте:

— Сафланыгыз! — диде.

Барча кызлар бер булып, кылдай мәйдан тарттылар. Җиңеләеп калган башлар тик тормый, алак-ялак боргалана.

— Һәркем алсын үз толымын! — диде тутай.— Яу чапканда толымнар арка як муенга куелсын. Дошман кылыч орса, үз толымың сакласын. Кирәк булыр алда... безнең баштан чыккан ошбу баулар.

Ахирәтләр толымнарын алды. Иң соңыннан үз толымнарыннан аркан ишеп, Сөен тутай да биленә урады. Бу эшеннән ул бик канәгать булды һәм янә әйтте:

— Колакларыгыз торсын,— диде.— Бу сәгатьтән мин Сөен тутай түгелмен. Мин — Акмирза.

Ахирәтләр янә аһ итте, ваһ итте, бары берәү тын калды — Сөмбелтай. Ул тутайның ни теләгәнен бик тиз аңлап алды:

— Бу сәгатьтән мин Сөмбел тутай түгел, мин — Таһир мирза торырмын! — дип кычкырды.

Сафтагылар моны уен санап, һәрберсе үзенә берәр егет исеме сайларга тотынды. Ализәк тутай — Галибәк, Бадәмгөл — Баһрам булды. Келәмче Татлыбик Бикбулатка әверелде. Бары тик Сауфиягә генә үз исеме калды... Ахирәтләр исемнәрен генә түгел, тышкы кыяфәтләрен дә үсмер егетләрчә үзгәртте. Сауфиядән башка һәркайсы, күнолтан итек кигәч, тупас йоннан баскан ябынча бөркәнгәч, ат менеп, камчы сабын бөергә терәп, базык тавыш белән сөйләшә башлагач, гел дә хәтәр егеткә охшап калдылар. Бу эштән бар да канәгать иде. Шушы кыяфәт илә алар далага якын базарда мул итеп казы, корыт, кызыл эремчек, каклаган ит, тоз, капчыклап он-ярма сатып алды. Корал-ярак базарыннан кылыч, сөңге, ук-җәя юнәттеләр. Шул тәгам вә яракларны төяп, алар далага кайтты, даладан чүлгә булды юллары.

Чүл бабасы Габдел Каюм, офыкка багып, яшь дустын көтте. Зарыгып көтүе озакка сузылгач, ул хафага төште. Хафасы кара шомга әйләнде. Соңгы тапкырында ул, офык белән чүл тоташкан җирдән сузылып чыккан кәрванны күргәч, кычкырып әйтте:

— Затлы сөяк Акмирза сүзендә торды, иншаллаһ! — диде.

Бабаның сыңар күзеннән сыңар яшь чыкты. Чүл җиле шулай шаяргалый кайчак. Аның куанычы — олы куаныч. Ятим карт өчен сынык нан юк, эчәргә чәе төкәнгән. Чүл уртасында адәми зат күрү дуадак Аблак өчен куаныч кына түгел, бәхет... Аблак, казан асып җибәрде дә, җәяүләп, кәрванга каршы китте...

Чүлбаба Аблакның алачыгын уртада калдырып, янәшәгә Акмирза тирмәсен кордылар. Калган «егетләр» өчен киез йортларны урам-урам итеп тезделәр. Баксаң, кечек кенә бер авыл хасил булды. Бу авылның хуҗасы — аксакал Аблак баба... Тирмәләр корылгач, атларны кое суы белән сыйлагач, утлауга куйгач, тәгамнарны салкын базга урнаштыргач, мәҗлес җыелды.

Аблак баба яшәреп китте сыман. Ул житез-кәр күңелле. Ул кырыс вә эшлекле. Кичләрен җыру-дастаннар тыңлап күңеле нечкәрә торган бабаны көндезләрен алыштыралармыни!

— Яу иренең һөнәре авыр ул, оланнар. Аның өчен хәзер үк ризыкны киметергә, билбау-кошакларны кысарга, әлсерәгәнче күнекмә ясарга, атна-ун көн сусыз торып карарга кирәк. Озын юлда, бөртек тәгамсыз, тамчы сусыз калгач, атыңның муенындагы тамырын ачып, ике-өч касә канын эчеп, ничек ач үлемнән котылырга була — аны да үгрәнерсез. Җәрәхәт алып сөрлеккән аттан ничек уңай егылырга, ыргып чапкан атка ничек атланырга — үзем күргән, үзем белгәннәрнең барысын да үгрәтермен!

Аблак баба белән ахирәтләр яу һөнәренә өйрәнергә чүлгә-далага киткәч, тирмәләр янында Сауфия тутай кала, ул утыз үс-

мергә вә карт остазга аш пешерә.

Бик авыр иде бу хәят үсмерләргә. Аблак баба һичкемгә тынгы бирми. Чеклә дими, җил-тузан дими, оланнарны башлап — өчәр сәгать, соңра арттыра барып, сигезәр сәгать интектерә. Сыдырылган тиреләрне, суелган бармакларны ялый-ялый, кызлар остаздан яшереп кенә елый. Эчләре суырылды, яңаклары эчкә батты. Кичке уен-мәҗлесләргә аларның көче калмый, шәфәкъ баткач ук, алар бер тустаган су эчә дә, егылып йокыга китә. Йокыга китеп тә өлгермәгән кебек, иртүк аларны быргы, бәрәбан тавышы уята:

— Торыгы-ыз! — дип Аблак остаз кычкыра.— Калкыны-гы-ыз! Таң салкынында эшләп калыш кирәк!

Өч ай булды дигәндә кызларны танырлык түгел иде. Кылыч сөңге сабы, аркан тотып, куллар — сөялләнгән, тавышлар — карлыккан, аяк атлаулар үзгәргән. Сауфия шуны үзалдына искәрде: тутайларны тутай димәссең, аягүрә торганда да алар тезләрен, балтырларын кушмый, ботларын аерып баса.

Бераздан, Аблак баба янында Сауфия белән Бикбулат-Татлыбикне калдырып, егерме сигез «егете» белән Акмирза каядыр сәфәр китте. Аларның озатып кергәч Сауфия әйтте:

— Чын яугирләр кебек! — диде.

Бикбулат кызның кабыргасына төртте; тегесе, хатасын аңлап, ике учы белән авызын каплады.

— Чын яугирләр булгач! — диде Бикбулат.

Аблак баба мыегы астыннан гына елмайды.

## Җен җегетләре

Ун санлы Нугай илендә хәбәр таралды. Имештер-мимештер түгел, күргән кешеләр сөйли: дала буйлап хәтәр ләшкәр йөри. Җенле атларга атланып, җенле җегетләр — хәтәр яугирләр барымталап мал ала икән. Мал белән бергә мирза хатыннарын, бай бикәчләрне дә әсир итеп ала икән. Үзләренеке итеп тотканнан соң, ул хатыннарны Мәвәрәәннәһер базарларына илтеп коллыкка саталар икән...

Ун санлы Нугай илендә хәбәрләр йөри. Җенле атларга атланган ул җенле җегетләр ятимнәргә, бичараларга ярдәм итә икән, йортсызга — йортлык киез, шаңгырак-киерге ташлап китә, атсызга елкы калдыра, кеше малын талаучы барымтачыларга каршы хәтәр орышалар икән, диләр.

Төрле сүзләр йөрде дала-җәйләү буйлап, әмма җен җегетләре эчендә Йосыф мирза олысының иң затлы яшь тутайлары икәнен берәү дә белмәде. Җен җегетләрен тотарга олы гаскәр тәртипләп, үлемнән курыкмас башкисәрләр күп тапкырлар яуга чыкты, поскын ләшкәрләр куеп та аларны сагаладылар. Сак куйган җиргә җен җегетләре килми; поскын ләшкәр, аларны сагалап, көн утыра, төн утыра, атна-ун көн утыра да буш кул белән кайта. Ул арада җен егетләре, искәрмәгән бер җәйләүгә төшеп, барымтачыларны кырып, малларны кире куып, хуҗасына тапшырып, юк булганнар. Алар Исмәгыйль мирзаның вә аның куштаннарының араннарындагы елкыларны да кире куып киткәннәр. Ни гаҗәп, җен җегетләре, ай күрде, кояш алды дигәндәй, бер кунышта ике көн тормый кубып китәләр дә эзсез югалалар. Әле генә аларны Җаекта күргәннәр, күп тә узмый — җен җегетләре, Идел тамагына барып чыкканнар да. Касыйм ханның бер өлеш малларын куып алып киткәннәр. Әрвахлардай кинәт пәйда булып, барымтачыларның каравылын кырып, малларны хуҗаларына кайтарып, игелекләре өчен рәхмәтне дә тыңлап тормаенча, өермә булып юкка чыга икән җен җегетләре.

Исмәгыйль мирзаның күңеленә шом төште. Шом башта, салкын

боз булып, күкрәк авызында туңдырып торды, аннан соң салкын шом кайнар уч дулкынына әйләнде. Даладагы вак җәйләүләрдән, нәсел-нәсәпсез, яклаучысызларның елкысын-дөясен барымтага куып, күпләп җыелгач, йөзәре-меңәре белән ул әлеге малларны Мәскәүгә куа, Василий кенәзгә, боярларга сата. Идел тарафындагы ярминкәгә дә иң күп елкыны Исмәгыйль мирза кешеләре китерә. Каян килә ул елкы көтүе Исмәгыйль мирзага — алучылар сорашып тормый, әмма кешеләр белә: барымтага алынган маллар алар. Болай барса эшләр, Елмаймас мирза елкы белән генә түгел, адәм белән дә сату итә башлаячак, диләр. Яу нәкәсе Исмәгыйль мирза чит-ят адәмнәрне генә түгел, үз туганнарын да базарда кычкыра-кычкыра, селки-болгый сатачак, диләр... Әмма Айга кулы җиткәндәй кылануччы Исмәгыйль мирзаның да кикриге шиңде. Соңгы айларда аның әтрәман егетләре барымтадан буш кайткалый. Хәтта аның үз малларын да куып киткәләделәр. Бу җен җегетләре эше иде. Барымтага алган соңгы елкыларны Ерак базарга алып барып, күп табыш казангач, шул табышны юып, рәхәт бәйрәм иткәч, Исмәгыйль мирза җен җегетләрен тотарга, кырырга, тереләй җиргә күмәргә үзе чыгачак иде. Җен җегетләренең башлыгы Акмирзаны ул, тере килеш тотып, Мәскәүгә, бөек кенәз Всилийга коллыкка сатачагын уйлап, рәхәт кичерә...

Идел аръягына елкы куып баручы гаскәр башында Исмәгыйль мирза үзе иде. Исмәгыйль мирзаның Самар кичүен, Җигүле тауга таба бихисап елкы куып барганын белгәч, җен җегетләренең башлыгы Акмирза үз гаскәрен дүрткә бүлде. Һәр бүлектә җидешәр җен җегете егерме-утыз данә яхшы ат белән дүрт якта берьюлы тузан куптарырга тиеш иде. Тузан туздырыр өчен шул даладагы ун мең башлы куй көтүен дә файдаланырга булдылар... Кичүгә бер күчем ара калгач, Исмәгыйль мирзаның төп гаскәре кечкенә урманга кергәч, шушы дүрткә бүленгән җен җегетләре үз эшләрен башкарырга тотынды, елкыларны, сарык көтүен куып, тузан куптара башладылар. Акмирза, өч ярдәмчесе белән маңгай якта торып, Исмәгыйль мирза каршына чыкты. Аларның авызборыны кара чүпрәк белән каплаулы иде.

— Тукта-а! — дип кычкырды Акмирза.— Кузга-алма-а!

Исмәгыйль мирза гаскәре туктады.

— Кем син? Юлымны кисәргә нә хакың бар?

— Без — җен җегетләре! — диде Сөен тутай.— Мин Акмирза!

Исмәгыйль мирза, билбавыннан табанча суырып чыгарды, шундук аткан да булыр иде. Әмма куаклар артындагы мәргән ук атты, мирза кулындагы утчагар-табанча чәчрәп очты. Исмәгыйльне курку биләде.

— Кузгалма, мирза! — диде җен җегете.— Сез урауда! Әнә кара, җен җегетләрем һәр куактан һәр кешеңә унар ук төбәгән!

Юлның бер ягында Сөмбелтай, икенче ягында Нәргәтай бик күп куакларга бәйләгән бауны тартып-тартып алды. Курыккан Исмәгыйльгә куак арты тулы укчылар сыман тоелды.

— Минем бер ишарәм җитә,— диде җен җегете Акмирза.— сездән иләк кенә калачак... Әнә, кара, Муса казыйның мордар баласы Исмәгыйль мирза, минем йөз меңлек ләшкәрем офыкны томалап килә...

Исмәгыйль мирза да, аның әтрәман-куштаннары да дүрт якта дүрт офыкны томалаган тузан болытын күреп коелып төште.

— Исмәгыйль мирза, елкы көтүеңне, астыңдагы атны — Чулбабасы Аблак картны үтереп алган мәшһүр Бүзтарланны да ташлап, кире борыл!.. Шарт хәзер үк үтәлмәсә, гәүдәләрегезне туфрак белән тигезләр өчен өстеңнән ун мең елкы җибәрәчәкмен! Малыңмы, җаныңмы?

Акмирза янындагы җен җегете быргы кычкыртты, дүрт яктан дүрт быргы шушы хәбәрне кабатлады.

— Бер, — дип саный башлады җен җегете.

Исмәгыйль мирза атлардан төшәргә ишарә бирде. Ул иярдән төшүгә, кемдер әче итеп сызгырды, быргылар уйный башлады. Иярләре бушаган атлар дала ягына ыргылды. Исмәгыйль мирза белән җәяүле каравыл гаскәре урманчык уртасында нәүмиз булып калды. Җен җегетләре бөтен елкыны далага куып алып китте.

Шулай итеп, Исмәгыйль мирзаны да төп башына утыртучылар табылды: ул ярминкә юлыннан үз җәйләвенә җәяү кайткан, ди... Хурлыклы бу хәбәр бермә-бер арттырылып, Исмәгыйль мирзаның үзегенә үтәрдәй мыскыллы сүзләр белән укмашып, телдән-телгә, җәйләүдән-җәйләүгә күчеп йөри башлады.

Байтак җир киткәч, елкы явын дала уртасында туктатып, җен җегетләре малларны иркенгә куйдылар да болай киңәш иттеләр. Малларны шушы җәйләүдә калдырып, як-якка хәбәр таратырга: таланган хуҗалар үз малларын, үз тамгаларын танып, алып китсеннәр.

Аблак баба хакы булган елкылар белән берничә дөяне куып, җен җегетләре чүл эченә кереп юк булды.

Каза күргән малчылар дала эченә килеп, таралып, утлап йөргән елкыларын алып китә тордылар. Азакта далада бер-ике ат, ялгыз дөя генә чемченеп калды.

Яшь яугирләрнең исән-сау кайтканнарын күреп, Аблак баба бик куанды. Бикбулат-Татлыбик белән Сауфия кыз да чамасыз шат иде. Аблак баба иң беренче итеп Бүзтарлан белән күреште. Мәхлук димә — ат та, хуҗасын күргәч, дәртле кешнәде. Аблакның кытыршы учларын иснәде, ялады. Чүлбабаның күзендә яшь бөртеге ялтырады. Ялтырады да юк булды, аны Бүзтарланнан башка бер җан иясе дә күрмәде, яшь бөртеге комга төшеп яшеренде. Хуҗа бабай Бүзтарланның тезгенен Сөен тутайга тоттырды да әйтте:

— Алың! Бүзтарлан синең мал! — диде.

— Ә-йа-а,— диде тутай-егет.— Бу ни кылмышың, Аблак баба?

Хуҗа кеше, бәхәскә урын калдырмаслык итеп, кискен әйтте:

— Елкы — синең мал! Ал, Акмирза балам!.. Миңа ун баш бия белән алты дөя җиткән. Кандагаем тузган,ияр менәр заман узган!

Зур җиңүне өч көн бәйрәм иткәннән соң, җен җегетләре тагын яуга-ауга китте.

Җаек белән Илек сулары кушылган җирдә барымта кайтарганда аларның юллары уңмады. Барымтачы ирләр күбрәк иде, ахирәтләр кире борылырга мәҗбүр булды. Барымтачылар аларны куа чыкты. Баһрам мирза аты алган Бадәмгөл тутай бу сугышта һәлак булды. Бадәмгөл ул көнне арка як муенына чәч толымын урамаган, барымтачы ир аның муен сеңерен чабып өзгән... Батыр ахирәт Бадәмгөл тутайны бик озак бузлап-егълап, олылап җирләделәр.

Шулай кайгы эчендә йөри торгач, алар бер кунышка туктады: далада чатыр корырлык түгел, каты җилдә атлар да көчкә басып тора иде. Куныш хуҗасы аларга ятак урын, кымыз биреп, казаны белән ит пешертте. Куныштагы башка юлаучылар, шәүлә кебек өнсез-сүзсез егетләрне күреп, чыш-пыш сөйләшә башладылар. Бөтен куныш йортка, куныш йорттан бөтен кышлакка сүз таралды: атаклы җен җегетләре Ташбәргән бидә кунакта икән...

Акмирза да, җен җегетләре дә ит-кымыздан соң аерым тирмәдә бик каты йоклый иде. Ни сәбәптәндер, Сөен тутай уянды. Аның янында кемдер бар, караңгыда шул «кемнеңдер» еш-еш сулаганы ишетелә.

— Таһир, синме? — диде Сөен тутай.

Еш сулаучы «кемдер» кайнар сулышы белән пышылдады:

— Таһир түгел.— диде.— Бу мин, куныш хуҗасы Ташбәргән би кызы Айсөлек.

— Нә кирәк сиңа, Ташбәргән би кызы Айсөлек? — диде Сөен тутай.

— Бөтен куныш халкы сүли, син җен җегетләре патшасы Акмирза икән! Мин сине төшемдә күрдем. Зөләйхадай мин сәга гашыйк. Кич утырып сәга хат яздым. Мә!

Сөен тутай елмайды, караңгылыкны капшап хатны тотты. Айсөлек ике куллап Сөен тутайның хат тоткан кулына ябышты. Би кызының кап-кайнар бите Сөен тутайның беләгенә ятты. Егет кешегә бу кылмыш рәхәт булыр иде, яшь кызның бу хәрәкәте Сөен тутайда тартыну хисе уятты; ул, имәнеп, кулын тартып алды да әйтте:

— Хуш! Иртәгә, яктыргач укырмын! — диде.

Янә Айсөлекнең кайнар пышылдавы ишетелде:

— Син мине үзең белән алып кит, Акмирза! Мәга үләнсәң, атам сине хур итмәс. Байтак бирнә бирер... Үләнмәсәң дә, мин сәга ябышып китәм. Син орышта үлсәң, мин зәһәр эчәм. Безнең хакта дастан әйтерләр. Акмирза белән Айсөлек җырын тыңлап бөтен халык егълар...

Сөен тутай Айсөлекнең хыялларын өзеп әйтте:

— Хуш! Яктыргач, йөзеңә баккач сөйләшербез! — диде.

— Хәзер үк чишенимме соң? — диде Айсөлек.

Кемдер пырхылдады, кемдер гырлый башлады. Тагын кайсыдыр, тыйлыгып-тыйлыгып, ябынча астында көлә. Бусы — ишекче Сөмбелтай-Таһир булды, ахрысы. Хуҗа кызы, кыргый мәчедәй, ишек ягына сикерде, ялгыш кемнеңдер аягынамы, кулынамы басты: «Ай, кем ул?» — дигән тавыш ишетелде. Тирмә киезе ачылып-ябылды, Айсөлек юк булды. Иң беренче Сөмбелтай, ябынчасын ачып: «Ай, үләм!»— дип кычкырды. Башкалар да аңа кушылып көлә иде. Сөен тутай тиз аякланды.

— Җәһәт булыгыз! — диде тутай. Аның тавышында тамчы да көлү әсәре юк иде.— Хәзер бөтен адәм безне тамаша кылырга җыелачак. Ихтимал, Ташбәргән би Исмәгыйль мирзага хәбәр дә салгандыр. Төнлә ике җайдак чыгып чапты.

Йөзгә хәтле санаганчы, җен җегетләре иярдә иде. Йокламаган да диярсең. Ташбәргән би таш йортыннан атылып чыкты да ай-вайлый башлады:

— Йортым хуш булмадымы, ашым шифа булмадымы? — дип сөйләнә-уфтана, Сөен тутай тезгенен тотып, икенче кулы белән өзәнгесен учлап, кунакларны калырга-сыйланырга кыстады.— Бәйрәм дәстәрханы әзерлим. Табын ташлап, мине рәнҗетмәң...

— Кунышыңа, сиеңа рәхмәт.— дип, җен җегетләре — син күр дә мин күр — очты-китте.

Ташбәргән бинең кызы Айсөлек, таш йорт болдырына басып, кул изәп калды.

Җан-фәрманга ыргып чапканнан соң, эз югалтыр өчен алар, кирегә борылып, килгән эздән кунышка таба йөрде. Аннан, янә борылып, иске эзгә төшмичә, ян-якка, чүлгә керделәр. Байтак баргач, атларын салмак адымга куеп, бераз хәл алдылар. Кызлар, Акмирза белән Айсөлекнең мәхәббәте турында сөйләп, иярдән тәгәрәп төшердәй булып көлешә. Сөен тутай гына моңсу. Дала тоткыны булып туган ул бичара кызның хыялыннан нигә көләргә? Җен җегетләренә кызыктыр, әмма Айсөлек атасы Ташбәргән бинең таш йортында мәхәббәтен, үз Мәҗнүнен көтә. Ул Таһирын, Йосыфын көтә, һич югында аның сөйгәне җенле җегетләр падишасы Акмирза булырга тиеш... Сөеннең моңлануына икенче олы сәбәп бар: Бадәмгөл тутайның һәлак булуы. Әрәм булды гүзәл

кыз, тугры ахирәте. Сабыйлык белән уйнап башланган яугирлек һөнәренең уен түгел, кан-үлем белән бәйле икәнен ул чабык муенлы Бадәмгөл мәетенә карап бузлаганда аңлады. Димәк, һәр ахирәтне, аның үзен дә һәр адымда үлем сагалый... Баксаң, рәхәт көлүче бу ахирәтләр үзләре дә нәкъ Айсөлек хәлендә бит, аларның эчендә дә Айсөлек утыра. Утыра, ләкин сиздермиләр генә.

Тагын бер мәхәббәт мажарасы Сөен тутайның уй-хыялларын тәмам үзгәртте... Соңгы сәфәрдән кайтып килгәндә, хәл җыяр өчен, алар бер бинең кунагы булды. Хуҗа би аларны каршы алырга үзе чыкты. Каршысында затлы сөяк мирзабәйләр ат биетеп торганын күргә. Конар би дәстәрхан тәйарлатты: абруйлы, дус мирзаларын чакыртты. Яшь мирзабәйләр белән күңел ачып, кымыз-буза коешып утырдылар. Шулай төн ката күңел ачканда Акмирза кыяфәтендәге Сөен тутайның күңеле борчыла башлады, нидер аңа комачаулык кыла, нәрсәдер аны бимазалый. Хөрмәт йөзеннән хуҗа би аны абруй күнчегенә утырткан иде, шул күнчекме аның урынын җайсызлый? Юк, җайсызламый, күнчектә утыруы бик тә рәхәт. Әллә эченә бер-бер аш ярамадымы? Юк, хуҗаның кымызы яхшы, ризыгы татлы... Һәм, ниһаять, ул төшенде: аңа кемдер озаклап, төбәп карап тора кебек, шул билгесез караш аны борчый. Табындашларына сиздермичә генә, ул әтрафка күз ташлаштыргалады. Дәстәрхан өендә аңа төбәп караучы кеше күренмәде. Сөен тутайга каршы диварга келәм эленгән. Келәм фарсы осталарының кулы белән эшләнгән чукъ гүзәл келәм иде. Келәмнең уртасында — зәңгәр болында кызгылт чәчәк бар. Әлеге чәчәк аңа карый иде. Сыйлаучы-кыстаучылар аның чәчәккә булган игътибарын өздe, тора-бара серле чәчәкне ул онытты. Әмма чәчәк багышы аны янә үзенә суырды. Димәк ки, зәңгәр келәм уртасындагы чәчәктә тишек бар, шул тишектән, аны йотардай булып, баядан бирле текәлеп кемдер аңа карап тора. Ихтимал, келәм диварының теге ягында бүлмә бар. Ул кемдер бит әле? Исмәгыйль мирза шымчысы булса? Мәҗлес тарала башлап, күрше мирзалар хуҗага, кунакларга рәхмәтләр укып, дога кылгач, йоклар алдыннан ат чаптырып, корсак шиңдереп кайту сылтавы илә Акмирза Таһир белән әлеге шикле караш турында киңәшмәкче булды. Конар би бу йөреп керешкә үзе катнашмады. Иптәшкә-сакка дип, үзенең дүрт нөкәрен күндерде. Сөен тутай Бүзтарланга атланып алда чаба иде. Сөмбелтай белән тигезләшкәч, ул келәмдәге тишек чәчәк хакында әйтте. Бер дә исе китмәенчә генә, Сөмбелтай болай диде:

— Кем булсын анда? Тагын бер яшь кыз яки, маена-канына чыдаша алмыйча, мажара котеп, ут йотучы берәр бикәчтер! — Сөмбелтай атының тезгенен бушатты. Урманчыкка кереп бераз баргач, кемдер Бүзтарланның башыннан тотты. Кара бөркәнгән әлеге зат, атны җитәкләп, урман эченә алып керде. Анда кечкенә юлчатыр корылган иде. Арттагы нөкәрләр дә, ахирәтләр дә, боларны күрмичә, чаптырып узып китте. Сөен тутай кылычының сабына ябышып, алга таба ни мажара булыр икән дип көтә. Кара бөркәнгән кеше әйтте:

— Зинһар, Тәңре хакы өчен җәяүлән! Сине менә бу чатырда көтәләр!

Сөен тутай җиргә сикерде. Бөркәвечле адәм Бүзтарланны тотып калды. Ул чатырга керде. Керүгә үк аны кемдер кочаклады, чупы-чупы, кая эләкте, шунда үбә дә башлады. Бу ярым ялангач хатын иде. Үбеш арасында кайнар сулыш белән ул:

— Кичерең мине... мин сүәмен сәне... Җен җегетләре патшасы Акмирзаны җаным-тәнемлә сүәмән...— дип пышылдады.

Менә кем карап торган икән келәм тишегеннән!

— Ир-егет кулын күптән тотканым юк,— диде хатын.— Минем

адәмем гел яуда, гел җәйләүдә, кайтканда да һәрзаман сәүгеләләре әчкәрисеннән чыкмый... Хатын кешегә кытыршы-сөялле-орылы кул кирәклеген белмисез шул сез...

Бикә Сөен тутайның кытыршы кулларын үбә, учларына капкайнар яңакларын куя. Нәрсә булды тутайга, нинди куәт аны чыгырыннан чыгарды, Айсөлек мажарасындагы кебек шаярырга кирәк иде дә, әмма ул, ике кулын да кинәт тартып алып:

— Мин — кыз-хатын! — дип әйткәнен сизми дә калды. Аның зиһенендә Йосыф гүзәлнең чабуын учлап тоткан әдәпсез-йөгәнсез теләкле Зөләйха чагылып куйды.— Мин ир түгел!

Сер сандыгындагы сандугач очты чыкты, хәзер аны тотып булмаячак иде инде.

— Әстәгъфируллаһ! — диде хатын, ирексездән Сөеннең күкрәгенә кагылып. Куллары тыгыз йомшаклыкка тигәч, илереп кычкырды: — Җомаби-и, алаша-а...

Җомаби дигәне белән бәрелешә язып, Сөен чатырдан атылып чыкты, өзәңгегә дә басмыйча ияргә сикерде; Бүзтарлан, куакларны ерып, юлга төште. Еракта быргы кычкырттылар. Бу Сөмбелтай быргысы шулай уйный. Сөен дә шул ук көйне быргысына өрде. Югалган Акмирзаны эзләүчеләр дә, бикәчнең кара бөркәнгән сакчылары да караңгыда буталып бетте. Хатын гына алар арасында күренмәде. Конар би йортына кайтканда бөтен өй эче аяк өстендә иде. Хуҗа аптырашта, яшь бикәсе чәч-баш туздырып елый. Өй эче:

— Кемдер бикәч янына керергә маташкан, сакчылар аны тота язган,— дип ду килә.

Бикәч Акмирзаны таныган, имеш. Мондагы канун буенча, кеше хатынына кул салган мордар шундук үтерелергә тиеш... Хуҗабай бөтенесен куып таратты да, Акмирза белән икәүдән-икәү генә калгач, әйтте:

— Син, Акмирза, чынында ир булып өлгермәгән... Ә бозыклыкка хәтдин ашкансың... Ихтимал, бикәч үзе сиңа күз кыскандыр көндезен. Аның ул шаярта торган гадәте бар, күпләр шуңа алдана... Бәс, кит син яхшылыкта. Бәладин башаяк. Олыс халкы уянганчы кит! Тиз кит!

Сөен тутай ләм-мим, бер кәлимә сүз әйтмәенчә, ахирәтләре янына чыкты. Унга санаганчы, алар ат өстендә иде. Кайсы якка китәсен дә белмичә, алар бу шомлы олыстан җен кугандай томырылып чапты. Таң атар атмаста алар күрде: барасы юл өстендә кара бөркәнгән бер җайдак тора. Җайдакка җитәр-җитмәс, ахирәтләр туктады. Кара җайдак каплавычын салды. Ат өстендә гаҗәп чибәр бер яшь хатын утыра иде.

— Мин Конар бинең яшь хатыны! — диде бикәч.

Җен җегетләрен әйләнеп узар өчен җенлеләрдән дә җенле айгырда җен җайдак булу кирәк, дип уйлады Сөен тутай.

Бикәч җәһәт кенә җәүләнде, Сөен тутайның аягына йөзен орып, Бүзтарланның тезгенен тотып әйтте:

— Ярлыка мине... кем дип әйтәем... тилергән мин, тилермеш хатын... Өйдәгеләр һичкемгә чыгармас. Син сөйләп йөрмә, зинһар. Уртак Тәңремез хаккыйна ялварамын. Төнен булган мажараңны кабергә күм. Көлке итеп сөйләп йөрмәң...

— Вәгъдәм! — диде Сөен тутай.— Серең миндә үлде. Минем белән бергә күмелер!

— Бөек догаларым сәга! — диде бикәч.— Инде белмим, хөкемдарым, кем син?

— Сөен бикә булачагым! — диде.— Йосыф кызы.

— Сөен бикә? — дип авызын ачты бикәч.— Әстәгъфируллаһ! Нугайның олы мирзасы Йосыф кызы Сөенеч тутай синме?

— Хәзер безгә юл сап! — диде Сөен.

Хатын тезгенне ычкындырды. Читкә, аты янына күчте. Ахирәтләр алае тупырдап узып китте.

Нигә соң ул серне ачып ташлады? Ялгышмы, әллә юрамалыймы? Бу турыда берәү дә сорашмады. Сөмбелтай да дәшмәде. Әмма Сөен тутай үзеннән үзе сорады: ни өчен? Беренчедән, урмандагы чатырда кыз заты икәнеңне әйтмәү мөмкин эш түгел иде. Җен җегетләре сүрәтендә кырык кыз юлбасарлык кыла икән, дигән хәбәрләр күптән йөри. Икенчедән, йөгәнсез бу хатынга сабак булсын, дип әйтте бугай ул үз исемен.

— Җитте! — диде ул алгы тукталуда.— Аблак баба янына кайтып хәл алыйк...

Чүл алачыгында җен җегетләрен зарыгып көткәннәр. Аблак бабаның хәлләре һәйбәт. Ярты малы кайткан, янә үрчем арта башлаган. Янында — үз балалары кебек җен җегетләре. Ул инде кышка әзерлек башлаган: дала тикле далага барып кизәк җыя, чүл тикле чүлгә кереп, саксаул коры-сарылары алып кайта.

— Аблак баба, кышлауга күч, кеше арасы булыр,— диде балалары.

— Юк,— диде баба.— Каберем шушы алачык булсын! — Бераз тын торгач, өстәп куйды: — Сез дә күп чаптыгыз, хәл җыегыз...

Хәл җыярга кайтмады тутай, уйларын җайларга кайтты. Сөен тутай, үз тирмәсенә кереп ятканнан соң, шуннан чыкмыйча өч көн, өч төн йоклады. Хәер, йокламады ул, кайта-кайта бер уй уйлады. Шаярып-уйнап кына егет булып йөрү тора-бара аны тупаслатты бугай. Ул орыш вакытында чын яугирчә сүгенә:

— Ток-кымыңны ораем!.. Атама х-хат-тын булаем!... Анаңа дуңгыз ир булгыры! — дип кылыч чаба.

Җитмәсә, хатын-кыз да аны, ир-егеткә санап, гыйшык хатлары юллый... Ул бармакларына бакты. Кыз кулы димәссең. Каткан каеш чишә торган куллар бу. Бертуктамый көнозын кылыч, сөңге ора торган куллар бу. Авызлыгын тешләгән асау айгырның башын каера торган куллар бу. Киерге-җәягә сәрпи ук куеп биш йөз адымнан адәмгә тигезә торган куллар бу. Дулап-ыргып хәтәр чапкан айгыр үлем җәрәхәте алып сөрлеккәч, ат башыннан очып төшкәч, тәкмәрләтеп, аягүрә бастырган куллар бу... Авырту тоймас, муртайган ике учына ул янып торган йөзен салды. Аның бите — хатын-кызныкы, куллары — ирләрнеке. Бер бәндәдә ике җенес булса, гайре табигыйдер.

Аның уянганын көтеп, Аблак баба арыды, ахрысы. Тутай тирмәсе яныннан алай үткәндә дә, болай сүткәндә дә бабаның артыграк тамак кырганын ул ишетеп ятты. Тирмәләрдән ерак түгел, атлар пошкыра, дөяләр чинаша. Алар да Сөен тутайны уятырга тырыша бугай. Әмма аның башында яу кайгысы түгел иде. Исмәгыйль мирзадан үч алу да аңа сөенеч китермәде. Нәрсә җитми соң аның күңеленә?.. Үч кайтару, маҗара эзләүләр белән мавыгып, аның хыялы — Ирәмбаг һәлак була язган. Шул борчый икән аның сизгер күңелен. Шәддад падишаһ та югалды. Исмәгыйльдән үч алу кебек вак, дәрәҗәсез теләге Ирәмбагтан өстенрәк чыктымыни?.. Җенле җегетләр падишасы Акмирза кыяфәтендә йөреп, ул яңа бер сорау алдында җавапсыз калды. «Йосыф вә Зөләйха» кыйссасын ул күңелдән белә, күңелдән белсә дә, ахирәтләреннән кат-кат сөйләтә, кат-кат ишетеп, ләззәт ала торган иде. Әмма соңгы утырышларда ахирәтләреннән берәрсе «Йосыф-Зөләйха»ны башласа, кырыс тавыш белән туктата.

— Җитте! Куй бу көеңне! — ди.

Сөмбелтай да аптырашта иде. Ләкин тутай бу үзгәрешнең сәбәбен аңлатмак өчен авыз ачмады... Ташбәргән бәк кызы бичара

Айсөлектән соңмы, бәлки, урмандагы чатыр эчендә бикәч белән булган мажара сәбәпчедер — соңга таба Сөен тутай «Йосыф-Зөләйха» кыйссасыннан тәмам бизде... Алтын-ахак тәхеттә утыручы Зөләйханың хәләл ире Кыйтфир өстеннән колы Йосыфны күкрәктәш итәргә теләвенә ачуы килә аның. Йосыф гаять чибәр булган бит, дияр кемдер, чибәрләр аздырмы бу дөньяда: шул чак Йосыфтан да чибәррәк ир табылса? Зөләйха Йосыф өстеннән ул ир белән дә йөреп, гайбәтчеләрне кунакка чакырып, тагын әфлисун вә пычак тоттырырмы?.. Ул үзе ике тапкыр Йосыф сәүче хәлендә калды. Бикәчнең аны кысырыклавы бер яктан көлке булса, икенчеләй бик имәнгеч бер фәгалиять иде. Нинди гыйшыктыр ул? Нәмәнди мәхәббәт соң ул? Юктыр, мәхәббәт түгелдер ул, гашыйклык түгелдер ул; гап-гади йөгәнсезлек, женси комсызлык бу. Хыянәтне, бозык эстәкне гүзәллеккә сылтап, аклап була икән, ни-нәрсә соң ул мәхәббәт? Бу мажаралар Сөен тутай алдында шундый сорау куйды. Ир-егет кыяфәтендә йөрү, ир затын түгел, хатын затын аңларга ярдәм итте шикелле. Бәс, аның «жен жегетләре» уенын башлавы мәгънәсез булмаган. Шулай дәвам итәргәме, юкмы?

Аблак баба, инде ничәнче мәртәбәсендә, тамак кыра, биясенә кычкыра, янәсе, тегесе саудырмый.

— Ни гозерең бар, Аблак баба? — дип кычкырды Сөен тутай.

— Яңа кымыз эчәсеңме? — диде баба.

— Керт! — диде ул, тиз генә торып, ишек катындагы жиз ләгәнгә авызын чайкап, битен-кулын сөннәтләп, жиңел ябынчасына уранды.

Тулык вә ике касә тотып, Аблак баба керде. Бисмилла әйткәнче үк, тутай бер касә кымыз эчте. Алдады Аблак баба, дип уйлады ул, кымыз бүгенге түгел, кичәге дә түгел, бу куәтләндерелгән кымыз, базда тотылган дәртле кымыз. Ул бу турыда Аблак бабага әйтмәде, бер-бер артлап тагын ике савыт эчеп куйды... Димәк, Аблак бабаның бик тәжел әйтәсе сүзе бар, шуңа күрә, тел ачкычының ачысын күтәргән... Сүз башта кымыз хакында, үләннәр турында булды. Тагын бер-ике касәдән соң, Сөен тутайның күңеле көрәйде, ул Аблак бабаның сүз башлавын көтә иде. Әмма Аблак баба юри көттерә, үзенең күзе касәдәге кымызда.

— Кызым! — диде баба.

Сөен тутай дертләп куйды.

— Кызым,— дип бастырып кабатлады хужа.— Бабаңны тыңлап баксаң...— Сөен тутайның нидер әйтергә кымыржып утырганын күреп, баба янә әйтте: — Аптырама, кызым Сөенеч тутай...

— Сауфияме әйтте?.. Татлыбикме, тефү-ү... Бикбулатмы? Кайсысы?

— Хафаланмаң! Уттай кызган тимер кыскыч та алардан сер тартып алалмас!.. Үзем белдем...— карт үз алдына көлемсерәде.— Жә, мин нинди остаз булам инде? Әгәр дә күзем булмаса. Һәр «жегетнең» билендә чәч толымы... Жегет булып йөрисез, берегезнең дә мыегы юк... сөрмә тарткан бала йоны гына. Арагызда житен чәчле, күк күзле чибәр Сауфия йөри, ник бер егет аңа күз кыссын, сүз катсын... Утызыгыздан егермегезнең күкрәге калыкканнан калка бара... Аннан соң...— Баба читенсенеп туктады, әмма әйтеләсе тиеш дигәндәй, тәвәккәлләде: — Аннан соң, тагын аерым билгеләр... эзләр дә була бит әле... далада, чүлдә... тирмәләр тирәсендә...

Сөен тутай да елмайды. Үзләренең беркатлы булуларына, саксызлыкларына оялып елмайды бугай.

— Син нигә баштук дәшмәдең, баба?

— Һе, йөрсеннәр, дидем... Яшь чагында чабып калсыннар, картайгач, оныкларына сөйләр мажаралары булыр, дидем...
— Рәхмәт, баба! — диде Сөен тутай.
— Әмма бу халәттә артыгын йөрү гайре табигый нәрсәләргә китерер...
Шул көннән соң Аблак баба Сөен тутайны чүлгә, далага алып чыга торган булып китте. Кызлар-ахирәтләр кизәк җыя, корысаксаул вата. Аблак баба белән Сөен тутай үлән, чәчәк тамырлары белән мәш килә.
Ир кеше хатын кыяфәтендә озак йөрсә, азмы-күпме хатын-кыз гадәтләрен үзенә ала. Тора-бара ул хатыншакка әверелә. Ир кабыгына керергә тырышкан хатын җенесе дә әкренләп ирдәүкә булып китә икән... Андыйлар ике җенеслеләр рәтен күбәйтә, кыз-тәкәләр ягына чыга... Җанварлар да, кешеләр дә, үсемлекләр дә, кошлар да бу имәнгечлектән хали түгел, ди...
Сөен тутай бу сөйләшүләрдән соң әкренләп үзгәрә башлады, толымнарын юып киптерде, тарап, кыска чәченә катыштырып үрде; әллә каян, капчык төбеннән табып, алкаларын такты, чигә чәченә айлар бәйләде. Ахирәтләре дә кыз сурәтенә керә барды. Баксаң, алар да яшереп кенә йөзек-алка, чәчбау саклаган икән.
— Һу-у,— диде Аблак баба.— Менә бит, табигать үзе биргән гүзәллекне кая яшереп асрагансыз!
Көннәрдән бер көнне Аблак баба әйтте:
— Кызым Сөен тутай,— диде.— Синең алгы юлың озын, катлаулы. Күзең синең сөрмәле, рухлы... Кирәк булыр, өйрән...
Аблак баба аңа үлән тамырларындагы, гөл-чәчәкләрдәге шифаны, ат тире белән нинди үлән катыштырсаң, кеше үтерә торган агу ясарга була, агулы ук тигән җәрәхәттән ничек агу кайтаргыч дару, ношгыя ясарга кирәклекне — барын да өйрәтте. Ни гаҗәп, утыз кызның, Сауфиядән башкасы, ник берсе гөл өзсен, ник берсе кызыксынып, Аблак баба әйткәннәрне тыңласын. Аларның бар белгәне уен, бизәнү. Аларның туйга әзерләнгәндәй кыланышына карап, Сөен тутай әйтте:
— Ант эчкәннәр,— диде.— Шартымыз куәтендә кала.
Хушлашу вакыты җитте. Тагын кыстап карасалар да, Аблак баба кышлауга күчәргә теләмәде.
— Үз көнемне үзем күрерлек малымны кайтардыгыз, шөкер! — диде карт.— Минем гомергә болар җитәр, иншаллаһ.
Сөен тутай Аблак бабаны кочты, иреннәрен картның маңгаена тигезде, янә ул Аблак бабаның уң кулын үпте, кул сыртын үз маңгаена куеп торды:
— Күрешергә язсын, Габдел Каюм баба! — диде.
Кайчандыр җәрәхәтле, ярымүлек бабаны тапкан саксаул куагына җиткәч, Сөен тутай каерылып артка карады: офыкта, чүл эчендә каракучкыл ваһа чалына. Аблак баба гәүдәсе дә, дөяләр дә күренми. Әмма Сөен тутайның күңеле сизә: карт әле һаман кереп китмәгән, кызлар киткән якка карап тора. Еларга күзе кипкән булса да, Аблак баба ятим күзе белән елыйдыр.
Сарай оланнары, сабый мирзалар, сәяхәттән кайтып килүче ахирәтләрне әллә каян күреп, кайсы — сөенче алырга сарайга йөгерде, кайсылары — каршы килеп, һәр атның тезгенен алып, капкага хәтле яннан атлап кайтты. Сөен тутай ана — башка, ата бер энесен, Әкрам Галине алдына утыртты. Тутай җәяүләнгәч, Әкрам Гали атны сулыш алдырырга йөртеп китте. Башка оланнар да ахирәтләрнең атларын салмак адым белән йөртәләр иде.
Ул көнне бөтен калада бәйрәм булды. Йосыф мирза тыңлаусыз кызын әрләргә дә, сөяргә дә белмәде. Сөяр идең — алдыңда җиткән кыз, төяр идең — кул күтәрелми. Шулай да мирза сүзне

кырысрак башларга булган иде. Әкрам Гали йортә торган айгырны тәрәзә аша күргәч, әзерләгән сүзен онытты, кызы Сөен тутайга бер карап, ишегалдындагы җен айгырына бер багып, әйтә куйды:

— Әстәгъфируллаһ! — диде.— Бу бит Исмәгыйльнең Чуерташы!

Сөен тутай сабыр гына җавап кайтарды:

— Атакаем! — диде.— Чуерташ түгел аның исеме — Бүзтарлан!.. Исмәгыйль мирзаныкы да түгел ул ат — Габдел Каюмныкы, ягъни Чүл бабасы Аблак картныкы. Багып торасың, атакаем, хәзер Бүзтарлан минеке!

— Димәк, халык дөрес әйтә! — диде мирза.

— Дөрес,— диде кыз.— Исмәгыйль мирзадан барымта кайтарып, мин аны хуҗасына дүндердем. Үлем якасыннан йолып алганыма күрә, хуҗасы бу малны һәдия сыйфатында миңа багышлады.

Йосыф мирза кинәт көлә башлады, бер буылып, бер бушанып көлә, рәхәт көлә ата кеше. Сөен тутай да, сүзнең икенчегә борылуына куанып, әтисенә наз илә бакты: атасы ул югында бирешкән, ак чәчләре арткан, сакалында да ике бармак киңлегендә бүз тасма пәйда булган. Ни сәбәпле ул йончыган? Сөенеч кызы хәсрәтеннәнме? Әллә ил эчендәге низаглар аны шулай изгәнме?

— Валлаһ, эчем катканчы көлгәнем юк иде. Исмәгыйль энекәшнең ике бот арасындин хәтәр айгыры Чуерташны хатыннар куып алып киткән дип сөйләгәч, ышанмаган идем...

Ата кеше көлү бизгәгеннән тиз арынды, күзенә килгән көлке яшьләрен кесә яулыгы белән сөрткәләп, бераз тын утырды, соңра әйтеп куйды:

— Исмәгыйль агаң моны болай гына калдырмас. Ул сине күптәннән аулый инде...— диде.

Сөен тутай дәшмәде. Йосыф мирза көрсенү аша янә әйтте:

— Исмәгыйль агаң...— диде.— Исмәгыйль мирза, урыс белән әшнәләшеп, нәселне корытмакчы, үзе Нугайга баш булмакчы... Ул инде азау ярган бүре. Хатын-кыздан шундый мәсхәрә күргәч, ун санлы ил алдында рисвай калгач, электә җенле агаңның җене унлата чыгачак. Ул сиңа да, миңа да пычакны кайрап куйган инде.

Сөен тутай дәшмәде.

Шулай, Йосыф мирза дөрес әйтте. Шулай, ул әйткәнчә булачак. Исмәгыйль мирза Нугай илен тураклап сатачак. Кем токымы диген син? Идегәй токымы! Кем бөек көзгене — Алтын Урданы ваткан, ваткан да, ваклап-ваклап саткан? Идегәйнең улы — Норадын, аның улы — Ваккас, аның улы — Муса, аның улы Исмәгыйль мирза. Ике-өч тун, бер сугыш киеме, дүрт-биш табанча өчен, үз халкын талап, батыр егетләрен бәйләп, урыс патшаларына сатар, дип кем уйлаган аны?

Ата белән кызы икесе дә тын калып, шул турыда уйладымы? Ихтимал, шулай булгандыр да, әмма тәдбирле уй Нугай йорты сарайларында тамыр җәйми шул. Тәдбирле уй ике исәп, бер уйлаудан соң тарала, кача. Йосыф мирзаның исәбе — буй җиткән кызын тирә-юньдәге ат казанган берәр бәккә, мирзага кияүгә биреп, мал-мөлкәтне ныгытырга иде. Иң сөекле баласы булгангамы, Сөенеч тутай иркендә үсте: шуңа күрә, атасы Йосыф мирза аны менә бүген бәйләп туй арбасына салып җибәрергә тулы хаклы булса да, ашыкмый.

Сөен тутай озак сәфәреннән бөтенләй үзгәреп, тулып-пешеп кайтты. Үндүрттән узган кыз инде сазаганнар рәтенә керә. Сөен тутай шушы олы гарьлектән дә курыкмый иде шикелле. Яучылар килә торды, тутай аларны кире бора торды.

— Атакаем,— диде ул, берничә яучыны буш кул белән кайтарып җибәргәч.— Күзеңә багып әйтәмен ки, тагын бер җәй, бер генә кыш иремнән, даламнан аерма, зинһар.

Ата кеше, бу кичектерүләрнең сәбәбен сораса да, төгәл җавап алалмады. Әгәр дә Сөен тутай:

— Мин төшемдә күргән Шәддад падишаһка гашыйкмын, шуны эзли чыгам,— дисә, һич шик юк ки, ул тозакка эләгәчәк, яшь тайны авызлыклап айгырга алып баргандай, кызны бәйләп озатачаклар. Тутайның кияүгә озатылмаганына бөтен сарай бикәчләренең эче поша. Көн тууга алар Йосыф мирзаны сагалый, котырталар, димлиләр.

— Анакаем мәрхүмәнең изге рухына,— диде Сөен тутай.— Сөекле хатының Сайгәле бикә хакына кызың Сөенеч тутайны ирексезләмә, атакаем. Сөйләшенгән вакыт үткәч, мин синең колың... Тел белән әйткән сүз үтмәгәнгә, атакаем, таяк та үтмәс, бары гомер генә заяга үтәр...

Күнде Йосыф мирза, шөкер. Сөенеч тутай үз ихтыярына куелган иде.

Утыз ахирәт кала буйлап ат уйнатып далага киткәндә дә, аудан-яудан ат уйнатып кайтканда да кешеләр, эшләрен ташлап, урамга чыга. Бу гүзәл «җен кызларына» кемдер кызыгып карый, кайсысыдыр көнләшеп бага, кайберәүләре соклана, кайберләре ачу катнаш киңәш итә:

— Иярдән төшәргә вакыт, бала үрчетергә кирәк! Тапканнар уен! Көн димиләр, төн димиләр, атланалар да чабалар. Ир-егетләргә баш бирмиләр,— дип кала.

Андыйларга ахирәтләр көлеп җаваплана:

— Ир-егетләрегез шундаен булгач! — дип уза.

Юк шул, туганкайлар, Сөен тутайның беләге иргә мендәр булыр өчен, түше түшәк булсынга яратылмаган. Ихтимал, Сөен тутай яхшы бикә була алмас, шуңа күрә, бөтенләй кияүгә чыкмый калу мең өлеш артыктыр... Ирәмбагны Шәддад падишаһы илә тапмаса, ул икенең берсен сайлаячак: йә атасы тапкан мирзага кияүгә чыгачак яки гомере буе дуадак ана каз булып калачак. Яшәешең, сөюең-сөелүең тарихларга кереп калмагач, мәхәббәт буламыни ул? Олуг Гыйшкың ил теленнән төшмәс булса гына сөй! Сине сөйсәләр дә сөй! Сине сөймәсәләр дә — син сөй!

Атасына ныклап каршы торуы да, шушылай уйлавы да гаҗәеп бер төш күргәннән соң булды...

Ул янә Ирәмбагта истирахәт кылды. Алтын-көмеш көпшәләрдән Кәүсәр чишмәседәй тәмле су атып тора. Бакча түрендәге ханәкәдә кемдер чаңкубыз чиертә... Һәр сукмак чатындагы баганага шамаилдай гүзәл язу элгәннәр:

«Илдә сирин ләтыйф вә хуш бөстан, кайсының эче тулы гөл вә рәйхан: төрле моңлы мәкам илә сайрыйдыр былбыллар, даим анда гол-гол итә тавислар...»

Ул ярсып-алгысып уянды. Ярсуы шуннан: төшендә ул Ирәмбагта Шәддад падишаһны күрмәде. Бу ни гамәлдер ки? Кыйсмәтнең алдан хәбәр бирүеме бу?.. Син табарсың Ирәмбагны — фани җәннәтне, әмма бакчачысын табалмассың, диме кыйсмәт?

Ул кисәктән торып утырды. Ялгыз башы изгән мендәренә бакты: ни гаҗәп, ике мендәрдә дә баш эзе бар. Бер мендәр батыбрак кергән, икенчесе, ул әле яңа гына башын алганы — сай чокырлы иде. Әйтерсең лә, бу ятакта икәү йоклаган. Бер мендәрдә аның үз башы, икенчесендә...

— Әстәгъфируллаһ, йоклаганда күчкәнмен! — диде дә тутай, тирәнрәк чокырлы мендәрне кабартырга дип кулын сузды; аннан соң янә: — Әстәгъфируллаһ,—диде.

Мендәр сүрүендә «Шәддад» дигән язуны күреп, Сөен тутай тораташ калды. Җен эшеме бу? Әллә Сөмбелтай белән Ализәкме шулай шаяра? Булмас. Җеннең дә, Сөмбелтайның да, Ализәкнең

дә башы ике түгел. Мендәрдәге бу сихри язуны аның үз чәче, башыннан аерылган үз чәче ясаган. Боргаланган-сыргаланган да «Шәддад» сүзенә охшаш сурәт заһир булган, бары шул гына, дип тутай үзен сабырлатты. Җен эше булмаса да, ахирәтләренең кулы уйнамаса да, Сөен тутай бу гамәлнең тәкъдир фәгалияте икәнлегенә инанды. Чәч ялгыш кына төшсен, тынычсыз йоклаганда башы боргаланып, ялгыш кына «Шәддад» исеменә охшаш сурәт хасил иткән булсын, ди. Әмма бу — хәбәр! Сөен тутайның язмышына ишарәдер!

Фасыл артыннан фасыл узгач, җәйләүләрдән, далалардан кышлауга кайткан малчылар туйга, бәйгегә, кодалаш-ячылашка хәзерләнә. Бәйрәмнәр күп булачак бу ел кышлау башында. Аллаһ боерса! Елкы бик мул үрчеде, симерде, дөяләр мантыды, өреп кабарткандай тыгыз-шома маллар чыдаша алмый; куйлар да, шөкер, басып тора алмый, койрыклары баса. Кызлар да өлгерде. Егетләрнең тиле каны уйный, ташлар кызган, кымыз-буза чемердәгән. Атларның да тояклары ут яна, бәйге көтә.

Шулай кайнашканда Йосыф мирза сараена хат килеп төште. Хат түгел иде ул, ярлык шәкелендә язылган, күн йомарлакка төрелгән, нишанлы мөһер сугылган, ул гына да аз булган, тамгалы балдак-мөһер дә басылган бу ярлык — мәктүп Исмәгыйль мирзадан иде. Ярлыкны Исмәгыйль мирзаның иң ышанычлы бахшысы Түкәй белән аның җансакчысы Алтай батыр китерә килгән; бүген үк, хәзер үк җавап алып, кире борылырга тиешлекләрен белдерделәр...

Шулай кирәк икән, шулай булыр,— чапкын-бахшылар кымыз эчеп алгалаганчы, Йосыф мирза хат-хәбәрне укып чыкты. Җәһәт кенә Сөен тутайны чакыртып алды. Сөен тутай тәхетханәгә ингәч, атасына тез йөгенеп, иелеп тәгъзим кылды. Йосыф мирза кызына кәгазь сузды.

— Бу хәбәр миңа аталган булса да, җавапны син үз кулың илә язарга тиеш, кызым!— диде.— Исмәгыйль мирза чабышкые Чуерташны кайтарырга боера, ярлыкны алган көнне үк, ягъни бүген үк, хәзер үк Алтай батыр белән Түкәй бахшыга биреп җибәрергә куша. Һич җае булмаса, бәйгегә ун көн кала Чуерташны китереп, аранга бәйләргә лазем, ди. Шулай булмаганда, Исмәгыйль мирза Йосыф абзасын да, Сөен сеңлесен дә рисвай кылырга вәгъдә итә.

Сөен тутай хатны ике кат укып чыкты.

— Биреп җибәр, кызым,— диде ата.— Чүп белән чүбәймәң. Сиңа елкы беткәнме? Мин сиңа иң яхшы узышкыйны бирермен.

— Атакаем,— диде Сөен тутай.— Шаехмамай агам белән син узындырдың шул фетнә мирзаны. Юл куя килдегез. Күз йома яшәдегез. Әнә, хәзер олы абзаларына яный. Үз канкардәшенә, бертуганына яу белән яскана. Илгә хәкарәт ташый. Сез, тугыз әмир, тугыз мирза, бер Исмәгыйль энегезне тыя алмыйсыз. Сизмисеңме, атакай, күрмисеңме, атакай, ул Сарайчык тәхетенә үрелә. Бүзтарлан ул сылтау гына, сәбәбе — тәхет! Бүзтарлан булмаса да, ул яу өчен, дау өчен сылтау табачак иде. Тапкан инде ул сылтау. Унбиш ел элек ачык орышта, карымта бәйгесендә үтерелгән Дилазар мирза өчен үч кайтармакчы. Үзе Дилазар мәрхүмнең малын гына түгел, хатыннары белән балаларын да барымтага куды. Юк!— диде Сөен тутай соңра.— Бүзтарлан — Исмәгыйль мирза малы булмаячак! Гадәттән, шәригатьтән, хет сәет бабадан оялырга иде аңар. Бөтен мир белә: Бүзтарлан — Габдел Каюм бабаныкы. Каюм баба үз бармагы басылган шарт-ярлыгы белән утыз ахирәтем шаһитлегендә Бүзтарланны миңа мөлек сыйфатында күндерде... Бәс, үз мөлкәтемне мин җанбаз Исмәгыйль мирзага үз ихтыярым илә һичкайчан бирмәсмен, атам!

Җавапны Сөен тутай үз кулы белән язды. Хат эчендә бары дүрт юл язылган иде:

Куян тоталмаз торнага җилкенер,
Торна тоталмаз Айга сикерер,
Ай киткәч, тайга ымтыныр,
Тайны тотканчы, гомер узылыр.

Хат азагына мөһерле балдагын басып, хатны кәгазь азагыннан төреп, хат башына балык җилеме белән ябыштырылган күнгә төреп, алтын укалы ефәк җеп белән бәйләп, тире көпшә өстендәге түгәрәк балавызга янә балдак мөһерен басты. Илчеләр, шул хатны алып, хуҗалары Исмәгыйль бәй янына кайтып китте.

Йосыф мирза кызының бу кылышына куанмады — сүзсез генә аһ орды. Илчеләрне озаткач, ул:

— Аллаһ хәерле кылсын! — дип, намазлыкка менеп басты.

Кышлау уеннарына бөтен Нугай иленнән халык җыелган, туйлар яман да яхшы булыр, бәйгеләр кайнар булыр, дип сөйлиләр. Сөен тутай белән ахирәтләр дә уеннарга бик нык әзерләнде... Туй мәҗлесләреннән, көрәш уеннарыннан, сүз әйтү, саз уйнау, кылкубыз чиртүләрдән, җырлы уеннардан соң, ат бәйгеләре башланды. Кыз куышта да, чауган туплы уйнаганда да Сөен тутай белән ахирәтләре баш бирмәде. Ат өстендә җегетлек күрсәтүдә дә кызларга олы бүләкләр тиде. Исмәгыйль мирза да нөкәрләре-әтрәманнары белән бәйгегә килгән иде. «Бу Елмаймас агай бәйрәм уртасындамы, азактамы гауга чыгарыр»,— дип уйлаган иде Сөен тутай. Ходаның рәхмәте, тегесе тын гына күзәтеп торудан башканы белмәде. Аның бәхәсләргә катнашмавы бәйрәмчеләр өчен рәхәт иде дә... Елмаймас агасының шулай тыныч йөрүе тутайның күңеленә шом салды. Бу фетнәби ниндидер әшәкелек уйлап йөри, ахрысы... Әйтеп-сөйләп торасы юк, олы бәйгедә, соңгы чабышта Бүзтарлан алда килде. Сөен тутайга иң зур бүләк: сигез аргамак белән бер дөя бирделәр. Елкылар белән дөяне мәйдан буйлап йөретеп, ун адым саен:

— Ризамы, аксакаллар? — дип сорап чыкканнан соң гына, Сөен тутайга тугыз тезген тоттырдылар.

Кышлауда уздырыла торган бәйрәмнең эссесе шул соңгы бәйгедән соң сүрелә башлый. Кунаклар берән-сәрәнләп тарала, мәйданнар бушап кала.

Сөен тутай, бәйге бүләкләрен алгач та, ахирәтләре белән өнәмәстән юкка чыкты. Алар — далага, даладан чүлгә кереп, бичара Аблак бабага үз аты — Бүзтарланы узып алган елкыларны, дөяне тапшырырга ниятләгән иде. Бер тәүлек юл узгач, кышлау әллә кайда, еракта калгач, көтүләрне узып, дала белән чүл никахлашкан эргәдәге ярлар, агачлар арасыннан чырайлары кара чүпрәк белән каплаулы бик күп атлылар каршыга чыкты.

— Каршыда хәрамиләр! — диде Сөмбелтай.— Мал таларга чыкканнар...

— Артка борыл! — дип кычкырды Сөен тутай.

Ахирәтләр уң тезгенне берьюлы каерды. Әмма артта да нәкъ шундый ук кара чиру баскан булып чыкты. Шулчак Нәргәтайның әче тавышы ишетелде:

— Алда илле, артта сиксәнләп юлкисәр!

— Утыз кызга йөз утыз ир! — диде Сөен тутай.— Ахирәтләрем, күбегез миннән яшереп кенә ислемай сөртенә, егет котә. Менә сезләргә форсат! Дүртәр ярым ир туры килә.

Сөен тутай гайре табигый тавыш белән әдәпсез көлде.

— Дүрт хатынлы ирләр бары мәгълүмдер,— диде Сөмбелтай.— Әмма, ахирәтләр, дүрт ирле хатын очратмадым.

Сөен тутай бу юлы ихластан көлде. Ахирәтләре дә көлгән булды, әмма эшләр бик мөшкел иде.

— Нишләп алар кузгалмый? — диде Сөен тутай. Билгесез яугирләрнең сүзсез тик торуы шомлы иде.

— Сора! Кемнәр алар? Аларга ни кирәк? — диде Сөен тутай. Һәм шундук аның башына бер уй йөгерде: «Бу бит Исмәгыйль мирза башкисәрләре. Ни тели алар? Мал талау, Бүзтарланны кайтару гына булса — хуш! Мәсхәрә юлында булса эстәкләре?»

Ул арада Сөмбелтай белән Ализәк, атларына тибә төшеп, сәер яугирләргә якынаеп сорады:

— Кемнәр сез? Ни кирәк?

Арадан бер ир, башлыклары булса кирәк:

— Елкылардан төшегез! — диде.— Йөзекләрегезне, бөтен алкабеләзек, чулпы, чәчкап, хәнҗәр, кылыч, ук-җәяне төйнәп, һәрберегез үз атына бәйләсен!

Кышлаклардан йөз чакрым чүлдә утыз кыз җәяүгә калса, теге якка да, бу якка да сусыз, ризыксыз... кайтып җитә алмаячак. Тиз уйларга кирәк. Сөмбелтай белән Ализәк, киңәш сорап, Сөен тутай янына килде. Ә ул аларга гына ишетелерлек итеп әйтте:

— Ализәк, синекеләр — Илек ягына, без Сөмбелтай белән ике арага ыргыйбыз!

— Багалмам,— диде Сөмбел.— Атлар хәл алмаган. Тегеләрнең атлары биеп тора.

Дөрес, хәрамиләр аларны бастырып җитәчәк. Сөен тутай уен ахырынача уйлап та бетермәде, авызы болай кычкырды:

— Әмир Муса углы Йосыф мирзаның кызы Сөен тутай торырмын!

Хәрамиләр башы әйтте:

— Безгә патша да бер, ханша да бер! Малыгызмы, җаныгызмы?

— Алайса,— диде тутай.— Минем уенчыларымның уенын, җыручыларымның җыруын тыңлап, рәкысчыларымның биюен баккыңыз!

Сөмбелтай эшне аңлап алган иде инде, ул кызларга иң зур келәмне җәяргә кушты. Уенчылар һәрберсе үз келәмнәренә утырып көй башлады, беренче булып Сөен тутай олы келәм уртасына чыгып басты. Җыру яңгырады. Тутай бии-бии, җырлый-җырлый иң әүвәл эше итеп, яулыгын салды, алкаларын ычкындырып, келәмгә ташлады. Кара яугирләр тамаша мәйданына якынрак килде... Сөен тутай үзе бии, үзе чишенә, кызлар да берәм-берәм чыгып, бии-бии чишенә, зиннәтле йөзек-беләзекләрен уртага сала. Көй матур, җыры матур, биюче кызларның тал чыбыгы кебек сыгылмалы гәүдәләре аннан да матур... Кызлар анадан тума ялангач калып, һич тартынмыйча,— әйтерсең лә алар үзләре генә,— онытылып бии. Могҗиза иде бу. Юлкисүчеләр җәяүләнеп, аптырап, сокланып басып тора... Сөмбелтай ике якка ике кыз юллады... Кара яугирләр, берәм-берәм битлекләрен салып, ялангач кызларга карап, авызларын ачкан. Бию кайнарлана барып, иң кызган урында гына кемдер, җир ярырдай итеп, сорнай-быргы кычкыртты, кемдер гаугә бәрәбаны кага башлады. Кызлар күз ачып йомганчы иярләренә сикереп менде. Быргы, бәрәбан тавышына кара яугирләрнең атлары өркеп далага таралды, кара хәрамиләр калган атларга сикереп менгәннәр иде — коешканнар да пычак белән киселгән, ат ыргылганда ияр, җайдагы-ние белән, артка тәгәри. Атлар кешни, ирләр сүгенә, кызлар чиный-сызгыра. Кара йөзле хәрамиләр җәяүле килеш камауда калды. Иярдәге шәрә кызлар аларны урап, берьюлы

утыз ук төзеде. Яугирләр кылыч сабына тотынды.

— Берегез дә моннан исән ычкына алмас! — дип ярсып кычкырды Сөен тутай.— Һәр ук башагы ягырга манчылган. Бер тын белән без бишәр ук атачакбыз. Йөз илле агулы ук!..

Яугирләр ыңгырашып куйды. Алар селкенә дә алмаслык хәтәр тозакта иде. Суырылып чыга башлаган кылычлар янә кынnarга кереп чумды.

Сөен тутай тагын боерды:

— Яракларыгызны чишеп, уртага атыгыз!

Башка чара калмаган.— әмер катгый, үтәргә кирәк. Уртада йөз егермеләп кылыч, шулкадәр ук хәнҗәр, ук савыты, җәя өелде.

— Хәзер сез чишенегез инде! — диде Сөен тутай.

Яугирләр кыюсыз гына чишенеп, киемнәрен яраклары өстенә атты. Ике бот араларына ике уч кушырып, алар иярсез атлары утлап йөргән якка йөгерде.

— Исмәгыйль мирзагызга миннән сәлам күндерегез! — дип кычкырды Сөен тутай.

Дала уртасында бай үлҗә калды: бизәкле хәнҗәрләр, затлы кылычлар, болан мөгезле җәяләр, зиннәтләп чигелгән садаклар — ук савытлары, сәрпи уклар, йөз егерме тире чалбар-кандагайлар.

Ил буйлап тагын хәбәр таралды: Исмәгыйль мирзаның иң куәтле батырларын шәп-шәрә калдырып, йөз чакрым артларыннан куган Сөен тутай, дип озак еллар сөйләрләр.

Ләкин Сөен тутай үзе бу җиңүенә куанмады. Шомлы җиңү иде ул. Гауга белән тулган Нугай иленә яңа гауга өстәү генә булмасмы бу вакыйга? Эчен үт шеше баскан Исмәгыйль мирза шунда туктап калмас бит. Бу эшнең куалашу учагына яңадан кыздырган май сибү икәнен тутай бик яхшы төшенде. Бәс, даладан качарга кирәк. Соңгы күргән төше дә шулай куша, сәфәргә чакыра...

## Сәфәр

Төшендә ул тагын Ирәмбагны күрде. Бакча уртасындагы ханәкәдә истирахәт кылып утырганда, ул йөзенә күләгә төшкәнен сизде. Кем, ни-нәрсә каплады кояшны, дип күтәрелеп бакса, күк йөзендә Хумай кошы талпынып тора. Аның күләгәсе Сөен тутайның йөзенә, бөтен гәүдәсенә төшкән.

Зур куаныч белән уянды ул. Бу төшне юратып торырга кирәк түгел иде. Гаҗәеп матур, кинаяле бу төш аның — Сөенеч тутайның — олы дәүләткә, бөек абруйга ирешәчәген сөйли иде. Изге китапларда да, әүлияләр телендә дә, төшлекләрдә дә бар: Хумай кошының күләгәсе кемгә төшсә,— шул кеше падишаһ була. Атасы Йосыф мирза дөрес хыял кора, ул кызын бер-бер солтанга, бәккә, ханга дип үстерә түгелме соң? Шәддад падишаһны тапса, аның төше рас булачак. Аллаһ боерса... Хумай кошы төш аша аңа хәбәр бирә. Ирәмбаг белән Шәддад аны нык чакыра.

Карар өлгергән иде. Ун кешегә бер казаннан — өч казан, ун кешегә бер шөшледән — өч шөшле, җан башына берәр без, җәмгысенә балта-чүкеч белән бер тимер сандал вә яу яраклары, чатырлар, киез-келәм алып, утыз кызга алтмыш ат йөгәнләп, ахирәтләр кәрваны Ирәмбаг хакиме Шәддад падишаһны эзләргә озынозак сәфәргә чыгып китте.

Аблак бабаның тагын бер астарлы сүзен колагына элмәгән икән ул чүлдә чакта: әтәч булып кычкырган тавыкны суеп ашыйлар. Кермә ирләр өлешенә, башсыз калырсың, дигән иде баба. Егет кыяфәтендә ул хатыннарга бәла китерде. Бичара Айсөлек ту-

тай, Акмирза сурәтендә кыз кеше булганлыгын халыктан ишеткәч, агу эчкән. Комар бинең тезгенсез хатынының да мәсхәрә булганы халыкка таралып, бикәч үзенә хәнҗәр кадаган. Йә хуш, ул хәзер үз сурәтендә — әмма һаман тынычлык юк. Хәзер аңа егетләрдән гыйш-гашрәт хатлары ява, калын калым, алтын-көмеш төяп килеп, Сөен тутайны алып китәргә телиләр. Әмма ул, яучыларны да, кияүләрне дә күрергә теләмичә, качып бара. Кая бара? Төштә күргән Ирәмбаг падишасы Шәддадны эзләп бара. Шәддадны тапса, ни булыр? Бизәп куелган бер карачкы кебек бакча түрендә утырырмы? Шәддадның хәләле булса, падишаның яуданаудан кайтканын көтеп зар елармы? Атасы Йосыф мирза белән Аблак бабаның фикере бер иде: хатын — хатын булырга, ир ир булырга тиеш! Әмма ул шунысын да сөйләгән-әйткән иде:

— Яса канунында хатыннар дәүләт эшләрендә катнашырга тиеш, диелгән. Һәр корылтайда ханбикәләр дә сүз әйткән. Ире Үдегәй үлгәч, тәхет Түрәгин ханшага кала... Көек хан мәрхүмендә Таймыш бикә идарәне үз кулына ала... Мәңгү хан сабый чакта, анасы Сөеркүктәни бикә дәүләткә рәһбәрлек кыла... Караколак вафатыннан соң Урһан бикә ун ел тәхеттә утыра... Хубулай хан хатыны Гүкчен солтан да патшалык итә... Тимер хан үлгәч, Булган исемле хатынның хакимиятен сөйләмим дә... Йөз мең иргә торган хатыннар булган тарихыбызда, шөкер...

Юлга чыгар алдыннан Сөмбелтай Сарай көтепханәсендәге гаҗәп матур бер дәфтәрдән Зәринә патшабикә турындагы хикәятне күчереп алган иде. Кунышларда, далада чатыр-тирмә эчендә ятканда укырга, дип алган иде ул аны. Һич шөбһәсез, Зәринә Сөен тутайга бик тә ошаячак.

Кәрван юлыннан бераз читкәрәк кереп, тау чишмәсе янында чатыр корып, атларны көтәргә ике кыз куеп, юынып, ашап-эчеп, чатыр күләгәсенә кереп, кырын яттылар. Менә шул чакта Сөмбелтай Зәринә кыйссасын ачты. Мотрибчы-уенчы кызлар саз-кубыз чалды. Кемдер, кулына без-шөшле алып, өзәңге каешларын рәтли, кайсысыдыр ияр бауларын, каешканнарны тегә башлады, бар да юл эше, кул эше белән мәшгуль булды. Сөмбелтай «Хикәяти Зәринә»не көйләп укый башлады:

... Саккый атлы халык яшәмештер. Саккый хатынлары ир-ат берлә яуга йөрүмештер. Саккыйларда хатыннар бәкләр илә бер диванда утырмышлардыр. Өйләнүләр мондый булмыштыр: кияүҗегет бикәч-кәләш илә атта узышырлар имди, вә дәхи кылыч орышырлар имди. Җегет җиңсә, кыз аңар бикәч булыр. Кыз өскә чыкса, йә үлтермеш җегетени вә йә хурлык илә азат кыйлыр. Саккый хакиме Кидрәй падишаһ ай йөзле Зәринә солтана өйләнгәндер. Мидәй иленең хакиме Астриангәй Кидрәй падишаһка яуга йөргәндер. Кидрәй падишаһ яуга каршы яу чыкканда уң кулъякка хатыны Зәринә бикәне куйган. Кочаман каты орыш булгай. Кидрәй патша яу кырын ташлап качкай. Астриангәй солтан арттан җитеп, Зәринә бикәне иярендин алгай. Кылычым күк керсен, кызыл чыксын, диеп кизәнгәндә Астриангәй тораташтай катып калгай. Зәринәнең ай йөзинәй һәмән баккай. Ошбу гүзәллеккә кылыч ормам, ук атмасмын, дия бикәне азат кыйлгай. Астриангәй бөек җиңү яуласа да, башын иеп, кара сагышлы булып, каласына кайтгай. Кидрәй патша унлата ләшкәр җыйгай. Мидәй хакиме Астриангәй өстенә яуга чыкгай. Ошбусында аллаһ аңа җиңеш яулай. Астриангәй солтанны ул әсир алгай. Тоткын солтанны үлтерергә Кидрәй патша хөкем кыйла. Зәринәкәй бикәч адәме Кидрәй падишаһка әйтер: Астриангәй сәне галәбә кыйлды, мәне әсир алды, тик үлтермәди. Сән дә, падишаһым, тоткыныңа җан калдырып, аны азат кыйлгыл, димеш. Кидрәй падишаһ хәләленең гозерен һич тыңламый, солтани затка кы-

лыч күтәрә. Зәринәкәй бикәч җәһәт кылыч алып, әсир солтанга арка куеп, хәләл адәме Кидрәйгә каршы орышадыр. Бу орышта хатын ирен үлтергәйдер. Астриангәй Зәринәгә бөек тәшәккүрләр илә ватанына кире дүнәр. Куәт туплап, шөһрәт казанмакта Астриангәй тол Зәринәгә өйләнмәк эстәген игълан итә. Зәринәкәй янә әйтер язу аша Астриангәйгә: сән сәвәсең мәне, мән сәвәмен сәне, тик бикярдыр бу гыйш-гашрәт, белгел. Кешеләрем разый булмас вә ярамас хәләл мәрхүм Кидрәй җаны өчен. Илче-яучылар буш кул илә кайтыр имди. Астриангәй янә мәктүп юллай мәгъшукасы Зәринәкәй тол бикәчәй: сән, бикәчем, җаным саклап, мәне хатың илә үлтермешсен, дия үз пычагы өстинә аумыш, җаны чыкмыш...

Сөмбелтай, кыйссаны тәмамлап, дәфтәрен каплады.

— Шуның илә «Хикәяти Зәринә» бетте имди,— диде ул.

Мотрибчылар уйнаудан туктады. Тирмә эче тулы кайгы мохите. Ахирәтләр тыела алмыйча елый. Күз яшьләре елга булып ага. Сөен тутай да кымшанмастан озак утырды. Ул күз кабакларын йомган, сулышы сизелер-сизелмәс. Күз яшьләре бәреп чыкмасынга күз йомганмы ул, әллә фаҗигале язмышлар хәсрәте өчен эчтән генә кайгырып, сызлану аша рәхәт кичерәме?.. Баксаң, Сөен тутай Зәринәнең батырлыгына шакката-шатлана, Астриангәйнең егетлегенә сокланып сыгына. Йә-ә, Аллаһ Тәгаләм, Зәринәкәй солтан Кидрәй падишаһка хатынлыкка ялгыш чыккан. Кидрәй Зәринәгә өйләнеп хаталанган. Зәринә өчен — Астриангәй, Астриангәй өчен Зәринә яратылган бит. Нигә язмыш шундый ялгыш-хата кыла? Язмыш хатасы өчен нигә өч яхшы адәм харап булды? Зәринә никахлы иренең җанын кыярга мәҗбүр булды. Бәхетсез мәхәббәте Астриангәйне һәлак итте. Зәринә — бәхетсез тол калды.

Күп уйлады ул Зәринә солтан турында. Җаны белән үз итте ул Зәринә солтанны. Шундый хәлдә Сөен тутай үзе ни кылыр иде икән? Анысын ул үзе дә әйтә алмас иде. Алдагысын аллаһ белә. Ни генә булмасын, Сөен тутай әдәпсезлек вә йөгәнсезлек дошманы булса да, үзен суфи хатын-рабияләккә әзерләми. Ул Кидрәй белән Зәринә хатасын кабатларга тиеш түгел. Ул үзенә тиң адәмнең хатыны булачак. Андый ир очрамый икән, юк икән — юк, гомерлеккә ул үзен дуадак каз язмышына багышлар.

Юл өстендәге кунышларда, кәрвансарайларда сораштылар:

— Ирәм бакчасы вә аның хакиме Шәддад падишаһ турысында белмисезме? — диделәр. Әмма «дыр, бугай, ихтимал»дан гайре тәгаенләп сөйләүче очрамады.

Айлар үтте, ел йөрделәр алар, юлның иге-чиге күренми иде әле. Вакыт узган саен, челтерәп көлүләр кими барып, ахирәтләр бер-берсе белән сөйләшкәндә күкерт кебек кабынып китә. Сәбәпсез елаулар күбәйде. Кызларны сагыш чорнады. Эзләгәнең табылмаса, өмет һаман саен саега барса, ризасызлык башлана, кешеләр җирси, күңелне сагыш ялый, бәдәнне хаста баса. Нәтиҗәдә, кешеләр бу җәфаларның сәбәпчесен эзли башлый. Бу шом Сөен тутайның күңеленә дә кереп оялады. Кызлар дәшми. Кызлар түзә. Эчтән генә, кире борылырга иде, дип уйлый барысы да. Тутай югында аларның телләре ачыла, яшеренеп кенә чышын-пышын нидер сөйлиләр. Озакламый алар, үзара талашу гына түгел, Сөен тутайга да каршы әйтә башлаячак. Сөен тутай моны бик яхшы сизә. Сәфәр дәрте сүрелгәннән сүрелә барып, ахирәтләр сәбәпсезгә елый торганга әйләнде...

Шулай барганда явыз ниятле кешеләр аларның юлын кисте.

Ахирәтләр һәр кышлак, һәр кәрвансарайда бу як халыкларын кан калтыратып торучы хәрамиләр һәм бу юлбасарларның башлыгы усал Юргабай турында күп риваятьләр тыңлаганнар иде. Юргабайга юлыккан кәрванчылар, мең сакчысы булса да, исән-сау

кала алмый, йә мал-мөлкәтен биреп котыла, йә шунда кырылып бетә. Юргабай белән беренче очрашуда ахирәтләр чак качып котылды. Хәрамиләрнең тау-таш арасында йөрергә күнеккән атлары дала атларын куып җитә алмады. Ул көнне ахирәтләр, дала түрендә тирмә корып, төн уздырды. Артка чиксәләр, кышлакларга кадәр биш кунышлык юл сузылып ята. Алга — максатка барыр өчен бары бер юл: таулар, кыя-ташлар ураган тар сукмак. Бер ягы упкын, бер ягы текә кыя. Берәр олы сәүдә кәрваны килгәнне көтеп, шул кәрванга тагылып кына тарлавыкны кичеп була, дип, алар дала эчендә яшәргә булды. Өч көннән соң су бетте. Далада аларның тирмәсеннән башка бер чатыр, бер көтү күренми. Тозлы далада кем йөрсен! Кәрван килмиме икән, шул уңайдан турсыктулымнарга чишмә суы алырсыз, дип Ализәк белән Нәргәтайны тарлавык авызындагы чишмәгә юлладылар. Көн азагында ике ахирәт атларын күбеккә батырганчы куып кайтты. Ализәк сүз әйтә алмады, ияреннән савылып төшкәндәй төште дә, тирмә күләгәсенә егылды. Нәргәтай җир ярып кычкырды:

— Юргабайлар килә-ә! — диде.

Тирмәләрне, казаннарны ашыгыч җыеп, алар эчкәрәк китте. Тау чишмәсе янында ни булганны Нәргәтай сөйләде:

— Рәхәтләнеп су эчтек, битләрне, кулларны юып, тулыкларыбызга су алып, ияргә мендек. Кайтыр юл өстендә, тар сукмакта җәяүле бер адәм басып тора: йөрәккәем жу итте. Алда — Ализәк. Әлеге адәм, елмаеп, Ализәкнең тезгенен алды.

— Мин — Юргабай! — диде.— Мин сезне күптәннән аулыйм инде... Курыкма-аң... Миңа сезнең байлык кирәгимәс. Миңа хатын кирәк, кәләш кирәк. Без яудан кайтканда, казан асып, көтеп торучы сылу кирәк. Менә син...— Юлбасар Ализәкнең балтырын тотты.— Син күңелемә бик ошыйсың, тутай... Син миңа биш-алты юлбасар үстереп бирерсең, мин сине алтынга маначакмын...

Шулчак Нәргәтай әче сызгырып, атына тибә, Ализәкнең аты да, өркеп, алга ыргыла. Юргабай чак читкә китеп өлгерә. Куаклар артыннан егермеләп уклы җәя күренә...

— А-атма-а! — дигән тавыш ишетә кызлар.

— Бу Юргабай шулай каты кычкырды,— дип хикәясен тәмамлады Нәргәтай.

Шул мәҗарадан соң Ализәк бик нык үзгәрде. Аз сөйләшә, кубызына кагылмый, төннәрен йокламас булды. Сырхау басты, хәрамиләр аның котын алган, диделәр. Төннәрен тирмәдән чыгып, ул далада йөри. Саташа, диделәр. Ахирәтләр бик нык ялгыша. Сырхау түгел ул. Саташмый ул. Юлбасарлардан да курыкмаган. Йоклаганда Юргабайның исемен кычкырып әйтүеннән шүрләп, йокларга ятмый кыз. Төнге йөрешләреннән соң ул, кайтып егыла да, йокыга китә... Тезгенен тотып торганда Юргабай аңа шулкадәр наз илә бакты. Ализәк ияреннән ава язды. Бик тиз булды бу күрешү — ай күрде, кояш алды. Шулай да аты ыргылган чакта аның колагына Юргабайның: «Төнен үзең генә шушында кил, мин көтә-ем»,— дип серле пышылдаганы кереп калды. Ахирәтләре йоклап беткәч, ул гел шул тарлавыкка — Юргабай юлбасар белән күрешергә чаба. Эшне очлы күз Сөмбелтай сизде. Ализәкнең муенында алсу-көрән тап юк иде, төн узган саен таплар арта. Сөмбелтай бу хакта Сөен тутайга әйтте. Тутайның иреннәре җеп булды. Уйлап тормастан ул:

— Хөкем! — диде.

Нәргәтай тирмәгә атылып керде дә йокыдагы Ализәккә төртеп:

— Тиз бул, Ализәк ахирәт, эшеңне сизгәннәр! Тутай бик тә ачулы! — дип хәбәр салды.

Хыянәтчегә җәза бирү өчен вакыт билгеләнде. Тик ахирәтләр җыенына Ализәк килмәде. Атын тотарга дип далага киткән кыз

юкка чыкты. Алай уйладылар, болай киңәш иттеләр дә күтәргә булдылар. Озак күтәргә туры килмәде. Нәргәтай тирмәдән язу кисәге алып чыкты.

— Кара ясарга вакыты тар булган,— диде Нәргәтай.— Ализәк хәнҗәр очын канына манып язган.

«Бөек тутам Сөенечем, ахирәтем, ахирәткәйләрем. Мең кәррә гафу сорыйм. Мин инде күптән Юргабайныкы. Ярлыкаңыз! Сезне бакый сүүче Ализәк ахирәтегез».

Ализәкнең бу батырлыгына сокланган-көнләшкәннәр аз түгел иде. Авызы белән сүксә дә, Сөмбелтай да Ализәкнең бу кыйлмышын күңеленнән хуплады.

— Егерме тугызау калдык,— диде Сөен тутай, аннан соң Ализәк язуын, ачу белән ерткалап, далага сипте.

— Сукыр булдым,— диде ул.— Сизгән булсам, йөз камчы! Аң булың! Җәза котылгысыз булачак!

Яңадан суга баргач, кызлар чишмә янындагы таш астыннан язу табып кайтты. Язу Сөенеч тутайга аталган иде.

«Бөек тутаем, бу таба Малик патша гаскәрләре килә. Юргабай белән мин дә китәм. Сезгә юл ачык. Һичкем тимәс. Битикче Ализәк хатын».

Шул көннән соң кызлар арасы еш бутала башлады, кара ләббәйкәлек бетте, әйтерсең лә, алда аларның һәрберсен үз Юргабае көтеп тора, һәм алар, һичшиксез, шуңа ябышып кияүгә чыгачаклар... Чыннан да, озакламый Малик патша гаскәрләре, тау хәрамиләрен эзләп, бу якка килеп чыкты. Ләкин Юргабайның юлбасарларыннан җилләр искән иде инде. Аның каравы, гаскәрләр белән бергә ахирәтләр алае тарлавыкны бәла-казасыз кичте. Гаскәриләр үз юлы белән тауларга менеп китте. Ахирәтләр Чыгымчак каласына таба юл алды... Шатлык качты алайдан. Ализәкнең юлбасар, ата хәрами Юргабайга ияреп китүе барысын да шөбһәле уйга ташлаган иде. Инде бетте түзем, борылырга кирәк, дип, Сөмбелтай үз сүзен Сөен тутайга әйтергә җыенган көнне куанычлы бер хәбәр килде. Чыгымчак каласында, чиннар, ягъни кытайлар тукталышында булды бу хәл. Кытайдан Идел аръягына баручы кәрванбаш уйгыр адәменең юл мәҗараларын тыңлаганнан соң, Сөмбелтай аңа дәште: юл йөргәндә кәрванчының Ирәмбаг турында ишеткәне булмадымы икән, янәсе.

Уйгыр адәме сакалын сыпырып куйды да әйтте:

— Һе... Ирәмбаг-Ирәмбаг... Бәхет вә гүзәллек бакчасын эзли чыктыгызмы, бикәчлә-әр?.. Бар андый бакча, бар! — диде дә, сизеләр-сизелмәс елмаеп, ахирәтләргә бакты. Бакты да бар нәрсәне дә аңлады кебек һәм шигырь әйтте: «Илаһи ләтыйф вә хуш гөлбостан, каюсының эче туп-тулы гөл вә рәйхан; төрле-төрле нәгам белән былбыл, даим анда кыйлыр ирде гол-гол. Һәр агачның үзгә җимеше анда, ширбәт вә шәкәр ширин сачмеш анда...» Күрдем мин ул бакчаны, бөек Бабур дәүләтендә ирер.— Кәрванчы уйгыр юл өйрәтте.— Ун куныш аралыкта булыр ул ил... Чыгымчактан барып, Җиһангәр ханлыгына чыгу лазем. Җиһангәрдән Кашгар каласына барыш кирәк. Аннан Пәшивар шәһәре булыр. Пәшивардан Кабулга ирешсәгез, алдыгызда торыр гүзәллек вә бәхет багы! Ул бакчаны күргән, ул бакчага кергән тән вә җан сафлыгы алыр... Әмма юллар кыен — гүр газабы. Пәшивардан Кабулгача арада Хәйбәр тарлавыгын үтәсе бар. Олы кәрван вә сакчы гаскәр көтегез. Тарлавыкка үзегез генә кермәгез. Ул яклар хәрамиләр илә тулган. Хәйбәрне кичсәгез, Кабулга тиз җитәрсез, иншаллаһ. Анда Хумаюн солтан хөкемдар.

Сөен тутай, төшендәге кебек, ни үле, ни тере сыйфатта тыңлады кәрванчыны. Уйгыр агага бүләкләр биреп, рәхмәтләр укып,

ахирәтләр юлга чыкты. Авыр юл иде ул. Япанга чыккач, Сөен тутай уйга калды, туктадылар. Егетләр кыяфәтен алсалар, юлбасарлар илә кылычка-кылыч орышырга, кырылырга туры киләчәк. Кызлар сурәтендә йөрсәләр дә аларга куркыныч — хәрамиләрнең никахсыз хатыны булып, гомерең коллыкта узачак. Башта алар егет киемендә йөрде. Һәм хак, аларны ир-егеткә санап, куа чыктылар. Бу орышта өч ахирәт һәлак булды. Хәл шундый мөшкел иде, бары тик атларның җитезлеге генә коткарды. Бичара өч ахирәтнең гәүдәләрен җир куенына тапшыра алмаганга үкенеп, үксеп еладылар. Кыз сурәтенә кереп йөргәндә алар тагын мөшкел хәлдә калды. Кичү янында аларны хәрамиләр урап алды. Бу юлбасарлар өчен ахирәтләрдән мал да, җан да кирәк түгел икән.

— Ике кыз! — диде атаман юлбасар.— Менә шушы ике кызның бирәсең дә, әнә бара юлың, кичү — сезнеке. Бирмәсәң, егерме алтыгыз да безгә була! Таулар арасында без сезгә кияү табарбыз.

Нишләргә тиеш иде соң Сөен тутай? Җан өшеткеч булды ул аерылышу. Мәңгегә аерылышу. Кызларның күзенә карамаска тырышып әйтте:

— Алыгыз! — диде.

Кызлар, тутайның аякларына асылынып:

— Бирмә, тутай, бирмә аларга! Харап итмә! — дип үксеп-үксеп елады.

Хәрамиләр аларны Сөен тутай балтырларыннан каерып алдылар да, атларга салып, таулар арасына кереп киттеләр. Юл ачык иде.

— Егерме дүрт калдык! — диде тутай.

Сөен тутай тешен кысып озак барды. Берәү дә сүз кузгатмады. Әмма ул шуны бик яхшы белә иде: Ирәмбагны тапканчы, бөтен ахирәтләре кырылып бетсә дә, ул йөриячәк, ялгызы йөриячәк.

Ләкин бу әле соңгы югалту түгел иде...

Гаҗәеп күрекле очрашу булды ул. Татлы сүзләр, гүзәл вә ләззәтле җырлар, сарайның зәукый ләззәт бирә торган хәзинәсе, алтынлы мәрмәр сандали-тәхетләр «Аһ, сөбһаналлаһ» сүзен теленнән тартып ала. Шәһәрнең төзеклеген күреп, нәфисәи сәнгать сарайларын, ул сарайдагы рәссамнар ясаган сурәтләрне күреп, ахирәтләр биһуш булды. Сөен тутайга иң куәтле тәэсир иткәне гүзәл бакча вә аның хуҗасы Хумаюн солтанның атасы Бабур падишаһ белән утырыш, мөсәхәбә кылышлар булды.

Хәйбәр тарлавыгы янындагы хәтәр маҗарадан соң, Кабул шәһәренә җитеп, дүрт көн хәл алгач, Хумаюн солтан ахирәтләр янына үзе килеп:

— Динкардәшләремез, телкардәшләремез, еракган килгән Сөен тутай вә ахирәтләри, сезләр Һиндстанның илек падишаһы Мөхәммәт Бабур атам хозурына боерыңыз! — диде.

Бөек Һиндстан мәмләкәтенең бөек хакиме Бабур падишаһ аларны Кабул тарафындагы Адинапурда, үзе үстергән Багый Вафа бакчасында кабул кылды. Хуҗа Сәрәян атлы чишмә тирәли вә дәхи, гүлләр, буалар әтрафындагы җимеш агачлары: кирни, җамән, камрак, бадхал, бәир, пәниала, хөрмә, әфлисүн, нар, шафталы, сәнгатар вә садафал, амрупал вә амалбидлар рәхәтләнеп үсә; исемнәре дә ишетелмәгән, җисемнәре дә билгеле түгел гөлләр анда чәчәк ата; шул чәчәкләрдә, агачларда йөз төрле тавыш белән сайрар кошлар кайнаша: шәрәк шөлди, кәнҗал вә пүлпәйкәр, харчал вә чарыз, тәвәторна вә сарас, маник вә ләкләкләр, ак бүзәк вә киек үрдәкләр, кызыл саескан, чуар куил вә олы карлыгачлар, зәңгәр тавис, аллы-гөлле тутыйлар колакларга рәхәтлек бирә. Арыкларда челтерәп чишмә суы ага. Хуш исле, ширин вә сирин бак-

чага кергәч, үзеңне ләззәт ефәгенә урангандай хис итәсең. Төшме бу, әллә өнме икәнен бу бакчада аерып булмый. Өнсез калган тутайларны Хумаюн солтанның сак тавышы уятты:

— Боерыңыз, чәһрияр бәгимнәр!

Хумаюн алданрак, кызлар арттарак йөреп китте. Арыклар арасындагы тар сукмаклардан йөреп, киңрәк юлга чыктылар. Кызлар, су сиптергеч көпшәләрне күреп, хәйран калды. Гаҗәп, дип уйлады Сөен тутай, атам сараендагы су көпшәләре — көмеш, бабам Идегәй су бөркегеч көпшәләрне алтыннан эшләткән, диләр. Никадәр бай булса да, Багый Вафа бакчасына Бабур падишаһ алтыннан да, көмештән дә сиптергечләр куйдыртмаган, чүлмәк көпшәләр эшләткән.

Сөен тутайның ни уйлаганын сизенепме, Хумаюн солтан:

— Атам Бабур падишаһның гозере шулай,— диде.— Көпшәләрне кызыл балчыктан эшләп, яндырып куялар. Мондый көпшәдә су салкынрак та, тәмлерәк тә була.

Олы сукмак аларны күл буена китерде. Күлдә аккошлар каңкылдаша. Күлдән бераз читтәрәк, ике агач арасындагы сандалидә бөек Һиндстан дәүләтенең бөек хөкемдары атаклы Мөхәммәт Бабур падишаһ утыра иде. Кошлардан башка падишаһ эргәсендә җан иясе юк. Падишаһның утырган сандалие бик тә садә, әмма гаҗәеп матур агачтан эшләнгән. Бабур бакча киеме кигән, яшел төстәге бизәкле читеге өстеннән зәңгәрсу башмак элгән. Уң башмагын салып, аягын сул тезенә куйган, озын җиңле кызыл бикасәп өстеннән алтын ука белән чигеп, җәйран сурәтләре ясалган, кыска җиңле, киң якалы көртәй кигән, билендә асылташлы кыйммәт камәр түгел, билбау. Билбавыннан алтын зынҗырлы котыйчык асылынган. Хакимнең башында зур чалма, чалма маңгаенда асылташлы мөштек, мөштеккә кара ләкләк каурые кадалган. Падишаһ китап укып утыра иде. Аның уң ягында чия агачы чәчәк аткан, сул ягында — шомырт агачы. Сөен тутай уйлап куйды: безнең якта үсә торган агачлар янына махсус утыргандыр. Хумаюн солтан чак ишетелерлек итеп әйтте:

— Падишаһ күңеленә хуш килгән миһманнарны гына бакчада каршылый,— диде.

Падишаһны күрүгә, ахирәтләр бил бөгеп, баш иеп тәгъзим кылды. Падишаһ, китабын ябып, янәшәсендәге көрсигә куйды. Хумаюн солтан, мәгърур вә тантаналы сурәттә атасына тәгъзим ясап сүз башлады:

— Бабамыз Гомәр шәех углы бөек хаким атамыз Мөхәммәт Бабур падишаһ! Углың Хумаюн солтанны ерткыч дошман Шерхан тырнагындин коткаручы синең каршыңдадыр!

— Мәрхәбә вә мәртәбә! — диде Бабур падишаһ.— Әфарин!

Күрәсең, Хумаюн шаһзадә Хәйбәр тарлавыгы әтрафындагы җәйләүгә сунар чыкканын да, дошманы әфгани Сур токымы Шерхан тозагына эләгеп, күп дусларының үлгәнен дә, үзен дә, бу тутайлар килеп чыкмаган булса, үлем көткән булуын тәфсилләп сөйләгәндер. Ихтимал шуңадыр, падишаһ сокланып-сөеп карый кызларга. Ул янә әйтте:

— Риваятьләр йөри. Амузыннар, ягъни атменәр, кылыч тотар кызлар турында тарихларда язалар. Җиһанда кырык алты ел гомер кичереп тә кыз яугирләрнең кылыч, җәя белән ир баһадирларны хәрабә вә тәхкыйрь кыйлганыйна һич инанмас идем. Хупхәер ки, инде инандым. Бу җәсүрлегеңезгә күрә, тәхети дивандан, умәрәдән, вәзарәдән, экавирдан вә әфазыйлдан кем бар исә, җәмгыйсы әфарин вә тахсин әйләдиләр вә солтан Хумаюн сезләргә Һиндстан энҗесе илә исмарланган чәч тажы верир.

— Без, падишаһым, күңелебез боерганча кылдык,— диде Сөен

тутай.— Бөек рәхмәтләремез! Аннан соң,— диде тутай.— Үземнең ерак канкардәшем, агам кешегә Аллаһ Тәгалә ярдәмгә өндәгән, мотлак.

Падишаһ та, яшь солтан да ялт итеп тутайга бакты, аларның башыгында бер сөаль яна иде: ничек? Кай яктан кардәш? Син үзең кем баласы?

Бабур падишаһ белән Хумаюн шаһзадә — шигырь вә кинаяле сөхбәттә азау ярган бәхәсчеләр, астарлы гыйбарәләр остасы, һәр табышмак вә мәкальнең төбенә тиз төшә торган, төртмә вә татлавыз әһелләре иде; юлаучы кызның Хумаюн шаһзадәгә ничек канкардәш булуын алар аңлап бетермәде. Аларның гаҗәпсенгәнен күреп, Сөен тутай янә әйтте:

— Падишаһым-солтаным! — диде.— Сарай каласының олуг шагыйре Сәйф Сараи Камышлы әйтәдер ки: Җир Кояш тирәли әйләнәдер. Түгәрәк Җир түгәрәк Кояш тирәсендәге бөҗра буйлый бөтерелә икән. Арбамызның көпчәк-тәгәрмәчләре дә бөҗра, падишаһым. Ә бөҗра — чиксез, азаксыз-очсыз. Дөнья түгәрәк нәрсәләрдән генә тора. Шакмак та түгәрәк, хәтта кеше гәүдәсе дә түгәрәк. Кендектән карыш белән бу якка үлчәсәң дә, теге якка үлчәсәң дә — бертигез чыгачак. Сәйф Сараи әйткәнчә, түгәрәк Җир дүрт фасылны: кыш, яз, җәй вә көзне узып, түгәрәк Кояш тирәли мәңге бакый бөтерелә дә бөтерелә. Һәм һәр узган фасылына барыбер әйләнеп кайта. Кешеләр дә Җир-Җиһанда күпме генә күчеп йөрсәләр дә, үз чыгышына, үз халкына әйләнеп кайта. Ир әйләнеп сөягеп табар, ат әйләнеп тияген кабар.

Сөйләшү җебенең очы бик озын булса да, падишаһ өчен бу гаять кызык иде. Мондый фәлсәфәгә кергән суфиларны Бабур падишаһ үз юлында күп күрде. Аларның күбесе, уйлый-фикерли торгач, кире мантыйкка килеп чыга да, үзләре корган фәлсәфә тозагына кереп адаша.

— Әйттем ки, падишаһым,— дип дәвам итте Сөен тутай,— каты матдәләрдә генә түгел, күренешләрдә дә чикләнмәгәнлек чиге бар. Түгәрәк мәйданга ике ат җибәреп карыйк. Берсе, һичшиксез, узачак. Яхшы тай, артык алга китеп, артта калган ябаганың артыннан җитә килгәндә, ул үзе түгел, ә ябагасы алдан чабадыр кебек була. Җиһанның тоткасы түгәрәк-бөҗра әнә шундый имәнгеч үзгәрешләр ясый... Бәс, артык тизлек имәнгечлеккә, гайре табигыйлеккә илтә. Җәмгыять мохите дә шулай: бер әйләнә дә бер баса. Хәтта Җир йөзендә булып узган вакыйгалар да яңадан кабатлана, үлгән кешеләр дә, үз фасылы килеп җиткәч, янә яши башлый, янә үлә... Җиңелмәс Чыңгызлар, Батыйларны да куласа басты. Бабагыз әмир Тимер дә җиһандар булып, Җиһанны куласадай әйләндерде-әйләндерде дә, үзе дә әйләнде, мәрхүм. Бабамыз әмир Идегәй дә дөньяны серле бөҗрадай зыр китерде... Әмир Тимер белән әмир Идегәй — ике дус вә ике кандошман. Шул ике дус вә ике кандошманның торыннары менә Җиһанның тап уртасы Багый Вафа җәннәтендә очрашты. Ходаның бирмеш көне, тау белән тау гына очрашмый, адәм белән кеше очраша. Әмир Тимер оныгының баласы Гомәр Шәех мирзаның углы син Заһретдин Мөхәммәт Бабур падишаһ, синең углың Хумаюн солтандыр.

Сөен тутай туктап тын алды. Бабур падишаһ сокланыш вә аптырашта иде. Өч тәүлек буена якыннан күрешеп яшәгәнлектән, Хумаюн солтан үзе бу батыр кызларның могҗизаларына ияләшә төшкән, шуңа күрә бик үк аптырашта түгел, бу сөхбәтнең атасына бик тә хуш булганлыгына куанып, елмаеп басып тора.

— Дөрест! Хак! — диде падишаһ һәм урыныннан калыкты.— Яртылаш бихуш падишаһыңны тулы бихуш итәргә теләсәң, үзеңнең кемлегеңне бәян иткел, и гүзәл бәгим!

Шулчак агачлар арасыннан Кояш чыга башлап. Хумаюнның күләгәсе Сөен тутайга төште. Сөен тутай елмаеп әйтә куйды:

— Падишаһларга падишаһ Мөхәммәт Бабур падишаһ! Кашыңда — гәүдәсенә, чәһрәсенә Хумай күләгәсе төшкән бер зат тора.

Дөрестән дә, бу җавап падишаһны аяктан екты. Бабур сандали-тәхетенә кире утырды.

Беренче углы тугач та Бабур падишаһ моңарчы күрмәгән, колак ишетмәгән туй уздырды. Хумай кошының күләгәсе төшкән адәм, һичшиксез, зур түрә була, аның беренче углы да үз урнына падишаһ булсын дип, ата кеше сабыйга Хумаюн аты куштырды. Амузын кыз, дала кызы боларны каян белә?

— Әстәгыфируллаһ! — диде хаким, аптыравын яшермәенчә.— Машаллаһ вә машаллаһ! Җиде икълимнең бишесен гиздем. Сайрар кош теле белән татлы сүз сүзләгән һәм дә кулда гаделлек кылычы Зөлфикарен уйнаткан бундай чәһриярны ишетеп бакмадым... Бирсен Ходай! Син инде мәртәбәдә басып торасың!

— Амин! — диде Сөен тутай.— Идегәй әмир — Тимер әмирнең кияведер. Тимер әмирнең иң чәһрияр кызы Акчәһрәнең беләге бабамыз Идегәйнең мендәре булгай. Идегәйнең углы Норадындыр, аның углы булса Уәккас, аның углы Муса, аның углы минем газиз атакаем Йосыф мирза булыр. Мин Сөенеч тутай атлы торырмын!

— Углым Хумаюн шаһзадә,— диде хаким.— Син миңа олуг бәйрәм ясадың бүген. Кашымызда Нугай йортының олуг мирзасы Йосыф кызы Сөенеч тутай бәгим пәйда булды.— Падишаһ аягына басты да, кочагын ачып, Сөенеч тутайга таба атлады: — Килең, килче яныма, кочыйм үзеңне!

Сөен тутай, атасына сыенгандай, падишаһка якын килеп, яңагын аның күкрәгенә куйды.

— Мәрхәбә вә мәртәбә! — диде падишаһ.— Хуш килдең, сөекле бәгим.

Шуннан соң олы кунаклар шәрәфенә олы мәҗлес җыелды. Мәҗлес дәвамында Бабур падишаһ углы Хумаюнның колагына пышылдады:

— Хумай кошының шәүләсе төшкән тутай бәгим Хумаюн солтанның бикәсе булырга тумаганмы? — диде.

Адинапурдагы Багый Вафада күп тапкырлар истирахәт кылганда Сөен тутай бер хакыйкатькә төшенде. Бу бакча Ирәмбагтан да гүзәлрәк булып чыкты. Димәк, ул теләгенә иреште. Фани дөньяда да җәннәт бакчасы төзеп була икән.

Бабур падишаһ белән озын-озак сөйләшкәндә дә бу хакта сүз булды. Сөен тутай нинди максат белән Ирәмбагны эзләп, куркыныч мажаралы сәфәргә чыкканлыгын әйткәч, падишаһның елмаюы югалды, ул сабыр, әмма җитди-кырыс тавыш белән әйтте:

— Сабыйлык хыялы... Сигез-тугыз яшемдә мин дә эзләдем ул хыялый Ирәмбагны. Чын күңелдән инанып эзләдем. Атакаем Гомәр Шәех бу бикяр эштән мине тыймады. Углының китап укып, хыялга батканына ул, ихтимал, куанган. Үсә төшкәч, бу хыялый хәяттән айныр, дип, атакаем мине бу уемнан аермаган... Бәтчәләр, мирзачыклар белән бик озак эзләдек Ирәмбагны. Унике яшемдә, атамның тәхетенә насыйп кылынгач, аңладым ки: Ирәмбаг ул — хыял. Әмма «Ирәмбаг» дип аталмаса да, «Багый Вафа» исемендә гүзәл бакча корып була икән.

Сөен тутай өстәп куйды:

— Ирәмбагтан да — хыялдан да гүзәлрәк Багый Вафа! Ләкин аермасы бардыр. Шәддад хаким үзе корган җәннәти бакчасында бер мизгел дә хәяти ләззәт кичерә алмый вафат булган...

Бакчада атналар буе истирахәт кылганнан соң, Хумаюн Сөен ту-

тыйны иң зур китапханәгә алып керде. Андагы хәзинәне күреп, тутай хәйран калды вә Хумаюн солтанга ишетелерлек итеп пышылдады:

— Менә аның сәбәбе кайда! — диде.— Бакчадагы чүлмәк көпшәләр алтын булса яхшырак, матуррак. Менә ул байлык, менә ул алтын көпшәләр кайда!

Китапханәнең зурлыгына, китапларның күплегенә сокланмау мөмкин түгел иде. Китап йорты белән чагыштырганда, падишаһның сарае кечкенә алачык кебек. Казан, Кырым, Хаҗитархан, Сарайчык шәһәрләрендәге китаплар — алачыкта, ханнар үзләре — алтын сарайда... Китапларның муллыгы — бер хәйран булса, тәртиппөхтәлек, серлелек һәм китапка, кулъязма дәфтәрләргә олы хөрмәт монда хаким. Падишаһ үзе дә, солтаннар, шаһзадәләр дә монда аяк очына басып йөри, пышылдап сөйләшә. Китап монда патшадан да олы. Монда йөзәр хәттат-бахшылар күчереп китап яза, китап төпли.

— Язын-җәен кайчак янгыннар була,— диде Хумаюн.— Янгын була-нитә калса дип, китапларның күчермә нөсхәләре икенче бинада саклана.

Сөен тутай бүлекләп-бүлекләп куелган, аңа таныш булмаган язу белән язылган китапларның муллыгына шаккатты.

— Бирedә Рум, Фрәнк, Юнан, Чин, Борынгы һинд китаплары саклана...— диде Хумаюн солтан.

Китапханәдән чыккач, Хумаюн солтан Сөен тутайны тагын да зуррак, биегрәк бинага алып керде. Иң зур могҗиза аны шунда көткән икән. Сөен тутай башта һични аңламады. Йортның түшәме биек, тәрәзәләр дә киң-биек эшләнгән. Тәрәзәсез диварларга бихисап күп рәсемнәр эленгән. Дивардагы рәсемнәрне әрҗә белән кыршаулаганнар. Идәндә, почмакта бер-берсенә, диварга сөяп куйган рәсемнәр бихисап. Тора-бара, күз ияләшә төшкәч, җентеклəбрәк карагач, рәсем үзенә тартып китерә.

— Бу бина,— диде Хумаюн солтан,— осталар ханәсе, нәкъкашларның, рәссамнарның рәсемханәсе.

Яу күренешләрен, затлы тәхеттә утыручы түрәләрне, җанвар-киек, тау чишмәләре рәсемнәрен карап йөри торгач, тутайның башы әйләнә башлады. Хумаюн солтан аны бакчага алып чыкты.

— Атам Бабур падишаһ Шираздан да, Тәбриздән дә, Дәһлидән дә, Аһра каласыннан да осталар чакыртты. Һиндлы нәкъкашлар, әфгани, төрки рәссамнар, һурду осталары монда эшли.

— Ислам сурәт ясарга кушмый,— диде тутай.— Җансыз сурәт ясаган бәндәнең җанын кыямәт көнендә шул сурәтләр сорар, ди. Сурәтче җанын бирмәс өчен йөгерер, ди. Куып җитеп, сурәтләр аның җанын алып, үзара бүлешерләр, ди.

Хумаюн солтан тутайның хикәятен елмаеп тыңлады. Сөеп-сөенеп тыңлады ул Сөенеч бәгимне. Сокланып тыңлады. Рухында да, тәнендә-бәдәнендә дә ир батырлар белән алышырлык гаярьлек саклаган шушы тутай бәгим әле бала гына икән. Хумаюнның кычкырып көләсе килде. Сөен тутай үпкәләр дип, ул көлмәде, шулай да җавапсыз калмады:

— Хак булырга тиеш,— диде солтан.— Бик тә хәтәр, әмма бик тә яхшы булыр иде, шулай булса.

Тутай аңламады.

— Ә ни өчен? — диде ул.— Бичара сурәтче кызганыч түгел-мени?

Хумаюн солтан Сөен тутайны бакчаның аулак почмагына, аккошлы күл буена алып барып, агач күләгәсендәге көрсигә утыртты. Үзе аягүрә калып, аңламас шәкертенә дәрес өйрәтүче остаз кебек сөйли башлады:

— Рәсем ясаучы үзе гаепле,— диде ул.— Сурәтенә җан иңәрлек булмагач, бу эшкә алынмаң! Башка, файдалырак һөнәр сайла. Арба яса — бик күркәле эш. Тире илә, күн, каеш яса. Рәхмәтле шөгыль. Маллар көт — чабан бул. Токымың ач булмас. Әмма куәң булмагач, сурәткә тотынма. Тотынгансың икән, ахирәттә җавап бир! Гөнаһсыз, җансыз сурәтләргә җаныңны яргалап бир. Аларның гаебе юк. Син аларны шулай җансыз яраттың. Ясаганда ук рәссам, үз җанын кыеп, сурәткә салмаса, рәссам була алмый, тутайбәгим. Ул гарипләр, җан талаучыларны гына үрчетәчәк. Чын рәссам өчен ахирәт куркыныч түгел. Чын рәссамның сурәтләренә ясалып бетү белән җан керә. Җанлы-гүзәл сурәт ясаган саен, сурәтченең җаны кими бара. Шул сәбәпле чын рәссамнар озын гомерле булмый, иртә үлә. Әмма ахирәттә ул рәссам мәңгелек җанга ия булачак... Ислам сурәт ясарга кушмый, дисең. Ислам җансыз сурәт ясарга кушмый, дип шәрехләп буламы?

— Була,— диде тутай.

— Аллаһ тәгалә киң күңелле, миһербанлы вә кодрәт иясе. Гүзәллек яраткан бәндәсен ярлыкарлык кына кодрәте җитәр, иншаллаһ! Адәмнәргә зәукый ләззәт бирердәй җанлы сурәт иҗра кыйлган рәссам җәза урнына Аллаһдин алкыш-савап алачак түгелме?.. Без — атам белән мөэмин мөселман. Мөхәммәт өммәтеннән, Ходага мең шөкер, Ислам өчен газават юлында күп йөргәнбез, иншаллаһ, алда да шулай булыр, әмма нәкъкашлар, рәссамнарның иҗра кылган әсәрләрен без Коръән Кәрим берлә бәрабәр саклыйбыз! Без — Ислам төркиләре, әмма Һиндстанда мәсҗетләр белән янәшә Будда сарайлары салдырабыз. Ислам киң күңелле булырга куша.

Сүзе төкәнгәч, Хумаюн солтан Сөен тутайның йөзенә бакты. Аның йөзе борчулы иде. Әле генә ишеткән сүзләр, андагы яңалык тутайның ихтыярын алган, ул сүзсез генә су өстендәге аккошларга карый. Күз карашы кошларда, күңел күзләре Хумаюнда. Солтанның үзенә текәлеп карап торганын күргәч, тутай әйтте:

— Мин хәзерендә һич сүз табалмыйм... Ни диярга дә белмим... Сөйләгәнең минем өчен чи каештан бәйләнгән төен...

— Монысына җавап кайтармасаң да мәгъкуль,— диде Хумаюн солтан.— Ә менә хәзеренгесенә җавапсыз калу гөнаһ булыр.

Сөен тутай елмайды да әйтте:

— Сөаленә күрә җавабы! — диде.

Икесе дә көлде. Сөен тутай, Хумаюнның сүз башлавын көтеп, җайлабрак утырды. Сөен тутай аның ни әйтәсең чамалый иде. Солтан кыюсыз гына болай диде:

— Сөенеч тутай, зинһар, гаҗәпсенмә... Атаң Йосыф мирза да ерактa. Син үзеңә үзең баш. Бәс, йоладан тайпылып, мин дә үзбаш сүз әйтәм. Хумай кошының күләгәсе икебезгә берьюлы төшсен иде...

Хумаюн солтан сүзен өзде. Сөен тутай читләтеп әйткән сүзне аңлап бетерсен дип түгел, тутайның ике күзендә дә яшь тамчысы күреп, ул шөбһәгә калды. Бер үк вакытта ул сөенде дә. Бәлки, бу шатлык яшьләредер.

— Кичерең, солтаным,— диде тутай. Ул, җиңеннән кульяулык чыгарып, күз яшен сөртте. Хумаюн әле һаман аптырашта тора иде.

— Мин аңладым сине, Хумаюн солтан. Сине аңлаганга күз яшьләрем бәреп чыкты... Мине солтан бикә итеп никахлашырга теләвең минем өчен сөйләп бетергесез мәртәбәдер. Олуг рәхмәтләрем сиңа. Мондый бәхет хан кызларына да тимәс. Әмма, мең кәррә кичер, Хумаюн солтан, мин Кабулга килен булып төшә алмыймын. Күп уйландым мин бу бакчада. Мин бәхетсез яратылган бугай. Мәхәббәт белән Мәҗбүрият орышы арасында һәлак бу-

лырмын, ахрысы... Төшләремдә гелән күрдем мин Ирәмбагны. Шәддад падишаһның мәгъшукасы булдым. Уянып киткәч тә мин Ирәмбаг вә Шәддад исмен кушып күп тапкырлар саташтым. Ни газаплар аша узып, мин хыялыма ирештем: менә мин җәннәт багында утырам, кашымда Шәддадтан да затлырак солтан үземне хәләллеккә сорап тора. Мәҗбүрият-Мөһимият дигән упкын аера безне, солтан. Илле көнлек ара ята ул упкында. Монда гүзәл бакча инде күптән шау чәчәктә. Минем кирәгем юк бу бакчага. Баксаң, Шәддад падишаһ түгел икән мин шашып эстәгән, юк, Шәддад түгел... Миңа бакчасы, бакчасы кирәк икән. Ләкин ул бакчаның үз ягымда булуы әүвәлге шарт. Бәс, шул сәбәпле мин, Шәддад падишаһны тапмыйча ук югалтырга мәхкүм.

Бу сүзләрне сөйләгәндә Сөен тутайның ике күзеннән яшь өзлексез агып торды. Хумаюн солтан аның фаҗигале тавыш илә сөйләвеннән, күз яшьләрен тыя алмавыннан ни кылырга белми гаҗиз булып калган иде. Ихтимал, ул Сөен тутай никахтан баш тартыр, дип уйламагандыр; бәлки, ул шул сәбәпле каушап калгандыр. Мәхәббәт солтанны алыштырганнармыни, ул коелып төшкән, бичара хәлдә. Сөен тутай аңа ачынып карап торды да янә үксеп, солтанның ике кулын алып, кайнар яшьле йөзенә куйды. Шул кулларны үбә-үбә, күз яшьләренә чылатып бетерде.

— Кичер мине, кичер Тәңрем хакына, хатын булып киләлмәемен синең катыңа,— дип такмаклый үзе.— Әмма атаң илә син солтанны мәңге онытмам, истән чыгармам. Без синең илә абый белән сеңел...

## Карт кыз

Бу сөйләшүдән соң ахирәтләр Кабулда әле шактый яшәде. Сөен тутай сәгатьләр буена китапханәдә укып утыра, аннан соң остаханәгә керә; нәкъкашларның балчык-буяу изгәнен, кысаларга киндер тарттырганын озаклап күзәтә. Аннан соң Багый Вафага юнәлә.

Яңгыр фасылы узганчыга кадәр Сөен тутай ахирәтләре илә Сарай янындагы аерым ханәдә яшәде.

Зур бүләкләр — Сөен тутай өчен иң зур бүләк падишаһ китапханәсендә бахшылар күчергән бизәкле, сурәтле «Шаһнамә»нең, «Хөсрәү вә Ширин»ның төркичә нөсхәләре һәм башка китаплар төяп алар кайтыр юлга чыктылар. Хумаюн солтан аларны ун куныш ара үз гаскәре илә озата барды. Алар елашып, кочаклашып аерылыштылар. Йөрәкләрендәге мәңге ачылмаячак мәхәббәт бөреләрен алып, Хумаюн солтан — Кабулга, Сөен тутай Җаекка кайтып китте. Хумаюн солтаннан аерылгач, аны сагыш басты. Ул, Бүзтарланын ашыктыра төшеп, алгарак чыкты да рәхәтләнеп елады, бушанды. Үҗәтлеге, кирелеге аркасында Хумаюн солтан никахыннан ваз кичүенә ачыну да, юл йөргәндә югалткан дистә ярым ахирәтен искә төшереп өзгәләнү дә иде бу. Харамиларга хатын булып калганнары, канлы орышларда һәлак булганнары, Кабулда чакта хасталыктан җан биргән ахирәтләре турында уйласа, ул һәрвакыт җаны белән елый. Хумаюн солтан никахыннан баш тарту да, ахирәтләренең фаҗигале язмышы да аның бәгырендә гомер төзәлмәс җәрәхәт булып калыр, әледән-әле ачылучы иске яра кебек, әҗәленәчә үзе белән йөрер. Утыз ахирәтеннән ундүрте исән калып, атасы Йосыф мирза биләмәләренә, туган-үскән Айдалага Бүзтарланның тоягы баскач, зиһене яктырып киткәндәй, ачык тойды: ияр, кылыч ташлап, һичшиксез, падишаһка чыгачак ул; бә-

хәссез. Аллаһ кушса, ул күп бала табачак, вә бай көтепханә илә истирахәт бакчасын үзе корачак. Аның Мәхәббәте өч вазифадан торыр: бала, китапханә, гөлбакча.

«Ә илаһи мәхәббәт? — диде ул үзалдына.— Мәхәббәт татымый гүр иясе булачакмынмы?»

Мәхәббәт?.. Сөен тутай мәхәббәттән башка яшәмәс. Иренә булмаса да, баласына булыр ул мәхәббәт. Иренә булмаса, иленә булыр ул мәхәббәт. Әмма, иремне сөймим, дип, үзен кимсетмәс, дошман сөендермәс... Ихтимал, уртак баланы сөю, бала атасына да күчәр. Бәлки, ул булачак иренә бер күрүдә гашыйк булыр! Бирсен Аллаһ! Амин, берук!

Сабый кыз булып сәфәр китеп, ничә ел мажаралы горбәттә йөреп, Нугай иленә житкән кыз, бикәч кайтып килә.

Далага дөя көтүе таралган. Көтү янында ике карт чабан һәм житез атка атланган бер үсмер кайнаша. Сөен тутай кычкырып сәлам бирде. Чабаннар аның кем икәнен тиз аңлады, ахрысы, комга төшеп, баш ордылар. Үзләре бертуктаусыз бер сүз кабатлый:

— Сөенче! Сөенче! Тутаебыз исән-сау!.. Сөенче, сөенче, Йосыф бәктән сөенче!

— Йосыф бәктән? — диде тутай.— Ялгышмы әйттегез?

Картлар моннан ел элек Шаехмамай түрәнең вафат иткәнлеген һәм дә Сарайчыкта тәхеттә Йосыф бәк калганын сөйләп бирде.

— Бабаң Муса түрәдәй, атаң Йосыф бәк тәхетендә картайсын! Амин! — диде чабаннар.

— Амин! — диде ахирәтләр.

Бу сөенче өчен Сөен тутай чабаннарга өч дирхәм ташлады.

— Бирегә кил,— дип, ул көтүче үсмерне чакырды.

— Боек тутакаем,— диде көтүче.— Башым өсте, йөз түбән, буй сынулы, тез чүгәм.

— Мәң! — диде тутай-бәгим.— Калага йөр! Атам Йосыф бәккә хатны житкез!

Сөенче алырга дип, үсмер Сарайчыкка чапты.

«Газиз атакаем Йосыф бәк! Әссәламегаләйкем вә рәхмәтуллаһе вә бәрәкәтеһү! Озакламастан өйдә булырмын. Жаным сине сагынды, тәнем һаман сыгынды. Мунча яктыр. Ташы шартлап кыза торсын! Хода кушса, тиз күрешербез,— диелгән иде хатта,— сөенчегә бу егеткә корыч хәнжәремне, бүре бүркем, алача тунымны багышлаң, зинһар».

Илгизәр ахирәтләрнең аз санлы алаен каршыларга бөтен халык эшен ташлап чыккан. Каршыга көтүче үсмер чабып килә, аның өстендә колатун, башында бүре бүрек, билендә хәнжәр иде. Егетнең авыз колакта. Аны бәхет баскан. Ул башкаларның да бәхетле булуын тели иде, үзе туктаусыз кычкыра:

— Сөенче, сөенче, Сөенеч тутай кайта-а-а! Сөенеч тутай кайта-а! — ди. Тутай янына житкәч, ул болай диде: — Сөенеч тутай, олуг бәк Йосыф агам түрә сине сараенда көтәчәк, ул жәйләүдән кайтып төште. Балакмырзалар да шунда!

Егет чабып узды. «Балакмырзалар» дигәне яучы кодалардыр, ахрысы.

— Кемнән икән ул балакмырзалар? Балакларына күрә үзләре, үзләренә күрә түрләре, түрләренә күрә түрәләредер,— диде тутай.

Нәргәтәй егет артыннан:

— Кемнән? Кайдан? — дип кычкырды.

Егет нидер әйтте. Арттагы ахирәтләр житкерде: егет: «Шәйбани хан токымыннан»,— дигән икән... Тутайның чырае коелып төште, ул үз алдына мыгырданып:

— Хан баласы! — диде.— Хан баласы түгел, чабан баласы. Себернең кайсы баласы буе житмәс агачка үреләӘ Иртеш буе Ту-

был Шәйбание токымы Аккорттанмы яучылар?

Хумай кошының канаты тигәннән бирле Сөен тутай теләк теләде. Аңа буласы ир — падишаһ-солтан булсын, хан яки шаһзадә булсын, һич югында бәкләр бәге булсын, дип Аллаһка ялварды. Менә, аның теләге кабул булды. Хумаюн солтанны бирде, менә хәзер Аккорт ханзадәне алдына куйды. Аккорт — Шәйбани хан токымы. Шәйбани үзе — Чыңгыз ханның оныгы Батый хан белән бертуган. Казанның иң мәсләксез, иң булдыксыз ханнарының берсе Мамыкның оныгы Аккорткамы ул хатын булсын? Бөек Бабур падишаһка, Хумаюн солтанга дошман йортның ханбикәсе булып рисвайда калсынмы? Нәселенең тамыры тирән, баганасы бар, әмма нихәл итсен соң бичара кыз? Тубыл, Себер ягына тартмый аның күңеле, юк. Бәс, ул кода-яучыларны рәнҗетмәенчә генә кире борырга атасын күндерер, иншаллаһ...

Шәһәргә җитәрәк, атлар үзләреннән-үзләре тибешрәк атлый башлады, атлау — юыртуга, юырту томырылып чабуга күчте.

Дошманнарны җиңеп кайтучы батырларны да болай алкышламаганнардыр. Олы бәйрәм ясады халык. Сарай капкасына җитәрәк, бәтчәләр, мирзачык оланнар, һәр атны тезгененнән алып, тутайларга иярдән төшәргә булышты. Халык аларны алкышлый, бикәләр каршыга чыккан, әмма сарай агалары, кунаклар күренми. Йосыф бәк кызы Сөен тутайны юл киемнәре, кандагай чалбар кигән кыяфәттә кодаларга күрсәтергә теләми, ахрысы. Мунча кереп, ял иткәч, өс-баш алыштыргач кына үз янына чакыртачак... Сөен тутайның чыгымчы холкын белгәнгә, бер генә бикә дә, бер генә дая да аңа якын килмәде. Ир затыннан бары берәү — Комбар ата гына йөри, анысы да үз мәшәкате белән ду килә, оланнарны ашыктыра:

— Бар, бар, мирзам, йөрең, йөрең!.. Атларның тоягына су төшмәсен!... Туктамагыз, йөреңнәр! — ди.

Сөен тутай, хатыннар халкына берьюлы гына сәлам биреп, Комбар атага:

— Бәйләүләрдә китаплар, ата, сакын! — дип, берәр мәгънәсезе туктатмаса ярар иде, дигәндәй, ашыгып мунча өенә кереп китте.

Ахирәтләре, елаша-елаша, даялар, сарай бикәчләре белән кочаклашып, күрешә калды. Аның белән Татлыбик, Сауфия, Нәргәтай беренче булып чишенде. Юл киемнәре берәм-берәм мунча алдына өелә барды. Чишенеп беткәннәр эссе якка уза торды. Мунча шаулап кызган иде. Ахирәтләр ләүкәгә тезелешеп утырды. Ләүкә такталары аларны көтеп кызган: «аһ-ух, эллә-лә-мәллә-лә, анакайларым ла, газиземне пешердем», дип шаяра-көлә торгач, бераздан тынып калдылар.

«Хәтәр якканнар һамамга. Димәк, атамның миңа үпкәсе юк,— дип уйлады тутай.— үпкәсе булса, яучылар хөрмәтенә шулай кыйланадыр».

Күкрәгеннән табанына хәтле тире алъяпкыч бәйләгән һамамчы хатыннар кереп, шаулап торган ташка бер бакрач су ташлагач, Сөен тутай пошаман уйларын онытты.

Бу нә хикмәт икән мунча дигәнең? Маңгай пешә, колак пешә, кул күтәрсәң, тырнак пешә. Әмма, әрнүләр белән берраттән, рәхәтлек кичерәсең... Бушанудан соң тир ага, тузанлы чәч астыннан агып, кайнар тир маңгайны җебетеп, керне ияртеп алып китә. Айлар буе билне буып йөргән каеш-бау эзләре кайнар һава бәрелүгә әрни дә, рәхәтлек биреп, узып китә. Күпме гомер узып, нинди маҗараларга очрап, максатка ирешеп, күп кайгы вә югалтулар аша ата йортына кайтып, кайнар ләүкәгә егылган Сөен тутайга бу мәл Ирәмбагтан да, Багый Вафадагы истирахәт кылыштан да ләззәтлерәк иде. Ахирәтләре дә бәхетле кебек. Карлыгач-

лар кебек ләүкәгә тезелгән ахирәтләре, тир бөртекләренең күкрәкләр буйлап агып, кендеккә кереп, кендек чокыры тулгач, агым булып, газизләренә юл алганын гамьсез генә карап утыра. Кайсылары күм-күк булып төзәлгән кылыч җәрәхәте җөйләрен сак кына сыпыра. Сөен тутай ахирәтләренә карап елмайды. Өлгерделәр, тулыштылар. Иң чандыр, иң сабый Сауфия дә яшь бикәч булырга әзер. Ни өчен елмайды соң тутай-бәгим? Алар өчен сөенеп елмайды ул. Тутай ахирәтлек антын инкарь итәчәк. Кызлар бу турыда белми. Ул аларның күбесенә ирек бирәчәк. Телиләр икән, каласы килгәннәр — аның ахирәте булып калсын. Һәрбер кыз өстеннән ант алыначак. Калганы — алар эше.

Тагын эссе дулкыны китереп бәрде. Кызларның тыгыз-тулы тәне изри, йомшара, кызара. Иреннәре көпшәсыман очлаеп сузылган, битләре юеш, иреннәре — җим көтеп торган кош балаларының авызы кебек. Шул эстәкле иреннәргә карап, Сөен тутай үзалдына әйтеп куйды:

— Җим көтми ул иреннәр, эссedән дә бүлтәймәгән... Ул иреннәр җегет иреннәрен көтә...

Сөен тутай, ике учы белән ләгәннән талык су алып, Татлыбикнең ачык авызына сипте. Ул айнып өлгергәнче, су чумырып, авызларын ябарга өлгермәгәннәргә дә өлеш чыгарды. Тутай һамамчы хатыннар кулындагы яңа пешкән себеркәчләрне алып, кемнең кай җиренә эләгә, кемнең кай җире кычыта — кызларны аллап-артлап чаба-кыйный башлады.

— Мәгез, алыгыз! Җегет кирәкме сезгә? Ир кирәкме сезгә? Мә, алыгыз, Мә-мә! — дип, үзен дә, кызларны да хәлдән тайганчы чапты.

Чыр-чу, көлү тавышлары мунчаны яра язды. Бу уен тутайның үз ахирәтләренә кол итеп түгел, үз итеп, тиң итеп каравы иде.

Тәннәр кып-кызыл булганчы икешәр минлек белән бик шәпләп чапканнан соң, минлекчеләр чыгып, юучылар керде. Болары, һәр кулына ат кылыннан үргән бияләй киеп, тәнне муеннан аяк очына хәтле сыдырып төшерергә тотынды, тәннең үле күзәнәкләре, кер белән бергә аралашып, токмач-токмач булып, бөтерелеп, кыл бияләйгә ияреп чыга. Арка якта эш беткәч, кыз йөзе белән әйләнә. Һамамчы янә үз эшенә тотына. Үз эшен белеп, сөеп, ләззәт белән башкара. Һамамчы хатын, ләззәт чакыргандай, ара-тирә:

— Ә-әх, менә шулай, тутай! — дип кабатлый.

Кылбияләй кызның күкрәк тирәреннән узганда һамамчы каты басмый, бияләй тияр-тимәс кенә, сак кына ышкылып китә, күкрәк тирәре кинәт бөке кебек атылып чыга. Шул чагында кызның бер тезе күтәрелә төшә; кыз, ихтыярсыздан, җиңелчә генә ыңгырашып куя. Бу ыңгырашу авыртудан түгел, чыдый алмау ләззәтеннән килә. Һамамчы хатын бу эшне гаять сак вә бер генә тапкыр эшли. Кылбияләй яңадан күкрәккә якынайганда кыз ләззәтнең кабатлануын көтеп ята. Ләкин тәҗрибәле кулдагы кылбияләй мөһим җирне сикертеп уза. Шунда кыз кеше бу ләззәт белән еш шаярырга ярамаганлыгын аңлый. Кылбияләй белән тән сыпырганда кызларның күбесе шушы хисне татый. Әмма изге вә яшерен яңалык турында беркемгә дә әйтми. Шуңа күрә һәр кыз: бу хикмәт минем белән генә булды, дип уйлый... Коенып, кибешеп, ахирәтләр чәй өенә керде. Чәй эчеп, тирләп, янә эссе мунчага кереп тир куганнан соң, алар суынып, тән корытып хәл алды. Касә-касә салкын кымыз эчтеләр. Менә шунда аларга кайнар ризык китерделәр. Өзелеп карын ачкан, эч тәмам бушаган, сәфәр тутайлары гаҗәп зур теләк белән тәгам җыйды. Ул арада төн төште... Ахирәтләр, салкынча, караңгы бүлмәләргә кереп, ап-ак чиста җәймә-

гә, түшәк-ястыкларга ятып йокыга чумды. Аларның йокысын яхшы саклар өчен тышкы якка — ир-егетләрдән, эчкәридә хатыннардан сак куелды.

Сөен тутай-бәгим уянмастан ике тәүлек йоклады. Аның уянуын зарыгып көтүчеләргә — Йосыф бәк белән яучы мирзаларга — бу ике тәүлек гасыр сыман озын тоелды. Көттеләр, түземнәре җитәрлек иде, әмма көтүләре генә заяга булды. Сөен тутай, төнлә торып, яшертен генә атасы янына керде. Җиткән кызының үз ятакханәсенә иңүен өнәп бетермәсә дә, сагынгандыр, уяну белән атасын күрергә ашыккандыр, дип, Йосыф бәк бу хакта сүз кузгатмады. Сагынылган, саргаелган: хәл-әхвәлләр сорашып, Бабур падишаһ белән Хумаюн солтаннан сәлам вә хатлар тапшыргач, тутай атасына янә бер язу бирде.

— Бусы тагын ни-намә? — дип, Йосыф бәк кәгазьне сүтте.

Бу хатта: «Сәүгеле атам вә саинле кунакларга Сөен тутайбәгимнән. Аллаһ тәгалә гыйнияте илә, кыйсмәт кодрәтенә күрә, мин ерак сәфәргә китәргә мәҗбүрмен. Йөрешем ике-өч елга сузылыр. Мең кәррә кичерү сорап ялварам. Йосыф бәк кызы Сөен тутай-бәгим»,— диелгән иде.

Йосыф бәк сикереп торды:

— Яхшыдан яман туган! — дип кычкырды ул.

— Атам, атакаем, шаулама! — диде кыз.— Мин беркая да китмим. Бары тик кодалар киткәнче чүл эченә, Аблак баба янына гына барып кайтам. Кызым качып киткән, дип, шушы хатны сонарсың. Шәйбанилар илә араң туры калыр. Син гаепле түгел. Мин тәрбиясез гаепле.

— Тәрбиясезлекнең аргы ягында!

Йосыф бәк шуннан башка сүз әйтә алмады. Мәрхүмә хатынының төсе буларак, кызының йөзенә бакты. Аның багышында: әллә соң бу кызның бер-бер ким ягы, артык җире бармы? Кияүгә чыгарга атлыгасы урында, атка атланып кияүдән кача, дигән шикчел бер уй кабынып алды. Кызы — сизгер, моны тиз күреп алды, бу шикчел сөальгә аның җавабы әзер иде:

— Хафаланмаң, атакаем,— диде ул.— Уналты яшьлек бикәчләрдән бер җирем артык та, ким дә түгел!

Бәк ялваргандай итеп әйтте:

— Күршебез Шәйбани хан нәселе бит...— диде.— Алар безгә әрбет чикләвеге, син үлеп сөя торган әрбет ташучы... агач бирүче, кеш-сусар сатучы бай ил. Тамырларында Чыңгыз каны ага... Ханзадә...

Сөен тутай атасы алдындагы келәмгә тезләнеп утырды:

— Атакаем,— диде ул.— Казаннан килгән яучы гына яучы.

— Казанда сиңа ир булырдай хан да, ханзадә дә юк! — диде бәк.

— Алайса Кырым кала! — диде кыз.— Анда бит шаһзадәләр.

— Кызыма яучы юллагыз, дип ярлык языйммы? Адәм рисвае!

Йосыф бәк чынлап ачулана иде.

— Теге чакта... Кырымның яшь солтаны Сафа Гәрәйгә сине бирергә дип, мин Бакчасарай хәтле Бакчасарайга кәрван йөрдем. Күпме мал, бүләк алып бардым. Килешеп кайттым. Ә син ахирәтләрең белән качып киттең: эзләмә, эзләтмә дә, имеш. Шуннан соң ай да узмады, Сафа Гәрәй Казанга хан насыйп кылынды. Инде хәзер бусыннан качасың. Ханнар-солтаннар бит алар санаулы гына, каян хан-кияү табып бетерим мин сиңа?!

Ата кеше сүзен әйтеп бетерде. Юк шул, дип уйлады бәк, юк... бәйләп кенә озатыр иде бераү булса... Кызы, аның саен атасына елыша барып, аның тезенә башын куеп, тыныч кына әйтте:

— Атакай гынам, мин кętәм,— диде.— Күңелем сизә. Теләгәнем миңа килер.

— Ике ел элек ни дигәнеңне оныткансың, кызым... Сәфәр йөреп кайткач, мин синең ихтыярыңда, дидеңме?

— Дидем.

— Нәтиҗә?

— Нәтиҗә булачак, атам, мин дигәнчә булачак!

«Юк, булмады, бәйләп кенә озатасы да бит. Аңа ышансаң, үз дигәнен итмәсә, бер-бер хәл кылыр. Аллаһ сакласын! Сабый чактан бөгелмәгән хәзер бөгелмәс — сынар».

— Төшең татлы булсын, атакай! — дип, Сөен тутай тавышсыз гына чыгып китте.

Икенче көнне, иртәнге намаздан соң, кунакханәдә яшь бикәч Сөенечне Аккорт шаһзадәгә ярәшү мәҗлесенә бөтен чакырулы голәмә килгән иде. Бары тик булачак килен белән аның ахирәтләре генә күренмәде. Киленчәкне көтү хәттин ашкач, диванби кереп:

— Түрәм Йосыф бәк, тутайның сиңа атап язган хаты бар! — диде.

Сөен тутайның ахирәтләре белән ерак сәфәргә качканы беленгәч, кодалар сүз астына зәһәр салып, теш арасыннан гына:

— Бөек тәшәккүр, Йосыф бәк, олыладың! — дип мәҗлестән китте.

Бичара бәк, мең тапкыр гафу сораса да, бүләк-санак биреп юмаларга тырышса да, илче-яучылар, бүләкләрне алмыйча, бүләк урынына зур үпкәләү күтәреп кайтып китте. Мәҗлеснең яме качты. Кунаклар таралды. Йосыф бәк бушап калган ханәнең баскычына утырып калды. Аның янында диванби тора икән. Ул Йосыф бәккә сак кына әйтте.

— Олуг түрәм, илгә бәла җыймыйсыңмы, бер кызыңны тыймаенча,— диде.— Исмәгыйль мирзаның бу ике елда сиңа ни күләм зәхмәт кыйлганын үзең беләсең. Барымта артыннан барымта. Карымта артыннан карымта. Нугай иле болгаерстанга әйләнеп бара түгелме? Инде хәзер арт күршебез Ак Урда да, Шәйбанилар да безгә терәк булмас... Хатын заты ул сабый чакта гына тәмиз булгай, соңынтын баштабалакка, ягъни болгаткыч таякка әверелә.

Дөрес сүзли лә ул диванби, барысы да мәгълүмдер: шулай, янган йөрәккә кызган май сибә, ахмак би. Барысын да өстенә өйгән бит. Гүзәллеге Хөсрәүләрең, Йосыфларың, Рөстәмнәрең, Мәҗнүннәреңне һуштан яздырырлык. Карашы — сихерченеке, кылышы — зиһенченеке. Нишләтәсең аны?! Исмәгыйль мирзаның азау ярган яугирләрен анадан тума чишендергән ул җен кызына кизәнсәң, ни буласын Аллаһ кына беләдер. Вахҗир, Баракил, Хәйбәр тарлавыкларын, тозлы далаларны узып, Кабулга җитеп, Бабур падишаһның үзе белән мөзәкәрә кылып, анда укып, ике дөягә төяп китап алып кайткан бу җәсүр кызга камчы орсынмы атасы!

— Аллаһ хәерле кыйлсын! — диде дә бәк, таш күтәргәндәй авыр калкынып, эчкәригә кереп китте.

*Ахыры киләсе санда.*

# Шигърият

## Мөдәррис Әгъләмов

### Кереш

Башланганда болай буласын белсәм,
Кулга каләм алмас идем,
Чын әгәр...
Ак кәгазьгә сүзләр булып кан тама,
Салкын тирләр бәреп чыккан аркама —
Утлы кыршау эчендә күк чигәләр,—
Авырлыклар шулай авыр чигәләр.

Еллар әнә көндәлек инә белән
Чигәләргә актан бизәк чигәләр...
Беркөн минем тарафыма килсәләр,
Мәртәбәле, тыныч ямьыш бирсәләр,
Барыбер алмас идем бит,
Чын әгәр
...Авырлыклар аз булса да чигәләр.

### И Ватан...

Син бит әни безгә,
Син бит изге,
Кем кулында соң син, и Ватан?!
Мин үземне, бәлки, килер буын
Ятим үсмәс, диеп, юатам.
Кем соң хөрмәт итәр — балаларын
Гел тинкәләп торган ананы,—
Кыйнап кына кеше итеп булмый
Ана назы көткән баланы.

Балаларың шуңа баш күтәрә,
Башка чыкмак булып, күрәсең,
Ә син һаман...
Һаман ләззәтләнеп
Улларыңның башын төясең.

Котылмакчы булып бәргәләнеп,
Каннар баскан инде күзләрен —
Ана сатар,
Ватан сатар көнгә
Җиткергәнсең инде үзләрен...

Азып-тузып җаның бушата да
Аттай эшләп күңел юата...
Син бит, әнкәй,
Син бит изге идең,
Кем кулында соң син, и Ватан?!

---

Мөдәррис ӘГЪЛӘМОВ (1946) — *шагыйрь, «Кыңгырау», «Учак урыннары», «Киләчәккә кайту» һ. б. шигырь китаплары авторы.* Казанда яши.

## Гареште̇ге ансы — гарештә

Яманлыкның кулы бәйләнмәгән,
Куркытырга сезне теләмим —
Хезмәттәге улларыгыз каны
Акмасын дип тибә йөрәгем.

Юк, аларга боерык бирелмәгән,
Бирелмәгән боерык гарештән.
«Син атмасаң, сине аталар», дип,
Унтугыздан алар ант эчкән.

Алар юкса сездән илчеләр бит,
Үлеме юк юкса илченең —
Ил Хуҗасы Ил булырга тиеш
Илең саклаганда ил чиген.

Тарих шулай: ант алганнар һәрчак
Хәле төшсә соңгы чигенә.
Ант эчкәннәр, калканына сыенып,
Илнең үзәгенә чигенә.

Яманлыкның кулы бәйләнмәгән:
Йодрык кысып кына түзә ул —
Халык
        кадәр
                халык
                        шартлый калса,
Күккә очачагын сизә ул.

Алла булып түрдә утырса да
Юл күрсәтмәк булып һәр эштә,—
Шартлап күккә очкач — Җир котәчәк
«Чүп чиләге» дигән гарештә.

Кычкырасы килә: — Нигә хода
Безгә генә әле каныктың?
— Сез Рәсәйнең аллалары белән
Чүп чиләге тулды тарихның! —

Хода тәгаләнең бу сүзләрен
Ишетмәсен иде колагым.
...Гыйбрәт булсын сезгә минем язмыш,
Диеп ята әнә Болагым.

Яманлыкның кулы бәйләнмәгән —
Канга баткан кулда танклар...
Кулы бәйләнгәнче, зинһар, халкым,
Үз юлыңны дөрес алып бар!

Үзең «яман» булгач, нихәл итим,
Изә безне шушы авырлык...
Дәүләт төзеп биргәч, дөнья сорый —
Сорый синнән соңгы сабырлык.

## Су буйлары

Казан алынганнан соң татар халкына
зур шәһәрләргә һәм зур су юлларына
40 чакрымнан да якынрак төпләнү,
тормыш-көнкүреш итү тыелган.

Кама ягы, Идел буе,
Зичә суы, Зәй буйлары...
Сыенганнар зур халыкның
Кеп-кечкенә авыллары.

Кырык вәхши кырык төрле
Кочкан чакта кырык яктан,
Кырык чакрым ара китеп,
Алар монда учак яккан.

Ут тергезгән, иген иккән,
Ауга йөргән, печән чапкан,
Бәхетеннән кырык чакрым
Китеп хәтта бәхет тапкан.

Иләп тире, сугып киндер,
Бизәнгән дә, атта чапкан,
Хокукыннан кырык чакрым
Китеп эшкә хокук тапкан.

Кайчак кеше вәхшилеккә
Кырык төрле сәбәп таба,
Иң соңыннан, сәбәп бетеп,
Канга сеңгән гадәт кала.

Шул гадәтең хезмәт булса,
Кирәк түгел яру тамак.
Кычкырырга өйрәнмәгән —
Хезмәт белән туйган тамак.

Ерып чыга алмас иде,
Йөрсә әгәр гел ач булып,
Түбән баскан, аралашкан
Сәүдәгәр йә тылмач булып.

Һәрбер телдә эш бертөрле,
Тылмач нигә кул эшенә?
Тылмач кирәк була башлый
Вәхшилеккә ирешүгә.

...Гәрәбәдәй сары идән
Керү белән болдырыннан.
Кырык чакрым үз өеннән
Китеп әнә өй булдырган.

Һәммәсен дә булдырганнар —
Үзләштереп төрле һөнәр...
Ә мин шагыйрь булмакчымын
Кырык чакрым китеп, юләр.—
Шул халыктан ары китеп...

## Ялангачлык

Кыяларга карау бик куркыныч,
кыяларда ялангачлык, диләр.
Ә шулай да,
миңа якын алар,
йолдыз шәлен япкач,
төн дә гүзәл.

Ә кыялар
кояш нурларын да,
кайгы сырларын да
яшермиләр.

...Ялангачлык,—
Бөек ялангачлык! —
Ә без чүпрәкләргә кереп качтык...

## Юл чатында

Сәүдәгәрләр — бу дөньяның
Төрле-төрле чатларыннан,
Сәүдә белән гөрләп торган
Данлы шәрык якларыннан,

Иделдәге дулкын белән
Тарткалаша-тарткалаша,
Агылганнар төрле якка,
Агылганнар Болгар аша...

...Кич җитүгә күбәләкләр
Җыелгандай янган утка,
Юлчылар да тукталалар
Юл чатында торган йортка:

Дуслар да төн кунып чыга,
Дошман да хәл алып чыга —
Бөек Болгарның зиннәтен
Хәтеренә салып чыга...

Кәрван килә, кәрван китә,
Берсе ала, берсе сата...
Яулар килә, яулар китә —
Берсе талый, берсе вата.

Юл чатында басып торган
Агач өчен язмыш ачы,
Узганның да, барганның да
Тиеп китә күчәр башы.

Юлчы уза, кәүсә куба,
Зәгыйфьләнеп агач ава...
Ил эчендә тарау-тарау
Җилләр сипкән орлык кала,—
Тарау-тарау.

## Якынаям

Җиргә тарта печән өсләрендә,
Покос-покос көннәр исләремдә —
Вакыт җыйды,
Вакыт күбәләде...
Күккә җитте кибән түбәләре.

Җиргә тарта урак өсләрендә,
Көлтә-көлтә өннәр төшләремдә —
Вакыт сукты,
Вакыт җилгәрде, һәй!
Алтын көшел — алтын көннәремдәй.

Җиргә бассам әгәр,
Курпы, камыл
Аяк табанымнан мине таныр,—
Якынлыгым килә әнә каян! —
Һәр көн саен җиргә якынаям...

# Эльмира Шәрифуллина

## Тәмуг кисәве

ПОЭМА-МӘРСИЯ

### Кыйсса башы

«Күрәчәккә бер сәбәпме әллә,
Картлык басты илне, дәүләтне...
Мин ни сөйлим, исәр,
Килегез сез:
Күрсәтәсем килә «җәннәт»не.

Дер селкетеп кинәт тирә-юньне,
Күк күкрәде, яшен яшьнәде...
Мин бу йортта өч ел җан асрадым,
Мин бу йортта өч төн яшәдем...»

### Беренче төн

Без бу йортны — картлар йорты түгел,
«Оҗмах сарае» дип йөртәбез.
Шулай, әби: оҗмахыңа сине
Вакытыннан алда кертәбез.

Шөкерана итеп түргә уз да
Хуҗасы бул шушы бинаның.
Сәрби куаклары урап алган
Тимер рәшәткәле койманың
Тышкы ягы тәмуг булып калды.
Калды,
        калды,
                калды ялгызы —
Мин язмышың синең, ялгышың, дип,
Баш очында янган йолдызы
Сүнде кинәт: хәтереннән качты
Шомырт тәмен бөркеп килгән яз.
Онытты үз исемен: Гайшәме соң?
Галиябану? Бәлки, Сәрбиназ?..
Ата-баба белгән, күргән эшме —
Картлар йорты һәрбер төбәктә.
Ятим бала, диваналар йорты —
Сыкрау, сызлау сала йөрәккә.

Шул йортларда җан асрый алар,
Кирәклекне тоймый һичкемгә.
Кунак көткән кебек әҗәл көтә,
Ятлар җирли сине ят җиргә.

«Гафу итәрсез бит, ярамаган
Сүзләр китсә әгәр ычкынып».
Күзләреннән укып язмышларын,
Сөйли әби,— көйли кычкырып:

«Каф тавына менәр балаларым
Мүкле сазламыкта калдымы?
Явыз шайтан әллә миңгерәтеп
Нәселемнең ушын алдымы?

Ә бит баксаң, минем балалар да
Дистә еллар белем көрмәде.
Ташка төренеп көн итәләр хәзер,
Бар дөньясы әллә төрмәме?

Үзем сөйлим бүген, сезнең авыз
Йозакланган, пешкән өчен дә.
Сөйлим, сөйлим,
Бөтенесен сөйлим
Эт елының җомга кичендә...

Ничек аңлатырга яшь-яшь хатыннарның
Күкрәгендә сөте кибүен?
Сабыйларның ана сөте түгел,
Тана сөте имеп үсүен?

Күрәчәккә бер сәбәпме әллә,
Картлык басты безнең дәүләтне.
Мин ник сөйлим әле? Килегез сез:
Күрсәтәсем килә «җәннәтне»...

---

Эльмира ШӘРИФУЛЛИНА — *шагыйрә, «Яңгыр җиле», «Гөлләр елы» исемле лирика, балалар өчен һәм проза китаплары авторы. Казанда яши.*

Журнал варианты.

Уйларында оеп утырганда
Сискәнде ул таныш тавышка.
Арттан килеп кемдер күз каплады,
Аваз салды: «Привет, бабушка!..»

— Исәнме, әбекәй! Күзләрең
Нигә соң моң баскан бу кадәр?
Җанымны ни нәрсә телгәли,
Алдыңмы куркыныч бер хәбәр?
Сизәм ич, үтәли күрәм ич,
Яшьләнгән күзләрең, яшьләнгән.
Ак яулык яшергән чәчләрең
Агарган, иртәрәк бәсләнгән.
Ни кайгың, әйтсәнә, әбекәй,
Улларың, кызларың исәнме?
Бармы соң оныклар-татлылар,
Авырмый сәламәт үсәме?
— Барын бар,
Барын бар оныклар,
Әмма дә җибәрдек зур ялгыш.
Шул ялгыш ясаган гариплек —
Гүрләргә кергәнче гел сагыш.
Ашкынып, дәртләнеп, яшәреп
Беренче оныкны көтүләр.
Кемем бар, күрегез, дигән кук,
Урамнан ирәеп үтүләр.
Булмастыр, дидем мин шул чакта
Бәхетнең моннан да олысы.
Булмастыр, башкада һич булмас
Сабыйның моннан да нурлысы.
Яраттым, уйнаттым: янәсе —
Заманнан бер адым калмасын.
Үзебез белмәдек,— ул белсен —
«Мама» дип әйттердем анасын.
Үзем дә аныңча, «пупалап»,
(Бала бит, үпкәли күрмәсен.)
Ваттым да җимердем инде мин
Урысның бичара җөмләсен.
Тел белү зыянга китермәс,
Өйрәнсен «зур агай» сабагын.
Ә алар мактәпне яптылар,
Ачтылар пивноен, кабагын.
Яптылар гел татар мәктәбен,
Туган тел укыту — вәссәлам.
Кем сорап торды соң атадан:
Кай телдә укытыйк, мәсәлән?
Балама ятлар баш булды да —
Телемнең тамырын кистеләр.
Ни татар, ни урыс булмаган
Имансыз төркемнәр үстеләр.
Бу безнең фаҗига, кадерлем.
Кайтарып ал идең — эш узган.
Өзелде буыннар,— беркем юк,
Беркем юк өч онык — өч кыздан.
Байлык соң байтак бит күңелдә:
Әкият, мөнәҗәт, такмаза.
Әткәем җырлары — әманәт.
Хуҗа юк, ни маза?
Ым белән,
Йә төртеп күрсәтеп,
Аңлатам үземә кирәкне.
Гарип бит — телсез бит оныклар,—
Шул телә,
Шул телә йөрәкне!

* * *

*Сәрби куаклары урап алган,*
*«Картлар йорты» дигән бинаның*
*Үзе иң түренә урнашса да,*
*Яшел сандыккае сыймады.*

*«Бушатырга» диләр әйберләрен —*
*Шырпы кабы кебек тартмага.*
*«Тумбочкага, әби, киреләнмә,*
*Искелеккә барма, вакланма».*

*Буйсынмыйча ни кыйрата ала,*
*Кеше кулына калгач, картаеп.*
*Сандыгына урын — утынлыкта,*
*Рәнҗеп ятар инде, муртаеп.*

*Еллар буе кул тимәгән малны*
*Кузгатты шул, дөнья кымшатты.*
*Төне буе әйбер барлады ул,*
*Төне буе сандык бушатты.*

*Ак ашъяулык чыкты сандыгыннан —*
*Киҗе-мамык белән чигелгән.*
*Исенә төште,— табын тирәсенә*
*Оныклары кайтып тезелгән:*

— Карап торам, тыңлап торам, уйлап торам,
Күңелеңнән ниләр табып булыр, олан?

Бармы анда рәхим-шәфкать, кадер-хөрмәт,
Мән-мәнфәгать — безнең өчен шулар кыйммәт.

Бармы анда санга санау бәндәләрне,
Искә алу инде гүргә кергәннәрне?

Зиратларын — каберләрен беләсеңме,
Яннарына башың иеп киләсеңме?

Милләт белән горурлану хисең бармы,
«Проклятый» дигәндә дә син татармы?

Тутыкмасын, күгәрмәсен күңел кылың,
Әкиятемне сөйлим сиңа... ә ул — озын.

Уттан кайнар булсын йөрәк ялкыннарың,
Күктән тирән, якты булсын акылларың.

Изге хисләр энҗе-таштан кыйммәт калсын —
Сатып алып, эзләп табып булмый ансын.

Карап торам, тыңлап торам, уйлап торам,
Күңелеңнән ниләр табып булыр, олан?

* * *

*Сәрби куаклары урап алган,*
*Тимер койма төргән бинаның*
*Аръягында калды узган юлы,*
*Үтте гомер,— ә ул туймады.*

*Үтте гомер! Еллар аңлаттылар —*
*Үткәненә аның сан югын.*
*Аңлаттылар... Ул бушата һаман*
*Кәләш чактан килгән сандыгын.*

*Ул бушата: күпме җан газабы,*
*Күпме яшьләр аккан нахакка?..*
*Сабые киеп үскән башлык чыкты,*
*Нур чәчрәде тиеп ахакка.*

*Күз алдыннан бала йөгереп үтте,*
*Әле көлә... әле телләшә.*
*Ә чынлыкта — яраланган күңел*
*Шушы башлык белән сөйләшә:*

— Бер бүлмәдә кырык кеше,
Картлар йортына килдем.
Шулай, олан, гомер булгач,
«Коммунизм»ны күрдем.

Хыялымда кайтам да бер,
Яшь бала нәүбәтендә,
Нәүмиз булып басып торам
Өлешсез әбәтемдә.

Туган якны гаепләмим,
Үпкәләмим халкыма:
Балаларым гөнаһ кылса,
Кичер минем хакыма.

Тәүбә итә белгәннәрдә
Миһербан булыр, дигән.
Миһербанлы йөрәкләргә
Сәгадәт тулыр, дигән.

Кырдагы чәчәкләр барсы
Киемгә күчәр, дигән.
Заман ахырында сакал
Кызларга үсәр, дигән...

Замана ахыры диеп
Сафсата сатам, имеш:
Акыл бирәм даһиларга
Картлар йортында килеш.

## Икенче төн

*Сәрби куаклары урап алган,*
*Карт-корыны җыйган бинаның*
*Яңа килгәннәргә ишек төбе,*
*Түр башында инде мин аның.*

*Киңәшем шул: «үземчә»не оныт,*
*Кирәк монда күндәм булырга.*
*«Ят» дигәндә, ятып йоклау фарыз,*
*«Бас» дигәндә, сикереп торырга.*

*Өйрәнергә кирәк тавыш-тынсыз,*
*«Теш агартмый» гына яшәргә.*
*Рөхсәт белән генә селкенергә,*
*Сәгать белән генә «кушәргә».*

*Зиһене ачык чакта җыр тыңлады,*
*Моң биләде фани дөньяны.*
*Баш бирмәгән уе ыргып үтте*
*«Җәннәт» ягын булгән койманы...*

...Бала-чага өер булып йөри,
Иманнары качкан нилектән?
Әнисенең авызына берсе
Кайнаган су койган чәйнектән.

Тфү, тфү, мин күрмәдем моны,
Шайтан күрде — китсен тәмугка.
Кәфенлеккә төренер шәһитләрем
Соңгы юлга чыкты табутта.

Әкият түгел, баш бетмәле хәлләр,
Шул газаплый, буа сулудан.
Үзең сакла, аллам, маңкортларны
Үстерүче ана булудан.

«Зиләйлүк»не җырлый, зыр-зыр килеп,
Дәверләрдән күчкән орчыгым.
Борчысам да, мин бит әниемне
Үз телемдә генә борчыдым...

Сыгылмалы чакта сыгып кал дип,
Юлларыма күпләр чыктылар.
Яшен булып кына сукмадылар,
Тамырымның сутын сыктылар.

Үз йоламда миңа ясин чыксын,
Үз телемдә дәшсен оныгым.
Ник гарип ул? Кем калдырды миңа
Суты кипкән каусә сыныгын?

* * *

*Сәрби куаклары урап алган,*
*Катлы-катлы соры бинаның,*
*Идәненә ак сөлгесен җәеп,*
*Бөтен шавын онытып дөньяның*
*Дога кылды,— теләк теләде ул,*
*Әрвахларга савап эстәде.*
*Бер намазын биш мәртәбә бүлеп,*
*Гөнаһына гөнаһ өстәде.*

*Күңел бит ул, иләсләнеп ала,*
*Суыра да сыза үй сазы.*
*Утын келәтендә ауный әнә*
*Яшел сандык — яшьлек җиһазы.*

*Әйтергә дә оят: «деревня» ул —*
*Кеше алдында дәшсә татарча.*
*«Казан ич бу, диләр, шәһәр ич бу,*
*Мөслим түгел сиңа... йә Арча».*

*Туган көннән башлап куркытуга,*
*Янауларга түзде, җәбергә...*
*Кабул кылсын гүре, бу дөньядан*
*Рәхәт күреп китми каберга.*

*Саргаюы арта барган саен,*
*Җиргә иңә барды коймагыз.*
*Җыелып килгән киңәш-зарын сөйли,*
*Соңгы сүздән аны тыймагыз!*

— Унга барыр бөтен эшең,
Уң аягың атла башлап.
Гадәтсезлек булыр киту —
Ярты юлда эшең ташлап.

Чәчәк бирсәң, бүләк алсаң —
Суз тәти кул — уң кулыңны.
Изге ният, изге сүздән
Сызып җибәр үз юлыңны.

Көрәшкәндә — якты итеп,
Ике куллап көрәш, балам.
Дөнья ярсу,— бу дөньяда
Тыныч фикер йөртү таман.

Йомыш тотма, аң бул, зинһар,
Мохтаҗлыктан килсә бераү.

Иңнәреңдә бурыч йөртмә —
Әҗерен бик авыр түләү.

Шөкер итә бер шатлыкка,
Исраф итмә дөнья малын.
Алыштырма усаллыкка
Шәфкать тулы анаң канын.

Мин сөйләгән йолаларны
Тормыш үзе ижат иткән.
Васыятемне әйттем сиңа,
Минем гомер инде үткән.

Телсезлегең җан телсә дә
Каһәрләмим,— тотмыйм уч тә.
Һич югында васыятемне,
Әкиятемне калдыр истә!

## Өченче төн

*Сәрби куаклары торгән йортка*
*Дошманың да туган, килмәсен.*
*Ташка үлчим — ярты мендәр белән*
*Кабер кебек шыксыз булмасен.*

*Килешмәде аңа «оҗмах» йорты,*
*Тәм табалмый сыек ашыннан.*
*Ятса-торса, оныклары кайтып,*
*Сөйли кебек сыйпап башыннан:*

— Син сөйләгән әкиятләрдә
Чәчәкләр җирдә иде.
Балык — сурәтләрдә түгел,
Елгада, күлдә иде.

Син сөйләгән әкиятләрдә
Диңгезләр зәңгәр иде.
Юл буйлары — бөпкә үлән,
Егетләр мәргән иде.

Син сөйләгән әкиятләрдә
Изгелек — савап иде.

Тарактан үскән урманнар —
Савапка җавап иде.

Син сөйләгән әкиятләрдә
Юк иде газ, нитрат.
Дәрәҗәсен һәм гайрәтен
Җуймаган иде ир-ат.

Әкиятеңне агуладык,
Кипте Җирнең җелеге.
Ата белән бәйләнми
Бүген нәсел кемлеге.

Кирәксенмибез шифасын,
Яңгырын, чиста карын.

Кайсы әкият сыендырыр
Без яшәгән Җир шарын?

* * *

*Сәрби куаклары урап алган,*
*Таш салкыны сеңгән бинаның*
*Кешеләрен аңлап, тоеп йөрде,*
*Кешелекне генә тоймады.*

*Кыйбла белән Мәккә йөрде уйда,*
*Кайда ялган? Кайда дөреслек? —*
*Сагынып кына сөйләр өчен калды...*
*Баштан ашкан җирдә — хәсетлек.*

...Үзем әби: әбиемне менә
Искә алып уйлап утырам.
Кемне хәтерләсәң — шул кеше юк,
Бар бушлыкны бер мин тутырам.

«Биш ир бала таптым бабагыздан,—
Дия иде әби-мәрхүмә.
— Астыртын эш йөртте кайберәүләр,
Исләремә төшсә, ми түнә.»

Без дигәнчә генә барды мени
Кемдер каһәрләгән тормышы.
Ир кадерен күпме татыдым соң,
Дистә ел юк — бөтен булмышы.

Күпме ләззәт күрде — һәр тамчысын
Сеңдерергә торган тәнебез?
Каян килсен тыныч хөкем йөртү,
Каян булсын әдәп, мәнебез?

Биш баламны итәгемә төяп,
Буш өемдә калдым утырып.
Сыңар канат кизәнде дә кайчак,
Сыңар канат куйды сыпырып.

Эзгә салып кара табигатьне,
Югалгачтын күпме акыллар...
Ата тәрбиясе бирә алмый
Ничә буын бакты хатыннар.

* * *

*Сәрби куаклары урап алган,*
*Сез «оҗмах» дип йөрткән бинаның*
*Салкын чәе... күбегезне көтә,—*
*Артын күрмәм димә, дөньяның.*

*Хәзер болай кадерсезгә калып,*
*Картлар йортларында йөргәч тә,*
*Уйлый-уйлый акылым алмашынып,*
*Зар елагач, йәки көлгәч тә —*

*Заманында яп-яшь ана иде,*
*Тудырды һәм бакты игезне.*
*...Качып кайтты бүген: мәче булып,*
*Елый-елый тырный нигезне.*

*Каргый-каргый бәрелеп-сугыла ул,*
*Кизәнә,— соң кемне тукмасын?*
*«Рәнҗешләрем, аллам, кире алам,*
*Үз баламны каһәр сукмасын.*

*Кем болгатты газиз бу Җиремне,*
*Телемне һәм денне корытты?»*
*Акылы белән өмет өзде аннан,*
*Тәмуг уртасына ыргытты.*

*һәм дә әйтте: «Син янарга тиеш,*
*Зәхмәтле син — тәмуг кисәве!*
*Нәселеңнән җәяү качкан нәрсә,*
*Нәләт сиңа ләгънәт исәван![1]»*

Баш тартабызмы әллә хакыйкатьтән,
Күңелләрен киттек, рәнҗеттек.
Кулларыннан ямьне тартып алдык,
Ни сөйләшсәк — шунда чит иттек.

Нәрсә бирә, кая алып бара,
Имеш, надан әби мәктәбе.
Ялгышканбыз: фәкать шунда булган
Оят,
намус,
әдәп,
әхлагы.

Кире кагып шәфкать-кануннарны,
Ямьнән мәхрүм иттек баланы...
Оныклары йөгергәнне көтеп,
Кара көйде күңел аланы.

Сөйләмәче, зинһар, эч пошырып,
Әбиеңнең серен, дидек без.
«Әбиеңә барып сөйлә анә»,—
Мыскыл итеп шулай көлдек без.

Бик тә сөйләр идек әби сүзен,
Аңламыйлар бүген оныклар:
Егерменче гасыр торбасыннан
Күңелләргә кунган тутыклар.

Йөрәкләрне юшкын басып киткән
Баш мицгерәп йөргән арада:
Өмет кипкән — бары тәне туып,
Аңы тумый калган балада.

---

[1] Тиз онытучан кеше (диал.)

Телсез бала... сандык... картлар йорты...
Кәләш чагы... кайтты уена.
Хәтерендә: елның шушы көне
Туры килде кызыл туена.

Сандыгыннан алып селкеде дә,
Туй күлмәген салды иңенә.
Картлар йорты кереп бара иде
Гадәти бер кара төненә.

Күк күкрәде кинәт, бик якында
Сызылып-сызылып яшен яшьнәде.
Үкенечле шунсы: дәүләтләрнең
Сырхау вакытында яшәде.

Сандыгына барып капланды да,
Ялварды ул күккә — ходайга:

«Каһәрләмә, раббем, бу бәндәңне.
Каһәрләнгән бит мин болай да.

Ал җанымны: китим бу дөньядан,
Кешеләргә кыен салмыйча.
Каргыш калдырудан куркам, аллам,
Интектермә җаным алмыйча».

Ялварды ул башын бәрә-бәрә,
Сандыгына акты яшьләре.
...Ул бу йортта өч ел җан асрады,
Ул бу йортта өч төн яшәде.

Һәм шул төндә,
Шул караңгы төндә,
Торган чакта яшен бер тынып,
Әүлиядай, бер җан Күккә ашты
Тәрәзеннән картлар йортының...

*1988—1990.*

# Камил Мостафин

Кем җаннары яши икән
бу шәрә далаларда,
туңып каткан урманнарда
һәм салкын һаваларда?

Киләчәге нинди икән
бәсләнгән тирәкләрнең,
кырау алган миләшләрнең,
өшегән йөрәкләрнең?

Нинди көчләр агыла соң
бу биек, соры күктән?

Ник көтеп алган көннәрнең
матурлыклары беткән?

Нәрсәләр чик куяр икән
заман ялгышларына?
Шыксыз карлар кардәш мәллә
кеше язмышларына?

Буш далада, зур дөньяда
офык эзли кешеләр,
югалып калган юлларны
яңа карлар түшиләр...

Чаң сугалар иске манарада,
тогәл башкаралар бу эшне,—
вакыт җиткәч, кемдер сорый кебек,—
сәгатегез, ягъни, дөресме?

Чаңнар сугып, җирне сискәндереп,
яңгыратып заман һавасын,—
дөресләргә иде намусларны!
...Андый чаңны каян табасың?!

---

Камил МОСТАФИН (1932) — *шагыйрь, татар һәм рус телләрендә дөнья күргән дистәгә якын китап авторы. Чиләбедә яши.*

Кооператор,— кыю кеше,—
вокзалларны алган биләп:
ул халыкка товар сата,
аңа бик күп акча кирәк.

Ул, елмаеп, күзен кыса
һәм сикертеп ала кашын:
— Яшәрбез, тик язмыш безне
акчабыздан аермасын!

Ә карт бабай урамнарга,
мәйданнарга чыгып китә,—
безнең усал заманадан
һаман изге эшләр көтә.

Ул бик тыйнак: ил алдында
иеп тора бүген башын:
— Түзәрбез, тик язмыш безне
ипи-тоздан аермасын...

Ә йокысын җуйган шагыйрь
шигырь яза янып-көеп,
кемнәрнедер каргап, сүгеп,
кемнәрнедер мактап-сөеп.

Сөйли кулын селти-селти
(ә йөрәге тибә ярсып):
— Яшьнәрбез, тик язмыш безне
иркебездән аермасын!

Очты башлар. Йөрде җирдә җәллад,
йөрәкләрне күмеп.
Тик кан аша, зар һәм ялган аша
гел калыкты өмет.

Менә дигән ирләр... Төсләре дә
инде чыккан истән.
Үзләре юк, юлда эзләре юк,—
өметләре исән.

Шәүләләре тузан булып оча,
күзге җилләр бәрсә...
Тузан түгел, томан түгел икән
өмет дигән нәрсә.

Тынган дөнья буйлап сагыш йөри,
йөрәкләрне өтеп.
Исәннәрнең күз яшьләре аша
карап тора өмет...

## Бер ышаныйк әле әйдә күз яшенә

Чүп-чар оча юллар буйлап, кырлар буйлап,
нишлисең бит, түзик әле,— җил чыккан шул,
киртәләрне генә түгел — иске-москы
капкаларны, терәкләрне ыргыткан шул.

Ә йөрәктә бүген сагыш белән бергә,
тагын нидер — офтану да, үкенү дә.
Тырыштык та, тырмаштык та, сугыштык та,—
бу хурлыклар, бу гарьлекләр безгә нигә?!

Офтаныйк та, үкеник тә, хурланыйк та,—
әнә шулай яңарсыннар безнең хисләр,
яңарсыннар туган якта, туган илдә —
кара төсләр, кызыл төсләр, яшел төсләр!

Уйланыйк та, талпыныйк та, кузгалыйк та,
алга сөрик гади һәм саф теләкләрне,
бер ышаныйк әле әйдә күз яшенә,
җәллик әле, санлыйк әле йөрәкләрне!

# Коллар

Дәһшәтле ташкынга әйләнде кол халык, тын халык.

Вольтер

Байракларны коллар күтәрәләр,
чыгып — ташкан, төнге урамнарга,
күтәрәләр — җилфердәтеп җилдә,
маңып — аккан канга.

Байракларда — иң кирәкле сүзләр,
байракларда — изге, якты сүзләр,
ә кол җаннар — корыч ихтыярлы,
салкын канлы ирләр.

Үз сүзләләр! Алар ябырылып
тыкрыкларга, мәйданнарга тула.
Үткен хәнҗәр — колга! Аңа каршы
сүз әйтмәсен Сулла!

Пистолетлар, автоматлар — колга!
Колның күзләрендә — ләгънәт, нәфрәт,
уйларында — мәхшәр, ахыр заман,
йөрәгендә — ләззәт.

Ишелгәндә өйләр, илләр, күкләр,
юнәлешне күрсәт кенә колга,
ул ташланыр, кирәк булса — уңга,
кирәк булса — сулга.

Кол ташланыр, киеп ак мундирын
яки — кара, нәхтә кожанкасын,
эшен эшләп йөрер:
кирәк булса — атып,
кирәк булса — асып.

Эше беткәч һәм вакыты җиткәч,
ул кулларын юар...
...Байракларны коллар — күтәрәләр
һәм таптыйлар — коллар.

# Күңелләр

Үзгәрәбез. Үзгәрешләр —
котылу түгел әле...
Иманыбыз да яңара,
нишләтик күңелләрне?

Антырап, сизеп торабыз:
иң кабахәт ялганнар
күңелләрнең бизәкләрен,
үзәкләрен алганнар.

Бу күңелләр яңа чорда
шатлыкларын табармы?

Без алла иткән кешеләр
таптап үткән аларны...

Сафлыкларын кем кайтарыр?
Яңгырлары зәһәр бит,
сагышлары — бигрәк тирән,
язмышлары — каһәр бит...

Күңелләрнең күге биек,
көннәр генә санаулы,
и замана, күтәр әле,
күтәр әле аларны!

## Нурихан Фәттах

# КИЧҮ

РОМАН

### IV



Картәтәй усал, ачы телле иде. Кайбер яңа, ят сүзләрне ул үзенчә бозып әйтергә ярата иде. Аннан соң, Шәмсебанат кызының «каңсамул» улы килгән саен, аны бераз чеметкәләп алудан да тартынып тормый иде. Шунлыктан Габделхәй аның белән сөйләшкәндә уйлабрак сөйләшергә һәм, гомумән, телгә-тешкә килмәскә тырыша иде.

Картәтәй исә йончылган, хәлсез кыяфәтенә бер дә туры килми торган бер җитезлек белән чабата ясавында булды — бармакларын тиз-тиз алыштырып, як-якка таралып торган шелеләрне тартып-тартып куйды, учы белән, бармак битләре белән сылап-сылап куйды һәм чандыр тез башында шакмакланып ак чабата күз алдында үсә барды. Шул ук вакытта картәтәй Габделхәйгә дә күз төшереп алды, бер-ике сүз белән Яңавыл турында, базар хәлләре, тегесе-монысы турында сораштырды. Габделхәйнең Яңавыл хәлләре турында да, базар хәлләре турында да сөйләшәсе килмәде. Аның барыннан да бигрәк үзе турында — үзенең унны бетерүе, аттестатында барлык билгеләрнең «отлично» булуы, Казанга укырга китәргә ниятләве турында сөйлисе килде. Картәтәсе аның быел унны бетергәнен әллә белми иде, әллә чабатасы белән артык мавыккан иде — Габделхәй сөйләргә теләгән нәрсәләр турында ул берни сорашмады.

Утыра торгач, Габделхәй шулай да түзмәде, беренче булып үзе башларга булды һәм күңелендәгесен барысын да берьюлы сөйләде дә бирде.

— Һы, алай икән,— диде карт исе китмичә.

Шуннан соң икесе дә тынып калдылар.

— Нәрсә алып килдең? — диде картәтәй кинәт кенә.

Ул моны шаяртып әйтмәкче булды сыман, ләкин бу бик туры әйтелде, тупас итеп әйтелде. Картәтәсе холкын белгәнгә, Габделхәйнең моңа да әллә ни исе китмәде. Ул аның шулай дип сораячагын алдан ук сизенгән һәм җавабын да алдан ук әзерләп куйган иде.

— Картый кайтсын инде,— диде ул һәм шундук сүзне икенчегә

---

Ахыры. Башы 7 нче санда.

борырга ашыкты.— Катнарга чабатаң бармы, бир әле үзем катныйм,— диде.

Мондый тәкъдимгә куанган сыман, картәтәй як-ягына карап алды. Никадәр карт һәм хәлсез булмасын, үз эшен ул үзе генә эшли, чит кеше кысылса кул бозыла, эш киреләнә, дип исәпли иде. Ләкин Габделхәйне ул чит кеше дип белми иде, ахрысы. Сике астыннан иелеп, ул калыплап куелган чабата алып бирде.

— Тезеңә әнә теге чүпрәкне сал, чалбарсыз калырсың ату,— диде картәтәй, киңәш итеп.

Габделхәй күрсәтелгән чүпрәкне тезе өстенә җәеп салды да эшкә тотынды.

— Шелеңне яхшы тарт, шөшле сабы белән сугып-сугып куй. Нык булсын,— диде Картәтәй, өйрәтеп, киңәш итеп.

— Ярар, шулай итәрмен,— диде Габделхәй.

Бераз вакыт сүзсез генә эшләгәч, картәтәй үз алдына зарланып куйды.

— Юкагач ташуы авырайды,— диде.— Бер барганда бишалтыдан ары күтәреп булмый. Бик бирештем быел, улым. Күз дә начар күрә. Урманнан кайткач, ике-өч көн бил авыртып җәдәтә. Анысына да түзәриең, каравылчы тота. Яз көне балтамны алып калды. Һы! Утырып кына җыламадым. Кыяктай үткер балтам эт кулында калды.

— Кайсы каравылчы? — диде Габделхәй болай гына, сүз урынына сүз булсын өчен генә.

— Һы! Җалабикыф Сабачианны белмәскә! — диде картәтәй.— Маңкасын җыялмаган бер нәрсә. Шул этләр көненә калдык. Бүә буе урманында икенче эзең булмасын — башыңны чабып өзәрмен, карт тәре, ди.

— Син үзең тәре димәдеңмени? — диде Габделхәй.

— Һы, әйтмәгән кая ул! — диде картәтәй.— Син ул тәре, мин — хак мосылман дидем. Аңлаймыни ул аны? Бик бирештем быел, улым. Үз урманың үзеңә, үз басуың үзеңә ирек түгел. Безнең ул Бүә буйларын, урманын-болынын патша да тартып алалмаган — болар алды. Денсезләр. Берсен калдырмый тартып алды. Эт көненә калдык, улым. Безнекеләр күреп кайткан — башы-аягы астына килгере Сабачианның чоланында ята ди минем балта. Әллә каян танырга була: сабына тимер каккан.

— Чоланында яткач, су эчәргә кергән буласың да, аласың да чыгып китәсең,— диде Габделхәй җиңел генә.

— Һы, алырсың эт авызындагы сөякне! — диде картәтәй.— Бер көнне тагын финагин килеп кергән өйгә... Пачай Матҗан. Анда карай, монда карай синең кебек. «Көненә ничә кием чабата ясайсың, карт? — ди. Ник кирәк ул сиңа, мин әйтәм, аягыңда күнитек, өстең бөтен, тамагың тук — үгез кебексең... чабата киеп йөрергә чамаламыйсыңдыр ич, мин әйтәм. Синең чабатаң кирәкмәй миңә, ди. Налук түләтәм мин синнән, ди. Калхув эшенә чыкмыйча баеп ятасың, ди. Эт көненә калдык, улым.

Урман каравылчысы Сабачианның картәтәсенең балтасын алып калуы турында Габделхәй белә иде инде. Бу хәл монан ике-өч ел элек булган. Шулай да менә картәтәсе һич шуны оныта алмый — килгән саен сөйли, сөйләгәндә дә гел әлерәк кенә, быел гына булган хәл итеп сөйли. Ләкин чабатага налог түләтмәкче булулары турында Габделхәйнең әле ишеткәне юк иде.

— Чабатага налук!.. Пачай Матҗан үзе генә уйлап чыгаргандыр аны, картәтәй,— диде ул, ышанасы килмичә.

— Һы, кем белә аларныкын,— диде картәтәй.— Алар бездән сорап эшләмәй — кирәк икән, тарта да ала. Тәкыйулланың алма бакчасын элегрәк мактап гәзитләргә язалары. Исәр әйткәндәй, әл-

лә утыз, әллә җегерме җыл карады, бала урынына тәрбияләп үстерде. Чичкә атканда ап-ак булып утырырые... бөтен авыл күрке булып. Кисте. Үч итеп кисте. Ачудан. Бар карап торганым шушы бакчае — анысы да харамга чыкты, диде. Әлеге дә баягы, Миннегали таягы... алма сатып баеп ятасың, дип налук китереп төшергәннәр. Шуннан каста булды. Һы, булмай булырсың каста. Тагын үзе килеп бәйләнә ди әле, ник кистең, сәвиткә каршы кул күтәрәсеңмени? дип әйтә ди. Эт көненә калдык, улым. Бәрәкәт качты дөньядан. Кот калмады. Үзебез гаепле... алланы оныттык, фасикъ булып беттек.— диде карт, фәлсәфи төстә сүзен тәмамлап.

— Чабата өчен налук түләдеңме соң шулай да? — диде Габделхәй мәсьәләне ачыклыйсы килеп.

— Һы! — диде карт үртәлеп.— Әнә иске туным, әнә иске киезем, менә ямаулы күлмәгем — ничә бет табасың, барысы да синеке! — дидем. Тиргәп чыгардым.— Кеше каны имеп симергәнсең,— дидем. Икенче килмәде.

Картәтәсенең мондый сүзләрен, мондый моң-зарын Габделхәйгә элегрәк тә тыңларга туры килә торган иде. Кайчан гына тыңламасын, нәрсә турында гына тыңламасын, ул аны бик үк аңлый да алмый иде. Картәтәсе аңа бүгенге көн кешеләре, бүгенге көн гадәтләре турында түгел, бәлки нindидер үткән заман турында, үткән заман кешеләре һәм гадәтләре турында сөйли кебек иде. Аның моң-зары гына түгел, башка кешеләрнең моң-зары да Габделхәйгә нишләптер ялган һәм ясалма булып, элекке заманнардан калган бер аңсызлык булып тоела торган иде. Зарланырга яратучылар, аныңча, бүгенге көндәге политик хәлне, илдәге төп законнарны, тәртипләрне аңламыйлар яисә аңларга теләмиләр сыман иде. Чабатага налук салу, әлбәттә, көлке, ләкин яшь юкә агачларын кисеп, урманны корыту да дөрес түгел! Җалабиков Сабачиан — урман каравылчысы. Урман — «хөкүмәтнеке». Дәүләт милкенә кул сузу — җинаять. Моның өчен төрмәгә утырталар, сөргенгә сөрәләр. Ярый әле картәтәй балтасын биреп кенә котылган. Әгәр сугыш елы законнары нигезендә алып киткән булсалар? Менә бит ул эшләр кая таба бара!

V

Утыра торгач, картәтәй үрелә торган чабатасы белән бергә тезендәге чүпрәген сыпырып төшерде дә аягына басты.

— Җитәр. Хәл юк.— диде һәм кунычы киселгән киезтекләрен өстерәп ишек төбендәге агач караватына барып ятты.

Кулларын баш астына куйды, аякларын сузып җибәрде. Үпкәләгән сыман озак кына тынып ятты да, коры гына:

— Инәң акча җибәрдеме? — диде.

— Юк.— диде Габделхәй.

Карт эндәшмәде. Аның чыннан да үпкәләгән, хәтере калган икәнлеге хәзер үзеннән-үзе сизелеп тора иде.

— Һы, көтәрсең аннан! — диде ул бераздан һәм тагын тынып калды.

Габделхәйнең инәсе белән картәтәсе арасында күптән инде читләшү, салкынлык сыман бер нәрсә яшәп килә иде. Картәтәйнең дүрт кызы, бер улы бар. Кызларының барысы да читтә, башка авылларда. Төп йортта — Вәлиәхмәт улы. Башка авылларда булсалар да, ата кеше үзенең кызларын да онытмый. Шулай да ул аларны мохтаҗлыкка төшкәч кенә исенә төшерә, ахрысы. Мохтаҗлыкның исә бер генә көнгә дә бетеп торганы юк. Кызларының, кияү-

ләренең тормышлары бик үк шәптән түгеллеген ул белми түгел, белә. Кайберсенең тормышы аның үзенекеннән дә начаррак. Бары тик Шәмсебанат кына, картәтәй исәбенчә, башкаларга караганда мулрак, иркенрәк тормышта яши. Алай гына да түгел, Шәмсебанат хәтта бик шәп яши. Шәмсебанат акча суга. Шәмсебанат кызының бай яшәвенә картның, билгеле, әз генә дә каршылыгы юк. Булдыра ала икән, кулыннан килә икән, яшәсен әйдә, рәхәтләнеп яшәсен. Тик шулай да ата кеше кайчагында үзенең кызыннан көнләшеп тә куя. Көнләшү генәме, шартлар дәрәҗәгә җитә!

Шәмсебанат аена йөз сиксән биш сум акча ала, җитмәсә ире өчен дә бушка акча килеп тора. Дөрес, аның бакчасы да бакча түгел — бер-ике түтәл кишер, суган утыртырлык уч төбедәй җире бар. Сыеры да, кәҗәсе дә юк. Аның урынына — дүрт тамак. Ләкин андый нәрсәләрне карт күрмәмешкә, белмәмешкә салына. Тамак өчен дә, өсбаш өчен дә, аныңча, Шәмсебанатка акча тотып торасы юк — балалары да, үзе дә, аныңча, балалар бакчасында туеналар, киемен дә «хөкүмәт»тән алалар. Шулай булгач, игелексез, миһырбансыз Шәмсебанат кызы аңа — карт атасына кимендә ун-унбиш тәңкә биреп барса да, бер җире дә кителеп төшмәс иде. Һы, биреп барырга тиеш тә бит, бирмәй, бармак гел үзенә таба кәкере.

Картәтәйнең күңелендә шундыйрак бер үпкә бар иде. Аена бер-ике мәртәбә базарга чабата сатарга баргач, ул, бик кирәсе килсә дә, кирелеген җиңә алмыйча, кызы Шәмсебанатка керми китә. Өйләре базардан әллә ни ерак та түгел, югыйсә. Шулай ук кызы Шәмсебанат та, атасының холкын белгәнгә, туган авылына сирәк кайта, кайтса да, әтәсе белән бозылышып-ачуланышып китә.

Бу турыда Габделхәй яхшы белә. Олылар арасына аның керәсе дә килми, кемнең дөрес, кемнең дөрес түгеллеген ачыклыйсы да килми. Менә хәзер яңадан шул күңелсез бәхәс шаукымы калкып чыккач, аның эче пошып куйды.

— Мин укырга китәм бит әле, картәтәй,— диде ул, сүзне икенчегә бормакчы булып.

Картәтәсе озак кына эндәшми ятты һәм үзенең берни аңлатмаган «һы» дигән ымлыгын әйтеп куйды. Габделхәй аны аз булса да кызыксыныр, ничек укыдың, кая барасың, кем буласың? дип әйтер, дип көткән иде. Ләкин картәтәсенең шул хәтер калдыргыч «һы»сы аны тынып, бөрешеп калырга мәҗбүр итте. Шундый атлыгып, шундый сагынып килгән өй, авыл кинәт чит-ят булып тоелды. Тәбәнәк өй эчендә аермачык булып ач чебеннәр безелдәве генә ишетелде. «Инәкәй бөтенләй монда... авылга кайтмакчы була тагын»,— дип уйлады Габделхәй, күңеленнән чиксез бер төшенкелеккә бирелеп. Кая кайтасың, ник кайтасың монда?!

## VI

Алар шулай тынып калган арада теге якта кемнәрнеңдер кайтып кергәне ишетелде. Габделхәй аларның кемнәр икәнлеген аяк тавышларыннан ук танып алды. Эшен ташлады да чолан аша теге якка чыкты.

— Китагай! Гаптелхәй улым түгелме соң?! — диде картый Габделхәйне күргәч.

Карты кебек үк озынча, чандыр гәүдәле картый, мич алдына якын килеп, алъяпкычындагы чыршы күркәләрен бушатып ята иде. Мич алды сикесендә, кояшлы болын исләре таратып, җиләк тулы агач савыт тора иде. Яланбашлы бер малай, чыршы күркәсе белән булашкан картыйсы ягына ялт-йолт каранып, савыттан учлапучлап җиләк ашый иде. Шунда ук малайдан зуррак бер кызый

да бар иде. Габделхәй абыйсын күргәч, җиләк буры тиз генә гөлбач артына шылды, кызый исә гаҗәпләнеп кунак абыйсына текәлде. Болар яшь бабайның балалары — Габделхәйнең туганнан туган энесе белән сеңлесе иде. Аларның берсе Зифун, икенчесе Сиринә дип атала иде. Эне белән сеңелнең өс-башлары ярлы, йөзләре чырайсыз, тәннәре чыра кебек иде.

Картый, чыршы күркәләрен бушатып, алъяпкыч итәген сыпырып куйды, кулларын итәгенә сөрткәләде дә, елмаеп, дәртсез генә гөрелдәп Шәмсебанат кызының зур улын яратып алды — аркасыннан каккандай, кочаклагандай итте.

— Китагай! Үскән, акыллыланган. Кайчан килдең? Инәң нишләп ята — тазамы, чирләмәйсезме? Бер дә килмәйсез, ташладыгыз,— диде ул, бер-бер артлы тезеп.

Шуннан соң, болай гына килешеп бетмәс дигән кебек, күз төпләрен чылатып алды, баш артына шуышып төшкән яулыгын тартыбрак куйды, һәм өстенә чигүле тастымал ябып куйган самавырга барып тотынды.

— Гаптелхәй улым килгәч, самавыр куймый ярамас,— диде.

— Инәкәй сезгә күчтәнәч җибәргәние,— диде Габделхәй, шүрлектәге төенчеген алып.

Аның кулындагы зур гына төенчекне күреп, картыйның куанычы арта төште. Кузгатылган самавырын урынында калдырып, ул өстәл янына килде һәм калтыранган куллары белән төенчекне чишә башлады. Шәкерт абыйлары алып килгән күчтәнәчне күреп, балалар телсез калдылар һәм комсызланып, түземсезләнеп төенчекнең чишелүен көттеләр.

Өй эчендәге ыгы-зыгыны ишетеп, күрәсең, сикедәге кызый да йокыдан уянып китте һәм уяну белән ни өчендер шыңшып җыларга тотынды. Аңа игътибар итүче булмады. Мендәр мамыгына баткан, тузгыган чәчләрен тырпайтып, чытык йөзле кызый олылар янына килеп җитте. Ул арада комсыз Зифун, төенчекнең чишелеп беткәнен дә көтмәстән, кулын сузып нидер умырып алды һәм, башкалар исләренә килеп өлгергәнче, кулына эләккән нәрсәне авызына кабып та җибәрде. Сиринә, энесе өчен уңайсызланып, кызарынып, шәкерт абыйсы ягына карап алды, аннары пышылдап, зәһәрле итеп: «Убыр!» — диде, ләкин «убыр»ның гына берниндн тәэсире юклыгын күреп, тәртипсез энесенең бәләгеннән чеметеп алды.

Габделхәй, аларның бу кыланышларын күрмәс өчен, читкәрәк китеп барды. Соңга калдым, ахрысы, дигән сыман ашыгып, картәтәй килеп керде. Кунычы киселгән киез итекләрен өстерәп, буш капчык шикелле асылынып торган киндер ыштан төпләрен җилфердәтеп, түргә, өстәл янына узды. Картәтәләрен күреп балалар тынып калдылар, читкәрәк тайпылдылар. Картәтәй, өстәл янындагы урындыкка килеп утырды да, балалар кебек үк түземсезләнеп, серле төенчеккә текәлде.

— Һы, самавыр куярга кирәк. Тамагы кипкәндер Гаптелхәйнең,— диде киңәш итеп.

Нык тартылган төенне картый, ниһаять, чишеп җибәрде. Төенчектән иң элек шундый кадерле һәм тансык ис бөркеп торган бер бөтен ипи — Яңавылда, тимер юлчыларның ипи заводында пешкән, чиле-пешле булып, ләчтә булып пешкән бер кирпеч ипи килеп чыкты.

— Их! — диде Зифун һәм онытылып тагын кулын сузды.

Чәче-башы тузгыган бәләкәй кызый шыңшудан чын-чынлап җылаучы күчте. Сиринә исә шулкадәр зур байлыкка ышанырга да, ышанмаска да белмичә, сихерләнгән кебек карап тик торды.

Казан яныннан, картый зур гына пычак алып килде, пычакның чыра телеп агарып, шомарып беткән йөзен алъяпкыч итәгенә сөртте

дә, ипинең әлерәк кенә Зифун сындырып алган почмагыннан бер юка телем кисеп алды. Телемне өстәлгә куеп аны өчкә бүлде, аннан соң һәр кисәкне икегә бүлеп чыкты. Олырак кисәкне ин элек картына бирде, икенче кисәкне кечкенә кызый Риммага тоттырды. Кырые китек кисәк Зифунга, аның ише Сиринәгә булды.

— Ии! — диде Зифун шыңшып.

— Шыт! Шул кирәк сиңа — комсызланмассың моннан соң! — диде Сиринә тантана итеп.

— Биргәнгә рәхмәт әйтергә кирәк,— диде картәтәй коры гына. Калган ике кисәкне картый шүрлеккә куйды.

— Монысы Гаптелхәй улым белән безгә,— диган булды.

Комсыз Зифун үзенә тигән кисәкне чәйнәп-нитеп тормады — шул көе йотып кына җибәрде. Бәләкәй кыз Римма белән Сиринә исә, Зифунны кызыктырып, яңакларын күпертеп, үз өлешләрен авыз эчендә генә сакларга булдылар.

— Китегез, кит! — диде картәтәй, балаларны өстәл янынннан куалап.— Җитеп торыр хәзергә.

Төенчек эченнән тагын ике кисәк иллешәр граммлы бөртек чәй, ярты кило чамасы эре шакмаклы шикәр, укмашып беткән карамель һәм шулай ук ярты кило чамасы печенье чыкты. Боларның барысы да Шәмсебанат апаның авылга җибәрергә дип күптән инде әзерләп куйган байлыгы иде.

— Һы! Шундый тәм-төмнәр генә ашап ятасызмы? — диде карт әтәй Габделхәйгә.

Ул моны комсыз бер гаҗәпләнү белән, атасын оныткан игелексез кызына карата ачу һәм көнләшү белән әйтте. Аңа каршы Габделхәй берни эндәшмәде. Балаларның, олыларның үз гомерләрендә беркайчан ипи, чәй-шикәр күрмәгән кебек кыланулары аңа бик авыр тәэсир итте.

Ул, аларның ыгы-зыгысына катнашырга теләмәгәнлеген сиздереп, стенага ябештерелгән иске гәзит кисәген укырга тотынды.

— Лыгырдама инде! Китагай! — диде картый ачуланып.— Тутырып куйганнар ди анда. Үзеннән, балаларыннан өзеп җибәргәндер әле. Синең аркада көллесе өйдән бизеп бетте.

— Һы! Бизәр шул, ник бизмәсен. Малайлар үсте, эшкә ярады. Ай саен акча килеп тора. Бизәр шул,— диде карт тешсез уртлары белән әкрен генә ипи йомшагын әвәләп.

— Тутырып куйган ди акчаны! Утырасың шунда, карт самый! — диде картый кычкырып.

Картый үзе шикәр-кәнфиткә дә, печеньега да кагылмады, бары чәйне генә борынына бик якын китереп иснәп карады да төенчекне бәйләп, кире шүрлеккә куйды. Шуннан соң ул шалтыр-шолтыр килеп яңадан самавырына тотынды.

Картәтәй, хәлсез терсәкләре белән өстәл тактасына таянып, авыз эчендәге ипиен әвәли-әвәли, урынында торып калды. Ашап бетергәч, өстәлнең бер башыннан икенче башына кулын сузып, әле генә корткасы ипи кискән төшне капшап карады. Ләкин аңа кадәр балалар өлгергән иде бугай инде — ашъяулыксыз такта өсте ялап алгандай чип-чиста иде. Картның кәефе кырылды. Хәзер ул үз ягына чыгып тормады — бу якның ишек төбендәге тар сикесенә барып ятты.

## VII

«Һы, тәм-төм генә ашап яталар!» — дип уйлады ул тынычлана алмыйча. Ул анда шикәр белән чәй эчсен, син монда карт

башың белән көн-төн бил бөгеп утыр, көн-төн балтырган шулпасы чөмер. Изгелек юк хәзерге кешеләрдә, миһырбан юк. Һы, укыган кешедә нинди миһырбан булмак кирәк? Үзләренә генә булсын аларның, карт атайга булмаса да ярай. Катмас әле! Катса тагын... Ипине менә мин ашарга тиешием дә, юк, тәтемәй. Укыган кешеләр ашай. Укыган икән, гәҗитен кимерсен. Ипине кем карап үстерә, шул ашарга тиеш. Юк шул, алай түгел — басуга аяк та басмаган, тырманы сабаннан аера белмәгән әрәм тамаклар ашай. Фасикъ дөнья. Бәрәкәт качты.

Фикерен ул шуннан ары үстерә алмады. Аның уйлары бер үк нәрсә тирәсендә буталды һәм уйлаган саен кәефе генә кырыла барды. Кәефе кырылгач исә тупасланасы, кырасы-җимерәсе килде. Бер кереп, бер чыгып, туктаусыз нидер эшләгән сыман йөреп торган корткасына кинәт ачуы килеп:

— Буламы инде анда, юкмы? — дип кычкырды.

— Була! Талагың ташыгандыр.— диде кортка, картның үзе кебек үк тупас итеп.

— Һы, син тотынсаң була инде ул... иртәгә,— диде карт зәһәрләнеп.

Картый җавап кайтарып тормады. Картәтәй озак кына үз алдына сукранып, мыгырданып ятты. Корткасы белән алар, гомумән, тату, тыныч яшәмиләр иде. Бернинди сәбәп юк чагында да корткасына кычкыру, җикерүне ул гадәти нәрсәгә саный, корткасы шулай ук җавапсыз калмый иде. Читтән тыңлап торганда аларның үзара сөйләшүе дә тиргәшү, кычкырышу булып тоела иде.

Аларның бу сәер гадәте дә, мондагы мохтаҗлык, ярлылык та Габделхәйгә ят нәрсә түгел иде. Шулай да, никадәр ярлы һәм мохтаҗ булмасыннар, килеп керү белән картыйсы карбаздан иң элек салкын катык алып кереп бирә торган иде. Бу юлы нишләптер күрмәделәр дә шикелле.

— Арыгансыңдыр, улым, ятып тор,— диде картый, Шәмсебанат улының күңелсезләнеп утыруын күреп.— Чәй кайнап чыккач уятырмын.

— Ятып торасы килми,— диде Габделхәй теләр-теләмәс кенә.

Картый кыстап тормады — балалар чыгып китүдән файдаланып, күчтәнәчле төенчекне яңадан үрелеп алды да, яңадан чишеп өстәлгә җәеп салды да, чәй-шикәр ише нәрсәләрнең барысын да яңадан әвеш-түеш китерергә тотынды. Тиздән самавыр да кайнап чыкты, ташып, җиз капкачын дыңгырдатып, түгелә дә башлады.

— Әнә, кара! — диде картәтәй, яткан җиреннән башын калкытып.

Картый, авыр самавырны шактый җиңел күтәреп, өстәлгә утыртты. Борыны китек чәйнүккә хуш исле бөртек чәй чеметкәләп салды да, чәй өстенә чыжлап торган кайнар су агызды, шуннан соң чәйнүкне шаулап торган самавыр өстенә утыртып куйды. Әчкелтем-төчкелтем аш-умач исләрен куалап, чебен безелдәвен томалап, өй эченә җылы, тәмле исләр таралды.

— Җәгез, килегез,— диде картый, карты белән Габделхәйгә эндәшеп.

Картәтәй урыныннан торды, аякларын идәнгә төшерде һәм барыргамы, бармаскамы дигәндәй, тынып утырды да, урыныннан кузгалды. Кыстатып тормыйча Габделхәй дә өстәл янына килде. Алар килеп урнашу белән, картый йомырыларга чәй агыза башлады. •

Шул чакны чыр-чу килеп тыштан бала-чага йөгереп керде.

— Актимер бабай килә! — дип кычкырды беренче булып Сиринә.

— Актимер-Күктимер! — диде Зифун, апасыннан калышмаска тырышып.

— Актимел-Куктимел! — диде бәләкәй Римма, көлә-көлә.
— Ут чыкканмы әллә — ник чабышасыз? — диде картәтәй.
— Актимер килә ич! — диде Зифун.
— Актимер? — диде картәтәй, сагаеп.
— Килсәни, кеше килгәнгә тилерәләрмени? — диде картый.

Картәтәй урыныннан торды, тәрәзәгә якын килеп, урам якка карады, аннары берни әйтмичә кире урынына килеп утырды.

— Һы, көтеп кенә торадырыем менә монда.— диде мыгырданып.

Шул ук вакытта диярлек шыгырдап капка ачылганы ишетелде. Барысы да, тын калып, керүчене көттеләр. Бер-ике минут чамасы вакыт үтмәде, тышта ишек төбендә кемнеңдер кычкырып сәлам биргәне, «Хуҗалар өйдәме? — дигәне һәм таягын тукылдатып, чолан баскычыннан менеп килгәне ишетелде. Кунакны каршыларга дип картәтәй урыныннан торды.

— Һы, Шуктимер мактап кына йөри әле,— диде сукранып.

Ачып куелган ишектән шомарып беткән таяк белән иске киндер капчык тоткан бәләкәй генә, чандыр гына бер карт килеп керде. Башына ул кулдан суккан киез эшләпә, аягына ак ыштыр урап, яңа чабата кигән иде. Чабата бавы балтырына аркылы-торкылы уратып, тезенә кадәр күтәртеп бәйләнгән иде. Янтыктан төньяктагы Ар-Уразының Актимер карт картәтәйнең күптәнге белеше иде. Янтыкка килеп чыккан саен диярлек ул кордашы Кәрим агайларга сугылмый узмый иде.

Актимер карт, таягын, капчыгын ишек төбенә куйды да, берике адым түргәрәк узды, җирән сакалын сыпырып алды һәм кычкырып:

— Ассаламагалайкум! — диде.
— Әйдә, түрдән уз, Актимер,— диде картәтәй.
— Саумы-исанме, Карим агай? — диде Актимер карт.— Исанлеклар ничыграк, жингай? Исанлек-саулыкме?.. А-ай, сездә кунак та бар икән. Гаптылхай иным түгелме соң? Исанме, иным.

Ул шулай һәркем белән исәнләшеп чыкты. Исәнлек-саулык алгач, картый юлаучыны чәй эчәргә чакырды, удмуртча белгән бердәнбер «пукче» (утыр) дигән сүзен әйтте. Картәтәй үзе янынннан урын җайлады. Актимер, башындагы эшләпәсен салып сикегә куйды да, күрсәтелгән урынга килеп утырды. Шуннан соң, хуҗаларга, табынга хөрмәт йөзеннән, кычкырып «бисмиллаирахман ирахим», диде.

— Мактап кына йөрисең икән, Актимер,— диде картый чәй ясап.
— Аллам сакласын сызны хурларга,— диде Актимер.
— Базарысьа бертиськот? Суресет луиза?* — диде картәтәй, удмуртчага күчеп.

Яшьрәк чагында ул бер ай Ар-Уразыда эшләгән, шунда беркадәр удмуртчага өйрәнгән. Үзенең дә төшеп калганнардан түгеллеген күрсәтмәкче булып, чит кеше алдында да, удмуртлар алдында да ул шулай бер-ике сүзне удмуртча әйтеп куйгалый иде.

— Базардан, Карим агай,— диде Актимер карт.— Ундым, дисан да ярай, унмадым, дисан да ярай. Сарык алып барганыем, Карим агай. Җыл да икы барән бирадырые. Саттым. Налукка кирәк, жингай. Бугаздан алалар. Җа налукны тулайсын, җа йортыңны язып чыгабыз, дилар. Җорттан колак кагасы килмай бит, Карим агай, жингай...

— Шулай инде, шулай,— диде картый, Актимерның сүзен җупләп.— Җәле, Актимер, житешеп кенә утыр әле.

— Җорттан колак каксам нишлармын, дидым, Карим агай,— диде удмурт карты, үз алдына куелган ипи кисәгенә кагылырга да, кагылмаска да белмичә.

---

* —Базардан кайтышмы? Юлың уңдымы?

— Аша, аша, тартынма, Актимер — анысы синең өлеш,— диде картый.— Бәхетле тамак икәнсең. Кызым җибәргән... Шәмсебанат.

— Сарык кадерлемы, җортмы, иным? — диде Актимер карт, Габделхәйгә карап.— Базардан кайтышлый ук кыреп түләдым налукны. Калганына шырпы-сабын алдым тыгеларьга, Карим агай.

— Аларга ышаныч юк, Актимер кордаш,— диде картәтәй.— Язып та алырлар, куалап та чыгарырлар.

— Нишләп кешене үз йортыннан куалап чыгарсыннар инде! — диде Габделхәй, сүзгә катышып.— Элек кенә... патша заманында гына ул куалап чыгарганнар. Хәзер — юк, алай түгел ул.

— Дурысь, иным, шулайдыр,— диде Актимер карт, бик тиз килешеп.

— Китереп терәделәр, кордаш,—диде картәтәй, Габделхәйнең сүзенә колак та салмыйча.— Каманизмга китереп терәделәр. Бай да юк, ярлы да юк — барыбыз да бертигез... барыбыз да хәерче!

— Хәерче! — диде картый кычкырып.— Булганына шөкер ит — алла сугар. Алдың тулы ризык, шуңа канәгать итмәгәч!

— Дурысь, җиңгай,— диде Актимер, ярарга тырышып.

— Үзебезнең комсызлык аркасында шушы көнгә калдык,— диде картый.— Биргәненә шөкер итәргә кирәк. Элекке пигамбәрләр әнә күпме михнәтләр күргәннәр!

Картый үзенчә укымышлы иде. Үз фикерен дәлилләү өчен ул еш кына китап сүзләре кулланырга, изгеләр тормышыннан мисаллар китерергә ярата һәм күңеле аеруча күтәренке чакларда элекке мөнәҗәтләрдән, хикәяләрдән кыска-кыска өзекләр сөйләп ала, тыңлаучы булса, бар белгәнен берьюлы чыгарып салырга да күп сорамый иде.

— Безнең күргән берни түгел, ни күрмәгән Йосыф пигамбәр! — диде ул көйләп һәм, чәй эчүчеләрнең каршы сүз әйтә алмавыннан файдаланып, Йосыф пигамбәрнең михнәтләреннән бер-ике кыйсса сөйләп алды.

— Дурысь, җиңгай,— диде Актимер.— Игыньнарь ничек сун сызьдә, Карим агай? Сабан ашлык бызда айбат булай, арыш кына сирак.

— Ничек булса да, безгә буласы түгел, Актимер,— диде картәтәй төшенке генә.— Урак вакыты гына җитсен, килерләр дә ялмап та алырлар, бөртеген калдырмый алып китерләр. Белмәйсеңме әллә?

— Дурысь, Карим агай,— диде Актимер карт уфтанып.

— Нишләп бөртеген дә калдырмасыннар инде, картәтәй?! — диде Габделхәй, картәтәсен оялтмакчы булып.— Йөз кило хөкүмәткә тапшырсаң, унбиш кило колхозчыга кала. Тырышып эшләгәндә...

— Бик бирештем быел, Актимер,— диде Кәрим карт, Габделхәйнең сүзләрен ишетмәмешкә салышып.— Күзем да начар күрә, кул да калтырай. Җегәр юк, Актимер, җегәр.

— Бызьга шул каберга барасы гына калды инды, Карим агай,— диде Актимер пошынып.— Исымнан чыккан, бызның бит тыге Юлдаш карт та улде. Але шушы атнада гына. Урыны уҗмакта булсын.

— Һы! — дип куйды Кәрим карт, белеше Юлдаш картны кызганып.

— Мәрхүм,— диде картый да.— Корткасы исәнме соң әле? Улы белән килене дә барые бугай.

— Барые, җингай,— диде Актимер.

— Һы! — диде картәтәй.— Сиксәнгә җиттеме Юлдаш карт.

— Җитмыш тугызда, дидылар,— диде удмурт карты.

Алар шулай дөнья хәлләре турында сөйләнгәләп, әз-мәз ипи каптылар, җебетеп кенә шикәр суырдылар һәм туктаусыз чәй эчтеләр. Чәйне картый ясап кына торды. Башта пешерелгән чәй җитмәде. Борыны китек чәйнүккә яңадан бер-ике чеметем чәй салырга, сүрелә башлаган самавырга күмер өстәргә туры килде. Ярый әле борынгы

«микулай» самавыры зур иде, хәзерге самавырлар булса, ихтимал, суы да җитми калган булыр иде.

Биш-алты йомырыны бушаткач һәм тәненә, маңгаена рәхәт тир бәреп чыккач, Актимер карт, хуҗаларга рәхмәт әйтә-әйтә, урыныннан кузгалды. Гәпләшеп чәй эчкәннең соңында картәтәйнең дә күңеле күтәрелеп китте. Бушап калган өстәл тирәсен шундук балалар яулап алды.

Актимер карт бусагага утырды да, куеныннан чигүле янчык чыгарып, караеп беткән төрепкәсенә тәмәке тутыра башлады.

— Уйдә тартмаймын — курыкма, җиңгай,— диде үз алдына сөйләнеп.

— Тупсага утырырга ярамый бит, Актимер, бәхетең булмас,— диде картый.

— Син ачуланма инды, җиңгай,— диде удмурт карты канәгать төс белән кеткелдәп.— Гумырга тупсага утырдым — бахытем шуннан булмагандыр. Кайнар чай ычкачь, торыпкамьне быр тартып җибарсам, миа хазырь шуннан артык бахыть киракмай.

— Һы, кемгә — бәхет, кемгә — ләхет,— диде картәтәй, Актимер картны яклаган сыман итеп.

Актимер карт, картый сүзен тыңлап, шулай да бусагадан торды, чакмасын чагып тәмәкесенә ут кабызды, таягы белән капчыгын кулына алды да, ике сүзнең берендә рәхмәт әйтә-әйтә, саубуллашып, әчкелтем тәмәке исе калдырып чыгып китте. Киселгән киез итеген өстерәп, Кәрим карт белешен капкага кадәр озатып куйды.

## VIII

— Карале, сиңайтәм, Ибрайлар зыянлап сыерларын суйганнар икән,— диде картәтәй өйгә кергәч.— Әллә бер-ике кила ит алып кайтасыңмы? Көтеп торырга бирерләр әле. Кирәксә, чабата белән түләрмен. Болай да алардан ике кием өчен аласы бар.

— Китагай! — диде картый шаккатып.— Сыйлы көнең — сыер. Җәй уртасында... мескенкәйләрем! Акчасын чыгарсалар, ярый да бит.

— Чыгармас Ибрай! Ике хакын чыгарыр әле ул. Базарга алып барсалар, кулына да тидермәсләр,— диде картәтәй.

— Көтәргә бирер микән соң? — диде картый.

— Бирер, бирер,— диде картәтәй.— Үз кешеңә дә бирмәгәч... Качарга җыенмыйбыз, үләргә дә...

— Гаптелхәй улым килгәч, бик әйбәт булыр. Киленнәр дә эттәй арып кайталар,— диде картый, ризалыгын белдереп.— Каяле, Сиринәне генә җибәрәем.

— Ниндәй Сиринә ул! — диде картәтәй.— Сиринәгә кем ит тоттырып җибәрсен — бар үзең.

Картый самавырын түгеп, өстәлен җыештырды да, башындагы яулыгын рәтләштереп, чыгып та китте. Картәтәй аның Ибрайлар ягында күздән югалуын гына көтеп торды да, урам як тәрәзәне иңеләй ачып, бар көченә:

— Сиринә! Сиринә! — дип кычкыра башлады.

Тамаклары туйгач каядыр уенга чыгып киткән балалар, картәтәләре тавышын ишетеп, озакламый көтүләре белән кайтып керделәр.

— Син чакырдыңмы, картәтәй? — диде Сиринә, картәтәсенең колагына якынрак килеп.

— Кайда йөрисең кычкырганда? — диде Кәрим карт кырыс кына.— Китмә. Көтеп тор.

Шуннан башка ул берни әйтмәде. Бик ашыгыч эше бар сыман, авырткан аякларын җитез генә өстерәп, чоланга чыгып китте һәм

тузанлы әрҗәләр, капчык, чапчак ише нәрсәләр арасыннан нидер эзләргә тотынды. Эзләгән нәрсәсен тапмагач, ашыгып кире өйгә керде, шүрлекне, сике астын, сандык артларын капшап карады. Шуннан соң нидер исенә төште дә янә лас-лос атлап, үз алдына сукранып, кире чоланга чыкты. Бераздан ул тузанга буялып беткән ярты литрлы кара шешә алып керде, шешәне чүпрәк белән сөрткәләп Сиринәгә бирде. Бөтен өйдә бердәнбер дип әйтерлек буш шешә иде бу. Картәтәй аны корткасыннан да, бала-чагадан да яшереп саклый иде. Булган барлык шешәне сугыш елларында, иң кадерле байлык сыман, «хөкүмәт»кә биреп бетергәннәр иде. Нимес танкларын шартлату өчен ул шешәләрдән бензинлы граната ясыйлар икән, дип сөйлиләр иде.

— Мә, тиз йөре! Нык тот,— диде картәтәй.

— Акча? — диде Сиринә, шешәне кулына алып.

Картәтәй күлмәк изүенә кулын тыгып, яшерен кесәсеннән йомарланып беткән берничә берлек алды, санап кызга бирде.

— Тиз йөре! — диде ул тагын кисәтеп.

Ибрайларга караганда магазин якынрак иде. Аннан соң көндез анда әллә ни кеше дә булмый иде. Сиринә тиз арада кайтып та житте һәм ике куллап тотып кайткан авыр гына шешәне исән-имин картәтәсенә тапшырды. Җәйге-көзге эш вакытында сатуда аракы өзелеп тормый иде. Аракыны Яңавылдан мичкәсе белән генә ташыйлар һәм кәрәчин саткан кебек, литрлап, чүмечләп саталар иде. Тулы шешәне Кәрим карт калтыранган кулына алды, алдап җибәрмәгәннәрме дигән сыман, кәгазь бөкене ачып, иснәп карады, борынын җыерды, бөкене кире шешә авызына тыгып куйды да чоланга чыгып китте.

Күп тә үтмәде, куанычыннан җиңел-җиңел атлап картый да кайтып керде. Шакмаклы ашаулык кисәгенә төреп, ул зур гына ит тоткан иде.

— Бирде, берсүзсез бирде, рәхмәт яугыры,— диде картый ишектән килеп керү белән.— Китагай! Бигрәк симез булган — кисәргә карасы юк. Бичаракайларым... безгә сөенеч тә сөенечен, үзләре зар җылыйлар шул. Яшь балалары бар, сөтсез кыен булыр инде.

Картәтәй итне кулына алды, башта авырлыгын чамалап карады, аннан соң яктырак килеп кыяфәтен карады. Корткасына кире бирде дә канәгать бер төс белән:

— Бөтенләй сал,— диде.

— Шуны да бүлгәләп торсаң! — диде картый эре генә.— Мондай эсседә ит саклап буламыни?! Исәпләшербез әле, белмәгән кеше түгел.— диде.

— Һы,— диде карт күңеле булып.

— Онытып торам икән,— диде картый нидер исенә төшереп.— Бүә буенда бер марҗаны үтереп ташлаганнар, ди. Яшь кенә, ди. Акчасы да күп булмаган. Турыдан киткән булган икән, теге Тирән чокыр янында үтергәннәр, ди.

Ишектән чыгып барган картәтәй туктап калды, аптырап, теле тотлыгып:

— Һы! — дип куйды.— Күрүчеләр булганмыни? Кайчан?

— Гыйльмулла малае күргән,— диде картый.— Берничә кеше җыелып кайтып киләләр икән, өстенә килеп чыкканнар. Килеп житкәндә теле булган, бичаракаемның. Җөрәк турысына гына кадаганнар, ди, пычак эзе шул көе ярылып ята, ди.

— Һы! — диде карт исенә-акылына килә алмыйча.— Кем икән, тотмаганнармы?

— Кем булсын — чуен юлдагы ышпана инде. Ничек Габделхәй улыма чыкмаганнар! Алла сакласын инде. Гел турыдан йөри. Ишетсен колагың, икенче турыдан йөрмә, улым,— диде картый бер читтәрәк эндәшмичә утырган Габделхәйгә.

— Ярар.— диде Габделхәй гамьсез генә.

— Һы! — диде тагын да картәтәй.— Алар шул хатын-кызга чыгалар да...

— Милитсиәсе дә юк бит аның кирәк чагында, — диде картый.

— Бүә буена да милитсиә куеп булмый бит инде! — диде Габделхәй картыйның аңсызлыгына исе китеп.

— Милитсиәсе ышпана белән бер сүздә булгач, куйсаңни, куймасаңни,— диде картәтәй.— Илдә бәрәкәт калмады, улым. Үз җиреңдә үзең иркенләп йөри алмайсың. Озакламый болар бер-берсен ашай башларлар әле.

— Тәүбә-әстәгафирулла! — диде картый коты алынып.— Авызыңнан җил алсын — фирештәнең амин дигәненә туры килер!

— Килсә килер инде,— диде карт.— Фасикъ дөнья. Илдән бәрәкәт качты. Олыны олы дип белмәйләр, кечене кече дип белмәйләр.

## IX

Кичкә таба, кояш баер алдыннан, печәнчеләр кайтты.

Әтәсе кебек бераз гына бөкрәеп йөри торган Вәлиәхмәт абзый ишектән беренче булып керде. Аның артыннан кулына ак төенчек тоткан, бик нык арыган кыяфәттә хатыны керде. Иң артта Иленура күренде. Иленура әтәсенә дә, инәсенә дә охшамаган — картыйсына тартым иде. Бернинди ачлыкка-мохтаҗлыкка карамастан, аның барлык саны төгәл, күркәм иде. Сылу ак йөзле, куе коңгырт чәчле һәм тере матур күз карашлы иде Иленура. Кояшта матур булып янган нәфис, түгәрәк муенына ул эре кызыл гәрәбә, ике як колак очларына көмеш сыман алкалар тагып куйган иде. Иленура Габделхәй белән бер яшьтәрәк иде. Төссез, хәлсез ата-аналары, картыйсы, картәтәсе һәм энеләре-сеңелләре янында Иленура ниндидер могҗиза белән генә кырау сукмый калган алсу чичкәне хәтерләтә иде.

Вәлиәхмәт абзый Габделхәйне күреп алды һәм теш казналарын тартып торган коры иреннәрен авырлык белән генә кыймылдатып, елмайгандай итте.

— Габделхәй килгән ич.— диде.— Исәнме, Габделхәй.

Шундый зур гәүдәле кешенең тавышы чыпчыкныкы сыман бик зәгыйфь булып чыкты. Габделхәйнең күңелендә яшьбабасына карата кызгану һәм әрнү хисе калкып куйды.

— Габделхәй дисеңме? — диде яшәби, шундый ук хәлсез бер тавыш белән.

— Габделхәй?! — дип кычкырды Иленура, бөтен өй эчен яшь, көр тавыш белән күмеп.— Гомерле булырсың әле, бүген генә сине сүләдек лапса. Әүлияме әллә син, Габделхәй?!

— Кызык, минем турында нәрсәләр сөйләдегез икән? — диде Габделхәй, печәнчеләр белән исәнләшкәч, Иленура янында озаграк тоткарланып.

— Сүләдек инде,— диде яшәби, кызы өчен җавап биреп.— Бигрәк сагындым шул Гаптелхәйне, ичмасам бер килеп тә чыкмай, диде Иленура. Кызлар күңелендә нәрсә булсын — сагыну да юксыну инде.

— Кит! — диде Иленура, инәсенә кычкырып, муенындагы гәрәбә шикелле кызарынып.— Бер дә алай димәдем. Укуын да бетергәндер, ичмасам бер килеп тә чыкмай, дидем лапса!

— Шулай диденмени соң әле? Истән чыккан,— дигән булды яшәби. Шуннан соң кулындагы төенчеген кайнанасына бирде һәм аңлатып, Габделхәйгә карап: — Көнлек ризык,— диде.— Ярты кила он. Печәнгә йөрүчеләргә җан башыннан өч йөз гырам он бирелә. Безгә өч кешегә күп тия. Яртысын болында пешереп ашайбыз, ярты-

сы өйгә кайта. Хәзер инде тамак тук. Печәннең файдасы бар аның, Гаптелхәй.

Бу сүзләрне ул Габделхәй алдында үзләренең һич тә ач түгеллекләрен күрсәтергә тырышкан сыман итеп әйтте, ләкин чынлыкта бу Габделхәйнең түгел, үзләренең күңелләрен юату өчен әйтелде бугай. Габделхәйгә уңайсыз булып китте. Төенчеккә төйнәп алып кайтылган куш йодрыктай он өчен, Иленура өчен, яшәбисе өчен уңайсыз булып китте. Күрәсең, яшь бабай да шундый ук уңайсызлык кичерде — бернигә катышмыйча, хәлсез бер елмаю белән елмаештырып, баскан урынында катып тик торды. Шуннан соң ул, кулындагы бишмәтен чөйгә элеп, аягындагы солдат итеген салып куйды, аяк астында диярлек аунап яткан бер мендәрне баш астына кыстырды да туп-туры как идәнгә сузылып ятты.

Эшчеләр кайткач, картәтәй дә үз ягына чыгып, ишек төбендәге сикесенә ятты. Габделхәй, эш югында эш булсын, дип, картәтәсенең калыплап куелган чабатасын катнарга тотынды.

— Печән ничек соң быел, яшьбабай? — диде ул бераздан.

— Печәне ярыйсы, эше авыр,— диде яшьбабай теләр-теләмәс кенә.

— Бодай уңган быел! — диде Габделхәй дәртләнеп.

— Шулай шул,— диде яшьбабай.

— Басу капкасына терәлеп утыра. Шундый биек! — диде Габделхәй, кирәгеннән артык мактауга бирелеп.

— Аны әле җыеп аласы да бар, энекәем,— диде яшьбабай сүлпән генә.

— Комбайннар җитәрлекме соң быел, яшьбабай? — диде Габделхәй аның саен белдеклеләнеп.— Комбайны булса, аны инде урып алуы берни түгел, иеме, яшьбабай?

— Анда гына эш тормай,— диде яшьбабай.

Шул чакны, сике такталарын шыгырдатып, картәтәй урынында кыймылдап куйды.

— Машина эшләй, машина ашай хәзер, улым,— диде Габделхәйгә эндәшеп.— Җире — безнеке, ашлыгы — хөкүмәтнеке. Сызыра да ала. Синең үзеңә ашарга каламы, юкмы — сорап та тормай.

Картәтәсенең кирле-мырлы сүзләрен ишетү белән, Габделхәйнең барлык изге теләкләре, күтәренке уй-хисләре юкка чыкты. Картәтәсенең дөрес сөйләмәгәнлеген дә яхшы белде, тик шулай да аның эше искелек калдыгы белән бәхәсләшергә үзендә көч тапмады. Бәхәсләшү түгел, аның белән хәтта җайлы гына, иплэп кенә сөйләшеп тә булмый сыман иде. Ул үзе турында гына, үзенең бүгенгесе, хәзергесе турында уйлый ала, үзенең чабатасыннан башка бернәрнәрсәне дә күрергә дә, белергә дә теләми. Бит мохтаҗлык Янлыкта гына, Яңавылда гына түгел. Бөтен илдә шулай! Сугышта җимерелгән-кырылган авылларны, шәһәрләрне торгызасы бар, завод-фабрикаларны эшкә җибәрәсе бар. Украина, Белоруссия әле һаман җимерек хәлдә. Андагыларның хәле безнекеннән дә яманрак. Ярый әле сугыш монда кадәр килеп җитмәгән — шуңа сөенергә кирәк. Ул әнә сөенә белми. Ул, гомумән, бер нәрсәгә дә сөенә белми бугай. Политик аңсызлыгы турында инде әйтеп тә торган юк.

— Синең шул бер үк балык башы булыр инде, картәтәй,— диде Габделхәй картәтәсен җиңелчә шелтәләп.

Күңеленнән ул яшьбабасының үзен яклавын өмет итте. Моңарчы еш кына аларның сүзләре килешә торган иде. Элегрәк шулай өчәүләшеп чәкәләшеп киткәндә яшьбабай гел Габделхәйне яклый торган иде. Ни әйтсәң дә, яшьбабай аңлырак, белемлерәк. Бөтен яшьлеге аның шау-шулы елларда — колхозлашу, культуралашу елларында үткән. Белеме дүрт сыйныфтан ары узмаган, ләкин шаулы елларда ул үз авылының, үз чорының иң алдынгы, иң актив яшьләреннән исәпләнелгән. Башта «каңсамул»га, ан-

нан «фартия» гә кергән, шуннан «ата каманис» булып киткән. Картәтәй бик үк риза булмаган, ләкин ул каршы килгән саен яшьбабай киреләнеп алдынгылар рәтендә йөри биргән. Сугыш башлану белән ул беренче елны ук сугышка алына. Сталинград янында каты яраланып авылга кайта. Ярты ел чамасы урында ятканның соңында яңадан аягына баса, ләкин ул вакытта инде хәрби хезмәткә яраклы булмый — сул як кулы гарипләнеп кала. Сугышта булып кайтуын исәпләмәгәндә, ул беркайчан читтә йөрмәгән. Бөтен гомере авылда үткән. Актив комсомол, актив коммунист авылда нинди эшләр башкара алса, ул шуларның барысын да башкарган. Колхоз оешкан елларда фермада ат караган, колхозда яшелчә бакчасы оештырылгач, шунда бригадир булган. Яшелчә бакчасыннан соң «Алга» колхозында җиләк-җимеш бакчасы утыртканнар. Баш кеше итеп, бригадир итеп тагын «каманис» Вәлиәхмәт иптәшне куйганнар. Сугышка ул шул чагында алынган. Сугыштан яраланып кайткач, хәле шәптән булмаса да, иң җаваплы эшкә — амбарга төнге каравылга билгеләгәннәр. Ныклап торып аягына баскач исә шул ук амбарда ашлык кабул итүче һәм «заф» булган. Быел менә бригадир итеп сайлаганнар.



## X

— Безнең әтәй әйтсә, әйтә инде ул,— диде яшьбабай, гамьсез генә, бер якны да яклыйсы килмичә.

— Мин әйткәнне тыңласагыз, эттәй уңган кеше буладырыегыз да, тыңламадыгыз,— диде картәтәй сикесеннән торып утырып.— Әнә, бәләкәй авыллар сугышка чаклы да, сугыштан соң да машина кертмәделәр — үзләре эшләй, үзләре ашай. Ул чакта да әйттем мин сезгә.

— Син әйтү белән генә бармый шул дөнья,— диде яшьбабай.— Югарыда синнән дә акыллырак кешеләр утыра, әтәй. План килеп төштеме, үтәмәй хәлең юк.

— Эшләү пылан белән, ашау гырам белән,— диде картәтәй.

— Пыланын да үтәйсең. Анысы гына үтермәй. Пылан өстенә пылан килеп төшә — шунысы үтерә, энекәем,— диде яшьбабай.— Былтыр көз орлыкка дип калдырган ашлыкны да илебатырга илтеп тапшырдык. Быел язга чыккач, үзебезнең шул ук орлыкны хөкүмәттән үтичкә сорап алдык. Анысы да ялынып-ялварып кына әле. Көз көне икеләтә түләү шарты белән, дүрәкәй!

— Элек байга сорап бардык, хәзер — хөкүмәткә! — диде картәтәй.— Бай бирсә үзенекен бирде, хөкүмәт — безнекен.

— Байның да үзенеке булмаган ла, ул да ярлыдан алган,— диде Габделхәй.

— Байның эшләгәне булды, эшләмәгәне булды,— диде картәтәй.— Үз ашлыгын теләсә сатты, теләмәсә ярлыга таратты.

— Тараткандыр! Табарсың байдан! — диде яшь җегет чамадан тыш остарып.

Картәтәй эндәшмәде — бала белән сатулашып торуны, күрәсең, киракссез санады.

— Элек аның ялкавы гына, эш сөймәгәне генә ярлы булган, энекәем,— диде яшьбабай.

— Машина бозды дөньяны, машина! — диде картәтәй ачу белән.

— Алайса, яңадан сукага, агач тырмага тотыныргамени? — диде Габделхәй.

— Һы! — диде картәтәй.— Элек, улым, сука да агачые, ашаган калачые. Хәзер әнә сука да тимер, тырма да тимер — б...ны кимер! Ишеткәнең юкмыни?

— Әтәйнең шул инде: атны сагына, суканы сагына,— дип куйды яшьбабай ялкау гына.

— Сагынырсың! — диде карт уфтанып.

— Сугышка чаклы аның җитәрлек аты да барые,— диде яшьбабай аңлатып.— Бөтен эшне ат белән башкардык. Трактор шул кызык өчен генә... Күпме атны сугышка алып кырдырдылар, дүрәкәй! «Башкырт дивизиясе» дигән булып, атка атландырып танкка каршы сугышка җибәрделәр. Әдәм әйтеп әдәм ышанмас: кулда кылыч, агач мылтык.

— Агач мылтык?! — диде Габделхәй ышанмыйча.

— Чып-чын агач мылтык! — диде яшьбабай.— Ничек исән калганбыздыр — әле дә исем-акылым китә. Күпме ат, күпме кеше кырылды! Таудай өелеп калдылар, дүрәкәй! Хәзер менә ат та юк. Аттан бигрәк, эшләр кеше калмады.

— Барысы да укымышлыга әйләнде,— диде картәтәй.

— Укымышлы! Тапкан бер сүз! — диде яшьбабай, әтәсенә кычкырып.— Эшләрдәй кеше ничек тә читкә китәргә тырыша — укыганы да, укымаганы да. Тамак куалый, энем, тамак.

— Ат та юк, кеше дә юк, шулай булгач, трактор-комбайн кирәкмимени? — диде Габделхәй, яшьбабасының йомшак җирен капшап.— Авылда никадәр машина күп булса, шулкадәр яхшырак түгелмени? Әнә, алдынгы колхозларда шулай бит... гәзитләрдә гел язалар.

— Болай караганда әйбәт ул,— диде яшьбабай беравык эндәшми ятканнан соң.— Машина тиз эшләй, күп эшләй. Ләкин ул бушка эшләмәй. Эшләгән өчен барысын да җыя да ала. Натурплата. Ат белән эшләгәндә натурплата юк. Хөкүмәткә тиешлесен илтеп саласың да, әзме-күпме үзеңә дә кала. Машина эшләгәч, алай түгел. Иң әүвәл хөкүмәткә план тутыра алмый җаның чыга. Аннысын тутырасың — натурплата дигәнен сала башлыйсың. Ягъни трактор, комбай эшләгән өчен мытыеска түләйсең. Мытыес кемнеке? Хөкүмәтнеке!

— Һы, аның чокырының тулганы юк,— диде картәтәй.— Күпме бирсәң дә ала — бир генә!

— Менә син шунысын да уйлап кара, энекәем,— диде яшьбабай Габделхәйгә.— Аның тагын шул ягы да бар: ат белән эшләгәндә элек кеше, әйтик, гектарыннан йөз илле пот алган, трактор белән эшләгәндә кайчагында иллегә дә тулмай!

— Булмас ла, яшьбабай! — диде Габделхәй шаккатып.

— Ник булмасын, була! — диде яшьбабай.— Шулай. Җылдан җыл кими бара. Җыл да каерылып уңмай ул ашлык!

— Ничектер ышанасы килми,— диде Габделхәй икеләнеп.— Әнә гәзитләрдә язалар: әллә нинди бай колхозлар, миллионер колхозлар бар, диләр. Сездә персидәтел булдыксыз — шуңа ул, яшьбабай.

— Их, энекәем! — диде яшьбабай, ачынып.— Яшь шул әле син. Китапчарак уйлайсың. Персидәтел бер үзе берни эшләй алмай. Теләсә кемне утыртып куй — барыбер шул булачак.

— Ник?!

— Ник дисәң, шул — персидәтелнең кулы-аягы бәйле. Гектарына мең пот алса да, халыкка, эшләгән кешегә тамагы туярлык бүлеп бирә алмаячак. Халык барыбер ач калачак.

— Шулай да — ник? Нишләп алай? — диде Габделхәй, төпченеп.

— Аңлаттым бит инде,— диде яшьбабай.— Үз планыңны тутырасың, өстәмә план килеп төшә. Күршеләр өчен, артта калган колхозлар өчен янәсе, үзара ярдәмләшү өчен. Район планын тутырсаң, тагын әйтәләр: сез, нәрсә, үз кайгыгызны гына кайгыртасыз — бөтен республика кайгысын кайгыртырга кирәк диләр.

— Кеше кайгысын кайгырткан арада үз халкың ачтан кырылып бетәчәк,— диде картәтәй.

— Гектарына... мең пот алып булса, ул чагында! — диде Габ-

делхәй, буш хыялга бирелеп.— Ул чагындамы, яшьбабай?!

— Алырсың — тот капчыгыңны! — диде яшьбабай көлеп.— Мин бит аны болай гына әйттем.

— Мең пот алсаң да, ике мең пот алсаң да, шул булачак,— диде картәтәй үзенекен тукып.

— Алырсың мең пот! — диде яшьбабай да тынычлана алмыйча.— Мытыеска гектар исәбе булсын да, натурплата булсын. Гектарыннан күпме чыга, анда аның эше юк. Ашлык уңса да, уңмаса да, мытыес үзенә тиешлесен каерып ала. Ул сөреп, чәчеп киткән урында ник шунда гөмбә үсми — гамендә дә юк. Менә бит ул эшләр ничегрәк, энекәем. Җирне яхшыртабыз, дип, бозып кына бетердек.

— Ничек бозып? — диде Габделхәй, аңламыйча.

## XI

Ул, игенче булмаса да, колхоз, авыл тормышын яхшы беләм, дип исәпләде, чөнки буш вакытларында әледән-әле Сталин клубындагы китапханәгә керә, шунда гәзит-журнал укырга ярата иде. Бүгенге көн политикасына кагылышлы озын-озын мәкаләләрне, докладларны, һәр төрле карарларны ул җентекләп укып, өйрәнеп бара иде. Моңа ул сугыш елларында әвәсләнде. Бит сугыш елларында, бигрәк тә соңгы елларда бер аның гына түгел, бөтен илнең күзе — гәзиттә, колагы — радиода булды. Һәркемне фронттагы хәлләр, иң соңгы хәбәрләр кызыксындырды. Ул вакытта безнең гаскәрләрнең һәр адымы, һәр җиңүе турыдан-туры аның үзенә дә кагылган кебек. Бөтен илдәге ачлык, мохтаҗлык та һәм шулай ук һәрбер уңай яки кире үзгәреш тә турыдан-туры аңа да кагылды. Шунлыктан авыл, авыл хуҗалыгы, колхоз турындагы һәр яңалык белән кызыксынмау мөмкин түгел иде. Ләкин бу мәсьәләдә ул күбрәк гәзиттә язганга, радиодан сөйләнгәнгә генә ышана һәм бары шуларны гына дөрес дип исәпли иде.

— Трактор җирнең әрлән балчыгын чыгарып сөрә,— диде яшьбабай, фикерен дәвам итеп.— Нурмысы аның — җегерме ике сантиметр. Җегерме ике сантиметр тирәнлектә сөрмәсең — штраф. Астагы әрлән балчыгын өскә чыгара, өстәгесен күмеп куя. Арышның, бодайның тамыры җегерме ике сантиметрга төшмәй. Өстә генә. Күп булса, ун сантиметр.

— Укыган кешенең шуңа да башы җитмәй,— диде картәтәй.

— Билчәннеке тирән китә,— диде яшьбабай.

— Һы! Башы булган кеше билчән белән арышны гына аерырга тиешие дә — баш юк. Аңгыранумнар! — диде картәтәй.

— Сүләсәң сүз күп инде ул, энекәем,— диде яшьбабай, көрсенеп.— Трактор, комбайн җирне таптап бетерә, ташка әйләндерә. Анда нindәй ашлык үссен?! Элек кеше җирне белеп, кадерләп торган. Хәзер аның кадере китте. Мытыеска җир кирәкмәй, колхозга — кирәкмәй, колхозчыга — шулай ук кирәкмәй.

— Ничек инде ул — «кирәкмәй»? — диде Габделхәй.

— Шулай. Кирәкмәй,— диде яшьбабай.— Әйтик, менә хәзер өләшеп бир элеккечә һәр кешегә — беркем алмаячак, төкереп качачак! Халыкны җирдән биздерделәр. Эш менә нәрсәдә, энекәем!

— Кызык,— диде Габделхәй.

— Кызык шул,— диде яшьбабай.— Шундаен да кызык, утырып кына җыласы калды, дүрәкәй! Калхуз да элекке калхуз түгел хәзер. Элекке бердәмлек, тырышлык, гаделлек юк.

— Үзе ашыга, үзе ачыга, үзе баралмай, үзе таралмай. Белмәйсеңмени? — диде картәтәй һәм янә көрсенеп, уфтанып куйды.

— Син гел дошман сүзләр генә сөйлисең, картәтәй,— диде Габделхәй коры гына.

— Һы, рәхмәт, улым,— диде картәтәй хәтере калып.— Мин инде күптәнге дошман. Калхузга мин беренче булып кердем. Җегерме җыл бил бөктем. Менә хәзер күзем дә рәтләп күрмәй, аякның да хәле юк. Өйдә чабата ясап ятам. Шулай да әле онытып җиткермәгәннәр — бау-шу ишәргә ҳирәк булса, миңа китерәләр. Акыллы кеше күптән төкереп качты шәһәргә, шахтыга... Без менә өелешеп ятабыз... дошман кешеләр...

Йомшак кына атлап чоланга яшәби килеп чыкты.

— Нишләп «өелешеп ятасыз» сез монда? — диде ул, күрәсең, кайнатасының сүзләренә ишарәләп.

Аңа беркем җавап бирмәде.

— Тиргәштегезмени? — диде яшәби.

— Һы, тиргәштек дисәң дә ярай,— диде картәтәй.

— Лыгырдама инде юк-барны! — диде яшьбабай, әтәсенә кычкырып.

— Син быел укуыңны да бетердең бугай? — диде яшәби Габделхәйгә.

— Бетердем,— диде Габделхәй теләр-теләмәс кенә һәм картәтәсен күз алдында тотып: «Нәрсә әйтер икән?» — диде уйлап куйды. Хәзер ул аннан ни өчендер шүрли башлагандай булды.

— Хәзер укыганнар заманасы,— диде яшьбабай, Габделхәйне мактап.— Безнең әтәй сүләй дә соң ул сүләвен, үзе томана: искечә дә белмәй, яңача да.

— Укымасак та яшәдек әле,— диде картәтәй.— Бер дә кешенекеннән ким җиребез булмады. Җимертеп эшләдек, җимертеп ашадык. Сез әнә укыган да бит, тамагың ач булгач, төкерәеммени?!

— Безнең Иленура назан калды инде,— диде яшәби пошынып, шулай да артык кайгырмыйча.— Җидене дә көчкә бетерештерде. Кеше арасында кием-салымы да булмады, ашарына да юк. Ач баланы интектергәнче дидек инде.

— Һы, бер дә кешедән ким җире юк әле,— диде картәтәй, Иленураны яклап.— Укымагач, көн дә әнә үзеңнең яныңда, көн дә өч йөз гырам он алып кайта. Укыган булса, койрыгын да күрмәсиең.

— Укыса, синеке түгел инде ул балаң — хөкүмәтнеке,— диде яшәби, кайнатасына ярарга тырышып.

— Калды инде,— диде яшьбабай да.

— Теләсә, әле дә соң түгел,— диде Габделхәй җанланып.— Бездә торып укыр — җибәрегез безгә, яшәби. Мин Казанга китәм. Иркенләп торырлар.

— И энекәем! — диде яшьбабай.— Кая инде ул безгә!

Шул чакны тыштан Зифун килеп керде, әтәсе янына сузылып ятты да колагына нидер пышылдарга тотынды.

— Зифун менә укымышлы булыр! — диде яшьбабай, малаен мактап.— Безнең Зифун әтәсеннән дә, инәсеннән дә уздырыр, апасы өчен дә укыр. Гел дөнья болай тормас әле, рәтләнер.

— Һы, көт, рәтләнер теге дөньяда! — диде үзсүзле карт.

— Сифуннар, Типуннар авыз тутырып эпи ашарлар,— диде яшьбабай, янындагы улын иркәләп.— Мукчаларын тутырып китәр лабаса минем улым бер көнне мәптеккә!

— Мукча тулы эпи булырмы? — диде бала, ихлас бер ышану белән.

— Мукчага эпи салмыйлар — китап-дәфтәр салалар,— диде әтәсе аңлатып.— Эпине син кесәңә салып барырсың.

— Мин кесәне бик зур итеп тектерермен! — диде малый хыялланып.

— Капчык кебек итеп тегеп бирермен, улым,— диде инәсе.

— Ыы шул, кулыма мукча тотармын, кесәмне аркама асармын,— диде малай көлеп.

— Һы, капчык асып чыгасы гына калды! — диде карт, сике такталарын шыгырдатып.

— Җитәр инде, пычрак каргасы! — диде яшьбабай, әтәсенә кычкырып.— Өзмәс тә, куймас та шул бер тотынса...

— Улың каманис булгач, пычрак каргасы булмай хәлең юк,— диде картәтәй, тынычлана алмыйча.



## XII

Казандагы итле аш, ниһаять, пешеп чыкты. Бөтен өйгә бәйрәм төсе керде. Барысының да күңелләре күтәрелеп китте. Балалар, ике өйне бер итеп чыр-чу килеп куыштылар да, кинәт кенә тынып калдылар. Олылар исә, әле генә булып алган сөйләшүне онытып, әкрен генә өстәл тирәсенә җыела башладылар.

Хатын-кызлар казан янында булашкан арада картәтәй, капшанып, шүрлектән өч йомыры алды. Йомырыларның зуррагын, яхшырагын Вәлиәхмәт улы алдына, икенчесен Габделхәй алдына, өченчесен, сапсызын үзенең алдына куйды. Шуннан соң, киезтекле аякларын шактый җитез хәрәкәтләндереп, чолан якка чыгып китте. Аның шулай тыз-быз килеп йөрүенең серен бик яхшы аңлаган яшьбабай канәгать төс белән көлемсерәп куйды.

— Безнең әтәйнең шул ягы әйбәт,— диде.

Картәтәй, берәрсе берәр сүз әйтсә, шундук аны чукып алырга әзер булып, җитди, хәтта усал бер кыяфәттә яңадан өстәл янына килде, яртылы шешәне тантана белән улы алдына утыртып куйды, калтыранган бармаклары белән кагәзь бөкене ачты да хөрмәт йөзеннән «каманис» улына:

— Әйдә, үзең кара. Түгәрмен кебек,— диде.

Яшьбабай шешәне үз кулына алды, тулымы-түгелме дигәндәй, чамалап бераз кулында тотып торды һәм иплән кенә әтәсенең йомырысына агыза башлады.

— Мин эчмим. Миңа салма,— диде Габделхәй ашыгып.

— Һы, синең әле шундый өнәрең дә бармыни? — дигән булды картәтәй.

— Эч. Буыннарың йомшап китәр,— диде яшьбабай, артык кыстамыйча гына.

— Аның буыны болай да йомшактыр. Укыган кешедә буын буламыни? — диде картәтәй.

Габделхәйнең ачуы килеп куйды. Картәтәсенә үч итеп аның үзенең дә «буынлы» икәнлеген күрсәтәсе килеп китте. Әйткән сүзеннән кире кайтып ул инде эчәргә дә ризалык белдермәкче иде, ләкин шул чакны яшьбабай аракы агызудан туктап калды.

— Нәрсә соң бу? — диде ул аракы салынган йомырыны күзенә якынрак китереп.

— Һы! — диде карт әре генә. — Каманис кеше ышанмай инде ул. Иснәп кара.

— Иснәп! Иснәп түгел, күзең белән кара син аңа иң элек! — диде яшьбабай йомырыны әтәсенең күзенә төртеп.

— Нәрсә бар? — диде карт каушагандай итеп һәм күрмәс күзләрен челт-мелт йомгалап, йомырыга текәлде.— Берни күрмәймен. Әллә чүп төшкән?

— Кара ич бу, язу карасы! — дип кычкырды яшьбабай.

— Нишләп кара булсын, ак лабаса! — дигән булды карт, шаяртмакчы булып. Урыныннан торып, ул аракылы шешәне яктырак, тәрәзә янынарак китереп карады.

— Каралы шешә. Яздан бирле йөридерие бер шешә буталып.— диде яшьбабай.— Күзең чыккандыр карабрак бирсәң. Кем алып кайтты — Сиринәме?

— Күзем булса, мин аны Сиринәгә кушып тормаган булырыем,— диде карт, акланмакчы булып.

— Нишләргә соң? — диде яшьбабай, икеләнеп.— Каян килеп кергәндер бу каралы шешә безнең өйгә?

— Эчмәгез, эчмә,— диде яшәби, кулын селтәп.— Әллә агуланырсыз.

— Әрәм бит әле,— диде яшьбабай.

— Әрәм булгач, эчәсең инде,— диде яшәби.

Картның ачудан, уңайсызлыктан калку яңаклары, ирен читләре тартышты. Үлсәм үләрмен, шулай да үземнекен эшләрмен, дигән бер кирелек белән үз йомырысын кысып тотты да шәмәхә төсендәге аракыны авызына якын китерде.

Барысы да, тыннарын кысып, аның авызына текәлделәр. Карт чыраен да сытмыйча, үзенә тигән өлешне эчеп бетерде, шомарып беткән зур учы белән авыз читләрен сөртеп куйды, капшанып тәлинкәдән суган кисәге табып алды һәм, тамагын кыргалап, тешсез авызында әвәләргә тотынды.

— Ай-йай, булдырасың икән әле син, дүрәкәй! — диде яшьбабай, әтәсен мактап.

— Төшеп калганнардан түгел,— диде карт тыйнак кына.

— Булдырмас ул! Чабатадай авызы килешеп кенә тора! — диде картый пыраннап.— Агу салып бирсәң, агу эчәр. Яшь чагында авызына да алмады, карт саңый! Кая ул чакта болай эчеп утырулар!

— Һы, элек! — диде карт канәгать бер төс белән.— Элек заманасы ниндәй булды? Коллык заманы. Сәвит безгә азатлык бирде. Хөррият. Теләсәм эчәм, теләмәсәм — түкереп ташлыйм.

— Хөрриятне аракы эчәр өчен бирмәгәннәрдер лапса! — диде Иленура, сүзгә катышып.

Картәтәсенең аракы эчеп, җитмәсә бозык, шикле аракы эчеп утыруы өчен аңа Габделхәй алдында бик нык уңайсыз иде. Ләкин картәтәсе аны ишетмәде дә. Ул хәзер, гомумән, беркемне ишетмәде, беркемгә игътибар итмәде — ашыгып, авызын пешерә-пешерә кайнар шулпа чөмерергә тотынды.

— Шөкәтсез! Шөшле авыз! — диде картый тынычлана алмыйча, картын игәп.

Ләкин картка инде берни дә тәэсир итәрлек түгел иде. Бөтен өй эчендә, барлык ирләр арасында бердәнбер батыр кеше буларак ул, беркемгә дә күтәрелеп карамыйча, ашавында булды. Яшьбабай да тәвәккәлләп йомырысын кулына алды, яртысын эчте дә ашарга тотынды.

— Ниме? — диде бераздан яшәби борчылып.

— Нәрсә «ниме»? — диде яшьбабай көлеп.

— Эчегезне актармадымы? — диде яшәби.

— Актарса, иң элек әтәйнекен актарырые,— диде Вәлиәхмәт абзый.

— Аталы-уллы... оят юк, тәүфикъ юк. Көферлек арттырып. Балалар алдында...— диде картый, тыела алмыйча.

Шулай да бераздан ул да тынып калды — кайнар аш, итле аш барлык ачуларны, кире тойгыларны юкка чыгарды. Беркадәр тамак ялгап алгач, яшьбабай үзенең, әтәсенең йомырыларына тагын аракы агызды һәм:

— Әйдәле, әтәй, кайгыларны онытып... тагын берне,— диде дә җырлап җибәрде:

— Сандугачлар ояда,
Оялары пыяла.

Яшәсен иптәш Ысталин.—
Шәп яшибез дөньяда!

Иленура әтәсе өчен оялып, кып-кызыл булды, гафу үтенгән сыман Габделхәй ягына карап алды. Габделхәй исә, күзләрен түбән иеп, эчүчеләр ягына карамаска тырышты. Картый белән яшәби дә күрмәмешкә, ишетмәмешкә салындылар. Картәтәй икенче йомырыны да кулына алды һәм улына җавап итеп:

— Сандугачлар ояда,
Оялары пыяла.
Дөмексен иптәш Ысталин —
Шат яшибез дөньяда! — диде.

Шулай диде дә йомырысын авызына каплады. Ул эчеп бераз торгач яшьбабай, шелтә белән:

— Әтәй! Җырның сүзен бозма! — диде.

— Лилин биргән хөрриәтне кысарга хакың юк! — диде картәтәй.— Теләсәм — җырлаймын, теләмәсәм — юк.

— Хөрриәт булгач, мин дә җырлап күрсәтәем әле.— диде картый сүзгә кушылып һәм көйләп янә такмак әйтә башлады:

— Исереккә сәлам бирмә,
Бирсә дә ул, аннан алма,
Исерекнең хәлен белмә,
Алла диген, бәдәвам.

Иленура, авызын каплап, пырхылдап җибәрде. Яшьбабай, «тик тор!» дигән сыман, яраткан кызына ачулы гына карап алды. Габделхәй исә, шагыйрь кеше буларак, картыйсының «шигыренә» шундук үзенчә бәя бирде. «Йомшак эшләнгән. Коры дидактика».— дип уйлады. «Коры дидактика»ны Антонина Семеновна әйтергә ярата иде. Габделхәй дә, аннан күрмәкче, теләсә нинди шигъри юлга карата шундый тәнкыйть сүзләре кулланырга тырыша иде. Ләкин «коры дидактика» картәтәйгә бөтенләй көтелмәгәнчә тәэсир итте. Корткасының җае чыккан саен китап сүзе сөйләргә, мөнәҗәт әйтергә ратуын ул болай да өнәп бетерми иде. Хәзер аның шулай ирләр арасына кысылып, остарып утыруы картның тәмам күңелен болгатып җибәрде.

— Тынычлап ашарга да ирек юк.— диде ул үпкәләп.— Ашаганың да күренә, эчкәнең дә. Үз акчама алган — сиңекенә түгел.

Шулай сөйләнә-сөйләнә, ул ашалып бетмәгән ашын калдырып, чайкалып урыныннан торды. Мысык-мысык борынын тарткалап өстәл арасыннан чыкты да ишек төбендәге сикегә, үз урынына барып ятты.

Габделхәйгә кыен, бик кыен булып китте. Менә хәзер кем дә булса торыр да, карт кешене барып юатыр, берәр җылы сүз әйтер шикелле тоелды. Ләкин беркем аның янына бармады, беркем юату сүзе әйтмәде. Барысы да тынып сагаеп калдылар.

— Картәтәй җылай! — диде Иленура беренче булып, кызганып.

— Җыласа... Эчмәскә яхшы булыр моннан соң... карт башына! — диде картый.

— Үзеңне үзең белмәгәч, әчәсе түгелие дә соң.— диде яшьбабай да.

— Ярар инде, каныкмагыз барыгыз да бер кешегә! — диде яшәби.

## XIII

— Картый, ишеттеңме әле — Бүә буенда бер марҗаны чәнчеп ташлаганнар.— диде Иленура, картыйсына эндәшеп.

— Ишеттем, кызым.— диде картый.— Ходаем, афәтле үлемнән сакла. Тамак харап итә кешене. Тамак тамукка кертә адәм баласын. Гаптелхәй улым да турыдан гына килгән бит әле.

— Турыдаң?! — диде Иленура, ашавыннан туктап.— Кит, дивана! Икенче җөре тагын шуннан!

— Каян йөрим соң? — дигән булды Габделхәй.

— Чигәсенә чәнечкәннәр, ди, мескенкәемнең.— диде Иленура, Габделхәйгә җавап биреп тормыйча.

— «Мескен» түгел, «мәрхүмә» кирәк.— диде картый, төзәтеп.

— Чигәсенә түгел, күкрәгенә.— диде яшьбабай да сүзгә катышып.

— Юк, чигәсенә! — диде Иленура.— Аннан — аркасына. Сәлимә әйтте.

— Белә синең Сәлимәң! — диде яшьбабай, әтәсенә кычкырган кебек кычкырып.

— Белмәс инде! — диде Иленура, сүзен бирәсе килмичә.

Үз сүзенә ныграк ышандырасы килгән сыман, ул хәтта иңбашын сикертеп куйды һәм «шулай ич, иеме?» дигәндәй, яклау эзләп Габделхәйгә карап алды.

— Фәнзия апаның кызы бар икән лапса, ишеттегезме әле? — диде ул шундук, «чигәсенә чәнечкән» марҗа кызын да, Сәлимәне якларга кирәген дә онытып.

— Монысы ничәнче инде? Бишенче бугай? — диде яшәби тыныч кына.

— Бишенче.— диде Иленура.

— Кызлардан бәхете бар инде анысы Фәнзиянең.— диде яшьбабай.

— Бер малайлары да булмагач, күңелсездер ул, иеме, әнкәй? — диде Сиринә, инәсенең авызына карап.— Безнең Зифун бар, иеме, әнкәй?

Олылар җиңелчә генә көлешеп алдылар. Сиринә, гаеп сүз әйттем, ахрысы, дип уйлап, олыларның әле берсенә, әле икенчесенә карап-карап алды, ләкин нинди гаеп сүз әйтүен аңлый алмады.

— Менә, энекәем.— диде кызмача яшьбабай, бернигә катышмыйча утырган Габделхәйгә.— Элекке заман булса, Фәнзиядән ярлы кеше булмасые.

— Нишләп? — диде Иленура.

— Ник дигәндә, шул, дүрәкәй, җир бүлгәндә кызларга элек өлеш чыкмаган, җир малайларга, ирләргә генә бирелгән.— диде яшьбабай аңлатып.— Менә шуннан, әйтик, берәүнең биш малае бар ди, дүрәкәй. Аннан килеп, үзе, ата кеше. Булдымы алты? Алты кеше, алты ир кеше, дүрәкәй. Моңарга хәзер, ызначытса, алты өлеш җир бирелә. Берәүнең хәзер биш кызы бар, ди. Фәнзияләрнеке кебек. Атасыннан башка ир заты юк. Бирелә моңа, ызначытса, бер өлеш җир.

— Нигә алай соң ул? — диде Иленура аңламыйча.

— Хатын-кызның хокукы булмаган патамушты,— диде яшь бабай, бөтен өйгә кычкырып.— Хокукың юк — җирең дә юк. Хатын-кызны чутка да тыкмаганнар. Менә шуннан, әйтик, безгә өч өлеш тия: әтәйгә, миә, Зифунга. Сезнең берегездә дә юк. Аңлашылдымы?

— Кит! Яшәгәннәр инде шунда! — диде Иленура иңбашын сикертеп һәм, «шулай ич, иеме?» дигән сыман, Габделхәйгә елмаеп куйды.— Безнең картәтәй генә мактай элекке заманны. Яшәгәннәр эт көнендә.

— Бер дә кешедән ким яшәмәдек.— диде картәтәй, сике ягыннан аваз биреп.

— Әй! Син исәнмени әле, әтәй? — диде яшьбабай көлеп.— Әйдә кил. Ату бетерәм.

— Кил инде, кил, әтәй — ашың да суына.— диде яшәби иплән кенә, ягымлы итеп.

Карт җавап кайтармады. Тагын бераз кызгандырып алырга теләгәндәй, ахылдады-ухылдады да торып утырды.

— Булмай. Тәкать калмаган,— диде ялындырасы килеп.

Габделхәй житез генә урыныннан торды, картәтәсе янына килде дә аны култыклап алды.

— Әйдә, картәтәй! — диде.

— Менә... игелекле бала булгач...— диде картәтәй, Шәмсебанат кызының улын мактап һәм бернинди каршылыксыз өстәл янына үз урынына килеп утырды.— Боларда шәфкать-миһырбан калмады, улым,— диде җыламсырап.— Минем күзләрем йомылганны гына көтәләр. Калдырыр байлыгым да юк... шөшлемнән башка. Күз кырыена да чыгармайлар, улым. Кайткач инәңә әйт, Шәмсебанат кызыма — килеп алсын. Бер көн торасым килмәй шушы зобаныйлар янында.

— Җә инде, әтәй, сүләмә юк-барны, әллә кеше ышандырырсың! — диде яшьбабай җиңелчә шелтә белән.

— Китагай! Аны гына кыерсыталардыр! — диде картый да.

— Картәтәй, аша инде, ашың суына лапса,— диде Иленура.

Яшәби кайнатасы янына ашлы кубәтәсен этебрәк куйды һәм мөмкин кадәр ягымлы итеп:

— Аша, әткәй, аша,— диде.— Син безнең алтын терәгебез. Бар карап торганыбыз — син. Син булмасаң, икенче көнне үк коры таякка калабыз без. Күңелеңә авыр алма безнең юк-бар сүзне. Аша, әткәй, аша.

Яшәбинең шулай юатып, юмалап, йомшак итеп әйткән сүзләреннән соң гына картәтәй кашыгына тотынды.

— Рәхмәт киленгә, ул гына аңлый мине, — диде.

— Менә, маладис безнең әтәй! — диде яшьбабай да, әтәсен мактап.

Шуннан соң ул буш йомырыга яңадан болганчык аракы агызды һәм йомырыны әтәсенең алдына куйды.

— Шуның өчен тагын берне күтәреп җибәр әле, әтәй,— диде.— Хатын-кыз тиргәшә торсын. Тиргәшмәсә ул хатын-кыз да булмай. Хәзергә без — ирләр. Ирләр авыр эш эшләй. Шуңа ул ашарга да, эчәргә дә тиеш. Шулай бит, иеме, энекәем Гаптелхәй?

— Утырган була лапса! — диде кинәт Иленура әтәсенә үпкәләп, матур иреннәрен күптереп. Ләкин шундук Габделхәй ягына борылып карарга да онытмады. «Син тагын чынга ала күрмә аның сүзләрен!» — диган сыман елмайгандай итеп куйды.

— Хатын-кызның бернинди хокукы булмаган аның, энекәем, — диде яшьбабай, кулларын болгап.— Хәзер алар безнең белән тигез хокуклы. Дөньяны менә шул бозды: тигезлек!

— Шуңа да муенга атландылар,— диде картәтәй, улының сүзен куәтләп. — Тын алырга да ирек юк.

Хатын-кыз, ирләр, тигезлек-тигезсезлек турында еш кына кузгалып куя торган бәхәснең башы чынлыкта, гомумән, барлык ирләр, хатын-кызлар арасындагы тигезлек-тигезсезлеккә кайтып калмый иде. Чынлыкта бу картый белән картәтәйнең күптәнге бәхәсенә, үзара нинди дер каршылыкларына кайтып кала иде. Габделхәй дә, башкалар да моны бик яхшы аңладылар һәм бер дә монда бөтен дөнья проблемаларын хәл итәбез, дип исәпләмәделәр. Тынычлана башлаган сыман тоелган картның яңадан үзен «кыерсытулары» турында авыз ачуы булды, картый да, эндәшми калуны кирәксез санап:

— Шөшле авыз! Атланганнардыр синең муенга! — диде.

— Һы, ирекә чыктылар! — диде картәтәй, үзенә карата әйтелгән тәнкыйть сүзләренә бу юлы бөтенләй игътибар итмичә. — Кияүгә барып өч көн тормайлар — ирек алалар да кайтып киләләр. Ирдән аерылып кайткан хатын бөтен авылга бер булырые булса. Хатын кыйнаган кеше дә бөтен авылга бер булырые. Андай кешене бөтен авыл халкы каһәрләрие.

— Элек бит, этәй, ирек улмаган, ирек! Хөррият! — диде кызмача яшьбабай. — Хәзер бөтен нәрсә ирек. Сүләмә син элеккене.

— Һы, ирек, — диде карт мыгырданып. — Барысы да ireккә чыкты. Берсенең ире кыйнай, икенчесенең хатыны кыйнай. Фасикъ дөнья.

— Ирек кирәкмәгәч алай, әчмә! — диде картый яңадан кыза башлап. — Оят кирәк әзрәк, карт самый. Шул яшеңдә... балалар алдында... Мәчит карты булып, сакалыңны сыйпап кына утыра торган бер вакытта.

— Кая мәчитең? Ник манарасын кисеп төшердең? — диде картәтәй.

— Ярар инде! Кит, тәмле ашның тәмен җибәреп,— диде Иленура.

Картый белән картәтәй тынып калдылар.

## XIV

— Фәнзиягә итле аш илтеп бирергә кирәк... баладан котылган кешегә...— диде шул чакны яшәби, урыныннан кузгалып.

— Әнкәй, үзем барам! — диде Иленура.— Габделхәй, әйдә икәү? Шунда кинога да керербез.

Әгәр Иленура кинога гына чакырса, Габделхәй әле берсүзсез риза булган булыр иде, ләкин аның бала тапкан хатын янына барырга чакыруы җегет кешенең хәтерен калдырды. «Үзе кебек хатын-кыз дип белә микән?!» — дип уйлады ул.

— Нинди кино ул тагын арыган көенә? — диде яшәби кызының «кино» сүзен ошатмыйча.— Фәнзия апаңнарга барырсыз да кайтырсыз.

— Һы! Кинага барма дип әйтеп кара син аларга! — диде картәтәй сукранып. — Элек без ата-ананың күз карашыннан да курка торганыек. Куркыр болар!

— Курка торган заманалар үткән инде, картәтәй! — диде Иленура җиңел генә һәм, «иеме»? дигән сыман, янә Габделхәйгә елмаеп алды.

Габделхәйнең күз карашы исә бернинди теләктәшлек белдермәде.

— Син нәрсә теләсә кемгә кычкырынасың әле? — диде яшьбабай үзенең ата кеше икәнлеген күрсәтәсе килеп. — Менә хәзер мин «барма» дип әйтәм икән, бармайсың! Ник дисәң, патамушты син минем кызым.

— Карарлар синең сүзеңә! — диде Иленура үчекләшеп, иңбашларын сикертеп.

Үпкәләгән сыман ул өстәл яныннан ук торып китте. Күп тә үтмәде, анысын анда орып, монысын монда орып, затлырак, рәтлерәк киемнәрен барларга тотынды.

— Ашап туйгач амин тоту юк, рәхмәт әйтү юк — торды да китте әнә, тәүфиксыз! — диде яшәби башбирмәс кызын шелтәләп һәм шул ук вакытта кайнанасы белән кайнатасына ярарга тырышып.

— Шуңа да бәрәкәт качты өйдән, — диде картәтәй.

— Кызыбыз кинога җыена. Болай булгач, Фәнзиягә үзең барасың инде, — диде яшәби яшьбабайга, серле елмаеп. — Фәнзия синең яраткан кызың ич. Хәлен дә белерсең.

Яшьбабай аның сүзләрен ишетмәде, ахрысы, — гармун тарткандагы кебек кулларын җәеп җибәрде дә бөтен өй эчен яңгыратып җырларга тотынды:

> — Кара каен саз саен,
> Төядем чана саен.
> Апакаем-җаныкаем,
> Карама кеше саен.

«Саен» күп кулланыла. Ямьсез. Коры дидактика», — дип уйлады үз алдына яшь шагыйрь, яшьбабасының җыр сүзләренә игътибар итеп.

— Кинога барып йөрисе юк — кәнсирт үзебездә башланды,— диде яшәби көлемсерәп.

Күп тә үтмәде, төзәнеп-ясанып Иленура Габделхәй янына килеп басты.

— Әйдә, киттекме, Габделхәй? — диде.

— Киносы нинди? Нәрсә күрсәтәләр? — диде Габделхәй Иленураның мондый җитезлеген бик үк ошатмыйча.

— «Ибан Грузный» бугай, — диде Иленура.

— Теге мөселманнарны кырган Ибан Грузныймы? — диде картый исе китеп.

— Шул булмый, шулдыр инде, — диде Иленура.

— Тәүбә-әстәгафирулла! — диде картый. — Кайдагыны казып чыгарганнар, илаһым. Көфер һаман көферлеген итә... алла дошманнары, мәлгуньнәр!

— Фасикъ дөнья, — диде карт. — Ирекка чыктылар. Хөррият.

— Мин аны күрдем инде. Барасым килми, — диде Габделхәй.

Иленураның шат йөзе күңелсезләнеп калды. Күңеле кырылганын күрсәтмәс өчен ул тиз генә читкә китеп барды. Яшәби чигүле сөлге белән төреп бәйләнгән зур гына чүлмәк тотып кызы янына килде, чүлмәкне кызына бирде дә:

— Кайнар. Пешә күрмә, түгеп җибәрә күрмә, — диде. Шуннан соң яратып кызының аркасыннан сөеп куйды. — Иртән иртүк торасың бар, кинога кереп торма, кызым. — диде.

— Карармын әле, — диде Иленура. Чыгып китәр алдыннан, күрәсең, бер карарга килеп, кискен генә әйтеп куйды: — Бармам, — диде.— Нәрсәм калган соң минем анда?! Кайтырмын.

— Саваптан булсын — менә монысын да бирерсең, — диде картый Иленурага кечкенә төргәк тоттырып. — Шәмсебанат кызымның күчтәнәче. Күз каргамаслык кына... чәй-шикәр. Тизрәк савыксын, дип әйттеләр диген.

— Әйтермен, — диде Иленура.

— И, энекәем! — диде яшьбабай Габделхәйгә эндәшеп. — Тотарсың хәзерге яшьләрне! Синең сүзеңне алар чүп урынына да күрмәйләр. Шулар белән менә алып бар син калхуз эшен. Син башлы җегет. Маладис син! Без менә укымаган. Илне туйдырырга кирәк, төзәтергә кирәк ул җимерек-ватыкны. Без дә эшләмәсәк, кем эшләр? Без, беләсең килсә, эш аты, энекәем. Бөтен әрәм тамакны туйдыручы эш аты. Эх, энекәем!

## XV

Иленура чыгып киткәч, өстәл тирәсе бушап, күңелсезләнеп калгандай булды. Вакыт инде соң иде, тышта караңгы иде. Иленураны озатып куйгач, яшәби күзләре йомылып беткән, шулай да олыларның сүзенә колак салып, кызык итеп утырган балаларны куалап йокларга яткырды. Шуннан соң кайнанасы белән икәүләп алар тиз-тиз генә табак-савытларны җыештырдылар. Тамагы туйган, күңеле түгәрәкләнгән картәтәй алпан-тилпән үз ягына чыгып китте. Өстәл янында Вәлиәхмәт абзый белән Габделхәй генә торып калды. Кызмача яшьбабай кычкырып җырлап-җырлап алды, озын куллары бутап сөйләнгәләп алды. Айнык чагында бик аз сөйләшә торган яшьбабай, бераз салып алгач, шулай кирәгеннән артык сүзчәнләнеп китә иде.

Тамагы тук булса да, Габделхәйнең эче пошты. Аның монда

яшьбабасы сөйләнгән сүзләрне тыңлап та утырасы килмәде, шул ук вакытта үзен генә калдырып китәргә дә уңайсыз шикелле иде. «Әллә Иленураны эзләп китим микән?» — дип уйлады ул утыра торгач. Ләкин аның караңгы урамга да чыгасы килмәде. Шулай нишләргә белмичәрәк утырганда Иленура үзе кайтып керде.

— Әнкәй! Фәнзия апаның бәбәен күрдем! — диде ул килеп керү белән, кычкырып, шатланып.

— Хәле ничек Фәнзия апаңның? — диде инәсе.

— Хәле әйбәт. Рәхмәт әйтте, — диде Иленура.

— Исем кушканнармы соң әле? — диде яшәби.

— Юк. Әй-лә. Белмәймен. Сорамадым, — диде Иленура. — Бер дә кеше баласы кебек түгел ул, песи баласы кебек кенә.

— Кит, самый, сүләмә юкны. Кеше баласын песи баласына охшаталармыни?! — диде яшәби.

— Нишләп самый булыйм мин? — диде Иленура инәсенең Габделхәй алдында үзен шулай дип атавына хәтере калып. — Ышанмасаң үзең барып кара.

— Ярар, хәзер китәм, — диде инәсе. — Менә әтәң белән икәүләп барып карарбыз. Әйдәле, Вәлиәхмәт иптәш. Кәнсирт тәмам. Җитәр. Йокларга вакыт. Шешә төбендә дә берни калмаган.

— Нәрсә, мине әллә шешә төбендәген көтеп утыра дип белдеңме? — диде яшьбабай хатынына бәйләнмәкче булып. — Дөрес, миңа җиткән. Артыгы белән җиткән. Миңа синең шешә төбең кирәкмәй, йокың да кирәкмәй. Ни өчен дигәндә, шул: туйдым мин бу дөньядан! Көн-төн чабасың бушка, өч йөз гырам он өчен. Бер тиенгә кирәге юк дөньягызның! Балалар хакына гына... Эх, энекәем Гаптелхәй!

— Бик ватылдың бу арада, Вәлиәхмәткәем, — диде яшәби ирен кызганып. — Тәмам хәлдән тайдың. Бу болганчык нәрсәң ярап куйды тагын. Зарары юк микән ул каралы савытның — шул гына эчемне тырнап тора. Тормышлар рәтләнгәч, су кебек чип-чистасын алып кайтып эчерермен әле мин сиңа, Вәлиәхмәткәем.

— Кирәкмәй су кебек чистасы да, болганчыгы! — диде яшьбабай киреләнәсе килеп. — Эчкече дип белдеңме әллә син мине? Юк, эчкече түгел мин. Сугышка кадәр этәйдән яшереп тә эчкәнем булмады. Сугышырга, мылтыктан атарга үрәтмәделәр, иң элек эчәргә үрәттеләр. Сугышка керер алдыннан үзләре бирәләр. Батырлык өчен, янәсе. Валлаһи, энекәем. Эчмәсәң, потсут. Итәки үрәндем, энекәем. Көнтөн камыт киеп тарттым. Бөтен бригат минем кулда. Аларны бит эшләтергә кирәк. Эшләткәч тамагын да туйдырырга кирәк, күңелен табарга кирәк. Бригадирмын дип кешедән артык гырам алганым юк. Гырам! Намусым саф. Безгә харам килешмәй, энекәем. Каманис булсам да, алладан куркам мин. Алладан бигрәк, кеше сүзеннән куркам. Ул бит синең күзеңә карап тора, алла урынына, патша урынына күрә сине. Минем үземә берни кирәкмәй. Бүген үлсәм дә үкенмәймен, энекәем.

— Китагай! Лыгырдама инде син дә! — диде картый улына кычкырып. — Кәфер сүзе сүләп монда! Фирештәнең амин дигәненә туры килер, мордар китәрсең, әстәгафирулла-тәүбә!

— Ачуланма, инәй, — диде кинәт яшьбабай күндәм генә...

## XVI

Көндез үк инде кояшның үтә нык кыздыруы, тупылдагы каргаларның кирәгеннән артык кычкырулары, шаулашулары, кичкә таба күптән көтелгән дымлы җил исеп куюы «янгыр явар, ахрысы» дигән бер сизенү тудырган иде. Чыннан да, шулай булып чыкты. Төн

рталарында барлык җанлы-җансызны уятып, дөбердәп күк күкрәәне, аннан соң коеп яңгыр яуганы ишетелде. Габделхәй куркып уянып китте. Чоланда яшьбабасының иске шинеле астында ул такта түбәгә шапылдап, бәреп яңгыр яуганын һәм түбә кыегыннан җир өстенә өзлексез яңгыр суы коелганын тыңлап ятты. Яңгыр бик озак яуды. Әле тынып, басылып яуды, әле җилләп, яшенләп яуды.

Җил, яңгыр, күк күкрәүләренә күнегә төшкәч, искәрмәстән Габделхәй яңадан йоклап китте. Күпмедер вакыттан соң тишек түбәдән тып-тып тамчы тамганын тоеп, тагын күзләрен ачып җибәрде. Башына, аягына авыр булып салкын тамчы тама иде. Караңгыда кулын сузып ул идәннең корырак җирен капшап карады да, урынын читкәрәк күчерде.

Яңгыр төне буе яуды. Таң атып хатын-кыз сыер саварга чыга торган вакытта да әле өстән туктаусыз сибәләп тора иде. Иртүк торган яшәби сөт савып керде, ләкин сыерны абзардан чыгармады. Болай өзлексез ява торган булса, көтүнең чыгуы икеле иде. Сөтле бидерәсен яңгырдан каплаштырып яшәби өйгә килеп кергәндә, өлкәннәрнең барысы да уянган, казан астына ягылган, самавыр куелган иде.

— Ял булды әле бу, иеме, әнкәй? — диде Иленура, яткан җиреннән.

— Ялын ял да, печәнгә барып булмаса, көндәгечә он кайтмаячак бит әле, кызым, — диде яшәби. — Яңгыр яуганда да килеп кенә торсыные ул он дигән нәрсә.

Яшәби белән Иленура өй эчендә сөйләштеләр. Чоланда Габделхәй аларның һәр сүзен ишетеп, тыңлап ятты. Бераздан ул да торды һәм башкалар кебек өстәл янына килде. Сүзсез генә, тәмләп кенә чәй эчтеләр, сибәләп яуган яңгыр тавышына колак салгандай иттеләр. Яңгыр әле әкренәйде, әле көчәйде. Бер-ике мәртәбә хәтта кояш та күренеп алды. Ләкин тиз генә аязыр шикелле тоелмады. Мондый чакта өйдә утырудан да хәерлесе юк иде.

— Гаптелхәйне дә печәнгә алып барырбызмы дигәниек, алла бабай каршы төште бит әле, — диде яшәби үзалдына сөйләнеп.

— Бүген бармасак, иртәгә барырбыз, име, Габделхәй? — диде Иленура.

— Иртәгә генә барып булмас әле, — диде яшьбабай. — Бер башлагач, китте инде бу бер атнага.

— Белгән юк инде ходайныкын, — диде картый.

Габделхәй сүзгә катышмады. Аның бик нык эче пошты. Ул үзен тоткындагы кебек хис итте. Бер атна буена шулай яңгыр яуса, нишләп утырыр икән соң ул монда күрәләтә артык кашык булып?

Төш урталарында яңгыр шулай да туктады. Яңгыр бәргәләвенә каршы торып арып-алҗып беткән тупыл яфраклары кинәт хәрәкәтсез калдылар. Бакчадагы җиргә яткан, егылган бәрәңге сабаклары хәлсезләнеп шулай ук тынып калдылар. Канаулардан болганчык сулар акты. Урамда ыштан балакларын күтәреп чабышып йөргән шат малайлар күренде. Кара ләпек сыланган авыр күнитекләрен көчкә өстерәп, урамнан ярым солдат киемендәге бер кеше узып китте.

— Кантурга барып кайтаем әле мин дә, — диде яшьбабай, урамдагы кешене күреп.

Ул җыенып чыгып китәргә дә өлгермәде, яңадан яңгыр сибәләргә тотынды.

— Йөрмә интегеп, беркем юктыр әле анда, — диде яшәби.

— Ничек түзеп ятмак кирәк өйдә? — диде яшьбабай.

«Шулай шул — ничек түзеп ятмак кирәк монда?!» — дип уйлады Габделхәй дә. Аның да җыенып чыгып китәсе килде. Әлегә ул кая китәргә, нәрсә эшләргә тиешлеген анык кына белмәде. Аның, билге-

ле, авылдан болай тиз генә кайтып китәсе дә килми иде, ләкин шул ук вакытта монда бер эшсез-шөгыльсез ятып та булмый иде кебек. Аннан соң өзлексез аның күңелен бер уй, бер кайгы-борчу тынгысызлап торды. Аның хәзер теге Уфа кызын яңадан күрәсе һәм ничек тә аның белән яңадан килешәсе, үзенең тупаслыгы өчен гафу үтенәсе килә башлады. Аннан соң ул бит Казанга китәсе кеше! Шулай булгач, Казанда укый торган кеше белән бөтенләй үк бозылышу да дөрес булмас кебек. Үзенең бу йомшаклыгын ул үз мин-минлеге алдында шулайрак дип акларга тырышты. Ни генә булмасын, Былбыл аңа хәзер бик кадерле һәм якын булып тоелды. Дөресен әйткәндә, ул аны чын-чынлап сагына һәм юксына башлады.

Бераз вакыт үткәч ул, икеләнүен җиңеп, юлга җыена башлады.

— Нишләп алай бик тиз? — диде яшәби.

— Тагын бер-ике көн тор әле, Габделхәй. Их, болынга да барып булмады! — диде Иленура өзгәләнеп.

— Кызлар белән танышырыең, — дигән булды яшәби шаярып.

— Минем әле документлар да әзер түгел Казанга китәргә, — диде Габделхәй.

— Ә, ие шул, — диде яшәби бик тиз килешеп.

Иленурадан башкалар аның шулай кисәк кенә китәргә ниятләвенә артык борчылмадылар да, ахрысы. Аңа бары кайткач сәлам әйтергә куштылар да, гафу үтенгән сыман: «Гаеп итмә инде — алама чакка туры килдең», — диделәр. Картый исә: «Илгизем белән Фидаилемә», — дип, Габделхәй үзе алып килгән чүпрәккә төреп, икешәр пешкән күкәй бирде, пешкән бәрәңге һәм кичә үзе җыеп алып кайткан җир җиләген бирде.

— Күпер аша кит, — диделәр аңа озатып калганда.

— Ярар, — диде Габделхәй.

— Үзем озатып куяем әле авыл чыкканчы, — диде Иленура, Габделхәй инде ишек тоткасына тотынгач.

Габделхәй көтәргә булды. Иленура мич артында гөлбәчтә киемнәрен алыштырды, көзгегә карап алды, Габделхәй янына килгәч, никтер көлеп куйган булды. Ишектән алар икәүләшеп чыктылар.

— Дөньяңны онытма — бәрәңге кумәсе дә бар, — дип калды яшәби кызы артыннан.

Урам уртасы җырып чыккысыз пычрак, аяк асты юеш иде. Баскан саен аяк батып, таеп китә иде. Габделхәй белән Иленура бераз җир янәшә бардылар да, урам читеннән корырак, катырак җир караштырып, бер-берсеннән аерым киттеләр. Урамнан шулай әле бер-бер артлы, әле янәшә атлап бардылар. Бөтен игътибарны аяк астына, юеш, пычрак җир өстенә юнәлтергә туры килде. Иленура әледән-әле кычкырып көлгән булды, нәрсәдер сөйләнгән булды. Закирҗан бабайларның капка төбендә өелешеп торган казлар янына килеп җиткәч исә куркып, «ай!» дип кычкырып җибәргән булды.

Чишмә тыкрыгында Габделхәй урамнан читкә борылды.

— Сау бул. Мин моннан китәм, — диде ул Иленурага.

— Ярар алайса, — диде Иленура. — Безне онытма. Их, рәтләп сүләшеп тә булмады!... Казанга китсәң, хат яз. Безне онытма, кара аны!

— Язармын, — диде Габделхәй.

Иленурадан аерылгач, ул иркен сулап куйды. Пычранмасын өчен иң элек чалбар балакларын күтәрде, кадерле ботинкасын салып кулына тотты. Юеш, тайгак җир өстеннән яланаяк барудан да җайлысы юк иде. Чишмә чокырын чыгып, сөзәк калкулык өстенә килеп менгәч, Габделхәй артына борылып карады. Кояш нурында кибенеп утырган, чыланып беткән бакчалардан, авыл өйләреннән, тупыллардан башка берни күренмәде.

Калкулык өстеннән беркадәр җир баргач, ул Яңавылга китә тор-

ган киң юлга барып чыкты. Яңавыл юлы үргә таба күтәрелде. Бәләкәй әрәмә янында олы юлдан уңга тар гына икенче юл тармакланып китте. Ике ягында да яшел бодай басуы җәелеп яткан тар юл турыга — Сакат ягына бара иде. Юл чатында Габделхәй туктап калды, икеләнгәндәй итте. Өйдән чыкканда «күпердән кит» дигән сүзләр исенә төште. Аның күпердән түгел, турыдан, кичүдән китәсе килде. Кичүдә, аннан да бигрәк, кичүгә якын болында аны кемдер көтеп тора сыман иде. Шул ук вакытта өйдәгеләрнең турыдан китмәскә киңәш итүләренә дә колак салмыйча булмый сыман иде. Әлерәк кенә кеше үтерелгән урман аша кайту, ни әйтсәң дә, бик үк күңелле булмаячак.

Кич булса, ул бернигә карамыйча күпердән киткән булыр иде, әлбәттә. Караңгыда иң куркынычы — мәет өрәге. Караңгы урман аша үткәндә кеше үтерүчеләр түгел, бәлки менә шул мәет өрәге аркылы төшәргә мөмкин сыман иде. Ләкин күк йөзендә балкып кояш көлеп торганда, яңгырдан соң бөтен дөнья шундый саф, якты һәм ягымлы булганда Габделхәй хәтта өрәкләрдән дә курыкмады — турыдан китәргә булды.



## Бишенче бүлек

### I

Райондагы барлык дәрәҗә кешеләре кебек, райбашкарма председателе иптәш Бикчурин да хезмәттә үзенә буйсынган кешеләр белән һәм шулай ук элекке таныш-белешләре белән шәхси мөнәсәбәткә керүне ярамаган нәрсә дип исәпли иде. Шуңа күрә ул үзенең кабул итү бүлмәсендә дә, урамда-нидә очрашканда да андый кешеләр белән үзен мөмкин кадәр коры һәм рәсми тотарга тырыша иде. Аны болай да районда коры һәм каты бәгырьле кеше дип беләләр. Чынлыкта исә ул бөтенләй андый кеше түгел иде. Районның баш кешесе, хуҗасы, бәләкәй генә патшасы иптәш Сафин кебек, ул да үзен, икенче дәрәҗәдәге булса да, баш кеше, хуҗа кеше итеп тотарга ярата иде.

Яңавыл районының барлык түрәләре сыман, ул да бу якта туып үскән кеше түгел иде. Аның каян килүен, элек кем булуын рәтләп белмиләр дә иде. Бары тик сайлау вакытларында игълан ителә торган кыскача биографияләрдә генә аның һәм аның кебекләрнең кайчан кайда туулары, кайда кем булып эшләүләре турында коры мәгълүмат бирелә һәм бары шул чагында гына серле башлыкларның әземәкүпме сере ачылып куела иде. Баксаң, аларның берсе, әйтик, Борай, Тәтешле ягында, икенчесе әллә кайда көньяк Башкортстанда яки хәтта Себердә туган булып чыга. Ләкин, кайда гына тумасыннар, аларның һәркайсы ярлы крестьян семьясында туган, бик тырышлык белән укыган, укыгач фермада, заводта, шахтада эшләгән; эшләгән чакта ук инде комсомол комитеты секретаре, партком секретаре була, аннан соң инде нindidер курсларда укый. Кайберләре армиядә хезмәт итәләр, сугышта катнашалар, батырлыклар күрсәтәләр, орден-медальләр белән бүләкләнәләр һәм, партия кая җибәрсә, шунда китәләр, иң җаваплы эшләрне башкаралар. Аларны тотып кына нинди һөнәр кешеләре икәнлеген дә әйтеп булмый. Игенче дисәң, игенче түгел, эшче дисәң, эшче түгел. Укымышлы, интеллигент дип тә булмый. Дөрес, аларның күбесе элекке мулла, мөгаллим затыннан. Ләкин алар инде күптән үз ата-бабаларыннан, үз авылларыннан, үз халкыннан баш тартканнар һәм, югарыдан-югарыга үрләү җиңелрәк булсын өчен, үз чыгышларын оста итеп яшереп бетергәннәр. Аннан соң сугыш елларында һәм сугыштан соңгы елларда, кеше-

нең чыгышына-тумышына егерменче-утызынчы еллардагы кебек артык игътибар да итми башладылар.

Райбашкарма председателе итеп куелганчы иптәш Бикчурин район финанс бүлеге мөдире булып эшләде. Финанс мәсьәләсендә ул, билгеле, әлепне таяк дип тә белмәде. Шулай да ул монда үзен бары яхшы яктан гына күрсәтте һәм озакламый аны райбашкарма председателе итеп күтәрделәр. Райфо бүлеге мөдире булып эшләгәндә аның үзенә буйсынган кешеләр арасында да, башка таныш-белешләре арасында да якын дуслары юк түгел иде. Ул чакта әле ул үзен иркенрәк, гадирәк тота һәм авылдан килгән агай-эне белән, инспектор, бухгалтер белән сөйләшкәндә: моңа ягымлы итеп карасам, үземә начарлык булмасмы, монысына кешечә җавап бирсәм, дәрәҗәм төшмәсме, дип кан калтырап утырмый иде.

Нәкъ менә шул чагында, ягъни иптәш Бикчурин райфо мөдире булып утырган чакта, алар Дәүләтгәрәй абзыйлар белән якынаеп калдылар да: бер-ике мәртәбә бер-берсенә кунакка бардылар, бер-ике мәртәбә уртак мәҗлестә булдылар, хәтта бер мәртәбә бергәләшеп Бүәдә балык та тоттылар. Ләкин иптәш Бикчурин югары үрләгәч, андый барышу-килешүләр, уртак мәҗлесләр һәм Бүәдә чыланып, пычранып җылым тартулар кабатланмый башлады. Бу үзеннән-үзе шулай килеп чыкты. Дәүләтгәрәй абзый беренче булып үзе бармады, иптәш Бикчурин шулай ук аларның бусагасын атлап керү дөрес булыр дип исәпләмәде. Хәзер алар иптәш Сафиннар белән генә йөрешә башлаганнар иде. Дөрес, алай-болай очрашканда Дәүләтгәрәй абзый белән дә бер-берсен күрмәмешкә салынып китмәделәр. Кешеләрчә хәл-әхвәл сораштылар, йорт-җирнең иминлеге, хатыннарның, бала-чагаларның исәнлеге белән кызыксындылар. Күңелләре нечкәреп китсә, «теге вакытта» Бүә буенда балык тотып, балык пешереп яткан чакларны искә төшерделәр. «Эх, тагын бер барып чыгасы иде!» — дигән сүзләр дә ычкындырдылар. Мондый сүзләрне күбрәк иптәш Бикчурин әйтте. Дәүләтгәрәй абзый — буйсынган кеше, түбән дәрәҗәдәге кеше буларак — тыйнаклык саклап эндәшми калуны артыграк санады.

Менә быел элекке дуслар тагын очраштылар. Ирләр түгел, хатын-кызлар очрашты.

Ул көнне Фәрхәнә апа белән Былбыл, кирәк нәрсә карангалап, базарда, базар тирәсендәге магазиннарда йөрделәр. Шулай, «Раймаг» дип аталган һәм бөтен Яңавылда иң бай саналган магазинның ярым буш шүрлекләренә күз атып торганда, кеше арасыннан көтмәгәндә Нәҗия килеп чыкты. Килеп чыкты да бу, бөтен магазин эчен шаулатып көлеп алды һәм урманда адашкан кеше сыман кычкырып:

— Туганкаем Фәрхәнә апа! — диде. — Исәнме-саумы? Хәлләр ничек? Исәнмесез! Теге бичырда рәтләп сүләшеп тә булмады, бер дә килмәй башладыгыз. Безнекенең вакыты юк — онытып бетердек берберебезне, туганкаем Фәрхәнә апа...

Нәҗия шулай бер-бер артлы тезде-тезде дә, исәнләшәм дип уйлап, күрәсең, Фәрхәнә апаның әле кулын кысты, әле беләгеннән тоткандай итте. Аннан соң, каршысындагы кешенең чыннан да Фәрхәнә апамы-түгелме икәнлегенә шикләнгән сыман, башын артка ташлап, күзләрен кысыштырып, сынап-сынап карагандай итте. Шул ук вакытта Былбылга да карап-карап алды һәм, бернинди әдәп сакламыйча, туп-туры сорап куйды:

— Бу кемнең шундаен да чибәр кызы соң әле? — диде.

Соравын шундый тупас итеп, йөзгә бәреп әйтүе кунак кызына бик үк ошап җитмәсә дә, сорау үзе күрәләтә мактау рәвешендә булганга, бу шалтыравык хатынга Былбыл берничек тә ачулана алмады — рәхәт бер уңайсызлык тоеп, кызарынып басып тик торды.

— Минем Уфадагы абыйның кызы, Зәйнулланың. Казанда

укый... унивирситта... Әйтә дә белмим шуны, — диде Фәрхәнә апа көлештереп.

— И, чибәрттәй! — диде Былбыл тагын да ныграк уңайсызланып.— Институтта гына диген инде, әйтәлмәгәч...

— Булмый, тел күнми шундый ят сүзләргә, — диде Фәрхәнә апа.

— Каяннар әйтеп бетермәк кирәк инде аларны, туганкаем Фәрхәнә апа! — диде Нәҗия сөенеп, Фәрхәнә апаны яклап. — Безнең тел каткан инде. Үз татарыңны белсәң, шул җиткән. Саескан да сандугач сайравына өйрәнмәкче булган икән дә, теле көтек булып калган. Кая инде безгә сандугач кебек сайраулар?! — Шулай, тын алырга да ирек бирмичә, тиз-тиз генә сөйләде дә, ашыгып: — Бездә дә Уфа кунагы бар лабаса, Фәрхәнә апакаем, — диде һәм үзенең шәп, елгыр кеше булуына куанып, башын артка ташлап көләргә тотынды.

— Теге чибәр җегетне әйтәсеңме? — диде Фәрхәнә апа, унынчы классларның чыгарылыш кичәсенә килгән яшь лейтенантны күз алдында тотып.

— Шул инде, шул, туганкаем Фәрхәнә апа, — диде Нәҗия һәм ялт кына артына борылды да, магазин залының икенче башында нидер карап торган хәрби кешегә эндәшеп: — Хәниф, кил әле монда! — дип кычкырды.

Хәниф, үз исемен ишетеп, Нәҗия апасы ягына борылды һәм ризасыз бер кыяфәттә, теләр-теләмәс кенә килә башлады. Бу вакытта Былбыл Фәрхәнә апа белән Нәҗиядән читтәрәк, пыяла витринага иелеп, төймә ише нәрсәләргә каранып тора иде. Ирексездән, ул хатыннарның үзара сөйләшкән сүзләренә колак салды һәм, «Хәниф» исеме чыккач та, сиздермичә генә аның ягына карап алды. Лейтенант Хәнифне ул бер күрүдән таныган сыман булды.

— Каяле, кил әле монда, үзеңнең авылдашың белән таныш, — диде Нәҗия яшь лейтенантның беләгеннән тотып алып.

Аның шулай чит кешеләр алдында, кызлар алдында малай сыман итеп кулыннан тотып алуына, үзе турында бөтен магазинга кычкырып «гайбәт сатуына» Хәнифнең, билгеле, ачуы килде. Фәрхәнә апа белән дә, Былбыл белән дә ул коры гына «исәнмесез» дип исәнләште дә тынып калды. Ләкин шат күңелле җиңгәсе аңа боегып торырга ирек бирмәде.

— Кара, кара! — диде ул аны җиңелчә генә шелтәләп. — Яхшылап күреш, таныш. Менә сиңа хәзерге яшьләр, туганкаем Фәрхәнә апа!

Хәнифнең йөзе үзгәреп китте, очлаебрак торган тәкәббер ияге муенына таба тартыла төште. Шулай да ул хатын-кыз алдында ямьсезләнүдән тыелып кала алды — көч-хәл белән үз-үзен елмаерга мәҗбүр итте һәм әдәп саклап башта Фәрхәнә апа белән, аннан соң Былбыл белән исәнләште, үзенең кемлеген әйтте.

— По-моему, без таныш, — диде ул Былбыл белән исәнләшкәндә. — Только вот исемнәребезне генә белмибез.

Фәрхәнә апа елмаеп куйды.

— Танышмыни? — диде.

— Таныш, — диде Хәниф.

— Шулай шул — таныш, — диде Былбыл да, лейтенантның сүзләрен дөресләп.

— Менә сиңа хәзерге яшьләр, туганкаем Фәрхәнә апа! — диде Нәҗия көлә-көлә.

## II

Былбыл белән Хәниф беренче мәртәбә Уфа автовокзалының билет кассасы янында очраштылар. Яңавылга баручы-кайтучы ха-

лык күп иде, автобус бер генә һәм буш урыннар бик аз иде, шуңа күрә касса алдында гадәттәгедән ныграк шау-шу һәм ыгы-зыгы иде. Билет сатыла башлау белән, күтеп торучылар барысы берьюлы касса авызына килеп тыгылдылар. Китте этеш-төртеш, китте кычкырыш!

Былбыл чиратка бик иртә баскан иде, аның урыны җиденче генә кеше иде, касса янында ныклы тәртип булганда, билет аңа җитәчәк тә җитәчәк иде. Ләкин, касса ачылу белән, чиратта торучылар янында күз алдында яңа чират барлыкка килде. Алар барысы да ирләр, көчлеләр һәм оятсызлар иде. Чираттагылар никадәр ныклык, усаллык күрсәтмәсен, аларның әле берсе, әле икенчесе акчалы кулын касса авызына китереп тыкты һәм кочактай билет алып китә торды.

Менә бер заман Былбыл алдында ике генә кеше калды — берсе яшьрәк ир кеше, икенчесе начар гына киенгән авыл хатыны иде. Ир кеше касса янына исән-имин барып җитте, кулын сузып билет алды да акылдан шашкан сыман бәхетле елмаеп җибәрде. Аның урынына шундук авыл хатыны басмакчы булды. Шул чакны каяндыр икенче бер ир кеше барлыкка килде. Өстенә шакмаклы пинжәк кигән, киң аркалы, үгездәй таза җилкәле ир кеше, өтәләнгән авыл хатынын җиңел генә читкә этәреп, калкандай гәүдәсе белән касса авызына капланды. Хатын чәрелдәп җибәрде, ярсып бар көченә үзенең законлы урынын яулап алмакчы була башлады. Шакмаклы пинжәк аның чәрелдәвен чебен безелдәве урынына да күрмәде — тыныч кына билет алды да оятсыз һәм мәсхәрәле көлемсерәп читкә китеп барды. Аның урыны бушау белән касса алдындагы «дзот»ны күкрәге белән алтын погонлы яшь лейтенант каплады.

Сугыштан соңгы еллар булганга, чираттагы кара халык арасында хәрбиләр булуы бер дә гаҗәп түгел иде. Хәрбиләрнең теләсә нинди погонлысын теләсә кайчан һәм теләсә кайда очратырга була иде. Хәрбиләр сугышта җиңүче булсалар да, кара халык чынлыкта аларны беркайчан яратмады. Яхшы киемле, тук, таза кыяфәтле булган өчен, халык сакчысы, халык якчысы булуына да карамастан, үзен халыктан өстен куеп, халыктан аерымланып яшәве өчен ятратмады. Өлкәнрәк яшьтәге, түбәнрәк дәрәҗәдәге хәрби кеше булса, халыкның әле, бәлки, ачуы да килмәс иде. Ни әйтсәң дә, солдат авыл агаена, авыл апасына аңлаешлырак та, якынрак та. Сугышта да булгандыр, кан да койгандыр, хәзер бәлки демобилизациягә эләгеп, армиядән котылып, туган ягына кайтып барадыр. Андыйларга күңелләр дә ачык, кассаларга юл да ачык. Монда исә әллә нинди ялт итеп торган погонлы япь-яшь кенә лейтенантның әрсезләнеп чират алдына килеп керүе болай да аягында көчкә басып торган халыкны ярсытып җибәрде. Чираттагы хатыннар, ирләр тагын да яманрак шауларга, кычкырырга тотындылар. Былбыл алдындагы авыл хатыны әле татарчалап, әле урысчалап лейтенантны оялтмакчы булды, алай да тәэсир итмәгәч, беләгеннән тарткалап чыгармакчы булды.

Ачудан авыл хатыны гына түгел, Былбыл да шартлар дәрәҗәгә җитте. Ничә сәгать аяк өсте басып торуы, иңбашларының, аякларының сызлавы, баш авыртуы — барлык газаплары өчен аңа бары шушы чибәр, тыныч һәм оятсыз лейтенант кына гаепле сыман тоелды.

— Ничек оялмыйсыз? Сез бит лейтенант! Халыкка яхшы үрнәк күрсәтү урынында! ...—дип кычкырды ул үз-үзен белешмәстән.

Ул хәтта авыл хатыны кебек кулын сузып аның кителеннән дә эләктереп алмакчы булды, ләкин яшь лейтенант та алай үзенә кагылдыра торган, үзен кыерсыттыра торганнардан түгел иде бугай. Ялт кына артына борылды да, теш арасыннан гына сыгып:

— Чәрелдәмәгез, зинһар! — диде һәм кассага акча сузды.

— Кертмәгез, кертмә!

— Өстерәп чыгарыгыз! — дип кычкырдылар арттан.

— Минем — бронь! Минем хакым бар. — диде лейтенант, аңлатырга кирәк табып.

— Безнең дә хакыбыз бар! Безгә дә кайтырга кирәк! — диделәр чираттагылар.

Төрле яктан кысылган, тирләгән-пешкән һәм бер-берсен чәйнәп ташлар дәрәҗәдә ярсыган хәлдә, бер-берсенә тыелгысыз ачу-нәфрәт тойган хәлдә, беренче мәртәбә алар шунда очраштылар.

Ул көнне лейтенантның да хәле шәптән түгел иде, әдәп саклап, хәтер саклап тора торган чак түгел иде. Шуңа күрә ул үзенә кычкырган, үзен йолкып ташламакчы булган халыкка ярыйсы ук усал һәм тупас сүзләр дә әйтте. Шул исәптән, әлбәттә, яшь, чибәр кызга да эләкте.

Тавыш артык зурга киткәч, каяндыр милиция сержанты килеп чыкты, сыбызгысын сызгыртып, касса янында әзме-күпме тәртип урнаштырды. Бу вакытта инде яшь лейтенант билет алып китеп барган иде. Лейтенанттан соң өтәләнгән авыл хатыны да билет алды. Чират Былбылга җитте. Былбыл акчасын сузарга өлгермәде, тар бүлмәдә, төннек сыман кечкенә тәрәзә артында бәхет өләшеп утырган кассир хатын, тәрәзә капкачын ябарга үрелде һәм:

— Билет бетте, — диде.

Нәкъ кинодагыча, нәкъ театрдагыча булды. Шулкадәр зарыгып, өметләнеп көт тә, борын төбендә генә касса ябылып куйсын әле! Утыр да җыла. Йә булмаса очраган бар нәрсәне кырырга-җимерергә тотын. Дөньяның астын өскә китер. Хәер, Былбылга инде болай да дөньяның асты өскә килгән сыман тоелды. Болай да аның җылыйсы килде һәм үзенә тиешле билетны тартып алган лейтенантны өзгәләп-йолыккалап ташлыйсы килде.

Бөтенесенә кул селтәп, ул өйләренә кайтып китте. Бераздан тынычлана төште, халык алдында үзенең кызып китүе, ярсып китүе өчен үкенү сыман бер нәрсә кичерде. Тик шулай да яшь лейтенантның салкын, мыскыллы күз карашы, тупас сүзләре, тәнгә кадалган шырпы булып, бик озак аның күңелен әрнетеп-ачыттырып торды.

## III

Көтмәгәндә таныш кешесен күреп, ул аптырап калды. Уфадагы, автовокзалдагы барлык хис-тойгысы ташкын булып әз генә вакытка яңадан калкып чыкты, кире кайтты һәм тагын шундый бер-бер хәл була-нитә калса, тагын шундый күз карашы, шундый ук сүзләр, шундый ук тавыш була калса, бар көченә ыргылырга әзер булып, күкрәк читлегендә тулып-чайпалып торды.

— Танышмы?! — дигән булды Нәҗия мут елмаеп, бармак янаган булып. — Бер авылдан булгач, барысын да белеп тә бетерә алмассың, туганкаем.

«Бер авылдан» сүзен ул аеруча ясатып әйтте һәм үз-үзеннән канәгать булып, көлеп куйды. Җиңгәсенең танышлыкка үзенчә мәгънә бирүе Хәнифкә, күрәсең, бик үк ошап җитмәде. Шуңа күрә ул үзенең Былбыл белән кайда ничек танышуын кыска гына аңлатып бирергә кирәк тапты. Ләкин аңлатканда үзенең тупаслыгын да, хәтер калдыргыч сүзләр ычкындыруын да әйтми калдырды. Аның сөйләвенә караганда, ул көнне чиратсыз билет алуы да, чираттагы халыкның кычкыруы, шаулавы да — барысы да бер шуклык, шаянлык кына булып тоелды. Җиңгәсе, аның сүзен бүлдереп, кычкырып көлеп алды, Фәрхәнә апа исә, бер якка да кушылмыйча, килешүчән бер төс белән көлемсерәп торды.

Былбыл көлмәде дә, елмаймады да. Ул Хәнифнең бер генә яклы итеп сөйләвен күреп-ишетеп торды, күңеленнән моңа нәфрәтләнмичә

булдыра алмады. Аның сөйләүчене бүлдерәсе, хатыннар алдында аның йөзен ертып: «Юк, алай түгел ул!» — дип әйтәсе килде. Ләкин шул ук вакытта ул аның ялганлавына һәм ул чактагы тупаслыкны искә алмавына, ямьсез, күңелсез урыннарны читләтеп үтүенә хәтта сөенгәндәй булды. Хәниф аңа тегендәге, теге вакыттагы кебек чит, дошман да түгел иде. Ул инде аңа ничектер якынрак сыман да иде — тегендә очрашкан, бозылышкан өченме, менә монда көтмәгәндә яңадан очрашкан өченме — бик күптәнге танышы кебек якын һәм аңлаешлы иде.

Шулай итеп, ачу-нәфрәт сизмәгәндә юкка чыкты. Бераздан Былбыл үз-үзеннән ояла башлагандай булды. Теге чакта ямьсез итеп кычкыруы, тупасланып аны чираттан кысырыклап чыгарырга тырышуы, гомумән, андагы тотнаксызлыгы өчен ояла башлагандай булды. Бер кызарып, бер агарып, ул төркемнән читтәрәк басып торды. Яшь, чибәр һәм ягымлы лейтенантка күтәрелеп карарга да курыкты. Аның алдында үзен хәзер бала-чага итеп, бернинди ихтыяры булмаган, бер нәрсәгә хакы-хокукы булмаган тәҗрибәсез бер кызчык итеп тойды.

Үзара сөйләнгәләп алар урамга чыктылар. Урам уртасында Нәҗия туктап калды.

— Карале, туганкаем Фәрханә апа, — диде. — Бөтенләй читләшеп беттек бит әле бу арада. Сез килмәйсез, без бармайбыз. Нишләп ташлаштык соң әле? Килегез әле Дәүләтгәрәй абзый белән парлашып.

— Бер дә җитешеп булмый бит, Нәҗия,— дигән булды Фәрханә апа, «ташлашу»ның сәбәпләрен бик яхшы белсә дә.

— Дөнья мәшәкатенең беткәне юк аның, туганкаем, — диде Нәҗия.

Фәрханә апаны ул култыклап ук алды һәм кызулабрак китеп барды. Яшьләр арттарак калдылар.

— Карале, туганкаем Фәрханә апа, — диде Нәҗия ярым пышылдауга күчеп. — Синең белән тел яшереп торасы юк. Туп-туры әйтсәм, үпкәләмәссең. Әйдәле сездә бер шаулатып аш-су ясап ташлайбыз? Өегез иркен, кеше күзеннән җырак. Исмәгыйльне әйтәм, сүрәп булса да алып барам мин аны сезгә. Болай да инде аның аркасында дуслар белән бозылышып беттем.

Бик сәер тәкъдим иде бу, иптәш Бикчурин хатыны Нәҗия генә әйтә алырдай кыю һәм әдәпсез тәкъдим иде. Фәрханә апа эндәшмәде. Эндәшсә дә, күрәсең, каршы әйтергә батырлыгы җитмәс иде. Аннан соң, аның алай каршы да киләсе килмәде. Ул хәтта күңеленнән сөенеп тә куйды. Нәҗия андый-мондый кешенең хатыны түгел ич. Аннан соң, алар бит элекке дуслар да!

— Кирәк нәрсәсеннән тормам — барысын да үзем җайлармын, Фәрханә апакаем. Әзерләшергә дә үзем килермен, — диде Нәҗия, Фәрханә апаның икеләнгәндәй итүен күреп.

— Әйдә инде! Сөйләмә юкны! — диде Фәрханә апа. — Кунак чакыру, аш-су ясау дигәндә безнең Дәүләтгәрәй үлә дә китә инде. Аңа шул балык булсын да, аш-су, мәҗлес булсын.

— Аларга шул балык та аракы инде, туганкаем! — диде Нәҗия.

— Килештек алайса, — диде Фәрханә апа ачылып, билгеле бер фикергә килеп. — Кайчанга? Шушы ялга ничек булыр? Кунагыгызны да калдырмагыз.

— Туганкаем Фәрханә апа! — диде Нәҗия балкып. — Тел яшереп торасы юк, турысын гына әйткәндә, шул кунакның күңелен табарга тырышам да инде мин. Исмәгыйльнең вакыты юк. Үзенә генә күңелсез. Карале, туганкаем Фәрханә апа, синең бу Сандугачың, чыннан да, былбыл кебек икән бит! Безнең кунакка менә дигән пар буласы икән.

Чигенергә кирәк булса, сүзне уенга әйләндерергә җай калдырып, җылгыр хатын көлеп куйган булды. Фәрханә апа тагын эндәшми калды. Ул инде болай да сизенгән иде. Аның һич тә Былбыл эшенә, Былбыл язмышына кысыласы килмәде. Аныңча, өлкәннәр, гомумән, яшьләр эшенә кысылырга тиеш түгелләр иде. Элекке заманнарда картлар әнә яшьләр эшенә кысылып, күпме бәхетле язмышны газапка әйләндергәннәр. Картларның үзсүзлелеге, кирелеге, аңсызлыгы аркасында күпме фаҗига булган элекке тормышта. Бүген андый фаҗигалар булмаска тиеш. Бүген һәртөрле димләүләр, ярәшүләр искелек калдыгы булып исәпләнелә. Башкалар өчен искелек калдыгы булган нәрсә Былбыл өчен дә, әлбәттә, шулай исәпләнергә тиеш иде. Инде чынлап та яратышып китәләр икән, анысы шулай ук яшьләрнең үз эше.

Бу мәсьәләдә Фәрханә апа шулайрак фикер йөртте.

— Җиңгәйгә охшаган. Безнең җиңгәй бик матур. Заманында илдә бер чибәр булган, — диде ул, Былбылның әнисен мактап.

— Хәнифне әйтәм, туганкаем Фәрханә апа, — диде Нәҗия. — Бер дә рәтле кыз табалмый. Читтә берәр марҗа башын-күзен әйләндереп куймаса ярарые, дип куркам. Әллә нинди белмәгән-күрмәгән кеше белән туганлашасы да килмәй. Без ичмасам, бертуган кебек. Озакламый хезмәтен тутыра. Үзебезгә кайтырмы, Уфагамы, Казангамы — әлегә белгән юк. Әллә, мин әйтәм, чәчләрен чәчкә бәйлибезме шул дошманнарның?! Валлаһи дип әйтәм, чукындырып салабыз без аларны, туганкаем Фәрханә апа!

— Чукындырырга дигәндә, бездән сорап тормаслар — бик теләп чукындырырлар, — диде Фәрханә апа. — Ошашсалар, килешсәләр... үзләре эше... Сөйләштек алайса, шушы ял алдыннан, кичке якта... рәхим итегез өчәүләп.

## IV

Былбыл белән Хәниф, Фәрханә апа белән Нәҗиядән калышып, әкрен генә арттан бардылар. Аларга хәзер бернинди димче дә, арадашчы да кирәкми иде. Алар болай да бергә, болай да таныш иде. Шулай булса да, бер-берсенә карата бернинди якынлык хисе тоймадылар. Киресенчә, аларның хәзер бер-берсеннән аерылып китәселәре, бер-берсеннән котыласылары килде. Беренче очрашу, шул чакта әйтелгән сүзләр, кыланышлар, шул чактагы хис-тойгылар тәэсире шундый көчле, шундый ямьсез һәм күңел кайтаргыч иде, — шул турыда яхшы белә торып, әле булса шуларны тиешенчә онытмый торып, менә хәзер кисәк кенә икенче җайга, икенче көйгә күчү, дуслашу, якынаю, гомумән, мөмкин нәрсә түгел сыман иде.

Сүзсезлектән интеккән Хәниф бара торгач чалбар кесәсеннән көмешсыман портсигар чыгарды, аны учында килешле генә тотып, икенче кулы белән «Казбек» папиросы алды, шартлатып портсигарын япты да, икенче кесәсеннән зажигалка чыгарды, ут кабызды һәм хуш исле төтен өреп, кабаланып тарта башлады. Төтенне ул читкә җибәрергә тырышты, ләкин үч иткәндәй төтен Былбыл ягына тартылды.

— Гафу итегез, — диде ул төтенне куалап.

— Тартыгыз әйдә... тартасыгыз килгәч, — диде Былбыл.

Хәниф йотлыгып бер-ике суырды да, утлы папиросын бармак очында әвәләп, читкә ташлады.

— Сезнең Яңавылда булганыгыз бармы? — диде ул сүз башлап.

— Бар, — диде Былбыл һәм, тәмәке төтененнән, ахрысы, тамагы карлыгып, сүзсез калды.

— Минем әле беренче булуым, — диде Хәниф.

— Ошыймы соң... безнең Яңавыл? — диде Былбыл.
— Ничек дип әйтергә... авыл инде, кара авыл, — диде Хәниф.
— Миңа ошый, — диде Былбыл.
— О, сез авыл патриоты икән! — диде Хәниф.
Аның тавышында җиңелчә көлемсерәү сизелде. Былбылның бу шундук кытыгына тиде. Аның аңа шундый ук мыскыллы көлемсерәү белән җавап бирәсе килде.
— Ие шул, авыл патриоты, — диде ул, көчәнүле бер горурлык белән. — Патриот булу сезгә ошамыймыни?
— Юк, што сез! — диде Хәниф, юл куючан бер өстенлек белән.
— Юк, сез яратмыйсыз Яңавылны! — диде Былбыл кирәгеннән артык кайнарланып.
— Мин авылда тумаган, шуңадыр, күрәсең, — диде Хәниф. — Сез... чыннан да Уфаныкымы?
— Мин Яңавылныкы, — диде Былбыл үчекләшкән сыман һәм үз ялганыннан үзе көлеп куйды.
— Ник көләсез? — диде Хәниф.
— Болай гына, — диде Былбыл. — Бер нәрсә искә төште. Сез, нәрсә, чибәрттәй әйткәнгә ышандыгызмыни?
— Нәрсә соң ул «чибәрттәй»? — диде Хәниф.
— Минем апа. Әнә теге бездән алдарак бара торган «Фәрхәнә апа», — диде Былбыл. — Мин аны чибәрттәй димен. Бала чактан ук өйрәткәннәр. Монда... бездә апаларны төрлечә атыйлар: чибәрттәй, чибәр җиңгәй, чибәр әби, чибәр бабай...
— «Бабай» да апамыни? — диде Хәниф.
— Анысы ялгыш әйтелде, — диде Былбыл көлеп һәм дәвам итте: — Актүтәй, актәй, мулләттәй...
— Телеңне сындырырсың, — диде Хәниф.
— Миңа ошый, — диде Былбыл. — Ник, ямьсезмени: баләби, балбабай, шикәрәби, шикәрбабай, картый, картәтәй, яшәби, яшьбабай, нәнәй, дүрнәй, җырак әби, җырак бабай... Нинди матур барысы да! Саф үзебезчә, татарча.
— Дүрнәй нәрсә? Дурной дигән кебек, — диде Хәниф.
— Дүрнәй ул — «зур инәй» дигән сүз!
— Дүрнәй — дурной, дурной — дүрнәй, — диде Хәниф кабатлап, яратмыйча.
— Сез бик тупас! — диде Былбыл үртәлә башлап.
— Извините... гафу итегез, — диде Хәниф. — Мин сезне оскорбить итәргә уйламадым. Просто так.
Бераз вакыт тагын сүзсез бардылар. Сүзне бу юлы да Хәниф башлады. Аның Былбыл белән сөйләшәсе һәм ничек тә үзе турындагы начар фикерне үзгәртәсе килә иде бугай.
— Нәрсә әйтте соң сезнең чибәрттәгез — нишләптер минем истә калмаган, — диде ул йомшаграк булырга тырышып.
— Кеше сүзен бик тиз онытасыз икән, — диде Былбыл.
— Кызлар хәтере кебек минем хәтер, — дигән булды Хәниф.
— Кызлар хәтере сезнеке кебек булса!..— диде Былбыл.
— Шулай диләр ич, — диде Хәниф. — Мин сезне Яңавылга кайтып баручы берәр укучыдыр дип уйладым.
— Дөрес уйлагансыз, — диде Былбыл. — Чибәрттәй дә шулай диде ич.
— «Чибәрттәй» кем була соң сезгә? Үзегез әйтәсез: Яңавылныкы дисез, үзегез нишләптер аның белән йөрисез, — диде Хәниф.
— Аның белән йөрергә ярамыймыни? — диде Былбыл.
— Сез кеше сүзен юри кирегә борасыз икән, — диде Хәниф.
— Нишләп кирегә бору булсын?! — диде Былбыл. — Ул минем апам — әтинең бертуган сеңлесе. Без үзебез Яңавылдан ун чакрымда Каймаша дигән авылда торабыз. Әти минем колхоз председателе.

Хәзер мин Яңавылда кунакта. Аңлашылмыймыни?

Ул боларны шаяртмыйча, җитди итеп, үзеннән яшьрәк, аңсызрак малай-шалай белән сөйләшкәндәге сыман итеп әйтте. Соңгы сүзен әйткәндә хәтта Хәнифнеке кебек көлемсерәү, өйрәтү, мыскыл тоны сизелеп китте. Яшь, чибәр лейтенант кызның шаяртуын аңлый алмады. Ул бары үзен түбәнсетүләрен генә сизенде. Бу аның мин-минлегенә тиде, күңелен кырды. Ул яңадан чалбар кесәсенә тыгылды, портсигар чыгарды, калтыранган бармаклары белән папирос кабызырга азаплана башлады.

— Аңлатуыгыз өчен рәхмәт. Мерси, — диде ул папиросына ут кабызгач, күрәләтә салкынлык белән.

— Ауфвидерзайн! — диде Былбыл.

## V

Шушы сөйләшүдән соң ике көн үткәч, алар тагын очраштылар. Монысы инде кунакта, Фәрхәнә апаларда булды.

Үзенең элекке хезмәттәшен, хөрмәтле иптәш Бикчуринны ашка алуга Дәүләтгәрәй абзый бик теләп, хәтта сөенеп риза булды. Алар шундук әзерлек чарасына керештеләр. Иң элек: ризабыз, килешенгән көнгә, килешенгән вакытта өчәүләшеп килегез, дип Нәҗиягә хәбәр бирделәр. Ялга каршы базарга чыгып, Дәүләтгәрәй абзый ярты сарык алып керде. Шул ук көнне иртәннән башлап олы мичкә ягылды. Фәрхәнә апа белән Былбыл көне буена диярлек мич тирәсендә, казан тирәсендә булаштылар. Төштән соң зур-зур сумкалар күтәреп Нәҗия килеп җитте. Үзе белән күп кенә бал-май һәм ят азыклар алып килде. Бер килгәч-килгәч дип, озак кына Фәрхәнә апага булышты.

Бер-ике сәгатьтән ул кайтып китте һәм көн кичкә авышканда, билгеләнгән вакытка яңадан килде. Монысында алар өчәүләп килделәр. Аларны тәрәзәдән карап, көтеп кенә торалар иде. Кадерле кунаклар күренү белән, каршы алырга дип иң элек Дәүләтгәрәй абзый чыкты, аның артыннан Фәрхәнә апа чыкты. Кунаклар кешечә җәяүләп кенә килгәннәр иде.

— Капкагыз ачыкмы — без киләбез! — дип кычкырды ерактан ук шат күңелле Нәҗия.

— Әйдәгез, әйдә, рәхим итегез! — диделәр Дәүләтгәрәй абзый белән Фәрхәнә апа бер-берсен бүлдереп.

Капкадан кергәч тә иптәш Бикчурин элекке хезмәттәшенә беренче булып кул бирде, елмайгандай итте, шулай да артык ачылып китмәде. Нәҗия исә шатлыгыннан Фәрхәнә апаны кочаклаплар алды. Бары Хәниф кенә үзен мәҗбүр ителгән кеше сыманрак хис итте һәм, үзара куанышкан кешеләргә якын килмичә, бер читтәрәк таптанып торды.

Җиңгәсе аны, чыннан да, мәҗбүр итеп алып килде. Аның шулай ни өчен «чибәрттәй»ләргә кунакка алып баруын Хәниф аңламады түгел, аңлады. Аның анда барасы да килде, шул ук вакытта аягы да тартмады. Өченче көн урамда саубуллашыр алдыннан булган сөйләшүдән соң ул үзен җиңелгәнгә, түбәнсетелгәнгә санады. Шуңа күрә, аныңча, ике арада әле сөйләшәсе сүз дә бетмәгән иде, тагын нидер ачыклыйсы да, нәрсәнедер хәл итәсе дә бар иде кебек тоелды. Ләкин кызлар янына абый-җиңгәй белән бергәләп бару, аларга ияреп, тагылып йөрү чамадан тыш ахмаклык булачак иде. Моңарчы ул кызлар янына беркайчан ярдәмчеләр белән йөрмәде һәм хәзер дә андый кешеләрнең кирәге юк иде сыман. Ул кискен рәвештә баш тартты. Тик Нәҗия җиңгәй аңа караганда үзсүзлерәк булып чыкты. Аннан соң, ни әйтсәң дә, ул бит кунак кеше монда! Кунак — хуҗа-

ның ишәге. Кая алып барсалар, шунда бар, нәрсә эшләргә кушсалар, шуны эшлә.

Ни булса булды, ул килде. Килүен килде, ләкин хезмәттә аякны ничек атларга, кулны, гәүдәне, башны кайчан ничек тотарга җитәрлек дәрәҗәдә белем алган лейтенант иптәш Фәрхәнә апалар ишегалдына килеп кергәч, нишләргә дә белмичә, каушады да калды. Аның күңеленә иң әүвәл: «Минем болай әрсезләнеп йөрүемә Былбыл ни әйтер?» — дигән бер уй килде. Ул икеләнде, ул уңайсызланды. Ихтимал, бу аның үз гомерендә беренче мәртәбә чын-чынлап уңайсызлануы булгандыр.

Аны күргән Былбыл, чыннан да, ни әйтергә дә белмәде. Шатланса, ачык йөз күрсәтсә, әдәпсезлек булыр сыман, ачуланса, караңгы йөз күрсәтсә, шулай ук әдәпсезлек булыр сыман тоелды. Егет чибәр иде, матур буй-сынлы иде, өстендәге хәрби киеме, түшендәге гвардия билгесе нур сибеп, әллә кайдан күзнең явын алып тора иде. Ул горур, тәкәббер иде һәм аның менә шул тышкы ягы — горурлыгы, тәкәбберлеге, кием-салымы, ялтыр-йолтыр нәрсәләре элекке барлык тупаслыкларын, ипсезлекләрен күмеп, томалап калдыра иде.

Кунаклар өйгә керделәр, яңа өйгә шаулатып сәлам бирделәр, туп-туры олы якка уздылар һәм мондый чакта булганча, анысынмонысын сөйләнгәләп, урыннарга утырыштылар, яңа өйне, өй җиһазын, тырыш, булдыклы хуҗаларны мактадылар.

Кунакларга өстәл тирәсенә якынаерга куштылар. Һәркем үзенә билгеләнгән урынга утырды. Өстәл уртасына зур мис белән кайнар аш китереп куйдылар. Тәлинкәләргә аш бүленде. Дәүләтгәрәй абзый рюмкаларга аракы салды һәм җиңел генә, шау-шусыз гына аш мәҗлесе башланып китте.

Былбылның урыны Хәнифкә каршы якка туры килде. Былбыл һич тә тыныч кына, басылып кына утыра алмады — берәр йомыш тапкан булып әледән-әле кече якка чыгып китте, андагы тәрәзә төбендәге көзге каршысына килеп, уттай янган битенә карады, чәчен төзәткәләде, изүен төзәткәләде. Тынычлангандай итте дә яңадан олы якка ашыкты.

Ул ничек тә лейтенант ягына карамаска тырышты, ләкин ихтыярсыздан күз карашы шул якка борылды. Мондый йомшаклыгы, җебегәнлеге өчен аның үз-үзенә, кунакларга ачуы килде. Аңа әллә нәрсә булды. Габделхәй янында да аңа «әллә нәрсә» булган иде. Ләкин аның янында ул үзен иркенрәк тоткан иде, үз-үзен шат һәм бәхетле итеп тойган иде.

## IV

Аш мәҗлесе тиз генә җанланып китә алмады. Барысы да болай мәҗбүри җыелышып, ашап-эчеп утыруның урынсызлыгын, вакытсызлыгын бик яхшы аңладылар. Шуңа күрә өстәл янындагы Хәниф белән Былбыл гына түгел, башкалар да үзләрен шактый кыен хәлдә сизделәр. Хуҗа кешенең иң олы кунактан түбәнрәк дәрәҗәдә булуы да нәрсәнедер тоткарлап торадыр сыман тоелды. Болай да начальниклар алдында буйсынучан Дәүләтгәрәй абзый хәтта үз өендә дә иптәш Бикчурин белән үзен тигез саный алмады һәм, кадерле кунакның хәтерен калдырудан куркып, ничектер тыелып-кысылып утырырга мәҗбүр булды.

Икенче рюмкадан соң иптәш Бикчуринның йөзе, ниһаять, ачылып китте. Шул чакны, өстәл янында, әйтерсең, балкып кояш чыкты. Кояш чыгу белән һәркемгә рәхәт, җиңел һәм күңелле булып китте. Нажия, чыккан кояшны болыт каплый күрмәсен дигәндәй, бөтен өйгә

шаулатып көлеп алды, көлә-көлә иренең аркасыннан сөеп куйган булды. Бәхеткә, өстәл янындагы кояшның сүнәргә исәбе юк булып чыкты. Райбашкарма башлыгы җанланганнан-җанлана барды, ике сүзнең берендә «Хәтерендәме, Дәүләтгәрәй?» дигәндәй сүзләр кыстырып, райфода бергәләп эшләгән чакларны, андагы кешеләрне һәм кайбер кызык хәлләрне исенә төшерде. Дәүләтгәрәй абзый исә: «Хәтердә, хәтердә! Нишләп хәтердә булмасын!» — диештереп, очлы, такыр башын сыйпаштырып, кадерле кунакны ашарга-эчәргә кыстады. Үзе дә иплән кенә берәр кызык хәл сөйләп алды. Аларга хатыннар кушылды, көлделәр, гөрләделәр һәм аш мәҗлесе мәҗлес төсенә керә барды.

Хәниф Йосыф янында утырды. Ашаган-эчкән арада ул аның укуы белән, киләчәктә нишләргә, кем булырга ниятләве белән кызыксынды. Йосыф кыска-кыска гына җаваплар бирде. Алар арасында әллә ни сүз ялганып китә алмады. Йосыф тамагы туйганчы ашады да, беркемгә дә бер сүз әйтмичә, өстәл яныннан торып ук китте.

— Кая барасың? — диде Фәрхәнә апа аның каядыр җыенуын күреп.

— Рамусларга, — диде Йосыф.

Бер-ике рюмкадан Хәнифнең дә күңеле күтәрелеп китте. Йосыфның кирле-мырлы торуына аның әллә ни исе китмәде. Йосыф каядыр чыгып киткәч ул, җаен туры китереп, шундук кыз янына күчеп утырды. Бөтенесе алдында, бигрәк тә җизнәсе белән чибәрттәсе алдында аның шулай кыюлануы Былбылга әдәпсезлек булып тоелды.

— Извините, сез миңа ачуланмыйсызмы? — диде Хәниф.

— Юк, нишләп мин сезгә ачуланырга тиеш? — диде Былбыл.

— Болай гына!— диде Хәниф.

Ул арада өлкәннәр урыннарыннан кузгала башладылар.

— Ял итеп, җырлап-биеп алыгыз,— диде Фәрхәнә апа кунакларга.

— Дәүләтгәрәй абзый, туганкаем, әйдәле эскерипкәңне уйнап җибәр әле бер!— диде Наҗия.

— Дөрес сүз бу, Дәүләтгәрәй,— диде иптәш Бикчурин да, хатыны тәкъдимен яклап.

— И, җизнәй, уйнале, уйна!— диде Былбыл да.

— Болай төрле яктан сорагач, уйнамый булмас,— диде Дәүләтгәрәй абзый тыйнак кына риза булып.

Аның мондый күндәмлеген Наҗия үзенчә аңлаткан булды.

— Яшьләр сорагач, шундук риза булды, туганкаем!— диде ихахайлап.

— Уйнар, кем сораса да, уйнар,— диде Фәрхәнә апа.

— Былбылны җырлатабыз!— диде Наҗия, кирәгеннән артык кыюланып.

Шулай сөйләнгәләп, ул яшьләргә якынрак килде, симез кулы белән өстәл читенә таянып, Былбылның үзенә генә әйтергә тиешле нииндидер сүзе бар сыман, колагына иелде һәм:

— Нинди җыр җырлыйсы килә, сеңлем?— диде.

Былбылның йөзенә ялкын үрләде, йөрәге дөпелдәп тибәргә тотынды. «Якын килмә!» дигән сыман кулларын югары күтәрде, кузгалгандай итеп куйды, ләкин торып китә алмыйча кире урынына утырды.

— Юк, юк!— диде ул, башын чайкап.

— Җырлыйбызмы, гөрләйбезме?— дип кычкырды Наҗия бөтен өй эченә.

— Каягыз әле... чыгарыгыз әле мине,— диде Былбыл, өстәл арасыннан чыгып китә алмыйча.

— Бетте, бетте, былбылым-күгәрченем!— диде Нажия кире чигенеп.— Жырламыйбыз, туганкаем. Гөрләшегез, гөрләш!

— Нажия,— диде шул чакны иптәш Бикчурин кырыс кына.— Кил әле монда!

— Әнә Исмәгыйль абый чакыра,— диде Хәниф җиңгәсенең симез беләгенә кагылып.

— Бетте, бетте, туганкайларым!— диде Нажия һәм җиңел-җиңел атлап, бармакларын шартлатып, идәннең ачык җиреннән йөзеп-биеп китеп барды. Ачык тәрәзә янында тәмәке пыскытып торган ире янына килде дә кыланчыкланып аны ике куллап кочып алды, үбеп алды.

— Ни булды, кем тия, картым?— диде.

— Сагындым. Утыр шунда гына,— диде Исмәгыйль абзый урындыкка күрсәтеп.

Нажия китеп бару белән Былбыл, читлектән котылган кош кебек, кабаланып кече якка чыгып китте. Күңеле кырылган лейтенант, өстәл янында беркем юклыктан файдаланып, яртылаш кына эчелгән рюмкасын тутырды да, ялт итеп эчеп куйды һәм шулай ук торып читкә китеп барды.

Шул чакны Дәүләтгәрәй абзый, скрипкасын көйләп, «Әпипә»не чыңлатып җибәрде.

## VII

Кече якта Фәрхәнә апа белән Былбыл шалтыр-шолтыр табак-савыт юдылар, нидер күчерделәр, нидер әзерләделәр. Көтмәгәндә алар янына Хәниф килеп керде.

— Берәр төрле булышчылар кирәкмиме сезгә?— дигән булды ул шаяртып.

— Булышчылар кирәк инде ул, Хәниф?— диде Фәрхәнә апа елмаеп.

Ашыгыч эше бар сыман ул тиз генә чыгып китте.

— Извините, сез әле дә миңа ачуланасызмы?— диде Хәниф үзенә яны беләнрәк торган Былбылга.

— Мин сезгә әйттем: мин сезгә ачуланмыйм,— диде Былбыл коры гына.

— Мин сезне шундый усалдыр дип уйламаган идем,— диде Хәниф.

— Сезгә ни кирәк монда?!— диде Былбыл, билен турайтып, дорфа гына.

— О-о!— диде Хәниф күзләрен зур ачып.

Бер-берсен беренче мәртәбә күргәндәге кебек, тегендәге, автовокзалдагы кебек алар бер-берсенә сынап, ярсып, дошманнарча карашып тордылар. «Менә нинди икән бу?!»— диде Хәнифнең гаҗәпләнгән күз карашы. «Урыныңнан гына кузгал — хәзер ботарлап ташлыйм!»— диде болай да тынычсыз һәм ярсыган кызның гүзәлдәһшәтле кыяфәте.

— Җиңгәңнең мыскыл иткәне җитмәгән... тагын сез мыскыл итмәкче буласызмы?!— диде Былбыл өзек-өзек тавыш белән, авызыннан утлар чәчеп.

— Извините, җиңгәй өчен мин гаепле түгел,— диде Хәниф.

— Кем соң?!— диде Былбыл үз-үзен белештермичә.

Хәниф көлеп җибәрде һәм бала-чаганы юатырга, башыннан сыйпаларга ниятләгән батыр кыяфәттә, ярты адым чамасы алгарак атлап куйды.

— Килмәгез!— диде Былбыл.

Ул тагын нәрсәдер әйтмәкче булган иде, киселеп калды —

көтмәгәндә кече якка Фәрхәнә апа килеп керде. Ул яшьләрнең кыяфәтләренә бөтенләй игътибар итмәгән булып күренергә тырышты һәм тыныч кына, ипләп кенә Былбылга:

— Булдымы? Самавыр куярбыз,— диде.

Хәниф шундук чыгып китте, олылар янына килде, папирос кабызды, ләкин өйдә тартырга ярамаганлыгын шәйләп, утлы папиросын гөл төбенә төртеп сүндерде дә, үз-үзен кая куярга белмичә, стенадагы фоторәсемнәргә текәлде.

Дәүләтгәрәй абзый скрипка уйнавыннан туктап калды, Нәҗия кул чапты, аңа иптәш Бикчурин кушылды. Хәниф тә, нәрсә өчен икәнлеген аңламастан, болай гына кул чапкан булды.

— Җитеп торыр хәзергә,— диде Дәүләтгәрәй абзый, скрипкасын чөйгә элеп.— Бик булдырып булмый хәзер, Нәҗия. Бармаклар да карыша.

— Ниндәй булмаган ди әле ул, Дәүләтгәрәй абзыкаем!— диде шат күңелле Нәҗия төчеләнеп.

— Булмый,— диде Дәүләтгәрәй абзый.— Менә минем Йосыф үземнән шәбрәк булдыра.

Нәҗия, аның сүзен үзенчә аңлап, шаркылдап көләргә тотынды.

— Уф, харап иттең, Дәүләтгәрәй абзыкаем!— диде күз яшьләрен сөртә-сөртә.— Кая соң әле ул Йосыф пигамбәр? Йосыф пигамбәребез кая булды соң әле безнең? Әле генә шушындае бит!

Шулай сөйләнеп һәм туктаусыз көлә-көлә ул кече якка чыгып китте. Ул чыгып киткәч тә Дәүләтгәрәй абзый ымлап ирләрне өстәл янына чакырды, рюмкаларга күздәй тутырып аракы салды да:

— Көлсәләр көләрләр инде. Әйдәгез әле күтәрик тегеләр күрмәгәндә!— диде.

Кызмача ирләр рюмкаларын тоттылар, чәкештереп-нитеп тормыйча, аяк өсте генә эчеп җибәрделәр. Иптәш Бикчурин белән Дәүләтгәрәй абзый эчкәч эһ тә итмәделәр. Хәниф исә, яшь һәм тәҗрибәсез кеше буларак, чыраен сытты, тиз генә каранып өстәлдәге тәлинкәләр арасыннан яшел кыяр эзләп тапты, кетердәтеп ашарга тотынды. Иптәш Бикчурин да өстәлгә күз йөртеп алды, уртадагы тәлинкәгә үрелеп, аннан бер кисәк какланган каз ите алды.

— Эх, яратам шушы каз итен!— диде майланып, лычкылдап торган кара-кучкыл ит кисәген кабып.

Аның артыннан ук диярлек Дәүләтгәрәй абзый да бер кисәк каз ите алды һәм тәмләп-тәмләп чәйнәргә тотынды.

— Син аны чәйнисеңмени, Дәүләтгәрәй?— диде иптәш Бикчурин гаҗәпләнеп.— Чәйнәмә син аны! Авызыңда тот — кәнфит кебек эреп кенә бетә ул.

— Шулай икән шул,— дигән булды Дәүләтгәрәй абзый бик тиз килешеп.— Белмәгәнмен синең каз яратканыңны, Исмәгыйль... иптәш Бикчурин. Җыл да каклап куям мин. Әле дә башланмаган ике казым бар. Берсе — сиңа болай булгач!

— Рәхмәт, Дәүләтгәрәй, рәхмәт!— диде иптәш Бикчурин, күңеле булып.— Андый нәрсә минем кулдан килми. Нәҗияне әйткән дә юк. Рәхмәт, Дәүләтгәрәй туган.

Шулай рәхмәт әйтә-әйтә ул уң кулы белән Дәүләтгәрәй абзыйның иңбашыннан кочып алды, сул кулы белән Хәнифне кочаклады һәм әле берсенә, әле икенчесенә карап:

— Иң якын кешеләрем — сез!— диде.— Бөтен Яңавылда, бөтен дөньяда — сез! Минем бит монда барышып-килешеп йөрерлек туган-тумачам да юк. Мин монда япа-ялгыз дияргә була. Миңа киләләр икән, сорарга гына киләләр, зарланырга... тегесе җитми, монысы җитми, анысын алай итәргә, монысын болай итәргә... Нәрсә дисең аларга? Ярар, ярар дисең, карарбыз, уйларбыз, дисең. Башкасы безнең кулдан килә торган түгел. Эх! Бөтен Яңавылда иң якын туган-

нарым — сез... Дәүләтгәрәй, Фәрханә апа... Райфода да без бертуган кебек яшәдек... Хәниф минем иң якын энем. Сөлек кебек чагы. Эх!

— Әйдәгез әле тагын берне күтәрик!— диде Дәүләтгәрәй абзый җайлап кына, өстәлдәге буш рюмкаларга үрелеп.

— Мин эчмим,— диде Хәниф һәм абыйсының кочагыннан чыгып читкә китеп барды.

Дәүләтгәрәй абзый өченче рюмкага салып тормады. Иптәш Бикчурин белән алар күтәрделәр, чәкештерделәр дә эчеп тә җибәрделәр. Дәүләтгәрәй абзый таза, юантык Исмәгыйльдән озынрак иде, шуңа күрә чәкештергәндә аңа чак-чак кына иелергә туры килде. Эчкәч, иптәш Бикчурин тагын каз итенә үрелде, бер кисәкне авызына капты да, үз-үзеннән, бөтен дөньясыннан канәгать бер төс белән:

— Эх, яратам шушы каклаган каз итен!— диде.—Авыл искә төшә, яшь чаклар искә төшә, Дәүләтгәрәй.

Аның артыннан ук диярлек Дәүләтгәрәй абзый да бер телем каклаган каз ите алып капты, әлерәк кенә әйткән сүзләрен искә төшереп:

— Бер каз синеке, Исмәгыйль,— диде.— Әйткән сүз — аткан ук! Синдәй кешегә каз җәлләп тораммы соң?! Син безнең иң якын кешебез, туган-тумачадан да якынрак кешебез. Моннан соң да гел барышып-килешеп яшәргә язсын.

— Шулай, Дәүләтгәрәй!— диде иптәш Бикчурин һәм баягыча тагын каты, нык кулы белән хуҗаның биегрәк иңбашына үрелде, кысып тотып алды.

— Әйдәле менә монда утырып торыйк,— диде Дәүләтгәрәй абзый өстәл янындагы урындыкларны идән уртасынарак күчереп.— Синдәй олы кешегә аяк өсте тору килешми.

— Синең янда килешә, Дәүләтгәрәй,— диде иптәш Бикчурин.— Беләсең ич, иң якын кешем — син! Эх, Дәүләтгәрәй! Күңелемдә авыр төер бар. Олыгая барган саен шул борчый. Беләсеңме, мин бит... кеше үтерүче!

## VIII

Бу шундый көтмәгәндә әйтелде, бу шундый ап-ачык итеп әйтелде, кызмача Дәүләтгәрәй абзый кинәт айнып китте, куркып китте, як-ягына каранып алды, күзләрен челт-мелт йомгалады, урыныннан торып ишеккә таба барып килде. Ярый әле якын-тирәдә тыңлап торырдай беркем юк иде.

— Туктале, тукта, иптәш Бикчурин...— диде ул каушап-кабаланып.— Алай кычкырып сөйләшмик әле без.

— Мин аны сиңа гына әйтәм. Синнән сүз чыкмаячагын беләм,— диде Исмәгыйль.— Эх, Дәүләтгәрәй!.. Юлбасар да түгел, талаучы да түгел, шулай да менә — кеше үтерүче мин. Ничек дисеңме? Ашыкма, хәзер әйтәм. Чиләбе трактор заводын ишеткәнең бармы? ЧТЗны? Менә шуны без төзедек. Юк, юк, мин түгел. Без саклап кына тордык. Этләр, автоматлар белән. Аңлыйсыңмы, төшендеңме хәзер? Минем биографиядә бу турыда: партия чакыруы буенча Чиләбе трактор заводы төзүгә китә, башта ташчы, аннан бетончы булып эшли; гади эшчедән бригадир булып күтәрелә, алдынгы була, фәлән-төгән, дип язылган. Төшендеңме хәзер? Мин ул таш-бетонның янына якын да барган кеше түгел. Аттык без. Кешеләргә аттык, Дәүләтгәрәй!

Эчкәч иптәш Бикчуринның чишелә торган гадәтен Дәүләтгәрәй абзый әлек тә белә иде, ләкин аның авызыннан әле беркайчан мондый сүзләр чыкканы юк иде.

— Күп... аттыгызмы?— диде ул, исен-акылын җыя башлап.

— Күп. Бик күп,— диде Исмәгыйль беравык эндәшми утыргач, авыр сулап.— Син сугышта булган кеше, Дәүләтгәрәй. Анда да без кеше үтердек. Ләкин анда без дошманны үтердек. Монда мин үз кешеләрне үтердем. Урысын-татарын, арын-чирмешен... берсе дә калмады. Үз кешеләр. Беләсеңме, бер гаепсез кешеләр!

— Бер гаепсез?!

— Бер гаепсез, Дәүләтгәрәй,— диде иптәш Бикчурин.— Башта конвойда йөрдем. Аңгыралыгымны, наданлыгымны күрделәр дә бәләкәй генә начальник иттеләр. Шуннан китте. Соңыннан зуррак начальник булдым. Зуррак начальник булгач, хата җибәрдем. Хатам шул — бер якташны, үзебезнең бер татарны кызгандым. Сизделәр, тикшерә башладылар. Атарга тиешләр иде. Сугыш коткарды... үзем теләп сугышка киттем. Яраландым. Шуннан менә бу якка, Яңавылга килеп чыктым. Анысын беләсең.

— Беләм,— диде Дәүләтгәрәй абзый.

— Бульдозерлар белән издерделәр кешеләрне, туфракка, вак ташка катыштырып издерделәр, Дәүләтгәрәй. Күбесенә мин үзем приказ биреп, карап тордым. Менә шунысы кыен. Искә төшә дә йоклый алмыйм. Әйтер кеше юк. Нәҗиягә сөйләргә куркам.

— Синең монда ни гаебең бар соң, иптәш Бикчурин? Минемчә, монда синең бер гаебең дә юк!— диде Дәүләтгәрәй абзый, кунагын тынычландырмакчы булып.

— Белмим. Бар микән, юк микән — белмим. Үземне үзем атып үтергән булсам, дөресрәк булгандыр кебек,— диде Исмәгыйль.— Беләсеңме, ул кешене мин яңадан фронтта очраттым! Үз кулымда үлде. Яхшылап күмдем. Менә ул язмыш. Эх!..

Дәүләтгәрәй абзый урыныннан торып әрле-бирле йөренде дә чөйдәге скрипкасына барып тотынды, ниндидер көй чыгармакчы булды — булдыра алмады, скрипкасын яңадан чөйгә элеп куймакчы булды, шулай ук булдыра алмады. Уен коралын утын агачы кебек тотып кече якка чыгып китте, ләкин анда да озак тора алмады — тагын Исмәгыйль янына килеп туктады.

— Утыр әле, йөрмә, Дәүләтгәрәй!— диде иптәш Бикчурин.

Дәүләтгәрәй абзый сүзсез генә үз урынына утыргач, ул ыргактай кулы белән аны яңадан әләктереп алды да:

— Эх, гармун юк, гармун!— диде.— Яшь чакта мин бөтен тирәякта беренче гармунчы идем, Дәүләтгәрәй. Эх!

Шулай диде дә, бар көченә кычкырып җырлап җибәрде:

— Биек тауның башларында
Карабодай күбәсе.
Бардыр әле башларымның
Әллә ниләр күрәсе.

Аңа әкрен генә, җайлап кына Дәүләтгәрәй абзый кушылды.

## IX

Алар шулай кочаклашып җырлап утырганда, олы якка Нәҗия килеп керде. Килеп керде дә идән уртасында туктап калды һәм бот чабып көләргә тотынды.

— Карале, кара, туганкаем Фәрханә апа — боларның дөньясы түгәрәкләнгән!— диде.

Нәҗиядән беркадәр калышып, ике куллап зур гына таба белән кайнар бәлеш күтәреп, Фәрханә апа керде. Бәлешне табасы белән өстәл уртасына, җәелгән чүпрәк өстенә куйды да, Нәҗиянең сүзенә колак салмаган сыман булып күренмим дигәндәй, тукталып, көлемсерәп карап торгандай итте.

— Әйдә, кисә башла, Нәҗия,— диде һәм ашыгып яңадан кече якка чыгып китте.

Алар шулай Нәҗия белән икесе әле теге якка, әле бу якка чыгып, тегесен-монысын әзерләделәр. Бөтен өйгә итле бәлеш исе чыкты. Иптәш Бикчурин белән Дәүләтгәрәй абзый дөньяларын онытып, парлашып җырлауларын белделәр. Тын алып, беркадәр тынычланып, тыштан Хәниф керде.

— Әйдәгез, утырышыгыз, кунаклар,— диде Фәрханә апа, кунакларны табынга чакырып.

Барысы да көттермичә яңадан урыннарына утырыштылар. Былбылның урыны буш калды. Аның юклыгына беренче булып Дәүләтгәрәй абзый игътибар итте.

— Кая соң безнең сандугачыбыз?— диде ул.— Диздекәй дә күренми.

— Диздекәй йоклый,— диде Фәрханә апа.— Былбылның башына ис тигән бугай. Аның башы авырта.

— Туктале, үзем алып килим әле,— диде Дәүләтгәрәй абзый, гадәттә булмаганча җиңел генә урыныннан кузгалып.— Мондый чакта йоклап яталармыни?!

— Ярар, йөрмә инде, үзем барып карармын,— диде Фәрханә апа, иренең юлына аркылы төшеп.

Дәүләтгәрәй абзый күндәм генә кире урынына утырды, үзенең төп вазифасын исенә төшереп, рюмкаларга аракы сала-сала, кунакларны ашарга-эчәргә кыстады.

— Әйдәгез әле, җитешегез, кунаклар,— диде.

— Бәлеше бик тәмле күренә, Дәүләтгәрәй, шайтан сидеге белән бутамыйча гына ашыйк әле,— диде иптәш Бикчурин кайнар бәлеш кисәген кулына алып.

— Ярар алайса,— диде Дәүләтгәрәй абзый.— Ашагыз, аша, кунаклар. Хәниф, син дә җитеш.

Кунаклар бәлеш ашый башлаганда Фәрханә апа да килеп җитте һәм сүзсез генә үзенең урынына утырды. Былбыл турында бер сүз дә әйтмәде. Башкалар да аның исемен телгә алмауны яхшырак күрделәр. Бары тик Нәҗия генә түзмәде.

— Их, мин булсаммы!— диде.— Мин булсаммы! Кызларның башы авыртканына карап торамммы?!

Ул моны ярым шелтә, ярым шаярту белән әйтте, алай гына да түгел, үртәлеп һәм гайрәтләнеп әйтте. Хәниф аның үзенә төрттергәнлеген бик яхшы аңлады. Йөзе бозылды, матур кара кашлары бергә кушыла язды, авызы ямьсез булып бөрешеп калды.

— Ярый әле син булмагансың,— диде иптәш Бикчурин.

— Мин булсаммы?! Мин булсаммы?!— диде әдәпсез Нәҗия бер үк сүзләрне кабатлап.

— Кирәкмәгән җиргә кысыласың, җиңгәй,— диде Хәниф телгә килеп.

— Ай алла, туганкаем! Бетте, бетте. Шуңа да ачуланып торырга син теге,— диде кайгыра белми торган Нәҗия.

— Ашап кына утырыгыз әле, кунаклар,— диде Фәрханә апа.

Кунаклар ашап кына утырдылар. Ашап утыру озакка сузылды. Өй өче караңгыланып китте. Тышта нидер дөбердәп куйды. Ачып куелган тәрәзәдән саф, дымлы җил исеп керде. Һәркем күңеленнән «яңгыр җиле» дип уйлады. Яңгыр күптән көтелә иде, яңгыр күптән кирәк иде. Дымлы җил шундук кешеләрнең кәефен үзгәрткәндәй булды. Караңгы тәрәзәне ялт-йолт китереп тавышсыз гына яшен яшьнәп алгач, берниндн шик калмады — бүген яңгыр явачак иде. Тәмле аш һәм яңгыр җиле, яшен һәм күк күкрәү тәэсирендә мәҗлес үзеннән-үзе түгәрәкләнә башлады.

Беренче булып иптәш Бикчурин торды, аның артыннан ук дияр-

лек Дәүләтгәрәй абзый торды, Хәниф торды. Алар, тирләгән битләрен, маңгайларын сөрткәләп, ишеккә таба юнәлделәр, тышка чыктылар.

— Ява бу, явачак,— диде иптәш Бикчурин, кара болытлар белән капланган тынычсыз күккә карап.

— Яусын инде,— диде Дәүләтгәрәй абзый.

— Ява башлаганчы кайтып китәбезме әллә?— диде Хәниф.

— Без белмибез, җиңгәңә әйт,— диде иптәш Бикчурин.

Аның әле кайтып китәргә исәбе юклыгы үзеннән-үзе сизелеп тора иде.

— Кунып китәрсез,— диде Дәүләтгәрәй абзый.

— Күп күрдем мин яңгырны,— диде иптәш Бикчурин.— Карлысын да, бозлысын да, кургашлысын да... Яңгырдан куркып тормыйбыз әле, энем Хәниф. Таңга кадәр күңел ачабыз!

— Дөрес, картым!— диде арттан килеп җиткән Нәҗия, иренең соңгы сүзләрен куәтләп.

— Мин нәрсә әйттем?— диде иптәш Бикчурин Хәнифкә карап, кете-кете көлеп.— Мин — начальник, җиңгәң — прокурор. Закун! Ул ничек әйтсә, шулай.

Хәниф кайту турында бүтән сүз кузгатмады. Портсигарын алып папирос кабызды һәм теләмичә генә тартырга тотынды.

Кунаклар яңадан өйгә керделәр. Керү белән иптәш Бикчурин Дәүләтгәрәй абзыйга күз кысты һәм тулы рюмкага килеп тотынды.

— Әйдәле, хатын-кыз күрмәгәндә генә...— дигән булды Дәүләтгәрәй абзый.

Алар эчеп җибәрделәр. Дәүләтгәрәй абзый тагын скрипка уйнамакчы булып карады, ләкин иптәш Бикчурин аны тагын кочып алды, урындыкка утыртты.

— Җырлыйк әле,— диде ул, якындагы буш урындыкка утырып.

Алар икәүләшеп эчкечеләр җырлый торган такмакларны сузып җибәрделәр. Фәрханә апа елмаеп куйды. Нәҗия көлеп җибәрде. Җырны иптәш Бикчурин әйдәп барды. Аның тавышы да көррәк, ягымлырак иде, җыр сүзләрен дә ул яхшырак белә иде. Бер-ике тыннан соң аларга сыек, моңсыз һәм чәрелдек тавыш белән Нәҗия кушылды. Бераз гына җырлагандай итте дә, тамагы карлыгып, йөткеренеп алды. Тын юлы алай да ачылып китмәгәч, кече якка чыгып кайнар чәй капты, яңадан ирләр янына килеп утырды һәм сул кулы белән ачык күкрәген тотып, кушылып китте. Шул чакны ул күңелсезләнеп утырган Хәнифкә күз төшереп алды.

— Әйдә син дә җырла!— диде.

Хәниф эндәшмәскә тырышты. Тыңгы белмәс җиңгәй урыныннан сикереп торып каен энесен җырларга кыстый башлады. Ирләр җырлауларыннан туктап калдылар.

— Нәҗия!— диде иптәш Бикчурин бармак янап.

— Әүкәй, Исмәгыйль?— диде Нәҗия, эт кояшыдай ялтырап.

Алар үзара аңлашкан арада Дәүләтгәрәй абзый скрипкасын көйләп җибәрде һәм, булдыра алган барлык осталыгын җигеп, янә дә «Эпипә»не чирттерә башлады. Иптәш Бикчурин бөтен өйне дер селкетеп, бармакларын шартлатып, биергә керешеп китте. Скрипка тавышына ул бик үк колак та салмады. Бары үз көен, үз ритмын гына белде һәм үз-үзен дәртләндереп сызгырып-сызгырып җибәрде. Биеп туктагач, «Эх!» диде дә, кулъяулык эзләп кесәсенә тыгылды.

— Гармун юк, гармун! Без яшь чаклардагы гармун булсыные хәзер!— диде.

Аңа кул чаптылар, мактау сүзләре әйттеләр.

— Әйдә, хәзер — син!— диде Нәҗия әлеге дә баягы Хәнифкә бәйләнеп.

— Мин болай бии белмим,— диде Хәниф.

— Нәрсә генә беләсең соң син, энекәем?— диде Нәҗия ачынып.
— Мин тансовать итәм,— диде Хәниф.
— Әйдәле, алайса, әйдә,— диде Нәҗия һәм бер кызудан Хәнифне җилтерәтеп әйләндереп алып китте.
Хәниф бу юлы карышып тормады — җиңгәсе белән парлашып бии башлады. Ләкин болай музыкасыз гына әйләнгәләүнең бернинди кызыгы булмады.
— Музыка кая, музыка?— диде Хәниф.
— Шул да булдымы бию?— диде иптәш Бикчурин, кулын селтәп.— Баскан саен табаныңнан ут чыкмагач, бию буламыни ул?!
— Яшьләргә ярый инде,— диде Фәрханә апа көлемсерәп.
— Яшьләргә дигән буласың, Фәрханә апа туганкаем, бар әле күгәрченеңне алып кил,— диде Нәҗия, әйләнгәләвеннән туктап.— Нинди эш инде бу вакытта йоклап яту?! Тансы-мансы биесеннәр. Җегетебез ялгыз. Күңелсезләнәсең килмәсә дә күңелсезләнерсең.
Җиңгәсенең сүзләренә Хәниф бөтенләй ачуланмады, киресенчә, бу аңа кыюлык булып тоелды.
— Каяле, үзем генә алып килим булмаса,— диде ул.
Җилләнеп ул чоланга чыгып китте һәм беренче очраган ишекне тартып җибәрде — ишек эчтән бикле иде. Шул ук вакытта диярлек аның янына ашыгып Фәрханә апа килеп җитте.
— Хәниф, Хәниф,— диде ул борчылып.— Анда түгел, акыллым. Үзем әйтермен, үзем чакырырмын. Син бар, кереп тор.
Хәниф, кызмача булса да, үзен үзе аңламас дәрәҗәдә түгел иде.
— Мин бит болай гына... болай гына,— диде ул гафу үтенгән сыман сөйләнгәләп.
Аңа кинәт оят булып китте, үзенә-үзе бик кызганыч булып тоелды. Аның хәзер Фәрханә апага зарланасы һәм аннан яклау табасы килде.
— Мин үзем чакырырмын, үзем,— диде Фәрханә апа пышылдап.
Шулвакыт тышта бик каты нидер шартлап ярылгандай булды, ниндидер дөбердек тавышы ишетелде һәм, озак та үтмәде, такта түбәгә бик каты бәреп яңгыр ява башлады. Фәрханә апа куркып, шомланып өйгә кереп китмәкче булган иде, искәрмәстән тышкы ишек ачылып китте һәм караңгыдан ашыгып Йосыфның кайтып кергәне күренде.
— Яңгыр ява!— диде Йосыф килеп керү белән.

## X

Сакат урманына җитәрәк яңгыр сибәли башлады. Көн дә караңгыланмады, түбә өстеннән элеккечә елмаеп кояш карады, шулай да менә яңгыр сибәләргә тотынды. Гаҗәп инде бу җәй көне. Яңгырдан котылмакчы булып, Габделхәй тизрәк урманга җитәргә ашыкты.
Менә ул йөгерә-йөгерә урманга килеп керде. Ләкин урман ул көткәнчә булып чыкмады. Яңгыр монда хәтта шәбрәк ява шикелле тоелды — бөтен тирә-як шаулап, шыбырдап тора иде. Юлдан читтәрәк бер-ике чыршы күренде. Чыршы астына кереп яңгыр туктаганны көтеп торырга булыр иде, әлбәттә. Ләкин бүтән вакытта аңа шундый якын, аңлаешлы була торган чыршы да хәзер нишләптер чит, ят булып тоелды. Ул анда кереп вакыт уздырмаска булды һәм юеш, тайгак юлдан бик кыенлык белән, саклык белән атлап, һаман алга баруында булды. Ул инде тәмам чыланып бетте. «Кайткач кибенербез әле»,— дип уйлады ул, үзләренең коры, җылы өйләрен күз алдына китереп.
Тау төшүе бик читен булды. Бер-ике мәртәбә таеп, ул пычрак

юлга утырды, чалбарын, кулын пычратты, янбашын авырттырды. «Ярар, кичүгә җиткәч Бүәдә юармын әле»,— диде ул янә күңелен төшермәскә тырышып. Шуннан соң ул корыган чикләвек таягы сындырып алды һәм аеруча тайгак җирләрдә таягына таянып төште. Сакат тавының иң текә җирен узып, юл буендагы Тирән чокырга җитәрәк, кинәт теге чәнчеп ташланган яшь марҗа хатыны исенә килде. Куркудан, яшь марҗа хатынын кызганудан йөрәге чемердәп китте. «Әллә чокырны читтәнрәк, урман эченнәнрәк әйләнеп үтим микән?»— дип уйлады ул икеләнеп. Анда, чокыр төбендә кемдер аны көтеп, сагалап торадыр шикелле тоелды.

Як-ягына каранып, курка-курка гына, ниһаять, ул чокыр турысыннан да узып китте. Чокырдан ераклашкач туктап калды, исәнимин котылуына ныграк ышанырга теләгәндәй, тирә-якка күз төшерде, як-яктагы тавышларга колак салды. Чокыр ягында да, күз күреме җиткән урман эчендә дә шикләнерлек берни сизелмәде, берни ишетелмәде. Кинәт ул үзенең бик нык арыганлыгын, ачыкканлыгын тойды. Хәзер инде ашыкмасаң да була иде. Кичүгә генә җитәсе дә, теге якка гына чыгасы да... анда инде Яңавылга күп тә калмый.

Ул яңадан кузгалып китте. Түбә өстеннән шыбырдап, эчне пошырып өзлексез яңгыр яуды, агач башларындагы яфраклардан, яңгырга кушылып, эре-эре тамчылар коелды. Биттән, муеннан яңгыр суы акты, тәнгә сылашкан, чыланган, авырайган киемнәр атларга, уйхыялланырга комачаулады.

Бу вакытта инде күкне тоташ болытлар каплап алган, көнне караңгылатып җибәргән иде.

Сакат тавын төшеп беркадәр җир тигезлектән баргач, Габделхәй күптән көтелгән кичү турысына килеп җитте. Килеп җитүен җитте, ләкин шул чакны аның алдында гаҗәеп бер күренеш ачылды. Бүә танымаслык булып үзгәргән, Бүәдә су күтәрелгән иде! Яр буендагы таллар, камышлар, куе үләннәр — барысы да кайдадыр су астында калган; башка вакытта пыяладай үтә күренмәле чиста су комланган, болганчыкланган; әле кайчан гына барлыгы-юклыгы да рәтләп сизелмәгән агымлы, юаш елга бары язгы ташу чорында гына була торган дәһшәтле кыяфәткә кереп, коточкыч тирән һәм куркыныч ташкынга әйләнгән иде. Бүә сай чагында эрсезләнеп яр астына ук төшеп үскән куаклар, муеннарыннан суга чумып, тынчыгып-калтыранып утыралар иде. Бөтен тирә-як каядыр омтылган һәм бар нәрсәне юып, күмеп, агызып алып китәргә көченнән килгән илаһи көч-куәт алдында тынып-йомылып калган сыман иде.

Җәй көне Бүәнең бу кадәр ташыганын Габделхәйнең әле күргәне юк иде. Ул бик озак исенә-акылына килә алмый торды. Бер үк вакытта соклану, таң калу да, курку һәм шомлану да кичерде. Үзе алдында берничә адымлык җирдә генә тетрәндергеч көч-куәт чыганагы күрде, кыргый гүзәллек күрде. Ирексездән ул аның алдында баш ияргә мәҗбүр булды һәм гоме ендә беренче мәртәбә серле табигать каршында үзенең ни дәрәҗәдә көчсез, ярдәмчесез һәм кечкенә икәнлегеен аңлагандай булды.

Адәм баласы әле куркып, әле онытылып, тулып аккан суга карап торды да торды. Каты җирне җырып, урман-таулар арасыннан җыландай боргаланып куышкан, туктаусыз агып торган бу шомлы, дәһшәтле ташкынга күпме карасаң да, ул сине ялыктырмый, киресенчә, караган саен сихерли һәм үзенә тарта, суыра бара сыман иде. Бу ташкынны тулысынча аңлау-төшенү өчен, әйтерсең, аңа бары кушылырга һәм аның белән бергә каядыр агып китәргә генә кирәк иде.

Габделхәй туктап калган җирендә каккан казыктай кузгалмыйча торды да торды. Ул арада яңгыр шәбәя башлады. Эре тамчылар су өстенә чупылдап-чупылдап коелдылар, чәчрәделәр һәм Бүәгә кушы-

лып юкка да чыктылар. Яңгыр пәрдәсе аша теге як бөтенләй күренмәс булды. Габделхәй туңа башлады. Ул як-ягына карангалап ышыкланырдай урын эзләде.

Калку урындагы моңаеп утырган ялгыз карама аны үз янына чакырды. Ашыгып ул шунда йөгерде, куе ботаклар астына керде дә калын, кытыршы кәүсәгә аркасын терәде. Сихерләнгән кебек, ул моннан да су өстенә карады. Беренче тәэсир — курку, соклану, шаккату тойгылары кими төшкәч, ул үзенең хәзерге хәле турында уйлый башлады. Нишләргә, кая барырга да, ничек итеп теге якка чыгарга? Күпергә китәргәме? Күпер ерак. Анда тиз генә барып җитәрлек түгел. Моның өчен иң элек Сакат тавын менеп, яңадан олы юлга чыгарга кирәк булачак. Аннан соң, мондый ташуда күперне су агызып алып киткән булырга тиеш, чөнки Буә күпере, гадәттә, җәйге вакыт өчен генә, җиңелчә генә салына. Елганы боз тоту белән, аны сүтеп алалар, сүтәргә өлгермәдеңме, яз көне аны су алып китә.

Болай булгач, кире Янтыкка кайтырга, су кимегәнен шунда көтеп ятырга микәнни? Ләкин аның хәзер һич тә авылга күңеле тартмады. Бу аңа нәрсәдәндер кире чигенү булып тоелды. Аның чигенәсе килмәде. Ул бары алга барырга, ничек тә Яңавылга кайтып җитәргә тиеш иде. Бит аны анда кемдер көтеп тора!

«Әгәр шушында төн кунсам?!» — дип уйлады ул билгеле бер фикергә килеп. Төнлә бәлки яңгыр да туктар, су да кимер. Иртән, бәлки, кичү аша чыгарга да булыр.

Аның өстендәге киеме бер генә кат иде, бер кулында таяк, икенче кулында ямалган ботинкасы белән картыйсы биргән төенчек иде. Үзе ул суга баткан чебеш кебек чыланып беткән, туңган-бөрешеп беткән иде. Читтән караганда аны хәзер хәер сорашучы берәр ятим бала дип уйларга бу́лыр иде. Ләкин ул үзенең тышкы кыяфәтен күрмәде һәм тышкы кыяфәт сыман юк-бар нәрсә турында уйламады да. Ул бөтенләй икенче нәрсәләр турында хыялланды. Үзе туктап калган җирне яңгыр пәрдәсе аша түгел, бәлки күңелендәге алсу томан элпәсе аша гына күрде. Шушында, шушы карама төбендә ул чыбык-чабыктан корамаланган, өстенә хуш исле печән капланган коры шалаш, шалаш алдында утлы учак күрде. Шалаш алдында, коры печәндә, имеш, елмаеп Уфа кызы Былбыл утыра. Ул әле генә су кереп чыккан. Ул шундый сылу. Аңа хәтта туры карап та булмый — күз ояла. Аның тәнендә су тамчылары елтырый. Учакта, корымлы бидерәдә балык пешә, бәрәңге пешә. Алар бүген бергәләп кайнар балык, бәрәңге ашаячаклар. Картый карбаздан салкын катык кертеп бирәчәк.

Салкын катыкны исенә төшергәч, ул суыктан калтыранып кинәт сискәнеп китте. «Карале, аяк өсте йоклап торам түгелме соң?» — дип уйлады исе китеп. Юк, болай аяк өсте йокларга ярамый. Туктале, шушы тирәдә печән кибәннәре булырга тиеш ләбаса! Нигә шунда барып кешечә рәхәтләнеп йокламаска... лапса!

Иленура хәзер рәхәтләнеп йоклап ятадыр инде, дип уйлады ул үзен озатып куйган кыз туганын исенә төшереп. Бигрәк тә аның менә шул «лапса»сы исендә калган да, матур муенындагы матур муенсасы исендә калган. Кашлары да, тешләре, иреннәре дә матур Иленураның. Исеме генә әллә нинди. Чыны — Эленора. Шуны бозып, Иленура диләр. Дездемонаны кем уйлап тапкандыр инде? Диздекәй дигәндә әле ярый, ләкин «Дездемона» диделәрме, әллә нинди ямьсез нәрсәләр күз алдына килә. Барысыннан да матуррагы, әлбәттә, Былбыл! Сандугач. Шәп исем, искиткеч матур исем.

«Әһә, тагын йоклап китеп барам түгелме соң?» — диде ул үз-үзенә. — Юк, болай ярамый. Кузгалырга кирәк, китәргә кирәк моннан — әллә су тартып алыр. Суны бит тарта, диләр. Юк, юк, китәргә кирәк!

Күптән түгел печәнчеләр өеп куйган кибән кичүдән ерак түгел иде. Габделхәй туры шунда кибән ягына китеп барды. Әле ныклап басылмаган печән кибәненнән актарып үзенә оя ясады һәм башы-аягы белән күмелеп шунда кереп утырды. Җылы һәм аулак иде монда. Ләкин яңа урында ул тиз генә йоклап китә алмады. Утыра торгач, картыйсы биргән күчтәнәчләрдән авыз итеп карамакчы булды. Башта бер бәрәңгене ашады, аннан икенчесен ашады, бер уч тутырып җиләк капты. «Бүгенгә җитеп торыр,— диде ул аннары үз-үзенә.— Җитәр. Иртәгә дә көн бар.»



## XI

Берзаман Габделхәй күзләрен ачып җибәрде һәм үзенең кайдалыгын чамалый алмыйча, озак кына уйланып ятты. Баштарак аңа ул үзләренең лапас түбәсендә печәнлектә йоклап ята сыман булып та, Янтыкта чоланда ята сыман булып та тоелды. Шулай да бу рәвешчә йокылы-уяулы яту озакка сузылмады. Келт итеп кичәге күренешләр исенә төште. Котылгысыз сорау булып, бөтен ихтыярын шундук рәхимсез чынбарлык биләп алды. «Ничек икән?»— дип уйлады ул ташыган Буәне күз алдына китереп.

Мүкәләп оясыннан чыкты, аягына басты. Яңгыр туктаган, көн яктырган иде. Бөтен табигатьтән бары тик яңгырдан соң гына була торган бер тынлык, сафлык һәм гүзәллек бөркелә иде. Үләннәр, агач яфраклары юеш. Кая карама, өзелеп төшәргә өлгермәгән яңгыр тамчылары асылынып тора, бөтен нәрсә җемелди, җир өстеннән җиңелчә бу күтәрелә. Кайдадыр аяк астында, күктә, тирә-якта көн тууына сөенеп вак кошлар чыркылдый, эрәмә ягында моңсу да, шомлы да итеп ялгыз с ескан шыгырдый.

Яңгыр туктагач, ташуның, һичшиксез, кире кайтачагына Габделхәй әз генә дә шикләнмәде. Ләкин ярга якынаю белән ул үзенең бик каты ялгышканлыгын аңлады. Буәдә су әз генә дә кимемәгән иде. Буә, ярларына сыеша алмыйча, кичәгедәй шаулап-ургылып, каядыр ага да ага, каядыр ашкына иде.

Габделхәй ярга якынрак килде һәм таң калып, куркып-шомланып, аккан суга карап торды да торды. Кичә ничек карап торган булса, бүген дә шулай ук карап торды. Буә дә, кичә ничек аккан булса, бүген дә шулай туктаусыз ага да ага. Әйтерсең, дөньяда берни үзгәрмәгән. Каян килә аңа бу кадәр су, бу кадәр көч-куәт? Гаҗәп бит бу! Иң гаҗәбе шул — елгада су әз генә дә кимергә уйламый иде бугай. Чыннан да, каян килә бу? Күрәсең, читтә, югарыда, Молотов өлкәсендә мондагыдан да көчлерәк яңгыр яуга дыр. Анда әле, бәлки, һаман явадыр.

Суга карап торган арада Габделхәй шуңа да игътибар итте: кичәгенәк ул посып торган калку урындагы карама бөтенләй яр кырыенда калган иде. Буә тагын берәр тәүлек тулып-артылып акса, карама агачы суга капланып төшәргә дә мөмкин иде.

«Әгәр шунда мин йоклап утырган булсам?!»— дип уйлады Габделхәй, караманың төбе-тамыры белән суга ишелеп төшүен күз алдына китереп. Куркып, тизрәк читкә китәргә ашыкты, калкурак җиргә килеп җитте дә тагын артына борылып карады — ул әле һаман суның сихереннән котылып җитә алмаган иде бугай.

Елга ягына караштыргалап, ул төенчеген чиште һәм изелеп укмашып беткән бәрәңгеләрне тәмләп кенә ашый башлады. «Нишләргә соң?»— диде үз-үзенә, аптырап. Кире Янтыкка кайтырга һаман аягы тартмады. Әгәр ул котмагәндә яңадан авылга кайтып төшсә, бу һич тә җегетлек булмас иде, әлбәттә.

«Туктале, монда бит кайдадыр шушы тирәдә Җобанайның сыер

фермасы булырга тиеш»,— диде ул үз-үзенә, уйлана торгач. Кичүдән үрдәрәк, калку җирдә һәр елны аларның җәйге фермалары була. Көймәләре юк микән? Булырга мөмкин. Бик мөмкин.

Күңеле күтәрелеп, максаты ачыкланган Габделхәй яңадан кузгалып китте. Төш вакыты якынлашканда, ул арып-алҗып, киемнәрен ерттырып, чытыр аша Җобанайның җәйге фермасы турысына барып җитте. Ферма теге якта, текә ярдан читтәрәк утыра иде. Елга аша салам түбәле озын каралтылар, киртәләп алынган утарлар һәм тәбәнәк кенә йортлар аермачык булып күренеп тора иде. Фермадан арырак, тигез җирдә, әрәмә буенда таралып сыер көтүе йөри, ләкин якын-тирәдә беркем күренми иде.

Габделхәй Буә ярына якынрак килде, ачыграк, калкурак җиргә басты да, кулын авыз турысына китереп, бар көченә кычкыра башлады.

Күпмедер вакыттан соң аны ишетеп алдылар. Янында ук бидоннар тезелеп торган бәләкәй генә өйдән бер-ике хатын-кыз чыкты. Берни аңламыйча, аптырап, тавыш килгән якка карап тордылар-тордылар да, ярга якынрак килделәр һәм соңлап булса да:

— Нәмә-ә?— диделәр.

— Чыгарың әле! Көймәгез юкмы?— дип кычкырды Габделхәй.

Хатыннар аңлап җитмәделәр, ахрысы, тагын «нәмә?» диделәр, яр кырыена ук килделәр һәм, «кем соң бу?» дигәндәй, озаклап карап тора башладылар. Габделхәй Буә аша чыгарга кирәклеген көч-хәл белән аңлатып бирде: Яңавылга кайтам, диде, Буә ташыганны белмәдем, Янтыктан киләм, диде.

Алар елга аша сөйләшкән арада тәбәнәк өй ягыннан тагын бер-ике кеше килде. Берсе ир кеше, икенчесе хатын-кыз иде. Хатыннар Габделхәйгә төрле сораулар бирделәр, үзләренчә киңәш иттеләр. Берсе әйтте: «Син инде бу якка чыгалмассың — Буәдә су кайтмаячак»,— диде. Икенчесе әйтте: «Күкнең төбе тишелгән — ишетмәдеңмени?» — диде. Арада чибәррәге, чаярагы: «Безнең янда калырга риза булсаң, үзем чыгып алам», — диде.

Ярым солдат киемендәге яшь ир кеше, хатын-кызлар шулай юкбар сөйләнгәндә эндәшмичә генә тыңлап торды да, билгеле бер карарга килеп:

— Көтеп тор! Хәзер чыгарсың! — дип кычкырды.

Тиз-тиз атлап, ул ферма ягына китеп барды. Бер ярты сәгать чамасы үткәч, җигүле ат килгәне күренде. Солдат киемендәге яшь ир кеше белән икенче бер олырак ир кеше яр кырына җиткәч, арбадан көймә төшерделәр. Дилбегә белән уратып бәйләнгән иске генә, бәләкәй генә көймәне ирләр җайлап түбәнгә, суга таба шудырдылар. Шуннан соң яшьрәк ир кеше көймәгә керде һәм кулындагы ишкәге белән ишә-ишә, Габделхәй ягына килә башлады. Исән-имин килеп җиткәч, яр буендагы талны эләктереп алды да көймәне коры җиргә якынрак тарттырды һәм дусларча көлемсерәп:

— Әйдә, киттек, — диде.

Габделхәй, агач ботакларына тотынып, яр читенә төште, сакланып кына көймә янына килде.

— Мә кулымны, мулла абзый! — диде ярым солдат киемендәге ир кеше, көлемсерәп, кулын сузып.

«Кем соң әле бу? Кайда күргән идем соң мин аны?» — дип уйлады Габделхәй сабан туе батыры сыман таза ир кешенең көчле кулына тотынып.

Икенче як ярга килеп чыккач, җиргә аяк баскач, ул куанычыннан елмаеп җибәрде һәм беренче сүзе итеп:

— Рәхмәт, абый! — диде.

— Рәхмәт булмыйча! — диде ир кеше.

Көймәгә җыеп салган дилбегә очын ул яр өстенә ыргытты. Яр

башындагы ир кеше дилбегәне тотып алды. Бауга шундук хатын-кызлар килеп тотынды һәм шаулашып-көлешеп шундук көймәне югары тарта да башладылар.

— Утырыгыз, тартып мендерәбез! — дип кычкырды хатыннарның берсе, яшьрәге, чибәррәге.

— Утырмай торсыннар әле! — диде икенчесе, олырагы.

— Җегете генә утырсын — үземә булыр, — диде хатыннарның яшьрәге.

— Бар, үзең төш, икәүләп агып китәрсез, — диде хатыннарның олырагы.

Көймәне тартып мендергәч һәм көймәчеләр үзләре дә яр өстенә килеп менгәч, әлерәк кенә шаулашкан-көлешкән хатын-кызлар кинәт тынып калдылар. Барысы да кызыксынып Габделхәйгә карады. Арада берсе хәтта Габделхәйне таный булып чыкты.

— Гаптелхәй Мөхеттинеф түгелме соң син, бәбекәем? — диде бу.

Ул алай «ана» булыр дәрәҗәдә карт та түгел иде, киресенчә, шактый яшь һәм чибәр иде.

— Каян беләсең син мине? — диде Габделхәй чын күңелдән гаҗәпләнеп.

— Бәт-тәч, белмәскә! Шагыйрь Гаптелхәй Мөхеттинефне генә беләбез без, — диде хатын елмаеп, матур ак тешләрен күрсәтеп.

Габделхәйнең йөрәге атылып чыгардай булып тибәргә тотынды. Шатлыктан һәм горурлыктан күз аллары томаланды. Шагыйрь! Аны, имеш, монда да... гап-гади кешеләр дә белә!

— Син үзең кем соң әле? — диде ул хатынга, үзеннән-үзе ерылган авызын йома алмыйча.

— Мин — Җәмиләнең апасы Кифая булырмын, бәбекәем, — диде хатын. — Сине бу якка алып чыккан менә бу «командир» — Җәмиләнең җизнәсе Гали батыр булыр.

— Минем исемем — Талия, — диде барысыннан да яшьрәк, шаянрак хатын, кояштай балкып. — Син — Гаптелхәй, мин — Талия. Икебез дә пар килгәнбез!

Түгәрәк алсу битле, чем-кара кашлы һәм матур сынлы бу яшь хатынга Габделхәй башта ук игътибар иткән иде. Үзе шикелле исеме дә матур икән. Талия. «Былбыл» дигән кебек. Туктале, нинди Җәмилә турында сөйли соң бу Кифая дигәне? «Сеңлем» ди, «җизнәсе» ди...

Алар шулай сөйләнгәләп ферма өенә таба атладылар. Өй янына җиткәч, Талия ярым ачык калдырылган ишектән кереп китте. Бераздан ул сөт үлчи торган литрлы чүмеч белән сөт алып чыкты.

— Әйдәле, эчеп җибәр әле — булдыра алырсың микән? — диде сөтле чүмечне Габделхәйгә биреп. — Моннан соң көтүдән аерылып йөрмәссең. Чөмер-чөмер!

— Эч әйдә, эч! — Бездә сөт җитәрлек, — диде Җәмиләнең апасы Кифая да.

Габделхәй, үзенә карап торучы хатын-кызлардан бераз гына тартынып, куе сөт тулы чүмечне авызына якын китерде һәм... бер тында диярлек эчеп бетерде дә авыз читен сөртеп куйды, пошкырып куйды, рәхмәт әйтте.

— Укырга Казанга китәсеңдер ич инде? — диде бераздан Кифая, үзенең бөтенесен белгәнлеген сиздереп. — Безнең Җәмилә дә шунда китмәкче була. Медицинскийга.

— Җәмилә?! — диде кинәт Габделхәй, кайсы Җәмилә турында сүз барганын әле яңа аңлап алып. — Җәмилә... безнең Җәмилә! Әйе, Казанга без бергәләп китмәкче булабыз. Документлар гына әзер түгел. Менә шуңа ашыгып кайтам да. Авылда да озак торып булмады.

— Җегетләргә кытлык бездә. Әллә үзебездә генә каласыңмы? — диде Талия елмаеп. — Икенче алай кибән төбендә кунып йөрмәссең. Өебез иркен. Иркәләп кенә йоклатырбыз.

— Казанга барсаң, сәлам әйт — анда минем дуслар җитәрлек, — диде «командир» Гали батыр да, сүзгә катышып.

Ләкин Казанда кемгә сәлам әйтергә кирәклеген шулай да ул ачык кына итеп әйтмәде, Габделхәй исә төпченеп тормады.

— Җәмиләгә сәлам әйт... күрсәң, — диде Җәмиләнең апасы.

— Әйтермен, — диде Габделхәй.

Сыер таптап бетергән баткак юлдан ул Яңавыл ягына кузгалып китте. Фермадан беркадәр ераклашкач, артына борылып карады. Өй янында җыелып торган хатын-кызлар аңа нидер кычкырган булдылар, кул болгадылар.

— Рәхмәт! Сау булыгыз, сау булыгыз! — диде Габделхәй, шулай ук кул болгап.

Юл буена ул шат күңелле чибәр Талия турында, Җәмиләнең апасы, җизнәсе һәм фермадагы барлык мәрхәмәтле кешеләр турында уйланып кайтты.

## XII

Яңавылга, үзләренә Габделхәй кичке якта кайтып керде. Ул кайтканда инәсе өйдә иде, бәрәңге пешерелгән, самавыр куелган иде. Өйдәгеләр аны шаулашып каршы алдылар. Кайтып керү белән Габделхәй яхшылап юынды, киемнәрен алыштырды да, гадәтенчә, өстәл янына килеп утырды. Бер-ике сүз белән авыл хәлләрен сөйләп бирде. Шуннан соң комсызланып ашарга тотынды.

— Улымны туйдырып җибәргәннәр икән, — диде инәсе, аның зур-зур кабып ашавына игътибар итеп.

— Туйдырдылар, — диде Габделхәй.

— Юк, туйдырмаганнар, — диде Фидәил.

— Картый сезгә күкәй пешереп җибәргәние, юлда ашадым. Ачуланмассыз инде, — диде Габделхәй энеләренә, гафу үтенгән сыман.

— Хәердән булсын, — диде Фидәил олыларча.

— Габделхәй абый — комсомол. Комсомолга хәер алырга ярамый, — диде Илгиз.

— Миңа ярыймы соң? — диде Фидәил.

— Утыр әле сөйләнеп! — диде Шәмсебанат апа кырыс кына. — Авызыңнан җил алгыры. Хәер сорашасың гына калды.

— Алайса Габделхәй абый картый җибәргән күкәйне кире бирсен, — диде Фидәил.

— Ашадым дидем ич! — диде Габделхәй.

— Нигә безнекен ашадың? — диде Фидәил. — Картый аны безгә дип җибәргән!

— Күчтәнәч кирәк булса, үзең барырсың, — диде Габделхәй.

— Эшли башлагач та, иң беренче күчтәнәчне инәкәй белән сиңа алып кайтып бирермен, — диде Илгиз Фидәилгә.

— Эшкә алдылармы соң әле сине? — диде Габделхәй Илгизгә.

— Алдылар, — диде Илгиз

— Котлы булсын, — диде абый кеше.

— Синең үзеңнең эшләрең ничегрәк соң? — диде инәсе утыра торгач. — Паспорт та алмадың бугай.

— Алган булсам, иң элек сезгә күрсәткән булырием, — диде Габделхәй.

— Тимер кызганда сугыла. Дәүләтгәрәй абзаң әйткәч тә барып кайтыргае, — диде инәсе ничектер пошынган сыман.

— Иртәгә барам, — диде Габделхәй. — Паспорт начальнигы өйдә юк, диделәр. Иртәгә булачак.

— Карале, абыйга язу бар бит. Военкоматтан, — диде Илгиз.

— Ә?! — диде Габделхәй ашавыннан туктап.

— Кичә кертеп киткәннәр, — диде Шәмсебанат апа, тыелып кына. — Иртәгә сәгать тугызга килергә кушканнар.

— Армиягә алсалар, Казанга китәлми дә калырсың әле, — диде Илгиз, абыйсын кызганып.

— Сугыш вакыты түгел. Ашаталар-эчертәләр, кием-салым бирәләр, — диде Шәмсебанат апа.

— Погон тагарсың, китель киярсең! — диде Фидәил һәм, урыныннан торды да, кулларын хәрбиләрчә селтәп, идән әйләнеп килде.

Габделхәй өчен дөнья кинәт туктап калгандай булды. Бөтен өй эчен ниндидер куе караңгылык томалап алгандай булды, күз алдындагы әйберләр күренмәс, тавышлар ишетелмәс булды. Якындагы кешеләрнең сүзләре аңа каяндыр күктәнме, җир астыннанмы килгән сыман тоелды. Бары тик күкрәгендәге тынгысыз кошчык кына каядыр иреккә чыгып китмәкче булган кебек, туктаусыз бәргәләнә башлады. Армия. Кительләр, погоннар, мылтык-автоматлар... Дөрес, сугыш бетте. Армиядә хәзер кеше үлми. Ләкин үлү генә мени? Армиядә шигырь язарга, филолог булырга өйрәтмиләр. Атарга, кеше үтерергә өйрәтәләр, гәүдәне төз тотып шап-шоп басып йөрергә өйрәтәләр. Шулай итеп, теләге булган кешегә шигырь язарга ярамый булып чыгамыни? Ник?! Әнә фермадагы хатыннар да аны шагыйрь дип беләләр. Бөтенесе аңа карап тора. Аны Казанга китәчәк дип, олы кеше, атаклы кеше булачак дип өмет итеп торалар. Солдатка китеп барса, аннан бит көләчәкләр!

— Сине алмаслар — курыкма! — диде Илгиз, өнсез калган абыйсын юатмакчы булып.

«Ник алмаслар икән мине?» — дип уйлады Габделхәй, ләкин шул фикерне сүзгә әйләндереп әйтергә нишләптер хәленнән килмәде.

— Әйтимме, әйтимме? — диде шул чакны Фидәил, Илгиз абыйсы белән инәсенә карап.

— Утырма инде кыланып, — дигән булды Шәмсебанат апа, кече улына ачуланып.

— Нәрсә... тагын? — диде Габделхәй.

— Син югында Сәкинә килде! — диде тишек авыз Фидәил.

— Сәкинә?! — диде Габделхәй гаҗәпләнеп.

— Сәкинә белән Җәмилә, — диде инәсе. — Сине сораштылар. Казанга кайчан китә, диделәр, бергә китәриек, диделәр.

«Армиягә алсалар, Сәкинәне... Җәмиләне алдау да була бит әле бу», — дип уйлады Габделхәй үз алдына.

— Күзгә-башка да күренми, югалды Габделхәй, диләр, — диде Илгиз.

— Һы, — диде Габделхәй картәтәсе кебек.

— Җәмилә әйтте, кереп чыксын әле безгә, диде. Сөйләшәсе сүзләре бар бугай, — диде Шәмсебанат апа.

— Сәкинә бер нәрсә дә әйтмәде, авызын җомып тик торды, — диде Фидәил.

— Сөйләшәсе сүзләре бардыр, кереп чык, улым, — диде Шәмсебанат апа үтенгән, үгетләгән сыман ягымлы итеп.

Кайчагында Шәмсебанат апа, күрәсең, балалар бакчасындагы гадәтенчә, үз малайлары белән дә кирәгеннән артык ягымлы, йомшак итеп сөйләшә иде. Ләкин үзе белән мондый үгет-нәсихәт рәвешендә сөйләшкәндә Габделхәйнең еш кына ачуы килә торган иде. Хәзер дә инәсенең артык ягымлылыгына ачуы килеп куйды. «Керермен, күрермен менә, көтеп торсыннар!» — диде ул үзалдына, киреләнеп. Ләкин инәсенең кирәкмәгән ягымлылыгы өчен ачулануның Сәкинә белән Җәмиләгә бернинди катнашы булмаска тиешлеген шулай да ул аңламый булдыра алмады. «Чыннан да, сүзләре бардыр. Күрергә, сөйләшергә кирәк», — дип уйлады бераздан. Ашап туйгач, корырак,

рәтлерәк киемнәрен киенә башлады һәм мыштым гына чыгып та китте.

Урамга чыккач, ул Җәмиләләр ягына барыргамы, Сәкинәләр ягына барыргамы? дигәндәй икеләнеп калды. Бит ул Сәкинә белән очрашуга бармады! Хәзер очрашкач нәрсә диярга аңа? Ашыгыч эш чыкты, дип ялганларгамы? Ләкин аны бит Сәкинә түгел, Җәмилә чакырган.

Теләр-теләмәс кенә кузгалып китте. «Апаң сәлам әйтте диярмен, җизнәңне күрдем, диярмен», — дип уйлады ул Җәмиләләр ягына баруына сәбәп табып. Аның, билгеле, өченче якка да барасы килде. Чынлыкта аның күңеле бары шул өченче якка гына тартты да. Шул ук вакытта Фәрхәнә апалар белән ике арада ниндидер каршылык, ниндидер киртә дә барлыкка килгән сыман иде. Иң туры, иң җиңел юл шулай да Җәмиләләр ягына илтә иде, ахрысы.

Көтеп кенә торган кебек, Җәмилә өйдә булып чыкты. Габделхәй бернинди икеләнү, уңайсызлану тоймыйча, туп-туры аларның өйләренә барып керде. Кычкырып исәнләште, кычкырып авыз тутырып Җәмиләне белеште. Аның килүенә Җәмилә дә, башкалар да сөенделәр. Барысы да өстәл тутырып ашап-эчеп утыралар иде. Җәмилә тиз арада өстәл яныннан торып китте, киенде, ясанды да үзен көтеп торган Габделхәй янына килеп тә җитте.

Урамга чыккач, алар әкрен генә атлап станция ягына китеп бардылар.

— Сәкинәгә дә кереп чыгарбыз. Бергә-бергә күңелле булыр, — диде Җәмилә.

— Ярар, — диде Габделхәй.

Ләкин Сәкинәләргә борыла торган тәшкә җиткәч, икесе дә нишләптер аны исләреннән чыгарып җибәрделәр һәм, сүзләренә мавыгып, юлларын дәвам иттеләр. Габделхәй үзенең Янтыкта булуын, кичү янында тоткарланып, печән кибәнендә төн кунуын сөйләде. Аннары бик тәмләп, көлә-көлә ферма турысында Бүә аша чыгуын, Җәмиләнең апасын, җизнәсен күрүен — берсен дә калдырмый сөйләп бирде.

— Мин дә булдым алар янында кичәгенәк. Очрашкан буласыбыз икән, — диде Җәмилә.

— Кызык буласы икән, — дип куйды Габделхәй.

Ул үзенең кичәге, бүгенге маҗараларын сөйләп бетергәч, тынып калды һәм алар беравык эндәшми бардылар да, Җәмилә, бик зур хәбәр әйткән сыман:

— Назиф килде, — дип куйды.

— Мәктәпкәме? — диде Габделхәй.

— Юк, безгә... өйгә килгән, — диде Җәмилә ничектер серле итеп.

«Ә, шулаймыни? Назиф та Казанга медицинскига барырга җыена микәнни?» — дип уйлады Габделхәй артык исе китмичә.

— Колхоз председәтеле буласы килмәде микәнни? — диде ул Назиф турында, көлемсерәп.

— Кем аны персидәтел итсен! — диде Җәмилә. — Шахтага китмәкче була.

— Шахтага? — диде Габделхәй төшенеп җитмәгән сыман. — Ник шахтага? Кайчан, ничек?

— Авылдан дүрт-биш кеше китә, ди. Вербовщик килгән, ди. Губаха дигән җиргә. Ишеткәнең юкмыни? Молотов өлкәсендә. Авылдан гел шул якка китәләр. Кием-салым бирәләр, ди, паек бирәләр, ди, акча түшә, ди. Шулай булгач...

— Киңәш сорарга килгәнмени? — диде Габделхәй.

— Киңәш сорарга, — диде Җәмилә.

— Син нәрсә дидең соң, «кит», диденме?

— Юк, мин алай димәдем, — диде Җәмилә, — Шахтадан башка

эш беткәнмени дөньяда, дидем. Ул әйтә, шахтага китәсе кешегә паспорт бирәләр, ди, армиягә дә алмыйлар икән, ди. Армиягә киткәнче, шахтага китеп бер-ике ел эшлим дә, барыбер үзебезнең Эткенәвылга кайтам, ди.

— Персидәтел булу уеннан баш тартмаган алайса? — диде Габделхәй.

— Шулайдыр, — диде Җәмилә икеле-микеле итеп.

## XIII

Беркадәр вакыт сүзсез баргач, Габделхәй, үзенә кагылмый торган бөтенләй чит нәрсә турында сөйләнгән сыман:

— Мине дә... армиягә алмакчы булалар ди бит әле, — дип куйды.

Моны ул мөмкин кадәр тыныч әйтергә тырышты. Ләкин бу турыда шулай да бик үк тыныч та әйтә алмады — сугыш дәһшәте һәм армиягә алыну куркынычы әле булса аның канында саклана иде. Аның тавышы чак-чак кына калтыранып, кысылып чыкты. Мондый хәбәр Җәмиләгә аяз көнне яшен суккан кебек тәэсир итте. Ул хәтта туктап калды, ирексез бер хәрәкәт белән Габделхәйнең беләгеннән тотып алды. Аның кулы кайнар иде.

— Ни сөйлисең? Сине?! — диде ул. — Син бит... Казанга китәсе кеше!

— Шулаен шулай да, — диде Габделхәй. — Военкоматтан повестка килгән. Миңа да Назиф белән бергәләп шахтага китәргә туры килмәсен әле!

Шахтага китү, җир астына төшеп күмер чабу, күмер тузаны эчү турында ул, билгеле, беркайчан хыялланмады. Шуңа күрә кычкырып әйткән үз сүзләре аның үзенә үк ялган һәм ясалма булып тоелды. Көчәнеп кенә ул үз-үзеннән көлеп куйган булды.

— Сез шахтага китәрсез дә.. өйләнерсез. Без нишләрбез соң, Габделхәй? Без дә бар бит әле дөньяда! — диде Җәмилә әкрен генә, әчке бер әрнү белән.

Беркайчан төшенкелеккә, күңел йомшаклыгына бирелми сыман тоелган Җәмиләнең тавышында каушау һәм шомлану сизелде. Габделхәй аның янында үзен ни өчендер гаепле саный башлады.

— Үз гомеремдә Сарапулдан ары барганым юк. Куркыта. Ничек барырсың Казанга, кемнәргә юлыгырсың... барысын да уйларга туры килә, — диде Җәмилә, үз алдына сөйләнгән шикелле. — Синең белән булсак, бергә-бергә күңеллерәк тә, җиңелрәк тә булырые.

— Шахта турында мин шаярттым, — диде Габделхәй, Җәмиләне тынычландырырга кирәк табып. — Мин инде нык уйладым: шахтага да китмәячәкмен, армиягә дә. Бары Казанга, университетка гына!

— Тормышта синең максатың бар, юлың бар, Габделхәй, — диде Җәмилә җиңел сулап. — Синең тәэсирдә, ахрысы, без дә Сәкинә белән үзебезгә юл ярмакчы булдык. Сәкинә нишләр, белмим. Мин барыбер медик булачакмын. Мин тырышачакмын. Җизнәй әйтте, ярдәм итәрбез, диде. Аңлы, акыллы кеше ул минем җизнәй.

— Шәп кеше ул синең җизнәң! — диде Габделхәй дә.

— Шахтага сине беркем мәҗбүр итә алмас, ләкин армиягә аласы булсалар, ничек котылырсың икән соң син, Габделхәй? — диде Җәмилә.

— Университетка керсәм, армиягә алмаячаклар, — диде Габделхәй. — Керү турындагы кагыйдәдә шулай дип язылган.

— Анысын мин дә беләм, — диде Җәмилә. — Безнең институтныкына да шулай дип язганнар. Ләкин сиңа иртәгә военкоматка барырга кирәк дисең! Әгәр шунда ук алып калсалар? Уйладыңмы шул турыда?

Мондый сүздән Габделхәй кинәт башына китереп суккандай булды. Чыннан да! Военкоматта күп сөйләшеп тормыйлар. Приказ диләр дә өзәләр дә куялар. Бу турыда нишләптер аның әле уйлаганы юк иде.

— Ничек инде?... Алай булмас... булырга тиеш түгел, — диде ул каушап, аптырап.

— Армия турында минем җизнәй әллә нәрсәләр сөйли, — диде Җәмилә. — Беләсеңме, көтеп ятарга ярамый сиңа. Нәрсәдер эшләргә кирәк!

— Бармыйча, качып калыргамы? — диде Габделхәй, көлеп.

— Көлмә! — диде Җәмилә. — Кирәк булса, качып та калырсың. Җизнәйләр янына барып киңәшеп карасак, ничек булыр икән?

— «Җизнәй» белән түгел, бәлки Василий Михайлович белән киңәшеп карарга кадыр? — диде Габделхәй уйланып. — Минем ишеткәнем бар: военкоматтагы капитан Зверев белән безнең Василий Михайлович әшнә икән.

— Василий Михайлович түгел, Антонина Семеновна әшнә капитан Зверев белән, бик беләсең килсә! — диде Җәмилә.— Капитан Зверевның хатыны — Ленинград марҗасы. Инәләре элек Антонина Семеновналар белән таныш булганнар, ди.

— Син каян беләсең аны? — диде Габделхәй, исе китеп. — Җизнәң әйттемени?

— Җизнәй дә әйтте, үзем дә беләм, — диде Җәмилә серле итеп.

— Кызык, син әллә нәрсәләр беләсең икән, — диде Габделхәй, күрәләтә мактау белдереп.

— Беләм. Син генә мине бер нәрсә дә белми дип йөрисең, — диде Җәмилә.

— Алай түгел лә инде, — дигән булды Габделхәй. — Алайса, мин Антонина Семеновна янына барам да әйтәм, шундый-шундый эшләр, Антонина Семеновна димен, капитан Зверев сезнең дустыгыз, танышыгыз икән, минем турыда бер-ике сүз әйтмәссезме димен...

— Юк, бара күрмә, Габделхәй! — диде Җәмилә туктап һәм баягыча кайнар кулы белән юлдашының беләгеннән тотып алды. — Син әле бер нәрсә дә белмисең икән, Габделхәй.

— Син беләсеңме? — диде Габделхәй үчекләшкән сыман.

— Беләм! — диде Җәмилә беркадәр күтәренкелек белән. — Антонина Семеновна сине яратмый. Ул безнең беребезне дә яратмый. Начар укыган өчен түгел, татар булган өчен, акцент белән сөйләшкән өчен яратмый.

— Син бераз арттырасың кебек, — диде Габделхәй уйчан гына. — Син үзең аны яратмадың, шуңа күрә ул сине, безне яратмый кебек тоела сиңа. Минем белән ул гел ягымлы сөйләшә. Миңа ул гел яхшылык теләде.

«Син әле Антонина Семеновна белән Василий Михайловичның рус теленнән сочинениене яңа баштан яздырганнарын белмисең. Белсәң, болай сөйләнмәс идең», — дип әйтәсе килде Габделхәйнең. Әйе, яздырдылар, төзәттерделәр, тик медален генә бирмәделәр.

## XIV

Габделхәйнең уйларын сизенгәндәй, Җәмилә кинәт тавышын әкренәйтә төшеп:

— Әйтимме бер нәрсә? — диде. — Ачуланмассыңмы?

— Гаҗәп, — диде Габделхәй, каушагандай итеп. — Нәрсә икән ул? Нишләп ачуланыйм мин сиңа — әйт...

— Рус теленнән сочинениеңне күчереп яздыңмы? — диде Җәмилә сорау алгандагы кебек.

Бу юлы инде Габделхәй туктап калды. Бу көтелмәгән яңалыктан ул кинәт телсез-өнсез калды.

— Син... каян белдең аны? — диде ул бераздан карлыккан бер тавыш чыгарып.

— Белдем инде, — диде Җәмилә җиңүче төс белән. — Минә, икенче минем белән уйлап сөйләшерсең. Бер нәрсә дә белми икән бу дип хаталана күрмә.

— Мин сине алай дип уйламыйм, — диде Габделхәй.

Җәмиләнең сүзләре, үз-үзен тотышы алдында аның мондый аклануы гына бик көчсез тоелды.

— Сатмасаң, мин сиңа барысын да сөйләп бирәм, — диде Җәмилә ашыгып. — Җизнәй әйтә, Габделхәйгә барыбер медаль бирмәсләрие ди. Ни өчен? Татар булган өчен. Аннан соң... синең әтәң бит... ни булган...

— Юк! — диде Габделхәй кызып китеп. — Ул бер дә «ни» булмаган! Аны аклаганнар! Ул сугыштан яраланып кайтты, яңадан китте, шунда ятып калды... батырларча һәлак булды, дип язуы килде!

— Мин анысын да беләм, — диде Җәмилә тыныч кына. — Мин бит әле бернәрсә дә әйтмәдем. Мин җизнәй әйткәнне генә әйтәм. Җизнәй әйтә, фронтта иң батыры татар булган. Ут эченә иң элек татарны җибәргәннәр. Шулай да «герой»ны да, орден-медальләрне дә күбрәк башкаларга биргәннәр.

— Сугыштан кайткан солдатлардан минем дә ишеткәнем бар андый сүзләрне, — диде Габделхәй. — Ләкин монда фронт түгел. Фронтта төрле ялгышлар, хаталар булырга мөмкин.

— Билләһи газим! Беләсең икән! — диде Җәмилә күрәләтә мыскыл белән. — Анда сугыш бетте. Сугыш хәзер монда бара. Сугышның тукталганы юк. Җизнәй шулай ди. Назиф шахтага китәргә мәҗбүр, сине армиягә алмакчы булалар, дисең. Авылларда — ачлык. Яшьләр, ирләр ничек тә читкә китәргә тырыша.

— Анысы миңа кагылмый, — диде Габделхәй. — Син әйтмәдең — сочинение турында каян белдең?

— Шуны да белмәгәч! — диде Җәмилә җиңел генә, күрәләтә өстенлек белән. — Халидә апа Әткенәавылныкы. Назифлар авылыннан. Халидә апаның авызында сүз тормаганлыгын белмисеңмени? Авылларына кайта икән дә, монда нәрсә булган, төкми-чәчми сөйләп китә икән.

— Сиңа Назиф әйттеме? — диде Габделхәй сизенеп.

— Әйтте, — диде Җәмилә. — Шигыреңә булышып син бер нәрсә дә күрмисең дә, ишетмисең дә. Ул турыда бөтен класс белә.

— Алай икән, — диде Габделхәй күңелсез генә.

Аңа оят, хурлык иде. Аның үләсе, каядыр югаласы килде. Ул үзенең кем янында баруын да, кая баруын да сизмәде. Аңа ул ничектер җир белән күк арасыннан шуып барган сыман тоелды. Менә сиңа алтын медаль. Менә сиңа укытучылар. Чыннан да, ул берни белми икән шул. Чыннан да, ул көтүдән аерылып калган бозау кебек икән. Фермада теге телчән Талия диган кыз шулай диган иде.

— Туктале, — диде ул бераздан, үзе өчен сер булган нәрсәне яңадан исенә төшереп. — Ничек болай була соң бу? Сочинениене мин хаталы язганмын. Мин әле дә хәтерлим — кызыл кара белән Антонина Семеновна минем хаталарны төзәтеп чыккан. Мин кызыл кара белән төзәткәнне яңадан язып бирдем. Чип-чиста итеп. Шулай булгач, сочинениедә бер хата да булмаска тиеш иде бит!

— Синең башта язганыңда бернинди хата булмаган. Алар юри, төзәткән булып, хата ясаганнар! — диде Җәмилә тантана белән.

— Юк, булмас! Ышанасы килми, — диде Габделхәй.

— Буласы булган инде, — диде Җәмилә. — Кая соң медалең — бирделәрме?

— Бу турыда мин күп уйландым. Василий Михайлович янына барам да, барысын да сөйлим дә бирәм! — диде Габделхәй кайнарланып.

— Син мине сатмаска булдың, — диде Җәмилә коры гына.

— Ярар, сине сатмам, — диде Габделхәй.

— Мине сатмасаң, Халидә апаны, Назифны сатачаксың. Эш зурга китәчәк, — диде Җәмилә.

— Мин беркемне дә сатмаячакмын! — диде Габделхәй үртәлеп.

— Шулай булгач, аның янына барып торасы да юк, — диде Җәмилә.

Алар станциягә барып җиттеләр. Вокзалда, перронда, халык арасында йөренделәр дә кире кайтыр якка борылдылар. Бу вакытта инде җир өстенә төн куна башлаган иде. Озак кына сүзсез баргач, яңадан Габделхәй үзен борчыган нәрсәгә әйләнеп кайтты.

— Миңа барыбер Василий Михайлович янына барырга, яхшылап сөйләшергә кирәк, — диде ул. — Медальне... онытыйк. Булмаган икән, булмаган. Миңа хәзер военкоматтан котылырга кирәк... шахтага китмәс өчен. Антонина Семеновна булышмаса, Василий Михайлович булышыр. Укытучым ич ул минем!

— Медаль алырга булышмаган кебек, монда да булышмаячак, — диде Җәмилә. — Хәзер аңа безнең кирәгебез дә юк. Аттестатын бирде, чыгарып җибәрде. «Йөз процент өлгереш» булды. Аңа шул җиткән. Синең белән минем өчен кемнәргәдер барып, соранып, вакыт уздырып йөрмәячәк ул. Син бит аның Рамусын кыйнагансың, хур иткәнсең. Оныттыңмыни? Рамус кына түгел, Халидә апа да, Василий Михайлович та бик ачулы сиңа, бик беләсең килсә, иптәшкәем!

— Карале, син чыннан да әллә нәрсәләр беләсең икән! — диде Габделхәй исе китеп.

Әйе, уңга карасаң да юк, сулга карасаң да юк. Дәүләтгәрәй абзыйлардан, Фәрхәнә апалардан башка, чыннан да, ярдәм итәрдәй, киңәш итәрдәй беркем юк икән шул.

— Әйтеп бетер — синең әле тагын әллә нинди яңалыкларың бардыр, — диде Габделхәй Җәмиләгә.

— Юк инде, җитеп торыр. Мине сөйләндерер-сөйләндерер дә көләрие бугай, — диде Җәмилә.

— Көлә торган түгел, җылый торган сүзләр бу, Җәмилә, — диде Габделхәй.

— Шулай шул, — диде Җәмилә дә.

Аның әле тагын «җылый» торган бер сүзе бар иде. Әйтәсе килсә дә, монысын ул әйтмәскә булды. Ул аны беркемгә дә әйтмәскә дип Назифка сүз бирде. Назиф аңа: «Миңа кияүгә чыгасыңмы?» диде. Әгәр риза булсаң, икәүләп китәриек шахтага, диде. Мин бит медицинскига укырга китмәкче булам, Назиф, диде Җәмилә. Булсаң ни! Өч-дүрт ел эшләрбез дә, өс-башны бөтәйтербез дә, акча тупларбыз да, икәүләп китәрбез Казанга — син медицина институтына, мин авыл хуҗалыгы институтына керербез, — диде Назиф. Берәр атна уйлыйм әле, диде Җәмилә. Аның ничек тә сузасы һәм Габделхәйнең хәлен беләсе килде. Габделхәй чынлап торып Казанга китсә, аның белән ул теләсә кая китәргә әзер иде.

Ләкин әнә аның да хәле шәптән түгел. Җәмилә, чыннан да, бер атна көтәргә булды. Габделхәй иртәгә военкоматта булгач, алар барыбер очрашачаклар бит!

Үзләренең урам яктагы агач бакчасы янында, капка төбендә аерылышканда Җәмилә шулай да тыела алмады — күңеле тулып җылап җибәрде һәм онытылып, кайнарланып, шагыйрь дустын кочагына алды.

— Сау бул! Армиядән котылып кал! — диде ул пышылдап.

Габделхәй төне буена уйланып чыкты. Күпме генә уйланмасын, берничек тә уеның очына-кырыена чыга алмады. Күзгә күренмәгән кешеләр белән, киләчәк язмыш белән тарткалашып, сугышып, бәргәләнеп ятты-ятты да искәрмәстән йокыга китте. Ул бик каты йоклады һәм иртән бөтенләй икенче кеше — сау-сәламәт һәм кайгысыз-борчусыз кеше булып торды. Бары тик көндәгечә барлы-юклы калдык-постык ризыкларны ашаштырып, тамагын туйдырган-дай иткәч, теләк тә, уй-фикерләр дә уянды һәм тынгы белмәс яшь җан яңадан талана башлады.

Бүген ул үз гомерендә бик зур эшләр башкарырга тиеш. Бүгенге көнне ул күптән, бик күптән көтте. Олы бәйрәм көткән кебек көтте. Бүген ул паспорт алачак. Бүген ул үзенең чын кеше, совет кешесе икәнлеген раслый торган документ алачак. Паспорты булган кешегә бу дөньяда яшәве мең рәхәт. Паспортлы, документлы кеше кая тели, шунда китә, эшкә керергә телиме, укырга керергә телиме — барысын да булдыра ала. Тик менә шагыйрь булырга теләгән кеше шагыйрь була ала микән, анысын әле ул бик үк белеп җиткерми. Паспортлыга Советлар иленең теләсә кайсы почмагына юл ачык. Шуңа да бит авыл кешесенә паспорт бирмиләр. Алар авылда яшәргә, иген игәргә, мал асрарга тиешләр. Паспорт бирсәң, алар аннан качышып бетәчәк, бөтен ил ач калачак. Тимер юллар эшләмәячәк, заводлар эшләмәячәк. Сугыштан соң җимерелгән авыл-шәһәрләрне торгызып булмаячак. Паспортны аны тиешле кешеләргә генә, башкалардан яхшырак һәм кирәгрәк кешеләргә генә бирәләр. Шахтага китсә, Назифка да бирерләр микән? Ул да бит авыл кешесе. Ярый әле ул, Габделхәй, авыл кешесе түгел. Яңавылда тумаса да, ул Яңавыл кешесе. Яңавыл — шәһәр тибындагы эшчеләр поселогы, дип атала. Димәк, Габделхәйне шәһәр кешесе дип тә әйтергә була икән. Кызык. Бик кызык. Әллә ничекләр бүлгәләнеп беткән бу кешеләр.

Милиция бүлеге урнашкан йортка җиткәнче Габделхәй шулай үз алдына масаеп, үзенең шәп кеше булуына куанып килде. Ләкин милиция йортына якынлашкач, адымы да әкренәйде, масаюлы, куанычлы уйлары да юкка чыкты. Күңеленә бер дә юктан шикшөбһә килеп керде һәм йөрәк турысында нидер борып, кымырҗытып үзенең барлыгын сиздерә башлады. Эче дә авырткандай булды. Тар һәм ярым караңгы коридорга килеп кергәч исә ул чын-чынлап курка башлады. Кемнән, нәрсәдән курыкканлыгын рәтләп төшенеп тә җитмәде, шулай да менә курыкты. Коридордагы тынлыктан, яктысызлыктан курыкты, бүрәнә стена буена тезеп куелган сынык-санык урындыклардан курыкты, каршыдагы тар, озынча ишектән курыкты. Дөресен әйткәндә, ишектән, урындыклардан да курыкмады — сораган нәрсәсен бирмәсләр, кире борып җибәрерләр, дип курыкты.

Дәүләтгәрәй абзый белән сөйләшкәннән соң ул инде монда булган иде. Ул чакта аңа әйттеләр, фото алып кил, диделәр. Фотосын алып килгәч, кирәкле язуга кул куярга начальниклары өйдә юк булып чыкты. Аны менә бүгенгә шушы вакытка чакырдылар. Юк, чакырмадылар. Шул көнне, шул сәгатькә килергә рөхсәт, диделәр.

Габделхәй таныш коридорга килеп кергәндә монда бер кеше утырып тора иде. Габделхәй аның ирме-хатынмы, яшьме-картмы икәнлегенә бөтенләй игътибар итмәде. Буш урындыкка килеп утырды да көтә башлады. Күпмедер вакыттан соң тар озын ишек ачылып китте, аннан кызарынган, чәчләре тузгыган бер агай килеп чыкты. Сөйләшеп тормыйча ул үз юлы белән китеп барды. Шуннан соң Габделхәй янындагы кеше дә урыныннан торды, көттереп, кирәгеннән артык тыйнак кыланып, тар ишекне ачты, нидер әйтте һәм керергә кыю-

лыгы житмичә, шул килеш кетеп тора башлады. Эчтәге яшь хатын-кыз ачуланып, түземсезләнеп: «Керегез!» — диде татарча. Теге кеше кереп китте, артына борылып ишеген япты — ябылып бетми калган ишек ярыгыннан Габделхәй аның шулай артына борылуын, ике куллап ишекне ябарга азаплануын күреп утырды. Ләкин үзеннән дә куркаграк бу бәндәнең ирме-хатынмы икәнлеген шулай да аера алмады.

Бу кешенең куркаклыгы Габделхәйгә кыюлык биргәндәй булды. Аннан соң көтеп утырган арада ул инде тынычлана төшкән иде бугай. «Ник куркам соң әле мин?» — дип уйлады ул, үз-үзен шелтәләп. Дәүләтгәрәй абзый сөйләшкән, фото бирелгән. Кире борып чыгарырга хәзер аның хакы юк. Нәрсә бу, нинди куркаклык бу? Шагыйрь буласы кеше, ун класс белеме булган кеше шундый куркак булырга тиешмени? Гел шулай начальниклар алдында кан калтырап төшә торган булсаң, киләчәктә ничек яшәрсең дә ничек эшләрсең? Әгәр без барыбыз да теләсә кем алдында куркып кала торган булсак, фашистларны ничек җиңгән булыр идек?! Куркак булса, Александр Матросов атып торган пулеметка каршы күкрәге белән каплана алган булыр иде микән? Менә бит ул эшләр кая таба бара, Габделхәй иптәш!

Уртасында зур гына өстәле булган кечерәк бүлмәгә килеп кергәндә ул, чыннан да, үзенең эчке каушавыннан котылган иде инде. Өстәл хуҗасы Вәсимә апа өченче ел унны бетергәч тә, милициядә эшләүче Галләмов абыйга кияүгә чыккан. Шуннан бирле менә шушында паспорт бүлегендә эшли. Вәсимә апаны Габделхәй ишетеп тә, күреп тә белә, хәтта яхшы белә. Вәсимә апа да аны белә булырга тиеш. Тик менә аның монда, бердәнбер тәрәзәсе тимер челтәр белән тотып алынган шушы бүлмәдә үзен элеккечә, кешеләрчә итеп түгел, ничектер коры һәм кырыс итеп тотуы гына гаҗәбрәк иде.

Габделхәйнең «исәнмесез»енә Вәсимә апа җавап та биреп тормады, яза торган язуыннан аерылып, башын да калкытып карамады. Габделхәй, Вәсимә апаның эше бетүен, үзенә күтәрелеп каравын көтеп, өстәл янында катып тик торды.

Ике колагында да борчак бөртеге кадәр генә алтын алка, түшендә бакыргач сыман ап-ак брошка ялтыраган Вәсимә апа, алдындагы калын дәфтәрне бер читкә этәрде дә, Габделхәйгә кырын күз белән генә карап:

— Утыр, — диде.

Габделхәй утырды һәм Вәсимә апаның һәрбер хәрәкәтен, һәрбер тын алуын күңеленнән кичереп, тыйнак кына көтә башлады. Вәсимә апа иелеп янындагы сейфтан язылмаган паспорт алды, калын дәфтәрен яңадан алдына җайлабрак куйды да, каләмен кара тушька манып, башын калкытмыйча гына сораулар бирә башлады: «Исемең, фамилияң ничек?» — диде.— «Кайсы елда, кайда тугансың?» — диде. Габделхәй ачык итеп әйтеп торды, Вәсимә апа туктамыйча язып барды.

Шулай ук башын калкытып карамыйча гына Вәсимә апа:

— Милләтең? — диде.

Бу сорауга Габделхәй беркайчан да тыныч җавап бирә алмады. Бу сорау исем-фамилия сораудан да, туган елыңны сораудан да кирәгрәк һәм әһәмиятлерәк иде. Бу сорау үзеннән-үзе горурлык та, сагаю һәм каушау да тудыра иде. Милләт турындагы сорауда кешенең җаны-рухы турындагы, атасы-бабасы һәм үзе белгән-аңлаган барлык уңай-кире яклары турында тулы мәгълүмат тупланган сыман иде. Бу сорауның монда, Яңавылда аның өчен тагын икенче бер мәгънәсе дә бар иде.

— Татар, — диде ул Вәсимә апаның соравына җавап итеп, ап-ачык итеп.

Вэсимэ апа язып куйды, паспортның бүтэн графаларын тутырып эшен бетергэч, Габделхэйгэ якынрак килергэ: кул куярга кушты hэм паспорт өчен фэлэн сум акча сорады. Акчасын алып, анысына да кул куйгач, өр-яңа катыргыны яшь җегеткэ тоттырды.

— Менэ, рэхэтен күр, — диде гади генэ, авылча гына итеп.

— Рэхмэт! — диде Габделхэй.

«Вэсимэ апа» дип өстэмэкче иде, эйтмэде, эллэ ошатмас, хэтере калыр, дип уйлады. Коридорга чыккач ул яктыга килде hэм миллэте графасындагы сүзлэрне укый башлады — кабинетта, өстэл янында утырганда аңа монда нэрсэдер шикле сыман тоелган иде. Аның шиге дөрес булып чыкты. «Татар» диясе урында аны «башкорт» дип язып куйганнар иде. Каушау, курку катыш сөенеч тойгысы хурлану hэм кимсенү белэн алышынды. Ишекне шакып-нитеп тормыйча, ул яңадан Вэсимэ апа янына барып керде.

— Мин бит «татар» дип эйттем, Вэсимэ апа — диде ул ризасызлык белэн, шулай да каты бэрелергэ кыюлыгы җитмичэ.

Вэсимэ апа беренче мэртэбэ күтэрелеп карады. Күзлэрен зур ачып, гаҗэплэнеп карап торды да:

— «Татар» булса ни, дэ «башкорт» булса ни, барыбер түгелмени? — диде.

— Барыбер түгел, — диде Габделхэй.

— Башкортстанда hэркем «башкорт» язылырга тиеш,— диде Вэсимэ апа, аңлатырга кирэк табып.

— Урыс та, удмурт, мари дамы? — диде Габделхэй, шаккатып.

— Татар турында сүз бара! — диде Вэсимэ апа. — Татар болай да күп.

— Төзэтеп языгыз, апа, — диде Габделхэй, бирешергэ телэмичэ.

Вэсимэ апа түшен киерэ төште hэм:

— Белэсеңме, энекэем? — диде ниндидер усалрак сүз эйтергэ җыенып. Шулай да эйтмэде, тыелып калды. — Паспорттагы язу төзэтелми, — диде тынычрак булырга тырышып. — Рэхмэт эйт тэ... эйдэ, алдыңнан артың!

Эйе, шулай диде. Габделхэй искэрмэстэн тукмалган, мэсхэрэ ителгэн кебек, кызарынып-бүртенеп чыгып китте.

Хэтер калу hэм күңел тырналуга караганда паспорт шатлыгы шулай да көчлерэк булып чыкты. Бер-ике сэгатьтэн инде ул Вэсимэ апасы бүлмэсендэ булган күңелсез сөйлэшүне оныта башлады. Үзүзенэ урын таба алмыйча базарда, станциядэ сугылып йөрде-йөрде дэ, инэсенең эшлэгэн җиренэ — балалар бакчасына юнэлде. Паспортны иң элек инэсенэ күрсэтэсе, аны сөендерэсе килде. Инэсе, чыннан да, бик сөенде.

— Менэ син дэ кеше булдың, улым, — диде буяу исе килеп торган яңа паспортны караштырып. «Татар» урынына «башкорт» язылуына аның эллэ ни исе китмэде. — «Башкорт» булуың эйбэт тэ булган эле. Читтэ урыс арасында кыерсытмаслар ичмасам, — диде.

Шуннан соң ул каядыр китеп барды, яңадан килде hэм тар гына почмактагы бэлэкэй генэ өстэлгэ җылы аш китереп куйды, аш янына «элүмин» кашык куйды.

— Аша иркенлэп, заф ронога китте, — диде.

Габделхэй иркенлэп тормады, алдына килгэнне күз ачып йомган арада ялт итеп куйды hэм шунда ук чыгып китэргэ дэ җыена башлады. Монда ул биш-ун минуттан артык торырга күнекмэгэн иде. Ул китэргэ дип кузгалгач кына, өстенэ ак халат кигэн юан повар үз кулы белэн сөтле кофе китереп бирде:

— Эч. Заф өйдэ юк, — диде ул да тынычландырып.

Паспортлы Габделхэй эчте, рэхмэт эйтте hэм чыгарга юнэлде. Инэсе озата чыкты.

— Дэүлэтгэрэй абыең белэн Фэрхэнэ апаңа да күрсэт инде пас-

портыңны, — диде ул. — Рәхмәт әйтергә онытa күрмә. Алар тырышты. Алар тырышмаса, булмасые.
— Әйтермен, — диде Габделхәй.

## XVI

Теге көнне Дәүләтгәрәй абзый белән Фәрхәнә апаның олы кунаклары таң алдыннан гына кайтып киттеләр. Дәүләтгәрәй абзый аларны ярты юл озата барды. Өчәүдән-өчәү генә калгач, олы кунакларның берсе — Нәҗия шундук эчендәгесен тышка чыгара башлады.
— Бу кадәр җебегән булсаң да булырсың икән, туганкаем!— диде Хәнифкә.— Ярый инде кеше алдында түзеп тордым, хәзер әйтәм, йөрәгем түзмәй — менә дигән кызны кулдан ычкындырдың.
Хәниф эндәшмәде, абыйсы эндәшмәде. Аларның эндәшмәвен үзенчә аңлап, Нәҗия аның саен узына бирде.
— Синең кебекләрнең инде укырга йөри торган балалары бар,— диде.— Кайчанга чаклы йөрмәкче буласың буй үстереп? Аның хәзер сына торган чагы, тотарга да сындырырга... Юк инде, ник телкәемне әрәм итеп сүләймендер? Ник шушыңа вакыт әрәм итеп йөримендер? Ул пагуннарыңны ник такканнардыр сиңа, туганкаем, шуңа да ярар җирең булмагач?!
— Нәҗия!— диде иптәш Бикчурин, янап.
— Нәрсә «Нәҗия»?— диде хатыны аннан да усалрак итеп.— Тумыштан бирле мин — Нәҗия. Сүздән тыймакчы буласыңмы? Тыймый тор! Син эчкәнне мин дә эчкән. Мин сиңа ялынып килгән калхуз персидәтеле түгел. Тыймый тор! Булмады бу, туганкаем. Шаулатып бер туй ясарбыз дип хыялланганыем, булмады бу.
— Нәҗия, җитте сиңа!— диде ире тагын да усалрак итеп.
Җиңгәсенең сүзләре Хәнифнең күңелен телеп-телеп алды, ачуын китерде. Шулай да ул авыз ачып бер сүз эндәшмәде. Ул үзен көчсез итеп, чыннан да җебегән һәм булдыксыз итеп тойды. Аның әле беркайчан мондый хәлгә тарыганы юк иде бугай. Шулай да өйгә кайтып башын мендәргә терәү белән ул шундук йокыга китте. Ул алай күп уйланып, юкка-барга йөрәк бозып яшәргә күнекмәгән иде.
Ул көнне алар көне буе диярлек йокладылар һәм бары кичке бишләрдә генә уяндылар. Юынгач, өстәл янына якынлашкан Исмәгыйль абыйсы белән иң элек баш төзәттеләр. Сөйләшмичә, артык сүз куертмыйча гына ашап-эчеп алдылар да, шуннан соң Хәниф төймәләрен ялтыратырга, күнитекләрен ышкырга-чистартырга тотынды. Шулай озаклап төзәнде-кырынды да, чистартынды, ялтыратынды да Фәрхәнә апаларга китеп барды.
Урам очындагы яңа өйгә бу юлы Хәниф бөтенләй үз кеше булып барып керде. Бусагадан атлау белән кычкырып сәлам бирде, хуҗаларның хәл-әхвәлен сорашты, Былбылны күреп, кайгыртучан төстә:
— Сәламәтлегегез ничек?— диде.
— Ярый, рәхмәт,— диде Былбыл тыныч кына һәм шундук күздән югалды.
Ялт итеп торган күнитекләрен шыгырдатып, матур хәрби фуражкасын кул очына тоткан килеш Хәниф кыю гына түргә узды.
— Баш авыртмыймы, Дәүләтгәрәй абый?— диде хуҗага, кичәгегә ишарәләп.
— Хикмәт, нишләптер беркайчан минем башым авыртмый, Хәниф,— диде Дәүләтгәрәй абзый.
Хуҗалар якты йөз күрсәттеләр. Фәрхәнә апа шундук табын әзерләргә тотынды, Дәүләтгәрәй абзый «өйдәгеләр»нең — ягъни иптәш Бикчурин белән Нәҗиянең хәлен белеште. Юк-бар сөйләнгәләп утырганда Хәниф күнегелгән гадәт белән чалбар кесәсенә тыгылды, портсигар чыгарды, папирос алды һәм портсигарын шарт-

латып япты да икенче кесәсеннән зажигалка эзләргә тотынды. Аның һәрбер хәрәкәтен күзәтеп торган Дездемона:

— Өйдә тәмәке тартырга ярамый. Чыгып тарт!— диде һәм абый кешенең кулындагы папиросына үрелде.

— Нәрсә? Нәрсә?— диде Хәниф аңламыйча.

— Өйдә тартырга ярамый!— диде Дездемона.

Бу вакытта Былбыл, тәрәзә төбендәге гөл савытларын күчергәләп, үзенчә тәртип урнаштырып йөри иде.

— Кара, нинди әдәпсез икән бу Диздекәй!— диде ул, кечкенә кызый өчен уңайсызланып.

Дездемонаның әдәпсезлегенә башкалар да игътибар иттеләр, шундук аны оялтырга тотындылар.

— Чорсызланма, кызым,— диде Дәүләтгәрәй абзый тыныч кына.

Фәрхәнә апа исә, беркайчан булмаган бер житезлек белән, тиз арада сөекле кызы янына килеп җитте һәм кулыннан әләктереп алып аны икенче якка алып чыгып китте.

Хәнифнең бүген күңеле күтәренке иде, мондый вак-төяк нәрсәләрне күрер хәлдә түгел иде.

— Мин бүген Былбылны танцыга приглашать итмәкче булам әле,— диде ул кулындагы папиросын әвәләп.

Барысы да тынып калдылар. Беркемнең дә беренче булып сүз әйтәсе килмәде. Бу, билгеле, бик четерекле мәсьәлә иде. Моны бары Былбыл үзе генә хәл итә ала иде.

— Үзе ни әйтә инде,— диде Фәрхәнә апа, елмаеп.

— Яшьләр арасына кысылып булмый,— диде Дәүләтгәрәй абзый да.

— Белмим шул,— диде Былбыл.

Аның бу «белмим шул»ы «мин риза» дигәнне аңлатты. Фәрхәнә апа моны шундук сизеп алды һәм ашыгып:

— Барыгыз, бар,— диде.— Болай да гел өйдә ятасың. Тансыларга йөрергә Йосыфның вакыты юк.

— Барыгыз әйдә,— диде Дәүләтгәрәй абзый да, ризалык белдереп.

— И чибәрттәй! Әйдә син дә!— диде Былбыл көтелмәгән бер куаныч белән.

— Әйдәгез!— дигән булды Хәниф тә.

Фәрхәнә апа көлеп кенә куйды.

— Бик соңга калмагыз,— диде ул шулай да кисәтеп.— Тансысы ошамаса, кинога керерсез. Өйдә ята торган чак түгел инде яшь кешегә. Безнең Йосыф кына ул һаман шул китабыннан аерыла алмый.

— Әйдә, Йосыф, син дә!— диде Былбыл китабыннан аерыла алмаган Йосыфка.

Йосыф «яшьләр» ягына күтәрелеп тә карамады, бары авыз эченнән нидер мыгырданып кына куйды. Габделхәй кебек, ул да Хәнифне өнәп бетерми иде. Яшьләр исә өйдәгеләрнең өнәвенә-өнәмәвенә карамастан, тиз арада җыенып, тиз арада чыгып та киттеләр.

Беренче кичне алар озак йөрмәделәр. Сталин клубында кино башланган, танцы булмаячак иде. Башкалар кебек, алар да тимер юл станциясенә таба юл тоттылар, юк-бар сөйләнделәр. Икенче көнне иртәрәк килергә, килгәндә кинога билет алып килергә сүз биреп, яшь лейтенант Былбылны өйләренә кадәр озатып куйды.

## XVII

Габделхәйнең күңеле гел Фәрхәнә апаларга тартып торса да, шулай да анда бару өчен аны нидер тоткарлап та тора иде шикелле. Габделхәй бу «нидер»нең нәрсә икәнлеген дә белде сыман. Шуңа

күрә анда бару өчен, һичшиксез, менә шул «нидер»не атлап чыгарга кирәк иде кебек. Паспорт алу аңа, әйтерсең, юл ачкычы бирде. Паспорт белән хәзер иркенләп Казанга китәргә, университетка керергә генә түгел, хәтта яңадан Фәрхәнә апаларга да барып керергә була иде. Шулай да, паспорт никадәр кыюлык һәм иркенлек вәгъдә итмәсен, Габделхәйнең күңелендә ямьсез бер тойгы торып калды. Ленин урамына килеп кергәч, әлеге ямьсез тойгы көчәя төште һәм аны инде паспорт шатлыгы да, ясалма горурлык та — берни дә җиңә алмас төсле иде.

Менә ул ерактан ук нурлар балкытып утырган таныш өйнең таныш капкасы янына килеп җитте, капканы ачып ишегалдына керде һәм никтер карыша башлаган аякларын авырлык белән генә атлап, баскычка якынайды. Нәкъ шул чакта ул алар белән очрашты.

Өстенә ачык төстәге җиңел, сихри күлмәк кигән, чәченә зур итеп, күбәләк канаты сыман итеп ак тасма бәйләп куйган Былбыл, бик зур куанычлы бар кеше сыман, коштай очынып баскычтан төшеп килә иде. Аннан беркадәр калышып, погоннарын, китель төймәләрен, күкрәгендәге гвардия значогын елтыратып озын буйлы чибәр лейтенант килә иде. Югарыда, баскыч өстендә тагын кемнәрдер бар иде — болары Дәүләтгәрәй абзый белән Фәрхәнә апа булды, ахрысы. Алар яшьләрне озата чыкканнар иде бугай.

Гөнаһ шомлыгына, Былбыл белән алар тар баскычта очраштылар, бер-берсенә орынып киттеләр. Былбыл, үзе дә сизмәстән, «а!» дип кычкырып җибәрде, учы белән авызын каплады да йөгереп тышка чыгып китте. Габделхәй юл биреп, читкә тайпылып калды. Үзе яныннан җиңүче төс белән узып киткән лейтенантны әллә күрде, әллә күрмәде — күз алдын томан каплады, аяк астындагы бар нәрсә тирбәлә, чайкала башлагандай булды.

Берзаман ул кайдадыр ерακта, нинди дер калын койма артында кемнеңдер: «Габделхәй»,— дигән тавышын ишеткәндәй булды. Бик авырлык белән генә башын калкытты. Аның каршысында гына, бер-ике басма өстәрәк, Фәрхәнә апа басып тора иде, ул аңа нидер сөйли, нидер аңлата сыман иде. Габделхәйнең күңелен: «Минем аның белән очрашканны ул күреп торган!»— дигән бер уй өтеп алды. Фәрхәнә апа алдында ул үзен нидер урлап тотылган сыман хис итте. Аның моннан тизрәк качасы, ирекә, иркенгә чыгып китәсе килде. Хәер, аны инде күрделәр. Аның турында өйдәгеләр дә, тегеләр дә барысын да белделәр. Хәзер инде качсаң да, качмасаң да, барыбер түгелмени?!

Фәрхәнә апаның ягымлы итеп эндәшүенә буйсынып, ул култыксага тотынды һәм әкрен генә атлап югары менде. Фәрхәнә апа һаман нидер сөйләнде, нидер аңлатты, ләкин Габделхәй әле булса берни аңлый алмады.

Өй эчендә беренче булып Дәүләтгәрәй абзый очрады.

— Әйдә, түрдән уз, Габделхәй,— диде ул сузып.

Кулларын җәеп, ямьсез чырылдап Дездемона килеп җитте, чандыр беләкләре белән аны кочып алды.

— Югалган мал, кайда йөрисең?— диде ул шырык-шырык көлеп.

Фермада «бозау» дип атадылар, монда — «югалган мал», дип уйлады Габделхәй үзе турында.

— Фидәил өйдәме, ыштаны чөйдәме?— диде телмәт Дездемона, туктаусыз тәтелдәп.

Габделхәй ирексездән елмаеп җибәрде. Башкалар да тыелып кына көлемсерәп алдылар, ләкин шул ук вакытта әдәпсез кызыйны оялтырга да тырыштылар.

— Кит, бәйләнмә Габделхәй абыеңа!— диде Фәрхәнә апа.

— Чорсызланма, кызым,— диде Дәүләтгәрәй абзый.

— Мин «кызым» түгел, мин — Диз-де-муна! — диде кызый, кыланып.

Тәрәзәгә, яктыга якын килеп өстәлнең бер башында Йосыф китап укып утыра иде. Тавыш-тынсыз гына Габделхәй Йосыф янына килде, шундагы бер урындыкка утырды.

— Син укыйсың да укыйсың икән,— диде ул.

— Син укымыйсыңмы? — диде Йосыф.

— Юк,— диде Габделхәй.

— Безнең Габделхәйнең хәтере яхшы аның,— диде Дәүләтгәрәй абзый.

Габделхәй аның шулай салпы якка салам кыстыруын яхшы аңлады, шулай да мактау сүзеннән җиңелрәк булып китте кебек.

— Синең әле онытылып та бетмәгәндер, Габделхәй,— диде Фәрханә апа да җайлап кына сүзгә кушылып.

— Онытылырлык вакыт та үтмәде бит әле, Фәрханә апа,— диде Габделхәй.

Өстәлдәге самавыр чыжлап утыра иде, савыт-саба җыештырылмаган иде. Әллә соң хуҗалар ашарга да утырмаганнар иде микән? Фәрханә апа, ягымлы елмаеп, Габделхәйгә якынрак килергә кушты.

— Әйдәле, Габделхәй, утыр әле,— диде.

Габделхәйнең ашарга утырасы килмәде. Ул үзенең килгән саен монда ашка-суга юлыгуын исенә төшерде. Бүгенгесе өчен генә түгел, элеккеләре өчен дә аңа оят, бик нык оят булды. «Юри ашаган чакта гына килеп керә дип уйлыйлардыр әле!»,— диде ул күңеленнән үз-үзен шелтәләп. Хәзер ул монда беркемгә, бернигә карата якынлык һәм күңел җылысы тоймады. Тиз арада аның моннан чыгып китәсе килде, чыгып китте исә, беркайчан да бу өйгә килү түгел, хәтта әйләнеп тә карамас иде шикелле тоелды. Монда ул һәркайда, һәр нәрсәдә үзенә хыянәт иткән җилбәзәк кызны күргәндәй булды. Ул да... кыз да аны күрәдер сыман, никтер аннан көләдер сыман тоелды. Юк, ул үзе генә түгел, җиз төймәле лейтенант белән бергәләп көләләрдер сыман тоелды. Дәүләтгәрәй абзый белән Фәрханә апаның, шундый акыллы кешеләр була торып, күптәнге дуслар-танышлар була торып, нинди дер Уфа кызыннан аны мыскыл иттерүләре инде берничек тә аңлашылмый иде.

— Мин паспорт алдым, Дәүләтгәрәй абзый... Фәрханә апа,— диде ул сүзгә башлап.— Бик зур рәхмәт инде сезгә. Сез булмасагыз, мин аны гомеремдә дә алалмаган булырыем. Инәкәй дә шулай диде. Рәхмәт әйт, диде.

Бөтенләй кирәкмәгәндә «инәкәй»не искә төшерү өчен аңа кинәт оят булып китте. Әйтерсең, рәхмәтне ул инәкәсеннән башка әйтә белми! «Шагыйрь, имеш! Җебегән! Рәтләп кешечә сөйләшә дә белмисең!» — диде ул күңеленнән үз-үзен мыскыл итеп.

— Яхшы булган, Габделхәй,— диде Дәүләтгәрәй абзый.

— Менә, син дә кеше булдың,— дип куйды Фәрханә апа.

— Инәкәй дә шул ук сүзләрне әйтте,— диде Габделхәй.

Аңа тагын оят булды. «Үзеңнең фикерең дә юкмыни? Инәкәң сүзләрен генә кабатлыйсыңмыни хәзер?» — диде ул үз-үзенә.

— Дөньяда иң кирәге — паспорт,— диде Дәүләтгәрәй абзый.

Дәүләтгәрәй абзый шулай ук: «Иң кирәге — акча»,— дияргә дә ярата иде. Аның мондый сүзләрен Габделхәй инде берничә мәртәбә ишеткән иде. «Кайсысы кирәгрәк соң — акчамы, паспортмы, Дәүләтгәрәй абзый?» — дип әйтәсе килде аның кисәк кенә. Ләкин күңеленә килгән уен сүзгә әйләндерә алмады — олы кеше, хуҗа кеше белән бәхәсләшү, аның йөзен ерту оят эш, хурлыклы эш булып тоелды. «Ярар, саубуллашам да, чыгып китәм»,— дип уйлады ул урыныннан кузгалып.

— Ярый, мин китим инде,— диде.
— Утырмадың, Габделхәй,— диде Фәрхәнә апа.
— Утырдым. Рәхмәт,— диде Габделхәй.
Шулай диде дә кинәт кызарынып куйды. Аңа хәзер үзенең сүзләре, сөйләшү рәвеше ошамый башлады. «Шуны аңлатып торалармыни?!»— дип уйлады ул янә үз-үзен түбәнсетеп.
— Башка документларың әзерме соң, Габделхәй? Кайчан китәргә җыенасың?— диде Дәүләтгәрәй абзый.
«Документлар» турында сүз чыккач, Габделхәй тагын үзе дә сизмәстән йомшаклык күрсәтте.
— Военкоматтан повестка килгән бит әле миңа, Дәүләтгәрәй абзый, Фәрхәнә апа,— диде.
Бу турыда монда берни әйтмәскә, дип ул инде күңеленә беркетеп куйган иде. Повестка турында әйтсә, бу, һичшиксез, Дәүләтгәрәй абзыйдан ярдәм үтенү һәм шул рәвешчә яңадан ялыну, түбәнсенү булыр сыман иде. Үзенең чын кеше, паспортлы кеше икәнлеген, үз язмышын үзе хәл итә ала торган, теләсә нинди хыянәтчеләрдән, коры куык калай этәчләрдән өстен кеше икәнлеген исбат итү өчен, әлбәттә, горур һәм бәйсез булып калырга кирәк иде. Менә алай була алмады. «Җебегән! Булдыксыз!»— диде ул үз-үзенә үртәлеп.
— Шулаймыни?— диде Дәүләтгәрәй абзый.— Кайчан барырга? Укырга алмакчы булалар микән әллә?
— Ленинградка, военно-морской училищега алалар икән,— диде Йосыф китабыннан башын калкытып.
«Кара! Нинди белемле!»— дип уйлады Габделхәй яратмыйча.
— Каян ишеттең соң әле син аны?— диде Дәүләтгәрәй абзый Йосыфка.
— Рамус әйтте, аңа этисе әйткән,— диде Йосыф.
«Кабахәт! Һаман шуның белән дуслашып йөргән була!»— дип уйлады Габделхәй Йосыф турында.
— Безнең ышкулдан да бер малай шунда китмәкче була!»— диде Йосыф, китабыннан күзен алмыйча гына.
— Безнең Назиф та шахтага китә икән әле,— диде Габделхәй, бөтенесен шаккатырмакчы булып.
Чыннан да, Назифның шахтага китүе Йосыфның хәбәреннән тәэсирлерәк булып чыкты. Дәүләтгәрәй абзый такыр башын кашып куйды, Фәрхәнә апа өстәл янында нидер эшләвеннән туктап калды һәм «тагын нәрсә әйтер икән бу?» дигән сыман көтеп тора башлады.
— Япь-яшь көе... нинди шахта инде ул балакайларга?!— диде Фәрхәнә апа, Назифны кызганып.
«Назифны кызгана, мине кызганмый»,— дип уйлады Габделхәй Фәрхәнә апа турында.
— Мин дә китәрием әле. Ленинградка,— диде Йосыф.
— Бар, минем өчен кит алайса,— диде Габделхәй.
Үзенчә ул моны усал итеп әйтәм, дип уйлады, ләкин тавышы бер дә усал булып чыкмады. Йосыф аны әллә ишетте, әллә ишетмәде — һаман шул үзенең «физика»сына төртелеп утырды.
— Урман кисәргә бару түгел инде ул, Габделхәй,— диде Дәүләтгәрәй абзый Йосыф өчен җавап биреп.

— Авиационный институтка китәргә җыенучыларның берсен дә алмаячаклар, алар болай да военный булачаклар дип әйткәннәр...— диде Йосыф.
«Мактана. Янәсе ул авиационныйга әзерләнә. Ул гына шәп кеше»,— дип уйлады Габделхәй.
— Алай икән,— диде Дәүләтгәрәй абзый.— Син, Габделхәй, бер дә кайгырма. Җайларбыз. Военкомат әллә кайда түгел — үзебездә генә, Яңавылда.

«Рәхмәт инде!— дип уйлады Габделхәй киреләнәсе килеп.— Син гел җайларга күнеккәнсең, Дәүләтгәрәй абзый. Анда җайла, монда җайла. Болай да хәерче кебек күп теләндем сезгә. Моннан соң үзем сөйләшәчәкмен. Аяк терәп. Мин дә... кеше!»

Күңеленнән ул шулайрак дип уйлады, ләкин өйдәгеләр белән саубуллашканда шулай да тавышы зәгыйфь һәм мескен булып ишетелде.

— Сау булыгыз,— диде ул, ишеккә юнәлеп.

— Сау бул, Габделхәй,— диделәр аңа.

Фәрхәнә апа хәтта баскыч төбенә кадәр озата чыкты. Габделхәй, артына борылып карамыйча, алпан-тилпән атлап китте. Ябылып җитмәгән яңа капка, аптырап, моңаеп артыннан карап калды.



## XVIII

Көтмәгәндә Габделхәй белән очрашкач, Былбылның күңел күтәренкелеге кул белән алгандай юкка чыкты. Хәни кә ул әз генә дә каршы да килмәде, юкка-барга киреләнмәде дә, шул ук вакытта аның белән ачылып, рәтләп сөйләшә дә алмады. Башын иеп, уйланып, күңелсез бер кыяфәттә янәшәдән атлап тик барды. Тиз арада җиңүгә ирештем дип хаталанган һәм шунлыктан башы-күзе әйләнә башлаган яшь лейтенант андагы бу үзгәрешкә бөтенләй игътибар итмәде. Ул моны кызларга хас бер оялчанлык кына дип белде. Юл буена Хәниф, кызның күңелен табам дип уйлап, башыннан кичкән кызык хәлләр турында сөйләде.

Икәүләп алар Сталин клубына бардылар, тансыга керделәр, бер сәгать чамасы әйләнгәләделәр дә яңадан урамга чыктылар һәм әлеге дә баягы станция ягына юнәлделәр. Хәнифнең төне буе йөрисе, урам таптыйсы һәм сөйлисе, мактанасы килде. Былбыл ярты юлдан ук кайту ягына каера башлады. Бары шул чагында гына Хәниф кызның бүген ул үзе уйлаганча ук ягымлы һәм якын түгеллеген чамалап алды. Бу, билгеле, аның кытыгына тиде. Алар кинәт сөйләшмәс-эндәшмәс булдылар.

Еракта чибәрттәләренең таныш йортлары күренгәч, Былбыл кызулый төште.

— Әллә янамы?— диде Хәниф.

— Әлегә янмый бугай,— диде Былбыл.

— Шулай булгач?— диде Хәниф.

— Арттан куа киләләр түгелме соң?— диде Былбыл күрәләтә мыскыл итеп.

— Сез һаман көләсез,— диде Хәниф.

— Озатып куюыгыз өчен рәхмәт. Мин кайтып җиттем,— диде Былбыл, туктап калып.

— Кайтып җитәргә әле тагын йөз дә илле бер адым калды!— диде Хәниф.

— Илле бер адым гына,— диде Былбыл.

— Юк, йөз дә илле бер адым!— диде Хәниф.

— Хушыгыз. Рәхмәт,— диде Былбыл урыныннан кузгалып.

— Болай булгач, мин сезне тоткарларга мәҗбүрмен,— диде Хәниф кызның беләгеннән тотып.

— Алайса, болай килешик: бер метр гына барыгыз да, калган иллесен үзем генә кайтырмын,— диде Былбыл, артык каршылык күрсәтмичә.

Алар тагын кузгалып киттеләр һәм шулай килде-китте сөйләнеп, таныш капка янына килеп җиттеләр.

— Соңгы кат сезгә рәхмәт. Мин кайтып җиттем,— диде Былбыл, капка тоткасына үрелеп.

— Мин сезне кертмим,— диде Хәниф, кызның юлына аркылы төшеп.

— Алайса мин кычкырам — өйдәгеләр чыгып алырлар,— диде Былбыл.

— Торыйк әле,— диде Хәниф үтенеп, хәтта ялварып.— Әллә ничек кенә булды. Сөйләшәсе сүз дә бар иде. Сөйләшеп тә булмады.

Ул тагын аның кулыннан тотып алды һәм каушаган-кабаланган хәлдә аны үзенә таба якынайта барды.

— Тотынмагыз миңа!— диде кыз читкә тартылып.

— Ягез инде? Ул кадәр усал булмагыз инде?..— диде Хәниф, серле пышылдап.

— Юк, юк!— диде кыз.

Аның тәне уттай яна, калтырый башлады. Ул үзенең серле тавыштан йомшый башлавын тойды. Аның ачуы килде, ләкин үзен мәҗбүр иткән, ихтыярын биләп алган көчкә, вәсвәсәгә каршы торырга нишләптер кыюлыгы җитмәде. Яшь лейтенант аны якынрак китерде, искәрмәстән кочып алды, үбеп алды.

Кызның кинәт башы әйләнде, аяк астындагы каты җир чайкалып китте. Күпмедер вакыттан соң, ул, ниһаять, җирне тойды, исенә-акылына килде. Якында гына ул ниндидер чит кеше барлыгын күрде, аның каты, тупас кулын, калай төймәле киемен тойды. «Ни хакы бар аның?!»— дип уйлады ул нәфрәтләнеп. Ташып чыккан ачуына ирек биреп, ул каты кулны, каты киемне төртеп җибәрде. Хәниф чак-чак кына читкә авышты, аптырап китте. Авызын ачып ни дә булса әйтеп өлгергәнче, янындагы кыз юкка да чыкты.

Урам капкасы кебек үк, чолан ишеге дә эчтән бикләнмичә калдырылган иде. Былбыл атылып ишектән керде, келәне эчке яктан бикләп куйды һәм, еш-еш тын алган хәлдә, бераз вакыт тыңлап торды — тышта бернинди тавыш ишетелмәде. Былбылның урыны чолан якка җәеп куелган иде. Өйдәгеләрне уятмаска тырышып, ул мыштым гына үз урынына кереп ятты.

Берзаман, яңа көн тууын белдереп, әкрен генә таң ата башлады. Ишегалды чүмәләдәй булып, тир исе, сөт һәм сыгрыйк исе аңкытып яткан олы сыер, таң атуын, һава алышынуын сизеп, уфылдап, пошкырып куйды. Лапас эчендәге әтәч, йокымсыраган тынлыкны бозып, шаулатып кычкырып җибәрде. Аңа җавап итеп, әле бер якта, әле икенче якта бүтән әтәчләр кычкырды. Тимер юл станциясе ягындагы паровоз тавышлары тоныграк, көчсезрәк булып ишетелгәндәй булды. Кәтмәгәндә авыр-авыр басып, такталарны шыгырдатып, Дәүләтгәрәй абзыйның тышкы якка чыгып баруы ишетелде. Аннан соң күп тә үтмәде, Фәрхәнә апа да торып тышка чыкты. Буш бидрәгә чыжлатып якында гына сыер сауган тавыш ишетелде.

— Капка бүген ябылмый калган икән,— диде җизнәй, йокылы тавыш белән.

Шуннан соң берни ишетелми башлады. Былбыл, тынычланып, көтелгән йокыга чумды.

Йокыдан ул бик соң торды. Җизнәй инде күптән эшкә киткән, Йосыф шулай ук каядыр китеп барган. Өйдә бары чибәрттәй генә калган да, аннан соң Дездемона әле булса йокы симертә иде бугай. Ашаганда да, аштан соң да Былбыл рәтләп сөйләшмәде. Ул сөйләшмәгәч, Фәрхәнә апа да төпченмәде.

Ашап туйгач, кунак кызы ашыгып автовокзалга китте. Ләкин инде соңга калган булып чыкты. Уфага дигән автобус китеп барган, икенчесе бары кичкә генә булачак иде. Былбылның кәефе кырылды. Аның хәзер үзе генә Яңавыл урамнарында йөрисе килмәде. Буш урамнардан китеп барды исә, кирәкмәгән кемнәрдер очрар, ямьле көннең ямен җибәрер шикелле тоелды. «Кичке автобуска билет ал-

ганчы шушында торам»,— дип уйлады ул һәм өченчеме-дүртенчеме кеше булып чиратка басты.

Шулай бер ярты сәгать чамасы басып торгач, көтмәгәндә автовокзал янынарак көлсу төстәге өр-яңа «Победа» килеп туктады. Өлкән яшьләрдәге шофер, ишекне яртылаш ачып:

— Кем Уфага?— диде.

Башкаларга караганда Былбыл машинага якынрак тора иде.

— Мин — Уфага! Мин!— диде ул ашыгып һәм тиз генә шофер янына килеп тә җитте. Касса янындагы башка кешеләр урыннарыннан кузгалмадылар. Кабинада, арткы урында юан гына, олырак кына б р хатын-кыз утыра иде. Шофер Уфага кадәр күпме түләргә кирәк булачагын әйтте. Былбыл берсүзсез риза булды.

— Әйберләрең кая? Әйберләрең бармы?— диде шофер, үзара килешенгәч.

Былбыл үзенең кайсы урамда, ничәнче йортта торуын әйтте. Шофер, киңәш сораган сыман, арттагы хатынга борылып карады. Хатын үзенең ризалыгын белдерде.

— Әйдә, утыр менә бу яктан,— диде шофер.

Былбыл, урталай бөгелә төшеп, кабинага, йомшак урынга кереп утырды. Машина кузгалып китү белән ул үзен иркендә, Яңавылдан читтә һәм еракта итеп тойды. Аңа бераз гына моңсу-ямансу булып китте. Кабина тәрәзәсе аша күренгән йортларга, кешеләргә ул хәзер бөтенләй икенче күз белән, икенче уй-теләкләр белән карады. Аңа хәзер шулай кисәк кенә бөтенесеннән аерылып, киселеп китү, шушы таныш урамнарны, йортларны, күк йөзен һәм шушы яктылыкны ташлап китү бик авыр, бик кыен булып тоелды. Шул ук вакытта аның бу урамнардан, бу йортлар арасыннан тизрәк чыгып китәсе һәм тирә-ягында бары тик иген басулары, урманнар, болыннар гына булган киңлеккә, иркенлеккә барып җитәсе килде.

Военкомат турысына якынлашканда, юл читеннән башын иеп барган Габделхәйне күргәч, ул сискәнеп китте. Габделхәй военкомат ягыннан базар ягына таба китеп бара иде. Аның йөзе боек һәм кайгылы сыман тоелды. Югалган бик кадерле нәрсәне искә төшергән чактагы сыман, яшь кызның күңелен сагыш һәм әрнү тойгысы телеп алды.

«Победа» кинәт туктап калды. Алар Фәрхәнә апаларның капка төпләрендә тук ап торалар иде. Былбыл ашыгып кабинадан чыкты, капкадан керде һәм йөгереп диярлек ишегалдын үтте дә атылып өйгә барып керде. Аның сулуы капты, аяк-куллары хәлсезләнде.

Куркып, шундук аның каршысына Фәрхәнә апа килеп җитте. Ул, ахрысы, аның «Победа» белән кайтып керүен тәрәзәдән күреп торган иде.

— Ни булды?— диде ул.

— Мин кайтып китәм, чибәрттәй!— диде Былбыл кабаланып һәм тыела алмыйча җыларга тотынды.

— Райком машинасы бит ул! Иптәш Сафинныкы,— диде Фәрх нә апа, коты алынып, әйтерсең, Былбылның кайтып китүенә шул машина гына гаепле иде.

— Кайтып китәм. Уфага, чибәрттәй,— диде Былбыл тыңламыйча һәм ашык-пошык кием-салымнарын җыештыра башлады.

— Нинди эш соң әле бу?— диде Фәрхәнә апа, нишләргә дә белмичә.— Ничек утыртасы иттеләр?

— Ачуланма инде, чибәрттәй. Шулай туры килде,— диде Былбыл яшь аралаш.

Фәрхәнә апа, олны кулларын алъяпкыч итәгенә сөрткәләп, әле кече якка чыкты, әле олы якка чыкты, тәрәзә янына килде.

— Галия апа. Сафинның хатыны,— диде ул үз алдына сөйлән-

гән сыман.— Кием кистерергә дә, чәч төзәтергә дә Уфага йөри икән, дип сөйлиләрие — дөрес икән. Нишләп болай булды соң әле бу?

Былбыл, анысын анда орып, монысын монда орып, үз әйберләрен эзләп тапты, чемоданын тутырды, җылады, яшь аралаш көлеп чибәрттәсен юатты. Шул ук вакытта башын иеп барган Габделхәйне дә уйлады. Бүә буендагы кояшлы көнне, кичүне, хуш исле болыннарны, су керүләрне уйлады. Чемодан капкачын бик нык басып, беравык аны ябарга азапланып карады, ләкин капкач нишләптер ябылмады. Капкачны ачып караса, нәрсәнеңдер тышкы якка чыгып, кысылып калганлыгын күрде. Капкачны яңадан япты да, чертләтеп бикләде дә, көчкә күтәреп-өстерәп ишеккә таба атлады. Нәкъ шул чакта шофер килеп керде.

— Буламы, кызым?— диде.

Чемоданны җиңел генә күтәреп, шофер кире борылды. Шофер белән Былбыл аллы-артлы баскычтан төшеп барганда аларны Фәрхәнә апа куып җитте. Былбылның кулына зур гына төенчек тоттырды.

— Әллә ничек кенә булды бит әле бу,— диде һаман тынычлана алмыйча.

— Ачуланма инде, чибәрттәй,— диде Былбыл сулкылдап.— Кайткач та хат язармын.

— Сәлам әйт инде... күп итеп... барысына да,— диде Фәрхәнә апа.

Капкадан чыкканда аның күңеленә бер уй килде.

— Сорасалар, нәрсә әйтермен соң?— диде ул.— Берәр сүз әйтимме синнән?

— Юк, юк, берни әйтмә!— диде Былбыл.

— Габделхәйгә? Йосыфка?— дигән булды Фәрхәнә апа.

— Аларга да... әйт...мә...— диде Былбыл, буталып.— Сау бул, чибәрттәй. Хуш, сау бул, хат язармын.

Шофер чемоданны артка, багажникка куйды, багажник капкачын япты, бикләде дә үз урынына кереп утырды. Былбыл алга, шофер янына утырды. Тәрәзәдән капка төбендәге Фәрхәнә апага кул болгады, кош теледәй кулъяулыгы белән күзен сөртеп алды.

Тын урамда янган бензин исе калдырып, көлсу төстәге машина җиңел генә кузгалып китте һәм озакламый күздән югалды.

## XIX

Военкоматтан, капитан Зверев яныннан чыккач, балтасы суга төшкән сыман башын иеп кайтып килгәндә Габделхәй үз яныннан «выжт!» иттереп узып киткән «Победа»га игътибар итмичә булдыра алмады. «Победа»лар Яңавылда күп түгел, көл төстәгесе, яңасы бары бер генә кешедә — район патшасы иптәш Сафинда гына.

Ихтыярсыздан Габделхәй машинага карады һәм андагы кешеләрне күреп алды. Моннан берничә көн элек кенә өзелеп, сагышланып уйлаган, үләрдәй булып күрәсе килгән теге кызны күреп алды. Ләкин үзе теләгәнчә, үзе өмет иткәнчә ягымлы, аңлаешлы һәм дус кызны түгел, бәлки чит һәм дошман, хыянәтче кызны күрде. Кичәгенәк теге лейтенант белән бергәләп баскычтан төшеп килгәндә ул әле башка кызлар кебек җилбәзәк кенә сыман тоелган иде. Аны әле күпмедер дәрәҗәдә аңлап та, аңа карата нәфрәтләнеп тә була иде кебек. Бүген, хәзер өр-яңа «Победа»да утырып барган кызны инде аңлап булмый, аңа шулай ук ачуланып, нәфрәтләнеп тә булмый сыман иде. «Победа»га теләсә кемнәр утыра алмый. «Победа»га бары шәп кешеләр — ике аяклы, ике куллы кешеләргә охшамаган, махсус рәвештә сайлап алынган, сайлап куелган һәм кара халык өстеннән хакимлек итәр өчен яратылган

аксөякләр генә утыра. Алар шулай узучы-баручыларга йөзләрен дә ныклап күрсәтмичә, тузан туздырып, «выжт!» иттереп узып кына китәләр. Машинадан төшкәч, алар аерым кабинетларда утыралар, боералар, кушалар, өйрәтәләр һәм, әлбәттә, һәр көнне туйганчы ипи ашыйлар, итле аш ашыйлар, кайнар бәрәңге белән салкын катык ашыйлар, ямаусыз яхшы ботинкалар, күнитекләр, шәп кительләр, затлы күлмәкләр кияләр. Алар таза, чибәр һәм итләч булалар. Андыйлар белән кешечә сөйләшеп-аңлашып та, дуслашып-яратышып та булмый. Кая ул! Аларга хәтта ялгыш кына кагылып китсәң дә, алар сине чәйнәп бөркергә әзер. Алар шулай икән, син дә шулай.

«Мескен, мескен!.. — дип уйлады ул бераздан, үз-үзен битәрләп. Сиңамы соң алар белән булышу, андыйлар турында хыяллану?! Оныт син аны... аларны...»

Ул онытты. Юк, онытып ук бетерә алмады. Тик шулай да барлык хис-тойгысын, аңын-ихтыярын богаулаган сихри, тылсымлы көч күз алдында юкка чыккандай булды һәм ике арада биек киртә булып читләшү һәм дошманлык барлыкка килде. Үзеннән, үзе кебек үк барлык өлешсезләрдән, ач-ялангачлардан өстәрәк, югарыдарак торган һәммә тукларны, байларны, боеручыларны ул җене кебек күрде. Андыйларга карата аның күңелендә һәрвакыт кискен каршылык һәм кыргый бер кирелек тойгысы яшәде. Аларны ул гафу да итә алмады, алар белән килешүгә дә кερә алмады.

Менә әле дә ул шундыйларның берсе янында булып чыкты. Чиртсәң кан чыгарлык кызыл йөзле, таза һәм зур гәүдәле капитан Зверев кабинетына ул, паспорт бирүче Вәсимә апа кабинетына керер алдыннан булгандагы кебек, тыелгысыз каушау һәм курку тойгысы белән керде. Военкоматка килгәндә юл буена сүземне русча рәтләп сөйли алмам, фикеремне русча дөрес итеп аңлата алмам, дип борчылды. Ярый әле түш кесәсендә яңа паспорты бар иде — шул гына әзме-күпме кыюлык һәм үз-үзенә ышаныч тойгысы биргән сыман булды.

— Мухутдинов, без сезне Ленинградский военно-морской училищега укырга җибәрәбез. Әзер булып торыгыз,— диде көр тавышлы капитан Габделхәйгә беренче сүзе итеп.

Үз-үзеннән канәгать, симез капитан тарафыннан бернинди шәфкать, миһербанлык булмаячагын Габделхәй бөтен күңеле белән аңлады. Булган барлык кыюлыгын җыеп ул:

— Нишләп ми е генә алырга булдыгыз, иптәш капитан?— диде.

Капитан Зверев, күрәсең, мондый сорау көтмәгән иде.

— Беренчедән,— диде ул бераз уйлангандай иткәч,— беренчедән, армиядә хезмәт итү — һәрбер совет гражданинының изге бурычы. Икенчедән, военно-морской училищега без бары яхшы укучыларны гына тәкъдим итәбез.

— Ләкин, СССР Конституциясендә язылганча, һәрбер совет гражданы укырга, белем алырга хокуклы,— диде Габделхәй.

— Сезне миңа яхшы укучы, ләкин үзсүзле дип әйткәннәр иде — дөрес әйткәннәр икән,— диде капитан, йомшый төшеп.

Аңа Габделхәйнең СССР Конституциясе турында искә төшерүе тәэсир итте булса кирәк. «Кем әйтте минем турыда?» — димәкче булды Габделхәй, ләкин тыелып калды.

— Без Конституциягә каршы килмибез, без сезне укырга җибәрәбез,— диде капитан, «укырга» сүзенә басым ясап.

— Минем Ленинградтагы военно-морской училищеда укыйсым килми. Мин Казан университетына кермәкче булам,— диде Габделхәй, алдан ук әзерләп килгән сүзләрен исенә төшереп.

— Ярар, шулай да булсын. Университетны бетергәч кем булыр-

га исәплисез инде сез?— диде капитан кызыксынып.

— Мин... шагыйрь булачакмын!..— диде Габделхәй кызарынып.

— Шагыйрь...— диде капитан һәм бер дә юктан өстәлдәге бармаклары белән барабан кагып алды.— Шагыйрь булу начар түгел, билгеле. Әнә Пушкин булган, Лермонтов булган. Шулай да әйтегез әле, сезнең телдә... татар телендә шигырь язып буламыни?

Мондый сорауга каршы Габделхәй нәрсә әйтергә дә белмәде. Капитанның мондый соравы туп-туры аның йөрәгенә, бәгыренә барып тиде. Бу аның үзен генә түгел, аның телен, халкын мыскыл итү булып тоелды. Кем соң бу — синең шулай иң нечкә җиреңә кагылып, сине кимсетүдән, мыскыл итүдән тартынмый торган, үзенең бөек халык вәкиле булуыннан тәм таба торган, масайган колонизатормы, әллә татарча шигырь язып булуын-булмавын да аңлай алмаган берәр туң башмы?

— Минем мондый сорауга җавап бирәсем килми,— диде Габделхәй караңгы чырай белән, утлы күз карашын шешенке күз кабаклы капитанга төбәп.

— Мине беләсем килә — татарда шагыйрьләр бармы соң? Чын шагыйрьләр,— диде военком, ягымлы булырга тырышып.

— Тукайны ишеткәнегез юкмыни?— диде Габделхәй үзе дә сизмәстән.

— Да, да! Ишеткәнем бар... Такой...— диде капитан үз хатасын танып.

— Такой түгел, Тукай!— диде Габделхәй.

— Токай икән, Токай... Такой-сякой дигән кебек,— диде капитан көлеп, дусларча кыланып.— Шигырьне армиядә дә язарга була, училищеда... хәтта татар телендә дә! Анысы тыелмый. Өч мәртәбә ашау, кием-салым тулысынча дәүләт исәбеннән булачак. Укып чыккач, хәрби диңгез флотында хезмәт итәчәксез. Сез аңлы кеше — армия безгә һәрвакыт кирәк. Сугыш бетте, без җиңдек, дөньяда хәзер бер генә дошман да калмады дип уйласагыз, бик ялгышасыз.

— Минем алай дип уйлаганым юк,— диде Габделхәй, капитанга күтәрелеп карыйсы килмичә.

— Армиядә хезмәт итүдән баш тартуыгыз шуны күрсәтә,— диде капитан.

— Мин алай дип әйтмәдем, иптәш капитан!— диде Габделхәй кызарынып.

— Алай дип әйтмәсәгез дә, тел төбегез шуңа бара,— диде капитан.— Без фашистларны җиңдек, ләкин киләчәктә безгә тагын да көчлерәк, тагын да зуррак армия кирәк булачак. Сез моны беркайчан исегездән чыгармагыз. Дөньяда ике лагерь, ике блок яши. Империалистик блок һәм социалистик блок. Ахыр чиктә социализм барыбер җиңәчәк! Сез укыган кеше, моны белергә тиеш. Кытай, Һиндстан, Африка колонияләре... империалистлар изүе астында интегә. Алар бездән ярдәм көтә. Шулай булгач, Совет Армиясен туктаусыз ныгыту, һәр төрле авантюрага тиешенчә отпор бирергә әзер тору — безнең изге бурычыбыз. Армиянең, хәрби флотның булачак кадрлары — сез, яшьләр. Бөтен нәрсәне кадрлар хәл итә, диде иптәш Сталин.

Соңгы сүзләрен капитан шулайрак тәмамлады, каршы әйтергә, каршы килергә бернинди чара калдырмый торган итеп тәмамлады. Капитан Зверев империализм-социализмны, иптәш Сталинны теленә алгач, Габделхәй үзенең бирелә башлаганлыгын тойды. Аның моңа каршы тору түгел, хәтта бу мәсьәләдә икеләнергә дә көче җитмәячәк иде. Иң куркынычы менә шул «империализм-социализм» иде. Моннан беркая качып котылып та булмый, моны шулай ук аңлап, аңлатып та булмый иде. Моңа бары башыңны иеп буйсынырга гына кала иде. Монда инде шигырьләр дә, мәхәббәт тә,

ашау-эчү кайгылары да истән чыгып бетә иде. Бүре авызына керер алдыннан бичара сарык нәрсә кичерә торган булса, «империализм-социализм» һәм «иптәш Сталин» алдында да мескен адәм баласы нәкъ шундый ук нәрсә генә кичерә ала иде. Хәер, курку, кот алынудан башка нинди дә булса кичерешнең монда булуы да мөмкин түгел иде.

Шулай да кире һәм үзсүзле малай-җегет киң күкрәкле тук капитанга каршы сүз әйтергә батырчылык итә алды.

— Мин укырга... Казанга китәргә булдым, иптәш капитан,— диде.

Капитан беравык эндәшми утырды, һәр сүзенә басым ясап:

— Аңлашылды, Мухутдинов,— диде.— Мин сезгә өч көн вакыт бирәм. Өч көннән соң килерсез. Барыгыз, уйлагыз. Карагыз аны, ныклап уйлагыз!

Габделхәй уйланды. Туктаусыз уйланды. Ләкин чынында инде ул җиңелгән иде. Бит аның өчен барысы да алдан ук уйланып, хәл ителеп куелган иде.

«Победа»ның алгы утыргычында утырып барган күптәнге танышын күрү белән, кинәт анда яңа бер көч барлыкка килде. Чындук ул башын күтәрде, күкрәген киерә төште һәм тапталган каты, кара җиргә нык-нык басып бара башлады.

Ул һаман уйланып барды. Ирексездән үзен дингезчеләр кебек озын буйлы, төз гәүдәле һәм өр-яңа киемнән итеп күрде. Аның белән бергә тигез атлап, штыклы автоматларын нык тотып, яшь моряклар колоннасы барды. Күз алдыннан каскалы солдатлар узды. Бөтен урамнар, кырлар-басулар калканлы һәм сөңгеле, тәреле һәм йолдызлы сугышчылар белән тулды.

Если завтра война, если завтра в поход...

— дип җырладылар сугышчылар, җирне-күкне дер селкетеп. Якыннан гына дөбердәп, каты үкереп корыч танклар, ракеталар барды. Күктә, түбә өстендә кара болыт булып самолетлар очты. Шул чакны ил өстендә якты кояш балкып китте — трибунадан иптәш Сталин бәхетле Габделхәйгә аталарча кул болгады.

Ләкин көтмәгәндә кемдер бәхетле җегетнең яңагына китереп сукты. Габделхәйнең күзеннән утлар чәчрәде, йөрәге әрнеп сулкылдарга тотынды. «Казан балшой, балшой, Масква малинки!» дип, «Бей татар!» дип кычкырдылар караңгы урамда малай-шалайлар, май гөл-рамуслар. «Такой-сякой!» диде капитан мыскыллап.

«Юк, товарищ капитан, без такой-сякой түгел. Без... без сугышта юлбарыстан көчлебез, без тынычта аттан артык эшлибез! Без әле моряк та булырбыз, шигырь дә язарбыз!»— дип уйлады Габделхәй, әчке бер киеренкелек белән Яңавылның каты-коты урамыннан алга атлап.

1956 — 1962 һәм 1988 — 1990 еллар.
Казан

# ҮТКӘН ГАСЫРЛАРНЫҢ БҮЛӘГЕ

СӘЙФ САРАИНЫҢ «ГӨЛСТАН»ЫНА — 600 ел

Әгәр дә без халкыбызның мәдәни тарихына мөрәҗәгать итсәк, кызыклы законлык күрербез: милли үзаң үсеше мәдәни үсешнең алшарты, нигезе икән. Бу — бер. Икенчедән, мәдәният чәчәк аткан заманнар үткәндәге рухи ядкярләргә актив мөнәсәбәттә торулары белән характерлана. XX йөз башы татар мәдәниятен генә алып карыйк. Бу чорның әдип-галимнәре һәм меңәрләгән укучылары, төрле кыенлыкларга да карамастан, тарихны — остаз, элеккеге рухи истәлекләрне дәреслек-әсбап итеп, тырышып күп нәрсәгә өйрәнгәннәр һәм шуның нәтиҗәсендә үзләре дә гаҗәеп бай мирас тудыруга ирешкәннәр. Кызганыч ки, аларның бу игелекле эшләре тиешенчә дәвам ителмәде, берьяклылык, субъективизм көчәйде: тарихтан гыйбрәт, сабак аласы урынга, без аны үзебез өйрәтә, шомарта, көндәлек лозунгларга яраклаштыра башладык. Ун ел эчендә ике мәртәбә алфавит алыштыру тарих, мәдәни мирас белән безнең араларны тагын да ераклаштырды, күп кенә традицияләрнең өзелүенә китерде. Шуның аркасында халкыбызда хәтерсезлек, әхлаксызлык артты, үзаң дигән төшенчә иң түбән дәрәҗәгә төште, телебезнең, халкыбызның алга таба яшәеше кыл өстендә калды.

Ниһаять, соңгы вакытларда, үзгәртеп коруга нисбәтән, бик әкренлек белән булса да халыкта милли үзаң җанлану, тарих, элеккеге мәдәни мирас белән кызыксыну күзәтелә башлады. Бу игелекле башлангычны тагын да үстерү, киңәйтү өчен безгә элеккеге рухи истәлекләрне өйрәнү, киң катлам укучыларга җиткерү эшен төрле чаралар ярдәмендә бермә-бер көчәйтү сорала.

Әйтергә кирәк, VIII—X йөзләрдә үк дөньяның Кытай, Һиндстан, Византия һәм аеруча мөселман Көнчыгышы белән тыгыз мөнәсәбәтләрдә торган борынгы бабаларыбыз мең гасырдан артык яшәү дәверендә гаять бай һәм күпкырлы мәдәни мирас тудырганнар. Сәйф Сараиның «Гөлстан»ы, үзенчә әйткәндә, «Гөлстан бит-төрки» әсәре — элеккеге рухи хәзинәбезнең мөһим ядкярләреннән берсе. Ул моннан 600 ел элек, ягъни 1391 елның август башында тәгаммәлләнгән.

С. Сараи һәм аның иҗаты хакында укучылар табып укырлык мәкалә-хезмәтләр шактый*. Шуңа күрә биредә без шагыйрь, «Гөлстан бит-төрки» турында кайбер фикерләр әйтү, белешмәләр бирү белән генә чикләнәбез.

С. Сараи 1321 елда (моннан 670 ел элек) Идел буендагы хәзерге Камышин урынындагы Камышлы шәһәрендә туган дип фараз кылына[1]. Аннан Алтын Урданың башкаласы Сарай шәһәренә килә: монда укый, шагыйрь булып таныла. Шуңа күрә дә ул үзенең тәхәллүсе итеп Сараи кушаматын ала.

XIV гасырның 60 нчы елларыннан Алтын Урдада ызгыш-талашлар, сугышлар көчәеп китә, тәхет өчен кан коюлы көрәш башлана. Туктамыш идарәсенә, ягъни 1379 елга кадәрге ике дистә ел эчендә, Сарай тәхетенә 25 ләп ханның утырып алуын искә

---

*Татар әдәбияты тарихы. Алты томда. I том. Урта гасырлар дәвере. — Казан: Тат. кит. нәшр., 1984. 246—273 б.; Миңнегулов Х. Ю. Сәйф Сараи. Тормышы һәм иҗаты. — Казан: КДУ нәшрияты, 1976. 190 б.;

Наджип Э. Н. Тюркоязычный памятник XIV века «Гулистан» Сейфа Сараи и его язык. В 2-х частях. Алма-Ата, «Наука», 1975. h. б.

[1] Габдрахман ага Таһирҗанов, «Хөсрәү вә Ширин» (1342) әсәрендә «төнката», — ыргаерга (барырга, килергә) кебек элементларның булуына карап, Котбның мишәр татарларына мөнәсәбәтле булуын искәрткән иде (Тарихтан — әдәбиятка. Казан, 1979, 107—109 б.). Бу төр күренешләр С. Сараи әсәрләрендә дә очрый. Мәсәлән, «бер кичә кәрван төн ката йөреб», «теләсәң булмага гашыйк» h. б.

төшерү дә илдәге хәлнең ни дәрәҗәдә тотрыксыз булуын ачык күрсәтеп тора. Ә инде шушы гасырның соңгы чирегe Аксак Тимер белән Туктамыш арасындагы коточкыч сугышлар белән характерлана. Шушындый шартларда Алтын Урдада яшәү һәм иҗат итү бик кыенлаша. Күп кенә галимнәр һәм әдипләр чит җирләргә китәргә мәҗбүр булалар. Аларның зур өлеше, шул исәптән С. Сараи да Мисыр мәмлүкләре янына барып чыга. Шагыйрь үз иленнән читкә китүне, башка җирдә яшәүне бик авыр кичергән, бу рухи халәте аның шигырьләрендә дә гәүдәләнеш тапкан. «Ни өчен язмыш миңа бу кадәр җәбер китерде, нинди гөнаһым бар!? Илаһым, кимет җәбереңне, мин (югыйсә) илгә тугрылыклы ул идем», — ди ул бер парчасында. Икенче бер робагыенда аның мондый юллары бар:

*Күрең: ни гаҗәб, җәфачы дәуран килде (дәвер.—Х. М.),*
*Кем халкы җиһан күзендән ал кан килде.*

С. Сараиның 80—90 еллардагы иҗаты Искәндәрия, Каһирә шәһәрләре белән бәйләнешле. Аның безгә мәгълүм әсәрләре, нигездә, Мисырда иҗат ителгән. Шушында ук шагыйрь 1396 елда, ягъни 75 яшендә вафат та була.

С. Сараи — хикәят, дастан, газәл, касыйдә, робагый, мәсәл һәм башка жанрларда язылган тәрҗемә, оригиналь һәм нәзыйрә әсәрләр авторы. Әдипнең иҗат мирасы безнең заманга «Китабе «Гөлстан бит-төрки» һәм «Ядгярнамә» дип исемләнгән ике кулъязмада килеп җиткән. Аларның беренчесе Голландиянең Лейден университеты китапханәсендә саклана. Аның фотокүчермәсе 1954 елда төрек профессоры Фәридүн Үзлүк тарафыннан Анкарада бастырып чыгарылды. Лейден нөсхәсендәге текстлар 1968, 1973, 1986 елларда Ташкентта үзбәк, 1969 елда Будапештта латин, 1980, 1981 елларда Казанда гарәп, татар язуларында нәшер ителделәр. «Гөлстан бит-төрки»нең 1978 елда Истанбулда чыккан басмасы да бар.

С. Сараи әсәрләре арасында мөһим урынны «Гөлстан бит-төрки» алып тора. Ул фарсы телендәге «Гөлстан» әсәренә (1253) мөнәсәбәттә туган. Сәгъдинең бу китабы — дөнья күләмендәге мәшһүр әсәр. Ул тулы килеш тә, өлешләп тә бик күп телләргә тәрҗемә ителгән, йөзәрләгән әсәрләр тууда чыганак, таяныч рәвешендә файдаланылган. Үтемле, гыйбрәтле «Гөлстан»ның мәктәп-мәдрәсәләрдә дәреслек, хрестоматия буларак кулланылуы да мәгълүм. «Кәлилә вә Димнә», «Мең дә бер кичә», «Тутыйнамә» кебек, бу әсәр дә татар дөньясында бик популяр була. Аның оригиналь нөсхәләре, тәрҗемә-шәрехләре бездә күпләп очрый.

«Гөлстан» тоташ сюжетлы әсәр түгел: ул шигырь белән аралаштырып, рифмалы проза белән язылган чагыштырмача мөстәкыйль хикәятләр, шигырьләр тупламыннан гыйбарәт. «Нәсыйхәт», «Хикмәт» дип исемләнгән парчалар да бар. Әсәрдәге хикәятләр һәм башка төр композицион берәмлекләр тематик яктан сигез бабка бүленеп, түбәндәгечә исемләнгәннәр: I — патшалар тормышы турында, II — дәрвишләр әхлагы, III — аз белән канәгать булуның хәере, IV — эндәшмичә торуның файдасы, V — мәхәббәт һәм яшьлек, VI — картлык һәм зәгыйфьлек, VII — тәрбиянең тәэсире һәм VIII — сөхбәт (сөйләшә, аралаша белү) әдәбе турында. Әсәрнең берничә битен традицион кереш һәм бетем өлешләре алып тора.

С. Сараиның «Гөлстан бит-төрки»е тәрҗемә әсәр дип хисаплана. Чөнки анда әдип, нәкъ Котбның «Хөсрәү вә Ширин»ендәге кебек, оригиналның төзелешен, төп эчтәлеген саклаган. Бу аеруча чәчмә текстларны бирүдә ачык күренә. Шигъри өлешләрдә исә төрлелек күзгә ташлана: биредә без төгәл һәм ирекле тәрҗемәне дә, нәзыйрә ысулы белән язылган юлларны да, оригиналь шигырьләрне дә очратабыз. Шагыйрьнең фарсы һәм төрки телләрен, әдәбиятларын камил белүе, көчле таланты, бай иҗат тәҗрибәсе аңа мөстәкыйль идея-эстетик кыйммәткә ия булган әсәр тудырырга ярдәм иткән. Шуңа күрә дә «Гөлстан бит-төрки» татар әдәбияты тарихында гына түгел, гомумән, урта гасыр төрки дөньясында да кыйммәтле ядкярләрнең берсе исәпләнә. Аның төрле шәһәрләрдә һәм илләрдә кат-кат басылуы, дөнья тюркологларының игътибарын үзенә тартуы да шуның белән аңлатыла.

Бабларның исемнәре үк «Гөлстан бит-төрки»дәге тематик төрлелекне күрсәтеп тора. Автор чынбарлык һәм кешеләр тормышының гыйбрәтле һәм гаҗәеп күп төрле күренешләре аша безнең бүгенге яшәешебездә дефицитка әйләнгән гаделлек, тыйнаклык, сүз һәм эш берлеге, тугрылык, юмартлык, киң күңеллелек кебек матур әхлакый сыйфатларны алга сөрә, төрле чаралар ярдәмендә аларның антиподларын гаепли, кире кага. Шунысы мөһим: әдип әхлакый төшенчәләрне еш кына яшәешнең башка мәсьәләләре белән тыгыз мөнәсәбәттә карый. Мәсәлән, автор фикеренчә, хөкемдарның гадел, кешелекле, белемле булуы шарт; бүре куйларга көтүче була алмаган кебек, «залим» патша да «рәгыятькә», ягъни халыкка җитәкче була алмый — андый хөкемдар алып ташланырга тиеш. Гамәлсез галимне балсыз корт белән тиңләп, Сараи белемлелек төшенчәсенә иҗтимагый мәгънә сала.

Мозаик төзелешле «Гөлстан бит-төрки» аша укучы күз алдына бүгенгедәй катлаулы, ыгы-зыгылы, каршылыклы чынбарлык килеп баса. Аның үзәгендә — төрле табигатьле һәм социаль хәлле кешеләр, аларның эш-гамәлләре, уй-теләкләре һәм фикер кичерешләре. Бер тәннең әгъзалары кебек, үзара бәйләнештә торган җәмгыять кешеләренең төп вазифалары һәм яшәү мәгънәләре — игелекле хезмәттә һәм бербереңә, башкаларга бәхет, шатлык китерүдә. Бу — әсәрдән саркып чыккан төп фикер. Әдип төрле юллар белән шәхесне олылый, аны түбәнсетүгә, кеше гомерен кисүгә каршы килә.

Тере ирне иңән асан (бик ансат — Х. М.) орып ук берлә үлтермәк
Вәликен үлене мең кем ирсә тергезә белмәс,

— диюе белән шагыйрь чын гуманистларча чыгыш ясый.

«Гөлстан бит-төрки» өчен тормышчанлык, фикри тирәнлек хас. Кечкенә генә хикәятләрдәге, шигъри парчалардагы фикерләр зур-зур әсәрләр өчен нигез, арка сөяге булырлык. С Сараи иҗатында без Йосыф Баласагунлы, Әхмәт Йүгнәки, Котб әсәрләреннән, халык мәкальләреннән һәм дастаннарыннан килүче афористик фикерләү, хикмәтле сүз әйтүнең үстерелешен күрәбез. Шунысы куанычлы: бу традиция алга таба «Идегәй»дә, Мөхәммәдъяр, Акмулла, Дәрдемәнд әсәрләрендә дәвам итә.

С. Сараи әсәре төрки-татар әдәбиятын мөһим фикерләр, яңа сурәтләр, кызыклы шигъри алымнар һәм чаралар белән баетты, телебезнең шигъри офыкларын тагын да киңәйтеп, сүз белән иҗади эш итүнең матур үрнәкләрен бирде.

«Гөлстан бит-төрки» — фарсы һәм төрки-татар әдәби бәйләнешләрын өйрәнү өчен дә мөһим бер чыганак.

Укучыларга без «Гөлстан бит-төрки»нең төрле бүлекләреннән аерым өзекләр, хикәятләр тәкъдим итәбез. Шигъри юлларның шактый өлеше С. Сараиның оригиналь иҗатын һәм нәзыйрәләрен дә үз эченә ала. Текстлар турыдан-туры Лейден кульязмасының фотокүчермәсеннән алынды. Шуңа күрә теге яки бу сүзне укуда, хәзерге язуда бирүдә моңа кадәрге басмалардан аерым үзгәлекләр булуы табигый.

Мәгълүм булганча, «Китабе «Гөлстан бит-төрки» кульязмасы XIV гасырның ахырында Мисырда төзелгән. Нәсхәдә аерым сүзләрнең, авазларның язылышында төрлелек күзгә ташлана. Мәсәлән, шигъри үлчәм, ритм һәм башка хосусиятләр таләбе нигезендә, берлек санның беренче һәм икенче зат алмашлыклары мин, син дип тә, мән, сән рәвешендә дә язылалар. Җәһан — җиһан, татар — тәтәр, әл — кул, вә — һәм, күп — күб, булып — булыб формалары да еш очрый. Кагыйдә буларак, о, у, ү, ы, авазлары бер үк вав яисә заммә билгесе, ә инде и, е(э) йай яисә кәсрә тамгасы белән билгеләнгән. Бу хәл сүзләрне укуда шактый кыенлык китереп чыгара. Текстларны хәзерге язуга күчерүдә без кульязма үзенчәлекләрен шактый дәрәҗәдә сакларга тырыштык.


Хикәятләргә исем, эчтәлегенә нисбәтән, безнең тарафтан бирелде. Кыскартулар өч нокта аша күрсәтелде.

«Гөлстан бит-төрки»нең, гомумән, тәрҗемә әсәр булуын, теленең чагыштырмача аңлаешлылыгын исәпкә алып, андагы үрнәкләрне без хәзерге телгә тәрҗемә итүне кирәк дип тапмадык. Сүзлек һәм белешмәләр текстны аңларга һәм кабул итәргә булышыр дип уйлыйбыз. Сүзләр, нигездә, контекстка таянып аңлатылды.

Урта гасыр әдипләре шигъри сүзне хакыйкатьне ачучы, илаһиятнең серләрен гәүдәләндерүче, кеше күңелен дәвалаучы изге бер чара итеп караганнар. «Сүзләмәкдә сән йөземне ак кыйл, Сүзләреми ил күңлигә йомшак кыйл», «Күни (дөрес. — Х. М.) сүзләгән кешене хак үгәр» (мактар, хуплар. — Х. М.), — ди XVI йөз шагыйре Мөхәммәдьяр. С. Сараи да «Игри (ялган, кыек. — Х. М.) сүзне күни диб ант эчмә», «Ир исәң, кой агызга бал вә каймак», «Теләсәң игү атың мәңгү калай, Айакдан төшкән илен тотгучы бул», «Адәми күңлен екар сүз сүзләмә», — дип кешеләрне дөреслеккә, рәхимшәфкатьлелеккә өнди. Гуманист әдипнең уй-теләкләре, шәт, хәзерге укучылар күңелен дә битараф калдырмас.

**Хатип МИҢНЕГУЛОВ,**
филология фәннәре кандидаты.

# ГӨЛСТАН БИТ-ТӨРКИ


كتاب كلستان بالتركي
ترجمة العبد الفقير الحقير
سيف السرايي عفا الله عنه
باسم الملك العلي المولوي الكبيري المليكي
المخدومي السيفي امير غاص حاجب الحجاب
بالديار المصرية اعلاها الله تعالى

*С. Сараиның Голландиядәге Лейден университеты китапханәсендә саклаучы «Китабе Гөлстан бит-төрки» кульязмасының фотокүчермәсе.*

## «Кереш»тән

... Гөл теләсә хатыйрең тулы табак,
Бу «Гөлстан»ымдан укы бер вәракъ[1].

Гөл җәмалы[2] берничә көндә кичәр,—
Бу «Гөлстан» даимә[3] күңел ачар.

Бу гаҗәиб кем гараиб монда бар,—
«Хөсрәү вә Ширин»[5] эчендә,— канда[6] бар?!..

---

[1]Вәракъ — кәгазь; бит. Хатыйрең — күңелең.
[2]Җәмал — матурлык.
[3]Даимә — даимән — һәрчак.
[4]Гаҗәиб... гараиб — гаҗәеп... күрелмәгән.
[5]Бирелә Котбының «Хөсрәү вә Ширин» (1342) әсәре күздә тотыла булса кирәк.
[6]Канда — кайда.

Төркигә кылыб гаҗәмдән[1] бу китаб,
Мәгърифәткә ачты сиккез төрле баб[2].

Тикмә бер җанга мөфәррих[3] булмага,
Тикмә хатыйрне мөшәррәф[4] кылмага.

Бу «Гөлстан»га тамаша кылган ир,
Дәмбедәм мәгънә йимешен тазә йир...[5]

Игү аты калса ирнең яхшырак,
Соңра калгинча тулы алтун рәвак[6].

Ядкаре калса кемнең игү ат,—
Үлмәс ул ир,— кемдә булса бу сыйфат...

Бу «Гөлстан» багбаны[7] ул әдиб,
Кем Сарайи Сәйф ирер, назмы гариб[8].

## Беренче бабтан.
## («Патшалар тормышы турында»)

Фетнә йөзле раст[9] сүздән бул ерак,
Мәслихәтле ялган андан яхшырак.

Гакыйл[10] ул — сүзне йирендә сүзләгәй
Һәм җавабыны мөнасиб күзләгәй[11].

Кем мөхалиф[12] булса солтан сүзенә,
Килтүрүр ул күб бәлаләр үзенә.

Сыйгар бер хөҗрәгә уникке миһман,
Бер иклимә сыйгышмас икке солтан[13]

Бүренең баласы булыр гакыйбәт[14]
Атасы кеби ул хәрами[15] бүре.

Ничә күб йидырсаң,[16] сәңа бер көн ул
Орыр зәхм[17] — андан саклана йөре.

---

[1] Гаҗәм — фарсы.
[2] Баб — бүлек.
[3] Мөфәррих — шатлык, куаныч.
[4] Мөшәррәф — кадерле.
[5] «Бертуктаусыз мәгънә җимешен җыеп торыр».
[6] Рәвак — сарай.
[7] Багбан — бакчачы. Биредә — «Гөлстан»ның авторы мәгънәсендә.
[8] Назмы гариб — ягъни «чит ил әдибе».
[9] Раст — дөрес.
[10] Гакыйл — «акыллы» мәгънәсендә.
[11] Мөнасиб күзләгәй — туры килешле (урынлы) бирер.
[12] Мөхалиф — каршы.
[13] Бер бүлмәгә уникке кунак сыяр, (әмма) бер илгә ике солтан сыймас.
[14] Гакыйбәт — ахыр чиктә, барыбер.
[15] Хәрами — карак, явыз.
[16] Йидырсаң — ашатсаң.
[17] Орыр зәхм — һөҗүм итәр.

⁂

Тотыб мескен кешенең пәнҗәсене[1]
Аермак көч белән — гайне[2] хатадыр.

Игеб золм орлыкын хәйр эстәгәнләр
Жәһәннәм утына үзен якадыр.

Котылмага теләсәң хәүф илендән,
Рәгыять[3] халенә яхшы бакадыр[4].

## Хикайәт (Залим хаким)

Бер залим хаким бер галим иргә сорды,[5] кем: «Гыйбадәтләрдә фазыйлрагы[6] кайсы торыр?» Әйтте: «Зөһер[7] вактын өемак, хәтта ул заман эчендә халыкны азар кылмагайсән»[8].

Күрдем өвлә[9] вакыт бер залим өер.
Әйттем: Ул фетнә өеса яхшырак.
Даим илгә золым кем кылса, аның
Үлмәге яхшы хәятыңдан бирак[10].

⁂

Дугелдер дустың — нигъмәтдә һәркем
Мәхәббәт лафыны орса яныңда.
Хакыйкать[11] дустың — ярыңдыр ул кем,
Кулың тотса аякдан төшкәнеңдә.

⁂

Нәсыйхәт тотмаган гафил[12] кем ирсә[13]
Төшәр даим мәшәкатьнең кыныны.
Белерсән: зәхмәнә[14] чөн такәтең юк,
Кулыңны сукмагыл гакрәб[15] өенә.

⁂

Әйа, гаклы тиңиз, сүзе гөһәрбар,[16].
Утырсаң, күзем өстендә йирең бар.

---

[1]Пәнҗә — кул чугы, биш бармак.
[2]Гайн — күренеп торган, ачык; бик.
[3]Рәгыять — бер дәүләтнең халыклары, кул астындагы кешеләр, масса.
[4]Бакадыр — бага тор — карый тор.
[5]Сорды — сорау бирде.
[6]Фазыйлрагы — әйбәтрәге, файдалырагы.
[7]Зөһер — төш вакыты.
[8]Азар кылмау — рәнҗетмәү.
[9]Өвлә — өйлә.
[10]Хәятыңдан бирак — тереклегеңнән (яшәвеңнән) бигрәк.
[11]Хакыйкать — чын.
[12]Гафил — зиһенсез; надан.
[13]Кем ирсә — ягъни «кеше».
[14]Зәхмәнә — зәхем — ору; чагылу.
[15]Гакрәб — чаян.
[16]Гөһәрбар — гәүһәрдәй, кыйммәтле.

Нигә кем фәһме[1] юк мескен ишәкнең
Күтәрмәк берлә йөкне — кыйммәте бар.
Ишәк ул адәмидән яхшырак, кем
Кылыр даим кешенең күңлен азар[2].

... Дәгый мескен кешеләргә көч итмә,
Аларның аһы утыннан хәзәр кыл[3].
Екар булсаң дәгый бер гәз күңелне[4],
Күңел аһы сәне кау[5] тик якар бел.

Кәйхөсрәү[6] тажының өстендә бу икке бәйтне язып торырлар:

Башымыз өстендә бу халкы җиһан
Сәйр иткәйләр[7] йир үзә[8] күп заман.
Илдән илгә[9] килде безгә мәмләкәт,
Илля һәм киткәй килеб илдән рәван[10].

## Хикайәт (көрәшче пәһлеван)

Бер көрәшче пәһлеван өч йөз алтмыш төрле көрәш гыйльмен[11] белер ирде. Тикмә бер көн[12] бер төрле гыйлем белән көрәшер иде. Шәкердләреннән бер сахибҗәмал[13] углан белән хатыйре мөтәгаллекъ булып[14] өч йөз илле тукыз төрле көрәш гыйлмен аңа үгрәтте. Углан ул гаятька йитте кем, бу вилаятьдә[15] ни кадәр көрәшче бар иде, барчасын басты. Бер көн солтан хедмәтенә килеб йир үбеп әйтте: «Остадымның мәнем үзә тәрбият хакки бар. Юкса, куввәтдә вә санәгатьдә[16] мән андан артыкмән». Бу сүз солтанга хуш килмәде, боерды кем: «Көрәшсенләр!» Мәкам[17] тәртиб кылдылар. Әркане дәүләт вә әгъйане хәзрәт, өмәра вә вөзәра хазыйр булдылар[18]. Углан исрүк фил кеби мәйданга кереб, тәссаувыр итте[19] кем, тимердән таг булса, йирендән купаргаймән. Остады дәгый белде кем, үзендән артык торыр. Ул бер гыйлемне кем мондан гизләп иде[20], аны гамәлгә китерде. Углан дәфегъ[21] итә белмәде. Угланны күтәреб һавадан йиргә орды. Халыкдан гари кубты[21]. Солтан боерды: остадына хилгать[22] вә нигъмәт бирделәр, дәгый угланны мәламәт[24] кылдылар кем: «Сән үз остадың белән дәгъви кылдың, дәгъвиең батыйль[25] булды». Углан әйтте: «Ул мәнем үзә куввәт белән га-

---

[1] Фәһме — акылы; зиһене.
[2] Азар кылыр — рәнҗетер.
[3] Хәзәр кыл — саклан.
[4] «Бер генә мәртәбә күңелне рәнҗетсәң дә» мәгънәсендә.
[5] Кау — каудан — коры үлән.
[6] Кәйхөсрәү — Иранның борынгы шаһларыннан берсе.
[7] Сәйр иткәйләр — йөрерләр; сәяхәт кылып торырлар.
[8] Йир үзә — җир өстендә.
[9] Илдән илгә — кулдан кулга.
[10] Рәван — бик тиз.
[11] Көрәш гыйльмен — көрәш ысулын.
[12] Тикмә бер көн — һәр көнне.
[13] Сахибҗәмал — гүзәл, матур.
[14] Мөтәгаллекъ булып — мавыгып, дуслашып.
[15] Вилаять — ил, өлкә.
[16] Санәгатьдә — осталыкта.
[17] Мәкам — урын, мәйдан.
[18] «Дәүләтнең терәкләре, олуг руханилары, әмирләр вә вәзирләр катнашалар».
[19] Тәссаувыр итте — уйлады, күз алдына китерде.
[20] Гизләү — яшерү.
[21] Дәфегъ итә — кире кага, каршы тора.
[22] Гари кубты — хуплады, алкышлады.
[23] Хилгать — өс киеме, бүләк ителгән кием.
[24] Мәламәт — шелтә.
[25] Батыйль — ялган, нигезсез.

либ[1] булмады, бәлки көрәш тәгълимендән бер дәкыйкаңы[2] гизләмеш. Аның белән галиб булды». Остады әйтте: «Бәли, ул дәкыйкаңы бу көн өчен гизләб идем.» «Гакыйллар мәсәле[3] торыр: дустка ул кадәр яри[4] кылгыл кем, дошман булса, сиңа зафәр[5] табмагай».

## Шигырь

Йа вафа[6] юк торыр бу галәмдә,
Йә кеше кылмады җиһанда аны.
Мәндән ук гыйльмен үгрәнеб киткән
Гакыйбәт[7] кылды ул нишанә[8] мәне.

❁

Кирәкле дуст күңлен табмак өчен,
Атасы багыны сатса рәвадыр[9].

Ашы бишкинчә[10] игү адәминең
Өвең рәхәтен тиреб утка якадыр[11].

Яманлык кылган иргә игүлек кыл,
Капар[12] эт агзына ләкмә атадыр.

❁

Тимер түккән беләк мең корла[13] яхшы,
Ул илдән кем күкесендә бикка каршы[14].

❁

Бойлә[15] сарыф итте гомрен ул сәрбаз[16],
Ни йийгай[17] кыш, дәгый ни кигәй яз?!

И бугаз, канигъ ит[18] бер итмәккә,
Кыл үзеңә бу күп җәфаны аз.

❁

Килер булса белек берлә сәгадәт,
Белексез һәйкәле булгай шәкавәт[19].

---

[1]Галиб — өстен, җиңүче.
[2]Дәкыйка — өлеш, элемент.
[3]Мәсәл — элек бу атама еш кына мәкаль төшенчәсендә кулланылган.
[4]Яри — яр-дус.
[5]Зафәр — җиңү.
[6]Вафа — тугрылык.
[7]Гакыйбәт — ахырда, ахыр чиктә.
[8]Нишанә — мишень.

[9]Рәва — урынлы, яраклы.
[10]Бишкинчә — пешкәнчегә кадәр, пешкәнче.
[11]«Өенең кирәк-яракларын (җиһазларын) җыеп утка ягадыр».
[12]Капар — тешли торган.
[13]Корла — мәртәбә, тапкыр.
[14]«Бик каршында күкрәккә куйган кулга караганда».
[15]Бойлә — шулай, бу рәвешчә.
[16]Сәрбаз — хәрби, солдат.
[17]Йийгай — ашагай.
[18]Канигъ ит — канәгать бул, риза бул.
[19]Шәкавәт — бәхетсезлек, бала.

Вәли әбләһ[1] батыбдыр кәнҗ[2] эчендә,
Белекле — хар вә мөфлис, рәнҗ эчендә[3].

Биреб мөлк[4] бу берене кылды солтан,
Йөретер бу берене ач вә горъян[5].

Җиһан бөнъядыны[6] бөйлә салыбтыр,
Бу эшкә гакыйл ир хәйран калыбтыр.

Аның хикмәтләренә гакыл ирешмәс,
Кем ирсә эшләренә һәм керешмәс.

## Икенче бабтан («Дәрвишләр әхлакы турында»)

Алдыңда юаш куй бикин мөшфик яр[7],
Артыңда — бүре кеби тирецне ертар.

Бер әбләһ уртада кылды яманлык,
Ничә гакыйлларга тигде зыяны,
Тулы булса бер олы биркә[8] мавәрәд[9],
Кылыр бер эт төшеб мордар[10] аны.

Әйа, дөнья өчен кигән мөрәккәгъ[11],
Булып садикъ[12] бу эшдән тәүбә кылгыл,
Ни хаҗәт башыңа — таҗе мәшаих[13],—
Татар бүркен[14] киеб дәрвиш булгыл.

Кичә бер хастә өчен саг ирнең
Таң аткинча күзендән яшь килде,
Таң атты, Хәкъ тәгалә әмре берлә
Сүкәл[15] ир саг булды, саг үлде.

---

[1]Әбләһ — ахмак.
[2]Кәнҗ — хәзинә.
[3]Белемле (кеше) — аяныч хәлдә, фәкыйрьлектә, рәнҗтә.
[4]Мөлк — мөлек — патшалык.
[5]Горъян — ялангач.
[6]Бөнъяд — бөнияд — нигез.

[7]Алдыңда — юаш куй кебек шәфкатьле дус.
[8]Биркә — бәркә — сусаклагыч, бассейн, коe.
[9]Мавәрәд — эчә торган, татлы.
[10]Мордар — пычрак, яраксыз.
[11]Мөрәккәгъ — дәрвиш кием.
[12]Садикъ — тугры, ихлас.
[13]Мәшаих — ишаннар, дин галимнәре.
[14]Татар бүрке — очлы бүрек.
[15]Сүкәл — авыру, хаста.

## Хикайәт (Әдәпне әдәпсезләрдән өйрәндем)

Локман хәкимгә[1] сордылар: «Әдәбне кемдән үгрәндең?» Әйтте: «Әдәпсезләрдән. Бактым аларның әфгаленә[2], кайсы хәрәкәт кем миңа хуш килмәде, андан ихтираз кылдым»[3].

Әгәр уйнаб бер кеше бер хәрф[4] әйтсә,
Алыр андан белек әһле нәсыйхәт.
Килер ахмак колакына уенчак[5],
Укыр булсаң йөз илле баб хикмәт.

Сән игү бул, яман дисен хәлаик[6],
Яман булып сәңа яхшы дигәнче.

Яхшы ир эвдәше[7] яман булса,
Җәүр эчендә ирен һәмишә[8] кыйнар.
Чөн аның сөхбәте[9] җәһәннәмдер,
Вә кина рәббәна газабен-нар[10].

Аның тик уздаң[11] иде ул йөзе ай,
Күрәр булсаң фәрештә юлдин азгай.

Сүзе шәккәр, үзе фәттан вә гаййар[12],
Күзе гамзә белән[13] заһидлар[14] алдар...

## Хикайәт (Авыр сүзне күтәрү авыр)

Бер салих[15] ир күрде: мең батман таш күтүргән[16] пәһлеванны. Газаби килеб, агызы күбекләнеб утырыр. Сорды: «Моңа ни булып торыр?» — диб. Бер кеше әйтте: «Боңа фөлан кем ирсә сүкте»[17]. Әйтте: «Бу әбләһ мең батман ташны күтүрүр, дагый бер сүкенечне[18] күтәрә алмас».

Бу ирлекдә үкенен лаф орырсән,
Ничөн бәс нәфсеңә гаҗиз булурсән.

---

[1]Локман хәким — Шәрыкта акыллылыгы белән мәшһүр легендар зат.
[2]Әфгалена — эшләренә, гамәлләренә.
[3]Ихтираз кылдым — тыелдым.
[4]Хәрф — хәреф, сүз.
[5]Уенчак — уен, кызык.
[6]Хәлаик — халыклар.
[7]Эвдәше — хатыны.
[8]Һәмишә — һәрчак.
[9]Сөхбәт — бергә булу.
[10]«И раббым, безне ут газабыннан коткар».
[11]Уздаң — гүзәл.
[12]Фәттан вә гаййар — юлдан яздыручы һәм хәйләкәр (үткен).
[13]Күзе гамзә белән — күз кысуы белән.
[14]Заһид — изге.
[15]Салих — изге.
[16]Күтүргән — күтәргән.
[17]Ягъни «моны фәлан кеше сүкте».
[18]Сүкенечне — сүгүне.

Дәгел ирлек агызга йомрык[1] ормак.
Ир исәң кой агызга бал вә каймак.

Күңел бирмә күңел бирмәс кешегә,
Ашыккан ир белән юлдаш булма...

Күрексез әбчинең[2] ире күзсез кирәк,
Гәр күрәр булса йөзен, бирер талак[3].

## Өченче баб
## («Аз белән канәгать булуның хәере»)

Кадәрендан[4] йийса кем артыкрак,
Ул йимәк, бел, аңа зыян китерер.
Кем йийса ач булыб коры итмәк
Мигъдәсендә шәкәр бикин утырыр[5].

## Хикайәт (Сараннан хаҗәт теләмә)

Бер яхшы ир татар орышында яман җәрәхәтле булды. Бер кеше аңа әйтте: «Синең бу җәрәхәтең дәвасы фәлан хуҗа катында бар. Барыб теләсәң булгай кем, андан сәңа биргәй. Вәликен ул хуҗаны әйтерләр: бөхил[6] белән мәгъруф[7] иде илля кем...

Гәр көнәшне кизләсә[8] итмәк бикин[9] ул сөфрәдә[10],
Күрмәгән еллар кичеб күз ул көнәшне бер янә.

Андан ул мәҗрүх[11] ир әйтте: «Аның бикин кешедән хаҗәт теләсәм, биргәй я бирмәгәй. Әгәр бирер булса, файда кылгай я кылмагай...

Хаҗәт теләмә хәсис[12] ирдән,
Богдай тәмгъ итмә шурә йирдән[13]...

Ничек кем мәсәлдә әйтерләр: мәзәлләт[13] белән тере йөригинчә, гыйлләт[14] белән үлсә яхшырак...

---

[1]Йомрык — йодрык.
[2]Әбчи — хатын.
[3]Бирер талак — аерыр.
[4]Кадәрендан — чамасыннан.
[5]«Ашказанында шикәр кебек утырыр».
[6]Бөхил — бөхел-саран.
[7]Мәгъруф — билгеле.
[8]Кизләсә — гизләсә — яшерсә.
[9]Итмәк бикин — икмәк кебек.
[10]Сөфрә — табын.
[11]Мәҗрүх — яралы.
[12]Хәсис — саран, түбән җанлы, әшәке.
[13]«Бодай (уңышы) көтмә тозлы җирдән».
[14]Мәзәлләт — түбәнсенү.
[15]Гыйлләт — авыру.

Төрш йөзленең илиндән йийкинча бал вә тәр каймак[1].
Көләч йөзленең илиндән алыб хәнзал[2] йийса хушрак.

*

Йөзеңне төрш[3] итеб китмә кешегә,
Аның күңлен дәгый гамыгин[4] кылырсән.
Көләч йөз берлә кем хаҗәт теләсә,
Эше багланмас[5] ул ирнең, белерсән.

*

... Килер мөфсид[6] кешедән күп яман эш,
Илендә[7] берничә динар[8] булса.

Ни эшләр кылгай ирде адәмигә
Карынчаның[9] канаты бар булса.

Сәгадәт күрмәгән табса вәзарәт[10],
Орып ир үлтерер уйнар булса.

Китәр башы аның бер көн бу юлда,
Ничә күп мал-у мөлк асрар булса.

Йомар күз бу җиһанның зинәтендән,
Кемә сабр-у канәгать яр булса.

*

Сусамыш ирнең агзында җәваһир[11]
Сәдәф берлән сәвадыр[12], и газиз ир.
Аның кем азукы юктыр күгәрмеш
Коры итмәк табып сөккәр[13] бикин йийр.

*

Төшеб бер көн атындан бу мәсәлне
Бадиһә назым итте[14] Хуҗа Исхак[15]:
Җиһан сөйгән кешенең күзләрене
Канәгать тулдырыр йә, үлсә, тубрак.

---

[1] «Чытык йөзленең кулыннан бал вә тәмле каймак ашаганчы».
[2] Хәнзал — ачы (өлгермәгән) кавын.
[3] Төрш — чытык.
[4] Гамыгин — кайгылы.
[5] Эше багланмас — эше туктап калмас.
[6] Мөфсид — астыртын, начар.
[7] Илендә — кулында.
[8] Динар — акча берәмлеге, алтын акча.
[9] Карынча — кырмыска.
[10] Вәзарәт — вәзирлек, югары дәрәҗә.
[11] Җәваһир — «җәүһәр» сүзенең күплеге.
[12] Сәва — тин.
[13] Сөккәр (-?) — шикәр.
[14] Бадиһә назым итте — экспромт белән шигырь әйтте.
[15] Хуҗа Исхак — XIV йөздә яшәгән Алтын Урда шагыйре.

## Хикайәт (Әҗәлдән котылып булмый)

Иле-аягы киселгән кем ирсә кырык аяклы җанвар үлтерде. Күреп аны бер гариф ир әйтте: «Сөбхән аллаһы, анының кем кырык аякы бар иде. Әҗәле ирешсә исә илсез-аяксыздан качыб котыла белмәде»...

*

**Ка(й)чан җан алгыйчы[1] дошман ирешсә,**
Әҗәл баглар йөгергәннең аягын.

*

Көч белән бетмәс эшең, акча кирәктер, акча!
Акчалы адәми мохтаҗ дәгелдер көчкә.

*

Китер акча, кимәгә кер, юк исә тышкары утыр,
Ул ирнең кувватене куйгыл, бер ирнең акчасын килтер.

---

[1]Алгыйчы — алучы.

---

*Котлыйбыз!*

## Әдип Маликовка 70 яшь



Әдип Малик улы Маликов 1921 елның 16 августында Башкортстанның Яңавыл районы Югары Чат авылында туган. Мәктәптән соң Пермь шәһәрендәге татар педагогия училищесында укый. Андагы әдәби түгәрәккә йөри, Казан, Свердловск газеталарында беренче шигырьләрен бастыра. 1939 елда училищены тәмамлагач, Пермь өлкәсе Бардым районы Солтанай авылында укытучы булып эшли. Бөек Ватан сугышы елларында Көньяк Сахалин утравында булып, аны япон самурайларыннан азат итүдә катнаша. 1946 елда «Совет әдәбияты» журналында дөнья күргән беренче поэмасы — «Атаудагы хисләр» — әнә шул еллар истәлеге.

1946—49 елларда Ә. Маликов Татарстан радиосының әдәби-драматик тапшырулар редакторы булып эшли. 1949 елда Мәскәүдәге М. Горький исемендәге әдәбият институтына укырга керә. «Яшь сталинчы»ның үз хәбәрчесе сыйфатында Минзәлә, Әлмәт төбәкләрендә эшли. Әлмәттәге әдәби берләшмәгә җитәкчелек итә, бирегә Язучылар оешмасы төзелгәч, 1965—67, 1972—82 елларда — оешманың җаваплы секретаре. Әдип Маликовның иҗат юлы да Әлмәт төбәге, нефтьчеләр тормышы белән үрелеп барды, аның күп кенә поэма һәм шигырьләре шуны раслый. «Без кояшны юлда каршылыйбыз», «Кембрига юл салучылар» кебек чәчмә әсәрләре һәм «Яшьлек утравым» истәлек-повесте да (1972) үз заманы елъязмалары булды.

1979 елда аңа Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре исеме бирелде. 1981 елда исә «Почет билгесе» ордены белән бүләкләнде. 1959 елдан ул — СССР Язучылар берлеге әгъзасы.

*Татарстан Язучылар берлеге идарәсе һәм «Казан утлары» журналы редакциясе юбилярны кайнар котлыйлар, аңа сәламәтлек һәм иҗат уңышлары телиләр.*

# ӘЙДӘ, ХАЛЫККА ХЕЗМӘТКӘ!

ЯЗУЧЫ МӨХӘММӘТ МӘҺДИЕВ БЕЛӘН ӘҢГӘМӘ



*— Мөхәммәт абый, әйдәгез, сүзне гап-гади нәрсәләрдән башлап җибәрик әле. Татар әдипләренең күбесе авыл җиреннән чыккан. Оя-оя булып кай төбәккә генә сибелмәсен, авылларыбызның һәркайсы — үзе бер дөнья! Анда агачтан чәчәк коючы балта осталары, өйне генә түгел, күңелеңне дә җылытырлык итеп мич чыгаручылар, тагынтагын әллә никадәр һөнәр ияләре яши. Һәр авылның үз осталары була — табигать адәм балаларын шундый талант белән бүләкләгән. Сизәсездер: мин сүземне язучылык талантына таба бормакчы булам. Сезнеңчә, язучы шәхесе каян, кайдан, ничек барлыкка килә? Аның «чишмә башы» кайларга барып тоташа икән?*

— Минем туган авылым бик һөнәрле. Аерым бер һөнәре, аерым бер эшкә зур сәләте булмаган кеше бездә юк. Бездә — балта осталары, морҗачылар, тәрәзә яңагы-тупсасы ясаучылар, пыялачылар, итекчеләр, тегүчеләр. Күз җитсә, авылыбызга ерак-ерак яклардан ат җигеп, машинага утырып килә башлыйлар: итекчеләргә йон китерәләр. Мин әнә шундый авылда туып үстем. Әтием дә бик һөнәрле иде.

Бик күп һөнәргә ия булган авылдан бер язучы да чыгарга мөмкин бит инде. Язып карау теләге беренче класста ук башланды. Стена газетасына мәкаләләр яза идем. Ләкин безнең совет мәктәбендәге тәрбияне беләсез: укытучылар мәкалә язганда гел кимчелек турында, иптәшеңдәге берәр җитешсезлек, аның берәр гөнаһы турында язуны таләп итәләр, яшерен исем астында язарга тәкъдим итәләр, кыскасы, хыянәтче булырга өндиләр иде. Павлик Морозов та әнә шуның корбаны булды шикелле. «Әйдә, син яза беләсең, менә өченче класста укый торган Вафин бик тәртип боза, шул турыда яз да, берәр исем куй»,— дип укытучы бик нык кыскач, мин дә күндем. Югыйсә, аңарчы «Чаңгы шуабыз», «Җәй көне урманга бардык» кебек биш-алты юллык мәкаләләр генә яза идем. Ә монда беренче класс малаен хыянәткә этәрәләр. Мәкаләне дәрестән алып калып яздырдылар, өлкән класс кызлары буяу карандашлары белән газетаны ясап яталар иде инде. Мәкаләм болай килеп чыкты: «Өченче класс укучысы Вафин кечкенә малайларны кыйный. Ул бик тәртипсез. Ул тәртипле булсын иде. Язучы «Каләм».

Кызлар газетаны чыгарганнар һәм, әлбәттә инде, кайтышлый ук Вафинга күрсәтеп мине «сатканнар».

Мин бернәрсә белмичә иртәгесен дәрескә керсәм, өлкән класс малайлары — унбишләп булыр — мине күтәреп торалар иде, килеп керүемә сугып ектылар да илумач итеп кыйнадылар, изделәр.

— Менә сиңа, менә сиңа, әләкче тәре,— дип озак кыйнадылар.

Ник кенә бер укытучы шунда мине аралап алсын!

Менә беренче «иҗат» дәверемдә шундый хата адым ясадым һәм кыйналдым. Бик дөрес кыйнадылар мине, рәхмәт аларга!

Сез язучы шәхесенең «чишмә башы» турында сорыйсыз. Минемчә, язучының «чишмә башы» — фаҗигада. Драма, тормыш драмасында. Шәхси тормышында фаҗига, хәсрәт, борчу кичермәгән кешедән язучы чыга алмый. Дөрес, язучы исемен күтәреп йөри ул, калын-калын китаплары да чыга аның, ләкин, заман рухы аз гына үзгәрү белән, ул китаплар коелалар да төшәләр. Әнә Мәскәүдә Язучылар Союзы аппара-

ты тирәсендә түрә булып утырган кешеләр Хрущев, Брежнев чорларында нинди генә калын китаплар чыгармадылар! Аларның портретлары да була иде китап эчләрендә: тук, канәгать чырай. Алар Хезмәт Герое да, алар бернichә мәртәбә лауреат та, депутат та, делегат та... Алар берьюлы бернichә нәшриятта күптомлык, сайланма әсәрләр һ. б. чыгарып кына калмыйлар, үзәк журналларда, «Роман-газета»да һәм, безнең өлешкә кереп, урындагы нәшриятларда да басылдылар. Мәскәү түрәләренең китабын монда басуны без колларча шатланып «милләтләр арасындагы дуслык акты» дип башкара идек.

Йә, әйтегез, шул бәхетле язучыларның калын китапларын бүген кем укый икән?

Язучының «чишмә башы» — халык язмышында. Бүген әдәбиятка килә торган яшьләрнең бик күбесе халыксыз, җирсез. Алар бүген яуган шифалы яңгыр дымы белән тишелеп үсәләр, чәчәк аталар, ул дым беткәч исә корыйлар. Ә үсү өчен яңгыр дымы гына җитми, тамырлар җир асты дымына тоташкан булырга тиеш. Хәер, бу фикер минеке түгел, татар халкының бөек улы Җамал Вәлидинеке.

*— Минем уйлавымча, язучының иң беренче миссиясе — үз халкыңа хезмәт итү. Язган әсәрләрең белән дә, көрәш һәм яшәү рәвешең белән дә. Сез ничек уйлыйсыз, бүгенге көндә, ягъни иҗтимагый-политик көрәш аеруча кыза барган заманда, «минем төп эшем — язу» дип үз кабыгыңа кереп бикләнү дөресме? Әдипләрнең көрәш активлыгын ни билгели?*

— Соравыгызда бераз төгәлсезлек күрәм. Язучы, әгәр халык өчен кирәкле әсәр яза икән, димәк, ул инде дөньяга бер дә чыкмый язып утырса да, үз кабыгы эчендә кала алмый. Сез сорауны бераз төребрәк, мәгънәсен эчкәрәк яшереп бирәсез. Ә мин бу сорауны «ялангачландырып» менә болай аңлыйм:

— Сез нишләп Татар иҗтимагый үзәге эшендә катнашмыйсыз, нишләп митингларда чыгыш ясамыйсыз? — дип сорамакчы буласыз. Әйдә, шулай ачыктан-ачык сөйләшик.

Мин — «митинговый» кеше түгел, ул сәләт миңа бирелмәгән. Мин утыз елга якын университетта лекция укыдым, карап сөйләмәсәм дә, алдымда һәрвакыт лекциямнең конспекты була иде, ул мине хата сүздән, буш сүздән «страховать» итеп тора иде. Ә митингта шпаргалка белән сөйләп булмый. Янымда кәгазем, планым булмаса, мин гомумән сөйли белмим. Андый талант бирелмәгән. Аннан соң, мин ул митингларның кайберсендә катнаштым, күрдем. Бездә сәяси митингны еш кына тамашага әйләндерәләр. Йә, күз алдына китерегез инде: халык хәрәкәте вәкилләре сәяси-иктисади мәсьәләләр турында сөйли һәм шунда ук чыгып берәр артист юмореска укый яки... сабый баланы җырлаталар.

Мондый концертлы сәяси митинг Европада юмористик планда бармый. Анда мәшһүр бер җырчы-трибун яки шагыйрь чыга. Аннан соң: татар халкының азатлыгы өчен көрәшүне кайберәүләр микрофон янына килеп гарәпчә исәнләшү төсендәрәк аңлыйлар. Ә ни өчен гарәпчә? Нигә үзебезчә түгел?

Мин динле, коръәнле гаиләдә туып үстем, әтием ун ел Сатыш мәдрәсәсендә укыган да, солдат хезмәтен үтәп кайткач, яңадан шунда барып ике ел укыган. Сагынып янына килеп чыккан сабакташлары белән алар, гарәпчә гыйбарәләр әйтә-әйтә, кызык хәлләр сөйләп яшьлекләрен искә алалар иде. Мин аларны камил рәвештә гарәпчә белгәннәрдер дип уйлыйм, чөнки әтием укыган гарәп телендәге китапларда хаталар төзәтелгән, эти дөресләп чыккан. Миндә дингә ихтирам бар — дөрес, инде үзем дин тотмыйм, без бит аракы эчәбез, дуңгыз ите ашыйбыз, ураза тотмыйбыз, намаз укымыйбыз. Митингларда безнең кебек үк гонаһлы кешеләр чыгыш ясап, бу җыелышка тиз генә дини төс бирергә омтылалар. Микрофон янына килләр дә:

— Әссәламогъәләйкем вә рәхмәтуллаһу вә бәрәкәтеһү,— дип халыкка дәшәләр.

Ә нигә чит телдә дәшәргә? Әгәр син шуннан ары гарәп телен белмисең икән, нигә кыланырга? Мин, мәсәлән, микрофонга килеп «бонжур» яки «гутен таг» дип әйтеп, шуннан да ары китәрлек мөмкинлегең юк икән, аларны әйткәннән генә мин француз да, герман да була алмыйм.

Сез игътибар итәсезме икән, үзгәртеп кору һавасында әллә кемнәр өскә калкып чыкты. Хәзер үзе дин тотмаган кайберәүләр дингә өнди, татар телендә сөйләшә белмәгән яки гаиләсендә балалары белән рус телендә сөйләшеп яшәгән кешеләр татар теле мәсьәләләрен күтәреп чыгалар, милләт мәнфәгате өчен 30—40 ел буе сукыр бер тиенлек файда китермәгән кеше бүген шау итеп милләт хадиме исемен күтәреп йөри. Тукай әйткәнчә инде: «Шауладык без, «шуу!» иттек, кузгалдык без «дуу!» иттек...

Менә татар алфавиты мәсьәләсен генә алыйк. Шуны бит бөтен кискенлеге белән куярга иде: 1939 елга кадәр бездә бик мөкәммәл алфавит — «Яңалиф» бар иде. Ул алфавитта безнең татар авызыннан чыккан бөтен авазга да хәреф бар иде. Тотарга да шуңа кайтырга! Юк, сузалар, эшкә ашмаслык проектлар тәкъдим итәләр.

ТИУнең эшен исә мин хуплыйм. Шуның эшчәнлеге аркасында гына лексиконыбызга әлек каһәрләнгән бик күп сүзләр кайтты, туган телебездә күп газеталар ачылды. ТИУ — бүгенге көндә идеяләр генераторы, сәяси хәрәкәт мәйданы булып тора.

Миңа карата «үз кабыгына бикләнү» сүзе туры килми. Газеталарда мәкаләләрем белән катнашып, мин дә милләтемнең күзен ачарга үземнән өлеш кертәм. Сез белсәгез иде, «хезмәт һәм сугыш ветераны» дигән катлау кешеләреннән миңа күпме хат килә! Алар эт итеп мине сүгәләр, Сталинга тел тидермәскә кушалар. Мин гаҗәпкә калам: болар чабатага, кычыткан ашына, «уфалла» арбасына, репрессияләргә кире кайтырга чакыралар. Сталин төрмәләрне аз салдырган, тиешенчә аттырмаган, әле тагын да күбрәк атарга кирәк иде, дип язалар. Безнең халкыбыз шулкадәр надан, шулкадәр кол микәнни — гаҗәпкә каласың. Хәтта галимнәрнең зур күпчелеге һаман әле Сталин режимын сагынып яши, әдәбиятыбызны, тарихыбызны яңача өйрәнү кирәк дип фикер әйтә башласаң, тиз генә ыжгырынып өстеңә ташланалар, утызынчы еллар шаукымындагы үтерергә, яндырырга, җимерергә, бөтен дөньяда революция ясарга, кан коярга чакырган әдәби әсәрләрне сабый балалар өчен булган дәреслекләрдә саклап калырга тырышалар.

Кыскасы, Сталин режимы әйләнеп кайтканны көтәләр. Бу шартларда намусы булган каләм иясе кабыгына бикләнеп ята алмый, әлбәттә. Көрәш — митинг белән генә бармый, минемчә, ул каләм сүзе белән дә бара.

*— 1990 елның 30 августы татар халкының милли бәйсезлек алу көне булып тарихка кереп калды. Бу көнне Республика Югары Советының чираттан тыш сессиясендә Татарстанның дәүләт суверенитеты турында Декларация кабул ителде. Республикабызның туган көне алдагы тормышыбызда яңа маяклар билгели, милләтләр арасындагы тигезлеккә һәм чын интернационализмга юл ача. Ләкин артык беркатлы булмыйк әле: Сталин һәм Брежнев конституцияләре кәгазьдә бик матур иде, ә гамәлдә әнә ничек килеп чыкты... Бу очракта да алдану хәвефе юкмы? Гомумән, татар халкының киләчәге нинди булыр дип кузаллыйсыз?*

— Сүз суверенитет турында бара бит инде. Әлбәттә, 30 август көнне депутатлар зур тарихи җиңүгә ирештеләр. Монда безнең язучы депутатларның чыгышы да хәлиткеч роль уйнады. Нибары бер депутат — Бәхтиевме әле? — икеләнеп калды. Мин инде аны икенче көнне үк сайлаучылары кире чакырып алыр дип уйлаган идем, ләкин безнең халык андый сәяси маршларга әзер түгел икән әле.

Хәзер мөстәкыйльлекне мин крестьянча гадирәк итеп күз алдына китерәм. Бу елның гыйнвар аенда без Тәлгать Галиуллин белән Чаллы шәһәренең «Полимер» заводында булып, цехларда йөрдек. Анда оргсинтез заводы калдыкларыннан, ташландык полиэтилен, целлофан капчыклардан, кыскасы, чүплектә, басуда, урамда аунап яткан синтетик чүп-чардан халык хуҗалыгы өчен кирәк булган әйбер эшлиләр: шланглар, торбалар, пакетлар, канистрлар, бачоклар, шешә тартмалары. Чүптән валюта ясыйлар. Заводның директоры Эльмен Әбүзәр оглы Гасанов мөстәкыйльлекне болай аңлый икән. Ул үзе эшләп чыгарган товарны бары тик алмашу юлы белән генә сата. Колхоз председателе, әйтик, яңа торба сорап килә. Директор исә ул торбаларны иткә алыштыра. Заводның үз кибетләре бар. Эшчеләр ашханәдә бушлай ашый. Кытайдан моңа килгәннәр нидер сорап — ул үзенең продукциясе өчен алардан туннар, яхшы аяк киемнәре алган да бөтен эшчеләрен киендергән. Тагын кайсыдыр илдән килгәннәр, ул исә алардан ике тонна һинд чәе алган. Принцип: мә сиңа, бир миңа. Директор әйтә: «Татарстаннан продукция үзеннән артканнан соң гына читкә сатылырга тиеш»,— ди. Чыннан да, ни өчен әле Татарстан үзе, авызын ачканда үпкәсе күренгән көе, читкә продукция чыгарырга тиеш?

Безнең мөстәкыйльлек, шулай итеп, күбрәк телдә әле. Ләкин бу беренче адым — сәяси әһәмиятле зур акт инде.

Татарстанның киләчәген мин баюда дип карыйм. Без бай булырга тиеш.

...Яфрак кына ашап, биленә чүпрәк кенә бәйләп, китмән белән коралланып гомер иткән гарәпнең бакчасына скважина куярга кирәк була. Бер атнадан инде бу хәерче гарәп Лондон яки Парижның иң затлы ресторанында утыра, алдында оҗмах азыклары, тезләрендә шул шәһәрнең иң гүзәл «миссисе». Зур шәһәр туйдыргач, ул әлеге «миссис» белән икесенә махсус самолет алып, Балеар утрауларына ял итәргә китә. Менә сиңа бер скважина!..

Безнең социалистик идеология гомер буе ярлылыкны, хәерчелекне мактап, хәерче булырга чакырып килде. Бу — безнең тарихи фаҗигабез. Кеше бай булырга, бай яшәргә тиеш. Карагыз сез утызынчы еллардагы шигырь-җырларны — без бит инде шулар белән тәрбияләнеп үстек. «Ярлы кызы — сөйгәнем...» дигән күпме җыр бар иде сәхнәдә.

Безнең халкыбыз тарихи яктан надан. Мин гап-гади авылда туып үстем, авылыбызда байлар, алпавытлар булмаган. Картлар, колхоз аларны умач ашына һәм чабатага калдыргач, сагынып сөйлиләр иде: элек һәр хуҗалык көзгә ат симертеп суйган, казылык ясаган, кыш буе пешеренеп-төшеренеп чыкканнар. Каз-үрдәкне мул асраганнар, көзен-кышын өмәләр ясап яшәгәннәр. Җәй көне җыен вакытында кунакка йөрешкәннәр. Күп кәҗә асраганнар, шәл бәйләгәннәр. Авылда фәкыйрь, ялкау берничә гаилә булган, алар ялланып мир көтүен көткәннәр. Бер абзыйның сыеры сигез баш булган, ләкин ул яллы хезмәт кулланмаган. Урманлы авыл булганлыктан, «мал курмысы» кайгысын белмәгәннәр, егермешәр баш сарык асраганнар. Ләкин моның белән әле мин «безнең халык бик рәхәт яшәгән» дип әйтергә җыенмыйм. Хуҗалыкны алып бару көн-төн эшләүне таләп иткән, ә эшнең барысы да кул көче белән башкарылган. Физик хезмәт — үзең өчен эшләү никадәр ләззәтле булса, шулкадәр үк газаплы да булган. Ләкин халык тук яшәгән. Дөрес, ачлык каһәрләгән игелексез еллар да булып торган. Тукай иҗатында, М. Галәү романнарында моңа байтак мисал бар.

Безнең тарих бит алпавытларны да сүгә. Ә менә Арча ягындагы алпавыт Габдрахман Ишморатов үз тирәсендәге авылларның барысына да мәчет салдырган, бу биналар әле дә исән, үз гомеренә мәктәп салдырмаган авылларда бу биналар әле дә мәктәп хезмәтен үтәп киләләр. Ишморатов, чит илдән пар машинасы кайтартып, алты пычкылы такта яру агрегатын оештырган. Ул машина үзе чыгарган пычкы чүбен яндырып эшли иде, әле илленче елларга кадәр бөтен районга игелек китереп торды. Алпавытның кирпеч заводы булган, әйләнә-тирә авылларны ул яхшы сортлы кирпеч белән тәэмин иткән. Безнең якта морҗа сүткәндә әле дә булса «Ишморатов кирпече» дип сөйләшәләр, чөнки ул ватылмый. Минем туган йортым 1915 елда салынган, аны ике тапкыр ремонтларга туры килде, димәк, ике тапкыр мич сүтәргә. Безнең бүгенге завод кирпеченнән чыгарылган морҗаны сүтә башласаң, балчык өеме генә кала, ә без ике тапкырында да шул ук Ишморатов кирпечләрен файдаландык. Алпавыт ат заводы тоткан һәм әйләнә-тирә крестьяннар атларының нәселен яңартып торган. Моннан тыш ул авылларга алмагач, чия, канәфер үсентеләре биргән, авылга килгәндә тарантас тутырып китап алып килгән һәм балаларга бушлай өләшкән.

— Кеше хезмәтен кулланган бит ул! — диләр сталинчы-картлар бүген. Әйе, кеше хезмәтен кулланган, без бит КамАЗны да, БАМны да кеше хезмәтен кулланып төзедек.

Г. Ишморатов үзенең имениесендә земская больница ачтырган, анда мин белгәндә карт рус Поляков эшли иде һәм татарлар авырган вакытта бер дә тегендә-монда түгел «Палаков духтыр» янына гына йөриләр иде — тегесе татарча сөйләшә белә. Имениедә шулай ук почта бүлеге дә эшләгән. Мин боларның барысын да 1938 елда ук күргән идем.

Шуннан нәрсә булды соң? Революциядән соң ат заводы бетерелә, тегермән ябыла; кырыгынчы елларда алпавытның сирень бакчасы бетерелә; илленче елларда почта-телеграф ябыла; алтмышынчы елларда — шифаханә; аннан — такта яру агрегаты һ. б., һ. б. Аннан калган биналарда хәзер СПТУ яши — механизаторлар укый. Ничектер биналарны җимереп бетерә алмаганнар.

Октябрь борылышына кадәр Россия хәерче булган дигән сүз — шулай ук ялган. Россия чит илгә икмәк саткан. Анда фән, техника үскән, химия, математика буенча зур ачышлар ясалган. Англия, Франция кебек илләр белән бергә, бездә авиация туган, тимер юллар салынган. 1910—1917 еллар эчендә Россиядә демократия эшләнгән, хокукый дәүләт системасына таба юл салынган. Россиядәге ярминкәләр гөрләп торган, кибетләрдә затлы балык, ит, лимон, әфлисун, һинд чәе, чикләвекләр, балык уылдыгы тулып яткан. Эшләгән, һөнәре булган кеше чабата кимәгән. Татар крестьянының өстендә яхшы кайры тун (бүгенге кибетләрдә аның бәясе 3500 сум!), аягында киез итек, муенында сарык йонынннан бәйләнгән шарф, юлга чыкканда калын толып, баеракларында, «төлке тамак» яки бүре толыбы булган.

Үткәнеңнән көлергә безне Сталин режимы өйрәтте. Әнә Лениногорск районыннан Ф. Хәмзин дигән бер абзый «Социалистик Татарстан» газетасына Россиянең үткәне турында яза; абзый гомере буе китапханәләрдә, архивларда утырып Россия тарихын өйрәнгән дип белерсең. Ул синең бөтен тарихчы галимнәреңне бәргән дә еккан. Вәт кешедә белем! Ул яза: «Соңгы вакытта Ленинга, Бөек Октябрьгә тел-теш тидерүчеләр күбәеп китте. Ә ул кешеләр Россиянең ул чактагы хәлен беләләрме икән? Хәерче Россияне сагынучылар кемнәр дисезме? Шул ук капиталист, кулак, алпавыт балалары яки оныклары. Әйе, алар начар яшәмәде. Әмма кем хисабына шулай типтереп яшәде соң алар? Әлбәттә, гади халык хисабына. Шуңа да халык социалистик революция ясады бит» («Соц. Татарстан», 1991 ел, 22 январь саны).

И абзый, абзый... Кулыңда уч тулы талондыр инде синең, кибетегезнең шүрлекләрендә тычкан аягын сындырырлыктыр инде, ә үзең әле дә булса тормыш

дәрәҗәсе буенча дөньяда беренче урында торган капиталистик Көньяк Кореяны, Тайваньны, Швецияне, Японияне сүгәсең. Беренчедән, нәрсә соң ул капитализм? Син әйтерсең инде, кеше хезмәтеннән файдалану, дип. Ник, социализмда да сарык һәм кәҗә хезмәтеннән түгел, кешенекеннән файдаланалар бит инде. Син әйтерсең инде, анда тиешенчә түләмиләр дип. Ә Япония, Швециядә эшчеләр безнекеләрдән күп яхшырак яши. Ә 1928—1956 елларда колхозда бөтенләй бушка эшләгәнеңне оныттыңмыни? Ак Диңгез-Балтик каналын, яңа шәһәрләр Магнитогорск, Комсомольск-на-Амуре кебекләрне тоткыннар, гаепсез җаннар сөяге өстендә төзегәннәрен белмисеңмени — алай Россия тарихы буенча фикер әйтерлек белемең булгач? Менә мин капиталистик Финляндиядә командировкада булдым, анда тимер юл, һава юлы, су юлы кассаларында чират юк. Заллар буп-буш. Көннең, кичнең теләсә ни вакытында теләсә кайсы кафега, ресторанга кер — чират юк. Килеп керүеңә официант янына меню китереп куя да ризыкны аңлата башлый:

— Менә монысын алмагыз, бүген бу балык бик шәп булып чыкмады,— ди.— Менә моны алыгыз, бүген көн бик салкын, калорий күп кирәк,— ди.

Оялып утырасың. Илең өчен. Ватаның өчен.

Профессор Гомәр Таһири өендә чәй эчеп утырабыз. Хатыны Халидә апа әйтә:

— Карале, картым, үзең кунак чакыргансың, чәй янына куярга пирожныебыз да юк,— ди.

Карт сикереп тора да телефоннан фин телендә сөйләшеп ала. Нәкъ сигез минут үтте — мин моны махсус хәтерләп калдым — ишектә кыңгырау! Көмештәй арбага ак салфетка ябылган, астында көмеш поднос белән пирожное. Егет чытыр ак курткадан, ак башлыктан. Карт аның арбасындагы бер кәгазьгә имзасын гына куйды, акча санап маташмады.

Мин оялып утырам. Үзебез төзегән социалистик тәртипләр өчен.

Менә син, абзый, алпавыт калдыклары дисең. Ә Мәскәү, Ленинград кебек шәһәрләрдә «алпавыт калдыклары» хәзер үзләренең оешмасын торгыздылар. Алар арасында зур галимнәр, артистлар, рәссамнар, зур хәрбиләр, дәүләт эшлеклеләре бар. Син абзый болай әйтергә телисең инде: менә мин — хәерчедән чыккан кеше, шәп кеше; ә тегеләр — бик начар кешеләр. Син әйтергә телисең инде: граф Толстой, дворянин Пушкин, Тургенев, миллионер Дәрдемәнд, мулла малае, эмигрант Гаяз Исхакый (большевизмны җаны-тәне белән кабул итмәгән), Дәүләт Думасы депутаты, мулла улы Садри Максуди, сәүдәгәр фабрикант улы Гадел Кутуй, морзалар нәселеннән булган Әмирхан Еники, Зәйнулла ишан оныгы булган Атилла Расих — бик начар кешеләр; ә менә мин — хәерчедән чыккан, мин — шәп кеше...

Кызганычка каршы, абзый, сез — күпләр. Шулай уйлап, хәерчелегебезгә сокланып, шуның белән мактанып яшәүчеләр, сез — күпләр. Әнә шуңа күрә без мөстәкыйльлеккә дә чыга алмыйбыз инде. Чөнки безнең милли характерыбыз шундый. Мәзәк бар бит: тамугъта ике казан кайный, эчендә кешеләр, ди. Бер казан янында каравыл бар, икенчесе янында юк икән. Комиссия вәкиле инспектор казан янындагы кизүдән сораган, нишләп алай, дигән. Кизү әйткән:

— Бу казанда яһүдләр кайный, аны сакламыйча булмый, чөнки берсе чыкса, калганнарын да коткарачак. Ә монысын саклауның кирәге юк, монысында — татарлар. Берәрсе чыга башласа, икенчесе шундук аны кире тартып казанга төшерә...

Менә бу — без инде.

— *«Перестройка» сүзен без һәрвакыт яратып әйтәбез. Чөнки ул тыныч, үзара аңлашу һәм парламент юлы белән революция ясауга юл ачты, милли үзаңыбызны күтәрде. Әле кайчан гына: «Туган тел бетә! Әдәбиятыбызны укыр кеше калмый!» — дип үзара өметсезлек белән сөйләшә идек. Ярый, без — яшьләр — ялган тарихны укып үстек, хакыйкатьне белми калдык ди. Ихластан әйтегез әле, ә менә күпне күргән сезнең буын үзгәртеп кору, хакыйкатьне әйтеп бирү көннәре киләсен алдан ук чамалый алдымы, юкмы? Әллә инде аңлап та, бөтенесенә кул селтәгән идегезме?*

— Кешеләр диалектик материализм дигән бөек фәнне белеп җиткермиләр. Бу — аларның бәласе. Ул бөек фәнне безгә вузларда Сталинның сыйнфый көрәш, халык дошманнары дигән ялган информациясенә бәйләп укыттылар. Диалектик материализмның исә бик тә элементар бер кагыйдәсе бар: һәр нәрсә үзгәрештә! Мәңгелек берни дә юк. Безнең империябез дә мәңгелек түгел. Борынгы Рим империясе булган, Эль-Искәндәр Зөлкарнәйн дәүләте, Чыңгызлар империясе булган. Бөекбритания, Франция империяләре бар иде, ләкин бит Аристотельләр, Демокритлар, Софокллар, Сократлар әйткәннәр: һәрнәрсә үзгәрештә. Сократ карт әле: «Бер суга ике тапкыр кереп булмый»,— дип тә әйткән. Үзгәртеп коруны без күптән көттек. Ә. Еникинең «Өч аршын җир», Н. Фәттахның «Артта калган юллар», Ш. Хөсәеновның «Әни килде» әсәрләре шул үзгәртеп коруны алдан сизү түгелмени? Язучы, гомумән, алдан сизәргә тиеш.

Муса Җәлил комсомол, пионер турында дежур шигырьләр язып, матбугатта алланы, мәчетне, динне сүгеп гомерен исраф итеп ятканда кинәт кенә тарихи тема — «Алтынчәч» кә килеп керә. Һич тә көтелмәгән пассаж бит. Ничек алай була соң? Шагыйрьнең күңеле алдан сизә. Кулупай пәһлеваннар бөтен илебезне актык кешесенә кадәр бетерергә дип килгәндә, көн тәртибенә бер халыкның икенче бер халыкны бетерү мәсьәләсе куела. М. Җәлил моны язганда Гитлер нәкъ шушындый план корып ята иде бит. Шагыйрь күңеле моны сизгән һәм комсомол рухлы, шикәрле шигырьләрен куеп торып, әнә шундый мөһим темага кергән. Дәрдемәндне алыйк: кайчан язгандыр ул аны, галимнәр әлегә төгәл әйтә алмыйлар, әмма, «капиталист» шагыйрь үзенең, үз сыйныфының киләчәген алдан күргән:

*Куанды ил, канат какты мәләкләр,*
*Шашып, аң-таң булып шайтан төкерде!..*
*Җитәр, җилкенмә, йолкынма, күңел, син.*
*Кияү булсаң да, ул түйга түгел син!*
*Җиһан тормыш туен иткән чагында,*
*Синең урның — үлекләр аймагында.*

1913 елда татар язучыларыннан берәү дә берни дә язмый (вак-төякләр бар, әлбәттә). Чөнки күңелләре сизә: илдә зур вакыйгалар булырга тиеш. Казан губернасының жандарм идарәсе шул мәсьәлә белән баш катыра, эт була: нәрсә көтәләр бу татар язучылары? Нәрсә булырга тиеш? Ф. Әмирхан 1913 елны әдәбиятта фәкыйрьлек елы дип атый. Язучылар көтәләр һәм... ялгышмыйлар.

1914 елга кадәр үк инде кешелек өстенә килеп ятучы беренче бөтендөнья сугышын Герберт Уэллс, Анатоль Франс, Ромен Роллан, Генрих Манн сизгәннәр!

Константин Симонов та, нәкъ Муса Җәлил шикелле, икенче бөтендөнья сугышы булачагын алдан сизгән. 1937 елда язылган «Ледовое побоище» поэмасында ул «Тиздән солдат итеге белән Европадан узарга туры киләчәктер безгә»,— дип яза. М. Шагинян Петербургта гимназиядә укыганда (1902—1903 еллар), Беренче рус революциясе буласын сизә идек, чөнки Россия һавасы революция заряды белән корылган иде, дип яза.

Язучы алдан сизәргә, алдан күрергә тиеш, шулай булмаганда ул — язучымыни?

Юк, без кул селтәмәдек, торгынлык елларында да көрәштек. Цензор Д. Шакирҗанова, түрә идеологлар, надан философлар, партаппарат чиновниклары белән каршылыкка кердек, көрәштек. Каләмебез белән.

Мин — бу көрәшнең иң авангардисты түгел. «Хөрмәтле иптәш...» дип С. Батыевка да, М. Мусинга да китапларымны язып биргәнмендер, бәлки. Мин — герой түгел, шул заманның бер шактый көчсез баласы. Трибуналардан торып бюрократиянең мине сүкмәвен өмет иткәнмендер. Ә бюрократия мине тунады. «Буби мәдрәсәсе» дигән мәкаләм өчен аеруча эләкте. Иң беренче мәкаләләрем «Социалистик Татарстан»да дөнья күргәч, миңа махсус рәвештә «предупредительный удар» ясадылар. Анда К. Гыйззәтов һәм башкаларның мәкаләләре күренде. Минем һәм тагын берничә кешенең исемен кем беренче булып телгә алгандыр инде, хәтерләмим, «үткәндәге шәхесләрне аклый» дип тамга суктылар. М. Әмир ага моны язучылар җыелышында да әйтте. Ул чакта газетада эшләгән Ф. Әгъзәмов моның тарихын яхшы белә. Безнең системадамы? Бездәме? Әгәр сиңа бер тамга тагылсамы? Русча әйткәндә, «не отмоешь». Һәм мин гомер буе кара тамгалы булып яшәдем. Миңа килгән хатлардан әле дә булса шул тамга белән яшәгәнемне аңлыйм. Сталинчы ветераннар мине яратмый. Чөнки заманында Буби мәдрәсәсен, С. Рахманколый, Гали Рәхим һ. б. шәхесләрне күтәреп чыктым.

*— Тарихтагы гаҗәеп бер күренешкә игътибар итик әле. Патша заманында миссионер Ильминский һәм аның дәвамчылары, йөзләрчә ел тырышып та, чукындыру сәясәтен ачыктан-ачык үткәреп тә, татар халкын милли тамырларыннан, туган теле һәм мәдәниятеннән аера алмады. Большевиклар, дөресрәге, Сталин һәм Брежнев хакимияте бу эшне чагыштырмача тиз арада, тавыш-тынсыз гына «менә дигән» итеп башкарып та куйды! Нәрсә, халыкның асылы үзгәрдеме, әллә куркү-өркетүгә корылган сәясәт шулай бик тә нәтиҗәле чара булып чыктымы?*

— Сез милли мәсьәләне Сталин, Брежнев хакимияте тиз арада башкарып куйды дисез. Ләкин бит моның тарихы тирәндә. Иван мөдһиш* Казанны алганчы ук үзенә «бишенче колонна» әзерләгән, татарларның үзләреннән сатлык җаннар туплаган. Без җылый-җылый бәетләр укыйбыз: имеш, Иван патшаның миссионерлары татар халкын елга буйларына этеп китереп, мәҗбүри чукындырган, православие диненә керткән, кан коюы, елаш-ыңгыраш булган. Ә бер тәңкә көмеш акча алыр өчен урыс чиркәвенә үз теләкләре белән кереп динен саткан агай-эне булмаганмы? Патшаларның

* Мөдһиш — явыз.

җир актларын гына өйрәнегез: чукынган татарларга җир бүлеп биргәндә нинди генә уңайлыклар, льготалар каралмаган аларда!..

Инде сезнең сорауда тарихи бер әйбер ята: ничек инде без бетмәгәнбез! Бөтен хикмәт, минемчә, диндә, әлифбада. Рус колонизациясе мәҗүсиләр булган мари, удмурт, мордва һ. б. халыкларга христианлыкны китереп бәйли, тегеләр исә моны артык зур каршылык күрсәтмичә кабул итәләр. «Противостояние» булмый диярлек. Әмма татар ислам дине һәм аның конституциясе белән коралланган була. Ул хәрби, икътисади, сәяси яктан җиңелсә дә, рухи яктан җиңелми, каршы тора, аңарда «противостояние» көчле була. Ә әлифба һәм шул әлифбадагы куәтле әдәбиятны кая куясың?

Бу турыда татарның күренекле журналисты Фатыйх Кәрими әйткән. Аның бу турыдагы Оренбург мәхәлләсе алдындагы чыгышын әләкчеләр Оренбург губернасы жандарм идарәсенә бәйнә-бәйнә язып биргәннәр, архивта мин моны укыдым. «Безне бетерергә теләү безне исән калдырды»,— дигән ул үзенең нотыгында.

Нигә дип без әле «нык үскән социализм»да бик тиз генә телсез, мәктәпсез калдык? Җавап гади. Сталин мәкерле акылга ия кешеләрнең берсе иде. Ул башта динне бетерде. Чиркәүләр, мәчетләр, монастырьларны юк итте. Хәер, аның остазы В. И. Ленин да үзенең эшен попларны, епископларны аттырудан, заложниклар алудан башлаган иде. Татарның бөек галиме Җ. Вәлиди әйтә, кисәтеп әйтә: «Дингә каршы көрәш ул — милләткә каршы көрәш»,— ди.

1930—32 елларда Сталин татарларның элеккеге зыялыларын аңлы рәвештә юк итә. 1937—40 елларда шәрран ярып сталинизмны яклаган зыялыларны (Г. Ибраһимов, Ф. С. Казанлы, К. Тинчурин, Х. Туфан һ. б.) юк итә.

Сәхнә буш кала. Буш калган сәхнәгә дилетантлар, конъюктурщиклар менә. Һәм алар, үз җаннарын саклап, тиз генә барысын да саталар: динне дә, әлифбаны да, шул ук Г. Ибраһимов, Ф. С. Казанлыны да, Мохтар Мутинны да... Г. Нигъмәтине дә, Җ. Вәлидине дә. Яшәргә кирәк бит, күреп торалар, Казан төрмәләре — Плетән төрмәсе, Кирпеч асты (Кремль) төрмәсе галим-голәмә, студент, артист, хәрбиләр, муллалар, поплар, монахлар белән тулган. Сәясәтне бит шәһәр ясый, зыялылар ясый. Авыл ул икътисадны хәл итә. Ә сәясәт ясаучы зыялылар — төрмәдә. Корт анасын юк иткәч, умарта күче бал җыя алмый, ул күч тарала, кыргыйга әйләнә. Без дә шулай. Безнең милләтнең идеологлары Г. Исхакый, С. Максуди, Һ. Атласи, Ф. Кәрими, Җ. Вәлиди, М. Солтангалиев — барысы да тегеләйме-болаймы читкә кагылганнар. Әйтергә кирәк, Сталин аларның барысын да яхшы белгән: 1923 елда рус телендә үзәктә чыккан Җ. Вәлиди китабын укыган ул, чөнки аны авыру Ленин үзенә соратып алдырып укыган... Һәр агач та тупыл яисә тал түгел: башын киссәң, чыршы да, нарат та, каен да (төзү материалы бирә торган агачлар) өскә таба үсә алмый. Без дә шул язмышка дучар булдык. Сез әйтәсез, Ильминскийлар да безне туган телдән аера алмады, дип. Анысы шулай, ләкин милли сәясәт безнең милләтнең бер йомшак ягын «тотып» алды: без үзебезне-үзебез бетерергә дә сәләтле халык, икәнбез.

Әйе, халыкның асылы үзгәрде. Аңа җитмеш өч ел буе тукып тордылар: элек тормыш начар булган, хәзер яхшы! Ач булдык, ләкин «бәхетле балачагыбыз өчен иптәш Сталинга рәхмәт!» дип сәхнәләрдән лозунг кычкырдык.

Кешегә ике ел буе «син — дуңгыз» дип тукып торсаң, ул мыркылдый башлый, диләр. Татар халкы әнә шундыйрак язмышка дучар ителде.

— *Инде әдәбиятка әйләнеп кайтыйк. Мөхәммәт абый, ялгышмасам, Сез әдәби иҗат эшенә кырык яшьтә генә тотындыгыз. Бу — табигый хәл идеме, әллә әдәбиятка артыгы белән соңарып килү идеме? Үкенмисезме — бәлки, иҗатка иртәрәк тотыну хәерлерәк булгандыр...*

— Һич тә үкенмим. Минем беренче язмаларым «Совет мәктәбе», «Чаян»да алтмышынчы еллар башында басылды. «Язгы җылылык» чорында. Шул елларда мин җиңел сулыш алдым: КГБдан әтиемнең гаепсезгә харап ителгәнлеге турында белешмә бирделәр. Мин әдәбиятка чиста күңел белән килдем. Төрмәләрне ачкан вакыт иде. Әгәр элгәрәк килгән булсам, Сталин режимын мактап берәр нәрсә язган булыр идем дә, хәзер шуңа оялып йөрер идем. Бүген исә элек язган бер әсәрем өчен дә оялмыйм. Җаным тыныч. Хәер, гадел булыйк: минем иң беренче мәкаләм унҗиде яшемдә язылган. Беләсезме ул нәрсә турында: «Юлбашчыбызның биографиясен өйрәнәбез». ...Архивымнан моны табып күрсәткәч, балаларым алдында минем дәрәҗә байтакка кимеде.

Аннан соң мәктәп дәреслекләрендә, бүгенге көн күзлегеннән караганда, үземә каршы килә торган бүлекләр бар.

— *Бер әдипнең көнләшеп-яратыпмы, әллә тәнкыйтьләпме, Сезгә карата әйткән*

*сүзләре хәтергә төшә. Ул болай диган иде: «Их, Мөхәммәттәге белем миндә булса!..» Әйе, Сездәге гыйлемне танымый мөмкин түгел. Әдип һәм галим буларак, Сездә ике «мин» кушылып киткән. Алар бер-берсенә комачауламыймы, әдәби әсәрләр язганда үзара «сугышып» аптыратмыйлармы?*

— Язучы гыйлемле булырга тиеш инде ул. Г. Исхакый, Г. Ибраһимов, Ф. Әмирхан — зур галим дә булганнар бит. Инде килеп, Ф. Кәрими, С. Максуди, Дәрдемәнд, Мәхмүт Галәү? Алар барысы да галимнәр. Хәзер әдәбиятка гыйлемне өстән-өстән генә алган яшьләр килә. Мин университетта, кабат әйтәм, утыз елга якын лекция укыдым. Лекцияләремдә, теориядән бигрәк, фактик информацияне күбрәк бирә идем. Күзәтә килдем: каләм тибрәтә башлаган яшь егет яки кыз, беренче әсәрләре матбугатта күренү белән, лекцияләргә йөрүдән туктый.

— Һи-и, алар нәрсә бирә соң миңа,— дип, остазларына өстән генә карый башлый. Редакциягә урнашкач исә тегенди-мондый сораулар белән мөрәҗәгать итә. Белем җитмәгәнлеге сизелә.

Мин берәүдән дә курыкмыйча әйтә алам: XX йөз башы татар әдәбияты курсыннан һәм татар халык иҗатыннан белем бирә идем. Йөзләгән студентларым моңа шаһит. Әмена бер семестрда «Сугыштан соңгы татар әдәбияты» курсын укытырга биргәннәр иде, булдыра алмадым — әзерлегем юк. Ул лекцияләремә йөрмәгән студентлар әллә ни югалтмаганнардыр дип уйлыйм.

Гыйлемле булу һич тә, һич тә әдәби әсәр язарга комачау итми.

*— Авылдагы печән өстен хәтерлик әле. Таза ир-егетләр арасында, гадәттә, шундыйлары була ки, ул печән чабып узганнан соң анда пеләш җир генә утырып кала... Сез, язучы буларак, авыл тормышын күп яздыгыз. Бу мәйданда покосны шулкадәр киң алдырып, гайрәтләнеп, намус белән эшләдегез ки, сугыштан соңгы һәм бүгенге көн татар авылы турында язар өчен инде бүтәннәргә «эш» тә калмады кебек. Бу фикер белән килешәсезме?*

— Авыл турында язучы кешегә нигә әле эш калмасын? Василий Белов әнә, «Кануны» диган әсәр язып, колхозлашу процессын яңа ягы белән ачып бирде. Бармы бездә шундый әсәр? Юк. Безнең галим-голәмә әле дә булса коллективизация дөрес уздырылган, раскулачивание дөрес булган, крестьянны атсыз-тунсыз, җирсез калдыру бик кирәк булган, дип инанып яши. Мин бер-ике тапкыр Һ. Такташның «Киләчәккә хатлар»ын мәктәп дәреслекләренә кертмик, чөнки анда «кулакларны» сөрү, юк итү аклана, шагыйрь канлы көрәшкә чакыра, дип әйтеп караган идем — кая ул! Миңа дәррәү һөҗүм иттеләр. Әдәбият тарихын 40—70 елларда чыккан зәгыйфь, чирле монографияләрдән генә белгән Р. Гатауллинның Такташ юбилеенда сөйләгән докладын әйтмим дә инде, әле бит шул еллардагы газета-журнал тупламаларен актарган кешеләр дә шулай сөйли. Олкән галимнәрдән берәү миңа әйтә:

— Менә минем үземә дин дә, алла да кирәк түгел, мин берсенә дә ышанмыйм,— ди.— Ә ни өчен син мәктәп дәреслекләреннән Такташның динне, коръәнне мыскыл иткән, попларны, муллаларны кыйнарга чакырган шигырьләрен чыгарып ташларга өндисең? Шулмы кирәк? Шулмы плюрализм?

Димәк, мәктәптә Сталинның «Кыскача курс»ын һәм Гитлерның «Майн кампф» әсәрен дә укырга мөмкин. Нинди аерма бар? Сталин «Кыскача курс»та троцкийчыларны, бухаринчыларны бетерергә чакыра, ә Гитлер — славяннарны (укыганым юк, шулай дип язалар), Такташ — нэпманнарны, кулакларны (ягъни, таза тормышлы крестьяннарны).

Такташның искиткеч талантлы — Шекспир дәрәҗәсендә! — язылган «Җир уллары» бар, 1923 елга кадәр язылган гаҗәеп көчле шигырьләре бар. Совет баласыннан әнә шул шигырьләрен яшереп тотабыз без. Үз-үзен ихтирам иткән халыклар мәктәп дәреслекләрендә храмны, чиркәүне, мәчетне сүкмиләр. Бу хәл — бездә генә.

Татар авылы турындагы тема — бетмәс-төкәнмәс хәзинә ул. Әнә шул 1928—30 еллар турындагы хакыйкатьне ачып бирәселәре бар әле язучыларның.

*— Чыңгыз Айтматовның, язучы һәр китабы белән үлә һәм икенчесен язар өчен яңадан туа, диган фикере истә калган. Толстой кебек олуг әдипләрнең дә үз әсәрләрен кат-кат эшләве мәгълүм. Кайта-кайта эшләү — әсәрне камилләштерү билгесеме, әллә талантлан тиешенчә файдаланып җиткермәү һәм ашыкканлык бәласеме?*

— Чыңгыз Айтматов дигәннән... Мин аны, чорыбызның даһие дип, «өчлек»кә кертеп лекция укый идем: Айтматов, Быков, Распутин. Хәзер күңелем бераз үзгәрде. Сәбәбе бер: аның туган җирендә милли сугыш барган, аның милләттәшләренең каны коелган чак, ә ул илче чапанын киеп, имеш, Европада сәясәт эшләп йөри. Люксем-

бургта илче булып утыра. Мин моны Горбачевның да, Айтматовның да кылануы дип кабул иттем. Әйтерсең, бездә МИМО (Московский Институт Международных отношений) юк, әйтерсең, Европага илче итеп җибәрергә махсус әзерләнгән кадрларыбыз юк. Язучы үз халкына авыр вакытта халкы янында булырга тиеш. Безнең ил болай да инде үз илләреннән киткән байтак кешене милли герой итеп оҗмах шартларында яшәтте. Алар арасында язучылар да юк түгел иде.

Инде сорауга җавап: һәркем үзенчә эшли. Берәүләр дүртәр тапкыр күчереп язалар әсәрләрен, икенчеләре басма саен төзәтәләр. Мин бер генә тапкыр язам, машинкадан соң хәреф хаталарын гына төзәтәм.

*— Социалистик реализмга мөнәсәбәтегез ничек? Кыргаяк үзенең аякларын саный башласа, йөрүен онытачак, диләр ич. Язучыга бәлки, төрле иҗат методларыннан читтә тору, аларны белмәү хәерлерәктер. Иҗат методы — әсәрнең эчке хасиятендә, логикасында, табигыйлегендә шикелле...*

— Бу турыда мин «Социалистик Татарстан»да язып чыккан идем инде. Галимнәр риза түгел ич, нишлисең инде. Кирәк диләр, шунсыз булмый диләр, мин бу хакта бүтәнчә бәхәскә керергә уйламыйм. Бәлки, алар хаклыдыр? Хәер, үз әсәрләремдә мин ирекле.

Миңа бернинди «изм» кирәк түгел. Халкыңа әйтәсе сүзең бар икән — әйт. «Яхшылык эшлә дә, суга ташла: халык белмәсә, балык белер»,— дигәннәр. Язганда бер дә тәртә арасына керәсе килми. Минем балачагым «уфалла» арбасының тәртәсе эчендә узды. Мин утын төягән шул арбаны урманның саздлы юлларында тезләнеп, елый-елый өстери идем. Тәртәгә мәхәббәтем юк.

*— Бездә әдәбиятның партиялелеге турында бәхәсләр булып алды. Әдәбият халыкка, җәмгыятькә хезмәт итә, дибез. Ә бит хәзер халык арасында төрле сәяси агымнар, төрле партияләр яши. Әдәбият шуларның барысына да берьюлы хезмәт итә аламы сезнеңчә? Гомумән, партиялелек теориясенә карашыгыз ничек?*

— Алдагы сорау белән болар икесе бер. Менә бер төркем язучылар бүген КПССтан чыктылар. Шау итеп, әйтеп, язып. Алар үз иҗатларында кайсы партиягә хезмәт итәргә тиешләр? Бездә бит хәзер партияләр күп. Әдәбиятның партияле булуы нәрсәгә китерде соң? Сталин партиясе авыл крестьяннарын Себергә сөрде, партияле әдәбият моны хуплады. Сталин «промпартия эше» уйлап чыгарды, завод-фабрикаларда, шахталарда «корткычлар» эзләү китте, татар әдәбияты шул темага драмалар, хикәяләр язды. Сталин «Солтангалиев эше» уйлап чыгарды, татар әдәбияты Солтангалиевне сүкте. Әдәбият беренче чиратта гуманизмга хезмәт итәргә тиеш. Кайсы партия шул максатка хезмәт итсә, шул партия әдәбиятның гуманистик миссиясенә таяна, аның белән коралланa ала. Без сокланып укыган Аркадий Гайдар да партияле әдәбият тудырган иде, әмма үзе гуманлы булмаган. Кызыл Армия отрядлары белән командалык иткәндә ул бик күп крестьянны аттырган. Александр Фадеев «Яшь гвардия»се дә партияле әдәбият иде, ләкин бу роман нахакка кешеләрне гаепләү, аларны төрмәдә тоту өчен нигез булган. (Бу хакта 1990 елда «Огонек» журналында мәгълүмат чыкты).

*— Хәбәрдарлык һәм тыелган темаларның бетерелүе нәтиҗәсендә, әдәбиятта кара төсләр артып китте шикелле. Әдәбиятның беренчел бурычы — кешегә матурлык тойгысы, эстетик тәрбия бирү. Кеше дигәнең социализмда да, капитализмда да һәм бәхетле, һәм бәхетсез булырга мөмкин. Безгә кешене югалтмау кыйммәт. Әгәр без кара төсләргә һаман саен ешрак мөрәҗәгать итсәк, әдәбият акрынлап матурлык тәрбияләү кебек кешелекле сыйфатыннан читләшмәс микән? Укучы арымасмы? Хәзерге буталчык, әхлакый кыйммәтләр югала барган шушы заманда рухи маякларга ихтыяҗ зур дип беләм.*

— Тормыштагы кара тапларны ачып бетерергә кирәк дип саныйм. Достоевский, Горький, Успенский шулай эшләгәннәр. Шуларны ачканда да тормыштагы саф күңелләләрне күрсәтеп була. Моның матур үрнәге бар бездә. Ул — М. Галәү романнары. Татар тормышындагы нинди зур драмаларны тасвирлап, ул ак төсләрне дә күрсәтә алган. Сез «рухи маякларга ихтыяҗ» дисез. Әдәбиятта рухи маяк бары тик хакыйкать кенә була ала. Калганы — язучының осталыгыннан тора. «Укучы арымасмы?» — дип хакыйкатьне тагын иннек-кершәнгә манып күрсәтә башлыйкмы? Укучы, киресенчә, ялганнан арды. Аны шуннан азат итәргә кирәк. Мин проза жанрында эшлим, ләкин күрмим түгел: прозабыз авырый. Укыр нәрсә бик санаулы.

*— Сезнең яшәү принцибыгыз бармы? Ул ничек?*

— Яшәү принцибы каян килсен инде безгә? Андый принциплар белән яшәү өчен син беренче чиратта матди яктан иректе булырга тиешсең. Лев Толстой, кышын Мәскәүдәге квартирасына килгәч, берничә көн буе яза алмаган. Гаиләдә киеренкелек туган. Ахырдан сәбәбен белгәннәр: ул Ясная Полянада яраткан авторучкасын онытып калдырган икән. Ясная Полянага шундук кеше чаптырганнар... Ә минем язып утырырга кабинетым юк.

Тормышымда эти-әни биреп калдырган принциплар бар. Ул турыда мин инде «Торналар төшкән җирдә» повестемда яздым. Эти-әни мине кеше малын, дәүләт милкен урламаска өйрәтте. Малаем дүрт яшендә вакытта балалар бакчасында бер кызның конфетын урлап алып кайткан иде. Сораштым.

— Аның әнисе буфетта эшли, аңа көн саен шоколад бирә, ә сез миңа бирмисез,— дип, ул үзенең бу эшен теоретик яктан нигезләде.

Иртәгесен без зур бер эш итеп конфетны теге кызның элгечтәге пальтосының кесәсенә илтеп салдык. Малаем шул хәтле бәхетле иде бу минутта.

Мин үз гомеремдә бер генә анонимка да язмадым. Бер кеше өстеннән әләк тә язмадым. Бу эшләргә нәфрәт белән карадым, чөнки әләк мине этисез калдырган иде.

Тагын нинди принципларым бар? Иртәнге почтаны актармыйча эшкә утыра алмыйм. Төшкә кадәр телефоннан чылтыратып бүлдергәннәрен яратмыйм, моны үземнең бер-ике генә дустыма рөхсәт итәм. Телефоннан озак сөйләшкән кеше минем ярты сәламәтлегемне ала. Мин андый вакытта утырам, басам, ятам, ат кебек аунargрыйм, эт кебек кашынам, ә\ теге кеше сүзен өзми дә өзми. Миңа аннан соң элеккеге эзгә керү өчен бер-ике сәгать вакыт кирәк була.

Тагын нәрсә? Финанс ягыннан мин бай түгел, чөнки драматург булып китә алмадым, шулай да кесәдә ничә сум акча барын белмичә йөрергә яратам. Ягъни санамыйча. Акча бик тәртипсез, ул өстәлдә кәгазьләр арасында да, календарь арасында да, паспорт эчендә дә була. Гомумән, 1955 елда хәрби хезмәттән кайтып эшли башлаганнан бирле акчага мохтаҗлык күрмәдем. Балаларымны акчага азындырмадым, алар миннән акча сораганда биреп барам, ләкин бик каты «ответ» белән: бу акча нәрсәгә, нәрсә алу өчен? Әгәр шул әйбернең кирәклегенә мине ышандыралар икән, берninди тоткарлык юк. Нигә шундый мөнәсәбәт акчага? 1935 елларда налог түләп кешелектән чыккан этинең авыр сулап әйткәне үзәгемә үтеп калган:

— Ай, көненә бер генә тәңкә акча керсә иде,— дип әйткәли иде ул. Ә без — хокуксызлар — алты бала идек, сыерыбыз юк, этине «хокуксыз» дип колхозга алмыйлар иде. Этинең колхозга алуларын сорап язган җиде гаризасы саклана иде. Барысында да бер сүз: «Мине колхозга алыгыз, колхозга умартачылык оештырып бирәм, үз умарталарымны да шунда тапшырам». Барысында да бер төрле генә: «Хокуксыз булганлыктан, колхозга алмаска». Имза. Ә беләсезме имзалар кемнеке? Барысы да 1915—30 елларда эти кулында укыган егетләрнеке. Алар 1928—30 елларда коммунист булып алганнар да, иң беренче эш итеп безне талауга тотынганнар. Йортка кереп, самавыр, түшәк, урындык, кара савытларына конфискация ясап йөрүчеләр төянеп чыгып киткәч, эти әйтә иде:

— Менә монысы минем иң яхшы укучым иде...

— Менә монысы язу буенча иң беренче иде.

Этине шулкадәр кычкыртып таладылар. Аннан төрмәгә озаттылар. Ләкин ул коммунистларның бик күбесе биографиясен начар очлады: эчүчелеккә сабышумы, колхоз милкен урлаумы, чит ояда бала үстерүме һ. б. Берсе, мин инде аякка баскач, кибет алдында ялынып миннән бер тәңкә акча сорады: үләм, энем, башым авырта, диде. Бер сум бирдем. Шул ук көнне моның хатыны миннән бер пачка чәй алырга акча сорап торды. Анысына да бирдем.

Менә сезгә, Рашат туган, принциплар.

*— Уйлый китсәң, бездә — бүгенге көн татар әдәбиятында — менә дигән шагыйрьләр, прозаиклар, драматурглар бар. Язучы таланты милләтенә, туган халкына хезмәт итә — бу кадәресе бик әйбәт. Ләкин милләтнең зурлыгын, бөеклеген, мәдәният сараеның иң биек ноктасын манарадай калкып торган зур шәхесләр, шул исәптән күренекле әдипләр дә билгели. Ни өчен әдипләребез (әйтик, Чыңгыз Айтматовтай) бөтенсоюз яисә бөтендөнья мәйданына чыга алмый? Сәбәбе нәрсәдә?*

— Бездә «школа» юк. Әлбәттә, Айтматов зур талант. Бездә әлегә андый популяр язучы күренми. Айтматов үз халкының бөтен милли сыйфатларын, бизәкләрен сеңдергән дә, үзе рус телендә язып, Мәскәү дәрәҗәсендә генә эш итә башлаган. Аны Европа, Африка, Азия тиз күреп алды. Ләкин мин М. Галәүнең ике романы һич тә Ч. Айтматов әсәрләреннән ким дип уйламыйм. Әмма без — яңгырамыйбыз. Каһәр суккан, сортларга аерылган структурабыз да «ярдәм итә» монда. Чит ил бит СССРдагы

унбиш халыкны гына белә. Ә без аларда «учетта» тормыйбыз. Мин яшь чагымда дистәдән артык «капиталистик» дигән илләрдә булдым, «татар әдәбияты», «татар милләте» дигәнне белгән, ишеткән кешене очратмадым. Менә хәзер капкалар ачылды инде, ә нигә, әйтик, Ә. Еникинең «Матурлык» хикәясен французча, инглизчә яңгыратмаска? Сез әйткән «манара» әнә шулай ясала. Аннан: безне кем тәрҗемә итә соң? Мәскәү. Ул синең милли бизәгеңне каян белсен? Мәскәү бит тәрҗемәчене безгә үзе билгели. Әнә Тукайны гына карагыз? С. Липкинның «Шүрәле»сеннән башка, П. Радимовның берничә тәрҗемәсеннән башка рус укучысы өчен Тукайдан нәрсә бар соң? Минем бер әсәремне Мәскәүдә чыгарганда, тәрҗемәче белән безнең арада мондыйрак язышу барды: кышкы юл кырыендагы маяклар — ул нәрсә? Мунча сыерчыгы — ул нәрсә? Көлтәдән куйган чүмәлә белән көлтәдән куйган кибән арасында нинди аерма бар? һ. б.

Айтматов дәрәҗәсендәге прозаиклар яшьләрдән чыгар дип уйламыйм. Игътибар иткәнегез бармы икән, бездән соң килгән бик күп прозаиклар еламыйча язалар. Язарга кирәк, күләм кирәк, роман яки повесть кирәк, бастырырга мөмкинлек бар, шуңа күрә язалар. Үземне кемнән дә булса өстен куярга омтылмыйм, ләкин минем дә «Мәңгелек яз» романымны бик күп кеше «барып чыкмаган» дип бәяләде. Ничек кенә булмасын, Айтматов дәрәҗәсендә әсәр тудыру өчен табигый талант һәм зур тормыш мәктәбе кирәк. Хәер, болар яңа фикер түгел. Өченче сортлы «автономияле республика» баласы ул зур мәктәпне кайда узсын инде? Булачак татар язучылары бит вуз тәмамлауга Казанда калалар, ә Казан — татар шәһәре түгел. Безнең шәһәрдә милли рух юк. Казан татары ул — синтетик татар. Бу атмосферада милләтнең зур язучысы туа алмый. Татар баласы вак тормыш эчендә гомерен уздыра: Казанда калуга, аңа квартира кирәк була. Мин үзем гаилә белән Казанга күчеп килгәч, сигез елдан соң гына квартира алдым — университеттан. Аннан яшь гаиләдә балалар бакчасы кайгысы, акча җиткерү, ашау-эчү мәсьәләсенең кыенлыгы. Шәһәрдә транспорт, кешегә хезмәт күрсәтү сферасының гадәттән тыш начарлыгы. Нервлары киерелгән чиратлар. Без бит социаль яктан беркем тарафыннан да яклау таба алмыйбыз. Казанның күпме эшчесе утызынчы еллардан бирле заводларда сугыш коралы ясый. Без инде аны, матур итеп, «оборона» дип сөйлибез. Ләкин ул оборона заводларының коралы белән 1968 елда Чехословакиягә бәреп кермәделәрме, 1979 елда Әфганстанга кермәделәрме? Гыйракка күпме корал сатканнар бездә Брежнев чорында! Үлем коралы эшләп яткан шәһәрдә әхлак була алмый. Язучы булырга тиешле яшь кеше әнә шул шәһәрнең ике тегермән ташы арасында кала — аннан сәламәт килеш чыгуы бик авыр.

*— Әдәбиятка килүче яшьләргә нинди теләкләрегез бар?*

— Нәрсә әйтим? Эшләргә кирәк. Бик аз эшлиләр бит яшьләр. Стационарда биш ел укып күпме белем алып чыгалар: сөйләшә башласаң, шаккатасың — алар безнең буын язучыларыннан акыллырак. Ләкин бик күбесе вакытын бушка уздыра, фразёр хәлендә йөри. Тукай үзенең җайсыз, уңайсыз тормышында җиде ел иҗат итеп безгә биш томлык әсәр калдырган, авыру Г. Ибраһимовныкы да ун томга бетмәс. Параличтан җәфа чигеп аяксыз калып яшәгән Ф. Әмирханнан күпме мирас! Г. Исхакый төрмәдә дә иҗат эшен ташламаган. Үрнәкләр җитәрлек — яшьләргә җиң сызганып иҗат итәргә кирәк. Хәзер язган әсәрең өчен өлкә комитетына чакыртып «келәм»гә бастырып торулар бетте. Язучылар белән КГБ да шөгыльләнмидер дип беләм.

Халыкка хезмәт итү бары тик эш белән генә була ала.

Әңгәмәне **Рашат НИЗАМИЕВ** үткәрде.

# *Ибраһим Салаховка 80 яшь*



Бүген — туксан беренче елның бишенче мае. Гүзәл яз! Әүвәл башлап шуны билгеләп, хәтердә төйнәп куйыйк. Ил белән катлаулы, буталчык күчеш чоры кичерәбез. Базар бәяләре генә түгел, аң, мөнәсәбәтләр тамырдан үзгәрә, язмышбызга, тулаем яшәешебезгә, кылган бар гамәлләребезгә, гамәл кылучыларга, тормыш баскычларына бәһаләр алмашына. Бүген әйткәннәр иртәгегә ярармы, кичә ордым-бәрдем ычкындырган сүз-фикер өчен кызарырга туры килмәсме — һәммәсен җидегә тапкырлап җиде кат үлчәргә кирәк. Ары-бире карангалап, төрле тарафтан ыжгырган җилгә колакны турылап, бүген «алкышлар астында, бертавыштан» раслаган йомгаклау фикерләреннән, тиз-тиз, «ай-һай, кеше күрмәсә ярар иде!» — дип баш тартмабызмы?

Моңарчы тыелып торган, югары даирәләр ачкан улакларга гына сыярга мәҗбүр ителгән сүз ташкыны бүген катлы-катлы ташлап, фикер буталышлары китереп чыгарды. Сүзгә, бәхәсләргә бирелеп, кайда гаделлек, кайда хыянәт икәнен аермас дәрәҗәгә җиттек. Тарихта, бүгенге көнебез дә нык болгана, туктаусыз тулгана, ә иртәгеге көн хакында кыеп сүз әйтергә дә куркыныч.

Сүзләр, сүзләр, сүзләр... Сүзләрнең кадере калмады. Иллә мәгәр бүген күңелем борчулы тыныч, әйтергә җыенган сүзем хак, уйларымда ярашу, юмалау, ялганның орнаты да юк. Туксан бернең егерме бишенче мае, Азатлык мәйданында рухи яңарышның узаманнары ач тора, милли каһарманнарыбыз Ил-көнебез, Идел-йортыбыз, бөек Татар дәүләте өчен җәфа чигә. Бүген ялган уй йөртергә дә, хаксыз сүз ычкындырырга да рөхсәт юк. Бүген мин сүзне милләт батыры, җирдә сиксән ел яшәп, үзенең кемлеген халыкка, илгә раслаган мөхтәрәм Ибраһим ага Салахов турында алып бармакчы булам.

Егерменче гасыр — татар өчен иң фаҗигале гасырларның берсе. Явыз Иваннан исән кала алган татар токымын егерменче гасырда дәүләт башына менеп утырган большевизм сытып-изеп бетерә язды. Тоташтан һәлакәт, фаҗигаләр эсканҗәсендә милләтебезне кемнәрнең һәм ничек итеп саклап калулары турында әле тарих тугры хөкемен әйтер. Егерменче гасырның татар өчен тар гына калган капкасын ябарга җыенабыз лабаса! Шартлатып ябабызмы без аны, әллә юаш кына, курка-курка кысып куябызмы? Уйласаң исең китәр: кыска гасыр дәвамында җир-күгебез бозылды, елга-күлләр чүплек базына әйләнде, басу-кырларыбыз тереклек чыганагы булудан туктап, кеше сәламәтлеген какшатырга керештеләр. Әдәбият-сәнгать аксады, моңыбыз җәрәхәтләнде, нәтиҗәдә — кеше күңеле бозылды. Күңеле бозыклар туган иленә төкереп карый башлый, телен оныта, милли тарихыннан йөз чөерә, дошманнары кочагына һич икеләнмичә күчә. Гасыр дәвамында ничәгә төрләнмәде татар! Шушы караңгы дәвердә сиксән ел яши алган, милләтенә тырнак очы кадәр дә хыянәт итмәгән, җәһәннәм газапларына баш бирмәгән, алай гынамы сиңа, каралык белән өзлексез көрәшкән олпат ирләребез арасында Ибраһим аганың да якты исеме, гыйбрәт булырлык гамәлләре бар. Бу җәһәттән мин аны милли каһарманнарыбыз Әмирхан Еники, Сибгат Хәкимнәр белән янәшә куяр идем. Әле Әмирхан Еникинең фаҗигале язмышы тулысынча халыкка барып ирешмәгән, бу юнәлештә ул үзе башлап сүз әйтте, журналыбызның 4 санында «Кем җаваплы?» дип исемләп, тормышының бер сәхифәсен укып бирде. Сибгат ага Хәкимнең тирәнгә яшеренгән фаҗигасе бөтенләй караңгылыкта кала килә. Сибгат агага багышлап хатирәләр язучылар сак һәм абай булсыннар, бәгырьләрне өзә торган «Өянкеләр», «Фазыл чишмә»се җырлары, ярты сүздән аңлаешлы моң гына түгел,

алар зирәк ил агасының ил колагына җиткерергә теләгән ораны да! Күлле Киме өянкеләре аша шагыйрь җәрәхәтләр белән телгәләнгән йөрәгенең серен, моңсу ишарәләр аша безгә, алдагы буыннарга җиткерергә омтыла. Әлегәчә безнең Әмирхан Еники, Сибгат Хәким язмышлары аша тарих тирәнлегенә үтеп керергә тырышканыбыз юк, без һаман сай сөрәбез, ярдан ерак китмичә генә сайда быкырдыйбыз.

Ибраһим Салахов хакында без күбрәк беләбез. Әдипнең иң кадерле китабы, байтак еллар качып-посып тирән баз-төрмәдә ятарга мәҗбүр ителсә дә, Ибраһим аганың һәм татар халкының йөз аклыгы булган «Тайгак кичү» романы якты дөнья күрде. Соңра «Колыма хикәяләре» дип исемләнгән бу мәшһүр романга керердән элек, әдипнең икенче бер романына — «Иманнар тамыр җәйгәндә» әсәренә бераз уебызны юнәлтик әле.

Бу ике китапны бер-берсеннән нигә аерып булмый икәнен алдарак күрербез.

Татар — зур милләт, бар аның токымы мәгърур кыпчаклардан килә торган ишле мишәре, дөнья тарихында нугай дип аталып сеңеп калган икенче бер тармагы бар, әлегәчә тарихы әдәбиятта тиешле бәя таба алмаган данлы Күчем хан дәвамчылары — себер татарлары бар. Әле без белмәгән, язмышлары урыс казаклары станына барып ялганган «т а т а р  к а з а к л а р ы» да булган. Мәшһүр режиссерыбыз, бүген нигәдер күзебездән китеп торган, картлыгында да егетлеген саклаган, яшьләргә күп акыл биргән тынгысыз Габдулла ага Йосыпов үзенең «татар казагы» булуы белән чиксез горурлана иде. Һәм шушы без белмәгән, күрмәгән татар кабиләсе  к а з а к л а р  арасыннан Ибраһим Салахов әдәбиятка һәм татар дөньясына ИЛЧЕ булып килде. Балтач ягы тумасы Ибраһим Салаховны язмыш Күкчәтау далаларына илтеп ташлый һәм ул шул якның атаклы улына әверелә. Татар казакларының тормышын, көн-күрмешен, гореф-гадәтләрен, гаскәргә озату йолаларын, Сабан туйларын, сөю-сөешүләрен, татулыгын, сугышчанлыгын әсәрендә ышандырырлык вакыйгалар аша ачып бирде.

Романның исеменә игътибар итегез: «Иманнар тамыр җәйгәндә». Октябрь революциясе алды чорын бәян иткән бу роман исеменең сере бик гади, фаҗигасе чамасыз авыр...

Тырыш, үзара дус, гадел татар казакларының тормышы Россия империясендә җиңелдән түгел һәм иманга тиң казаклар җәбер-җәфалардан, кимсетелүләрдән котылу юлларын эзләгәндә большевикларга юлыгалар. Большевиклар хакимияте, совет власте бу иманнарга мәңге нык булырдай тамыр җәяргә юл ачачак, дип ышаналар. Кашки! Шулай булсачы!.. Бу роман — сабыйларча өмет баглаган большевизмның казакларны һәлакәткә илткән авыр юл турында булып чыга. Әйе, большевиклар ялган вәгъдәләренә, шалтыравыклы шигарьләренә, Ленин игълан иткән властьның «эшче-крестьян» власте икәнлегенә беркатлы инанган һәм шул ышанычлары белән бер дә юкка корбан ителгән асыл татарларга багышлый Ибраһим ага бу әсәрен. Бездә хәзер большевикларга, коммунистларга бер төрлерәк караш ныгып килә. Булган, октябрь идеалларына чын күңелдән ышанган, большевикларның саташулы идеалларына баш биреп гомерләрен кызганмаган гадиләр булган. Алдарак офыкны яулап алачак тираннар гадиләрнең әнә шул ышануларыннан явызларча файдаланганнар да инде!..

Роман озак һәм бик күп көч түгеп язылган. Әсәрен башлаганда Ибраһим ага үзе дә әле яшьлек еллары, комсомол шаукымыннан арынып бетә алмагандыр, чөнки совет власте, большевиклар режимы геройларның якты өметләренә манчылып тасвирлана. Әле әсәрдә иманнарнең тамыр җәясенә тулы ышаныч яши. Татар казакларының башын кисы кылычлар инде коелган булса да, иртәгесе көннең шушы кадәр явызлык китерәсен берәү дә башына китереп карамый. Болары әле алда булачак, Октябрьгә берсүзсез ышанган, большевикларның мәкерле планнарын, аларның канлы тираниягә омтылуларын аңламаган миң-миллионнарның озакламый Колыма, Магадан, Караганда лагерьларында һәлак ителәчәген без бер ишарәдә дә әле күрә алмыйбыз...

«Иманнар тамыр җәйгәндә» — бу якты өметләр, ышанулар, бүтәннәрне дә шуңа ышандырулар, кешелек тарихының кискен каршылыкларын социализм идеяләре юкка чыгара дип, алдагы көннәрдән бары тик гаделлек, яхшылык кына көтеп торулар...

Һәм тормыш бөтенләй кире якка, төрмә-лагерь юлларына кереп китә. Ленин-Сталин корган дәүләт берәүне дә, шул җөмләдән, иманнар булып совет властена иңнәрен куйган гади большевикларны да аямый. Тора-бара совет властеның югары эшелоннарына да кулы җитә большевик җәлладларның!.. Заман Ибраһим Салаховны да ялмап йота. Аны да чәбәләнгән тарих мәйданнарына — Колыма җәһәннәменә илтеп ыргыта! Һәм бу яңа дөньяның тулы вәкаләтле ИЛЧЕСЕ булып, ул Күкчәтау ягына кайтып егыла. Бу юлы ул бөтенләй башка кеше, аяусыз реалист, аның миң-миллион корбаннар исеменнән сөйләргә тулы хакы бар...

Бу ике романны бер-беренең дәвамы рәвешендә һәм аларга уртак бәя биреп йөртергә вакыт җитмәдеме икән? Бу ике романда күтәрелгән һәм дәвамлы чишелгән мәсьәләләр милли казанышларыбызны бер баскыч өскә күтәрә алачак. Ибраһим Салахов кебек якты шәхесләр милләтне югары күтәрсә, милләт тарафыннан кабул ителгән шәхесләр тарихны ныгыталар, явызлар төрле тарафтан аны кимерергә вә җимерергә ташланганда корыч калкан ролен үтиләр. «Иманнар тамыр җәйгәндә» һәм «Колыма хикәяләре» — большевизм салган канлы юллар чагылышы.

Заман көнләп түгел, сәгатьләп үзгәрә. Төпле акыл ияләребез ишәя, көнне генә түгел, кара төнне дә үткен күз аша күрә алырлык яшь әдипләр барлыкка килде. Заманны татарча, татар ихтыяҗларыннан чыгып аңларга омтылучы зыялылар көн туса арта тора; юристлар, инженерлар, экономистлар, завод директорлары, соң булса да, үзләренең т а т а р булуларын искәрде. Иллә-мәгәр заман югарылыгында фикер йөртерлек тәнкыйтьчене генә күрә алганыбыз юк. Юкса әдәби хәрәкәтебезнең үзәгендә торырлык әсәрләр иясе Ибраһим ага Салаховның бу ике романын бер төпкә җигеп, аның алдынгы фикерләрен әдәби көрәш мәйданына күптән чыгарырлар иде. Ибраһим аганың күңел сизгерлеге нәтиҗәсендә туган бу ике әсәр берберсен тутыралар, тулыландыралар, йомгаклау фикеренең кыйммәтен арттыралар.

Быелның, ягъни туксан бернең тугызынчы маенда, Җиңү көнендә Ибраһим аганың чираттагы хаты килде.

*«5 май 1991 нче ел. Кызылъяр авылы.*

*Әссәламәгаләйкем хөрмәтле дуслар — Аяз әфәнде һәм дә Нәкыя ханым. Хәерле көн!*

*Сезгә, егетләргә, ихлас күңелдән сәлам. Дәрт-дәрман, илһам теләп догадамын. Хатыңны алдым, рәхмәт. Ул, гадәттәгечә, тирән эчтәлекле һәм укырга авыр. Нишләмәк кирәк — ачы хакыйкать шул, милләтебез аяныч хәлдә. Без үзебез боз өстендәге балык кебек чәбәләнәбез, бер ярдәм кулын сузучы юк. (Алай гынамы, үзебезнең мөртәт-мордарлар аяк чала!) Әле монда 10 патшаның мәкерле килешүкапкыннары ябылды, үзебезнең диндәш, кардәш төрки түрәләр, кяферлар белән кочаклашып, безне танырга теләмиләр. Юкса казакъ-төрекмәнне, үзбәк-кыргызны мәгърифәткә татар хәлфәләре, муллалары алып чыкты бит. Казакъ зыялылары асыл татар кызларына өйләнеп кыяфәтләрен, җәлпәк борыннарын, җаенке битләрен үзгәрттеләр. Инде бүген шулар татарга сәлам дә бирми. Менә шул аяныч хәлдән чыгу өчен Күкчәтауда, ярты гасыр югалып торганнан соң, татар мәдәнияте үзәге оештырдык. Менә аңа бер яшь тулды. 3 майда үзәкнең еллык эшенә йомгак ясау җыелышы үткәрдек. (Имәнтау авылында Сабан туе, Тукай көннәрендә татар яшьләренең очрашу кичәсе, чит төбәкләрдән татар ансамбльләрен чакыру, татарча уку-язу курслары, татар матбугатын тарату һ. б. һ. б.)*

*Җыелыш башланыр алдыннан Нури Арсланов турында мин һәм бүтән иптәшләр истәлекләр сөйләдек, аның пластинкага язылган шигъри авазын тыңладык. Соңыннан зал аягүрә басып үзенең кадерле җирдәшен искә алды. 60 ел югалып торган Күкчәтау татар җыр һәм бию ансамбле җыелыштан соң концерт күрсәтте. Без былтыр ук Казаннан 6 мең сумга татар милли киемнәре алдырган идек. Костюмнар да, концерт та тамашачыларга бик ошады. «Татаринформ»ны эзлекле рәвештә таратабыз, бу юлы,— җыелыш көнне 150 данә килгән иде. Халык бик кызыксынып алды. Инде татарча газета чыгару, радиода татарча тапшырулар оештыру күздә тотыла. Алда Сабан туе! Планы әзер. Менә шундый мәшәкатьләр казанында кайныйбыз.*

*«Жизнь Мухаммеда» китабы кулыңа төшсә, миңа җибәр әле.*

*Иҗади уңышлар теләп, ихтирам белән — Маһинур апаң белән мин — Салахов».*

Ибраһим ага мәзкүр хатына бик җитди пост-скриптум теркәгән. Менә ул.

*«Аяз!*

*Кара әле, син үзең дә төрмә-лагерьлар ләззәтен татыган зек. Нигә инде Казанда истәлек-мемориаль музей төзү эшен кузгатмыйсың? Ялгыз мин даладан кычкырганны бер н ә ч ә л н и к тә ишетми. Нури китте, мин чиратта. Исән вакытта бу зур эшкә ниндидер файда күрсәтер идем. Мин үлгәч: «Әх, соңардык бит!» — диярсез. Тотын үзең, башкаларга ышаныч юк!»*

Афәрин, Ибраһим ага! Гомерең озын булсын, ил агасы! Сиксән яшеңә җитеп тә зиһенең ап-ачык, кайберәүләр сыман бүксә киереп «Мин бик бәхетлемен!» — дип ялган чәчеп ятмыйсың. Һәр фикерең — дөнья бәясе! Халкы бәхетсез булган әдип бәхетле була ала димени?! Сиксән яшендә көч-егәре таралмаган, халык гамен үзенеке иткән, гаделлек ИЛЧЕСЕ булудан туктамаган Ибраһим ага алдында бүген тирән ихтирам белән башымны иям. Шәт иншалла, алда да шулай булыр.

**Аяз ГЫЙЛӘҖЕВ.**

*Татар халкы:*
*төрле төбәкләрдә, төрле илләрдә*

## Дамир Исхаков

# ПЕРМЬ ТАТАРЛАРЫ

Пермь татарлары — татар халкының үзенчәлекле бер этнографик төркеме. Ул төркем вәкилләре Пермь һәм өлешчә Свердловск өлкәләрендә яшиләр (соңгы өлкәнең чиктәш районнарында). Революциягә кадәрге административ-төбәк бүленеше буенча Пермь татарлары Пермь губернасының 4 өязе (Пермь, Оса, Көнгүр һәм Красноуфим) составына кергәннәр. Ләкин, Пермь татарлары турында сөйләшкәндә, аларның күршеләре булган (кайбер очракта бер үк авылларда яшәгән) «башкорт» дип аталган төркем вәкилләрен дә читтә калдырырга ярамый. Беренчедән, аларның шактый өлеше башкорт дип элекке вакытларда гына аталып йөреп, хәзер үзләрен татар дип исәпли. Икенчедән, паспорты буенча «башкорт» дип язылганнары да (алар Пермь өлкәсенең Барда районында тупланган) татарлардан телләре, культура-көнкүрешләре белән һич тә аерылмыйлар. Шуңа күрә бу якларда яшәүче милләттәшләребез паспорт буенча билгеләнгән «миллилек» (национальность) турында әллә ни уйлап тормыйлар, элек-электән кыз биреп, кыз алышып яшәгәннәр һәм сөйләшкәндә бер-берсен аерым халыкка бүлеп түгел, ә ике «якка» бүлеп кенә сөйләшәләр («Барда яисә гәйнә ягы» һәм «Көнгүр ягы» дип). Татар һәм башкорт дип йөртелүче бу ике төркемнең бик тирән тарихи бердәмлеге бар. Монда шуны гына әйтеп үтәсе килә: хәзерге Барда районына караган «башкорт»ларның бабалары XVI — XVII йөздә төрле исем белән аталган, шул исәптән «татар» исеме астында да йөргәннәр. Мәсәлән, 1618 елгы документта «Гайнә волосте Тулва елгасы (хәзерге Барда районы территориясе, — Д. И.) буеннан... татар кешесе Иванайко Бахторозов» телгә алына. 1619 елны «тулвалы ясаклы татар... Байса Енбатыров» турында әйтелә. 1619 — 1620 елларда «Тулва татарлары» еш искә алына[1]. Шул ук хәл XVII йөз ахырларында да күзәтелә. Мәсәлән, 1668 елгы документта Барда авылында «татар» һәм «чирмеш» кешеләре искә алына. 1696 елны Сараш авылында (Гайнә волосте) татар кешесе Ишейко Алишев, «Тулвада Елпачиха» авылында татар кешесе Азняшкә Казаев турында әйтелә (бу мисаллар бастырылган чыганаклардан алынды[2]).

Пермь татарларының формалашуын күпмедер дәрәҗәдә төрле риваять-легендалар, авыл тарихлары һәм шәҗәрәләр чагылдыра. Иң башта шул чыганакларга күзәтү ясыйк.

Кызыклы бер легенданы Пермь өлкәсе Барда районында фольклор белгече Ә. Н. Кирәев язып алган [3]: «Тол елгасы буена бертуган Гайнә һәм Әйнә килә (бу легенданың бер варианты буенча, алар күктән төшәләр, ә икенчесе буенча — карлы илләрдән киләләр). Бертуганнар изге боланга утырып баралар. Бер урында болан, туктап, аягы белән җиргә тибә. Шул урында явыз хуҗабикә Тулава яшергән ут (яисә кояш) бар икән. Ике бертуган шул ут өчен Тулава белән көрәш башлыйлар, көрәштә берсе үлә. Җиңеп чыкканы, Гайнә исемлесе, җир астыннан утны (кояшны) алып, болан тиресеннән ясалган капчыкка салып, Тол елгасының көньяк ярына чыгып, анда җәйләү, ил корып, Гайнә ыруына нигез сала».

Шушы ук якка караган икенче бер риваять Барда районы Байавыл (Куземьяр) дигән авылда яшәгән М. Аптуков тарафыннан язып алынган [4]. Кыскача эчтәлеге түбәндәгечә:

---

[1]Бу документлар тарих институтының Ленинград бүлеге архивында саклана (Кара: 122 ф., 1 тасв., 447, 457, 458, 468, 482 эшләр).

[2]Кунгурские акты XVII в. (1668—1669) Спб. 1888, документлар № 18, № 70.

[3]Киреев А. Н. Этногенетические легенды и предания башкирского народа.— Археология и этнография Башкирии, т. IV. Уфа, 1971, 61 б.

[4]Кульъязмада, аны бастырып чыгаручы М. Әхмәтҗанов күрсәтүе буенча, мондый искәрмә бар: «Габдулла аша сулагай Зәки мулладан килеп чыккан кыйсса булыр»(Кара: Пермские татары. Казан, 1983. 161 — 163 б).

«Бохарадан өч туган гаиләләре белән килгәннәр Казан шәһәренә... бер туганнары Казанда калган. Ике туган семьялары белән Кама иделе буйлап менгәннәр дә, Толтүзгә (түзтамак. Д. И.) җиткәч, Тол суы буйлап менеп китмәкче булганнар. Әрмәншаһ исемлесе Толтүздә нишләптер тукталып калган, ә Гайнетдин исемлесе Тол суы буйлап менеп киткәндә, Толбаштан бирерәк тукталып калган һәм шунда тора башлаган... Бу җирдә гел урман булгач, иген игәрлек булмаган. Әрмәншаһ балык аулап, балык ашап, шуның белән тукланып торган. Тол суында балык аулаганда Толдан йомычкалар, агач кайрылары агып килеп чыккач, Әрмәншаһ: «Бу су буенда тагын да торучылар булырга кирәк», — дип, шушы Тол суы буйлап менеп киткән. Бара-бара агасы Гайнетдин янына барып чыккан да, агасы белән кочаклашып, күрешеп танышканнар. Алар танышкан авылга «Таныпъ дип исем биргәннәр. Әрмәншаһ... торган җиргә «Әрәмә» авылы дип исем биргәннәр... Әрмәншаһ Толга төшеп китеп үлгән. Аның хатыны... җылый-җылый: «... инде исемең Тол булсын!» — дип дога кыла. Тол исеме шуннан калган.

... Гайнетдин тиен, куян һәм башка төрле хайваннар атып, шуның итен ашап, тиресен җыеп, Көнгүр ягына чыгып киткән. Бара-бара Көнгүргә барып чыккан да бу тиреләрне шунда саткан һәм анда сорашкан: «Бу урманнарның, бу җирләрнең баш кешесе бармы?» — дип. Әйткәннәр: «Бу җирләр — бер падишаһ җире, аның падишаһы Чырдин дигән җир, шул Кама суының башында яши»... Бу Гайнетдин Көнгүрдән кайткан да киткән Чырдингә...» Шактый өлешен калдырып, кыйссаның ахырын китерәбез: «... Падишаһ дугувыр төзегән (Гайнетдин белән — Д. И.): «Шушы суына нинди сулар төшәләр, шул суларның башларыннан барлык урман һәм җирләр синең ихтыярда булыр...» Шуның өчен «Гайнский участок» дип атаганнар. Шуның өчен бу илне Гайнә дип атаганнар».

Хәзер инде XIX йөздә күренекле татар галиме Риза Фәхретдинев кулы белән күчерелгән бер шәҗәрәне карап үтик. Анда әйтелгән: «Урак би сар Иван Василич падишаһга Чурдингә (Чердынь шәһәренә. — Д. И.) барган. Кыш көнендә чаңгы белән барып, баш салып, кол булырга теләгән. Падишаһ сөенеп, жалуанный грамота биреп, ярлыкап кайтарган... Аның кош белән тамгасы, өй башына берәр сусар бирәсе булып кайткан. Сусар тапмас улгандин, Урак би белән Терберди Али углы барып сусар хакына акча түләргә үтенгәннәр. Падишаһ һәм акча рәҗа күреп (яраклы күреп. — Д. И.), кабул күреп алынган»[1].

Ниһаять, Пермь шәһәреннән ерак булмаган Куян һәм Култай дигән ике авылның халкы исеменнән язылган 1794 елгы бер документта мондый риваятьләр китерелә: «XIII йөздә бабалары Азиядән килеп Идел һәм Кама янында утырганнар, аннан соң Чусавой елгасы тирәсендә яшәүчеләрне буйсындырып, үзләренең күчеп йөрү төбәген Камага коючы елгалар буена җәелдергәннәр... Алар кыпчак һәм Казан патшаларына буйсынганнар, ләкин үзләренең йортларында (аерым бер биләмә, төбәк мәгънәсендә; рус чыганакларында юрт дип бирелә) үз биләре булган. Иван Грозный Казанны буйсындырган вакытта Мулла елгасы тамагында яшәгән мулла татарларының биләре Урак би Мәмәтколов булган, ә Түбән Муллада яшәүчеләрдә би булып аның энесе Сөендек үз кешеләре белән яшәгән, аларның аталары Мәмәткол имам (яисә мулла) булып торган... Бу татар биләре, русларның көчен күреп, үз җирләрендә аучылык белән шөгыльләнергә гадәтләнү сәбәпле, алар кул астындагы кешеләр белән киңәшеп, русларга буйсынганнар. Моның өчен алар хезмәттән тыш һәр гаиләдән яисә йорттан 1 сусар тиресе түләргә тиеш булган... Шуны алар башта Чурдингә, соңга таба тулвалылар белән бергә 1700 елга кадәр 276 шар сусар тиресе итеп, ә 1700 елдан соң акчалата түләп торганнар»[2].

Бу риваятькә өстәп, 1784 елны шушы ике авыл халкы һәм барлык Оса өязенә караган «башкорт» һәм «татарлар» исеменнән язылган риваятьне китерик: ...«Бу башкорт һәм татарлар тархан нәселеннән булып, үзләре сөйләшүләре буенча, монда бик борынгыдан яшиләр. Иван Васильевич Казанны алгач, алар рус дәүләтенә буйсынганнар, ә аңарчы үз хөкемдарлары нугай патшасына буйсынып торганнар. Ул вакытта тагыниләр булганлыгын алар хәтерләми, ләкин шуны ишеткәннәре бар: аларның ханы боларның иң яхшы кешеләреннән кызларын алып үзендә берәр ел тотып кире кайтара торган булган, аннан соң башкалардан тагын кызлар алып, бу кызларның саны 10 — 20 булып, кызларның аталары мондый хәлне үзләре өчен күңелсез вакыйга дип санаганнар»[3].

Бик әһәмиятле бер шәҗәрә текстын да күрсәтү кирәк (аны М. Госманов Пермь өлкәсе Уинск районы Иштирәк авылында табылган бер кулъязмадан алган; үз чиратында ул шәҗәрә шул ук өлкәнең Октябрь районы Саз авылында укучы бер шәкерт тарафыннан күчерелгән булган). Текстта болай диелә: «Җан-Егет атасы Бойырган, Бойырган ата-

---

[1]Долоткозина С. Х. Шеджере башкир племени гайна о присоединении к Русскому государству.— Источники и источниковедение истории и культуры Башкирии. Уфа, 1986, 57—60 б.

[2]Из истории башкирского землевладения в Пермском уезде и грамоты башкир. Труды Пермской учен. архивной комиссии (ПУАК). Пермь, 1893, 77—78 б.

[3]Пермский областной архив, ф. 316, оп. 1, ед. хр. 78.

сы Хуҗаш, Хуҗаш атасы Хуҗа Шәех, Хуҗа Шәех атасы Нур Собу, Нур Собу атасы Дәүләт Бирде, Дәүләт Бирде атасы Сайын хуҗа, Сайын Хуҗа атасы Буйын Хуҗа, Буйын Хуҗа атасы Байсары би, Бүреҗан би, Күкбүре би — бу өч агалы-энеле Нугайдан чыкканнардыр. Әүвәл падиша хәзрәтләренә баш салган Хуҗаш бидер...»[1]. Искә алынган Сал авылының хәзерге исеме — Йанапай (Енапай) булса кирәк. Ул — иске авыллардан. Моның шулай икәнлеген тел белгече Д. Б. Рамазанова язып алган риваятьләрдән күрергә була. Аларда Ирән елгасы буена башлап 4 туган — Бикбай, Иштирәк, Йанапай һәм Карьяу (Карҗау) килүе турында сөйләнә. Шушы исемдәге авыллар хәзер дә саклана. Алар кулында җир бик күп булган (Көнгүр-Сернушка-Красноуфим-Кунгак араларында). 1977 елгы җирле район газеталарында чыккан мәкаләсендә Ф. Пшеничников, халыктан ишеткән хәбәрләргә таянып, түбәндәгечә яза: «Енапай һәм Мәмәтев байларның җирләре бик күп булган, ул җирләр аларда 1566 елгы грамота нигезендә калган... Бу вакытта Енапай карт кеше булган»[2]. Бу язманың дөреслеген тикшерү авыр, ләкин 1619 елгы бер документта Енабай дигән кеше искә алына. Аның атасы Карей дип йөртелгән (Карей Мемсяков)[3], Этнограф И. Г. Мөхәммәтшин язып алган риваятьләргә караганда, Карьяу (Карҗау) авылы (аның тагын бер исеме — Иске авыл) чынлап та борынгы авыллардан булып, Көнгүр белән бер вакытларда барлыкка килгән дип санала. Көнгүр шәһәре исә 1647 елларда төзелеп, аның урынында инде аңарчы ук татарлар яшәгәнлеге билгеле.

Риваять һәм шәҗәрәләрдә без, татарлар, нугайлар белән очраштык. Әмма ләкин чынбарлык катлаулырак булган, шуңа күрә, пермь татарларының борынгы тарихларына үтеп керү өчен, язма чыганакларга да мөрәҗәгать итәргә кирәк.

Шушы чыганакларның иң әһәмиятлеләреннән берсе — XVII гасырда язылган, эчтәлеге ягыннан XVI гасырның 70 нче елларына караган «изге Трифон» (1543 — 1612 еллар) исемле рус миссионеры тормышына багышланган язмадан гыйбарәт [4]. Шунысы игътибарга лаек: бу Трифон дигән кеше 1570 еллар тирәсендә югарыда искә алынган Түбән Мулла елгасы буенда берникадәр торып алган һәм соңыннан аның тормышын тасвирлаганда әле исән булган.

Трифон бу якларга инде алар Рус дәүләтенә кушылгач, Строгановлар биләмәләреннән Кама елгасы буенча көймәгә утырып килеп чыга. Бер буш җиргә чыгып, шунда тора башлый. Ләкин бу җир шунда яшәгән халыкның (алар документта «остяк» дип аталганнар) изге урыны булып чыга. Документка сүз бирик (эчтәлеген бозмас өчен, хәзерге рус теленә яраклаштырып, русча бирәбез):

— Место же то... было кладбище остояцкое или жертвище идольское. Там стояли деревья великие и ветвестые... Узнав о поселении близ их остяцких жилиц Трифона... начальный их человек, по имени Зевендук, собрав с собой нечистывых остяков до 70 человек... пришел туда...» Шуннан соң, танышкач, Трифон аларга христиан дине турында сөйли һәм болай ди: «... вы веруете не небесному творцу Богу ... но нечувственным кумирам, глухим и бездушным богам». Бу турыда Зевендук һәм аның иптәшләре Амбал исемле князьләренә барып әйтәләр. Бераз торганнан соң Трифон аларның изге агачларын кисеп аудара. Текстта язылган: «идолжертвенное древо, глаголемое ель, самое большое среди прочих... Утварь бесовская на дереве... серебро, злато, шелк и ширинки и кожи...» Бу турыда белгәч, Амбал күп кеше җыеп килә һәм әйтә: «его отцы наши и мы почитали как бога... велик бог христианский и нашего бога сильнее». Шулай дип әйтүгә карамастан, «остяклар» Трифонга кагылмыйлар, ә шикаять белән Сылва елгасы буена — рус шәһәрчегендәге администрация-идарә урнашкан җиргә баралар. Рус администрациясе вәкиле аларга Трифонга тимәскә куша. Бу вакыйгадан соң, үзләре өчен уңай бер вакытта «остяклар», Зевендук белән килеп, Трифонны үтерергә дә җыеналар. Ләкин «җитие» буенча могҗиза булып, шунда «изге җан» күзгә күренмәс була. Шуннан соң инде «остяклар» һәм «вогуллар» (барысы да түгел, кайберләре, бигрәк тә князьләренең кызлары) чукыналар. Трифонны хөрмәт итә башлыйлар.

Билгеле, бу язмага төрлечә карап була, ләкин ике әйберне инкарь итеп булмый: беренчесе — Сылва елгасы тирәсендә яшәүче җирле халык арасында XVII йөз башында ук рус (христиан) исемнәрен очратырга була, икенчесе — язмада искә алынган Зевендук исемле «начальник» һәм риваятьләрнең берсендә күренгән Урак бинең энесе Сөендек бер үк кеше булып чыга, чөнки вакыт һәм җирлек туры килә. Шулай итеп, безнең алда «остяклар» пәйда була.

Әйтергә кирәк, «остяк» (татарча һәм башкортча — иштәк) дигән төркемнең Пермь татарларының бабаларының берсе булуы турында документлар бик күп һәм бу мәсьәлә бәхәссез[5]. Берничә чыганак кына китерик: 1760 елны Яңа Байсы дигән авыл татарлары әйтә: «Аларның бабаларының бабаларына һәм бабаларына 1627 — 28 еллардагы кенә

[1]Госманов М. Каурый каләм эзеннән. Археограф язмалары. Казан, 1984, 52 б.

[2]Пшеничников Ф. П. На берегу Ирени.— Газ. «Верный путь», 1977, 27 октября.

[3]Преображенский А. А. Очерки колонизации Западного Урала в XVII — начале XVIII в. в. М., 1956, 17 б.

[4]Кара: Житие преп. отца нашего Трифона Вятского чудотворца. Памятник русской духовной письменности XVII в. (приложение к «Православному собеседнику»). Казань, 1868.

[5]Кара: Исхаков Д. М. К вопросу об «остяцком» компоненте пермских татар и его связи с носителями Сылвенской культуры.— Проблемы средневековой археологии Урала и Поволжья. Уфа, 1987, 114—121 битләр.

гәләр буенча бирелгән җир биләмәләрендә остяклар язылган, соңыннан шул авылда алар татар дип йөртеләләр». 1798 елны әйтелгән авылдан бер татар аңлатып бирә: «1627 — 28 еллардагы кенәгәләрдә күрсәтелгән, остяк дип исемләнгән Байса Акбашев һәм Урмамет Гайсин аларның бабалары була». Красноуфим өязендә яшәгән татарлар XIX йөз башына караган бер документта язалар: «Чынлап та, остяклар бу җирләрдә яшәгәннәр һәм инде күптән башка җирләргә күчеп киткәннәр, ә кайберләре (игътибар — Д. И.), татарлар белән туганлашып, алар белән кушылган, алардан соң Сарс елгасы буенда калган җирләр, уртак биләмә буларак, Югары-ирән татарлары дачасында һәм татарга әйләнгән остяклар биләмәсендә калган». XVII йөз башына караган (1610 — 1620 елларга) документлар Сылва һәм Ирән елгалары бассейнында яшәгән халык гел ике төркемгә бүлеп йөртелгән — «остяк»ка һәм «татар»га. Ләкин инде шул вакытта ук «татар» белән «остяк» арасында әллә ни аерма булмаган, ахрысы. Чөнки бер документта мондый кызык аңлатма бар: «Югары Сылва татары остяк Беклибай Еболаков». Димәк, бу очракта «остяк» шул ук «татар» булып чыга.

Безнең күзәтүләр буенча, XVI йөзнең ахыры — XVII йөзнең башлары тирәсендә Тулва елгасы буенда яшәүчеләр «башкорт» һәм «татар» дип йөртелсә («остяк» атамасы сирәгрәк кулланыла), Сылва һәм Ирән елгалары бассейнында яшәүчеләр «остяк» һәм «татар»га бүленеп, «башкорт» дип азрак аталганнар. (Ләкин XVII йөзнең урталарыннан аларның да бер өлеше «башкорт» дип языла башлаганнар). Кайбер галимнәрнең фикере буенча (өлешчә без аларга кушылабыз), мондый бүленешләрнең бер сәбәбе — ике административ өлкәгә карау (Уфа һәм Көнгүр өязләренә), ягъни Уфа өязенә керүчеләр күбрәк «башкорт», ә Көнгүр өязендәгеләр «татар» булганнар. Әмма, кем дип аталуларына карамастан, бу төркемнәрнең этник нигезләрендә зур уртаклык булган. Әйтик, шул ук Трифонның «житие»сендә, чыршы агачы үскән «изге урын» турында мондый юллар бар: «...было тут их, агарян и многих язык идольское жертьвище и от всех стран и рек, с Печеры, и с Сылвы, и с Обвы, и с Тулвы, князи их: остяцкий Амбал, вогулский Бебяк и иные многие языки со всеми своими улусы, остяки и вогулучи... в то... место съезжались... по своей поганской вере, идольские жертвы творили под деревом...» Күрганегезчә, Тулва елгасы буе «остяклар» яшәгән урын булып чыга. Чөнки «вогуллар», башка чыганаклар буенча, Обва елгасы ягында яшәгән. Шуны да искәрик: руслар «остяк» дип хантларны, «вогул» дип мансиларны атаганнар. Димәк, сүз монда, гомумән, угор халыклары төркемнәре турында бара.

Мәкаләбезнең бу өлешендә Пермь татарларының этник катлауларын һәм компонентларын билгеләп, аларның бер төркем булып формалашу процессына аңлатма бирү бурычы куела. Бу шактый катлаулы эш һәм аны башкарып чыгу өчен безгә Пермь татарлары оешуның төрле этапларын аерып, якынрак чордан «түбәнгә» төшә бару юлын сайлау кулайрак булыр.

**а) Урта Идел буеннан күчкән татарлар (XVI йөзнең икенче яртысы — XX йөзләр).**

Пермь татарларының Идел — Урал буенда таралып урнашкан татар халкының этнографик төркеме булып оешуның соңгы чорында, ягъни XVI—XX йөзләрдә, Пермь якларына Урта Идел төбәгеннән күчеп килүче милләттәшләр зур роль уйнаган. Миграция процессы бигрәк тә Казан ханлыгы Рус дәүләте тарафыннан яулап алынгач көчәйгән. Бу турыда беренче чиратта этнографлар язып алган авыл тарихларына бәйле булган риваятьләр сөйли[1]. Аларда татарларның «Казан ягыннан», «Татарстаннан» Иван Грозный вакытында чукындырудан качуы турында сөйләнә. Кайбер очракларда халыкның чыккан урыны төгәлрәк итеп: «Казан ягыннан, Саба районыннан», «Чистай өязеннән», «Сембер губерниясеннән», — дип күрсәтелә. Күчеп килүләр турында риваятьләр Барда районында да бар (мәсәлән, Танып авылында), ләкин бу күбрәк татарлар яшәгән авылларга карый (Енапай, Усть-Турка, Агафонкова, Саескан, Урта Богалыш, Турыш, Туктамыш һ. б.). Тарихи чыганаклар да миграция турында сөйли. Әйтик, Усть-Турка авылында Казан ягыннан күчүчеләр арасында Кызылбай, Тимербай һәм «ар» Актырнакбай телгә алына. Тарихи документларның берсендә исә (1625 ел) бу кешеләрнең татарлардан икәнлеге, Иметкай, Тимербай һәм Кызылбай — «Левкас балалары» дип язылган. Алар һәм аларның туганнары кулында инде җир биләмәләре булган[2]. Ләкин әле 1623 — 24 еллардагы халыкны исәпкә алуда бу кешеләрнең исемнәре күренми[3]. Димәк, алар бу исәптән соң килгәннәр. Шулай ук Енапай авылы зиратында, И. Г. Мөхәммәтшин язмасы буенча, «Әгерҗе кызы Фатыймага» куелган 1664 елгы таш булган. Гомумән, XVII — XVIII йөзләрдә Пермь якларында Татарстанның Тау ягыннан, хәтта Касыйм өязеннән күчүчеләр дә документларда күренә. Ниһаять, Урта Идел буеннан булган миграция турында культура үзенчәлекләре дә сөйли. Мәсәлән, Пермь татарлары торган авылларның кайберләрендә җыен бәйрәме үткәрелгән. Әйтик, Усть-Турка авылында «җуа җыены» бәйрәм ителгән. Шушы исемдәге җыен

---

[1]Аларның бер өлеше басылып чыккан. (Кара: «Пермские татары». Казан, 1983).

[2]Преображенский А. Н. Очерки колонизации Западного Урала в XVII — начале XVIII в. М., 1956, 29 б.

[3]Шишонко В. Писцовые книги Пермской губернии Соликамского и Кунгурского уездов. Пермь, 1872, 119—150 б.

исә Татарстан авылларында да булган (Балтач, Зеленодол, Апас, Әгәрҗе районнары).

Мондый фактларны тагын да өстәргә булыр иде. Ләкин төп фикер аңлашылса кирәк: Пермь татарларының соңгы «катламын» Урта Идел ягыннан күчеп килгән татарлар тәшкил итә. Алар үзләре белән Идел төбәгендә таралган культура үзенчәлекләрен дә алып килгәннәр. Пермь якларында мөселман дине йогынтысы нык көчәю дә күчеп килүчеләр белән бәйле дип уйларга урын бар. Билгеле, Урал буена ислам дине үтеп керү инде XIV йөзләрдән үк активлаша башлаган (алга таба кара). Шуңа күрә миссионерлык белән шөгыльләнгән Трифонның «остяклар»ны гел мәҗүси итеп күрсәтергә тырышуына тәнкыйть күзе белән карарга кирәк. Бу турыда кайбер галимнәр инде революциягә кадәр үк язып чыктылар. Алар, мәсәлән, Трифон турындагы язмаларга анализ ясап, аларда «остяклар» турында язганда берничә тапкыр «агарян», «бусурман» дигән сүзләр кулланyга игътибар иттеләр[1]. Ә бу сүзләр русларда мөселман динен тотучыларга карата кулланылган. Аннан соң, Мулла елгалары буенда яшәүчеләрнең биләреннән Уртак һәм Сөендекнең аталары Мәмәткулның имам (мулла) булуы да шул турыда сөйли. Шулай ук агачка «табыну» мәсьәләсенә дә аек күз белән карарга кирәк. Башкорт культурасын бик яхшы белгән С. И. Руденко, башкортларның иске каберлекләргә табынуларын күрсәтеп (ул татарларга да хас), түбәндәге фикерне әйтә: «Еш кына андый каберлекләр — борынгы курганнарда, ә аларны урман каплаган... Шундый каберлекләрдә үсүче агачларга кагылырга ярамаган»[2]. Шуңа күрә Ирән-Сылва, Тулва буйларында яшәгән «иштәкләр»не инде XVI йөзгә мөселманлыкны кабул итеп баручы төркем дип исәпләргә кирәк. Ләкин ислам динен таратуда Урта Идел ягыннан күчүләрнең аерым ролен күрсәтү дөрес булыр. Мәсәлән, XIX йөз урталарында Оса өязе тирәсендә булган П. Небольсин гайнә башкортлары турында болай ди: «... Сөйләшүләре буенча алар мөселман динен Иван IV чорында үзләрен чорнап алган татарлардан кабул иткәннәр». Үзенең фикерен исбат итү өчен бу галим гайнә иле халкында булган мәҗүсилеккә бәйле бер мисалны — «кара нәрсәгә» корбан чалу гадәтен китерә[3].

Тагын бер мәсьәләне әйтмичә булмый: күчеп килүче татарлар еш кына үзләренең элек торган урыннарындагы күршеләре — мордва, мари, удмуртлар белән бергә килгәннәр. Халык хәтерендә сакланган мәгълүматлар буенча, бу фин халыкларының бер өлеше Пермь ягында татарлар арасында «эреп», ассимиляцияләнеп, алар составына кереп киткән (авыллардагы «ар», «чирмеш» токымы һ. б. атамалары шул турыда сөйли).

**б) Кыйлап-кыелдап сөйләшүчеләр. Көнгүр һәм Бөркет би (XV — XVI йөзләрдә Пермь ягында нугайлар)**

Урта Идел ягыннан татарлар килгәнче үк Тулва, Сылва һәм Ирән елгалары буенда халык яшәгән һәм ул халыкның бер өлешен, һичшиксез, нугайлар тәшкил иткән.

Пермь татарларының тел үзенчәлекләреннән башлыйк. Шул үзенчәлекләрнең берсен язучы Риза Ишморат истәлекләрендә күрсәтеп: «Без инде Уразай авылында яши башлагач (Минзәлә ягы), биредә гайнә илендәгечә, кыйлап-кыелдап сөйләшүне бераз оныткан идек»[4]. Тарихчы М. Госманов күрсәткәнчә, «кый» кушымчасы кушып сөйләшү (бардым-кый, алдым-кый, ягъни, бардым бит, алдым бит) Кавказ нугайлары өчен хас күренеш (гый-кый вариантында), казакъларда да бар (гуй)[5]. Пермь татарлары сөйләшенең кайбер үзенчәлекләре белән нугай теленең ак нугай диалекты арасындагы охшашлыкны диалектолог Д. Рамазанова да раслый[6].

1623 елгы халыкны исәпкә алу кенәгәсендә әйтелгән: «Карьев остякларының вотчиналары Камгур» (Көнгүр — Д. И.). Кайбер мәгълүматлар буенча, бу исем — Көнгүр топонимы (ул, елга исеме булып, соңыннан Кунгур шәһәре исеменә әйләнгән), нугайларның кабилә яисә ыру исемнәреннән[7].

Каръяу (карҗау) топонимы шулай ук игътибарга лаек. Бу исем гади генә исем түгел, чөнки XVII йөз башы документларында «Карьево улусы» искә алына, аның үзәге, күрәсең, Каръяу авылында булган[8]. Шушы нисбәттән бер кызыклы шәҗәрә искә төшә[9] (ул Р. Ишморатның әнисе ягыннан булган шәҗәрә). Башында Бөркет би булып, ул алга таба түбәндәгечә дәвам итә: Алманчык би — Үрдәк би — Сүнчәли би — Сондык би — Кара җау — Турбай — Кармыш — Истәк һ. б. Шәҗәрә Пермь татарларына бик якын урында — Бөре өязенең төньягында язып алынган һәм андагы авыллар исемнәрендә (мәсәлән, Үрдәк, Истәк, Турай) югарыда саналган шәхесләрнең исемнәре

---

[1]Осокин И. М. К вопросу о миссионерской деятельности преп. Трифона.— Труды ПУАК, в. 7. Пермь, 1904, 25 б.

[2]Руденко С. И. Башкиры. Историко-этнографические очерки. М — Л., 1955, 276 б.

[3]Небольсин П. Отчет о путешествии в Оренбургский и Астраханский край. № 11 Вестник РГО, ч. 1., кн 1 (VI). Спб. 1852, 18 — 19 б.

[4] Ишморат Р. Гомер сукмаклары. Истәлекләр. Казан, 1987, 89 б.

[5] Госманов М. Каурый каләм эзеннән. 230 б.

[6] Рамазанова Д. Б. Говоры татар среднего Прикамья. — Автореферат дисс. канд. филолог. наук. Казань, 1970, 34 б.

[7] Кара: Калмыков И. Х. Из истории ногайцев Дагестана, Терека и Ставропольской губернии в XIX — начала XX в. — Проблемы археологии и исторической этнографии Карачаево-Черкесии. Черкесск, 1985.

[8] Шишонко Вас. Писцовые книги... 114 б.

[9] Ишморат Р. Күрсәтелгән хезмәт. 9 б.

чагылыш тапкан. Шуңа күрә мондый сорау туа: шәҗәрәдәге Кара Җау белән Карҗау авылы исеме арасында бәйләнеш юк микән? Әгәр дә ул бәйлелек бар икән, Буркыт би исеме безне кайсы якка алып барыр? Әйтергә кирәк, Риза Ишморат кулындагы шәҗәрәдә мондый юллар бар: «Буркыт биләр Чыңгыз хан иде. Синең агачың чаган, кошың һәд-һәд, тамгаң әмзәдер[1] (монда бераз мәгънә бозылган бугай, чөнки сүз Чыңгыз ханның әйткән сүзе турында бара: ул кабилә башларына кабиләнең билгеләре булган агач, кош һәм тамганы «бүләп» бирә). Бу язманың эчтәлеге «Дәфтәре Чыңгызнамә» белән туры килә. Анда Чы гыз хан заманындагы биләр арасында Бөркет би телгә алына (кошы, агачы туры килә; оран да әйтелгән, «борх»)[2]. Шулай ук Иске Турай авылында табылган (Башкортстанның Дүртөйле районы) тагы бер шәҗәрәдә «шамшадин ыруы»ның (кабиләсенең) башы итеп Тарагай би күрсәтелгән, аның атасы — Буркат би. Тарагай би «Кырымнан килеп, Агыйдел буйлап күчеп килгән». Аның ике улы — Олы Чокыр һәм Кече Чокыр булганнар. Этнограф Р. Кузеевның, каңлы кабиләсе вәкилләре арасында шушы ук шәхесләр — Тарагай би һәм аның уллары «Кара диңгез буеннан, Кырымнан» килгән, дигән фикере бар. Р. Кузеев бу шәхесләрне кыпчаклар белән бәйли[3]. М. Әхмәтҗанов шулай ук «буркут» этнонимының кыпчаклар белән бәйле халыклар арасында таралганлыгын күрсәтә[4]. Шулай итеп, без тагын нугай-кыпчакларга килеп терәләбез.

Тарихи материаллар нугайларның бу якларда булганлыгын раслыймы соң? Безнең фикер буенча, турыдан-туры булмаса да, раслый. Мәсәлән, 1547 елны «нугай татарлары» русларны Чердынь янында тар-мар итәләр[5]. 1564 елны Строгановлар «нугай кешеләреннән һәм башка урдалардан саклану өчен» Орлов шәһәрчеген төзиләр[6]. 1572 елны Строгановларга[7] җибәрелгән грамотада нугайларга (икенче урында аларны башкорт дип атыйлар), чирмешләргә, удмуртларга һәм остякларга каршы көрәшү турында әйтелә.

Хәзер инде алда каралган риваятьләрдәге нугайлар турындагы фактларга игътибар итик. Әйтик, Оса өязендәге татарлар һәм башкортлар XVIII гасырда үзләренең Казан алынганчы Казанга һәм кыпчак (нугай) хөкемдарларына буйсынулары турында сөйләгәннәр. Шулай ук бу буйсынуның чагылышы — кызларын ханга җибәрүләре — бер дә уйлап чыгарылганга охшамаган. Өстәп тагын шуны да әйтик: Мулла елгалары буендагы «остяклар» башында торган биләр токымыннан булучыларның тамгалары — кыпчак тамгасы һәм ул тамга затлы катлауларга хас («капка» тамгасы).

Көнгүр тирәләрендә күчмә тормыш алып бару өчен шартлар да булган, чөнки Көнгүрдән көньякта, Сылва һәм Ирән елгалары араларында, «көнгүр даласы» дип аталган урманлы дала зонасы башлана. Билгеле булганча, 1546-47 елларда Урал буеннан нугайлар Төньяк Кавказ якларына күпләп күчә башлыйлар. Бу процесс Казан ханлыгы алынгач тагын да көчәя, аннары калмыклар нугайларны Идел буеннан бөтенләй кысрыклап чыгаралар. Ләкин нугайларның бер өлеше Урал буенда кала һәм, юрматы кабиләсенең шәҗәрәсендә әйтелгәнчә, бу калган нугайлар «иштәк»кә әйләнәләр («иштәк аталдылар»)[8]. Шушы ук процесслар Көнгүр якларында да булган, күрәсең. Димәк, бу яклардагы татарларның бер өлеше турыдан-туры нугайдан татарга әйләнеп киткән булырга да мөмкин. Ә инде кайберләре, башка этник төркемнәр белән кушылып (аларның уртак исемнәре — бәлки, нугайлар тараткан уртак исемдер — иштәк булган дип уйларга урын бар), тора-бара «башкорт»ка яисә «татар»га әйләнә. Бу процессны аңлау өчен «иштәк проблемасы»на күчү кирәк.

### в) Иштәкләр, «Костяк җире» һәм пермь татарларының иң төптәге (субстрат) катламы турында

Пермь татарларының нугай компоненты турында сүз алып барганда ук әйтеп китәсе бер сүзебез шул: нугайлар күчмә халык булган һәм аларның хуҗалык системасы урманнарда яшәү өчен яраклашмаган. Шул ук вакытта гайнә иле (Барда районы) ягында язылган риваятьләр Тулва елгасы буенда бик калын урманнар булу турында сөйлиләр. Шундый ук урманнар пермь татарларының башка төркемнәре яшәгән урыннарда да булган (Көнгүр даласыннан тыш). Аннан соң, XVI — XVII гасыр документларын өйрәнгәндә, шул да ачык күренә: пермь татарларының хуҗалыгында ул чорда аучылык, балыкчылык һәм умарта кортлары тоту зур роль уйнаган. Бу — дала халыкларына хас нәрсә түгел. Безнең уебызча, күрсәтелгән фактлар Пермь якларында яшәгән «иштәк» дип аталучы төркемнәр белән бәйләп каралырга тиеш.

---

[1] Ишморат Р. Күрсәтелгән хезмәт, 36 б.
[2] Кара: История Чингиз хана и Тамерлана. — Труды Оренбургской ученой архивной комиссии, 19 вып. 1907, 135 б.
[3] Кузеев Р. Г. Происхождение башкирского народа. М.: Наука, 1974, 359 б.
[4] Ахметзянов М. И. К этнолингвистическим процессам в бассейне р. ИК (по материалам шедже ре). — К формированию языка татар Поволжья и Приуралья. К.: ИЯЛИ КФ АН СССР, 1985, 64 б.
[5] Дмитриев А. Покорение угорских земель и Сибири.— Пермская старина, вып. 5. Пермь 1894, 184б.
[6] Шишонко Вас. Пермская летопись. 1-й период. Пермь, 1881. 52 б.
[7] Шунда ук, 65 б.
[8] Башкирские шеджере. Уфа, 1960, 32 б.

## 1) Әйнә белән Гайнә

Ике бертуган — Әйнә белән Гайнә турындагы Ә. Кирәев тарафыннан язып алынган риваять зур әһәмияткә ия. Чөнки, тарихчылар фикеренчә, бу риваятьтә болан культы һәм фин-угор халыкларына хас булган башка ышанулар да чагыла. (Тул-ава — ут хуҗасы дигән сүз) Шуның өстенә, Әйнә дигән исем дә бик кызыклы. Билгеле булганча, венгрлар хәзерге торган урыннарына IX гасырда Идел — Урал буеннан күчкәннәр һәм ул вакытта аларның җиде кабиләсе булган. Шуларның берсенең исеме — «jепо», Әйнә атамасына бик якын. Аннан соң, бу «jепо» атамасының енәй (җәнәй) атамасы белән бер икәнлеген венгр галиме Д. Немет исбат итте инде. Соңгы атама исә «башкорт» кабиләсенең исеме, ләкин енәйләрнең күпчелек өлеше — хәзерге татарлар, чөнки алар элекке Сарапул өязенә (Вятка губернасы) һәм Минзәлә өязенә караганнар. (Бу җирләр хәзер Татарстанга карый.) Енәйләр яшәгән төбәк гайнә иленә бик якын, асылда алар бер культура зонасына керәләр.

Икенче бер риваятьтәге Гайнетдиннең туганы Әрмәншаһ торган авыл исеме дә (Әрәмә авылы) игътибарга лаек. Беренчедән, Тулва бассейнында (русча исеме — Ермия) шул исемдәге елга бар. Икенчедән, 1666 елгы грамотада әйтелгәнчә, чыннан да, «Ермей» дигән авыл булган (аның икенче исеме шул вакытта ук «Танып» дип бирелгән) һәм ул авыл халкы кулында (алар «башкорт» дип язылганнар) Тулвага коючы Барда елгасы буендагы җирләр булган[1]. Үз чиратында Әрәмә — Ермия — Ермей исемнәре башкортларда сакланган Юрми кабиләсе исеменә тоташа. Башкорт шәҗәрәләре буенча исә, Юрми-би Юрматы бинең улы булган. Соңгы исем венгрларның борынгы кабиләләре исеменә барып тоташа (д'ярмат). Шулай ук, Р. Кузеев исбат иткәнчә, юрми исеме болгарлардагы бер кабилә (яисә ыру) исеме. Димәк, Тулва елгасының көньяк өлешендә без шул ук угор, яисә болгар-угордан чыккан төркемне очратабыз. Шунысын да күрсәтеп үтик: юрми кабиләсеннән чыгучылар безнең республикада — Азнакай районында яшиләр һәм, билгеле инде, үзләрен татар дип саныйлар. Барда районындагы Танып авылы халкы да үзен татар дип саный һәм документларында да татар дип күрсәтелә.

Шулай итеп, Тулва елгасы бассейнында яшәүче «иштәкләр»нең угор һәм болгар-угор төркемнәре белән бәйлелеге ачылды.

Күп документлардан күренгәнчә, пермь татарлары составына тагын башкорт булып йөргән «сызгы», алар белән бәйле «тирсә» (тирсәк), «балыкчы», «кошчы» һәм «упей» дигән кабиләләр вәкилләренең бер өлеше кереп киткән. Безнең фикеребезчә, упей кабиләсе чагыштырмача соң формалашып, гайнә, сызгы һәм тирсә кабиләләреннән күчүчеләрдән тора. Сызгы кабиләсе вәкилләре үзләрен гайнәләр белән тугандаш дип санаганнар. Шуңа күрә сызгылар җирендә рус документлары буенча инде безгә яхшы таныш булган «остяклар» яшәве бер дә гаҗәп түгел. Р. Кузеев та аларны фин-угор төркемнәре белән бәйләп карый. Балыкчы кабиләсенең көньяктан күчүе билгеле булса да (Урта Азиядән каракытайлар белән килгән), алар төньякка үтеп кергәндә анда «чирмешләр» белән очрашалар (бу «чирмешләр»нең кем булганлыгын берсенең исеме күрсәтә — Юрмиаз; сүз шул ук юрмиләр турында бара булса кирәк). Кошчы исә балыкчының туганы, дигән риваятьләр бар (Р. Кузеев). Бу кабилә шулай ук күчмә төркиләр белән, шул исәптән, нугайлар белән дә бәйле булып, Пермь якларында соңрак чорларда урнашкан һәм анда җирле халык белән элемтәгә кергән. Әйтик, 1618 елгы бер грамотада мондый юллар бар[2] (русча китерәбез): «учнут торговать на Ирени Уфимского уезду Аксиевы волости и Белоканские и Кушымские и Балакчинские татара и остяки медом и воском». Күргәнегезчә, халыкның бер өлеше «остяк» дип йөртелгән. Татар дигән өлеше, бәлки, Урта Идел татарларына гына түгел, ә башка төркиләргә дә бәйледер (нугай-кыпчак һ. б.). Ниһаять, тирсәкләр (тирсәләр) турында берничә сүз. Р. Кузеев күрсәткәнчә, тирсәкләр үзләрен «чирмеш нәселеннәң» дип санаганнар[3]. О. Долгих[4] һәм Р. Кузеев аларны угорлардан дип саныйлар. Шунысы кызыклы, иң борынгы документларда (1602—03 еллардагы)[5]. Тирсә волосте (халкы «чуваш» дип язылган) Татарстанның хәзерге Әгерҗе районына керүче территориядә — Иж елгасы буенда күрсәтелә. Ә бу урыннар енәйләр яшәгән җирләрдән ерак түгел. Тагы бер тапкыр барлык мәгълүматлар да Пермь якларында урта гасырларда угорларга, беркадәр болгарларга бәйле төркемнәр яшәгәнлеген исбат итә.

Бу төркемнәр монда кайчаннан бирле яшиләр соң?

## 2) Әмәт Хәмәт (Самат) заманнары

«Гайнә иле» кешеләренең риваятьләре буенча, аларның бабалары Тулва буена «Кама Иделе буйлап», «Бохарадан» килгәннәр. (М. Әхмәтҗанов «Болгардан» дип укырга кирәклеген искәртә.) Р. Кузеевның халык арасында язып алган мәгълүматларында

[1] Кара: Пермь өлкәсе архивы, ф. 297. оп. 1. саклау берәмлеге 1015, 1 б.
[2] Тарих институтының Ленинград бүлеге архивы, ф. 122, 1 тасвирлама, эш кәгазе 448, 1 б.
[3] Кузеев Р. Г. Происхождение башкирского народа... 241 б.
[4] Долгих О. Б. Родовой и племенной состав народов Сибири в XVII в. М., 1960, 21 б.
[5] Кара: Писцовая книга Казанского уезда 1602 — 1603 гг. Публикация текста. — Казань: изд-во КГУ, 1978, 39 — 41 б.

шулай ук гайнәләрнең «Болгардан чыгулары», «Минзәлә ягыннан» килүләре күрсәтелә. Мулла елгасы буенда яшәүчеләр XVIII йөз ахырында шулай ук бабаларының «Идел һәм Кама яннарында утырганнарын», аннан соң Пермь якларына күчүләрен сөйлиләр. Тирсә кабиләсенең башта шул җирләргә якын булганлыгын әле генә күрсәтеп үттек. Юрмиләр шулай ук XIV йөзләргә кадәр Зәй-Шишмә тирәләрендә яшәгәннәр (Р. Кузеев фикере). Кошчы кабиләсе вәкилләре дә бер чорда Ык елгасының һәм Агыйделнең түбән агымнары буенда (Алабуга шәһәренә каршы урында) яшәгәнлекләре турында сөйләгәннәр (Р. Кузеев [1]).

Шушы мәгълүматларга бәйләп карый торган мисаллар бар тарихта: беренчесе, Алабуга якларына бәйле ярым риваять төсендәге мәгълүматлар (Хисаметдин Болгарида сакланган)[2]. Ул күрсәткәнчә, Аксак Тимер яу белән килгәндә Алабугада ханлык итүче Уразбакты улы Илбакты бернинди дә дин тотмаган (мәҗүси булган). Аксак Тимер аны ислам диненә кертергә тырышкан. Ләкин Илбакты аның белән килешмәгән; икенчесе билгеле төрки чыганакта — «Дәфтәре Чынгызнамә»дә Аксак Тимернең Болгарны туздырып кире кайткан вакытында «Кыйа» дигән җиргә[3] барып, андагы Әмәт һәм Самат дигән ханнарга көчләп ислам динен кертүе турында. Шул ук чыганакта Самат хан Бүләр шәһәре белән дә бәйләнә[4]. Шушы вакыйгаларга бәйле урын юрматы кабиләсенең шәҗәрәсендә дә бар: Анда әйтелгән: «Ул заманда Әмәт Хәмәт дигән ханның кул астында тордылар... Шул ук заманда Җәнбәк хан илән Аксак Тимер хан иде. Булар вакытында йортка олуг бөлгенлек булды, һәр тарафка яулар булды. Әмәт Хәмәт йорты бозылды». Шул ук язмада бу Әмәт Хәмәт җирләренең Зәй-Шишмә буйларында булганлыгы күренә[5].

Күргәнегезчә, болгар дәүләтенең көнчыгыш чикләрендә XIV йөз ахырына кадәр болгарлар белән бәйле, ләкин ислам дине әле кереп бетмәгән төркемнәр яшәгән. Бу тарихи чыганакларга туры киләме соң? Археология материаллары бу мәгълүматларны өлешчә раслый. Мәсәлән, археолог Е. Казаков фикеренчә, Ык һәм Агыйдел елгаларының түбәнге төбәкләрендә әле XIV йөзнең икенче яртысына кадәр угор төркемнәре белән бәйле булган халык яшәгән (Чиялек археология культурасы). Аларга мөселман дине үтеп керсә дә, мәҗүсилек билгеләре яхшы күренә (бигрәк тә каберлекләрдә)[6]. Шундый ук хәл Алабуга тирәсе өчен дә хас булган (XIV йөзгә кадәр).

Соңыннан бу җирләр барысы да нугайлар кулына күчә. Нугайларның көчәюе, бәлки, XIV йөз ахырында Аксак Тимернең Болгар илен туздыруы белән бәйледер. Шул вакытта бит халык төрле якка тарала. Халыкның бер өлеше, бигрәк тә угорлар белән бәйле төркемнәрнең, үзләренә якын булган Кама һәм Агыйделдән төньяграк төбәкләргә күчүләре шушы чорга карамый микән? Бу фикерне Р. Кузеев әйтеп чыккан иде. Без, аны хуплап, бер тарихи чыганак китерәбез. Ул — Епифаний исемле Троице-Сергеев обителе дигән җирдән булган монах язмалары (соңыннан ул язмалар рус елъязмаларына эләгә). 1396 елгы мәгълүматларда Епифаний Пермь ягында яшәүче халыкларны санап китә (русча бирәбез): «а се имена живущим около Перми землям и странам и местом иноязычным: Двиняне, Устюжяне, Виляжане, Вычегжане, Южане, Сырьяне, Гаиняне, Вятчане, Лопь, Корела, Югра, Печера, Вогуличи, Самоядь, Пертасы, Пермь Великая, глаголемая Чусовая»[7]. Күренә ки, коми-зыряннар янында һәм Вятканың югары агымында яшәүчеләр тирәсендә «гайна» дигән халык искә алына. Бу — безгә билгеле булган гайнәләр булырга тиеш, соңыннан кайбер рус елъязмаларында «гайна» урынына русларга таныш булган «галичане» сүзе кертелә, ләкин бу очракта Епифанийга күбрәк ышанырга кирәк.

Гайнәләр һ. б. төркемнәрнең Минзәлә якларыннан килүләре турында тагын бүтән фактлар да сөйли. Мәсәлән, пермь татарлары яшәгән җирләрдә Азиби дигән күл бар. Шул ук топоним (авыл исемнәре: Рус һәм Татар Азибие) Минзәлә өязендә дә булган. Шул өяздәге халык тамгалары белән гайнәләрнең тамгалары арасында охшашлык табылды безнең тарафтан. Минзәлә якларыннан килгән, тамырлары белән угор булган, болгарлар белән дә бәйләнгән халык Пермь якларында күренгәндә, ул җирләр буш булмаган. Археологлар фикеренчә, бу төбәктә шул ук угор төркемнәре яшәгән (Сылва археология культурасы). Р. Кузеев язып алган риваятьләрдә дә гайнә кабиләсе үзенә туган «таныпъ» кабиләсен эзләп килә, дип күрсәтелә. Соңгылары гайнәләрдән бераз көньяктарак яшәгән. Шул ук таныпъ кабиләсе вәкилләре үз риваятьләрендә бабаларының «чын мари зат» («чирмеш!») булганлыгы, еланнарга табынганнары һәм мари патшасы янына Урал артына барулары турында сөйләгәннәр[8]. (Мәҗүсилек күренеп тора монда.) Чыннан да, «Минзәлә якларында» яшәгән угорлар өчен Урта Урал буена күчү беркадәр кире кайту булган, чөнки, археологлар әйтүе буенча, угорларның Идел Болгарстанына үтеп керүләренең беренче дулкыны IX гасырларда булса (борынгы венгрлар

---

[1] Р. Г. Кузеевның «Происхождение башкирского народа» дигән хезмәтен кара.

[2] История Татарии в материалах и документах. М., 1937, 44 б.

[3] Тарихчы Ә. Б. Булатов күрсәткәнчә, Агыйделнең Камага койган җирендә, Идриси (XII гасыр) мәгълүматлары буенча, Каракыя дигән шәһәр булган. (Кара: Булатов А. Б. Восточные средневековые авторы о башкирах.— Археология и этнография Башкирии, т. IV. Уфа, 1971, 324 б.).

[4] История Чингиз хана и Тамерлана... 151—152 б.

[5] Башкирские шеджере. Уфа, 1960, 27—28, 31—32 б.

[6] Казаков Е. П. Памятники болгарского времени в Восточных районах Татарии. М.: Наука, 1978.

[7] Дмитриев А. Древности бывшей Перми Великой. Пермская старина, вып. 1. Пермь, 1889, 62 б.

[8] Кузеев Р. Г. Күрсәтелгән хезмәт, 347 б.

белән бәйле), икенчесе X—XI гасырларга туры килә һәм Урал ягыннан килә. Соңгы дулкын вәкилләре XIV йөзгә кадәрге археологик материаллар аша да ачык күренә, бигрәк тә Болгар дәүләтенең төньяк-көнчыгыш читләрендә.

Пермь яклары Урта Идел буе татарларына (беренче чиратта, Казан татарларына) XVI йөзгә кадәр үк билгеле булган, ә бу якларның җирләре Казан ханлыгы составына кергән. Әйтик, шул турыда, башка фактлардан тыш, 1496 елны Казан ханы Ибраһим бөтен гаскәрләрен җыйганда, төрле гаскәр җибәрүче «җирләр» арасында «костяк» (остяк, иштәк) җире булу да сөйли (ул «җир» удмуртлар яшәгән «Сыплин», «Вотяк» һәм төркиләр белән угорлар яшәгән «Агыйдел», шулай ук «башкортлар» яшәгән төбәкләр арасында санала)[1]. Казан ханлыгы чорында бу якка Казаннан яу еш килеп тора. Мәсәлән, 1468 елны русларга Кама буенча менүче (Агыйдел койган җирдән ерак түгел) татарларның зур булмаган отряды очрый[2]. Бөек Пермьга каршы Казан татарлары соңрак та килә (1539—40 елларда)[3]. Бу яклардан руслар һәм комилар көньякка Казан ханлыгына буйсынган җирләргә шулай ук еш һөҗүм итеп торганнар.

Казан ханлыгы белән булган бәйләнеш, билгеле, борынгырак чорда барлыкка килгән элемтәләрнең дәвамы. Мәсәлән, XIV йөз ахырында, Әл Гомәри әйтүе буенча, «Болгар сәүдәгәрләре Чулманга кадәр (Чулман дип Каманың Агыйдел койган өлешеннән төньякта булган агымы аталган булса кирәк — Д. И.) барганнар, ә Чулман сәүдәгәрләре төньякның чиге булган Югор җирләренә барганнар»[4]. Монда шуңа игътибар итик: угорлар белән угордан «чыккан» халык эш иткән. Археология материаллары болгарлар белән Пермь яклары арасында (шул исәптән, Сылва культурасы таралган урыннарда да, ягъни, Сылва-Ирән бассейнында) барган үзара йогынтыны ачык күрсәтәләр. Ләкин бу элемтәләрнең тамыры тагын да тирәнрәк. Әйтик, Әбу Хәмит әл-Гарнәти (XII йөз) күрсәтүе буенча, болгарлар сәүдә итеп Вису җиренә барганнар, ә соңгылары «Иура (ягъни, Югра) җиренә» йөргәннәр[5].

Соңгы чорларда да, Пермь тирәләре Рус дәүләте кулына күчкәч тә, Казан татарлары бу яклар белән булган традицион сәүдә элемтәсен саклаганнар. Мәсәлән, 1618 елгы бер чыганакта Чердынь өязенә караган Сылва һәм Ирән елгалары тирәсенә «йомшак товар» — мехлар алу өчен рус сәүдәгәрләре генә түгел, ә Казан һәм Уфа өязләреннән «татарлар», «остяклар» һәм «башкортлар» килүе әйтелә[6].

Борынгы чорлардан килгән туганлык һәм Болгар иле белән «иштәк» җирләренең үзара бәйләнеше, бу угор һәм төркиләшкән угор төркемнәренең этник үзаңына йогынты ясамый калмаган. Мәсәлән, шул «иштәкләр»дән саналып, соңга таба «башкорт» исемен кабул иткән «әйле» кабиләсе вәкилләренең берсе (Таҗетдин Ялчыголның улы) үзенең язмаларында атасының сәяхәтен тасвирлап[7], Кубань тирәсендә нугайлар белән очрашуын күрсәтә. Нугайлар сорау бирәләр: «Син нинди җирнең улы» (баласы?). Җавап болай яңгырый: «Болгарлык иштәкмен». Билгеле, урта гасырларда ук формалашкан мондый этник аң, «иштәкләр»нең шактый өлешенә бердәм татар халкы һәм татар милләте оешу чорында татарлар белән консолидацияләнүне җиңеләйткән. Дин ягыннан бердәмлек тә шуңа этәргән. Моның шулай икәнлеген пермь татарларының этник тарихы яхшы күрсәтә.

Пермь татарлары оешуның барлык мәсьәләләре дә инде чишелде дип әйтеп булмый әле. Әйтик, югарыда аерып күрсәтелгән, бу төркемнең компонентлары булган төрле пермь татарларының аерым катлауларыннан бер бөтен булган берләшмә барлыкка килү процессын, аның механизмнарын төгәл итеп күз алдына китерү бүгенгә әле мөмкин түгел. Шулай ук бу процесста себер татарларының да катнашуы ачылып бетмәгән әле. Халбуки, Сылва, Ирән буйлары бик борынгыдан Себергә бара торган юлның бер өлеше булган һәм себер татарлары бу юлдан актив файдаланганнар. Шуңа күрә пермь татарлары сөйләшендә себер татарлары һәм Алтайда таралган төрки телләргә хас кайбер үзенчәлекләр чагылу (Д. Рамазанова фикере) юкка гына түгелдер. Ләкин бу — үзенә аерым зур мәсьәлә. Аның очы Урал аша инде VI—VII гасырларда ук Урал артыннан Урта һәм Көньяк Уралга күчкән төркемнәр гел угор булганмы, әллә алар арасында инде төрки һәм төркиләр белән катнаш төркемнәр дә булганмы, дигән мәсьәләгә килеп тоташа. Бу мәсьәлә, билгеле, IX—X гасырларда Уралдан Идел буена күчкән этник массага да карый. Бүгенгә бу сорауга бер төрле генә җавап юк әле.

---

[1] ПСРЛ, т.26. — Вологодско-Пермская летопись. М. — Л., 1959, 227 б.
[2] ПСРЛ, т-11—12 Патриаршая и Никоновская летописи. М. — Л., Из-во АН СССР, 1965, 119—120 б.
[3] Дмитриев А. Древности бывшей Перми Великой... 184 б.
[4] Сборник материалов, относящихся к истории Золотой Орды. Извлечения из сочинений арабск. Спб, 1884, 236 б.
[5] Путешествие Абу Хамида ал-Гарнати в восточную и центральную Европу (1131—1153) М., 1971, 31—34 б.
[6] Тарих институтының Ленинград бүлеге архивы, ф. 122, 1 тасвирлама, эш кәгазе 448.
[7] Кара: Башкирские шеджере, 169 б.

# КОРЪӘН СҮРӘЛӘРЕ

Узган 1990 елда «Казан утлары» журналы бер бик күркәм эш башлап җибәрде: күп санлы укучыларның үтенечләрен искә алып, Коръәннең кайбер сүрәләрен бастырып чыгарды. Бу эш журнал укучылар күңеленә хуш килеп, алар моның өчен бик күп рәхмәт хатлары яздылар һәм башлаган эшне дәвам итүне сорадылар. Аларның үтенечләрен канәгатьләндерү йөзеннән, без быел тагын берничә сүрә белән таныштырып китәрбез. Күп кенә хатларда «Тәбарәк» сүрәсен һәм Коръәннең утызынчы пәрәсенә, ягъни утызынчы кисәгенә керүче сүрәләрне басып чыгаруны үтенәләр. «Тәбарәк» сүрәсе Коръәндә «Мүлк» сүрәсе дип атала, ул «Тәбарәкә» дип башланып киткәнгә күрә, халык телендә сүрә исеме дә шулай йөри. Сүрә башланып киткән сүзгә бәйле рәвештә аның исеме дә үзгәртелү очраклары шактый. Мәсәлән, Коръәннең үзендә «Фатиха» сүрәсе — «Әлхәм» сүрәсе дип («Әлхәмдү...» сүзе белән башланып китә); «Нәбаә» сүрәсе — «Гаммә» сүрәсе дип; «Ихлас» сүрәсе — «Куль һүвәл-лаһ...» дип аталуларын һәм башкаларны күрсәтеп булыр иде. Коръән үзе утыз пәрәдән, ягъни утыз кисәктән тора. Шул пәрәләр эченә 114 сүрә керә. Пәрәләрнең бәгъзеләре бер сүрә эчендә берничә булса (мәсәлән, «Бәкара» сүрәсе эчендә 2 пәрәдән артык), кайберләре — үзләре берничә сүрәне эченә алалар. Шундыйларның берсе һәм халыкта иң танылган, шулай ук бик еш укыла торганы — утызынчы пәрә. Бу пәрә җитмеш сигезенче сүрәдән башлап йөз дә ундүртенче сүрә беткәнче, ягъни Коръән тәмамланганчы дәвам итә һәм үз эченә утыз җиде сүрәне ала. Хәтта бу утызынчы пәрәне аерым китап итеп бастырып чыгару очраклары да бар. Шуңа мисал итеп, Багдадта басылган һәм «Кагыйдәэи Багдадия. Гаммә, пәрәэи 30» дип аталучы ике кисәктән торган китапны күрсәтергә була. Әлеге китапның беренче кисәге укырга һәм язарга өйрәтүче үзөйрәткечтән, ә икенче кисәге Коръәннең утызынчы пәрәсенә керүче сүрәләрдән тора. Журнал өчен утызынчы пәрәне әзерләгәндә әлеге китаптан да файдаланылды. Ләкин анда, сүрәләрне урнаштыру тәртибе — ахырдан башланып алга табан, ягъни 114 сүрәдән башлап 78 сүрә беткәнче, күләмнәре ягыннан иң кечкенә сүрәдән башлап зурракларына табан бирелә. Болай бирү тәртибе — Коръәндәге тәртипкә каршы килгәнлектән, сүрәләр ул китаптагы тәртип буенча түгел, Коръәндәгечә бирелделәр. Транскрипцияне, ягъни сүрәләрнең бүгенге гамәли кулланылышта булган хәрефләр белән язылышын һәм укылышын эшләгәндә академик, фәнни транскрипциянең татар әдәби теле нормаларына якынайтылган үрнәген һәм тәҗвид кануннарын, Коръәндәге сүзләрнең өсләренә яки асларына, башларына яки азакларына куелган аерым шартлы билгеләрне дә истә тотып эшләнде. Шунлыктан, сүзләрнең бер төрле язылып та икенче төрле укылышына һәм язылышына, кушымчаларның төрлелегенә укучы гаҗәпләнмәсен иде.

Кайбер укучылар сүрәләрнең исемнәрен дә, шулай ук эчтәлекләрен дә Коръәннең әлегә кадәр басылып килгән академик И. Ю. Крачковский тарафыннан рус теленә тәрҗемә ителгән нөсхәсе белән чагыштырып караучан була. Янәсе, татар теленә дөрес итеп, ягъни И. Ю. Крачковскийдагыча бирелә ме?.. Мондый укучыларга мин болай дип әйтер идем: беренчедән, Коръән русчага Крачковский тарафыннан баштан азакка кадәр камил һәм төгәл тәрҗемә итеп бетерелмәгән — ул вафат була һәм каралама хәлендәге кульязмасын шул көе аның якты истәлегенә багышлап бастырып чыгаралар. Әлбәттә, әгәр ул исән булса, бу эшен дә башка күп хезмәтләре кебек үк җиренә җиткереп, шомартып, камилләштереп эшләп бетергән булыр иде, ләкин мәшһүр галим өлгерә алмый кала. Табигый ки, аның караламасында да аңлашылып ук җитмәгән урыннар да, төгәлсезлекләр дә, кытыршылыклар да очрый. Чөнки ул иң авыр өлешен тизрәк эшләп бетерергә ашыккан, ә шомартуга, төгәлләүгә явыз үлем вакыт калдырмаган. Икенчедән, гарәп теле шул кадәр бай ки, аның кайбер сүзләре бик күп мәгънә төсмере белдереп киләләр. Күрәсең, Крачковский да Коръәнне тәрҗемә иткәндә әнә шундый бик күп мәгънәгә ия булган сүзләрнең берсен — кайбер очракта төп мәгънә агышына бик үк тәңгәл килеп үк җитмәгәнен кулланган-

дыр. Укучы мине дөрес аңласын иде: мин монда дөньякүләм танылган галимне тәнкыйтьләргә җыенмыйм. Бу — минем бурычым да түгел. Мин бары тик аның биниһая кыйммәтле, күп санлы хезмәтләренең берсе булган Коръәннең русчага тәрҗемәсен кулга алып укып карагач һәм инде, әлбәттә, бу сүрәләрне матбугат өчен әзерләү вакытында Шәйхелислам Хәмидинең 1907 елда Казанда басылган «Әл-иткан фи тәрҗемәтил-Коръән» дип аталучы тәфсирен һәм башка тәфсирләрне файдаланып эшләп утырганда туган фикерләрем вә күзәтүләрем белән уртаклашмакчы булам. Миңа Октябрь инкыйлабына кадәр татар телендә басылган берничә Коръән тәфсире белән танышырга һәм фикер тулылыгы яки камиллек өчен алардан файдаланырга туры килде. Менә шуларның камиллеге һәм тулылыгы ягыннан югарыда телгә алынган Шәйхелислам Хәмиди тәфсире иң уңышлылардан санала. Тегe яки бу тәфсирнең сыйфаты авторының үз өлкәсендә никадәр мәгълүматлы булуына һәм осталыгына, шулай ук күп мәгънәләргә ия сүзләрнең иң кулаен, иң уңышлысын сайлап алып тәрҗемә итә белүенә, иң мөһиме, сиземләү сәләтенә бәйле. Шәйхелислам Хәмидидә бу сыйфатлар бар дип әйтер идем мин. Дөрес, аның хезмәтендә дә бәгъзе кытыршылыклар очрый, ләкин ул, гомумән, үз эшенә җитди, зур җаваплылык белән караган.

Академик И. Ю. Крачковский тәрҗемәсендәге һәм Шәйхелислам Хәмиди тарафыннан эшләнгән тәфсирдәге, журнал өчен әзерләнгән сүрәләрнең кайберләренең исемнәрен генә чагыштырып карыйк әле (төп тәрҗемә текстына кагылып, чагыштырып тормыйбыз): русча тәрҗемәдә «Ән-назигат» дип аталучы җитмеш тугызынчы сүрә «Вырывающие» («Йолкып алучылар», «суыручылар») дип бирелә. Хәмидидә барлык сүрә исемнәре тәрҗемә ителмичә, Коръәндәгечә генә биреләләр. Ә миңа нишләргә? Крачковскийдагыча бирергәме, әллә мәгънәне һәм сүрәнең эчтәлеген ачып торган сүзләрне үземә эзләргәме? Бик күп борынгы сүзлекләрне актарганнан соң, «Ән-назигат» сүзенең «Җан суыручы фәрештәләр» мәгънәсен белдерүе ачыкланды (сүрәдә дә сүз нәкъ шул турыда бара). Ә Крачковский «Ән-назигат» сүзенең «Әл» артикле булып килүче «Ән» алкушымчасын төшереп калдырып кына тәрҗемә итә һәм мәгънә төсмере ачылып бетмичә кала. Русча тәрҗемәдә «Буруҗ» дип аталучы сиксән бишенче сүрә «Башни» («Манаралар») дип бирелә һәм беренче аять: «Клянусь Небом — обладателем башен!» («Манаралар иясе булган Күк белән ант итәм») дип тәрҗемә ителә. Ә сүзлекләрдән эзли торгач, бу сүзнең «Йолдызлыклар» дигән мәгънәсе дә табылды һәм шул сүз сүрә исеменең тәрҗемәсе итеп бирелде. Шәйхелислам Хәмиди тәфсирендә дә беренче аять «Йолдызлыклар иясе булган Күк белән ант итәмен» дип тәрҗемәләнә. Русча тәрҗемәдә «Әт-тарикъ» дип аталучы сиксән алтынчы сүрә «Идущий ночью» («Төнлә баручы») дип бирелә һәм беренче аятьтә: «Клянусь небом и идущим ночью!» («Күк һәм төнлә баручы белән ант итәм!») дип тәрҗемә ителә. Эзли торгач, бу сүзнең «Төнлә калкучы йолдыз» дигән мәгънәсе дә табылды. Шәйхелислам Хәмиди тәфсирендә исә бу беренче аять: «Күк һәм кичне яктыртучы гаҗәп сыйфатлы булган тарикъ (йолдыз) белән ант итәмен» дип тәрҗемәләнә. Русча тәрҗемәдә «Әл-гашийә», дип аталучы сиксән сигезенче сүрә «Покрывающее» («Каплаучы», «томалаучы») дип бирелә һәм беренче аять: «Дошел ли до тебя рассказ о покрывающем?» («Сиңа каплаучы турындагы хикәят барып җиттеме?») дип тәрҗемә ителә. Сүзлекләрдә бу сүзнең «Үлекләр терелә торган көн» дигән мәгънәсе дә табылды һәм ул сүрә исеменең тәрҗемәсе итеп куелды. Шәйхелислам Хәмиди бу беренче аятьне: «Әй, Мөхәммәд! Чыннан да, сиңа адәмнәрне куркытучы көннең (ягъни кыямәт көннең — үлекләр терелә торган көннең — Ә. Х.) хәбәре килде» дип тәрҗемәли. Шундый ук рухтагы күзәтүләрне туксан дүртенче, йөзенче, йөз дә беренче, йөз дә икенче, йөз дә өченче, йөз дә унберенче һәм башка сүрәләрнең исемнәрен чагыштыруда, шулай ук тәрҗемәдәге аермаларда да күреп була. Шулай итеп, югарыда китерелгән мисаллар русчага тәрҗемә белән тәфсирнең икесе ике нәрсә икәнлеген исбатлый. Ә безнең максат — И. Ю. Крачковский тарафыннан җибәрелгән кайбер төгәлсезлекләрне дә искә алып, Шәйхелислам Хәмиди һәм башкалар эшләгән тәфсирләрдәге җитешсезлекләрне дә күздә тотып, хәл кадәренчә тулырак та, һәркемгә аңлаешлырак та бер Коръән тәфсире чыгару. Бу эшнең нигезе — Шәйхелислам Хәмидинең «Әл-иткан фи тәрҗемәтил-Коръән» дип аталучы тәфсире.

Укучыларга тәкъдим ителә торган Коръән сүрәләре әлеге тәфсирдән алынды. Мәгълүм булганча, XX йөз башындагы һәм аңа кадәрге телебездә бик күп гарәп, фарсы, төрек сүзләре һәм борынгы төрки сүзләр кулланылган. Шуны күздә тотып, әлеге тәфсир бүгенге укучыбыз аңларлык дәрәҗәдә җиңелләштерелеп, гадиләштерелеп, шул ук вакытта төп мәгънәне саклаган хәлдә хәзерге телебезгә күчерелде.

**Әнвәр ХӘЙРИ,**
Г. Ибраһимов исемендәге Тел,
әдәбият һәм тарих институтының
өлкән фәнни хезмәткәре.

АЛТМЫШ ҖИДЕНЧЕ СҮРӘ
БАРЛЫГЫ УТЫЗ АЯТЬ.

## ٦٧ سُورَةُ ٱلْمُلْكِ مَكِّيَّةٌ وَآيَاتُهَا ٣٠

بِسْمِ ٱللَّهِ ٱلرَّحْمَٰنِ ٱلرَّحِيمِ

تَبَٰرَكَ ٱلَّذِى بِيَدِهِ ٱلْمُلْكُ وَهُوَ عَلَىٰ كُلِّ شَىْءٍ قَدِيرٌ ﴿١﴾ ٱلَّذِى خَلَقَ
ٱلْمَوْتَ وَٱلْحَيَوٰةَ لِيَبْلُوَكُمْ أَيُّكُمْ أَحْسَنُ عَمَلًا وَهُوَ ٱلْعَزِيزُ ٱلْغَفُورُ ﴿٢﴾
ٱلَّذِى خَلَقَ سَبْعَ سَمَٰوَٰتٍ طِبَاقًا مَّا تَرَىٰ فِى خَلْقِ ٱلرَّحْمَٰنِ مِن تَفَٰوُتٍ
فَٱرْجِعِ ٱلْبَصَرَ هَلْ تَرَىٰ مِن فُطُورٍ ﴿٣﴾ ثُمَّ ٱرْجِعِ ٱلْبَصَرَ كَرَّتَيْنِ
يَنقَلِبْ إِلَيْكَ ٱلْبَصَرُ خَاسِئًا وَهُوَ حَسِيرٌ ﴿٤﴾ وَلَقَدْ زَيَّنَّا ٱلسَّمَآءَ
ٱلدُّنْيَا بِمَصَٰبِيحَ وَجَعَلْنَٰهَا رُجُومًا لِّلشَّيَٰطِينِ وَأَعْتَدْنَا لَهُمْ عَذَابَ
ٱلسَّعِيرِ ﴿٥﴾ وَلِلَّذِينَ كَفَرُوا۟ بِرَبِّهِمْ عَذَابُ جَهَنَّمَ وَبِئْسَ ٱلْمَصِيرُ ﴿٦﴾
إِذَآ أُلْقُوا۟ فِيهَا سَمِعُوا۟ لَهَا شَهِيقًا وَهِىَ تَفُورُ ﴿٧﴾ تَكَادُ تَمَيَّزُ مِنَ
ٱلْغَيْظِ كُلَّمَآ أُلْقِىَ فِيهَا فَوْجٌ سَأَلَهُمْ خَزَنَتُهَآ أَلَمْ يَأْتِكُمْ نَذِيرٌ ﴿٨﴾ قَالُوا۟
بَلَىٰ قَدْ جَآءَنَا نَذِيرٌ فَكَذَّبْنَا وَقُلْنَا مَا نَزَّلَ ٱللَّهُ مِن شَىْءٍ إِنْ أَنتُمْ إِلَّا فِى

[1] «Мүлк сүрәсе», башланып киткән беренче сүзгә бәйле рәвештә, икенче төрле «Тәбарәк сүрәсе» дип тә атала.

ضَلَٰلٖ كَبِيرٖ ﴿٩﴾ وَقَالُواْ لَوۡ كُنَّا نَسۡمَعُ أَوۡ نَعۡقِلُ مَا كُنَّا فِيٓ أَصۡحَٰبِ
ٱلسَّعِيرِ ﴿١٠﴾ فَٱعۡتَرَفُواْ بِذَنۢبِهِمۡ فَسُحۡقٗا لِّأَصۡحَٰبِ ٱلسَّعِيرِ ﴿١١﴾ إِنَّ
ٱلَّذِينَ يَخۡشَوۡنَ رَبَّهُم بِٱلۡغَيۡبِ لَهُم مَّغۡفِرَةٞ وَأَجۡرٞ كَبِيرٞ ﴿١٢﴾ وَأَسِرُّواْ
قَوۡلَكُمۡ أَوِ ٱجۡهَرُواْ بِهِۦٓۖ إِنَّهُۥ عَلِيمُۢ بِذَاتِ ٱلصُّدُورِ ﴿١٣﴾ أَلَا يَعۡلَمُ مَنۡ
خَلَقَ وَهُوَ ٱللَّطِيفُ ٱلۡخَبِيرُ ﴿١٤﴾ هُوَ ٱلَّذِي جَعَلَ لَكُمُ ٱلۡأَرۡضَ
ذَلُولٗا فَٱمۡشُواْ فِي مَنَاكِبِهَا وَكُلُواْ مِن رِّزۡقِهِۦۖ وَإِلَيۡهِ ٱلنُّشُورُ ﴿١٥﴾
ءَأَمِنتُم مَّن فِي ٱلسَّمَآءِ أَن يَخۡسِفَ بِكُمُ ٱلۡأَرۡضَ فَإِذَا هِيَ تَمُورُ ﴿١٦﴾
أَمۡ أَمِنتُم مَّن فِي ٱلسَّمَآءِ أَن يُرۡسِلَ عَلَيۡكُمۡ حَاصِبٗاۖ فَسَتَعۡلَمُونَ كَيۡفَ
نَذِيرِ ﴿١٧﴾ وَلَقَدۡ كَذَّبَ ٱلَّذِينَ مِن قَبۡلِهِمۡ فَكَيۡفَ كَانَ نَكِيرِ ﴿١٨﴾ أَوَلَمۡ
يَرَوۡاْ إِلَى ٱلطَّيۡرِ فَوۡقَهُمۡ صَٰٓفَّٰتٖ وَيَقۡبِضۡنَۚ مَا يُمۡسِكُهُنَّ إِلَّا ٱلرَّحۡمَٰنُۚ
إِنَّهُۥ بِكُلِّ شَيۡءِۭ بَصِيرٌ ﴿١٩﴾ أَمَّنۡ هَٰذَا ٱلَّذِي هُوَ جُندٞ لَّكُمۡ يَنصُرُكُم
مِّن دُونِ ٱلرَّحۡمَٰنِۚ إِنِ ٱلۡكَٰفِرُونَ إِلَّا فِي غُرُورٍ ﴿٢٠﴾ أَمَّنۡ هَٰذَا ٱلَّذِي
يَرۡزُقُكُمۡ إِنۡ أَمۡسَكَ رِزۡقَهُۥۚ بَل لَّجُّواْ فِي عُتُوّٖ وَنُفُورٍ ﴿٢١﴾ أَفَمَن يَمۡشِي
مُكِبًّا عَلَىٰ وَجۡهِهِۦٓ أَهۡدَىٰٓ أَمَّن يَمۡشِي سَوِيًّا عَلَىٰ صِرَٰطٖ مُّسۡتَقِيمٖ ﴿٢٢﴾
قُلۡ هُوَ ٱلَّذِيٓ أَنشَأَكُمۡ وَجَعَلَ لَكُمُ ٱلسَّمۡعَ وَٱلۡأَبۡصَٰرَ وَٱلۡأَفۡـِٔدَةَۖ
قَلِيلٗا مَّا تَشۡكُرُونَ ﴿٢٣﴾ قُلۡ هُوَ ٱلَّذِي ذَرَأَكُمۡ فِي ٱلۡأَرۡضِ وَإِلَيۡهِ

يُحْشَرُونَ ﴿٢٤﴾ وَيَقُولُونَ مَتَىٰ هَٰذَا ٱلْوَعْدُ إِن كُنتُمْ صَٰدِقِينَ ﴿٢٥﴾ قُلْ
إِنَّمَا ٱلْعِلْمُ عِندَ ٱللَّهِ وَإِنَّمَآ أَنَا۠ نَذِيرٌ مُّبِينٌ ﴿٢٦﴾ فَلَمَّا رَأَوْهُ زُلْفَةً
سِيٓـَٔتْ وُجُوهُ ٱلَّذِينَ كَفَرُوا۟ وَقِيلَ هَٰذَا ٱلَّذِى كُنتُم بِهِۦ تَدَّعُونَ ﴿٢٧﴾
قُلْ أَرَءَيْتُمْ إِنْ أَهْلَكَنِىَ ٱللَّهُ وَمَن مَّعِىَ أَوْ رَحِمَنَا فَمَن يُجِيرُ ٱلْكَٰفِرِينَ
مِنْ عَذَابٍ أَلِيمٍ ﴿٢٨﴾ قُلْ هُوَ ٱلرَّحْمَٰنُ ءَامَنَّا بِهِۦ وَعَلَيْهِ تَوَكَّلْنَا
فَسَتَعْلَمُونَ مَنْ هُوَ فِى ضَلَٰلٍ مُّبِينٍ ﴿٢٩﴾ قُلْ أَرَءَيْتُمْ إِنْ
أَصْبَحَ مَآؤُكُمْ غَوْرًا فَمَن يَأْتِيكُم بِمَآءٍ مَّعِينٍ ﴿٣٠﴾

ТРАНСКРИПЦИЯ

*Бисмилләһир-рахмәнир-рахим*

*Тәбарәкәл-ләзи бийәдиһил-мулкү вә һүвә галә күлли шәйэин кадир (1). Әлләзи халәкаль-мәүтә вәл-хайатә лийәблүвәкүм әййүкүм әхсәнү гамәлә, вә һүвәл-газизүл-гафуру (2). Әлләзи халәка сәбга сәмәватин тыйбакам мә тәра фи халькыйр-рахмәни мин тәфавут, фәрҗигыйль-бәсара һәл тәра мин футур (3). Сүммәр-җигыйль-бәсара кәррәтәйни йәнкалиб иләйкәл-бәсару хәсиэән вә һүвә хәсир (4). Вә ләкад зәййәннәс-сәмәәд-дүньйа бимәсабиха вә җәгальнәһа руҗүмән лиш-шәйатыйни вә әгътәдна ләһүм газабәс-сәгыйр (5). Вә лил-ләзинә кәфәру бираббиһим газабү җәһәннәм, вә биэсәл-мәсыйр (6). Иза үлку фиһа сәмигу ләһа шәһикан вә һийә тәфур (7). Тәкәдү тәмәййәзү минәл-гайз, күлләмә үлкыйә фиһа фәүҗүн сәәаләһүм хәзәнәтүһа ә ләм йәэтикүм нәзир (8). Калү бәлә кад җаәәна нәзирун фәкәззәбна вә кульна мә нәззәләл-лаһү мин шәйэин ин әнтүм иллә даләлин кәбир (9). Вә калү ләү күннә нәсмәгу әү нәгъкыйлу мә күнна фи әсхабис-сәгыйр (10). Фәгътәрафу би-зәмбиһим фәсүхкал лиәсәәхабис-сәгыйр (11). Иннәл-ләзинә йәхъшәүнә раббәһүм билгайби ләһүм-мәгфиратүв вә әҗрун кәбир (12). Вә әсирру кауләкүм әвиҗһәру биһ, иннәһү галимүм бизатис-содур (13). Ә лә йәгъләмү мән халәка вә һүвәл-латыйфүл-хабир (14). Һүвәл-ләзи җәгалә ләкүмүл-арда зәлүлән фәмшу фи мәнәкибиһа вә күлү мир ризкыйһ, вә иләйһин-нүшүр (15). Ә әминтүм-мән фис-сәмәэи ән йәхсифә бикүмүл-арда фәиза һийә тәмүр (16). Әм әминтүм мән фис-сәмәэи ән йүрсилә галәйкүм хасыйба, фәсәтәгъләмүнә кәйфә нәзир (17). Вә ләкад кәззәбәл-ләзинә мин каблиһим фәкәйфә кәнә нәкир (18). Ә вә ләм йәрәү иләт-тайри фәүкаһүм сааффатин вә йәкъбидънә, мә йүмсикүһүннә илләр-рахмән, иннәһү бикүлли шәйэим-басыйр (19). Әммән һазәл-ләзи һүвә җүндү-ләкүм йансурукүм мин дүнир-рахмән, инил-кәфирун иллә фи горур (20). Әммән һазәл-ләзи йарзүкукүм ин әмсәкә ризкаһ, бәл ләҗҗү фи гутүүин фә нүфур (21). Ә фәмән йәмши мүкиббән галә вәҗһиһи әһдәә әммән йәмши сәвийййән галә сыйратыйм-мустәкыйм (22). Куль һүвәл-ләзи әншаәәкүм вә җәгалә ләкүмүс-сәмга вәл-әбсарә вәл-әфъэидәһ, калилән мә тәшкүрун (23). Куль һүвәл-ләзи зәраәәкүм фил-арди*

*вә иләйһи тәхшәрув (24). Вә йакулунә мәтә һазәл-вәгъду ин кунтүм садыйкыйн (25). Куль иннәмәл-гыйльму гыйндәл-лаһи иннәмә әнә нәзирум-мубин (26). Фәләммә рәәәүһу зулфәтән сиәәт вөҗүһүл-ләзинә кәфәру вә кыйлә һазәл-ләзи кунтүм биһи тәддәгун (27). Куль ә рәәәйтүм ин әһләкәнийәл-лаһу вә мәм мәгыйә әү рахимәнә фәмән йүҗирул-кәфиринә мин газабин әлим (28). Куль һүвәр-рахмәну әмәннә биһи вә галәйһи тәвәккәлнә, фә-сәтәгъләмүнә мән һүвә фи дәләлим мубин (29). Куль ә рәәәйтүм ин әсъбаха мәәүкүм гауран фәмән йәәтикүм бимәәим мәгыйн (30).*

СҮРӘНЕҢ ТӘФСИРЕ

Мәрхәмәт итүче, рәхимле Аллаһ хакына.

Һәрбер нәрсәгә падишаһлык кылучы Аллаһы Тәгалә кимчелекле сыйфатлардан пакь булды. Ул, Аллаһы Тәгалә, һәр нәрсәгә көче житүчедер... (1). Ул, Аллаһы Тәгалә, үлемне һәм тереклекне бар итүче заттыр. Боларны бар итүе — Аллаһы Тәгаләнең сезне кайсыгыз гамәл йөзеннән гүзәлрәк икәнен сынар өчен... Ул, Аллаһы Тәгалә, һәр нәрсәдән өстен һәм һәрбер гөнаһларны ярлыкаучыдыр (2). Җиде кат күкләрне кат-кат итеп яратты Ул, Аллаһы Тәгалә... Әй, рәсүл! Син Аллаһының барлыкка китергән күкләрендә төрлелекне күрмәссең. Яңадан күзеңне ачып кара, күкләрдә бер-бер тишек яки ярык күрерсеңме? Әлбәттә, күрмәссең (3). Моннан соң, тагын күзеңне әйләндергәннән соң, тагын әйләндереп кара! Күпме карасаң да, күзең, теләгәненнән мәхрүм булып, күкләрдә өметсез рәвештә ярык күрә алмас (4). Чыннан да, Без түбәнге Күкне якты йолдызлар белән зиннәтләдек, һәм дә ул йолдызларны зарарлы затларны күктән сөрүче кылдык. Инде йолдызларның яктылыгында кич караңгысында йөрүче ерткыч хайваннар һәм угрыларның зарарыннан саклану мөмкин булганлыктан, Аллаһы Тәгалә йолдызларны шул нәрсәләрне куучы һәм сөрүче кылдык дип бәян итте. «Йолдыз атылу — йолдыздан ут кисәге атылу» дигән сүздер. Ул шайтаннар өчен янып торучы ут газабын хәзерләдек Без (5). Раббеләренә иман китермәгән кяферләр өчен, иң яман урын җәһәннәм газабы булыр (6). Әгәр ул тәмугка кяферләр салынса, уттан бер кабәхәт тавыш ишетелер. Кяферләр керәчәк ут шундый яман сыйфатлыдыр (7). Әгәр тәмугка кяферләрдән бер гөруһ, ягъни төркем салынса, шул вакытта тәмугның сакчылары ул гөруһтан: «Сезне иманга өндәп, кяферләргә тәмуглар булачак, дип куркытучы пәйгамбәрләр килмәдемени?» — дип сорарлар... (8). Бу сорауга кяферләр әйтерләр: «Дөрес, безгә пәйгамбәрләр килделәр, әмма аларны ялганга чыгару аркасында Аллаһы Тәгалә һич нәрсә җибәрмәде... (9). Янә дә кяферләр әйтерләр: «Әгәр без пәйгамбәрләрнең сүзләрен тоту нияте белән тыңлаган булсак иде, яисә аларның сүзен гакылыбызга салып уйлаган булсак иде, әлбәттә, тәмуг әһелләре эчендә булмас идек»,— дип (10). Тәмугда хәлләрендә кяферләр үзләренең пәйгамбәрләргә карышу гөнаһлары белән телдән язарлар. Әмма бу урында тел язулары файда бирмәс: тәмуг әһелләре өчен Аллаһының рәхмәтеннән ераклык булыр. Ягъни аларны Аллаһы Тәгалә рәхмәтенә якын кылмас. Никадәр ялынсалар да, никадәр еласалар да, файда бирмәс (11). Дөреслектә, Раббеләреннән, Аның газапларын күрми торып курыккан кешеләр өчен гөнаһларын ярлыкау һәм дә олуг ял (җәннәт йорты) булыр (12). Мәҗүсиләр үзара киңәш итешкәндә берсе-берсенә әйтешәләр иде: «Сүзләрегезне яшерен сөйләгез, Мөхәммәднең Аллаһысы ишетмәсен!» — дип. Аларның шул яман фикерләрен бетерү өчен ошбу аять иңде. Мәгънәсе: «Әй, адәмнәр! Сүзләрегезне кирәк — яшерен кылыгыз, кирәк — кычкырып сөйләгез, барыбер. Чөнки Аллаһы Тәгалә күңелләрдә булган серләрне белүчедер» (13). Әй, адәмнәр! Үзегез уйлагыз, сезне юктан бар кылган Аллаһ сезнең сүзләрегезне белмәсме? Ул Аллаһ — һәрбер нечкә һәм яшеренНәрне белүче һәм һәрнәрсәдән хәбәрдар булучы (14). Ул Аллаһы шундый Заттыр, Җирне, сезнең файдалануыгыз өчен, тигез итеп яратты. Инде сез ул Җирнең тирәләрендә йөрегез һәм дә Аллаһы Тәгаләнең Җирдә барлыкка китергән ризыгын ашагыз! Ләкин Аллаһының фарманын тотыгыз! Биргән нигъмәтләренә шөкер

кылыгыз! Чөнки үлгәннән соң Аллаһы Тәгалә хозурына хисап өчен барачаксыз (15). Әй, кяферләр! Әллә сез Күктә дип уйлый торган Заттан сезне Җиргә ирештереп, кая барырыгызны белмәс хәлгә китерүеннән тыныч булдыгызмы? Яисә шул ук Күктә дип уйлаган Затыгыздан сезгә куәтле җил җибәреп, сезне һәлак итүеннән тыныч булдыгызмы? Тиздән белерсез, Минем куркытуым ничек булганын (16). Аң булыгыз! Ягъни күктә дип уйлаган бөтен нәрсәне барлыкка китергән Аллаһы, Карунны Җирдән йоттырган кебек, сезне дә йоттырмас дип уйлыйсызмы? Гад кавемен җил белән һәлак иткән Аллаһы Тәгалә, сезне дә җил җибәреп һәлак итә алмас дисезме? (17). Бу Мәккә кяферләреннән элек булган кяферләр дә пәйгамбәрне ялганга чыгардылар, Минем аларга җәза бирүем ничек яман булды! Ягъни бу кяферләргә дә шундый газап бирергә көчемнән килмәс диләрмени? Әлбәттә, теләсәм, боларны да газаплармын (18). Ул ышанмаучылар һавадагы канатларын җәйгән һәм канатларын җыйган кошларга карамадылармы? Ул гамәл кошларны түбәдән егылып төшүдән сакламас. Мәгәр һәрнәрсәне күрүче Аллаһы Тәгалә генә саклап тотар... Мондый кодрәт иясенең кяферләрне газапка дучар итәргә көче җитмәсме? Әлбәттә, җитәр (19). Әй, кяферләр! Әллә сезнең Аллаһыдан башка, Аллаһының газаплавыннан саклауда ярдәм итүче, булышучы затларыгыз бармы? Әлбәттә, юк. Бары кяферләр, алданып кына, Аллаһының газабыннан котылабыз, дип йөриләр... (20). Әллә сезнең, Аллаһы Тәгалә ризык бирүне туктатканнан соң, ризык бирә торган затларыгыз бармы? Әлбәттә, Аллаһыдан башка ризык бирүче һичбер Зат юк. Бары кяферләр каршылыкта һәм дә хактан ерак торуда гына булдылар... (21). Болардан кайсы тугры юлда саналдылар: йөзтүбән йөрүче кешеләрме яки тугры юлда тигез йөрүче кешеләрме? Әлбәттә, тугры юлда бик тигез йөрүче кеше тугры юлда саналыр. Ягъни мөэмин-мөселман белән кяферләрнең мисаллары шуның кебектер (22). Әй, Мөхәммәд! Адәмнәргә әйт син: «Ул Аллаһы — шундый Заттыр, сезгә колак, күзләр һәм калеб, ягъни йөрәк бирде. Сез аз гына шөкер кылмыйсызмы?» — дип, ягъни, Аллаһы Тәгалә һәрбер кешегә колак бирде, хак сүзләрне ишетү өчен. Күз бирде. Аллаһының гаҗәеп эшләрен карау өчен. Күңел бирде, ишеткән, күргән нәрсәләрне уйлап, хаклыкны табу өчен. Инде бу нигъмәтләрнең шөкере боларны шул билгеле урыннарына тоту белән буладыр... (23). Әйт син адәмнәргә, әй, Мөхәммәд: «Ул Аллаһ шундый Заттыр — сезне җирдә яратты, һәм сез үлгәннән соң Аллаһы Тәгалә тарафына кубарылачаксыз!» — дип (24). Кяферләр рәсүлуллага һәм дә мөэмин-мөселманнарга әйтерләр: «Әгәр дә сез ул әйткән эшләрне әйтүегездә дөрес булсагыз, бу кубарылу, газап вәгъдәсе кай заман җитәр»,— дип (25). Әйт син, әй, Мөхәммәд! «Ул вәгъдәнең кай вакыты икәнен белү Аллаһы Тәгалә ихтыярындадыр. Әмма минем ул вәгъдәнең вакытын белүдә эшем юк. Бәлки мин Аллаһы Тәгалә тарафыннан шундый булачак эшләрдән куркыту өчен җибәрелгән рәсүл генәмен»,— дип (26). Ул кяферләр вәгъдә ителгән газап көнен күргән заманда йөзләре каралып рисвай булырлар һәм дә шул вакытта Аллаһы Тәгалә тарафыннан: «Дөньяда вәгъдә ителгән көн һәм газап — ошбудыр»,— дип әйтелер (27). Әйт син, әй, Мөхәммәд: «Әй, кяферләр, әгәр дә Аллаһы Тәгалә мине, һәм дә минем белән бергә булган мөэмин-мөселманнарны һәлак кылса, яисә безгә Аллаһы Тәгалә мәрхәмәт һәм рәхмәт итсә, безгә Аллаһы Тәгалә шулардан кайсын эшләсә дә эшләр, ләкин шул вакытта үлгәннән соң булачак каты газаптан кяферләрне кем йолып калыр? Шуны уйлап карадыгызмы? (28). Әйт син, әй, Мөхәммәд!: «Мин сезне мәрхәмәт итүче булган Аллаһыга иман китерүгә өндимен! Без ул мәрхәмәт итүчегә иман китердек һәм дә Аңар тәвәккәлләдек. Инде сез кемнең ачылган азгынлыктан икәнен тиз белерсез» (29). Әйт син, әй, Мөхәммәд!: «Әгәр дә сезнең чишмә һәм коелардагы суыгыз җиргә сеңсә, шул вакытта сездән кайсыларыгыз тибеп, һаман да чыгып торучы су китерә алыр, шуны беләсезме? Әлбәттә, һичберегезнең кулларыннан килмәс»... (30).

*Дәвамы бар*

**Китап күзәтү**

# ИРТӘГӘ ДӘ ЯШИСЕ БАР...

Чаллыда яшәп иҗат итүче балалар язучысы Рәшит Бәшәрнең олы һәм урта яшьтәге балалар өчен «Иртәгә дә яшисе бар» дигән китабы басылып чыкты. Китап өч повестьне эченә ала: «Яшел поезд», «Миләш», «Иртәгә дә яшисе бар».

Иң башта шуны әйтик: ул матур тел белән, балаларга барып җитәрлек итеп язылган. Рәхәтләнеп, онытылып укыйсың.

Китап балаларга зур бүләк булган. Ул яшүсмерләрдә намуслылык, рәхимлелек сыйфатлары тәрбияли. Яшьләрне табигать серләрен аңларга, табигатьне сакларга чакыра. Мәсәлән, «Яшел поезд» дигән повестьта:

— Нинди балык капсын соң сиңа, аракы белән тәмәке исен яратмый бит ул балык,— ди Рәхимнең әтисе, тәмәке кабызып балык тотып утыручы абыйга.

Бу повестьта төп геройлар — Рәхим белән Алмазия. Рәхим шәһәрдә туган малай. Әтисе авылны сагынганлыктан, шәһәрне калдырып, авылга кайталар. Ул авылны да ярата, шәһәрне дә сагына. Еш кына шәһәргә дә барып, үзләре торган йортны карап кайткалый. Алмазияны да чакыра:

— Әйдә, бәлки анда әниеңне очратырсың,— ди. Шул шәһәр юлында йөргәндә, Рәхим Акбаен югалта, «Космонавтлар белән сөйләшә торган» аппарат ясамакчы була, хыяллана.

— Их, сөйләшергә иде шулар белән. Акбайның да кайда икәнен әйтеп бирерләр иде! — ди.

Рәхим олылар белән сөйләшкәндә дә, әнисе кебек булырга тырышып, аның сүзләрен кушып сөйләшә:

— Исәнме, әбекәй, шөкер генә яшисеңме?

Алмазия да яхшы күңелле кыз. Әбисенең бердәнбер ярдәмчесе. Аны карый, тәрбияли, юындыра. Олыларга бик ихтирамлы кыз. Әбисен дәвалый да белә ул.

Рәхим дә, Алмазия да, әбисе дә, шулай ук Рәхимнең әтисе дә үз тирәләрендәге табигать бозылуга бик борчылалар. Шуның нәтиҗәсендә хайваннарга, пошиларга янаган бәхетсезлекне авыр кичерәләр. Поши баласы чокырга төшеп имгәнгәч, Рәхимнең әтисе күзләреннән яшьләр тәгәрәп төшә. Алмазияның әбисе исә, кешеләрдән табигать белән тупас мөгамәләсе турында ишеткәч, төннәр буе йоклый алмыйча борчылып чыга.

Рәхим көткән әр-яңа яшел поезд килә. Әмма аның көткәне булмый. Рәмзия апасы кайтмый. Бары тик поезд туктап торган арада, кешеләр урман аланын чүпләп, ризыклар һәм икмәк телемнәре чәчеп китәләр. Боларны күргәч, Рәхимнең тагын йөрәге сызлый...

«Миләш» дигән повесть яшүсмерләргә багышлана. Мул тормыш шартларында үскән Витя (аның әтисе заводта начальник, әнисе китапханәдә эшли) бозык юлга баса, үзенә җиңел кәсеп сайлый. Авыр тормыш шартларында үскән Илдарны да үз юлына тартырга тырыша. Илдарның әнисе генә эшли. Әтисе эчә, йомшак характерлы, үзен-үзе кулга ала алмый, эшкә керсә дә озак эшләми... Илдар һаман да алга омтыла, укырга — һөнәр алырга омтыла. Авыр шартларда үскән Асия аны чын иптәш итеп таный:

— Синең белән мин ялгыз түгел,— дип куана.

Әнә шулай «Миләш» дигән повесть яшүсмерләрнең ничек итеп ялгыш юлга кереп китүләрен, яки ул юлга ничек итеп керми калу мөмкинлеге булуны да ачыклый. Яшьләрнең остазы Эльбрус Хакович та үз шәкертләрен: «Әле ялгышлык белән брак детальләр китүе мөмкин, тик кеше үзе брак булмасын»,— дип кисәтә.

Кызганычка каршы, бездә «брак» малайлар-кызлар да очрап куя шул... Повесть менә шул мәсьәләләрне күтәрә. Яшьләрне дөрес итеп тәрбияләү проблемасы куела анда.

Өченче повесть — «Иртәгә дә яшисе бар» — КамАЗ тормышына багышланган. Анда да бүгенге кызыклы чынбарлык тасвирлана.

Кыскасы, язучы Рәшит Бәшәрнең балалар өчен дигән иҗади хезмәтенә тагын да зур уңышлар теләп каласы килә.

**Заһирә ГОМӘРОВА.**

## ТАТАРСТАН ТАРИХЫНДА БЕРЕНЧЕ ТАПКЫР

6 август. Казанда, Кремльдә, Татарстан республикасы Президенты М. Ш. Шәймиев рәислегендә Татарстан ССР Президенты Советының беренче утырышы булды. Анда республика дәүләт тормышына кагылышлы мөһим мәсьәләләр каралды.

«Татарстан ССР төзелү турында» белдерү белән ТССР премьер-министрының беренче урынбасары М. Х. Хәсәнов чыгыш ясады. Узган ел Татарстанның дәүләт суверенитеты турында Декларация * кабул ителүгә бер ел тулуга бәйле рәвештә Президент Советы 30 августны — Татарстан ССР төзелү көнен республика күләмендә ял көне дип игълан итте. Татарстанда яшәүчеләрнең дуслык һәм шатлык бәйрәменә әверелгән бу көн республика башкаласында, шәһәр һәм авылларында зур тантана төсендә үтәчәк.

Утырышта шулай ук суверен дәүләтләр — Башкортстан белән Татарстан республикалары арасында дуслык һәм хезмәттәшлек турында Килешү проекты каралды. Пенсионерларга, инвалидларга, ярдәмгә мохтаҗ ялгыз гражданнарга һәм балаларга гуманитар ярдәмне көчәйтү максатыннан, Президент Советы гражданнарның шушы категорияләренә социаль ярдәм буенча өстәмә чаралар турында Указ проектын тикшерде һәм хуплады.

Премьер-министр М. Г. Сабиров белдерүе буенча, мөлкәт хокуклары турында Президент Указы проекты каралды, анда республика территориясендә урнашып та, моңа кадәр Союз һәм Россия буйсынуындагы булган барлык предприятиеләр һәм оешмалар Татарстан ССР милке дип игълан ителә.

## ТӨРКИЯДӘ — ТАТАРСТАН ДЕЛЕГАЦИЯСЕ

Мөстәкыйль Татарстанның чит илләр белән элемтәләре һаман саен киңәя бара.

Июль ахырында «Дегерә» фирмасы чакыруы буенча, ТССР премьер-министрының беренче урынбасары М. Х. Хәсәнов җитәкчелегендә Татарстанның хөкүмәт делегациясе Төркия республикасында рәсми визит белән булды. Делегация составында, республиканың җаваплы әһелләре белән бергә, язучылардан — «Казан утлары» журналының баш мөхәррире Р. Г. Фәйзуллин, Казан дәүләт университеты проректоры профессор М. А. Госманов һәм М. Г. Маликова бар иде. Визитның максаты — фән, белем, мәдәният, сәламәтлек саклау һәм матбугат өлкәсендә үзара элемтәләр урнаштыру.

Очрашу барышындагы килешүләр Татарстан белән Төркия арасындагы икътисади һәм мәдәни бәйләнешләрне яңарту һәм ныгыту эшенә хезмәт итәчәк.

## ... ҺӘМ ТАТАР АРТИСТЛАРЫ

Республикабызның Дәүләт җыр һәм бию ансамбле дә күптән түгел Төркиядә булды һәм төрки халыкларның Әнкарада үткәрелгән халыкара сәнгать фестивалендә катнашты.

Ансамбльнең 37 кешелек коллективыннан тыш, Татарстанның Әнкарадагы «сабантуе»нда Г. Тукай исемендәге Татар дәүләт филармониясенең «Болгар» группасы, М. Җәлил исемендәге Татар дәүләт академия опера һәм балет театры җырчылары да чыгыш ясады. Фестиваль бәйгесендә Казахстан, Үзбәкстан, Азәрбайҗанның сәнгать вәкилләре дә осталыкларын күрсәттеләр. Татарстаннан килгән кунаклар сынатмады. Аерым алганда, җыр һәм бию ансамбленең илебезнең төрле төбәкләрендә яшәүче татарлар хәятыннан борынгы һәм беренче фольклор-этнографик композиция программасы хуҗаларның аерым игътибарына лаек булды.

## БАРЛЫК ТАТАРГА МИЛЛИ МАТБУГАТ

28 июньдә СССРның матбугат эшләре Дәүләт комитетында «Казан утлары» журналын теркәү булды. Нәтиҗәдә, журнал илебездә һәм чит илләрдә яшәүче күп санлы татарлар өчен чыгучы бөтенсоюз басмага хокук алды. Шундый ук статус «Татарстан», «Сөембикә» һәм «Мәгариф» журналларына да бирелде. «Казан утлары» шикелле үк, алар да «Газета һәм журналларның Бөтенсоюз каталогы»на кертеләр.

Географик чикләрнең бик тә шартлы һәм гаделсез бүленеше нәтиҗәсендә Татарстаннан читтә яшәүче милләттәшләребез ничек яшиләр, тел, мәдәният һәм милли гореф-гадәтләрне алар ни дәрәҗәдә саклыйлар? Казанда чыгучы әлеге журналлар менә шушы һәм тагын бик күп кенә сорауларга җавап табуда дус, киңәшче, ярдәмче булып тора. Казахстан, Үзбәкстан, Таҗикстан, Кыргызстан һәм Украинада татарлар аеруча күп яши. РСФСР территориясендә дә милләттәшләребез тупланып яшәгән төбәкләр бихисап. Аларның саны якынча 6 миллионлап исәпләнә.

Милли матбугатка ил күләмендә юллар ачык, кардәшләр!

## «ВАТАН» ВАТАНДАШЛАРНЫ ТУПЛЫЙ

«Ватан» җәмгыятенең чит илләр белән мәдәни бәйләнешләр советы утырышы булды. Анда җәмгыятьнең бер еллык эшчәнлегенә йомгак ясалды. Нәтиҗәләр куанырлык: Төркия, Германия, Япония, АКШ, Финляндия, Австралия, Кытай, Швеция, Польша, Румыниядә яшәүче байтак кына милләттәшләр белән яхшы элемтә урнаштырылган.

Якынча исәпләүләр буенча Җир шарының төрле илләрендә 100 меңләп татар яши. Әйтергә кирәк, әле кайбер илләрдә моның саны төгәл ачыкланмаган. Шуңа күрә «Ватан» оешмасы, шушы юнәлештә мәгълүматлар сорап, төрле дәүләт илчелекләренә мөрәҗәгать итте.

Казанда Нәүрүз бәйрәме һәм мөселман кызлар арасында чибәрлек конкурсы уздыруда да «Ватан»ның катнашы зур булды. Чит илләрдәге ватандашлар белән мәдәни генә түгел, эшлекле бәйләнешләр да юлга салынып килә. Әйтик, «Ватан» шулай ук җөмһүриятебездә уртак предприятиеләр төзүдә катнашырга теләге булган татар эшмәкәрләре белән элемтә урнаштырды.

Утырышта мәдәният, икътисад, сәясәт, Татарстанда милли мөнәсәбәтләр буенча халыкара информация алмашу, чит илдәге татарларны тарихи ватаннарына кайтару мәсьәләләре дә каралды. Совет җәмгыять Уставына кайбер үзгәрешләр кертте, социаль тармаклар буенча комиссияләр составын раслады.

## ТАГЫН БЕР ЯҢА ЖУРНАЛ

Быелның 1 августыннан киләсе ел өчен газета-журналларга язылу башланды. Яңалык: киләсе ел өчен айлык фәнни-популяр һәм әдәби-нәфис журнал — «Мирас»ка да язылырга мөмкин. Ул татар телендә чыгачак. Журналның төп максаты һәм бурычы — татар халкына әдәби-эстетик, фәнни-фәлсәфи һәм тарихи-мәдәни мирасны кайтару һәм әдипләребезнең «онытылу»га дучар ителгән әсәрләрен, шулай ук чит илләрдәге татар мәдәни мирасын дөньяга чыгару, халыкның рухи ихтыяҗларын тулырак канәгатьләндерү.

«Мирас» киң катлам укучыларга адреслана.

## ӘЙТ СҮЗЕҢНЕ, ЯШЬЛЕК!

Июль азагында «Идел» халыкара лагеренда Бөтендөнья татар яшьләре көннәре узды. Аның бер атналык программасы вакыйгалар һәм очрашуларга гаять бай иде.

Яшьләр, Шәһре Болгарга сәяхәт ясап кайтканнан соң, Казан мәчетләрен төзекләндерү өмәләрендә катнаштылар. Кабан арты мәчетендә яшьләр аеруча тырышып эшләделәр һәм моның үзенә күрә мәгънәсе бар иде. Биредә 1926 елда беренче тапкыр азан әйтелгәннән соң, мәчетне тартып алып, төрле хуҗалык оешмаларына биргәннәр, хәтта ресторан ясарга да җыенганнар...

Өмә тәмамлану белән мәчет манарасыннан икенче тапкыр азан яңгырый. Тиздән монда мәдрәсә ачылачак.

## ИСЕМЕҢӘ ЛАЕК!

Татарстан Совет Социалистик Республикасы Президенты Указы белән совет әдәбияты өлкәсендәге хезмәтләре өчен Әлмәттә яшәп иҗат итүче шагыйрь Гамил Афзалга «Татарстан ССРның халык шагыйре» дигән мактаулы исем бирелде.

# АЛТЫН КИРПЕЧ

Тышлыкның беренче битендәге рәсемне редакциябезгә тарих фәннәре кандидаты, В. И. Ульянов-Ленин исемендәге Казан дәүләт университеты укытучысы, археолог Әзһәр Мөхәммәдиев алып килде. Ул менә күп еллар инде университетта белем алучы яшьләр белән борынгы Алтын Урда һәм Казан ханлыгына кергән шәһәр урыннарында казыну-тикшеренү эшләре алып бара. Журналыбызның алдагы саннарында сез, хөрмәтле укучылар, бу экспедицияләр вакытында табылган тарихи истәлекләрнең кайберләре белән таныштыгыз инде. Аларның һәркайсы бабаларыбызның югары зәвыклы сәнгатькә, зәргәрлек, һөнәрчелек осталыгына һәм бу өлкәдә гаять дәрәҗәдә камиллеккә ирешүе турында сөйли. Көнкүрештә кулланылган балчык, бакыр һәм көмеш савыт-саба, тормыш кирәк-яракларына, һөнәрчелек әйберләренә — барысына да моннан йөзләрчә еллар элек яшәгән кешеләрнең йөрәк җылысы сеңгән. Алар әле бүген дә күңелләребезгә әнә шул шифалы җылының тәэсирен өретәләр кебек.

Кызганыч, ваграк әйберләрне туган җиребез үз кочагына алып, киләчәк буыннар өчен саклап калдыра алса да, ул заман сәяхәтчеләрен сокландырган, явыз баскынчыларның күзен кыздырган мәһабәт шәһәрләр, гүзәл корылмалар безнең көннәргә килеп җитә алмаган. Халкыбызның аяныч язмышы шаһитлары буларак, алар үзләре дә янып көлгә әйләнгәннәр, исән калганнары исә баскынчылар тарафыннан кирпече кирпечкә таркатылган, соңрак дәвердә аларны, хәтта кабер ташларын, йорт нигезләренә салганнар, дуңгыз абзарлары төзегәннәр.

Инде безгә ул йортларның матурлыгын, гүзәллеген берәмләп, бөртекләп җыелган таш һәм кирпеч кыйпылчыкларыннан күзалларга гына калды. Рәсемдә әнә шундый ядкарьләрнең берсе — яндырып эшләнгән һәм ялтыравыклы зәңгәр глазурь өстенә алтын йөгертеп бизәк төшерелгән кирпеч кыйпылчыгы. Тарихи чыганаклардан күренгәнчә, Казан патшалыгындагы бай йортлар — хан сарае, мәчет-мәдрәсә биналары, бәкләр-морзаларның ташпулатлары әнә шундый кирпеч белән тышлана торган булган.

Урыс явы белән килгән гаскәр җитәкчеләренең берсе — кенәз Курбский — Явыз Иванның һәм башка сәргаскәрләрнең, Казанны беренче тапкыр күргәч, экияти гүзәллектән телсез калуларын язып калдырган. Шундый ук мәгълүматларны Казан ханлыгында егерме ел яшәгән, ислам динен кабул иткән һәм мәмләкәт тар-мар ителгәч, яңадан христианлыкка күчеп, Явыз Иванның мәрхәмәтен алган билгесез урыс авторы иҗат иткән «Казан патшалыгы турында риваять»тән дә табарга мөмкин.

**Флүс ЛАТЫЙФИ.**

**Тышлыкның дүртенче битендә:** Татарстан җөмһүриятенең Г. Тукай исемендәге Дәүләт бүләге иясе, танылган шагыйрь Марс Шабаев.

**Дмитрий БУНТУКОВ** фотосы.

# Укучыларыбыз игътибарына!

Алдагы еллар тәҗрибәсен һәм күп санлы укучыларыбызның теләген искә алып, журналга язылуны җиңеләйтү максатыннан, бу санда 1992 ел өчен әзер квитанция тәкъдим итәбез. «Казан утлары»н алдырырга теләүчеләр, квитанциягә үзенең тулы адресын язып, исем-фамилиясен күрсәтеп, аны өзек сызык буенча кисә һәм элемтә бүлегенә тапшыра ала.

Исегезгә төшерәбез: «Казан утлары» — унике томнан торган еллык китапханә ул. Анда хәзерге татар әдәбиятының иң яхшы әсәрләре, заманыбызның үткен мәсьәләләрен күтәргән язмалар, аянычлы һәм бай үткәнебезне яктырткан мәкаләләр урнаштырыла. Журналга ярты елга да, өч айга да язылырга мөмкин. Ләкин, алда әйткәннәрне истә тотып, татар халкының рухи дөньясын эзлекле күзәтеп-танышып бару өчен, аңа алдан ук бер елга язылып кую хәерлерәк.

Сезгә уңышлар теләп —
редакция хезмәткәрләре.

Ф. СП-1

Министерство связи СССР
„Союзпечать"

АБОНЕМЕНТ на журнал 73210 (индекс издания)

"Казан утлары"
(наименование издания)

Количество комплектов: I

на 1992 год по месяцам:

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| X | X | X | X | X | X | X | X | X | X | X | X |

Куда
(почтовый индекс) (адрес)

Кому
(фамилия, инициалы)

ДОСТАВОЧНАЯ КАРТОЧКА

ПВ место литер

на журнал 73210 (индекс издания)

"Казан утлары"
(наименование издания)

| Стоимость | подписки | ___ руб. ___ коп. | Количество комплектов: | I |
|---|---|---|---|---|
| | переадресовки | ___ руб. ___ коп. | | |

на 1992 год по месяцам:

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| X | X | X | X | X | X | X | X | X | X | X | X |

Куда
(почтовый индекс) (адрес)

Кому
(фамилия, инициалы)

# «КАЗАН УТЛАРЫ» — ИҢ ЯХШЫ БҮЛӘК!

Иң якын дустыңа, туганыңа яңа елга нәрсә бүләк итәргә?

Киңәшебез бар: **«Казан утлары» на бер еллык подписка** бүләк итегез!

**Бер еллык подписка** — ул бүгенге татар әдәбиятының иң яхшы әсәрләреннән төзелгән 12 томлык саллы китапханә дигән сүз.

**Бер еллык подписка** — кимендә дүрт-биш роман, алты-җиде повесть, хикәяләр, драма әсәрләре, шигырьләр һәм поэмалар, заманның үткен мәсьәләләрен күтәргән ялкынлы мәкаләләр.

**Бер еллык подписка** — күп акча туздырмыйча китапханә туплауның иң җиңел юлы.

Журналның бер саны нибары 1 сум 80 тиен. Китап бәясе исә кимендә 6—7 сум булачак. Оттырмагыз!

## ПРОВЕРЬТЕ ПРАВИЛЬНОСТЬ ОФОРМЛЕНИЯ АБОНЕМЕНТА!

**На абонементе должен быть проставлен оттиск кассовой машины.**

При оформлении подписки (переадресовки) без кассовой машины на абонементе проставляется оттиск календарного штемпеля отделения связи. В этом случае абонемент выдается подписчику с квитанцией об оплате стоимости подписки (переадресовки).

Для оформления подписки на газету или журнал, а также для переадресования издания бланк абонемента с доставочной карточкой заполняется подписчиком чернилами, разборчиво, без сокращений, в соответствии с условиями, изложенными в каталогах Союзпечати.

Заполнение месячных клеток при переадресовании издания, а также клетки «ПВ—МЕСТО» производится работниками предприятий связи и Союзпечати.

1988 г. Обл. тип., г. Кострома, зак. 983, тир. 141.150.000

# «КАЗАН УТЛАРЫ» 1992 ЕЛДА

Редакциябезнең киләсе ел хәзинәсендә халкыбызның үткәнен һәм бүгенгесен сурәтләгән, тормыштагы күп кенә сорауларга җавап табардай, кызыксынып укырдай роман һәм повестьлар байтак. Менә аларның кайберләре:

**Мөсәгыйть Хәбибуллин.** «Шайтан каласы». *Тарихи роман.*
**Ринат Мөхәммәдиев.** «Солтангалиев». *Роман.*
**Җәмит Рәхимов.** «Батырша». *Тарихи роман.*
**Айдар Хәлим.** «Өч аяклы ат». *Повесть.*
**Рәфкать Кәрами.** «Каргышлы юллар». *Роман.*
**Фәнис Яруллин.** «Рәнҗемәгез безгә, балакайлар». *Повесть.*

Безнең өчен язалар һәм әсәрләрен тәкъдим итәргә җыеналар: Гомәр Бәширов, Әмирхан Еники, Аяз Гыйләҗев, Мөхәммәт Мәһдиев, Гариф Ахунов, Рафаил Төхфәтуллин, Миргазиян Юныс һ. б.

Шигырь сөючеләргә исә киләсе елда танылган шагыйрьләрдән Гамил Афзал, Илдар Юзеев, Равил Фәйзуллин, Рәшит Әхмәтҗанов, Роберт Әхмәтҗанов, Зиннур Мансуров, Зөлфәт, Мөдәррис Әгъләмов, Газинур Моратов һәм башкаларның яңа шигырьләр бәйләме тәкъдим итeләчәк.

Публицистика сәхифәләрендә, әлбәттә, үзгәртеп кору заманының үткен проблемаларын күтәргән очерклар, түгәрәк өстәл янында сөйләшү материаллары урын алачак. Татарстанның дәүләт суверенитетын яклау, ныгыту һәм аны тормышка ашыруга үзеннән өлеш кертүне журнал иң җаваплы бурычларның берсе дип саный.

Мәдәни мирасыбызга да киң урын биреләчәк. Әдәбиятыбыз һәм сәнгатебез үсеше, тарихи үткәнебез, туган телебез һәм гореф-гадәтләребез язмышы, бөтен дөньяга сибелгән милләттәшләребез матди һәм иҗтимагый тормышы (Илбарис Надиров. Финляндия татарлары; Миркасыйм Госманов. Голҗа татарлары; Сәлих Апакай. Сан-Францискода татар җәмгыяте) халкыбызның киләчәге турында истәлекләр, тикшеренүләр дөнья күрәчәк, бу мәсьәләләр буенча кайнар фикер алышуларда галимнәребез, җәмәгать эшлеклеләребез, сәнгать белгечләребез, танылган каләм ияләребез катнашачак.

Татар әдипләренең Татарстанда, СССРда һәм чит илләрдә чыккан яңа китапларына күзәтү ясалачак. Журналыбызның соңгы битләрендә исә республикада, илдә, чит илләрдә халкыбыз тормышыннан яңалыкларны даими хәбәр итеп торачакбыз.

Укучыларыбыз үтенечен искә алып, гарәп һәм латин әлифбасы нигезедә язма үрнәкләр бирүне дәвам итәчәкбез. Шулай ук укучы хатларына да урын биреләчәк.

«Казан утлары» Бөтенсоюз басмасы буларак теркәлде, аның каталогтагы индексы — 73210. Аңа Советлар Союзының барлык элемтә бүлекләрендә һәм чит илләрдә чикләнмәгән күләмдә язылырга мөмкин. Бәясе — бер елга 21 сум 60 тиен.

Бәясе 1 сум 50 тиен. Индекс 73210



# КАЗАН УТЛАРЫ (ОГНИ КАЗАНИ)

Ежемесячный литературно-художественный и общественно-политический журнал (на татарском языке)

Журнал включен во Всесоюзный каталог